ISSN 0206-4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

9.2004





Габдерәхим Утыз Имәни Әл–Болгари
(1754 — 1834)

**Казан утлары**
**Qazan utları**

*2004*

# 9

**(983)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Идарә*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Фоат Галимуллин**
**Талгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Фаяз Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатиуллина, Ихтыяр Газизов, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** *(баш бухгалтер)*, **Эльвира Камалова.**

Адрес: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркатип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 92-93-16.
**Факс** — (8432) 43-56-12.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru

КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Габдерәхим УТЫЗ ИМӘНИ ӘЛ-БОЛГАРИ. Шигырь. .... 5
Марсель ГАЛИЕВ. Йөрәкленең йөрәгенә... Шигырьләр. .... 58
Мөсәгыйт ХӘБИБУЛЛИН. Айбиби. Роман. .... 63
Фирүзә ЖАМАЛЕТДИНОВА. Җәйге чеглә. Шигырьләр. .... 85
Нәҗибә ӘМИНЕВА. Яшисең... Шигырьләр. .... 88
Камил КӘРИМОВ. Куен җылысы. Хикәя. .... 90

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

Рабит БАТУЛЛА. Җимерелгән бәхет. Пьеса. .... 6

**ФӘН**

Солтан ШӘМСИ. Күк капусы ачылса... Тарихи-фәлсәфи бәян. .... 95
Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. .... 173

**ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА**

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Гыйбрәтләр алырлык үткән юл. *(Язучылар оешмасының 70 еллыгы уңаеннан кайбер күзәтүләр, хатирә-уйланулар)* .... 116

**ДИСКУССИЯ: "БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ"**

Рөстәм ЗАРИПОВ. Пегас кашына микән? .... 154
Реваль РАКОВ. Укыр җаннар бетмәсен! .... 158

**ХӘТЕР**

Миргазиз Укмасыйның тууына 120 ел. .... 161

Рәфкать КӘРАМИ. Иҗатташларым. .... 163
Руфина ФӘТТАХОВА. Бер әсәрнең басылу тарихы. .... 168

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ. Бәндәләр хатасы—бәндәгә сабак. .... 178

"Казан утлары" архивыннан. .... 182
Хатлардан юллар. .... 184

Әхмәт РӘШИТ. Җитмешкә җитәм дигәндә... .... 186

Котлыйбыз! (Шамил Рәкыйповка 75 яшь). .... 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. .... 189

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": роман М. ХАБИБУЛЛИНА "[illegible]" (окончание).
рассказ К. КАРИМОВА "Нечаянная нежность"; стихи Г. УТЫЗ-ИМАНИ АЛЬ-БУЛГАРИ, М. ГАЛИЕВА, Ф. ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ, Н. АМИНОВОЙ.
"Драматургия": пьеса Р. БАТУЛЛЫ "Разрушенное счастье".
"Наука": С. ШАМСИ. "Когда откроются Звездные Ворота";
А. ТИМЕРГАЛИН. "Словарь нации".
"К истории литературы": статья Р. ФАЙЗУЛЛИНА "Славный и поучительный путь" (к 70-летию Союза писателей Татарстана).
Дискуссия "Герой нашего времени": статьи Р. ЗАРИПОВА и Р. РАКОВА.
"Память": стихи М. Укмаси (к 120-летию поэта); Р. КАРАМИ. "Соратники по перу".
Р. ФАТТАХОВА. "История публикации одного романа".
"Книжное обозрение": Р. ШАРАФИЕВ рецензирует книгу Ф. САФИНА "Мнимый рассвет".
К 70-летию Р. Хисматуллина—статья А. РАШИТА.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: духовно-оздоровительный центр Ильдара ХАНОВА в п. Аракчино г. Казани; писатель-публицист М. ЗАРИПОВ.

# IN THIS ISSUE:

*This magazine edits monthly*

"Prose and poetry": Novel by M. KHABIBULLIN: "[illegible]"(Ending).
Story by K. KARIMOV "Unintentional tenderness"; verses by G. UTYZ-IMANI Al-BULGARI, M. GALIEV, F. ZAMALETDINOVA, N. AMINOVA.
"Dramatic art": Play by R. BATULLA «Destroyed happiness».
"Science": S. SHAMSI "When star gates open"; A. Timergalin "Vocabulary of the nation".
To the history of literature: Article by R. FAIZULLIN "Glorious and educational way" (to the 70th anniversary of the Union of writers of Tatarstan).
Discussion "Hero of our time": articles by R. ZARIPOV and R. RAKOV.
"Memory": to the 120th anniversary of M. UKMASI; article by R. KARAMI "Colleagues of writing".
R. FATTAKHOVA "Publication of one novel", "Books review": R. SHARAFIEV reviews the book by F. SAFIN "Imaginary rise".
To the 70th anniversary of R. KHISMATULLIN—Article by A. RASHIT.
From photo-archive of magazine.
Diary of public-cultural life.
On our covers: Ildar KHANOV'S spiritual-health improving centre in the settlement Arakchino, Kazan city; writer-publicist M. ZARIPOV.


• Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
• Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
• Басмаханә гаебе белән китап җитешсезлекләре өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алмаштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 19.08.2004 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 7025. Заказ Э—606.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2


© «Казан утлары», 2004 ел.

# Габдерәхим Утыз Имәни Әл-Болгари

## Шигырь

Тисә киңәш шәменнән нур кешегә,
Тулыр нур күңленең барлык төшенә.
Ерак торса киңәшләр бакчасыннан,
Урын алыр наданлык сәхрасыннан.
Гыйбрәтләр ярдәм итмәс ул чак аңар,
Өмет итсә дә йөз-мең яхшы хәбәр.
Укысаң да аңа Тәүрат һәм Инҗил,
Укып Коръән, шуны итсәң дә дәлил,
Пәйгамбәр сүзләрен торсаң кабатлап,
Арадан иң кирәк сүзләрне сайлап,
Сөйләп сүзләрнең иң кыйммәтлеләрен,
Өйрәтсәң дә гадәтен изгеләрнең,—
Колак салмас синең яхшы сүзеңә,
Сине хурлап, гаеп ташлар үзеңә;
Котырган эт кебек тешләр аягың,
Сугыйм дисәң, аңа җитмәс таягың.
Табылыр һәрчак аны яклаучылар,
Түгелер сүзең, гүя терек сулар.
Кадрең җуйма, кач син андый кешедән,
Үзеннән һәм күзеннән һәм эшеннән.
Киңәш тыңлаучыны тапсаң әгәр син,
Ишекләрен сүзеңнең ач аңар син.
Берәү тыңламаса киңәшне рәтләп,
Телең тешлә, авызың куй пичәтләп.

*Бүгенге әдәби телгә күчерүче—*
*Әхмәт Исхак.*



## Рабит Батулла

# ҖИМЕРЕЛГӘН БӘХЕТ

ИКЕ ПӘРДӘЛЕК ТАМАША

**Катнашалар:**

1. З а һ и д а   х а н ы м   Т и н ч у р и н а — Кәрим Тинчуринның тол хатыны, 90 яшьтә.
2. З а һ и д а   т у т а ш — Заһида ханымның яшь чагы, 15-16 яшьтә.
3. Ш а һ б а з г а р ә й   Ә х м ә р о в — 25 яшьтә, тантаналы бәйрәм киемендә.
4. Д и а н а   К у д р я в ц е в а — яшь кыз, алмаз муенсалар таккан, бәйрәм киемендә.
5. Х а д и ч ә   т у т а ш   А л к и н а — яшь кыз, татар зиннәтләре киемендә, калфаклы.
6. Х а д и ч ә   х а н ы м   Ә х м ә р о в а-А л к и н а — олы яшьтә чагы.
7. М ә һ и п ә р в а з — аның беренче кызы, мәһабәт ханым, табибә.
8. К а р а   Ш ә у л ә — һәр чыкканда үзгәреп торган вәсвәсәче, шомлы зат, бер чыкканда ул кара эчле кызыл бөркәнеч ябынган, икенчесендә кызыл эчле кара бөркәнечтән, өченчесендә кара эчле кара бөркәнечтән, дүртенчесендә кызыл эчле кызыл бөркәнечтән булыр.
9. С у ф и я — Хадичә ханымның икенче кызы, артистка, тулы-матур гүзәл ханым.
10. С а р а — Хадичә ханымның өченче кызы, хокукчы, соңра католик диненә күчкән гүзәлләр гүзәле.
11. И л ь я с — Хадичәнең олы улы, юнкер, патша армиясе офицеры.
12. Й о с ы ф — хәрби табиб, патша армиясе офицеры, мәһабәт ир.
13. Д а у т — хокукчы, мәһабәт ир, патша армиясе офицеры.
14. А с к ә р — Мәһипәрвазның улы, 15 яшьтә.
15. С е м б е р   б е к — тулы гәүдәле, затлы киенгән, чалбар, костюмы европейский, башында шоп каракүл бүрек.
16. А с к ә р   Ш ә е х - Г а л и — генерал улы, күп телләр белүче, аристократ.
17. Г а я з   И с х а к ы й — 35 яшьлек чагы, европача кәттә киенгән.

---

*Рабит БАТУЛЛА (1938) — прозаик, драматург; күпсанлы китаплар (балалар өчен повестьлар, хикәяләр, "Сөембикә", "[illegible]" романнары h.б.) авторы. Г. Исхакый премиясе лауреаты. Казанда яши.*

18. Н ә ф и с ә — генерал утарынын хуҗалык эшләре мөдире Гәрәй углы Низам Тактаевнын кызы, 16 яшьтә, чибәрләр чибәре.
19. Х а н и ф ә — Тактаевнын икенче кызы, 15 яшьтә, чибәрләр чибәре.
20. А т  к а р а у ч ы.
21. Г е н е р а л  Ш в е ц о в.
22. Д е н ь щ и к.
23. М ә р в ә р  х а н ы м.
24. Г а б д у л л а  К а р и е в.
25. К ә р и м  Т и н ч у р и н.
26. С л е д о в а т е л ь.
27. Ф а т ы й м а  И л ь с к а я.

Хатын-кызлар, гәҗит таратучы малайлар, солдатлар.

*Вакыйгада катнашучы татар хатын-кызларынын барысы да өч төрле киенергә мөмкин. Европача бай кием, татарча бай хатыннар киеме, европача киемнәргә бары тик кечкенә калфакчык каларга мөмкин. Ир-егетләрнен дә шулай киенүе зарури: алар европача кием өстенә затлы татар бүреге кия.*

## Беренче бүлек

**Китап шкафлары, китаплар. Савыт-саба шкафы. Борынгы кытай ташаягыннан эшләнгән табак-савыт. Савыт-сабаның яртысы кителгән, ватылган. Бер кырда язу өстәле, анда иске язу машинкасы. Диварларда кытай-япон миниатюралары. Икенче кырда чаршау белән капланган ятак. Таң ата. Кайдадыр музыка уйный, сәгать суга. Эңгер-меңгердә К а р а  Ш ә ү л ә күренә. Кара Шәүлә чаршауны селкетә.**

З а һ и д ә  х а н ы м *(чаршау артында).* Ә? Кем ул анда?

К а р а  Ш ә ү л ә. Мин әле бу, статский советник Шаһбазгәрәй Әхмәров кызы, Кәрим Тинчуриннын хатыны Заһидә ханым!

З а һ и д ә  х а н ы м *(чаршау артыннан чыга).* Ә-ә, сезмени әле бу һаман. Тагын ни кирәгем чыкты?

К а р а  Ш ә ү л ә. Монда сорауларны без бирәбез, Заһидә Тинчурина!— Сезнең эш җавап бирү!

З а һ и д ә  х а н ы м. Ничек туймыйсыз сез, шулай айлар, еллар буе кеше артын сагалап йөрүдән? Инде кешенең йортына кереп кенә калмыйсыз, кешенең түшәгенә дә кереп җәфалыйсыз.

К а р а  Ш ә ү л ә. Миннән тормый бит ул, Заһидә ханым.

З а һ и д ә  х а н ы м. Ә кемнән тора соң?

К а р а  Ш ә ү л ә. Сезнең үзегездән тора. Мин бит сезнең Кара Шәүләгез. Үзегезнен шәүләгез, ханым-әфәнде.

З а һ и д ә  х а н ы м. Юк, сез минем шәүләм түгел идегез. Сез иң башта атама тагылган Кара Шәүлә булып йөрдегез. Сез: Шаһбазгәрәй Әхмәров татар интеллигенциясен үстерергә тырышучы, татар зыялыларын бергә тупланырга чакыручы, дип донос язган Шәүлә. Купчырайлы, кара йөзле Шәүлә. Таныш Шәүлә. Атам вафатыннан соң сез Тукай артына куелган Шәүлә булдыгыз. Тукай вафатыннан соң сезне Такташ артына куйдылар. Такташтан соң Тинчуриннын Шәүләсенә әверелдегез. Аннан соң инде менә ничә ел сез мине эзәрлеклисез.

К а р а  Ш ә ү л ә. Атаннын, Тукайнын, Такташнын, Тинчуриннын Шәүләсе сезгә төшкәнгә мина рәхмәт укыгыз.

З а һ и д ә  х а н ы м. Рәхмәт инде.

К а р а  Ш ә ү л ә. Ә сез көлмәгез, Заһидә ханым. Мин ихлас сөйлим. Мин бит сезнең язмышыгыз.

З а һ и д ә  х а н ы м. Кара язмышым.

К а р а  Ш ә ү л ә. Язмыштан узмыш юк.

З а һ и д ә  х а н ы м. Мин Газраилне көтеп ятам, сез килеп керәсез. Чират юк, итагать юк. Өемдә тентү ясадыгыз, таладыгыз, инде хәзер үләргә яткан карчыкның җанына тентү ясарсызмы?

К а р а  Ш ә ү л ә. Куаныгыз сез, Заһидәкәй, Газраилдән алдан мин килгәнмен икән, димәк, әле сез озак яшәрсез.

З а һ и д ә х а н ы м. Минем яшисем килми инде. Мин күргәннәрне күрергә дошманына язмасын. Кемгә тидек, кемне рәнҗеттек без, кемнәр безне шулай каргады? Нигә кирәк булды бу корбаннар? Һич мәгънәсез корбаннар... Максим Горькийга ачуым килә башлады минем. "Человек—это звучит гордо!" Кеше дигән исем мәгърур янгырый!—имеш. Чүп ул кеше, бер дә горур яңгырамый. Мескен ул бәндә, яраклаша, гаделсезлеккә каршы сүз әйтмичә яраклаша белә. Мин үзем дә шундыйлардан булып чыктым...

К а р а Ш ә ү л ә. Нигә әле сез, гомер буе Горькийны мактаган әдәбият укытучысы, бүген генә аны тәнкыйтьлисез? Классикага тел тидерәсез!

З а һ и д ә х а н ы м. Мин үземне горур, көчле шәхес дип уйлый идем. Мин дә чүп булып чыктым. Гаделсезлеккә каршы чыга алмагач, үземә үзем кул сала алмыйча гажиз булдым. Пычак белән менә шушы тамырга гына сызып җибәрәсе дә—вәссәләм! Йокы даруын учлап йотасы да—беттен-киттен. Бау саласын да—шушы нәжес дөньядан китәсен дә барасын. Кара Шәүләм юкка чыгар иде, ичмасам.

К а р а Ш ә ү л ә. Без эшсез тормабыз, анысы. Даһи вафат булса, исән даһилар кала тора безнең бәхеткә. Ләкин әле синең янда эш төкәнмәгән, ханымәфәнде.

З а һ и д ә х а н ы м. Куркытма, минем синнән курка торган күлмәкләрем әллә кайчан тузып беткән инде.

К а р а Ш ә ү л ә. Рәхмәт укы миңа, Заһидә ханым. Мин булмасам, синең картлык көннәреңне кем бизәр иде, ә? Синең беркемең юк, булганнары да синең ишегеңне ачып карамый. Ярый әле мин бар, хәлеңне белешеп торырга.

З а һ и д ә х а н ы м. Шулай да әйт әле, Шәүлә, ни калган сиңа минем янда? Аласын алдыгыз, бирәсен дә бирдегез, ничек кенә мыскылламадыгыз сез мине. Бүген ни йомышын калган монда? Менә хикмәт!

К а р а Ш ә ү л ә *(усал)*. Хикмәт шул, гражданка Тинчурина-Әхмәрова! (Заһидә ханым сискәнеп китә.) "Хикмәтле доклад" пьесасын безнең работниклардан сез яшереп калдырдыгызмы?

З а һ и д ә х а н ы м. Бу мәгълүм бит инде.

К а р а Ш ә ү л ә. Туры җавап бирегез, гражданка.

З а һ и д ә х а н ы м. Әйе, мин сакладым ул пьесаны. Ләкин мин аны яшереп алып калмадым. Тентү ясаучылар ашыктылар, ахрысы, кульъязмаларның барысын да алмадылар. "Хикмәтле доклад" исән калган.

К а р а Ш ә ү л ә. Димәк, сез сөеклебез Сталинны хурлый торган әсәрне саклагансыз.

З а һ и д ә х а н ы м. Ул әсәрдә Сталин исеме юк. Мортазадан көлә Тинчурин.

К а р а Ш ә ү л ә. Хәйләкәр сез, Заһидә ханым-әфәнде. Мортазаны бәреп төшергәннән соң тагын икенче Мортаза килә. Һәм ул анда, финалда кычкыра:—Системаны үзгәртергә кирәк! ди. Ирегез Кәрим Алиевич Тинчурин совет системасын үзгәртергә хыяллана идемени?

З а һ и д ә х а н ы м. Сезгә язучы гына буласы калган, сездәге фантазия, йөз илле татар язучысына бүлеп бирсәң дә артып калыр иде *(Көлә.)* Анда Мортазаны бәрәү дә алыштырмый, пьесада андый сүзләр юк. Сез бит спектакль турында сораштырасыз. Ә спектакль һәм андагы өстәмәләр өчен драматург түгел, режиссер җавап бирсен...

К а р а Ш ә ү л ә. Ә кем иде спектакльнең режиссеры? Кем ул контра?.. Дәшмисез!.. Нәрсә ялганларсыз икән, гражданка Тенчурина-Ахмерова! Аның кем икәнен хәтерләмим, белмим, дип әйтерсез инде, шулаймы?

З а һ и д ә х а н ы м. Хәтерлим! Ничек хәтерләмисең инде андый талант иясен? Исемен дә атый алам!

К а р а Ш ә ү л ә. Кем? Кем ул контра?

З а һ и д ә х а н ы м. Мохтар Мутин!

К а р а Ш ә ү л ә. Ашыйм мин аны! Атам мин аны! Контра-а! Кайда ул?

З а һ и д ә х а н ы м. Мутин күптән гүр иясе булды инде! Аны сез этләрдән талатып үтердегез! Сез совет этләреннән талаттыгыз бөек актерны, режиссерны—Мутинны!

К а р а Ш ә ү л ә. Гражданка Тинчурина! Советлар властен этләр белән тиңләштергәнегез өчен под суд!

З а һ и д ә х а н ы м. Мин ялгыш сүз әйттеммени?

К а р а Ш ә ү л ә. Ялгыш түгел! Контр сүз әйттегез! Сез совет чекистларын этләргә тиңлисез!

З а һ и д ә х а н ы м. Мин "чекистлар—совет этләре" димәдем. Мутинны совет этләреннән талатып үтердегез,

дидем. Ул этләр чекистлар кулында тәрбияләнгән этләр, шулаймы? Юк, сез җавап бирегез, шулаймы?.. Шулай булгач, алар чекистларга, советларга ярдәм итәргә өйрәтелгән этләр, ягъни совет этләре булып чыга.

Кара Шәүлә. Алар немецкий овчаркалар иде! Алар урыс-совет овчаркалары түгел иде.

Заһидә ханым. Немец овчаркасымы, урыснныкымы, алар барыбер совет КГБсына хезмәт итә!

Кара Шәүлә *(кыңгырауга баса, кыңгырау зыңгылдый). Алыгыз! (Заһидә ханымны чаршау эченә төртеп кертә.)* Ялгыз карцерга!

**Шәүлә китә. Ишек кыңгыравы тагын зыңгылдый... Кыңгырау тагын да таләпчәнрәк зыңгылдый. Чаршау дулкынлана. Чаршаудан Заһидә ханым килеп чыга.**

Заһидә ханым. Фу, әстәгъфирулла. Тагын саташып беттем... *(Кыңгырау тавышы).* Хә-әзер... хәзер... Кайсы рәхмәт төшкере шулай каты баса кыңгырауга? Мине саңгырау дип уйлыйлармы? Халатымны кияргә дә ирек бирмиләр... аты коргырлары... *(Ханым башмакларын элеп, ашыга-пошыга йөреп, ишек янындагы эшермә артына кереп китә.)* Кто там? Ә-ә, сезмени әле бу! Һо-о, чәчәкләр! Рәхмәт. Узыгыз, түрдән узыгыз, язучы әфәнде!.. *(Бераздан кулына чәчәк бәйләме тоткан Заһидә ханым күренә.)* Кемгә кирәгем бар, кем борчый шулай, тынычлап үләргә дә ирек бирмиләр, дисәм, сез икән, утырыгыз!.. *(Күренми торган кунакны утырта, чәчәкләр бәйләмен савытка куя.)* Ни сөйлим соң мин сезгә, иптәш язучы? Хәтерем дә начарая башлады инде... Сезне ни кызыксындыра? Тинчурин? Тинчурин белән танышканчы әле мин Шаһбазгәрәй Әхмәров кызы Заһидә туташ булып яшәдем, егерме бер ел аз гомер түгел. Шуңа күрә, мин сезгә үз тормышым турында сөйләрмен. Аның беренче өлеше Шаһбазгәрәй Әхмәровның гаиләсе турында булыр, икенчесе Кәрим Тинчурин белән булган гомеремне үз эченә алыр. Зинһар, сез сораулар биреп, мине бүлдермәгез, юкса мин җеп очымны югалтам. Туксан яшьлек карчыкның хәтере дә үзе сымак кына инде аның. Килештекме? Башладык! Бисмиллаһ ир-раһмән ир-рахим...

**Заһидә ханым язучы каршысындагы өстәлгә фотосурәтләр китереп куя.**

Заһидә ханым. Сез татар сүзлекләреннән, татар тарихыннан карап белерсез: кем ул татар арасыннан иң беренчеләрдән булып, университет тәмамлаган һәм генералга тиң "Статский советник" дәрәҗәсе алган Исмәгыйль углы Шаһбазгәрәй Әхмәров? *(Заһидә ханым яшәреп киткәндәй төзәя, мәгърур кыяфәт ала, ул үзенең шәҗәрәсе белән нык горур.)* "За безупречную и верную службу Российскому государству в области народного образования" диелгән патшаның указында. Шаһбазгәрәй! Аның исеме генә дә ни тора! Шаһбазгәрәй Әхмәров! Потомственный аксөяк! Алтын Урдадан ук килә торган морза Әхмәр токымы. Сембер ягыннан була минем атам. Нәсел кырылып бетә. Сукыр анасы белән генә кала Шаһбазгәрәй мырза. Әбием Сембердә сукыр килеш, япа-ялгыз яшәп тә, нәселдән килгән яшерен хәзинәне бәрәкәтле итеп, углы Шаһбазгәрәйне Казанга җибәреп укыта, кеше итә. 1853 елда туган атам Шаһбазгәрәй морза 1878 елда Казанда Императорский университетны алтын медальгә тәмамлый. Аны урыс-татар мәктәбенә вәкил итеп куялар. Кечкенә булса да, бик һәйбәт фатир бирәләр аңа. Ул сукыр әнисен үз янына алдыра. Хәзер инде өйләнәсе генә кала. Сукыр ананы, коллежский инспекторны карап торырга яхшы хатын кирәк. Борынгы татар йолаларында тәрбия алган анасы урыс арасында күп чуалган углы Шаһбазгәрәйнең высший свет маржа дамалары арасында шактый уңыш казанганын белеп, шарт куя: улым Шаһбазгәрәй, Алтын Урдадан килә торган саф канлы бәкләр нәселен бозма, зинһар. Үзебезнең токым арасыннан сайла килеңне, ди.

Мин уйлыймын: атам—Шаһбазгәрәй мырза аналитик акылга ия булган кешедер, дим. Ул университет тирәсендәге югары даирәле аксөякләренең кызлары арасыннан берәүсенә гашыйк та була. *(Ханым язучы алдындагы рәсемне ача.)*

**Бию музыкасы яңгырый. Заһидә ханымның хыялында атасы Шаһбазгәрәй белән биюче гүзәл кыз җанлана. Алар вальс бии, текст дәвамында мазуркамы, тагын шундый классик бию башкаралар.**

**Заһидә ханым тамашачы буларак, аларны бер кырыйда карап утыра. Биючеләр тирәсендә Кара Шәүлә бөтерелә.**

Заһидә Тинчурина. Новый клубта, Университет залларындагы бәйрәмнәрдә, губернатор сараендагы балларда Шаһбазгәрәй беренче номерлы биюче. Вальс, мазурка, краковьяк биергә дамалар аны ангажировать итә торган булалар. Урыс аксөяк гаиләләре үсеп килүче Шаһбазгәрәйне кияүлеккә кандидат итеп күрә башлыйлар. Ләкин Шаһбазгәрәй морза бары тик бер кызны—тайный советник Кудрявцев кызы мадемуазель Диананы гына сөя. Шул кызга өйләнә калса, тизрәк үсәсен дә, тизрәк байыйсын белә Шаһбазгәрәй, ләкин чикләрне узмый.

**Биюдән соң Шаһбазгәрәй кызны озатып куя. Аның янына Кара Шәүлә килә.**

Кара Шәүлә. Гаҗәеп шәп!

Шаһбазгәрәй. Нәрсә шәп? Вальсмы? Әлбәттә—Штраус!

Кара Шәүлә. Штраус шәп, Штраустан да шәбе - мадемуазель Диана. Сез, Шаһбазгирей Измаилович, Диана Филимоновна белән искиткеч пар. Чын күңелемнән әйтәмен, ей Богу, сез каратут йөзле, шәрык тибындагы джентельмен, Диана мәхәббәт алиһәседәй гүзәл, наз илә, нәфислек илә тум-тулы йөзле, аксыл чәчле, зәп-зәнгәр күзле кыз. Ә нәселе? *(Як-ягына карангалап.)* Тайный советник кызы!

Шаһбазгәрәй. Әфәндем! Кояшны: бу—Кояш дип исбатларга тырышуда ни файда?

Кара Шәүлә. Шаһбазгирей Измайлович, гүзәллек турында ишеттереп хыяллану гөнаһмыни?

Шаһбазгәрәй. Татлы сүзләрегезне әрәм итмәгез, зинһар.

Кара Шәүлә. Әфәндем, сезнең тиздән түгеләз була, дигән сүзләр йөри.

Шаһбазгәрәй. Астрономнар әйтә: тиздән Койрыклы йолдыз—Галлей килә, ди. Озакламый дөнья бетә, дип сөйлиләр.

Кара Шәүлә. Европа белеме алган татарның башы-теле урысныкына караганда яхшырак эшли.

Шаһбазгәрәй. Мактавыгыз өчен күптин күп, чуктин чук рәхмәтләр. Мерси, мосье!

Кара Шәүлә. Чынлап әйтәм. Багыгыз сез урыс халкының башында торучыларга. Пушкинның остазы Державин—татар, урыс тарихының башында торган Карамзин—татар, "Слово о полку Игореве"ны саклап калган һәм эшкәрткән кеше, Мусин-Пушкин—татар, Аксаковларның остазлары татар. Татарга урыс каны катнаштырсаң, гел даһилар гына чыга. Бу—бәхәссез мәсьәлә. Шуңа күрә, сез—татарлар киләчәк буыныгыз даһи булсын, дисәгез, маржага өйләнегез, кызларыгызны урыска кияүгә бирегез. Мин даһимы? Даһи! Чөнки мин урыслашкан татар. Ха-ха-ха... Сез-татарлар Иван Грозныйга никадәр нәфрәтле булсагыз да, анда да татар каны бар, татар тиклем татарны аяк астына салган икән—димәк, Иван Грозный даһи, ха-ха-ха... Сүз иярә сүз чыккач әйтим әле, Шаһбазгирей Измаилович, сез бая Койрыклы йолдыз—Галлей якынлаша, дидегез. Сез университетны алтын медальгә бетергән акыллы, укымышлы кеше буларак, беләсез: чыннан да, Галлей кометасы 1909 елда киләчәк. Аңа әле вакыт бар, шөкер. Утыз ел вакыт бар. Аңа чаклы без әле яшибез, ей Богу. Иван Грозный ничәнче елда туа әле? 1530 елда туа сөекле Иваныбыз. Шәрыкъның сөеклесе Бабур солтаны кайчан үлә әле? 1530 елда үлә бөек Бабур солтан. Шул елны Галлей Койрыклы йолдызы уза җир шарына тияртимәс кенә. Бабур вафатыннан соң мөселман илләре көчсезләнде. Мәсәлән, 1552 елда Казан ханлыгын Мәскәү пыр туздырып ташлады. Иван Грозныйдан соң Русия куәтләнде. Койрыклы йолдыз да, Ходай да безгә—Русиягә хезмәт итә. Килсен Койрыклы йолдыз! Ул шәрекънең бетүенә, Русиянең мантуына китерәчәк. Бу—Хакыйкать, әфәндем. Бәс, Дианага өйләнү сезнең тәкъдирегез.

Шаһбазгәрәй. Сездән менә дигән яучы чыгар иде. Татар белән урыс катнашыннан килгән куәтегезне юккабарга сарыф итәсез.

Кара Шәүлә. Аңламассың сезне, ей-Богу. Шаһбазгирей Измаилович, күпме дворяннар Диананың кулын үбәргә хыяллана, күпме офицерлар Диананы төшләрендә күрә, сезгә шундый илаһи бәхет ишелеп килгәндә... Сез, әлбәттә, шәрык кешесе, Диана ул саф христианка. Бәла түгел, яки мадемуазель Диана исламны кабул итә дә, сезгә кәләш була. Яки... сез христианлыкны кабул итәсез. Юкса, бер як та: ни поп, ни мулла ике

диндәге кешене кушмаячак...

Ш а һ б а з г ә р ә й. Мин өченче юлны сайлармын, ихтимал.

К а р а Ш ә ү л ә. Шурлэдегез, Шаһбазгирей Измаилович, шундый гүзәллекне, шундый байлыкны кулда тота алмам, дип курыктыгыз?

**Биючеләр тарала.**

З а һ и д ә х а н ы м. Атам гүзәл кызга артык якынаймый. Буйдак килеш кала бирә. Чөнки анын уе мөселман кызына өйләнү, мөселман гаиләсе кору, борынгы затлы нәселгә чит-ят кан катнаштырмыйча, мөселман буларак, токымны дәвам итү була. Тора-бара мадемуазель Диана да өметен өзә: аны башкага кияүгә бирәләр, ул ире белән Петербургка бөтенләйгә китеп бара. Шаһбазгәрәй хәйлә табып, сөеклесен озатырга вокзалга да төшми. Атам хис кешесе булудан битәр, акыл-зиһният кешесе булган. Ул Дианага булган хисләрен кысып, акыл белән уй йөртә: аерылгач, аерылырга кирәк, ничу сентиментальничать итеп, вокзалларга төшеп, елаша-елаша аерылу трагедиясе уйнарга. Китә бирсен, Диананын үз язмышы, үз юлы. Шаһбазгәрәйнен үз язмышы, үз юлы. Атам ир булып өлгергән чакта Казан мохитендә, татар зыялылары арасында "Милләт", "Милләтче", "Милләтпәрвәр" кебек сүзләр бик йөрештә иде. Химаячылардан, иганәчеләрдән акча сораганда да хәйрия җәмгыяте кешеләре һәрвакыт: "милләт өчен", дип әйтә торганнар иде.

Мин атама күнелемдә чиксез мәхәббәт тәрбия кылган кеше. Атам Шаһбазгәрәй хисләрен, мәхәббәтен авызлыклардай куәтле рухка ия шәхес. Бурычны, вазифаны хиссияттән, мәхәббәттән алга куйган кодрәт иясе. Андый кодрәт теләсә кайсы иргә дә тәтеми ул. Ихтимал, мин атама охшаганмындыр.

Нәрсә ул мәхәббәт? Әйттем исә кайттым, философлар, шагыйрьләр, психологлар гасырлар буе баш ватканнар, ләкин барыбер тулысы белән анлата алмаганнар. Атамнын язмаларын, хатларын укып, мин шаккатам, ул да философ, ул да психолог булган икән. Кайбер ирләр хатын-кызга кыска вакытлы ләззәт өчен яралтылган җан иясе һәм бала табар өчен яралтылган әсбап итеп кенә карыйлар. Фән дә, философия дә хатын-кызга түбән катлау вәкиләсе итеп карый килде. Ирләр белән тигез хокуклы хатын-кыздан алар сатлык мал һәм сатып алырлык товар ясадылар. Андыйларда хис тә, мәхәббәт тә юк. Икенче бер төрлеләре хатын-кызны илаһилаштырып, аларны бары тик мәхәббәт өчен генә яратылган алиһәләр итеп карадылар. Хатын-кызга кагылмыйча гына, аны үпмичә, кочмыйча гына яратырга, ерактан гына карап сокланырга. Әфләтун мәхәббәте тәрбиячеләргә кушалар иде. Ике тараф та бер яннан икенчесенә бәреләләр. Хатын-кыз ул урталыкта, ирләр кебек— урталыкта, алардан фәрештә ясарга маташканнар сонра аларнын фәрештә түгел, гап-гади хатын икәнен анлыйлар, аларнын мәхәббәте сүрелеп, нәфрәткә әверелә. Хатын-кызны бала ясау станогы, вакытлыча женси ихтыяҗ канәгатьләндерү әсбабы итеп караганнар да рухи фәкыйрьлеккә килеп чыга. Андыйлар рәхимсезләнә, кансыз садистка әйләнә. Поляк кызына үлеп гашыйк булган Андрейны атасы Тарас атып үтерә. Гүзәлләр гүзәле Юдифь халкын коткарып калыр өчен, юрганы астына кан дошманын алырга мәҗбүр була. Ләззәт кичкәннән сон Юдифь дошманынын башын чабып өзә. Күчем хан төп гаскәре белән чик сагында торганда, юлбасар Ермак Күчем ханнын җәй кальгасын камап ала. Калада капка сакчылары гына, карт-коры, хатын-кыз, бала-чага гына була. Күчем ханнын сөекле хатыны, дөнья гүзәле Сүзгәбикә манарага менә. Капкаларны ачтыр, ханбикә, юкса, кальгагызга ут төртәм, сине үземә хатынлыкка алып китәм, дип кычкыра Ермак астан. Ярар, ди Сүзгәбикә, мин капкаларны ачтырырмын, үзем сина булырмын, ләкин син картларны, балаларны кальгадан җибәрергә рөхсәт бир. Гаскәренне читкәрәк ал, ди ханбикә. Ермак гаскәрен читкәрәк ала. Камалыштан халыкны, байлыкны, балаларны, хатын-кызлар, картларны озатканнан сон, Сүзгә манарада ялгызы кала. Ачык калган капкадан кереп, Ермак атылып гүзәл хатын янына менә, Сүзгә юлбасарнын комсыз, канлы күзләрен курүгә ук, хәнҗәрен йөрәгенә батырып, манарадан егыла. Сүзгә дә халкын коткарып һәлак булуны хуп күргән. Шушы өч шәхес турында күп уйладым мин. Никадәр көчле рух бу әсәрләрдә. Барыбер түгел идемени Сүзгәбикәгә, Күчем хан хатыны булды ни дә, Ермак хатыны булды ни? Юк, Сүзгәбикә хал-

кына, иренә булган мәхәббәтенә хыянәт итә алмый, үзен үзе үтерә.

Шаһбазгәрәй минем булачак анам Хәдичә туташ Алкинага булган мәхәббәтенә үзен әнә шулай, классик әсәрләрне өйрәнеп, үзен үзе әзерләгәндер, дим. Мина шунысы мәгълүмдер ки, атам Шаһбазгәрәй Әхмәров нәселе, дине, халкы алдындагы изге бурычын шәхси мәхәббәттән, шәхси теләкләреннән, хиссияттән өстен куйган. Ул бу эшкә аналитик акыл, үз зиһнияте белән килгән шәхес. Хупларгамы атамны бу гамәле өчен, әллә хурларгамы? Ләкин шунысы хак: атамны коры прагматик кына булган, дип уйлаудан мин ерак торам.

Анам Хәдичәнең токымы—Алкиннар да бик борынгы, затлы нәсел. Хан заманында да бәк булганнар, патша заманында да төшеп калмаганнар: дворянлыкта яшәгәннәр. Анам хәтерендә саклanганнары байтак. Габделлатиф Алкин Чистай ягындагы ирексезләп чукындырылган мишәр татарларын мөселманлыкка кайтару эшен башлап җибәргән морза. Бу эше өчен аны 1867 елда кулга алалар да Турухан ягына каторгага озаталар. Юлда баргандамы, төрмәгә барып житкәчме, 50 яшьлек Габделлатиф бабайны кыйнап үтерәләр. Шаһиәхмәт Алкин, хокукчы, потомственный дворянин, "Иттифак әл мөслимин" фиркасын оештыручы, присяжный поверенный Казанской судебной палаты, Дәүләт Думасы депутаты. Революциягә чаклы Казан губерниясының баш полицеймейстры, морза кызы Хөнсебикәгә өйләнгән була. 1919 елда 52 яшьлек бабам юкка чыга. Күрәсең, ул кызыллар кулына эләккән булгандыр. Ике углы Ильяс белән Жиһангир татар халкының азатлыгы өчен көрәшүчеләр, берсе унтугызынчы елда, икенчесе утыз җидедә үтерелде. Анам Хәдичә шул нәсел кызы. Коръәннән, татар йолаларыннан тәрбия алган шәхес.

Атам Шаһбазгәрәй сукырайган анасын Казанга алдыргач, өйләнү эшенә керешә. Ләкин татарның бай гаиләләре аннан килгән яучыны буш кул белән бора торалар.

—Хәерче учительгә дип кыз үстермәдек,—диләр.

Атакай үз яучысын атаклы дворян нәселле Алкин йортына юллый. Бу йортта унсигезе тулмаган Хәдичә исемле итагатьле кыз тора. Бабай да, агаларым да каршы төшәләр:

—Сукыр кайнаналы йортта нишләр Хәдичәбез? Ризалык юк! Учитель акчасына нишләр кызыбыз Хәдичә? Фатиха булмас!—диләр.

Оләби боларны тыңлап-тыңлап утыра да тамак кыра. Һо-о, Оләбинең авторитеты зур була гаиләдә.

—Туктагыз әле балалар,—ди Оләби.—Сез тышка, урамга багыгыз. Анда ни күрәсез? Сәяси урамда хәлләр үзгәрергә тора анда. Сәүдәгәрләр бөлә. Байлык—бер айлык. Байлар хәерчегә кала. Дворяннарның барысы да чабаталы морзалар. Шаһбазгәрәй әфәнденең төпле һөнәре бар: югалмас! Чабаталы морза булса да, каны затлы. Миннән фатиха!

—Уйла!—ди әбием Хәдичәгә.— Уйла! Күрмичә чыкмассың. Сине ирексезләп кияүгә бирергә жыенмыйбыз. Очраштырырбыз. Ошатсаң, ризалык бирерсең, ошатмасаң, ихтыярың, кызым.

Яучылык хезмәте татарларда электән үк камилләшкән бер йола булган. Мин хөрмәт итәм шул йоланы.

Нәрсә соң ул мәхәббәт? Китап укып, кино карыйлар да "мәхәббәт" дип авыз суы корыталар. Алдын-артын уйламыйча гашыйк булалар да, фажигага килеп теләләләр. Менә мин статский советник Шаһбазгәрәй Әхмәров кызы— Заһидә, революциягә чаклы ук гимназия бетергән кеше, француз, урыс телләрен һәм әдәбиятын белүче, классик музыка, классик әдәбиятта гына тәрбия алган заманча, светская дама, татарларның борынгы яучыларын мактап тормыш көнем. Яучылар нинди ысул белән эш кылганнар соң? Ялангач мәхәббәт ысулы беләнме, ягъни хис, мәхәббәт кагыйдәләре белән генә эш иткәнме? Әллә зиһният аша мәхәббәткә юл салганнармы татар яучылары? Беренчесе разочарованиегә китергән, икенчесе чын мәхәббәткә юл салган. Ромео белән Джульетта фажигасе көтә, Ләйлә белән Мәжнүн бәхетсезлеге көтә андыйларны. Минем борынгы бабам Алкин әбием Бибимәфтуханы күрмичә, яучылык аша өйләнгән. Унике бала тапкан Мәфтуха әбием. Унысы үскән. Алар кебек бербереен сөеп яшәгәнннәр сирәк була. Дус кызым Аннушка Петрова:—Мине прапорщик Василийга бирмәсәгез, асылынып үләм, дип ата-анасын куркытып Васяга чыкты. Ике айдан Василийны ташлап, карт миллионерга кияүгә чыгып, Америкага китеп барды.

*(Ятлаган сүзләрне сөйләгән кебек.)* "Тилергән шагыйрьләрнең мәхәббәт турындагы тиле шигырьләрен укып тилергәннәр дөньяның тигезлеген боза. Житди шәхес, зиһенле ир ул шигырьләрне укымый, укыса да "илаһи мәхәббәт" дип тилерми. Андый кеше мәхәббәт өлкәсендә дә Вазифа, Бурыч үти. Ата-ана алдындагы бурыч, хатын алдындагы бурыч, балалар алдындагы бурыч, Ватан-милләт алдындагы бурыч: шуларның бөтенесе Аллаһ алдындагы Вазифа булып калка. Чын ир, чын каһарман шундый булырга тиеш".

Бу—минем атам Шаһбазгәрәй фәлсәфәсе. Бүгенге заманада хатын-кызны бары тик женес әгъзасы йөртүче жан иясе, бала табу станогы, "башла да ташла әсбабы" итеп караучылар Аллаһ яралткан тәртипләргә, иманыга яла яга, шул тәртипләрне боза. Андыйлар Иблистән дә куркынычрак. Эш шунда ки, ир заты белән хатын заты аерым-аерым гына алып караганда бербөтен түгел, ярым-йорты гына жан ияләре булып кала. Алар бергә кушылганда һәм ярашканлык хасил иткәндә генә бербөтен була ала. Хатын ирдән, ир хатыннан берничек тә өстен яки түбән була алмый. Алар тигез. Алар бары тик берсендә булмаганны икенчесе тутырып кына тора. Әлбәттә, ир кеше хатыннан куәтлерәк булырга мөмкин, әмма хатын үзенең тормыш алып баруы белән, бала табуы белән ирдән өстенрәк. Бер өстенлек икенчесе белән кисешә дә, тәнгәллек барлыкка килә. Әллә нинди операцияләр ясасалар да, ир кеше бала таба алмый, баланы бары тик ана гына таба ала.

Шаһбазгәрәй Әхмәров дөнья философлары дәрәжәсендә фикер йөрткән. Әйтик, күрмәгән-белмәгән хатынга өйләнү, күрмәгән-белмәгән иргә чыгу, бер караганда кыргыйлык кебек. Тирәнрәк уйлап баксаң, Вазифаны алга сөрсәң, кыргыйлык түгел, киресенчә: бу—алгарыш, бу—прогресс. Әгәр дә никах ялган, артык купайтылган мәхәббәткә генә корылса, дөньяда дүрт миллиард кеше түгел, дүрт кеше дә булмас иде. Янәсе, "илаһи мәхәббәт" көтеп, бер кеше дә өйләнмәс иде, нәсел үрчемәс иде, инсаният кысыр килеш бетәргә мәхкүм булыр иде.

Ир беркайчан да хатын кылганнарны кыла алмый. Хатын беркайчан да ир кылганны кыла алмый. Аларның икесе дә кыла алган уртак мөмкинлекләре дә бар: гаиләне саклау, сәламәт балалар тәрбия кылу. Балаларга ата-ана мәхәббәте тәрбияләү. Димәк ки, ир белән хатын икесе дә тип-тигез. Шуны аңламаган кеше беркайчан да матур гаилә кора алмаячак.

Яучылык аша кавышкан ярлар ике төрле була. Беренчесе—мәжбүрият, заруръят гаиләсе. Язмыш кушкан икән, сөймәсәң дә шушы яр белән тор, нәсел үрчет, таза нәсел тәрбия кыл. Бусы яраклашып яшәү, дип атала. Ир хатынына яраклаша, хатын иренә—тормыш шартларына яраклаша. Һәм еш кына бу гаилә таза-нык була. Ир: мин хатынымны сөймим, дип кеше сөендереп кычкырып йөрми. Хатын: мин иремне яратмыйм, дип сер сатмый. Ул яхшы хатын, яхшы ана, яхшы кайнана булып кала бирә. Мәрхәбә! Машалла! Котлыйбыз андый гаиләләрне. Чөнки алар сау-сәламәт буын калдыра.

Икенче гаилә өстенрәк, илаһирак гаилә. Болары да яратышып, сөешеп өйләнмәгән, мәжбүрият аша тормыш корган. Әмма тора-бара, балалар пәйда булгач, ир белән хатын арасында назик хисләр хасил була. Уртак балаларга булган сөю хисләре ир белән хатынга да көчә бара. Ир-хатын чын мәхәббәт белән бер-берсен сөя башлый. Монысы—ярашып яшәү, дип атала. Яраклашып түгел, ярашып яшәү. Яратышып яшәү.

Менә шул була инде ул чын мәхәббәт.

"Чын мәхәббәт", "чын сөю", "хакыйкый ярату" дип күп яздылар инде бу дөньяда. "Мәхәббәт шагыйре" дигән дәрәжәне дә көн тәртибенә куйды әдәбият белгечләре. Шагыйрь булгач, ул мәхәббәт шагыйредер инде. Мәхәббәтсез шагыйрь, мәхәббәтсез шигырь, мәхәббәтсез роман, мәхәббәтсез пьеса буламыни? Һәр шагыйрь мәхәббәт турында яза лабаса. Кем соң ул мәхәббәт шагыйре? Тукай язмаганмы мәхәббәте турында? Такташ язмаганмы мәхәббәте турында? Жәлил язмаганмы гыйшкы турында? Димәк, шагыйрьләрнең барысы да мәхәббәт шагыйре? Ә шулай да, шулай да мин мәхәббәт турында язган бары тик бер генә шагыйрьне аерып куяр идем. Мәүла Колыйны. Анам Хәдичә шушы шигырьне гел яттан сөйли торган иде, мәрхүмә.

*Хәләл нуры нурлы торур көнәш нурдин,*
*Хәләл берлә сәвешмәк татлыг балдин;*

*Ике хәләл бер-берсенә хушнуд кыйлмак*
*Нәзек торурназиклектә нечкә кыйлдин.*

*Кыз углан рәушан торур йакты көндин,*
*Ата-анага ләззәтләкләр шәкәр, балдин;*
*Хак әмреилә хәләлына тапшырмаклык*
*Назиклектә назик ирмеш өзелер кыйлдин.*

*Гашыйк улдыр—Хак юлында гашыйк ирсә,*
*Дидар теләп җан күңлени фида кыйлса,*
*Бу дөньяны күзгә алмас хальгә килсә,*
*Гашыйклар тик Хак йулына кергүм килүр.*

*Ир-хатын мәхәббәттә сөхбәт кыйлса,*
*Анлар өчен хәсәнатлар хасыйл булыр.*

Анам абыстайда укыган, Коръәнне яхшы белә иде. Татарнын борынгы әдәбиятыннан да дәресләр алган анам. Унҗиденче гасырда иҗат иткән Мәула Колыйның чын исеме Бәйрәмгали Колыев икәнен дә, аның Казан артындагы Чыты авылында туып үскәнлеген дә каткат сөйли торган иде. Иң гаҗәбе, борынгы татар шагыйренең шушы шигыре дөнья әдәбиятындагы шедеврлар рәтендә торырга тиеш. Ләкин аны татарлардан башка милләт белми. Идеаль гаилә кору тәртибен Мәула Колый ундүрт юллык шигырьгә сыйдырган да куйган. Без әле һаман "Нәрсә ул чын мәхәббәт?" дип авыз суы корытабыз. Мин шушы шигырьне гимназиядәге укытучыбызга тәрҗемә итеп бирдем, урысчага да, французчага да тәрҗемә иттем. Кызлар шундук аны ятлап алдылар. Француз теле укытучысы әйтә:—Каян килә ул татарларга шундый шигърият?—ди.

Миңа калса, атам Шаһбазгәрәй белән анам Хәдичә шушы фәлсәфәне бер-берсен күргәнче үк кабул иткән. Алар инде бер-берсен сөяргә күптән әзер булган. Язучысы да аларның уртак зәукын чамалагандыр. Бик бәхетле, ярашып яши торган гаилә коралар алар.

Еллар узган, гасыр узган, мин атамның кыяфәтен күзаллыйм. Аның сөйләшү рәвешен колагымда тотарга тырышам. Нинди затлылык булган Шаһбазгәрәй Әхмәровта, минем атамда. Менә аның хаты. Йөз ун ел элек сөеклесе Хәдичәгә язган хаты. *(Ханым язучы алдындагы рәсемне ача.)*

**Яшь Шаһбазгәрәй белән яшь Хәдичә җанлана. Шаһбазгәрәй язу өстәле янында, хат яза. Хәдичә ханым кәнәфидә хат укый. Шаһбазгәрәй тавышы тасмада яңгырый.**

З а һ и д ә  х а н ы м. Нинди тел! Нинди җөмләләр! Нинди затлылык!

Ш а һ б а з г ә р ә й. "Әле яна гына мәгълүм ханым аша Сезнен язуны алдым, Сезнең беренче хатыгызга бүгенгә чаклы җавап яза алмавымны бераз аклар өчен, шундук хат язарга утырдым. Сезнең кыйммәтле сөальләрегезгә, сәтырларыгызга җавапларны иркенләбрәк язасы иде дә, хатыгызны каткат укый торгач, мин аны ятлап бетердем инде һәм аңлыйсым-аңлатасым килде. Ләкин, бер юлга кичерерсез шөт, бу юлы кыскача гына язармын. Чөнки озакламый без театрда очрашачакбыз, иншалла. Нә мәгълүмдер ки, анда яхшылап сөйләшеп булырмы, юкмы? Шулай да күрешүебез хәерлегә булыр, дим. Сезне җиде дингез артындагы Баян утравында яшәүче, хыялдагы әкияти кыз кебек итеп күзаллауга караганда, күрешеп сөйләшү, танышу яхшырак булыр, дим. Ниһаять, үземнең ялгыз түгеллегемне аңлар вакыт җитте шикелле. Мин сезнең алда ант итәм: моннан соң мин гел Сезнең турыда гына уйлармын. Сез мине яман кеше дип уйлый күрмәгез. Сезнең дикъкатьне вә ышанычыгызны яулар өчен мин бар көчемне масраф итәчәкмен. Сезнең рухи тынычлыгыгыз өчен мин барысын да Сез теләгәнчә эшләрмен, монарчы булган яшәү рәвешемне үзгәртәчәкмен. Ант итеп әйтәмен ки, валлаһи, Сезнең гаилә белән туганнарча мөнәсәбәтләргә кергәндә һәм Сезнең ризалыгыгызны сораганда мин үзем турында түгел, башкаларны бәхетсез итмәү турында уйлыймын. Үз бәхетем һәм тынычлыгымнан битәр, миңа Сезнең бәхетле булуыгыз кадерлерәк. Мин шуның өчен тырышачакмын һәм, Аллаһ боерса, ул шулай булыр да. Миннән шикләнмәгез, зинһар. Сез язганча: "мин үземнең юньле булганымны, булмаганымны Сездән күрермен". Сезнең укымышлы булу-булмавыгыз хакында Сез зерә хафаланасыз. Күрербез әле, укымышлылык мәсьләсендә минем Хәдичәм кебекләр бармы икән әле бу дөньяда... Әгәр карточкагыз булса, зинһар, мине куандырыгыз. Мин Сезнең сурәтегезгә багып, зәукый ләззәт кичерермен. Тиздән күрешкәнебезгә кадәр сау калыгыз. Сезнең Шаһбазгәрәегез".

З а һ и д ә  х а н ы м. Аларны берен-

че тапкыр театрда очраштыралар. *(Язучы алдындагы рәсемне ача.)*

**Шаһбазгәрәй казакин, затлы каракүл бүрек кигән, кулына затлы таяк тоткан, Хәдичә туташ күп бәбәйтәкле күлмәк кигән, башында энҗе калфак. Алар театр фойесенда салмак кына әңгәмә кора. Фойеда татар музыкасы яңгырый, Шаһбазгәрәй белән Хәдичә, салмак кына, сизелер-сизелмәс хәрәкәтләр белән музыка тактына бии. Кара Шәүлә керә. Аның йөрүе тавышсыз, шомлы. Ул җай сагалап читтә тора, форсат чыккач кына үзенең кара эшен башкара.**

Заһидә ханым. Театрда берничә тапкыр очрашкач, хатлар алышкач, болар бер-берсен бик ошаталар. Атам Шаһбазгәрәй белән анам Хәдичә никахлашалар.

Атамның мәхәббәт, сөю, ярату турындагы фәлсәфәсе төгәл һәм ачык фәлсәфә. Бу аның Европа, бөтен дөнья фәлсәфәсен, тарихын өйрәнеп чыкканыннан киләдер, мөгаен. Ни гаҗәп, шәрекьчә тәрбия алган анам Хәдичә дә шул ук фәлсәфәне хуплый. Һәм бу ике изге зат матур гаилә корып җибәрә. Атам сүзендә тора. Ул көне-төне намуслы хезмәт итә һәм, ниһаять, акча туплап, ул 1897 елда Петропавловская белән Молочный ряд (хәзерге Профсоюзный белән Җәлил урамы) почмагындагы зур гына таш йортны Геркина исемле дворянкадан 40 000 сумга сатып ала. Анам да атама яхшы хатын, балаларына яхшы ана була. Ярашкан гаиләдә ярашканлык, мәхәббәт һәм сөю хөкем сөрә. 1879 елдан 1900 елгача, 21 ел буена бәхет нуры балкып тора Шаһбазгәрәй йортыннан. Барысы да атам уйлаганча бара. Барысы да анам теләгәнчә бара. Ун бала кереп адашырлык зур, күп бүлмәле йортта. Һәрберсенә зур-зур аерым бүлмәләр. Абыйларым да югары белемле, апаларым да чит илләрдә укып кайткан шәхесләр. *(Кара Шәүлә хәрәкәткә килә. Ул уртада басып торучы Шаһбазгәрәйгә каплавычы белән кагылып уза, шартлау тавышы ишетелә, Шаһбазгәрәй егыла.)* Мин туып өч ел узгач та бу бәхетле гаиләгә беренче бәхетсезлек килә. Атам — статский советник, Казан губерниясындагы халык училищеларының башлыгы, тагын дүрт ел хезмәт итсә, действительный советник, тагын дүрт ел хезмәт итсә, тайный советник буласы кеше — Шаһбазгәрәй Әхмәров 47 яшендә кинәт вафат була. Менә шуннан башлана инде бәхетнең җимерелүе.

Француз, урыс һәм бөтен дөнья әдәбияты белгече булсам да мина каләм көче, язучылык сәләте бирелмәгән. Әгәр дә мин каләм иясе булсам, Шаһбазгәрәй Әхмәров белән Хәдичә Әхмәрованың гаиләсе, Заһидә белән Кәрим Тинчурин турында китап язар идем. Шушы китап бөтен татарның язмышын көзгедә күрсәткән кебек, чагылдырыр иде. Ул китапны мин "Җимерелгән бәхет" дип атар идем. Җимерелгән бәхет... Ул китапны, иншалла, сез язарсыз, хөрмәтле әдип-әфәнде. Анам минем белән йөккә калгач, хафага төшә. Балаларыбыз болай да күп, шөкер, монысын инде Аллага тапшырыйк, дип ул атамнан мине төшерергә рөхсәт сорый. Ләкин атам ана рөхсәт итми: бәлки шушы туасы бала кулына калырбыз, кем белә, тусын, җан биргәнгә Аллаһ җүн бирер, ди. Атакаем мине бик тә нык яраткан. Мин аны хәтерләмим. Теге балалары үсеп җиткәнгәме, атам мине алдыннан төшермәгән. Ул вафат булгач, мин: нигә атакаемны чәй эчәргә уятмыйсыз, дип җылаганмын. Зиратка, җирләргә алып киткәндә: атакаемны уятыгыз, дип кычкырам икән. Бик озак вакытлар мин атакаемның бүлмәсеннән чыкмыйча: хәзер атакаем кайта, ул мине үчтеки иттерә, дип көтеп утырганмын. Сабый кызның акылына зыян килмәсен, имчәктән дә аерылыр, дип мине күршебез, асравыбыз Вафиягә ияртеп авылга юллыйлар. Авылда атна-ун көн торгач, мине янә йортка кайтаралар. Кайтып керүгә анакаем мина күкрәген каптыра, мин имчәкне төкереп, анакаемны каты итеп этеп җибәргәнмен дә, кабат иммәгәнмен... Мин инде туксанны тутырып килә торган карчык. Һаман уйлыйм, һаман баш ватам. Анам мине чынлыклап сөймәде бит. Табасы килмичә тапканынамы? Әллә башка сәбәпләр булдымы, мин сабый чагымнан ук сизенә идем, мин анакаема үги бала кебек идем. Аның олуг ана мәхәббәте Сара апам белән Йосыф абыема була килде. Маһипәрвәз белән Суфия апамнарны да ул ярата иде, әмма Сара! Сарага ул ана буларак та, хатынкыз буларак та, гаилә башлыгы буларак та гашыйк иде. Сара апам анакаемның бөтен өмете, киләчәге, сөеклесе, иң кадерле кешесе булып кала бирде. Сукыр мәхәббәт белән ул Сарага гашыйк иде.

Сара апам фәүкыльгадә, гадәттән тыш зиһенле, хәттин ашкан гүзәл иде. Акыллы, чибәр, серле Сара иде ул. Аңа гашыйк булмаган кеше булмагандыр бөтен Казанында. Мин аңа гашыйк булганнар турында сонрак сөйләрмен, шулай да сезне кызыктырып куйыйм: Фатих Әмирхан, Гаяз Исхакый...

Туксан яшемдә мин уйлап куям, атам вафатыннан соң, авылда торып кайтканнан соң, мин-сабый анамны ашатучы, имезүче, ана буларак инкарь иткәнмен. Каты эткәнмен. Белмим, бу вак мәсьәләдер, бәлки, әмма анакаем кич утырганнарда, картайгач та гел-гел шул турыда еш сөйли иде. Ул минем белән һәрвакыт кырыс булды. Дөресен әйтим, мин ана назын күрмәдем. Бәлки шуңа күрәдер дә, мин ирем Кәрим Тинчуринның анасын, кайнанам Мәхмүдәне жаным белән сөйдем. Ул миңа чын ана була белде. Мин ана назын кайнанамнан күрдем. Бу—аерым мәхәббәт. Тинчуринның миңа булган хисләре, анасына булган чиксез мәхәббәте турында да мин сезгә сонрак сөйләрмен. Аларның мәхәббәте—аерым бер поэма. Минем бу картлык сөйләнүем гел мәхәббәт турында булыр кебек. Бөек сөю, олуг мәхәббәткә ия шәхесләрне мин күп күрдем. Шулар турында мин сезгә сөйләп китим. Менә кемнәр турында дастан язарга кирәк, хөрмәтле язучылар. Кәримнең анасын яратуы, анасының Кәримне сөюе турында язгыз сез. Мин андый мәхәббәтне бүтән күрмәдем. Ләкин Кәримгә кадәр байтак юллар узасы бар. Менә бу Шаһбазгәрәй Әхмәровның тулы гаиләсе булыр. *(Сурәтне ача.)*

**Сәхнә уртасында гаилә әгъзаларының барысы да нәкъ фотодагы кебек урнашалар. Маһипәрваз ханым, Суфия ханым, Сара ханым, Ильяс, Йосыф, Даут, Аскәр, Заһидә туташ, Хәдичә ханымның өлкән чагы. Иң азактан гына, башкаларга сиздермәскә тырышып, Кара Шәүлә дә артка килеп баса.**

З а һ и д ә х а н ы м. Фу, әстәгыфирулла, сез каян килеп чыктыгыз тагын?

К а р а Ш ә ү л ә. Тсс, шаулама. Мин болай гына.

Х ә д и ч ә. Син нәрсә сөйләнәсең анда, Заһидә?

З а һ и д ә х а н ы м. Юк, болай гына, анакаем. Фотода күземә бер шәүлә күренеп китте.

К а р а Ш ә ү л ә. Дәвам ит, алар барыбер мине күрми.

З а һ и д ә х а н ы м. Алар күрмәсә, язучы күрер.

К а р а Ш ә ү л ә. Татар язучылары синең хыялындагын түгел, булганын да күрми. Татар язучыларының күңел күзләре сукыр бит, Заһидә ханым.

З а һ и д ә х а н ы м. Ун бала табып, өчесе сабый чактук вафат булып, Хәдичә ханым жиде бала үстергән ана. Монысы туганнан туган энем Аскәр Дәүләткилдиев булыр. Шулай итеп анам 38 яшендә жиде бала белән тол кала. Шаһбазгәрәй Әхмәров гаиләсендә беренче бала булып Маһипәрваз, Маһи тәтәм дөньяга килә. Бәхетле бала була ул. Казанның затлы нәсел балалары гына укый торган Ксенинская гимназиясен Маһи тәтәм көмеш медальгә тәмамлый.

М а һ и п ә р в а з. Чыннан да, мин бәхетле бала булып үстем гаиләдә. Атам-анам тигез, тормышыбыз көр иде. Егерме яшемдә мин борынгы морза токымы Рөстәм Дәүләткилдиевка кияүгә чыктым. Без бәхетле идек. Йөккә узгач, шатлыгымны күрсәгез. Анамның куанычын күрсәгез. Бәхетсезлек безне сагалап кына торган икән, озак та узмый, ирем Рөстәм тимгелле тифтән вафат булды. Мин йөкле килеш тол калдым. Аскәрем дөньяга килде. Инде нишлим, атабыз да вафат, ирем дә вафат, атабыз вафатыннан соң анакаебыз жилкәсенә тормыш алып баруның бөтен авырлыгы ишелеп төште.

Х ә д и ч ә х а н ы м. Атагыз беренче балабызны ир-олан булыр дип көткән иде. Маһипәрваз дөньяга килде. Атагыз сер бирмәде. Никадәр генә ир-олан көтсә дә, сиздермәде. Чыннан да ул син туганга бик шатланды. Сине сөеп туймый иде ул. Шунда мин әйттем: атасы, мин Маһипәрвазыбызны егетләр кебек итеп тәрбия кылырмын, Маһипәрваз ким-хур булмас, мине аны укытырмын, дидем.

М а һ и п ә р в а з. Бу имчәк баласы белән укып буламыни, әнкәем.

Х ә д и ч ә х а н ы м. Аскәрне үзем багармын, ләкин сине надан калдырмам. Минем атагызга биргән вәгъдәм бар. Жаның теләгән уку йортына бар.

М а һ и п ә р в а з. Ә син, анакаем?

Х ә д и ч ә х а н ы м. Ходай тәгалә жан биргәнгә жүн бирер.

З а һ и д ә х а н ы м. Маһи тәтәм Аскәрне анакаема калдырып, Петербургка

Югары медицина институтына укырга китте. Аскәргә ун яшь иде ул институтын тәмамлап Казанга кайтканда.

Маһипәрваз. Ләкин безне тагын афәт сагалап торган икән. 1918 елда уналты яшьлек Аскәремне кызыллар атып үтерде. *(Алгы планга Кара Шәүлә чыга, ул алтатар чыгара. Ату тавышы яңгырый. Аскәр егыла, калганнары хәрәкәтсез утыра кала. Маһипәрваз ике учы белән битен каплый. Кара Шәүлә читкәрәк китә.)* Нинди каргышка юлыктым икән, дип мин күп уйландым бу фажигаләр турында. Сәбәбенә һич төшенә алмадым.

Кара Шәүлә. Төшендең син аның сәбәбенә, Маһипәрваз ханымәфәнде.

Заһидә ханым. Шәүлә! Катышма син безнең гаилә эшләренә.

Кара Шәүлә. Мин катнашкан инде. Күптән. Сезнең берегез дә миннән башка тыныч кына гомер кичермәячәк. Берегез дә. Сезнең маңгаегызга язылып куелган: затлы нәсел, борынгы токым, акыллы нәсел. Сезне узындырмаска, мөмкин кадәр азайтырга кирәк! Беләсезме, Заһидә ханым, бая Маһипәрваз ханым әйтте, хәер, сез дә әйттегез ул сүзне: кемгә тидек, кемне рәнҗеттек без, кемнәр безне шулай каргады? Өстебезгә килгән бу афәтләрне аңламадым, диде. Бик гади ул ханым-әфәнде. Ямьсезләр янында гүзәллек һәрвакыт нәфрәт чыганагы булды. Гүзәллек ул көнчелек чыганагы, гүзәллек ул кызыгуны котырта торган шәй. Гүзәллек ул бер генә кешенеке була алмый яки аны тартып алалар. Гүзәллекне үзендә булдыра алмаганнар башканың гүзәллеген юкка чыгаралар. Гүзәллек—ул җинаятьләр сәбәпчесе. Гүзәллек—ул сатуалу әсбабы. Гүзәллек—ул мал. Малны кем көчле—шул ала. Татарларның мөкәммәллеккә якын гүзәл дәүләтләре бар иде. Урысның бернәрсәсе дә юк иде. Татар теле, Болгар, Алтын Урда теле бөеклеккә ирешкәндә, урысларның теле юк иде. Татар иленә, Алтын Урдага, Казан ханлыгына кызыкмаган күршеләр юк иде. Телсез, бернисез урыс халкы гүзәл, теле мөкәммәл, борынгы данлы тарихы булган татарны аяк астына салып таптады да үзе әнә алга китте. Азагын сез беләсез. Дәвам ит! Курыкма, алар мине ишетми дә күрми дә. Алар мине күрсә, ишетсә, сез әллә кайчан беткән булыр идегез.

Заһидә ханым. Мин сезне ишетәм дә, күрәм дә.

Кара Шәүлә. Син беткән бит инде. Син беткәнгә мин сиңа күренәм. Дәвам ит!

Заһидә ханым *(булмаган язучыга).* Кичерегез мине, зиһенем чуалып китте. Апамның исемен хәтеремә төшерә алмый азапланам... Ие, Маһипәрваз апам... *(Көлемсери.)* Маһи тәтәм бик тырыш, бик тә акыллы иде. Аны Ленин ордены белән бүләкләделәр. "Татарстанның атказанган табибы" дигән мактаулы исем бирделәр, ул бик абруйлы табибә иде.

Маһипәрваз. Ие, мин ирсез калдым, Рөстәмемнән башка кешене мин ярата алмадым, башкага чыкмадым. Аскәрем үтерелгәч, мин бөтенләй аралашмас булдым. Мин авыруларны дәваладым, аларга булдыра алганча ярдәм итәргә тырыштым. Әйе, миңа Ленин ордены да бирделәр, "атказанган"ны да мин алдым. Биргәннәренә рәхмәт. Ләкин боларның берсе дә миңа куаныч китермәде. Бәхетем мәңгегә кителгән иде инде. Ни өчен тырыштым мин? Гиппократ анты эчкән кеше буларак, мин мохтаҗларга, сызланганнарга ярдәм итәргә тиеш идем. Баламны атып үтергән кызыл армеецмы ул, элеккеге дворян кешесеме ул—минем бурычым адәмнәрнең сызлануын киметү булды. Мин уйдырма сөйләмим, чыннан да, улым, бердәнберем Аскәрне атып үтергән кызыл армия командирының баласын мин үлемнән алып калдым. Операция ясамасан ул үлә иде. Мине гаепләүче булмас иде. Операцияне соңлабрак ясаган булсан да үлә иде. Операция ясаган булып, бер укол төртсән дә ул үлә иде. Ләкин мин операция өстәлендә ыңгырашып, күземә карап, ярдәм көтеп яткан кешенең җәллад токымы, дошманым баласы икәнен онытым. Дворян кызы, ак офицерның тол хатыны, патша армиясе юнкерының анасы ничек яшәргә тиеш иде соң Совет мохитендә? Тегеләр әйтмешли: судан да тыныч, чирәмнән дә түбән посарга тиеш идем мин. Бу дөньядан мин шулай кара кайгы төяп киттем.

**Маһипәрваз сөйләгәндә Кара Шәүлә сиздерми генә берәр карыш кына атлап, янга чыга. Маһипәрвазның соңгы сүзләрендә нинди дә хәрәкәт ясый. Маһипәрваз егыла. Шәүлә китә. Сурәттәгеләр арасыннан Заһидә туташ чыга.**

З а һ и д ә  т у т а ш. 1885 елда Шаһбазгәрәй Әхмәров гаиләсендә икенче кыз бала—Суфия пәйда була. Ул да ата-анама шатлык китерә. Ләкин Маһипәрваз апамнан аермалы буларак, Суфия тәтәм ялкау, иренчәк иде. Өчле-тугызлы гына укып, көчкә-көчкә гимназия бетерде. Аның каруы, Суфия тәтәм җырлый, бии, егылып романнар укый иде, күзгә күрсә, аерыла алмый йөди иде.

Х ә д и ч ә  х а н ы м. Кызым Суфия! Сина гимназия бетерттек. Син дә апаң кебек Петербургка барып яки медицинскийга яки юристлыкка укырсың. Врач белән адвокаттан да яхшы һөнәр булмас.

С у ф и я. Анакаем, нигә миңа уку? Петербург бик расходлы шәһәр. Беткәнме Казанда берәр уку йорты? Әйтик, музыка! Әйтик, берәр җайлы эш? Ә мама? Же ву при, мама, ля мурр, шарман... Әйтик, кияүгә чыгу. Шушындый затлы кызны кем алмас икән?

Х ә д и ч ә  х а н ы м. Кыланма! Сине укытырлык кына көчем бар әле минем. Кабат сүз юк!

З а һ и д ә  т у т а ш. Суфия тәтәм Петербургка китә китүен, ләкин ул юридическийга да, медицинскийга да керми, туп-турыдан Югары драматик курсларга барып керә. Режиссер, артистка булып 1908 елда Казанга кайтып төште. Суфия тәтәм татар хатын-кызларыннан беренче булып Югары театраль белем алган кеше. Чыннан да, ул бик тә сәләтле артистка, бик тә сәләтле режиссер иде. Кайтуга ук ул Гаяз Исхакыйның "Алдым-бирдем"ен сәхнәгә куйды.

С у ф и я. Чыннан да, ул спектакльне Абдулла Кариев үзе килеп караган иде. Һо-о, это было великая честь для меня. Премьера бик уңышлы узды. Мин баш рольләрне дә уйнадым.

З а һ и д ә  т у т а ш. Премьерасы да яхшы узды, артистка буларак та уныш казанды Суфия тәтәм, Кариевның бөтен өмете, укымышлы артистка буларак та, режиссер буларак та Суфия тәтәмдә иде. Ләкин Кариевның өметләре һәба-ән мансу-рә булып, ягъни янып, җилгә очты-китте.

С у ф и я. Фи, татар театрында классиканы уйнарлык артистлар юк бит анда. Бөтенесе надан, бөтенесе түмәр, галахлар. Кем белән мин анда Шекспирны куйыйм? Татар драматурглары юк дәрәҗәсендә. Это не по мне.

З а һ и д ә  т у т а ш. Кияү күзли башлады бу. Мин уйлап куям: аның Петербургка барып укуы да, театрда эшләп йөргән булуы да бары тик кияүгә чыгу, егетләр сайлау өчен генә булгандыр, дим. Ячылар белән өй тулды. Кияүләр куера башлады. Коллежский регистратор Афеногеновның улы да, байбәтчә Мирзабәк тә—барсы да бар. Ләкин анакаем...

Х ә д и ч ә  х а н ы м. Ярар, синеңчә булсын, еллар буе укуың да җилгә очсын, минем тиенләп җыйган акчам да суга аккан, миннән фатиха. Ләкин син, мут кызый, үзебезнең кешегә кияүгә чыгарсың. Башкача ризалыгым юк! Юкса, миннән фатиха да бирнә дә көтмә.

С у ф и я. Ярар, анакаем, синеңчә булыр.

З а һ и д ә  т у т а ш. Әмма кияүгә чыгу алай ансат кына булмый икән ул.

С у ф и я *(күзгә алдында, сәхнәнең ике ягында ике кеше күренә, аларның берсе Сембер бае, ул шактый юан гәүдәле, затлы кием кигән, икенчесе генерал Шәех-гали улы Аскәр, бик мәһабәт егет.).* Карале, Заһидә, кайсысына чыгыйм икән, ә? Генерал Шәех-Гали углы Аскәргә барыйммы? Әллә Сембер бае — Нигъмәт Габдерәшитовкамы?

З а һ и д ә  т у т а ш. Сембер бае Габдерәшитовка чык, тәтәм.

С у ф и я. Ул бай анысы, ләкин образованиесе юк. Надан!

З а һ и д ә  т у т а ш. Алайса, син, тәтәм, генерал Шәех-Гали углы Аскәргә чык.

С у ф и я. Генерал Шәех-Гали углы Аскәрнең хантамасыннан башка акчасы юк, ләкин Аскәр күп телләр белә, мазурканы, вальсларны яхшы бии, ләкин ул миннән дүрт яшькә кече. Нишлим икән, ә?

З а һ и д ә  т у т а ш. Суфия тәтәм мин белӛм кемгә чыгасыңны.

С у ф и я. Әйт, сеңлем, зинһар әйт.

З а һ и д ә  т у т а ш. Тутыйнамәдә мона җавап бар.

С у ф и я. Сөйлә, зинһар, йөгендермә мине.

З а һ и д ә  т у т а ш. Хан кызын кияүгә бирәләр. Күрше патшаның углы аны хатынлыкка алып кайтып барганда алар бер бинен өенә кунарга төшәләр. Юлбасарлар басып кереп, шаһзадәнең башын чабып өзәләр. Хуҗаби башы чабылган шаһзадәне күреп, курка, мине

ике патша да үтерер, дип үз башын чабып өзә. Кыз уяна, ике баш, ике гәүдә тәгәрәп ята. Әбүгалисинаны сарайга чакырталар. Тылсымчы кызга башларны муеннарына терәп куярга куша. Әфсен укый, тегеләр терелә, ләкин гөнаһ шомлыгына күрә, бинең башы шаһзадә гәүдәсенә, шаһзадәнең башы бинекенә береккән була. Кыз кайсысын сайлаган? Би гәүдәле шаһзадәнеме, әллә шаһзадә гәүдәле бинеме?

С у ф и я. Заһидә туташ, олылардан көләргә ярамый!

**Әллә каян гына Кара Шәүлә пәйда була. Ул тавышсыз, хәрәкәтсез дип әйтерлек. Әкрен генә Аскәр Шәех-Гали янына килә. Заһидә туташ белән Суфия арткы планда бәхәсләрен дәвам итә, аларның сүзе артка күчә.**

К а р а Ш ә ү л ә. Бәй-әфәндем, сезгә киңәш итәр идем...

А с к ә р. Мин сездән киңәш сорагамымны хәтерләмим.

К а р а Ш ә ү л ә. Ә шулай да, икеләнәсез. Чөнки Суфия туташ сездән дүрт яшькә картырак.

А с к ә р. Карт түгел, өлкәнрәк.

К а р а Ш ә ү л ә. Шайтан алып олаксын, сүзгә бәйләнмәгез, зинһар. Сезнең бит мөмкинлегегез чиксез. Зиһният, буй-сын, киң маңгай, нәселегез каһарманнар нәселе. Сезгә чәнчә бармак кыймылдатсагыз да житә, дөньяның барча яшь-яшь принцессалары аяк астыгызда булыр.

А с к ә р. Чәнчә бармак кыймылдатканга килеп, аяк астына ятарлык булгач, димәк, алар принцесса түгел. Статский советник Шаһбазгәрәй Әхмәров кызы, Югары драматик белем алган, гүзәл Суфия туташ принцессаларыңны орып бирә.

К а р а Ш ә ү л ә. Ну, бу татар бәтчәләренең теленә саескан гына түгел, Иблис үзе төкергәндер, ей-Богу.

А с к ә р. Карагыз әле, әфәндем, сез шушы киңәшләрегез белән минем янга бер-ике тапкыр килгән идегез бит инде.

К а р а Ш ә ү л ә. Ие, бәй-әфәндем, килгәләдем. Мин сезгә жиләк кебек чибәр, Саран Рыцарь кебек бай бирнәле кәләшләр генә димләдем. Аннан соң яшь аермасы, әфәндем... борынгыдан ук ир кеше белән хатын арасында яшь аермасы кире якка түгел, унай якка таба булырга тиеш. Анагыз Тәфкилева атагыз Шәех-Галидән егерме яшькә кече. Һәм бу нормально. Чөнки хатын-кыз тизрәк картая. Шуна күрә мин сезгә үзегездән ун яшькә кече кәләшләрне генә димли килдем. Ә инде Суфия туташ сездән ун елга алда картаячак, сезгә яшь хатын эзләргә туры киләчәк. Физиология мәсьәләләрен инкарь итәргә ярамый, Аскәр әфәнде.

А с к ә р. Сез мине хәттин ашкан бай алпавыт кызы, гүзәл туташ Элеонора Степановнага өйләнергә бик тә үжәт кыстаган идегез... Мин бит сезнең киңәшне тотмадым. Аннан сез мина полковник Стародумскийның кызын димләдегез... Мин сезнең киңәшне тотмадым. Сезгә аңларга вакыттыр, господин Харашевлинский, мин сез теләгәннең нәкъ киресен кыламын. *(Музыка башлана. Аскәр белән Суфия бии-бии арткы планга күчә.)*

К а р а Ш ә ү л ә. Ха-ха-ха, глупец! Сез Харашевлинскийны белеп бетермисез шул әле. Сез нәкъ мин дигәнчә гамәл кыласыз. Сезнең үжәт холкыгызны белгәнгә күрә, минем киңәшемне тыңлап бакмаячагыгызны белгәнгә күрә, мин аларны сезгә димлим дә. Суфияга өйләнсен, дип мин башкаларны тәкъдим иткән булам...

З а һ и д ә х а н ы м. Суфия апам таки генерал улы Аскәрне сайлады... Суфия тәтәм мәхәббәт белән чыкмады ул генерал улына. Кызык бит дөнья. Мәхәббәт белән чыкмады, әмма ирен үзе сайлады. Укымышлы якны сайлады. Тора-бара Суфия тәтәм Аскәрне ярата башлады. Аскәр жизнәм яратмаслык түгел иде шул. Генерал улы дисәң дә була. Аскәр жизнәмнең атасы Кавказ имамы Шамилнең иң якын мөритләреннән, Хажи Моратлар белән рәттән "полевой командир"ның берсе - Дәүләт мирзаның улы була. Шамил кулга алынгач, Дәүләт мирза патша хезмәтенә күчкән була. Аның улы Али Петербургта пажлар мәктәбендә укый. Күп сугышларда катнашып, батырлыклары өчен ул патша тарафыннан өч орден белән бүләкләнә. Генерал Али Дәүләтович Шәех-Гали ул гажәеп мәһабәт шәхес иде. Какча озын, төп-төз буй. Аксыл йөзле, бераз кәкре туры борын, кара кашлары астыннан үтәли тишеп чыга торган караш, гажәеп затлы сөяк. Ул атаклы Тәфкилефнең кызы Гөлсем такайга өйләнгән иде. Әнә шул мохиттә үскән Аскәр дә бик көркәм ир иде. Су-

фия тәтәм генералның килене булды. Ике кыз бала тапты, бәхетенен түренә менеп утырды. Генералның Шаршады авылында имениесе бар иде. Пристаньнән утыз-утыз биш чакрым ат белән менәсе. Апам кияүгә чыккач, генералның углы минем жизнәм булгач, мин дә рәхәткә чыктым. Һәр жәйне апаларым, абыйларым белән мин Шаршадыга, генерал утарына кайтам. Ат чабышларында катнашабыз, качышлы уйныйбыз, су коенабыз, генерал өендәге сәхнәчектә спектакльләр куябыз... Менә шунда мин Гаяз Исхакыйны беренче тапкыр якыннан күрдем... Ие, ие, генерал утарында... Гаяз Исхакыйны беренче тапкыр якыннан күрдем, дигән идем...

**Сәхнә генарал утарын сурәтли. Заһидә туташның яшь чагы сәхнәгә чыга, өлкән Заһидә ханым арткы планга күчә.**

Заһидә туташ *(яше)*. Гөлсем такай... без ул вакытта "тутакай" сүзен шулай кыскартып әйтә торган идек... Гөлсем такай борынгы токымнан иде. Атаклы Нурсолтан ханбикәнен торыны иде ул Гөлсем такай. Уналтынчы гасырда Бүкәй-Нугай урдасының ханы Ураз Гали Мөхәммәт Тәфкил ханнан башлана. Аннан кала урда ханы Жиһангир, аннан кала Мәмәш, анын углы Котлы Мөхәммәд 1674 елда туган, Петр патша ягында генерал майор булып хезмәт итә. Котлы Мөхәммәднең торыны Батыр Гали Тәфкилев 1850 елда туган, 1917 елгача патша армиясе генералы, Дәүләт думасының 1,2,3,4 чакырылыш депутаты. Мөселман фракциясенең рәисе. Сәлимгәрәй Тәфкилев исә 1805 елда туган, Оренбургта Мөселманнарның духовное собраниесендә мөфти итеп сайлана. Тәфкилевләрнең хантамалары биек иде, һай, алардагы хантама...

Заһидә ханым *(Көлә.)* Хантамамы? Тәкәббер, горур, үзен әллә кемгә куя торганнарга "анын хантамасы биек" дип әйтә торганнар иде. Бөлгән байларның, чабаталы мырзаларның хантамасы биек, өйрәләре сыек була торган иде. Ыспай тунмас калтырар, сөякләре шалтырар, диләр иде. Анысы мин булам инде... Ирсез, йортсыз, исемсез калган булсам да мин, жае чыккан саен: сез мине кем дип белдегез, все-таки, мин бит әле Шаһбазгәрәй Әхмәров кызы, все-таки, мин бит әле Кәрим Тинчуриннын хатыны!—дип жибәрә торган идем. Шулай да, бәлки генерал Шәех-Гали белән Тәфкилев нәселле Гөлсем такайның хантамасы биек тә булгандыр, алар күбрәк Петербургта яши иде, әмма генералның углы, минем жизнәм Аскәр хантамасын биеккә күтәрми иде. Күп телләр белүче, прекрасный танцор и фехтовальщик, прекрасный наездник Аскәр бик ипле, интеллигентный шәхес иде. Байбәтчәләрнен хантамалары һәрчак биек була торган иде. Аскәр жизнәм бик кешелекле, эшчән иде. Анын кулыннан килмәгән бер генә эше дә булмагандыр. Арба ватылса, ул ат карауччылардан төзәттерми, үзе төзәтә, сабан-сука ватылса, тимерчегә түгел, Аскәргә киләләр, чалгы чүкисе булса да, ат дагаласы булса да Аскәр жизнәмә киләләр, бер дә байбәтчә, генерал малае димәссен. Хәтта патефон-граммофон көйсезләнсә дә, сәгать төзәтәсе булса да әллә кайлардан генерал утарына алып киләләр. Ул эше өчен акча алмый. Ана ватык машиналарны төзәтүе кызыграк иде. Ул ижат итә иде. Ул гади төзәтүче генә түгел, ул уйлап табучы да иде. Татарның Кулибины, татарның Левшасы иде ул. Шулар өстенә ул рәссам да, ул философ та иде. Искиткеч күп талантлы шәхес иде жизнәм Али углы Аскәр Шәех-Гали. Татарлар өчен язу машинкалары эшләүдәге анын инженерлык хезмәте бәяләп бетергесез. Дөньяда, гарәп илләрендә дә гарәпчә язу машинкасы булмаган заманда Аскәр жизнәм шул машинаны уйлап табучы, патент алучы иде. Казаннын пишмаш заводында ул эшләп чыгарган гарәпчә машинкаларны Кытайдан, Әфганстаннан, Ираннан, Урта Азия, Төньяк Кавказдан, Һиндстаннан, Ливаннан, Төньяк Африка илләреннән күпләп-күпләп соратып алалар иде. Беренче бөтендөнья сугышында офицер буларак катнашкан каһарман. Мин жизнәм Али углы Аскәр Шәех-Галине изге җанлы кеше, дип атар идем. Хатын-кызларны нишләтәсен инде аларны, күргәне бере Аскәр жизнәмә гашыйк була иде. Казанга килер хәле юк—аны дамалар, мадмуазельләр чолгап ала. Шуна күрә, Аскәр жизнәм күбрәк авылда, үз утарында яши иде. Шулай итеп, ул ирексездән гөнаһ кылмас өчен, гүзәл хатыннар, чибәр кызлар мохитеннән качып яшәргә дучар иде. Алай гына хатын-кыз хисләреннән качып котылып буламыни? Ге-

нерал утарында асрау кызлар тоталар иде. Авылдан килгән яшь-яшь кыз Шәмсиҗамал гаиләдә гауга чыганагына әверелде. Апам Суфия көнләшә иде. Үлеп гашыйк иде ул үз иренә. Белмим, гашыйклык булдымы икән ул, мәхәббәт булдымы икән, анлатуы кыен, бәлки апанын яшь олылыгы мона сылтау булгандыр, бәлки, ул чыннан да Аскәрнен ир буларак ныгый, гайрәтенен өлгерә барганлыгын, үзенен сула барганлыгын сизенгәндер, бәлки, ул чыннан да үз иренә үлеп гашыйк булгандыр. Әмма Суфия тәтәм бакчадагы печән кибәненнән дә көнләшә иде. Менә шул Шәмсиҗамал исемле яшь кыздан көнләшә башлады тәтәм. Кызга көн бетте. Анын эшләгәне ошамый. Ютәлләгәне ошамый, чәй эчүе дә нәфрәт чыганагына әверелә бара. Шәмсиҗамалнын ипине күкрәгенә терәп кисә торган гадәте бар иде. Апа ана ачу белән астан гына карап:—Ничә тапкыр әйттем, ипине альяпкычына терәп кисмә, кунага салып тура, диде. Суфия тәтәм кыз кулындагы пычакны тартып алган иде, кулы киселде. Кулы каный башлады, һай, буран куптарды инде тәтәм. Карчыга күгәрченне ботарлагандай, йоннар гына тузгып калды аш табыны янында. Ахырда, Шәмсиҗамалны елата-елата үз авылына илтеп куйдылар. Мина калса, ул бала гөнаһсыз иде. Шашып сөю әнә нинди матур булмаган хәлләргә китереп чыгара. Шашып сөюме ул, әллә сөюдән тилерүме? Сөю парадокслары, мәхәббәтнен имәнгеч яклары күп була инде анын. Алга таба сөйләрмен. Гаяз Исхакый әле һаман генерал утарына килеп житә алмый интегә булыр... Әнә, "барабыз"га утырып тау менеп килә бугай... 1913 ел иде булса кирәк. Жәйге татилдә генерал утарында без—кызлар, эштән бушаган асрауларнын кызлары, генерал утарынын хуҗалык эшләрен алып баручыларнын кызлары жыелып, качышкачыш уйнап йөрибез...

З а һ и д ә т у т а ш. Нәрсә ул татил дисезме, иптәш язучы әфәнде? Татил—ул каникул, жәйге ял вакыты дигән сүз. Без халык дошманнары булмаган чакта шулай сөйләшә идек. Жәйге татил, кышкы татил, ди идек... Мин татарча укымадым, урысча гимназия бетердем, институтны да урысча бетердем, анабыз шулай сөйләшә иде, туганнарыбыз, танышларыбыз шулай сөйләшә иде. Безнен өйдә бөтенебез дә фәкать татарча, Ана телендә сөйләшә идек. Сез бит хәзер "Ана теле" димисез, "Туган тел" дигән буласыз. Тукайнын урысча "Родной язык" шигыренен тәржемәсен байрак итеп күтәрдегез. "Туган тел" гыйбарәсе "Ана теле"н үтереп ята, сез язучылар уйлап та бирмисез. Радио-телевидениедәге дикторларнын телен ташка үлчим, язучыларыгыз "кызганычка каршы, бәхеткә каршы, между прочим, тәк эскәзәйт" дип авыз суы корыта. Сез дә тормагач, Ана теле сагында кем торыр, хөрмәтле язучы әфәнделәр?

З а һ и д ә х а н ы м. Гает бәйрәмнәрендә бер-беребезне телеграммалар, хатлар белән телефоннар аша котлый идек. Абыйларыбызга, апаларыбызга күчтәнәч, хәер илтә торган идек... Бетте ул матур йолалар да... Сез бит алласызлар, дәһриләр, атеистлар...

З а һ и д ә т у т а ш. Кичерегез, мин читкә киттем... Нәрсә турында сөйли идем әле? Ә-ә, Гаяз Исхакый һаман тау башына менеп житә алмый икән әле. 1913 елнын жәйге татиле иде. Карыйбыз: пристань ягыннан, таугa таба бер ат менеп килә. Фаэтонга бик горур кыяфәтле бер ир кеше утырган. Яхшы киенгән, Европача пальто кигән, яхшы костюм өстендә, ул чакта бик модный иде, күбәләк галстук, шуны муенына беркеткән, кулында шәмсия, кулчатыр, сезненчә—"зонтик" була инде. Сез харап культурный булып киттегез бит, без элек, халык дошманнары булмаган чакта кояштан, янгырдан саклана торган нәрсәгә "кулчатыр" яки "шәмсия" дип әйтә идек.

З а һ и д ә х а н ы м. "Халык дошманнары булмаган чакмы?" Революциягә чаклы халыкнын дошманнары юк иде бит, революциядән сон гына әллә каян килеп чыктылар да шул халык дошманнары матур гына ныгып бара торган илне харап итеп ташладылар, кабахәтләр. Халык дошманнарын әйтәм. Болгаттылар, болгаттылар суны, пычраттылар, пычраттылар дөньяны да, үзләре китеп барды, башта без коендык халык дошманнары болгаткан ул пычрак суда, инде сез коенысыз... Фаэтонга утырып, затлы кием киенеп берәр байбәтчә генерал утарына кунакка килә торгандыр, дибез.

**Сәхнә үзгәрә. Яшь кызлар Заһидә, Нәфисә, Ханифә туташлар арбадан төшүче әфәндене чорнап алалар. Бу—Гаяз Исхакыйнын 35 яшьлек чагы. Чыркылдашу.**

Н ә ф и с ә. Бай әфәнде, безне дә атына утырт әле

Х а н и ф ә. Дилбегәсен үзем тотам, кызлар.

И с х а к ы й. Әгәр дә сез, гүзәл туташлар, Гаяз абыегызга генерал Шәех-Гали утарына юл күрсәтер булсагыз, утырырсыз.

Н ә ф и с ә. Күрсәтәбез, Гаяз абзый!

З а һ и д ә т у т а ш. Кызлар чыркылдаша-чыркылдаша фаэтонга төялеп маташкан арада Гаяз әфәнде Исхакый мина текәлебрәк бакты. Аның карашы бик үткер иде, үтәли тишеп чыгардай туры караш иде ул. Ләкин аның матур керфекләреннән серле нур агыла иде. Ул елмайды да...

И с х а к ы й. Сез, туташ, Сара Әхмәрованың сеңлесеме?

З а һ и д ә т у т а ш. Мин, сихерләнгән сыман, аптырап калдым. Сара апамның гүзәлләр гүзәле икәне бөтен югары даирәләргә мәгълүм. Шаһбазгәрәй Әхмәровнын иң затлы, иң гүзәл кызы, дип һәр мәжлестә сүз куба торган иде ул вакытта. Чыннан да аңа соклanмаган зат юк иде. Ә мин кем? Мин томсык борынлы, ямьсез генә бер кыз. Мин гомерем буе шушы яньчек борыным өчен хафаландым. Бөтен жирем килешкән минем, гәүдәм дә, атлавым да матур диләр, ләкин биргән бит мина гына шушындый ирләр борыны. Нинди күзәтүчәнлек! Нинди хәтер кешедә! Димәк, ул Сара апама игътибарлы булган?

З а һ и д ә х а н ы м. Бәлки гашыйк та булгандыр, дип уйладым шул чакта һәм минем фаразларым тора-бара расланды да кебек. Гаяз әфәнде Исхакый гүзәлләр гүзәле Сара Әхмәрованы эзләп, генерал утарына килгән. Гаяз Исхакый шул елның язында гына сөргеннән кайтып төшә. Күп нәрсәдән хәбәрдар түгел. Минем апам шул елны Германиягә практикага киткән иде. Күрәсең, ул апамны генерал утарында ял итә дип уйлаган. Сара апама гашыйк булмаган ир кеше булмады шикелле. Карт булсалар да, өметкә юл калмаса да, һәр ир Сара апама соклана, хыялында гына булса да аны кочарга тели иде шикелле. Ләкин Сара апам бик озак еллар кияүгә чыкмады, жегете дә булмады. Аның серле башында серле теләкләр, серле уйлар күп иде.

З а һ и д ә т у т а ш. "Әйе, мин Сара Әхмәрованың һәм Суфия Шәех-Галинең сеңлесе Заһидә Әхмәрова буламын", дидем мин. Үземнең Сара сеңлесе генә түгел, Суфиянең да сеңлесе булганыма аеруча басым ясап.

И с х а к ы й. Бик хуп, туташ! Димәк, Аскәр әфәнде сезнең жизнәгез булып чыга?

З а һ и д ә т у т а ш. Әйе, ул минем жизнәм...

И с х а к ы й. Мин язучы Гаяз Исхакый буламын.

З а һ и д ә т у т а ш. Сезне белмәгән кеше юктыр ул, Гаяз әфәнде.

И с х а к ы й. Ә сез каян беләсез? Сез бит урыс гимназиесендә укыйсыз.

З а һ и д ә т у т а ш. Мин сезне Суфия тәтәм куйган "Алдым-бирдем" тамашасында күрдем. Ул бит сез язган пьеса.

И с х а к ы й. Публикага ошый, әмма усаллар матбугатта тәнкыйтьләп туймый.

З а һ и д ә т у т а ш. Дөрес язганнары да бар бит, Гаяз әфәнде.

И с х а к ы й. Дөресләре дә бар. Ләкин каян алыйк соң без профессиональ артистлар, артисткаларны? Килер заман, безнең дә театр институтыбыз булыр, анда профессиональ уенчылар хәзерләнер. Бүгенгә әнә шул һәвәскәрләрен үстерик. Ул институтта сезнең тутакаегыз—Суфия ханым да профессорлык кылыр, иншалла. Юкса, хатын-кызларны ир-егетләр уйнарга мәжбүр. Бу бит—пародия, мыскыл. Хатын-кызның битен ачарга кирәк, азат итәргә кирәк.

З а һ и д ә х а н ы м *(олы яшьтәгесе, әкрен генә алга чыгып сөйләшүне тыңлап тора-тора да әйтеп куя).* Ашыкмагыз, Гаяз әфәнде, хатыннар иреккә чыгар, йөзләрен генә түгел... күкрәкләрен дә ачарлар, килер заман, Отеллоны уйнар ир калмас театрларда, ир-егетләрне башкарыр ир-егетләр сирәгәя барыр, ирләр ролен хатын-кызлар уйный башлар, чөнки сакал тагып сәхнәгә чыгарлык озын буйлы чын ирләр калмас, сакалга ябышып йөрүчеләр күбәйгәннән-күбәя барып, хатын-кыз хәрәкәтле ирләр, иршәк хәрәкәтле хатыннар басып китмәсме театрларны? *(Яшь кызлар белән Исхакый киләсе күренешкә әзерләнә.)*

З а һ и д ә т у т а ш. Һо-о, Гаяз әфәнде Исхакыйның генерал утарын зиярәт итүе ул минем өчен тулы бер чор булды. Ул минем дөньяга карашларымны тамырыннан болгатып ташлады...

З а һ и д ә х а н ы м. Гаяз Исхакый зиһенемдә гомер буе утырды, әле һаман

да утыра. Мин анын белән булган хәлләрне язарга да кыжрап йөргән идем, түземлегем житми килде. Башта Исхакый турында язарга түгел, уйларга да ярамады. Хәзер язарга ярый бугай инде. Язсам да ул коры чыгар иде. Тотынмадым. Мин сезгә сөйләрмен, сез теркәп барырсыз. Тарихка калсын, дип сөйлим... Чәегез беткән, хәзер чәй ясыйм...

З а һ и д ә  т у т а ш. Мин бит, язучы әфәндем, рус культурасы, рус әдәбияты, француз, герман әдәбияты, гомумән, Европа культурасына гашыйк кыз идем. Дөресен генә әйткәндә, атам-анам никадәр генә миннән чи татар кызы ясарга тырышмасын, минем күп вакытым рус арасында, рус гимназиясендә, рус дусларым арасында уза иде. Татарларның борынгысын да, бүгенгесен дә белми, анламый идем. Нигә инде ясанып торырга! Мин рус ягына ныклап авышкан гимназистка идем. Татарда фикер ияләре, нәфис сәнгать ясаучылар юк. Татар театрында кеше ышандырып уйнарлык артистлар юк. Театрда профессиональ белем алган сынар режиссер да юк. Татарнын профессиональ музыкасы юк. Татарда чын әдәбият юк. Булганы да суррогат, катнаш, корама, чуплэнгэн... Исхакый белән берничә көн аралашу мине ике яклап үзгәртте. Башта гашыйк булыр дәрәжәдә соклану хисе, соклану фикере биләде мине. Мин мескенгә санап йөргән татарнын шушындый мәһабәт кыяфәтле, татарча сөйләшсә, татарчасы, урысчага күчсә, урысчасынын камил булуы, фәлсәфи фикерләр ташлаштыруы, сөйләгәндә үз фикерләрен куәтләр өчен Европа, урыс, Шәрык классикларыннан дәлилләр китерүе Исхакыйны минем каршыда гына түгел, Мәскәүдән, Петербургтан килгән генерал кунаклары арасында да биеккә күтәрә иде... Еллар буе төрмәдә, сөргендә утырып, кеше җәмгыятенә зарыкканмы ул, әллә язып бетерә алмаган фикерләрен сөйләргә атлыгып кайтканмы, Гаяз Исхакыйнын гайрәте барыбызны да хәйран калдырды.... Ләкин шул ук вакытта беренче сокланулар әкрен-әкрен сүнә барып, кай очракларда хәтта нәфрәткә әверелгәнен сизми калып булмый иде. Исхакый—ул татарский Чацкий иде. Возмутитель покоя, ниспровергатель устоев общества. Суфия апа аңа шундук кушамат такты: резонер-бузотер! Исхакый булган җирдә тынычлык бетә, бәхәс куба. Тын гына ашап булмый. Анын янында нервничать итә башлыйсын. Ул сина тәэсир итә. Башта үзенә тарта, аннары сине кискен рәвештә читкә этәрә. Нииндидер сәер көче бар иде анын. Гаяз Исхакый башка беркемгә дә охшамаган кеше. Суфия апа да аңа башта даһига караган кебек мөкиббән иде. Кызлар белән Гаяз абзыйны утарга алып кайтканга Суфия апанын куануларын күрсәгез. Мәскәү, Питер кунаклары онытыла язды, уртага Исхакый сурәте калыкты: мунча, да коймак та, бәлеш тә, атта йөрешләр дә, спектакль күрсәтүләр дә олы бәйрәм рәвешен алды. Суфия апам белән аларнын уртаклыклары күбрәк иде. Суфия апам профессиональ актриса, Гаяз Исхакыйнын күп бәхәсләр кузгаткан "Алдым-бирдем"ен сәхнәгә куйган режиссер. Сөйләшер сүз күп иде. Сонгы көннәрдә Суфия апамнын да Исхакыйга ачуы чыга башлады. Чөнки Гаяз Исхакыйнын бездән өстен ягы бар иде. Ул без белгән классикларны белә, ә без ул белгән Хайямнарны, Нәсимиләрне, Дәрдмәндләрне, Юныс Әмрәләрне, Мәгарриләрне белмибез. Суфия тәтәмнен шуна ачуы кабара иде булса кирәк. Һәрхәлдә мин үземне Исхакый каршысында унайсыз хис итә идем. Ин беренче бәхәс кичке чәй янында башланып китте. Ул вакытта Толстой да Толстой иде бит инде телебездә. Суфия тәтәм дә, мин дә, башкалар да Толстойга гашыйк, үтереп мактыйбыз, яттан өзекләр укыйбыз.

**Мәйданчык әзерләнеп бетә. Генерал утарында, салонда кич утыру. Кемдер рояльдә моңлана. Кемдер чәй эчә. Кемдер бәйли. Кемдер китап укый.**

С у ф и я. Анакаебыз Толстойнын берничә әсәрен татарчага тәрҗемә итте... Ул да Толстой дип үлеп китә... Сез, Гаяз әфәнде, укымадыгызмы анамнын тәрҗемәләрен?

И с х а к ы й. Начар тәрҗемәләр түгел, ханым-әфәнде. Бер дә начар түгел.

С у ф и я. Их, татарда юк шул Толстойлар, Достоевскийлар, Островскийлар...

И с х а к ы й *(һөҗүмгә әзерләнгәндәй аягүрә баса, уртагарак чыгып, тыеп торылган сабырлык белән).* "Воскресенье"се белән Толстой үзен сызып ташлады! *(Символик шартлау тавышы. Барысы да шөгыльләрен туктата. Рояль та-*

*вышы тына, укыла торган китап шартлап ябыла, бәйләүдән туктыйлар. Кемнеңдер чәй эчәргә дип күтәргән тустаганы һавада асылынып кала. Тынлыкны озаккарак сузып, Исхакый өстәп куя.)* Мин ул әсәрне кабул итә алмыйм. Чөнки ул әхлаксызлыкны аклый, бозыклыкны яклый торган зарарлы әсәр! *(Икенче шартлау яңгырый. Бар да тораташ.)*

С у ф и я. Ничек сез, Гаяз әфәнде, Русиянең икенче патшасы сыман Толстой тиклем Толстойга тел тидерәсез?

З а һ и д ә т у т а ш. Тәүбәгә килегез, Гаяз әфәнде!

Н ә ф и с ә. Авызымнан тартып алдыгыз, Гаяз әфәнде. Мин дә шулай уйлыймын.

Х а н и ф ә. Ә мин килешмим аның фикере белән.

С у ф и я. Берәр рус кешесенә шулай әйтсән, бу татарлар һаман кыргый икән, дияр иде.

**Кызлар, кунаклар арасында шау-шу башлана.**

И с х а к ы й. Көчләде, алдады, кешене фәхешлек сазлыгына төртеп төшерде дә, соңыннан гафу алып, тынычлап, сабый бала кебек, янадан туды. Толстовщина, христиан попларының черек фәлсәфәсе. Кешенең кылган гөнаһларын кеше үзе дә, поплар, епископлар да ярлыкый алмый Алладан башка. Алладан да куәтле адәми затны мин күз алдына китерә алмыймын. Кайда Алла? А где Бог? Көчлә, фәхешлек кыл, соңыннан сине корбаннарың да, поплар да, Алла да ярлыкар. *(Мыскыллы елмаю.)* Нинди каһарманлык Нехлюдов тарафыннан! Ул интегә бичара, үзен-үзе юл газапларына ташлый, Катядан ярлыкау сорап, ялвара-ялвара Себергә хәтле бара. Хуҗасыннан бер сынык икмәк өмет итеп бөтерелгән эт кебек, Нехлюдов Пермьгә хәтле сөйрәлә. Һәм ул Катядан ярлыкау ала. Кешелектән чыккан Катюша ата җинаятьчеләр арасында гомерлеккә сөргенгә китеп бара. Нехлюдов бәхетле килеш иректә кала. Ата җинаятьче Нехлюдов үзен-үзе аклады. Пьеса тәмам. Озакка сузылмаган кул чабулар.

**Мәйданда үзгәреш. Халык тарала. Алгы сәхнәдә Заһидә туташ белән Заһидә ханым.**

З а һ и д ә т у т а ш. Мин төне буе йоклый алмадым. Гаяз Исхакыйның изге даһи Толстойга кизәнүенә җенем чыккан иде.

З а һ и д ә х а н ы м. Ләкин Исхакыйның мантыйгы җенемне тагын да котырта, ачуны китерә иде.

З а һ и д ә т у т а ш. Шулар өстенә мин Гаяз Исхакыйдан мона кадәр мина мәгълүм булмаган ниндидер тәэсир көче ургылганын сиздем. Ул бакчага чыгып йөргәндә мин ерактан, сиздермичә генә аны күзәтә идем. Ни уйлый бу адәм, аның максаты ни? Нинди куәт аны ил буйлый йөретә? Ул төрмәләрне күп күргән революционер, шөһрәтле татар әдибе. Кызганыч ки, мин аның бер генә китабын да укып белмим. Суфия апам аның драмаларын күккә чөя иде.

З а һ и д ә х а н ы м. Башта, Исхакый безгә, утарга килгән көннең икенчесендә без Суфия тутакаем әзерләгән "йорт театры" спектаклен уйнап күрсәттек. Анда кечкенә сәхнә бар иде, үзенә күрә тамаша залы да бар. Как никак, генерал утары бит. Суфия тәтәм "Гроза"дан Катерина монологын сөйләде. Сокландыргыч актриса иде ул Суфия тәтәм. Аның коронный номеры— Катерина.

З а һ и д ә т у т а ш. Мин аны карый-карый ятлап бетердем инде... Олы кунаклар килгән саен Суфия тәтәм үзенен яраткан рольләреннән парчалар уйнап күрсәтә. Ә мин җылыйм. Катеринаны җәлләп җылыйм.

С у ф и я *(Катерина ролендә).* Чирләп егылсам яхшырак булыр иде, ичмасам, юкса, әйбәт түгел. Әллә нинди хыяллар килеп керә минем башыма. Шул хыялларымнан мин беркая да кача алмам. Уйлап карыйм—зиһенемне җыя алмыймын, гыйбадәт кыла башласам—гыйбадәтем барып чыкмый. Телем белән дога сүзләре укыйм, ә башымда чит-ят нәрсәләр кайный: әйтерсең лә колагыма Иблис вәсвәсә пышылдый, әллә нинди ярамаган эшләр турында пышылдап, яман эшләр эшләргә котырта. Шул эшне күз алдына китерсәм, үземә оят булып китә. Ни булды мина? Ниндидер бер афәт килә минем өскә, бу шунын галәмәтләредер! Төнлә йоклый алмыйм мин, Варя, һаман серле пышылдаулар колагыма ишетелә: кемдер шундый назлы сүзләр сөйли кебек тоела, әйтерсең, ул мине иркәләп сыпыра, әйтерсең, күгәрчен гөрли яным-

да. Хәзер инде элеккеге кебек җәннәт агачлары да, мәһабәт таулар да төшемә керми; әйтерсен лә мине кемдер кочаклый, кысып-кысып кочаклый да әллә кайларга алып китә, мин аның артыннан карусыз барам да барам, барам да барам... Аһ, Варя, минем уем—гөнаһлы уй! Ничә тапкырлар, мин бичара, җыладым, ниләр генә эшләмәдем үземә! Кача алмыйм мин ул гөнаһтан. Беркая да кача алмыйм. Яхшы түгел бит бу эш, иеме, Варенька, башканы сөю—ул коточкыч зур гөнаһ бит, иеме?.. Нишләргә сон мина! Көчем бетте тәмам. Кая барыйм, бу сагыштан мин үземә бер-бер хәл кылачакмын!.. Әгәр дә мин аның белән бер генә тапкыр күрешсәм дә, өйдән качып китәчәкмен, дөньяда әллә ниләр булса да мин кабат өйгә әйләнеп кайтмаячакмын.

**Монолог тәмам. Тамашачылар гөрләтеп кул чаба: "Бис, браво, афәрин" кычкыралар.**

З а һ и д ә т у т а ш. Аннан соң без—Нәфисә, Ханифә, Аскәр жизни—кечкенә күренешләр уйнадык. Тамаша тәмам булгач, табын янына утырыштык. "Худсовет утырыш"ы башланды.

З а һ и д ә х а н ы м. Исхакый сөйләгәннәрнен бөтенесе дә истә калмаган, әмма ике сүзе гомерлеккә бәгыремә уелган иде. Мин аларны гомерем буе онытмадым.

И с х а к ы й. Заһидә туташ... сез артистка булып тугансыз! Сезгә уйнарга да уйнарга кирәк. Олы артистка булыр өчен сезнен бөтен жирегез житеш, ин нигезлесе: сезнен эчтә актерлык гайрәте посып ята. Сездә күкрәктән чыга торган калын тавыш, зифа буй һәм ин әһәмиятлесе: сезнен күнел күзегез сукыр түгел!

З а һ и д ә т у т а ш. Суфия тәтәмнен бераз кәефе китте... Ничек инде ул? Петербургта "Высшие драматические курсларны тәмамлаган, дипломированная артистканы" мактамыйча, ниндидер һәвәскәр кызнын уенын мактап утыралар... Мина унайсыз булып китте... Ләкин Гаяз Исхакый кесәсендәге ташны ыргытмаган иде әле. "Катерина"га биргән бәясе безне аяктан екты.

З а һ и д ә х а н ы м. Мин бүген дә әле шул турыда уйлыйм. Ниндидер күләмдә мин Исхакыйнын мантыйкый фикер йөртүенә шаккатам. Ул мина кайчак мәкерле даһи, котыртучы Иблис булып күренә башлады. "Суфия ханым", дип башлады кунагыбыз.

И с х а к ы й. Суфия ханым! Сезнен төп ялгышыгыз, гомер буе үкенәчәк язмышыгыз менә шушында—генерал утарында булыр. Сез бары тик домашний театрда гына баш рольләрне уйнаячаксыз! Шушы оештыру сәләтегезне кухаркаларга режиссер булып, шушы буйсын, шушы актерлык гайрәтегезне вакытлыча гына ялга килгән кунакларга "Леди Макбет", "Катерина"ларны уйнап, куәгезне, чынлыкта, заяга исраф итүегез—сезнен олы сәнгать алдындагы жинаятегез, ханым-әфәнде!

С у ф и я *(сабыр булырга тырышып).* Минем шәхси тормышымны көйләргә тырышуым жинаятьме, Гаяз әфәнде?.. Сезнен Болгарскаяларыгыз, Волжскаяларыгыз кебек шәһәрдән-шәһәргә, Мәкәрҗәдән Мәкәрҗәгә хәер эстәп йөрергә тиешме мин?

З а һ и д ә т у т а ш. Мәҗлескә гауга оеткысы салынган иде инде. Суфия апа эчтән кайный башласа да, үзен тыныч тотарга тырыша, Гаяз әфәнде сокланырлык дәрәҗәдә тыныч иде, әйтерсен лә, ул барысын да алдан белә, үзенә каршы төшәчәкләрен дә, аны сөймәячәкләрен дә ул сабыр кабул итәчәк.

С у ф и я. Сезгә, Гаяз әфәнде, тәрбия дәресләре бирелмәгән, бирелгән булса да сез ул тәрбияне тәрмәдән тәрмәгә йөри торгач, җуйгансыз!

И с х а к ы й. Суфия ханым... мин ихластан, чын күнелдән әйттем бу сүзләремне. Тупасрак әйтелгән икән, бу минем сезнен язмышыгыз өчен борчылуымнан килә... Сез талантлы артистка. Сез никадәр талантлы булсагыз, профессиональ театрда уйнамыйча, шул кадәр микъдарда халыкка зыян китерәсез. Алайса, сез ни өчен артистлыкка укыдыгыз? Вакыт һәм, ниһаять, гаиләгезнен акчасын сарыф иттегез...Адвокатлыкка укыган кеше мал карауга күчсә, ул адвокат булудан туктый. Анын укыганы бушка оча. Сез генерал утарындагы кухнә артисткасы... Сез бит Мирсәлимова кушаматы белән уйнаган рольләрегездә тамашачыны аяктан ектыгыз. Нигә ул талант генерал утарында харап була?

З а һ и д ә х а н ы м. Гаяз әфәнде авырткан жирнен кайсы төшенә басарга кирәклеген бик яхшы белә иде кебек. Шул ук вакытта ул комплиментлар да

әйтергә онытмый. Аның “сез талантлы артистка” дигәне хуҗабикәбезнен ярсыган күңелен йомшата төште.

И с х а к ы й. Чыннан да, сезнен бүгенге уеныгыз мине хәйран калдырды. Катеринаны әле болай итеп, җан әчесе белән башкарганнар сирәк иде. Татар сәхнәсендә бөтенләй булмады. Ләкин бу “Катерина” шушында—утарда гына калачак... Тик мин әйтергә тиеш булып чыгамын ки, сез Катеринаны башка бөтен артисткалар кебек, романтик рухта шәрехлисез, аннан саф лирика эзлисез һәм, әйтергә кирәк, сез аны табасыз да. Хикмәт лирикада да, артисткаларның образны гел бертөрле шәрехләвендә дә түгел... Хикмәт Катеринаның әхлаксыз хатын булуында!

**Шартлаган тавыш ишетелә. Барысы да тораташ булып кала.**

З а һ и д ә т у т а ш. Ашау онытылды. Чәй онытылды. Мин куырылып килдем. Бу юлы мине курку, ачу һәм кызыксыну—бөтенесе бергә биләп алды. Дәресләрдә, матбугатта Катеринаның мәхәббәтен Джульетталар, Ләйләләр хисе белән бер дәрәҗәгә куярга өйрәтәләр иде. Шул хисләрдә тәрбия алганнар өчен бу арттан пычак кадауга тиң иде. Бу юлы кычкырышу булмады. Ләкин киеренкелек һич тә кимемәгән, шул киеренке тынлыкта без бу вакыйганың дәвамын көтә калдык. Дәвам озак көттермәде. Гаяз әфәнде үзе дә киеренке халәттә иде бугай, ул кыза бара, аягурә торып һөҗүмгә күчте.

И с х а к ы й. Анна Каренина кебек, Катерина да бозык күңелле хатын. Тихон начар ирме? Катеринаның торырга яхшы өе, киярга яхшы киеме, ашарга затлы ризыгы—барысы да бар. Яшә, балалар тап, аларны үстер. Мал таба торган иренне тәрбия кыл. Юк! Катерина һич гаепсез, гөнаһсыз, ипле ирен күрә алмый. Маена чыдаша алмыйча, ул башка ир, мәһабәтрәк ир, яхшы сөяркә эзләп, капканы, коймаларны җимереп чыгып чаба.

Н ә ф и с ә. Ул бит чынлап гашыйк, аның чын мәхәббәте шул Кудряшка.

Х а н и ф ә. Сез, Гаяз әфәнде, мәхәббәтне инкарь итәсезмени?

И с х а к ы й. Инкарь итмим! Шундый тилергән гашыйклык нигә китерә? Фаҗигагә! Матур көр гаилә җимерелә. Бу әхлаксызлык христиан кануннарына да, башка дин кануннарына да сыймый! Катерина котырган женси ихтыяҗын үз ире белән канәгатьләндерә алмагач, гайрәтлерәк ир эзли һәм әхлак киртәләрен җимерә. Гаиләсен бәхетсез итә.

С у ф и я. Это банально! Это оскорбление чистых чувств, господин Исхаков!

Н ә ф и с ә. Чын сөю, чын мәхәббәт сезнеңчә ничек булырга тиеш соң?

И с х а к ы й. Әле укылган монологны гына алып багыгыз сез. Катерина үзен үзе котырта, үзен үзе алгысыта, хәттин ашкан хисләрен тыясы урында, ул аларны өстерә-өстерә, котырта-котырта үзен гөнаһ кылырга әзерли. “Чын сөю, чын мәхәббәт” гыйбарәләре үз бозыклыгын каплар өчен калкан гына!

Н ә ф и с ә. Какой ужас!

Х а н и ф ә. Адәм страмы!

С у ф и я. Сез бик примитив фикер йөртәсез. Сез Таһир - Зөһрәләрнең изге рухын рәнҗетәсез, Гаяз әфәнде!

И с х а к ы й. Каренина да шул ук тип түгелмени, әфәнделәр, ханымнар вә туташлар? Каренин һәйбәт хуҗа, яхшы ир, малы бар, абруе бар. Анна да Катерина кебек үзенә башка юаныч таба. Бөтен дөнья шушы тотанаксызлыкны мактый. Шулай булырга өйрәтә. Тормышта да һәр хатын үзенең Вронскийларын, Кудряшларын эзли чыга. Тыелган мәхәббәт барысын да юа, дигән зарарлы формула уйлап, бозыклыкка, йөгәнсезлеккә атыла.

З а һ и д ә т у т а ш. Гаяз әфәнде боларны ихластан сөйлиме, әллә безне үртәр өчен генә бу бәхәсләрне уйлап чыгардымы, һич аңлап булмый иде. Әллә ул бары тик безне—“генерал утарында бурсып яткан буржуйларны” уятыр өчен генә, мәҗлесне кыздырыр өчен генә сөйлиме? Әмма аның бу кыланышларында ниндидер мактану, “күпбеләмлек” галәмәтләре дә чагыла иде кебек. Чыннан да ул оригиналь фикер иясе булып чыкты. Гаяз әфәнде арлы-бирле йөренгән җиреннән кинәт китап шкафы янына килеп, Толстойның “Анна Каренина”сын алды, арткы битен ачып, һич тоткарлыксыз, әйтерсең лә ул бөтен текстны алдан әзерләп куйган—укып китте..

И с х а к ы й. ... “Через месяц Алексей Александрович остался один с сыном на своей квартире, а Анна с Вронским уехала за границу, не получив развода и решительно отказавшись от

него.”... Ана кеше үз баласын, баланың атасын ташлап качты. Үз баласыннан баш тарткан хатынны мин беркайчан да аңлый алмаячакмын.

Н ә ф и с ә. Ул бит Вронскийны ярата! Ул аннан башка яши алмый.

И с х а к ы й. Бозыклар калканы, Нәфисә туташ! Бала анасын яратмый идемени? Каренин Аннаны сөйми идемени? Анна үзен һәм Вронскийны бәхетле итте. Ике кешене—ирен һәм баласын бәхетсез итте.

С у ф и я. Толстой Аннаның фаҗигасен күрсәтә.

И с х а к ы й. Суфия ханым, сезнең матур кызыгыз бар. Сез хәзер берәр килмешәк барчукка гашыйк булып, иregезне, кызыгызны ташлап качар идегезме?

С у ф и я. Гаяз әфәнде, Толстой: Анна Каренина кебек булыгыз, дип аны үрнәк итми бит. Аның фаҗигасен күрсәтә.

И с х а к ы й. Аклый ул аны—Толстой!

С у ф и я. Минемчә, сез Толстойның бөек язучы булуын кичерә алмыйсыз, Гаяз әфәнде. Аннан сез көнләшәсез. Сез үзегезне “Мин татарның Толстое” дип игълан итмәкче буласыз, күрәм.

И с х а к ы й *(көлә)*. Толстой белән мине чагыштырырга ярамый, Суфия ханым. Толстойның аның эш башка. Аның урыс халкына ирек даулап, дин ирege, тел ирege, йола ирege яулап зинданнарда утырасы юк. Яшерен корылтайлар оештырып, һәр идән тактасы шыгырдаган саен бу шпик түгелме дип тын алырга да шүрләп ятасы юк. Телемне бетерәләр, мәктәпләремне, мәдрәсәләремне туздыралар, талыйлар, мәчетләремне кыралар, муллаларымны каторгага аткаралар, олау-олау төяп алып чыгып тарих китапларыбызны, халык әсәрләрен яндыралар, дип кайгырасы юк. Ул бары тик иҗат белән мәшгуль. Без төрмәдә туганбыз, төрмәдә иҗат итәбез. Безем бөтен чабалануларымыз милләтебезне йота торган балыктан коткарып калу өчендер. Менә сез дә, ханым әфәнде, үз “Ясная поляна”гызда ятасыз, язгыз сез дә Толстой кебек. Сезгә яна сауган сөт китерә татар крәстияне, сезгә бүген суйган мал ите китерә, ашата, татар мескеннәре. Сез дә граф, генерал, сез дә Толстой. Мин бары тик татар милләтенең инкыйразын тоткарларга алынган әдип кенә.

С у ф и я. Укыдык без сезнең ул әсәрегезне. Сез татар халкының тәкъдирен алдан әйтеп бирүче оракул, әүлия булып күренергә, татар халкының бердәнбер милли каһарманы булырга дәгъва кыласыз.

И с х а к ы й. Сез бик тә төгәл анлагансыз мине, Суфия ханым. Мин дәгъва кылсам да, кылмасам да, мин инде милләтебезнең каһарманы урынында. Сез тиздән, ун-егерме елдан мин әйткәннәрнең хак икәнен анларсыз. Ләкин соң булыр. Инкыйраз инде сезнең нәселне кискән. Сезнең тамырны гына түгел, бөтен милләтнең тамырын кисү ихтималияте мангаебызда.

С у ф и я. Кем кисә, кем милләтне инкыйразга илтә, әфәндем? Милләт үзүзеннән кача. Үз теләге белән рус-европа культурасына тартыла. Үз теленнән үзе кимсенә. Чөнки аның культурасының тарту көче зәгыйфь.

И с х а к ы й. Милләт шундый шартларга куелган. Кешене үзе асылынып үләр дәрәҗәгә житкезәләр дә, ул үз ихтыяры белән дөньядан китте, дип акланалар. Мәрхүмне үз ихтыяры белән китәргә мәҗбүр иттеләр. Бу—саф сафсата, демагогия, ханым. Бу сафсата шовинистлар, бетәргә йөз тотканнар өчен бик жайлы шәй. Менә сезнең гаиләне алыйк. Урыс армиясенең татар генералы. Атаклы Тәфкил бәктән килгән нәсел. Сезнең гаиләдә генә дә инкыйраз үзе чәчәк ата. Сезне, атаклы Шаһбазгәрәй Әхмәров кебек затлы мәгърифәтчебезнең кызы, югары белем алган кызы утар саклап ята. Һәм аның үз кызы Динәрә дә татарча белми кебек. Тагын бәбәегез булырга тора. Аларның балалары татар булып үсәр, дип кем кистереп әйтә ала? Сез балагыз белән урысча сөйләшәсез. Татар китаплары күрмим китапханәгездә, урыс, француз китаплары. Бала Ана телендә укый алмый икән, сөйләм телен белсә дә, ул тулы канлы татар кешесе була алмый. Мәгърифәт—азатлык юлындагы беренче адым! Ана сөте белән ачылмаса, баланың теле башка тел белән ачылачак. Ханнар заманасыннан килгән дүрт затлы нәсел: Алкиннар, Әхмәровлар, Тәфкилевләр, Шәехгалиләрнең токымы тө - кән - де! Бетте күз алдында! Ике йөз елга да житмәячәк татарның гомере, әгәр шушылай барса!

З а һ и д ә х а н ы м. Мәҗлес таралды. Барысының да борыннары салынкы, күңелләре төшенке иде. Гаяз әфәнде бакчага чыгып китте. Озак күренмәде ул.

Әллә ничек булды шунда... Мин аны эзләп киттем.

З а һ и д ә т у т а ш. Гаяз әфәнде урман кырында, басуда жир сукалап азапланучы кешеләргә карап тора иде. Ни уйлый иде икән ул? Белмим. Крәстияннең авыр тормышы турындамы? Әле генә булып узган бәхәсләр турында уйлый идеме? Мин ерактан тамак кырдым... Эһем-эһем... Сез борчылмагыз, Гаяз абый. Суфия апам тиз оныта ул... Инкыйраз турында сез дөресен әйттегез... Сез шул турыда уйлый идегезме, кичерегез.

И с х а к ы й. Юк, туташ... Мин кызым турында уйлый идем.

З а һ и д ә т у т а ш. Кызыгыз турында? Ә ул кайда соң?... Гаяз Исхакый кызы Сәгадәтнең туган авылында яшәве, төрмәләрдән-төрмәләргә йөрийөри сирәк күрешүләре, кызын тәрбияләргә вакыты булмавы турында сөйләде. Ул бик житди иде. Хәтта моңсу да иде кебек. Шул көннән соң без, төшке аштан соң гел бакчадагы агачлар арасында икәү генә йөри башладык... Күрешкән саен сәер хисләр били мине. Бу кешенең оригинальлеге мина бик тә охшый иде. Монарчы: какшамас хакыйкать, дип уйланылган төшенчәләргә башка яктан каравы мине аңа этәрә иде. Шул ук вакыттта аның үзеннән читкә куа торган, синең фикереңне инкарь итеп, бары тик үзенеке генә дөрес, дигән шикелле катгыян әйтеп, мишәрләргә хас турыдан яруы белән күңелгә ятып бетми торган катлаулы шәхес иде ул Гаяз әзи... Әйе, бу кеше яхшы күңелле зат, әйе, бу кеше каһарман, бу кеше оригиналь фикерли торган, укымышлы, талантлы шәхес. Ләкин аның белән еш очрашу, озак сөйләшү сине ардыра. Аннан тизрәк котыласы, качасы, ял итәсе килә башлый. Бераз вакыт күрешмичә торсаң, тагын ана тартыласың. Безнең бик еш икәүдән-икәү генә урманда йөрүебезгә Суфия апамның эче поша башлады.

С у ф и я. Әллә шуңа гашыйк булдыңмы, тиле кызый?

З а һ и д ә т у т а ш *(үртәп)*. Нигә, тәтәм? Гашыйк булмаслыкмыни ул? Бик оригинальный әзи.

С у ф и я. Шашкан! Син сабый гына әле.

З а һ и д ә т у т а ш. Уналты яшьлек сабый буламыни, апам?

Су ф и я. Арттырма! Сиңа унбиш кенә әле.

З а һ и д ә т у т а ш. Тынычлан, тәтәм, минем баш алай гына югалмас. Аның алты яшьлек кызы бар. Аннан соң аның игътибары миндә түгел, тәтәм. Сара апамда!

С у ф и я. Анысын каян алдың тагын, тилергән кызый?

З а һ и д ә т у т а ш. Интуиция, күңел сиземләве.

С у ф и я. Сараның тимер йөрәген ватып керергә Гаяз абзанның көче житмәс! Бала өстенә, тол иргә барырга Сараның башына тай типмәгән.

З а һ и д ә т у т а ш. Сара апама егерме жиде яшь, сайлана торгач, карт кыз булып утырып калды инде ул. Гаяз абзыйга утыз алты бугай, апама егерме жиде, суйган да каплаган. Балалы толга бармыйча, кемгә барсын? Вакыт узган, тәтәм.

С у ф и я. Син инде барысын да чутлап куйгансың, кызый.

З а һ и д ә т у т а ш. Көннәрдән бер көнне Гаяз әфәнде ялгызы гына йөреп, кич белән, караңгы төшкәч кенә ахшам ашына кайтты. Аның иртәгә иртәнге пароходка өлгерәсе бар иде. Ул кичне без йокламадык. Гаяз әфәнде дә йокламады. Аның кыяфәте басынкы, сагышлы иде. Әллә ул генерал гаиләсенә алып килгән бимазалы, гаугалы бәхәсләре өчен борчыламы? Әллә аны башка берәр нәрсә бимазалый идеме? Белмим. Әмма кичке табын янында үз гаебен юарга теләгәндәй, ул сагышлы гына елмаеп, сүз башлады...

И с х а к ы й. Заһидә туташ дөнья әдәбияты, урыс әдәбияты мөгаллимәсе булырга жыена. Бик хуп. Мин, чыннан да, бу эшегезне мактыйм. Сез чыннан да урыс әдәбиятына гашыйк туташ. Сез яхшы мөгаллимә, яхшы артистка булырсыз. Урыс әдәбиятының шаһ әсәрләрен татарчага тәржемә итәргә кирәк. Әлбәттә, минем алда сөйләгәннәремне сез кабул итә аласыз, кабул итмәскә дә хаклысыз. Сүз юк, урыс әдәбияты зур, бай әдәбият, андый бай әдәбият нинди-дер тәнкыйтьтән генә кечерәймәс. Ләкин һәр укыган әсәр турында синең үз фикерең булырга тиеш. Өстән, рәсми тәнкыйть тарафыннан ирексезләп тагылган фикер түгел. Кечкенә булса да—үз фикерең. Фикерегезне катгыян канун итеп куймасагыз да, үз шәрехегезне бәян итәр дәрәжәдә мәгълүматка ия булыш кирәк, ханымнар, әфәнделәр. Алыйк Гогольнең "Ревизор"ын. Заһидә туташ,

сез ничек уйлыйсыз, нәрсә ул "Ревизор"?

З а һ и д ә т у т а ш. Ачуым килде! Гимназиядә Гогольне миннән нык белгән кеше юк иде. Алтын медальне әдәбият белгечен башлангыч сыйныф баласы дип белдеме? Миннән имтихан ала, имеш. Дәшмәдем.

И с х а к ы й. Суфия ханым, сез ни уйлыйсыз "Ревизор" турында?

С у ф и я *(кыланып)*. "Великая сатира на царскую действительность. Сатира на самого Николая Первого. Друг Герцена Сазонов говорил, что героем "Ревизор"а является никто иной, как Николай, превращенный в мелкого чиновника. Гоголь творил суд над Николаевским режимом!" Во! Госэкзамен бирдек!

**Барысы да, Исхакый да рәхәт көлә. Исхакый кинәт җитдиләнә.**

И с х а к ы й. Браво! Афәрин! Суфия ханым! Хрестоматияләрнең барысында да шулай язылган. Гогольнең батырлыгы—Николай патшаны сатира утына тотуда, диләр гасырлар буена. Имеш, пьесада бер генә уңай каһарман да юк, барысы да тискәре, әхлаксыз, ришвәтче һәм башкалар. Әйе, бу сүзләрне язып калдырган галимнәр, тарихчылар хаклы да кебек. Әмма әйдәгез әле бераз гына уйлап багыйк сана, хөрмәтле господалар! Нишләп әле пьесада уңай персонажлар булмасын?.. *(Тынлык.)* Кем ул яки кемнәр алар уңай персонажлар?

Б а р ы с ы д а. Андый персонажлар әсәрдә юк!

И с х а к ы й *(мохитне кулга алган, җиңгән кыяфәттә)*. Тарих укытучысы уңай каһарман түгелмени?.. Ә?.. Ул талантлы укытучы түгелмени? Ә? Үл үз фәнен белеп, сөеп, балаларга хакыйкатьне яхшылап аңлатырга теләмимени? Ә?

Н ә ф и с ә. Нинди тарих укытучысы?

Х а н и ф ә."Ревизор"да андый кеше юк.

С у ф и я. Бар, ләкин ул сәхнәгә чыкмый.

И с х а к ы й. Чыкмасын! Яхшы, талантлы укытучы шул мохитнең бер кисәге түгелмени? Аның образы городничий сөйләвендә сәхнәгә уңай образ булып килеп чыга. Димәк, шул черегән мохиттә дә саф күңелле кеше яши. Ул тарих фәнендәге гаделсезлекләргә түзеп тора алмый, кафедрасыннан чыгып, урындыкны дөмбердәтеп, ялган тарихчыларга нәгърә ора, гаделлек өчен көрәшә. Менә сезгә бер уңай каһарман, господалар!.. Городничий—Антон Антоныч Сквозник-Дмухановский да мотлак тискәре образ түгел, җәмәгать. Аның да бит яхшы кешеләргә хас яклары бар... Әйе, әйе, беркая яшереп булмый аның кешелекле якларын. Әйтик, ул еш кына мәктәпләргә барып, уку-укыту эшләрен тикшереп йөри икән. Дәресләргә кереп утыргалый. Мәктәп җиһазлары турында да кайгырта. Кайсы шәһәр башлыгының дәресләргә кереп утырырга вакыт тапканы бар? Бу да городничийның уңай яклары. Дөрес, ул озак еллар утыруы аркасында мүкләнгән, симергән, гамьсезләнгән, ришвәткә баткан... Суфия ханым чәй яңарттырмассызмы? Тамак кипте... *(Чәй китерү белән мәшгульлек.)*... "Ревизор"ны менә шушы тарафтан бераү дә сезгә аңлатып бирмәс, әфәнделәр. Бу әсәрне дөньяда өч кенә кеше шушылай аңлата алган булыр иде. Аларның икесе инде күптән мәрхүм. Мин әле исән, шөкер... Моннан соң инде сез дә шушылай аңлата алырсыз, шәт... Госпожа присяжные! Мәҗлесебезнең иң югаргы нокта-и назарына килеп җиттек... "Ревизор"ны, әлбәттә, һич шик юк ки, патша хәзрәтләре Беренче Николай укып чыккан. Укып чыккан, сәхнәгә куюны тыймаган. Үзеннән көлгән әсәрнең премьерасына тәхет варисын - улын ияртеп килгән. Галерка тулы студентлар. Балконнар тулы урта чиновниклар, партер тулы югары даирәләр. Ул моноклыләр, ул биноклыләр, ялт та йолт. Чышы-пышы киләләр. Имеш, авторны, Николай Васильевичны патша хәзрәтләреннән каһкаһә белән көлгәне өчен, бүген үк, спектакльдән соң Себергә, каторгага алып китәчәкләр икән. Бельэтажда Гогольнең дуслары—Пушкиннар, Мусиннар, Огаревлар, Стасовлар. Партер тулы Гогольнең дошманнары: Булгариннар, Вигельләр утыра. Сәхнәгә керә торган арткы ишек янында, урамда кара киемле җандармнары белән кара карета тора. Ул карета дәүләткүләм ата җинаятьче Гогольне Әби патша юлы белән Себергә алып китәчәк. Керә алмый калганнар, билет табалмаганнар шул карета ягына тупланганнар. Спектакльне карап булмаса, авторын алып киткәнне карап калырга исәпләре. Спектакль башлана. Спектакль бетә.

Залда кара тынлык урнаша. Сәхнәдә артистлар катырып куйган мумияләр шикелле, төрлесе төрле позада баскан. Залда тамашачы торараш булып каткан. Нишләргә кирәк икәнен берсе дә белми. Кул чабаргамы, әллә сызгырыргамы, әллә "долой" дип кычкырыргамы? Хәтта ни кыю галерка да, студентлар да хәрәкәтсез утыра. Әле яңа гына сәхнәдә Русиянең ришвәтчеләре, әхлаксыз чиновниклары, Русиянең моделе булган "N" шәһәрендәге казна акчасын талаучылар турында спектакль уйналды. Залдагы чиновникларның күбесе үзен таныган. Барысы да Николай патшага текәлгән. Шушы сатирадан, мыскыллардан соң патша нишләр? Николай патша сәхнәгә баккан килеш тик утыра. Шуннан соң ул ак бармакчалар кигән кулы белән учына чабып:—Браво, Гоголь! Брависсимо, ди. Шуны гына көтеп торган куштаннар, патшаның әнчекләре, ишетелер-ишетелмәс әйтелгән сүзне куәтләндереп, бөтен залга кычкыралар. Браво, Гоголь, брависсимо! Аларга галерка, балконнар, бельэтаж, партер кушыла. Барча халык аягурә басып уңышны алкышлый. Гогольне алып китәргә әзер торган кара карета эшсез кала. Халык актерларны, драматургны котларга сәхнәгә ыргыла, чәчәкләргә күмә... Әфәнделәр, ханымнар! Николай патша ни өчен "Ревизор"га кул чапкан? Ни өчен ул үз системасын әче сатирага тоткан Гогольне алкышлаган?.. Чөнки Николай патша укымышлы кеше була. Ул сәнгатьне залда утыручы барча кешедән дә тирән аңлый торган шәхес булган. Гоголь үзе генә аңлаган кинаяне, әсәрнең тел төбен бер Николай патша аңлаган. Әгәр дә ул шул табышмакның җавабын тапмаган булса, пьесаны куйдыртмас иде, куйдыртса да тыяр иде. Гогольне Себергә сөрер иде. Аңлаган, чөнки Николай Васильевич Гоголь үзенең "Ревизоры" белән Николай патшаның гадел патша булуына мәдхия җырлый!

З а һ и д ә т у т а ш. Без могҗиза ясаучы, күз буучы, оста фокусник концертында утырган кебек булдык. Чыннан да, кунак бүлмәсендәге кешеләр сәнгатьне тирән белүче, тирән аңлаучы дворяннар иде. Мин дә дөнья әдәбияты буенча белгечлек дипломы алырга җыена торган туташ. Гаяз әфәнде бөтен мәсъәләләргә безнеңчә карамый, аның карашы, аның күрү сәләте безнекенә охшамаган. Ул көзгенең теге ягында йөри. Без аны көзгенең тискәре ягында йөри дип уйлыйбыз, баксаң, үзебез тискәре якта түгелме? Без фокусны карадык та шаккаттык. Инде хәзер фокусның серен беләсебез килә.

И с х а к ы й. Хлестаков бит ялган ревизор. Ана ришвәт бирәләр, ул ала, аңа хатын тәкъдим итәләр, ул аны да ала. Ә чын ревизор килә калса, боларның эш харап. Аларның өстенә бомба төшәчәк. Икенчесе, чын ревизор, Николай патша гаделлек урнаштырырга җибәргән ревизор ришвәткә сатылмаячак. Ул городничий йортында кунак булып ятмаячак. Ришвәтчеләргә Николай патшаның кылычыннан котылу юк. Жандарм кереп әйтә ич: "Приехавший по именному повелению царя из Петербурга чиновник требует вас сей же час к себе. Он остановился в гостинице",—дип, барысының ушын ала. Менә шуннан соң катнашучыларның барысын да яшен суга. Николай патшаның гаделлек яшене! Николай Гогольне түгел, үзен алкышлаган!

**Ат караучы керә.**

А т к а р а у ч ы. Әфәнделәр, атлар җигүле!

С у ф и я. Нәрсәләрне ташый торыгыз!

И с х а к ы й. Суфия ханым, барыгызга да күп-күп рәхмәтләрем... *(Көлә).*

З а һ и д ә т у т а ш. Безне тораташ итеп катырды да, үзе көлә!

И с х а к ы й. Китәр алдыннан серне чишим инде, бүленеп калмасын. Әфәнделәр, мин сезнең алда шамакайландым. Фәлсәфә куерттым. Минем халкымны фикерләргә өйрәтәсем килә. Шуңа күрә чарасызлыктан үзем килешмәгән нәрсәләр турында сөйләнгән булам. Каршы төшегез, бәхәстә ачыла хакыйкать... Шөпшә оясына таяк тыгып болгау, дип атала бу номер. Ә Толстойны мин бик хөрмәт итәм. Яратам хәтта. Мин аның ике бөек әсәре өчен җанымны фида кылырга да риза. "Хаҗи Морат" белән "После бала" хикәясе өчен. Нинди олы язучы ул Лев Николаевич Толстой! Чечняны, Кавказны яулап алучы урыс гаскәренең офицеры була торып, милли азатлык өчен көрәшүче татарларга, чеченнәргә нинди соклану белән яза ул. Аларны кимсетә торган ярты кәлимә сүз дә кулланмый. "После бала"сы да татарларны яклап язылган әсәр бит. Армия полковнигынын шәрә

татарның сыртын шпицрутеннар белән чиләндереп кыйнатканын күреп, *(бу кыйналудан соң татар кешесенең исән калуы икеле!)* урыс егете Иван Васильевичның полковникның кызына бөреләнгән мәхәббәте сүрелеп, полковникка нәфрәт булып әверелә. Бөек әдипләр беркайчан да урыс булмаган халыкларны рәнҗетмиләр. Рәхмәт Лев Толстойга. Жюль Верн "Сиксән мең чакрым су астында" китабында христианнар тарафыннан халкы кол ителгән, шул халыкның вәкиле капитан Немо—һиндлы бит. Халкының галелсезгә кырылганы өчен Немо ак тәнлеләрдән үч ала. Жюль Верн христианнарны башка диндәге халыкларга миһербанлы булырга чакыра. Бөек язучы. Проспер Мериме "Кармен" әсәрендә чегән хатыны белән аз санлы баск егетенең язмышы өчен борчыла. Испаннар-христианнар аларны кешегә дә санамый. Мериме үзенең үлмәс шедевры белән христиан булмаганнарны яклап чыга. Шул түгелме интернациональлек, әфәнделәр? Русиянең төп халкыннан да мин шуны ук өмет итәм.

Н ә ф и с ә. Гаяз әфәнде, ә инкыйразны туктату юлларын сез әйтмәдегез.

И с х а к ы й. Татар милләтенең үз кабыгына гына бикләнеп, кадимчә яшәвен мин хупламыйм. Бу киречеллек, ягъни консерваторлык булыр иде. Европага тинләшәм, дип, йолаларны ташлап, телне мыскыл итеп, ажгырып урыслашуга женем белән каршы. Ул милләтнең тәмам бетүенә китерер. Димәк, урталыкны сайларга кирәк. Шуның өчен җәдитчелекне башладык. Урталыкны тотарга форсат булмаганда, тулысы белән йотылуга караганда, мин алга китмичә, хәтта артта калып, милләтне бербөтен итеп саклар идем. Узар вакытлар, халык исән булса, артта калганлыкны бетереп булыр. Озакламый татар кимсетеп карый торган халыклар татарны куып житеп, узып китәчәк. Чөнки алар артта калып, үзләренең бербөтенлеген саклап калачаклар.

Н ә ф и с ә. Кайсы халыклар инде алар татарны узып китүче?

И с х а к ы й. Чуаш, казакъ, төрекмән, башкорт... Килер форсат, алар алга китәр, ул вакытта татар артта калыр...

Н ә ф и с ә. Булуы мөмкин түгел. Чуаш белән казакъмы татарны узып китәчәк халыклар? Бу кеше ышанмаслык сүз, Гаяз әфәнде!

И с х а к ы й. Ышанырсыз әле. Хакыйкать алдына китереп бастырсалар.

С у ф и я. Китабыгыз өчен күп рәхмәтләр, Гаяз әфәнде.

И с х а к ы й. Суфия ханым, Заһидә туташ, сезнең урыныгыз сәхнәдә, кайтыгыз Казанга.

**Барысы да китәргә җыена. Заһидә туташ алга чыга. Артта шау-шу, хушлашу.**

З а һ и д ә т у т а ш. Таң атып беткән. Мин әле һаман сихердән айный алмый торам. Гаяз әфәнде тапшырган шулкадәр мәгълүматны баш тиз генә пешереп бетерә алмас. Нинди сәбәпләр белән чуаш алга китәр, казакъ татарны узар? Казакъ далаларында татар мулдәкәләре казакъларга хәреф өйрәтә, Урта Азиясендә татарлар башка халыкларга кино, театр оештырып йөри. Ничек итеп алар татарны уза алыр икән? Мин аңламыйм... Шулай да Гаяз Исхакыйның олы җинүе иде бу. Хушлашканда ул минем кулымны кысты, елмайды, бимазалар китергәне өчен гафу сорау кебек иде аның елмаюы. Шул чагында ул миңа бөтен инсаниятне сөюче Хозыр Ильяс кебек күренде. Нәфисә, Ханифә—өчәү аны пристаньга озата төштек. Пароход кычкыртты.

И с х а к ы й. Бәхил булыгыз, туташлар! *(Пароходка сикерә.)*

К а р а Ш ә ү л ә *(пәйда була)*. Стой! Туктатыгыз пароходны!

З а һ и д ә т у т а ш. Пароход сузып кычкыртты. Чулман өстенә сагыш моңы таралды.

К а р а Ш ә ү л ә *(яр астыннан менә)*. Утыра алмый калдым, нәләт.

Н ә ф и с ә. Бу нинди сурәт тагын?

Х а н и ф ә. Исхакый артыннан тагылган койрык.

К а р а Ш ә ү л ә. Извозчик!

Н ә ф и с ә. Хәзер килер навозчик!

К а р а Ш ә ү л ә. Навозчик димим, извозчик, дим, кызыкай.

З а һ и д ә т у т а ш. Чуаш, казакъ, башкорт халыклары ничек итеп татар милләтен куып житеп, узып китәчәк икән ул? Аңлый алмыйм.

К а р а Ш ә ү л ә. Минем ат белән пароходны куып житкәнем кебек.

З а һ и д ә т у т а ш. Ничек, Кара Шәүлә?

К а р а Ш ә ү л ә. Татар милләтенең үсешен тыеп, тегеләрнең узыш атын алга

чыгарып. Татар торып тора, тегеләре куып житә дә узып та китә. Уравниловка дип атала ул. Извозчик! Атларынны яндырганчы ку! Алабугада куып жит әнә теге “Меркурий” пароходын. Акчасыннан тормам!.. *(Извозчикка китеп барышлый.)* Туташ-әфәнде, мин Кара Шәүлә түгел! Кара Шевлинский. Ягъни, моннан түбән “карать, каратель” сүзеннән чыккан “Кара” басымы белән әйтегез минем исемемне. Әйдә, ку атларынны! *(Китә).*

З а һ и д ә  х а н ы м. Еллар узды. Тугыз елдан сон, мин ачлык елда Ташкентта Гаяз Исхакыйнын бердәнбер сөекле кызы Сәгадәткә дә мөгаллимә булдым. Исхакый ул вакытта читкә киткән иде инде. Сәгадәтне дә яшьләр белән Төркиягә юлладылар. Исхакыйны кабат күрү мина насыйп булмады. Ул чит илдән кайтмады. Тагын еллар узды. Гомер үтте. Ләкин Исхакыйнын йөзе һаман күз алдымнан, сүзе колагымнан китми. Гомерем буе мин “Гроза”, “Анна Каренина”, “Ревизор”, “Хажи Мурат” “После бала” “Кармен” кебек әсәрләрне шәкертләремә анлаттым. Ярамаганда Исхакый исемен әйтмичә генә, бер татар әдибе дип, шул фикерләрне әйтеп уза торган идем. Генерал утарына ул гүләйт итеп кенә килмәгән иде, әлбәттә. Анын максаты татарларнын вәзгыятен өйрәнү, икенче максаты Суфия тәтәмне театрга кайтару, өченчесе инде күнел эше, Гаяз абый, мина калса, Сара апамны туры китерергә өметләнеп килгән иде. Әлбәттә, балалы тол иргә Сара тәтәм карар идеме, юкмы икән, белмим, әмма Гаяз Исхакый белән Сара тәтәм еш очрашкан булсалар, тормыш, бәлки, башка юлдан киткән булыр иде.

**Янә гаилә рәсеме тәртибендә утыралар. Маһипәрваз, бәләкәй Аскәр, Суфия юк. Сәхнәдә Ильяс, Йосыф, Даут, Сара, Заһидә туташ, Заһидә ханым, Кара Шәүлә.**

З а һ и д ә  х а н ы м. Беләсезме, дускайларым! Мин сезгә хәзер беркем дә белми торган сер әйтәм. Хәзер ярый торгандыр инде. Вакыйгада катнашучыларнын барысы гүр иясе булды. Ул вакыттагы татарлар арасында Сара апамнын игътибарын жәлеп итәрлек ике генә кеше бар иде. Берсе—Гаяз Исхакый. Икенчесе—Фатих Әмирхан.

С а р а. Дөрес, сенлем Заһидә. Гаяз төрмәдән төрмәгә йөрде. Мине түгел, үз баласын багарга да жае булмады. Мин сизә идем, белә идем: Гаяз Исхакый мина битараф түгел! Ләкин ул минем кешем түгел иде. Белә идем, сизенә идем, Фатих Әмирхан да мине эзли иде, мине очратырга тырыша иде. Мина зур өметләр илә бага иде. Петербургта торган чагында, хәтерлисенме, Заһидә, безгә Фатих әфәнде Әмирхан еш килә иде.

З а һ и д ә  х а н ы м. Хәтерлим, тәтәм. Гажәеп чибәр кеше иде ул Фатих абый. Өйгә килеп керүгә үк ул мине ике терсәгемнән тотып һавага күтәрә иде. Мин чиный идем. Куркып түгел, рәхәтлектән, биеклектән ләззәт алганга чиный идем.

С а р а. Чын затлы сөяк Фатих Әмирхан! Мин аны сайлаган идем.

З а һ и д ә  т у т а ш. Түшәмгә күтәреп озак тота иде ул мине. Мин ана өстән карыйм. Шунысына мин гажәпләнеп туймый идем, апам. Фатих абыйнын якасы һәрвакыт ап-ак була иде. Мина калса, ул синен янга керле яка белән килә дә алмас иде.

С а р а. Гажәеп шәхес иде ул Фатих Әмирхан.

З а һ и д ә  т у т а ш. Могжизасы алда әле, апам: Фатих абый мина астан карый. Анын зу-ур күзләре кап-кара бәбәкле иде, күз аклары искиткеч ак, хәтта бераз зәнгәрләнеп тә тора иде.

С а р а. Анын күз аклары шулай зәнгәрсу-ак иконен мин генә күрә идем кебек. Син, кызый, кайдан аларны беләсен? Сина ничә яшь иде ул вакытта?

З а һ и д ә  т у т а ш. Сигез.

С а р а. Сигез яшьтән ир-егетләргә шундый жентекле игътибар сина каян килгән? Син миннән иртәрәк кияүгә чыгарсын, ахрысы.

З а һ и д ә  т у т а ш. Сара апам, мин күп нәстәләрне сизә идем. Син Фатих Әмирханны эчтән генә ярата иден.

С а р а. Бәлки...

З а һ и д ә  т у т а ш. Бәлки түгел... Син аны ярата иден... 1907 елда, ике елдан сон, Фатих абый күтәрәмгә калгач, синен атналар буе сөйләшмичә йөргәненне бер мин белә идем. Син көчле шәхес, син бу күнелсезлекне тиз жинден.

С а р а. Тиз жиндем. Ике аягы тин йөрми торган кеше белән мин язмышымны бәйли алмый идем бит инде.

Заһидә туташ. Мин сине һич тә гаепләмимм, апам.

Сара. Әмма мин инде ике затлы кешедән коры калгач, үз жаемны үзем карадым. Шулай да мин тагын жиде ел беркемгә дә карамадым. Дөресен генә әйткәндә, мине ирләр кызыксындырмый да иде.

Заһидә туташ. Яшермә, апам. Питербургта чакта Шакир Мөхәммәдъяров, Кәбир Бәкер кебек мәһабәт ирегетләр синнән күз алмыйлар иде.

Сара. Шулай булды бугай шул. Шакир әфәнде мәһабәт, акыллы егет иде.

Заһидә туташ. Тукайны Петербургта докторга күрсәтүне оештырган кеше Шакир Мөхәммәдъяров бит.

Сара. Ләкин ул салкын карашлы иде. Ә менә Кәбир Бәкер—анысы башка. Кәбирнең эчке нуры бар иде аның. Ләкин ул да минем өчен яралтылмаган иде. Бер урында озак утыра алмый иде ул. Аны күп төрле сәләте бер урыннан икенчесенә куып йөретә иде. Ә миңа салмак, сабыр, утрак тормышлы ир кирәк иде. Татарлар арасында андый ир тапмадым. Сеңлем, шайтан ботын сындырган заманда аларның язмышы ни булып бетте?

Заһидә ханым. Шакир Мөхәммәдъяров Урта Азиягә качып котылды. 1967 елда шунда вафат булды. Кәбир Бәкернең күп тапкырлар малын таладылар, төрмәләрдә утырып, сөргеннәрдә булып, атарга хөкем ителеп йөри торгач, 1944 елда Самарада үз түшәгенә ятып вафат булды.

Сара. Исхакый?

Заһидә ханым. 1954 елда Анкарада—чит илдә, горбәттә вафат.

Сара. Менә күрдеңме инде? Әгәр дә мин шуларның берәрсенә кияүгә чыккан булсам, ни булыр иде? Миңа төпле, сабыр ир кирәк иде.

Заһидә ханым. Син католиклар сектасына язылдың.

Сара. Син каян беләсең?

Заһидә ханым. Мин бит очлы күз.

Заһидә туташ. Мин бит өйдә хатын-кызлар арасында үсмәдем. Олы апаларым кайсы кая китеп таралды. Кияүгә чыктылар, тол калдылар. Мин абыйларым янында үстем. Ихтимал, бу минем холкымда да чагыла торгандыр. Синең сыман, мин артык сентименталь булмадым. Әйткән сүземне жиренә житкезеп үтәмәсәм, мин йоклый алмый идем. Нәкъ синең кебек. Ни кыен чакларда да кешегә бурычка кермәдем. Бу—минем абыйларымның тәрбиясе. Кешеләргә ярдәмгә атлыгып торсалар да, абыйларым беркайчан да кеше бусагасына барып егылмадылар, горур булдылар. Горурлык миндә барыгызга да житәрлек. Олы абыем Ильяс 1887 елда туган. Беренче ир баланы атам-анам сөенеп каршы алганнар. Статский советникның улы буларак, аны юнкерскийга бирәләр. Бә-әк мәһабәт гәүдәле, шәм кебек төз... *(Ильяс мәһабәт юнкер булып жанлана.)* Ие, ямандыкның күзенә баса-баса, алга барыр өчен бәхетле жәмгыять-гаилә корылган иде атам-анам тарафыннан. Ләкин Шаһбазгәрәй токымы өстендә әллә нинди кара шәүлә пәйда булды. Ильяс абыемның бөтен мөмкинлекләре бар иде. Ләкин ул юнкерскийны бетереп тә, институттан институтка күчеп йөреп тә олы шәхес була алмады. Нинди дер авыр уй бар иде аның башында. Жәмгыятьтәге еш үзгәрешләрне ул бик авыр кичерә иде. Шуңа күрә, күпме кыстасалар да ул өйләнмәде. Ана изреп аракы керде өйгә. Ул түләүле хатыннар янында үзенә ямь табарга тырышты. Аннан да бизде. Менә шул вакытта 1914 елгы сугыш башланды. Сугыш башланганны ишеткәч, Ильяс абыемның йөзе яктырып китте. Сугыш башланганга шатландымы ул? Белмим, ул иң беренчеләрдән булып фронтка китте.

Ильяс. Шатланмадым мин сугышка. Ниһаять, рухи буталыштан котылыр өчен алгы сызыкка киттем. Атака артыннан атакаларга күтәрелдем, минем сугыш кырында батырларча һәлак буласым килде. Мин тормышның мәгънәсен тапмадым. Шуңа күрә, гаилә кормадым, мәгънәсез тормышка, интегергә балалар үрчетәсем килмәде. Үземә үзем кул салырга уйладым. Ләкин мин ул эшне башкара алмадым. Бер юл иде минем котылышка—сугышта һәлак булу. Сугышның иң кайнаган жирләренә үзем атылып керә идем. Үлем теләгәннән үлем кача. Үлемнән качып, окопта ятканнарны үлем ядрәсе эзләп таба иде. *(Кара Шәүлә чыга. Бөркәвечен күтәрә. Өч тапкыр аткан тавыш ишетелә. Ильяс күкрәгеннән тотып катып кала. Шәүлә китә.)* Өч тапкыр каты яраланып та мин исән калдым. Госпитальдан терелеп чыкканыма мин шатланмадым. Анам йортына имгәк булып кайттым... Имгәк булуның ни икәнен мин шунда аңладым.

Тол хатын тапкан малны имеп яту, бер файда китерә алмыйча, хатын кеше казынып-казанып тапканны ашап яту икән ул имгәк булу.

Х ә д и ч ә. Юкны сөйләмә, Ильяс!.. Син миңа имгәк түгел. Газиз балам син минем. Соңгысын сатып булса да мин сине ташламам.

З а һ и д ә  х а н ы м. Ташламады аны әни. Ильяс абыйны аякка бастырырга бөтен көчен сарыф итте. Ильяс абыем аякка басты. Янә чибәрләнде. *(Ильяс белән чибәр генә шансоньетка керә, алар артыннан Кара Шәүлә ияргән.)* Ләкин абыем эчә башлады. Ильяс абый шул эчке мәҗлесләрендә утырганда Ожеговның төнге ресторанында шонсоньетка булып биюче Надежда Ивановнага бәйләнеп, анакайдан шуңа өйләнергә фатиха сорады.

Х ә д и ч ә. Нинди фатиха сезгә, оятсызларга? Мин улымны фахешханәдә эшләүче маржалар өчен дип үстердемме?

И л ь я с. Анакаем, мин аннан башка яши алмыйм. Даруларга да акча күп кирәк. Син тапканны тотасым килми. Миннән артта әнә ничәү бит балаларың. Кичер мине, анакаем. Фатиханы теләп килдем яныңа!

Х ә д и ч ә. Атаңның рухы ни әйтер? Ни йөзең белән син... шушы... кулдан кулга күчкән...

З а һ и д ә  х а н ы м. Анакаем сүзен йомгаклый алмады, аның ярсулы ачуы күз яшьләре булып тышка чыкты.

И л ь я с. Анакаем...

Х ә д и ч ә. Чыгып китегез! Кабат күземә күренмәгез! Син инде безнең нәсел кешесе түгел. Күземнән югалыгыз!

**Хәдичә чыгып китә. Бер кырда Надежда Ивановна елый.**

З а һ и д ә  т у т а ш. Успокойтесь, Надежда Ивановна... Ильяс абый, син дә бик бетерешмә.

И л ь я с *(анасы киткән якка)*. Анакаем, ичмасам, килеп йөрергә рөхсәт ит!

Х ә д и ч ә  т а в ы ш ы. Рөхсәтем юк!

З а һ и д ә  т у т а ш. Чыннан да сез бүген анакайның күзенә күренмәсәгез әйбәтрәк булыр иде... Шуннан соң бичара Ильяс абыем белән Надя җиңгәм өйдән чыгып китте. Ильяс абый өйдән берни алмады. Бары тик кырыну әсбапларын гына кесәсенә тыкты. *(Ильяс, Надежда алар артыннан Кара Шәүлә чыгып китә.)* Шуннан соң анам аларның икесен дә өйгә кертмәде. Анакаемнан яшереп кенә мин аларга барып йөри идем. Берсендә анакаем мине тотты.

Х ә д и ч ә. Һәр якшәмбе син кая болай качасың? Тагын тегеләр янынамы?

З а һ и д ә. Анакаем, кызганыч бит алар.

Х ә д и ч ә. Торыр урыннары бармы? Кайда торалар?

З а һ и д ә. Алар Подлужныйда тора, кечкенә бер флигельдә.

Х ә д и ч ә. Әнә, костюмын ала кит!

З а һ и д ә. Рәхмәт, анакаем!.. Әйбәт хатын булды Надя җиңгәм абыем Ильяска. Аның яраларын бәйләүче дә, киендерүчесе дә, дарулар сатып алучысы да, анасы да, хатыны да иде ул абыемның. Балалары булмады... Анакай исенә төшкән саен елый иде, аннан күз яшьләрен сөртеп, кырыс тавыш белән:

Х ә д и ч ә. Юк минем Ильяс исемле газиз улым, үлде минем өчен газиз балам.

З а һ и д ә  х а н ы м. Газиз бала! Газиз абыемны Надя җиңгәмне кара тәкъдир көткән икән, мәрхүмкәемне. *(Кара Шәүлә кызыл эчле бөркәвечен җәеп, артык тантана илә сәхнәне каплап, түрдән төшә.)* Сугыш кына беткән иде, илне революция каплады. Юнкерләргә, дворян токымнарына кара көннәр килде. Теткәләнеп беткән Ильяс абыемны—ватан өчен кан койган каһарманны да... *(Кара Шәүлә хәрәкәт ясый. Ильяс белән Надя егыла. Бар да катып кала.)* Мең үлемне кичкән, әҗәлне үзе эзләп йөргән мәһабәт ир Ильяс Әхмәров яшисе килеп, савыгып килгәндә шулай һәлак булды. Аны, патша армиясе офицеры, суелып бетмәгән татар морзасы дип, кызыл иблисләр харап итте.

Х ә д и ч ә. Иннә лилләһи вә иннә иләйһи рәҗигун.

З а һ и д ә  т у т а ш. Авыр туфрагың җиңел булсын, Ильяс абыем!

Сәхнә түреннән Кара Шәүлә килә. Ул музыкага, акрынайтылган кинокадрлар кебек атлап, сәхнәне әйләнеп чыга да, бөркәвеч канатларын җилпеп чыгып китә.

З а һ и д ә  х а н ы м. Өч абыемның өчесе тиң сугышка китте. Ильяс абыем өч тапкыр каты яраланып, гарипләнеп кайтып, инде аякка бастым, дигәндә генә һәлак булды. Йосыф абыем сугыштан кайтмады. Йосыф абыемны анакаем врачлыкка укытып чыгарган иде. Бик

яхшы укып, яхшы врач булды ул. Шаршадыдагы генерал утарынын хужалык эшләре мөдиренен Нәфисә исемле бик чибәр кызы Йосыф абыема гашыйк иде. Йосыф абыем да аны бик ярата иде. Алар өчен анакаем жан ата, сөенә иде. Ниһаять, бер улым саф мөселман кызына өйләнә, дип куана иде.

**Йосыф белән Нәфисә жанлана.**

Х ә д и ч ә. Углым Йосыф! Атан сина тикмәгә генә пәйгамбәр исеме куштырмагандыр. Син чыннан да Йосыф кебек мәһабәт, һөнәрен дә бик гуманная профессия. Нәфисә кызым, сез бик пар килгәнсез. Мин сездән канәгать, Йосыфым...

Н ә ф и с ә. Йосыфыбыз!

Х ә д и ч ә. Ие, Йосыфым, Йосыфыбыз орыштан исән-сау әйләнеп кайткач, иншалла, туй итәрбез. Сезнен туегызга дип мин аерым мая саклыйм. Ә хәзергә никах укытып китегез. Дөнья хәлен белеп булмый, Алла сакласын.

Йосыф белән Нәфисә янәшә басып, башларын аска иеп катып калалар. Никах укыган тавыш ишетелә. Кара Шәүлә алар алдыннан узып китә. Калганнар тарала.

З а һ и д ә т у т а ш. Йосыф абыем сөекле Нәфисәсен, безне калдырып китеп барды. Бу абыем чыннан да Йосыф пәйгамбәргә охшагандыр кебек иде. Анын кешелекле булуы! Берәр гаделсезлек күрсә, чәчрәп чыгып, кыерсытылганны яклаучы да, ярдәм сорап килгәннәргә сонгысын чыгарып бирүче дә, анакайны изге итеп, ана наз илә багучы да Йосыф абыем иде.

З а һ и д ә х а н ы м. Анакаебыз Хәдичә кызлары арасыннан Сара апамны аеруча сөйсә, уллары арасыннан Йосыфны ныграк яраткандыр, дип уйлыйм. Анакаебыз башкаларыбызга да гадел, әмма кырыс булды. Тик Йосыф белән Сарага ул аеруча наз белән бага: урысча әйтсәк, она их боготворила, обожествляла, лелеяла.

З а һ и д ә т у т а ш. Фронттан жан өшеткеч хәбәрләр килеп тора. Каты сугышлар бара. Яралылар агыла. Үлем кәгазьләре өй саен керә. Даут абыем да фронтта. Шаһбазгәрәй йортынын өстендә Кара Шәүлә йөри. Суык, ачлык, өметсезлек хөкем сөрә иде. Шундый шомлы кичләрнен берсендә Нәфисә киленебез йөгереп керә.

Н ә ф и с ә. Заһидә туташ, ахирәтем, әйдә киттек фронтка. Бөтен курсисткалар фронтка язылa. Без дә язылыйк. Мин Йосыфымны эзләп табар өчен китәм. Жыен, киттек фронтка!

З а һ и д ә т у т а ш. Анда мин нишлим?

Н ә ф и с ә. Яралыларнын жәрәхәтләрен бәйләрбез. Абыен Йосыфны эзләп табарбыз, аны сакларбыз.

З а һ и д ә т у т а ш. Юк, Нәфисә, мин авыру Ильяс абыемны, ялгыз анамны ташлап, фронтка китә алмыйм.

Н ә ф и с ә. Мин китәм! Анакаем, фатиханны бир, мин Йосыфымны эзләп табачакмын. Анын яныннан китмәячәкмен.

Х ә д и ч ә. Нишләмәк кирәк, син шәфкать туташы, табибә, бәлки шулай эшләргә дә кирәктер. Мин каршы килмим. Бар, Йосыфымны... Йосыфыбызны эзләп тап, аны сакла! Батыр йөрәкле киләш булып чыктын син, Нәфисә туташ. Хәерле юл!

З а һ и д ә х а н ы м. Китте минем ахирәт дус кызым, безнен сөекле килебез, гүзәлләр гүзәле Нәфисә сөеклесе Йосыфын эзләп, мәхшәргә китте. *(Дәһшәтле гөрелте, фронт хәбәрчесеме ул гөрелте, әллә Шаһбазгәрәй токымы өстенә ишелеп төшә торган афәт гөрелтесеме?)* Нәфисәнен гүзәллеге өстенә чаялыгы да житәрлек иде. Фронт аша фронтны узып, Йосыф хезмәт итә торган армияне табып, ул шунда санчастька табибә булып урнашкан бит. Шаккатарсын кешенен мәхәббәтенә, исен китәр кешенен кыюлыгына, валлаһи. Шунда кадәр барып житәргә кирәк бит.

**Солдатлар, офицерлар арасында мәһабәт буйлы Йосыф.**

Н ә ф и с ә. Йосыф!

Й о с ы ф. Нәфисәм!

**Кочаклашалар.**

Й о с ы ф. Син ничек килеп чыктын монда, жәһәннәмгә?

Н ә ф и с ә. Без—шәфкать туташлары ополчениесе. Мин синен дивизияне сайладым.

Й о с ы ф. Жаным ла, Нәфисәкәем лә.

Н ә ф и с ә. Димәк, мин лазаретта сина буйсыначакмын. Анакай сина күчтәнәч юллады... Ильяс абый каты яраланып кайтты. Заһидә сина кульяулыгы бирде...

Й о с ы ф. Рәхмәт, жаным.

Г е н е р а л Ш в е ц о в. Господин военный врач Ахмеров!

Й о с ы ф. Я, господин генерал.

Г е н е р а л. Эта дама будет предоставлена в ваше распоряжение.

Й о с ы ф. Так точно, господин генерал. Буду глядеть в оба. Она моя жена, господин генерал.

Г е н е р а л. Жена, ваша жена?

Й о с ы ф. Так точно, господин генерал.

Г е н е р а л. Какая же храбрая ваша жена, господин военврач! Поздравляю. Не скрою, она мне очень понравилась. Очень уж она красивая.

Й о с ы ф. Господин генерал, у нас не принято говорить комплименты замужним женщинам.

Г е н е р а л. У кого это—у вас?

Й о с ы ф. У татар!

Г е н е р а л. Разве она татарка?

Н ә ф и с ә. Так точно, господин генерал!

Г е н е р а л. Я думал, что она или армянка, или азарбайджанка, на худой конец—цыганка.

Й о с ы ф. Нет, она есть самая любимая сноха моей матери Хадичи ханум.

**Тирә-якта көлешәләр. Генерал китә.**

Н ә ф и с ә. Әллә нинди ул генерал Швецов... Штабта да кеше бар дип тормый, комплиментлар әйтә, кулымны үбә.

Й о с ы ф. Ярый әле кулынны гына үбеп калган...

**Б е р н и ч ә о ф и ц е р с ө й л ә ш ә.**

— Появление такой красавицы на переднем плане опасная тревога, господа.

—Да-а, хороша, черт побери.

—Не завидую я военврачу.

—Генерал глаз положил на красавицу.

—Он не только глаз положит...

**Каты гөрелте, тревога, барысы да качып бетә.**

З а һ и д ә х а н ы м. Йосыфның зирәк җавапларымы, әллә шундый да гүзәл хатынның Йосыф кәләше булуы сәбәпче булганмы, генерал шуннан соң атлаган саен Йосыфка бәйләнә, Нәфисәгә артык игътибарлы була башлый. Сылтау табып, ул Йосыфны алгы сызыкка яралыларны җыярга җибәрә.

**Кара Шәүлә чыга.**

Н ә ф и с ә. Йосыфым, мин куркам ул Швецовтан! Ул инде хәттин аша башлады.

Г е н е р а л. Господин военврач Ахмеров!

Й о с ы ф. Я, господин генерал.

Г е н е р а л. Вам приказано срочно оперировать, ампутировать левую руку и правую ногу рядовому Султанмуратову.

Й о с ы ф. Господин генерал...

Г е н е р а л. Отставить! Выполняйте приказ!

Й о с ы ф. Господин генерал...

Г е н а р а л. Разговоры!

Й о с ы ф. Султанмуратову ампутировать руку и ногу нельзя... Потому что там нет гангрены, это просто покраснение, когда его тащили с поля боя на плащ палатке ... Да и у него нет температуры.

Г е н е р а л. Приказы не обсуждаются, а выполняются, господин военный врач!

Й о с ы ф. Ваш глупый и не профессиональный диагноз и такой же глупый приказ человека оставит калекой на всю жизнь. Ведь он столяр, что он будет делать без одной руки и без одной ноги?

Г е н е р а л. За нарушение военной присяги расстрелять на месте!

**Кара Шәүлә узып китә. Йосыф егыла.**

Н ә ф и с ә. Кабахәт!

Г е н е р а л. Что? Что вы сказали!

Н ә ф и с ә *(генералның битенә төкерә)* Я сказала, что вы сволочь и изменник России!

Д е н щ и к *(атылып керә, кулында гәҗитәләр, листовкалар).* Революция-а! Разоружайся-а! Бей макаронников! Вся власть советам!

**Генералны кулга алалар, буталыш, сөенеш, куркыныч. Кара Шәүлә сәхнәне әйләнеп чыга, сәхнә тулы мәетләр ятып кала.**

З а һ и д ә х а н ы м. Чибәр Йосыф, пәйгамбәргә тиң Йосыфыбыз әнә шулай һәлак булды.

**Сәхнәдә Сара, Хәдичә, Заһидә туташ, Даут, акылдан язган Нәфисә.**

З а һ и д ә т у т а ш. Анакаебызны алмашына дип торабыз! Ул кеше әйткәнне ишетми, кеше йөргәнне күрми иде кебек. Йосыфның үле хәбәре аны шулай изгән иде. Нәфисәбез дә... *(Күнеле тула.)* Нәфисәбез, чая ахирәтем, Йосыфның сөеклесен дә харап иттеләр... Генералны терәп аткан революцион солдатлар, җитәкчесез калган өерләр, вагон-вагон булып төялеп кайтып киттәләр, Нәфисә исерек революцион солдатлар кулына эләгә.

**Кара Шәүлә узып китә, Нәфисә егыла.**

Заһидә туташ. Күз алдында Йосыфын атып үтергәнгәме, солдатларның кыргыйларча кыланганнарынамы, Нәфисәм акылдан язды, каядыр китеп суга баттымы, әллә аны саташып йөргәндә үтерделәрме... шулай итеп, юкка чыкты Нәфисәкәй.

**Тагын Кара Шәүлә керә.**

Заһидә ханым. Шәүлә күренә икән, димәк, афәт булачак. Минем җанымны алырга килденме, Кара Шәүлә?

Кара Шәүлә. Әдәбият укытучысы имеш! Дөрес әйтмисең син минем исемемне! Кара Шәүлә түгел, Кара Шевлинский мин!

Заһидә ханым. Тагын кем артыннан килдең?

Кара Шәүлә. Давыт абыең... Давыт абыеңны яшереп калдырмакчы буламсың? Ә?

Заһидә туташ. Даут абый! Һоо, Даут абый да Даут пәйгамбәр кебек буласы иде дә... *(Кара Шәүлә узып китә.)* Абыйларым минем төшеп калганнардан түгел иде анысы. Әмма анам Йосыфын артык ярatса, мин Даут абыемны ореолда күрә идем. Йосыф абыем чибәр иде, әмма Даут абыйга җитми иде. Һо-о, Даут абый дан ярата торган булса, бәләкәй генә карьерист булса, ул әллә кайларга барып җитә иде. Шыр надан Распутин, бозыклык даһие Казанова, Дон Жуаннар аның каршысында кәтәнә, плебей, тәбәнәк Пипин булып калыр иде. Даут абыем ул мәхәббәт каһарманы булыр өчен яратылган иде. Ул үзенең кадерен белмәде. Хәер, кешене гаепләргә җинел ул. Бәлки ул мәхәббәт каһарманы булырга теләмәгәндер дә.

Заһидә ханым. Даут абый, юридическийны бетергән иде, шәп адвокат, сугыштан исән-сау кайтты, шөкер. Дөньяның мәшһүр чибәрләре аны хатлар белән дөмбәсли. Барысы да әйбәт. Шунысы хәтердә калган, Казанда, Петербургта гүзәллеге белән дан казанган татар кызы Гайнелхәят Мамина бар иде. Шушы Гайнелхәят туташ минем абыем Даутка гашыйк булмасынмы? Петербургта укый бу кыз, татилгә Казанга бай ата-анасы янына кайта. Җәйне Даут белән бергә узгаралар. Без инде анам белән шатланабыз, ичмасам, Даут татар кызын алыр, дибез. Миннән битәр анакаем куана. Ул вакытта мина татар ни дә, урыс ни—барыбер иде. "Ләйлә белән Мәҗнүн" дип йөртәләр иде үзләрен. Бөтен Казан аларны аерылгысыз мәхәббәт каһарманнары буларак кабул итте. Анакаемның куанычы йөзенә, торышына чыга торган иде.*(Гөрелте. Кара Шәүлә уза.)* Татил беткәч, Петербургка киткәндә Даут абыем Гайнелхәятне озата төшмәде. Ул китүгә ай узар-узмастан, Даут абыем атаклы гинеколог Дамперның кызы Ольга Ивановнага өйләнде дә куйды. *(Шартлау).*

Хәдичә. Суйдың син, Даут, мине, кистең нәселне!

Даут. Гафу ит, анакаем. Нишлим соң? Яратам бит мин Оляны!

Хәдичә (еламсырап). Алар ягына алтын сылап куйганнармыни соң? Үзебезнең мөселман кызлары бетәрлекме? Җиләк кебек гүзәлләре бар, башка милләтләр татар чибәрләре өчен сугыша, дөнья куптаралар, сез-татар егетләре шушы чибәрләрне күрмәслек сукырмыни соң? Ольга Иванова, әлбәттә, яхшы канлы, матур кыз, Гайнелхәят янында ул бит күләгә генә. Нигә, ни өчен сез бриллиантларны ташлап, чүерташлар җыясыз, татар егетләре? Анламыйм, хәлем юк, анлата алмыйм мин бу тилелекне *(кырыс).* Син, Даут, минем өчен юк! Син нәселне кистең!

**Кара Шәүлә уза, шартлау, Даут егыла.**

**Сәхнәдә Хәдичә, Сара, Заһидә туташ кала.**

Заһидә ханым. Шулай кырыла барабыз. Сезнең каршыда анакаемның горурлыгы, өмете, киләчәк яктылыгы, элеккеге булган ялгышларын төзәтү чарасы—Сарасы утыра. Петербург, Мәскәү, Казан голәмәсенең фикере бер иде—Сара Әхмәрова иң алдынгы, күп телләрне мөкәммәл белүче, аналитик зиһенле, зифа буйлы, чибәр йөзле фәрештәдәй саф зат. Казан, Мәскәү, Петербург кына түгел, бу турыда Германия, Гамбург, Берлин шулай сөйли иде. Шаһбазгәрәйнең иң истигдатлы, иң гүзәл баласы ул—Сара Әхмәрова икәнен мин үзем сезгә тәкърарлап тормыш кәнем. Маһи тәтәм бәхетсез булды, ире үлде, улын үтерделәр, гомеренә тол калды. Сафия тәтәм олы талантлы була торып, утарбикә булып калды. Ильяс абыем сугыштан гарипләнеп кайтып, кафешантан маржасына

өйләнде, үзен кызыллар атып үтерде. Йосыф абыемны урыс генералы атып үтерде, киленебезне революцион солдатлар көчләп һәлак итте. Даут абыем маржага өйләнде. Хәдичә Әхмәрованың соңгы өмете—зиһенле кызы Сара калды. Беләсезме, мин фаҗигаларны күп күрдем, кешенекен дә, үземнекен дә, анамныкын да. Ләкин анамның иң олы фаҗигасы, үтерелгән уллары да түгел, минем тол калуым да түгел, анакаемнын-бичаракаемнын иң олы кайгысы—иң сөекле Сарасы булды. Иң итагатьле мөселман-татарның зыялы кызы Сара Әхмәрова чукынган, урыска кияүгә чыккан, дигән хәбәр газеталарда да, мәҗлесләрдә дә телдән төшермичә еллар буе дәвам итте.

**Гәзитә сатучы малайлар ду килә, кычкыра-кычкыра гәзит саталар.**

—Атаклы мәгърифәтче, статский советник Шаһбазгәрәйнең атаклы кызы Сара Әхмәрова чукынган!

—Шаһбазгәрәй Әхмәровның кызы Сара туташ христиан динен кабул иткән!

—Татар зыялыларының балалары чукына, маржага өйләнә, урыска кияүгә чыга.

—Сенсация! Сенсация! Татарская красавица из знатной семьи Шахбазгиреевых, окончившая юридический институт, золотая медалистка Сара Ахмерова вышла замуж за еврея и приняла котоличество вместе с мужем.

**Кара Шәүлә Сара артыннан һич калмый.**

Заһидә туташ. Сара апакаем, сиңа анакаебыз кызганыч түгелмени?

Сара. Загида, ты еще молода, ничего ты не понимаешь. Вырастишь, все поймешь.

Заһидә туташ. На дворе 1914 год. А мне 17 лет. Я не понимаю поступок такой умной женщины.

Сара. Мой ум и моя красота ничегошеньки не стоят. Я абсолютно равнодушна была к моей внешности и к своему уму. Ты же видела: я ни разу не притрагивалась к пудрам, помадам, парикам. Видимо, я не сексуальная особа. Я юрист и математик. Знаю множество языков. Мин гарәпчәне дә өйрәнеп чыктым бит, сенлем, татарчасын да ким белмимен. Мин бөтен дөнья фәлсәфәсен сөреп чыктым, Казанда, Петербургта, Мәскәүдә, Берлинда, Һамбургта бөтен диннәрне өйрәндем. Самая научная, самая человечная, самая логически верно выстроенная религия это—христианство, а особенно католичество! Это очень строгая религия. Жесткая религия. Но верная.

Заһидә туташ. Знаю... Католики, самые гуманные верующие, живьем сжигали безвинных людей на кострах. Католики самые гумманные верующие, истребляли целые-целые народы Американских континентов. Христиане, самые гуманные верующие, грабили не христианские народы Африки, Азии во время крестовых походов. Христиане, самые гуманные верующие, дотла истребили культуру татарского народа. Католическое христианство самая нетерпимая в отношении чужих религий... Анам сокланган, анам өмет баглаган Сара апам шушы көнгә калганмы?

Сара. Мадемуазель Загида, не перегибайте палку.

Заһидә туташ. Я тебя поняла, Сара! Во-первых, ты свихнутая шизофреничка. Я поняла: ты параноик!

Сара. Загида!

Заһидә туташ. Во-вторых, ты сексуальна голодная. Ты подавляла свою красоту, ты подавляла свои природно-физиологические потребности ради того, чтобы потом с избытком удовлетворить накопленный потенциал. Гаяз абый Исхакый кебек бөек шәхес сине сөя иде. Фатих Әмирхан белән сез Петербургта сәгатьләр, атналар буе бакчада йөри идегез. Син бит аларны сынап карадың. Боларның кайсысы синең сексуаль партнерың була ала? Бичара татар зыялысы ул бит нахал түгел, алар сине шатырдатып кочаклап алган булса, бәлки син алар белән якынайган да булыр идең. Шулай итеп, син үз женси жененне авызлыклап, монашка кебек, бер кеше белән дә үбешмичә 27 яшькә җиттең. Синең бу тыйнаклыгың, тотанаклыгың саф әхлак галәмәте түгел, синең бу кылмышың сексуаль паранойя.

Сара. Ничего ты не поняла, милая. Мне, конечно, жаль матери и вас жалко. Себя—еще больше. Ведь я жертва предрассудков, жертва материнских предрассудков. Мин үземне бөтен тыюлардан, бөтен кысалардан азат итәргә алынган кеше.

Заһидә туташ. Әгәр дә син католик динле гаиләдә туган булсаң, шушылай ук мөселманлыкка качкан булыр идең. Бу синең параноик холкыннан килә. Алайса, сиңа нигә кирәк булды анакаебызнын тиенләп җыйган ак-

часына еллар буе кыйммәтле институтта уку, Германиягә барып уку нигә кирәк иде? Син бит хәзер адвокатлык белән дә шөгыльләнмисен, тарих белән дә шөгыльләнмисен, син телләр дә өйрәтмисен. Син чиркәүдән чиркәүгә йөреп, публика алдында динне яхшы белгәнлеген турында сафсата куертасын. Инде анысын ташлап, жайлы кияүгә чыктын да, йортбикә булып ятасын. Синен талантын юкка чыкты.

Сара. Алла каршысында гыйбадәтләр кылып, мин анама бурычымны түләрмен. Алла каршысында бөтенесе чүп, Заһидә. Минем шушы халәткә килүем өчен мин барысын да узарга тиеш идем. Шахһбазгәрәй Әхмәров гаиләсендә туып, яхшы тәрбия алып, анам назын тоеп, институтлар бетереп, илләр гизеп яшәргә тиеш идем. Бу—тәкъдир. Мөселман, Ислам дөньясына бөтен илләр, милләтләр каршы торачак. Гаепләре бармы мөселманнарның—юкмы, әһәмиятле түгел, мөселман булганы өчен генә кешенен дөньяда яшәргә хакы юк. Мин шуны ике йөз ел алдан аңладым.

Заһидә туташ. Чуртым да аңламадын син, Сара апам. Син дә Кара Шәүлә котыртыгы белән яшисен.

Сара. Не поняла.

Заһидә туташ. Ты стала одержимой, дорогая моя сестра Сара. Великая опасность одержимости состоит в том, что ставшие одержимыми не замечают произошедшей с ними перемены, не осознают того, что стали орудиями низких тварей, как Кара Шевлинский, отбросила законы матери. Поэтому одержимость есть показатель духовного омертвения как отдельного, так и всего человечества. Аллаһы Тәгалә әйтә: диндә артыгын кыланмагыз, ди. Ана кануннарын инкарь итеп, син артыгын кыланган бәхетсез хатын...

Сара. Нигә сон сез бер Сараның чукынганына ду күчәсез? Яныгызда гына күпме керәшен—христиан татары. Нигә аларга нәгърә ормыйсыз?

Заһидә туташ. Ике нәрсәне бутамагыз, госпожа попадья Сара ханум! Керәшен электән үк христиан булган халык. Алар чукынган татар түгел, алар электән христиан динен тотучы татар. Ике әйберне болгатып дөньяны харап итәргә азапланучылар бар. Керәшеннәр алар, нинди кыенлыкларга карамастан, Ана телебез—татар телен саклап калган христианнар. Ана телебезне саклаган халыкка без һәйкәл салырга тиеш. Чукынган татарлар алар башка. Әнә, Йосыповлар, әнә, Ширәмәтевләр, әнә башкалар. Алар инде татар түгел, алар инде урыс. Алар керәшен дә түгел—алар чукынган татар. Син дә татар түгел инде—урыс, урыс кына да түгел—католик. Син, Сара попадья, диненне алмаштырып, Ана телебезне сакларга алынасынмы? Юк! Синен бер генә балан да Ана телен белмәячәк һәм татар халкына хезмәт итмәячәк.

Сара *(аерылышканда барысына да кул суза, ләкин сузылган кул һавада асылынып кала).* Ярый, Заһидә сенлем, анакаем, хушыгыз!

Заһидә туташ. Чукынганнан сон, Сара апабыз ире Яков Букшпан белән башта Петербургка, аннан Мәскәүгә китте дә, кабат безнен янга әйләнеп кайтмады. Бу гамәл анакаебызны тәмам аяктан екты.

Хәдичә ханым. Тагын бер балам юкка чыкты. Ильясның фахишәгә өйләнгәне дә фажига булмаган икән, Ильяс маржа белән торса да чукынмады бит, денен ташламады. Даутның маржага өйләнүен дә гафу итеп була икән, Даут чукынмады бит. Сараның чукынуын, католик булып китүен берничек тә гафу итеп тә, аңлап та булмый. Сара, син безнен нәсел өчен үлден!

**Кара Шәүлә Сара алдыннан узып китә, шартлау яңгырый. Сара егыла.**

Заһидә ханым. Анакаем белән без икәү калдык. Шушы бимазалар, ишелеп төшкән кайгылар анакаем Хәдичәне бик таушалтты.

Мин бу дөньяда бик күп яшәдем инде. Артыкка китте. Ләкин Аллаһ язган тәкъдиргә каршы барыр хәл юк. Күпме биргән, шуны яшәп бетерергә тиешбез. Минем бу дөньяга, тормышка мөнәсәбәтем дә, карашым да билгеләнгән. Эшлисе эшләнгән, эшләргә рөхсәт булмаганнары хәрәкәтсез калган. Чибәр хатыннар, мәһабәт ир-зат бозыклыкка ныграк тартыла, диләр. Әлеге дә баягы ир белән хатын-кыз мәсьәләсе кебек, монда да урталыкта торырга кирәктер, мөгаен. Ә мин беләм гүзәл хатыннарның да саф намус, тугрылык илә гомер кичергәнен. Ә мин беләм адәм карамаслык ямьсез кешеләрнең бозыклык дәрьясының аръягына чыкканын. Гүзәлләр арасында да, ямьсезләр арасында да һәрберсе тигез. Бозыклык ул чырайга карамый, әхлаксызлыкка ка-

рый. Чибәр йөзле булып та, ике сәгатьтән соң күнелең бизәрдәйләр бар. Ямьсез чырайлы булып та, тора-бара аның матурайганын, күнеленә якын кешегә әверелә барганына шаһит булганыгыз юкмыни? Гүзәл булып, миһербанлы да булса—шул булыр камиллек. Ямьсез булып, ямьсезлек кылса, шул булыр нәҗеслекнең үзе. Ирләр алар үзгә холыклы бәндәләр. Аларны да анларга кирәктер. Кайсылары хатын-кыз артыннан куа торгач, һәр җиңүен дәфтәргә терки торгач, чырагындагы маен вакытыннан элек яндырып бетерә, хатыннарның да бәгъзеләре сан артыннан куып, иртә әлсериләр. Эчен ашап ташлаган йомырка кабыгыдай, суы корыган ермактай кибеп, тамыры киселгән гөл кебек шәлперәеп кала андыйлар. Элеккеге танышлары андыйлардан кача. Чарасызлык, бушлык, өметсезлек һәм ачу кала түләү булып. Теләге булып та гайрәтсез булса, бәндәдән син игелек көтмә. Гайрәтле ирләрне алар күз йоммыйча суяр, гүзәл хатыннарны алар чәнчер. Мина булмагач, башкаларга да булмасын! Шушы җенси мәсьәләне рухи дөньяга, иҗат өлкәсенә күчерсәк, шул ук нәрсә килеп чыга. Чиксез талант иясеннән бөтен рухи импотентлар көнләшә, талантны алар күрәлми, андыйлар—иҗади импотентлар—талантны ашый башлый, чага башлый. Көнчелек җене чүлмәктән чыгып, дөньяны каплап ала. Ленин белән Сталин әнә шул җенне, көнчелек җенен, импотентлык гыйфритен азат иткән затлар. Алар мәхәббәтне үтергән җәлладлар... Әй баш ваталар, кешелеккә игелек кылырга алынган гамәлләр кешелеккә каршы бәла булды, нишләп тә нишләп шулай килеп чыкты соң?—диләр. Эш бик гади бит, язучы иптәш. Русиядә мәхәббәт үлде. Бөтен бәлаләр, бөтен җинаятьләр, гаиләләрнең җимерелүе, ата-анага рәхимсез мөнәсәбәт, бөтен гаделсезлекләр, көчләүләр, талаулар шуннан килә, гасырлардан-гасырларга килеп тә үзгәрмәгән йолаларның юкка чыгуыннан килә. Ана-белән атаның мәхәббәте балага, баланың мәхәббәте ата-анага, ата-ананың мәхәббәте әби-белән бабага, әби белән бабаның мәхәббәте Аллага юнәлмәсә яки киресенчә—баланың мәхәббәте Аллага, әби-бабасына, атаанасына туганнарына юнәлмәгән булса, дөньяда этбашсыераяк—хаос башлана. Ул хаос сезнең күз алдыгызда тора. Ул хаос—Россия. Һәр җирдә имәнгеч тәртипләр, кешелеккә, инсаниятка каршы система корылган. Һәм шул инсаниятка, миһербанга, мәхәббәткә зыян сала торган тәртипне махсус саклаучы оешмалар бар. Кешелекне миһербансызландыру, гаделлекне үтерү өчен армия, НКВД асрыйлар. Юкса, ничек анлатырга кирәк Кәрим белән безнең язмышны? Юкса, ничек анлатырга кирәк миллионнарча гаепсезләрнең һәлакәтен? Юкса, ничек анлатырга кирәк бүгенге хаосны?

**Кара Шәүлә узып китә.**

Тәнәфес

# Икенче бүлек

**Кара Шәүлә биюе.**

Кара Шәүлә *(чаршау янында)*. Һу-һу!

Заһидә ханым. Кем йөри анда! Тынычлап үләргә дә ирек бирмисез!

Кара Шәүлә. Торыгыз, Заһидә ханым, тәнәфес бетте.

Заһидә ханым. Ә-ә, синмени әле бу үлем шәүлегәне!

Кара Шәүлә. Йоклап ятар вакыт түгел!

Заһидә ханым. Эчемне пошырып торма, күземнән югал. Кеше белән рәтләп сөйләшеп тә булмый, киләсен дә тыкшынасың! *(Кынгырау зынгылдый, Заһидә ханым сискәнеп китә.)* Хәзер, хәзер ачам! Ә син югалып тор! *(Шәүлә китә. Заһидә ханым ишекне ача. Үзалдына сөйләнә.)* Узыгыз, язучы әфәнде, узыгыз... Нәрсә дидем әле?.. Ие, Кариев! Һо-о, Габдулла Кариевмы? Кариев белән Исхакый мине артистка

итте... Минем беркайчан да артистка булырга хыялланганым булмады. Ләкин "Сәйяр" труппасында мин биш ел уйнадым. Начар уйнамадым. Мин башлыча инженю драматик рольләрне башкара идем. Ягъни, олы яшьтәге хатыннарны, карчыкларны яхшы уйный идем, түбән күкрәк тавышым бар, гайрәтле холкым бар. Инженю комикларны Синяева, Болгарская, Ильскаялар уйный иде, ягъни мәхәббәт гүзәлләрен. Гаяз Исхакый мине генерал утарында артистка булырга димләде, ул минем андагы һәвәскәр уенымны хуплаган иде. Аның шул бер караганда очраклы гына әйткән сүзләре җилгә очмады. Мин чыннан да артистка булып киттем.

З а һ и д ә т у т а ш. Беркөнне укудан кайтып керсәм, залда Кариев утыра. Анам белән әңгәмә корганнар. Мин баш иеп исәнләштем дә, үз бүлмәмә узып киттем.

Х ә д и ч ә. Заһидә кызым, чык әле, Габдулла әфәнде синең белән сөйләшергә дип килгән.

К а р и е в. Заһидә туташ, Әшрәф Синяева курслар бетереп, Казанга, театрга кайтты. Мин аның белән шартнамә төзедем, ул безнең театрда эшләячәк. Ләкин безгә белемле артисткалар һаман җитешми. Кытлык аркасында урамнан алып кереп сәхнәгә чыгарабыз. Безнең теләк татар зыялыларын театрга тарту. Мин сезне сәхнәгә кодалап килдем, туташ.

З а һ и д ә т у т а ш. Габдулла әфәнде, мин уйный алмам. Мин университетка керергә әзерләнәм. Артистка булырга уйлаганым да юк. Мин үземне мөгаллимлеккә, әдәбиятка багышларга уйлыйм. Мин артистка була алмам. Кичерегез!

К а р и е в. Заһидә туташ, үзем өйрәтермен. Бик үтенәмен, зинһар, килегез театрга. Валлаһи, үзем алынам сезне өйрәтергә. Апагыз Суфия ханым драматик курслар тәмамлап кайткан иде дә, бик өметле артистка, яхшы режиссер иде дә, театрны ташлап, кияүгә чыкты. Ильская да китә театрдан. Театрны ябасы гына кала.

З а һ и д ә т у т а ш. Мин һаман карышам, киреләнәм, озак бәхәсләшә торгач, Кариев бик үтемле итеп...

К а р и е в. Заһидә туташ! Милләт өчен! Милләт өчен риза булыгыз, зинһар!

З а һ и д ә т у т а ш. Милләт өчен риза булыгыз, диде. Ул вакытта "милләт" сүзе гаҗәеп бер могҗизалы сүз иде, Гаяз Исхакыйның үтемле итеп әйткәне дә кинәт искә төште, мин түзмәдем: ярый, Габдулла әфәнде, мин риза! дидем.

К а р и е в. Тәшәккүр, Заһидә туташ! Иртәгә үк репетициягә килегез. Тик, зинһар, сез дә әллә кайдагы кешегә кияүгә чыга күрмәгез!

З а һ и д ә х а н ы м. Сумбатовның "Лачыннар һәм козгыннар" исемле пьесасында мин олы хатын ролен башкардым. Уңышсыз түгел иде. Хәтерем яхшы, тавышым яхшы, мин бик тиз отып ала идем сүзләрне, хәтта партнерларның сүзләрен дә яттан белә идем, онытсалар, пышылдап кына әйтеп җибәрә тора идем. Синяева мәхәббәт гүзәлен уйнады. Начар уйнамады. Финалда тамашачы аягүрә басты. Тинчурин:—Баш иегез, туташ, диде. Тамашаның уңышлы чыкканын шул сүздән аңладым. Бу Синяева белән минем уңыш иде.

**Кара Шәүлә күренә. Ул кемнедер алып китәргә чамалый.**

З а һ и д ә т у т а ш. Ләкин Әшрәф Синяеваның хантамасы артык биек иде. Чибәр, зифа буйлы, тавышы матур, җырлый, бии, искиткеч мәхәббәт гүзәле иде ул. Ләкин ул татарларга өстән, кимсетеп карый иде, әйтерсең лә үзе француженка! Юкса, минем туганнарым Алкиннарның утарында управляющий булып эшләүче абзыйның кызы гына. Ә борын—күкләрне тишеп чыгар. Урысча гына сөйләшә. Анысын да француз сүзләре белән аралаштырган була. Бер тапкыр әйтә бу миңа:—Мадемаузель Загидэ, у татар культура отсталая, татары неграмотный народ, диде. Мин әйттем:—Вы образованная татарка, вот вы и поднимайте его культуру! Йотты, каршы бер сүз дә әйтмәде. Театрда ул әллә ни озак эшләмәде, Ситдыйк Айдаровка кияүгә чыгып, Казанны тарсынып, театр оештырырга дип, Петербургка китте. Ситдыйк Айдаров бик талантлы артист иде, буй-сын, тавыш, җыр, бию. Ситдыйк Биектау ягының Чыршы авылында туып үскән егет иде. Казанга килеп театрга эшкә керде. Хатын-кызлар аны сырып ала иде, бер дә буш тотмадылар. Әшрәф ханым анда да, Питербургта да озак яши алмады, яшьли вафат булды. Ситдик Айдаров 1938 елда юкка чыкты. Аны җәзалап үтерганнәр икән, дип сөй-

ләделәр. Авыр туфраклары җинел булсын.

Кичерегез, мин озак сөйлим. Арсагыз, әйтегез... Алайса, дәвам итәбез... "Дәвам итәбез"ме, әллә "дәвам иттерәбез"ме?.. Сез—язучы, сез белергә тиеш. "Әз"ме, "аз"мы, "хәзер"ме, "әзер"ме, "әче"ме, "ачы"мы? Татар теле язучылар, галимнәр тарафыннан бер эквивалентка китерелмәгән, журналисты да, язучысы да, галимнәре дә надан булгач, нишләп шулай булмасын! Кичерегез, мин сезнең турыда әйтмим... Мина калса, "әз" булса, тотып булмый торган әйберләр турында: hава, су, уй... "Аз" булса: кеше, акча, алма... "Әзергә бәзер" гыйбарәсеннән чыгып, фикер йөрткәндә "әзер"—"готовый, на всем готовом" булыр, "хәзер" ул "сейчас" буларак кулланылган. "Әчегәнкупчегән" гыйбарәсеннән чыксак, "әче"—"кислый", "ачы"—"горький" булырга тиеш. Ул телефон кенәгәсен алып баксан—этбашсыераяк. "Батруддинов, Бадурттинов, Бедретдинов"—ташка үлчим... Нәрсә дип калган идем әле мин?.. Аh, әйе, Тинчурин!.. Сез бит картаеп беткән Заhидә янына Тинчурин турында сораштырырга дип киләсез... *(Астар белән, үпкәләп.)* Тинчуринның хатыны—Шаhбазгәрәй Әхмәров кызы Заhидә шәхесе сезне кызыксындырмый бит, так себе, Тинчурин шәхесенә мичәү буларак кына кирәк мин сезгә... Мичәүме? Бетте татар теле, татарның язучысы да "мичәү" сүзен белмәгәч, булмый инде ул Ана теле. Инкыйраз билгесе шул бит инде, балакайларым: тел, Ана теленең бетүе. *(Кыза бара.)* Каян алдыгыз сез шул "Туган тел" дигән тәгъбирне? Тукай язган! Урыс шагыйренең "Родной язык" шигырен Тукай "Туган тел" дип тәрҗемә итүе аркасында гына "Ана теле"н үтерикмени?.. Ие, "мичәүгә җигелгән ат", пар атның сынары, төпкә җигелә яхшы ат, аның янына, бау белән генә тагылган, тартыр-тартмас ялкауланып бара торганы "мичәүләнгәне" була. Тинчурин—төпкә җигелгән яхшы ат, Заhидәсе, тәк сибә, ияреп баручы гына, дип карыйлар бит минем шәхесемә. Бәлки, Кәрим Тинчуринны Кәрим Тинчурин иткән, аның күз карасы кебек әсәрләрен яшереп-качырып-посырып саклап калган шәхес—ул Шаhбазгәрәй Әхмәровның кызы Заhидә ханымдыр?.. Гафу итенмәгез, зинhар... Ирен саткан, ирен зинданда череткән хатын, әнә, ире аклангач, хәзер даhи хатыны булып президиумның алдында утыра. Әнә, үлем түшәгендәге ирен ташлап, башкага ияреп киткән хатын ире аклангач, хәзер даhи хатыны буларак, ире турында истәлекләр яза. "Мактаулы пионер" булып мәктәптән мәктәпкә йөри. Алар турында радио-телевидение сөйли, язалар, әңгәмә өчен артларыннан аулап йөриләр. Минем янга килеп караган кеше дә юк. Әйтерсен лә мин "Сәйяр" труппасында биш ел артистка булып эшләмәгән. Әйтерсең лә мин алтмыш ел әдәбият укытмаган. Ни Язучылар берлегеннән, ни театрлардан килеп кызыксынсыннар. Ничек яши Тинчурина, яшәргә, торырга урыны бармы Тинчуринаның? Житмеш бер яшемдә генә минем үз почмагым булды. Әйтерсең лә мин... Һәй, төкер башына... картая башладым, зарланам... илле ел эт типкәсендә яшәп тә зарланмаганнарым бүген чыга. Син үзең мине гафу ит... *(Ачуы кайта, тынычлана, көлемсери.)* Чыннан да, мина әйтәләр иде: Заhидә ханым, Тинчурин сезгә өйләнеп алгач, тибешрәк эшли, яхшырак яза башлады, диләр иде. Әлбәттә, ярарга тырышу да булгандыр мондый салпы якка салам кыстырулары-ның, әмма мин горурлана идем Кәрим белән. Уйлап бакканым бар, чыннан да, Кәрим безнең никахтан соң аеруча күп эшләгән. Бәлки, бу очраклы гына туры килүдер, әмма дөресе шул. Аның минем күз алдымда язган, язып бетерүгә мина укыган әсәрләре: "Американ", "Сүнгән йолдызлар", "Җилкәнсезләр", "Зәңгәр шәл", "Кандыр буе", "Хикмәтле доклад" һәм иң шәбе—"Мәрҗәннәр". Болар татар халкы яшәгәндә үлмәс әсәрләр... Тинчурин турында ни сөйлим икән сон? Шундый-шундый эшләр, тора-бара нишләр, терекөмеш буаны тишәр, ди торган иде мәрхүмә Гөлсем Болгарская... Алай-болай бәхәс чыкса, өйдәгеләрне үрти идем:—Ачуымны китермәгез, юкса, Сара тәтәм кебек урыска чыгармын!

Х ә д и ч ә  х а н ы м. Авызыннан җил алсын!

З а һ и д ә  т у т а ш. Ильяс белән Даут абыкайларым маржага өйләнде, Сара тәтәм чукынуның аргы ягына чыгып, католичка булды, ә нигә мин генә чукынмаска тиеш?

Х ә д и ч ә  х а н ы м. Алай әйтмә, Заhидә, алай телмә бәгырьне.

З а һ и д ә  т у т а ш. Ничек әйтим сон?

Х ә д и ч ә. Ичмасам, маржа булды, диген.

З а һ и д ә т у т а ш. Юк, анакаем, кызын Сара маржа булмады, ин сөекле кызын Сара чукынды. Маржа булу куркыныч түгел, керәшен булу да куркыныч түгел, ә менә көпә-көндез атасын, анасын, денен, телен, туганнарын ташлап, католик булу ул инде, Гаяз әфәнде әйтмешли—инкыйраз.

З а һ и д ә х а н ы м. Анакаем бик нык каушаган иде, хантамасы шактый шиңгән иде инде. Ул үзенен бөек хатасын аңлаган иде. Ләкин инде сон иде. Ул, шәрык-татар йолаларында тәрбия алган кыз, статский советникнын хатыны булып алгач, балларда, югары даирәләрдәге мәҗлесләрдә оятка калмас өчен, урыс телен, әдәбиятын, француз теле, дөнья әдәбиятын үҗәтлек белән өйрәнә башлаган кеше. Балаларым татарлар кебек мокыт булып калмасын, дип аларга урыс-европа тәрбиясе бирергә бөтен көчен сарыф иткән батыр хатын, ләкин ул хәттин ашкан хатын иде. Европа, урыс культурасын, әлбәттә, өйрәнергә кирәк, әмма үз культурана игътибарсыз калырга ярамый иде. Анакаем урталыкны тота алмады. Урталык ул шәрык белән европаны тигез өйрәнү. Урталык ул—Шекспир, Толстой, Достоевский, урталык ул—Тукай, Фатих Әмирхан, Заһир Бигиләр...

З а һ и д ә т у т а ш. Анакаем котчыккыч хатасын аңлаудан тәмам гажиз булды. Аның соңгы өмете мин—төпчек кызы Заһидә идем. Аның соңгы омтылышы: хет мине саклап калу, милләт өчен саклап калу иде.

З а һ и д ә х а н ы м. Ул чакта, халык дошманнары булмаган чакта, Казанында Шәрык һәм Европа мәдәниятында тәрбия алган ике куәтле нәсел алда бара иде. Әхмәровлар, Терегуловлар нәселе. Әхмәровлар мәгърифәт йөген үзенә алган нәсел, Терегуловлар нәселе мәдәният өлешен химаягә алган иде. Ибраһим Терегулов Казанда Шәрекъ клубын оештыруда башлап йөргән кеше. Алар арасында Гыйздетдин Сәйфел Мөлеков тә бар. Халыкара журналист Фәрит Сәйфелмөлековнын атасы. Терегуловнын кызлары ике яклап та яхшы белем алган заман кызлары иде. Анакаем мине татар ягына тартыр өчен соңгы көчен сарыф иткәндер, ихтимал. Мин өлгереп житкән яшь кыз. Озакламый кияүгә бирергә кирәк. Ә мин күбесенчә урыслар белән аралашам. Анамның максаты, ничек тә булса Заһидәне мөселман-татар кешесенә кияүгә бирү иде. Ярлы булса да, бары тик татар кешесенә генә чыксын. Терегуловлар белән кинәшеп, анакаем мине татар җәмгыятенә тартырга яшерен план кора. Нишләптер монарчы сирәк күрешә торган Мәдинә Терегулова безгә еш килә, "очраклы" рәвештә генә йә кибеттә, йә урамда очрый. Дуслашып киттек. Шәрык клубына мине ин беренче әнә шул Мәдинә Терегулова алып барды. Заһидәне татарлаштыру операциясе әнә шулай башланды. Ул мәсьәләдә Шәрык клубы бик зур әһәмияткә ия иде. Хәзерге Камал театрына каршы яктагы бина да иде ул "Шәрык клубы". Татарнын бөтен зыялылары шунда туплана, шунда аралаша иде. Шәрык клубы булмаса, Мәдинә туташ мине шунда алып бармаган булса, Кәрим Тинчурин белән без очрашмаган да булыр идек. Гомерем буе мин Мәдинә Терегуловага рәхмәт укыдым. Терегуловларнын тамыры борынгыга барып тоташа. Терек угыл, Тере кол, Терегол Казан ханлыгында бик олы урын тоткан бәк. Бу кеше Казан дәүләтенең Мәскәүгә юллаган илчесе булыр. Бу нәселнен очы әнә шул Әбүбәкер Тереголов, Ибраһим Тереголовларга килеп тоташа. Терегулов фамилияле кеше укымышлы, олы дәрәҗәле булыр. "Шәрекъ клубы"нын сәхнәсе бик кечкенә иде аның. Ләкин "Гамлет"ны, "Макбет"ны, "Отелло"ны шунда теттереп уйныйлар иде татарлар. Меценатлары бар иде. Алар тамаша вакытында беренче рәттә утыра. Берәр артистнын бенефисы булса, татар байлары бик олылыйлар иде артистларны. Акча, алтын сәгать, алтын чылбырлар бүләк итәләр иде. Спектакльдән сон кыллы оркестр меллдермеллдер итеп уйнап жибәрә. Нигездә мандолина иде оркестрнын. Тан атканчы рәхәтләнеп биибез. Вальс та бии идек, ул чакта падеспан, краковяк, хиялатто, мазурка, кадриль бии идек. Ул чакта "туташ" сүзе бик кин таралган иде. Своеобразную, интересную эпоху пережили мы. Татар зыялыларынын үсә башлаган чоры иде ул. Кариев би-ик зур фигура. Аны әле бәяләп бетергәннәре юк. Габдулла Кариевтан кала Галиәсгар Камалдыр, Мирхәйдәр Фәйзидер, аннан Кәрим Тинчурин. Ин беренчесе—Кариев! Ул театрнын атасы, башка беркем дә

анын урынын алалмый. Бөтенесенең исемнәрен театрларга биреп бетерделәр, Кариевка өлеш чыгарганнары юк. Менә бу алтын тартмачыкны химаячы бай сәүдәгәр Мусин бүләк иткән иде. Артына "Любимому автору и бенефиссианту К. Тенчурину *(Узбеку)* 1917, 31 март, от М. Мусина" дип язылган. Кәримнең сәхнә кушаматы Үзбәк иде. Татарның мәшһүр байларыннан Хөсәенов килеп керә беркөн Шәрык клубына. Мелдер-мелдер мандолина уйный, без шайтан чабып биибез. Бу бай үзе бер сыйныф та укымаган, әмма сәнгатьнең, мәгарифнең халык өчен кирәклеген яхшы аңлаган химаячы иде. Нишләп сез, татарлар рояльгә биемисез, дип кесәсеннән шундук акча чыгарып, кешеләрен рояль алырга җибәрде. Ап-ак рояль иде ул. Китереп куйдылар ап-ак рояльне, шуннан соң оркестр булмаганда рояльгә бии башладык. *(Көлә.)* Төннәр буе бии идек. Бию арасында "Почталы" уйнау була иде. Кызларга жегетләр, жегетләргә кызлар хат яза, имзасын куймый, яки мәхәббәте турында яки яратмаган яклары турында яза. Бер жегетме, кызмы мина хат язган. "Заһидә туташ, сезнең гәүдәгез бик зифа, тәнегез дә бик матур, сез яхшы биисез, күбәләк кебек очып кына йөрисез, сез белемле, культуралы, затлы кеше, ләкин сезнең борынызыз ямьсез, шул борын сезнең йөзегезне бозып тора", дигән. *(Көлә.)* Бер дә исем китмәде. Мине бу пырлап чыгып китәр, дип өмет иткәндер инде бичара. Хатны иплэп кенә төрдем дә кесәмә салып куйдым. Шуннан соң Ситдыйк Айдаровны биергә чакырдым. *(Заһидә туташ белән Айдаров бию.)* Ул бик яхшы бии, прекрасный партнер на сцене. Без икәү бии башласак, башкалар биеми, безгә карап тора иде... Галия Кайбицкаяга Такташ әйткән шундый кичәләрнең берсендә: Заһидә ханым кебек сылу-зифа буйлы кыз Казанында юк!—дигән.

Заһидә туташ. Безнең кичәләргә татарларнын каймагы гына йөри иде. Сәяси комментатор Фәрит Сәйфел Мөлековнын атасы Гыйздетдин Сәйфел Мөлековлар, Солтан Габәшиләр, Фатих Әмирханнар, Галиәсгар Камаллар, Мутиннар, Солтановлар, Тукайны да анда очратып була иде. Кызык яши идек. Матур яши идек. Иртәнге дүртләргә чаклы күнел ачабыз. Ләкин шәраб эчү юк. Безгә шәрабсыз да бик күнелле була иде. 1910 елда Габдулла Тукайны мин Шәрык клубында тынлаганым да бар. "Халык әдәбияты" турында Тукай нотык сөйли, дип бөтен дөнья шау итте. Басып торырга урын юк иде. Шуннан соң Тукай озак тормады, вафат булды. Без урыс гимназиясендә дүрт татар кызы укый идек. Реверанс ясап, сыйныф житәкчесеннән үтенеп сорадык: Лидия Петровна, у нас великое горе, скончался поэт Тукай, наш татарский Пушкин, разрешите уйти с уроков, дидек. Һичсүзсез җибәрделәр. Йөгердек Клячкинга. Сафсаф булып, озата бардык. Зиратка кермәдек. Ул чакта гореф-гадәт бик нык иде, без - хатын-кызлар зират капкасы янында калдык. Озата баручылар арасында курсисткалар, гимназисткалар, "Высшие женские курсы"ларда укучылар, реальное училищедә укучылар, эшчесе, крәстиәне—барысы да жылый иде. Без дә кызлар белән жылый-жылый шешенеп бетек. Ил кайгысы иде Тукай. Авыр туфрагы жинел булсын.

Тинчуринга һаман килеп житә алмыйбыз әле. Мәдинә Терегулова кияүгә чыкты, мине туена чакырды: килми калма, мәжлестә Тинчурин да була, ди бу. Мактый инде Тинчуринны, теттереп мактый. Киттем туйга. Туй башланды. Тинчурин юк. Кайда синең Тинчуриның?—дип сорыйм Мәдинәдән. "Хәзер килеп житәр, бераз сонга каладыр". Туй уртасы житте. Тинчурин юк. Таралыр вакытлар житкәч кенә: Кәрим абый килде, Тинчурин килде, дип пышылдаша башладылар. Беренче тапкыр мин Кәримне шунда күрдем. Ошамады мина сезнең Тинчуриныгыз. Без студентлар белән гитара уйнап, жырлап утыра идек, Тинчурин килеп керде дә, төксе генә исәнләшеп, пианинога таянып, без жырлаганны тынлап торды-торды да чыгып та китте. "Шушымы инде синең бик мактаган Тинчуриның?"—дим Мәдинәгә. Ул да аптырый. Күрәсең, ул синең студент жегетләр янында жырлап утырганынны ошатмагандыр, диде Мәдинә. Шуның белән бетте.

Заһидә ханым. Ул вакытта Шәрык клубына киткәндә анакаем мине Җиһангир Алкинга житәкләтеп җибәрә иде. Җиһангир минем таң атканчы биегәнемне көтеп утыра. Аннан түкмичәчми анакаема алып кайтып тапшыра. Кичә башланганда жегет кеше күзе

төшкән кыз янына килеп:—Туташ, бүгенге кичәдән соң сезне озата кайтырга мөмкинме? дип—сорый иде. Җиһангир килә алмаганда мине дә төрле егетләр озата иде.

**Мутин Заһидә туташ янына килә. Кара Шәүлә күренә. Мутин кая барса, Шәүлә аннан калмый.**

З а һ и д ә т у т а ш. Беркөнне минем янга Мутин килде. Һо-һо, Мутин! Мутин тау кебек биек, шәхес буларак бөек! Мин аның Шекспирны уйнаганын күреп шаккаткан идем. "Заһидә туташ, бу кичәдән соң сезне өегезгә озата барырга буламы?" диде. Мин ике дә уйлап тормадым:—Була Мохтар әфәнде!—дидем. Кич буе дус кызларым тенкәмә тиеп беттеләр: ничек инде, Заһидә туташ, син шул аю кебек тупас, тәрбиясез кешегә озатырга рөхсәт иттең?—диләр. Мохтар Мутинның шундый яманаты чыккан иде. Һо-о, тупас түгел иде ул, тәрбиясез дә түгел, укымышлы морза нәселе. Беренче бөтендөнья сугышы каһарманы. Бөек трагик. Юлда кайтканда ул мине күз карасы кебек саклап алып кайтты, аерым урыннарда гына терсәгемнән сак кына тотып, куркыныч урынны кичерә иде. Аның тавышы! Аның сөйләшү манерасы искиткеч иде. Юан, куе, бәрхет тавышлы иде ул. Салмак кына сөйләшкәндә дә күк күкрәгәндәге кебек, күкрәк аз гына вибрация кичерә. Органның ин түбән тавышы кебек, салмак куәт ургый иде аның күкрәгеннән. Ир дисән дә ир, актер дисән дә актер. Ул мине озатып куйды, мин аның авызыннан ник бер әдәпсез сүз ишетим! Мутин театрның наданнарыннан көлә иде. Тупас, мәгънәсез сорауларга тупас һәм мәгънәле итеп җавап кайтара иде. Шуна күрә, тупаслар, наданнар аны сөйми иде. Шулар, тупаслар, наданнар Мутинны харап итте дә инде. Егерме дүрт көн буе Мохтар Мутинны судить иттеләр театрда. Бөтенесе Мохтар Мутинны "халык дошманы" дип атады. Аны төрмәдә этләрдән талатып үтерделәр.

**Кара Шәүлә Мутинга җиле белән кагылып китә. Мутин егыла.**

З а һ и д ә х а н ы м. Нинди бөек кешене харап иттеләр.

З а һ и д ә т у т а ш. Тинчурин белән икенче очрашу Шәрык клубында булды.

**Кәрим Тинчурин белән Заһидә туташ.**

З а һ и д ә х а н ы м. Ул мине озатырга теләде: минем озатучым бар, дидем. Ул:—Мутинмы?—диде. Юк, Мутин түгел, Җиһангир әфәнде!—дидем. Мин Кәримнең Мутиннан көнләшкәнен сиздем. Аның көнчелеген котыртасым килеп:—Җиһангир озата, дип, аеруча басым ясап әйттем. Тинчурин төшеп калганнардан булып чыкмады. Башка бер вакытта, биюләр беткәч, кайтырга җыенганда: бирегез номерыгызны, дип мин җавап бирергә әзерләнеп өлгергәнче кулымнан номерымны алып, киемнәрне күтәреп читкә алып китте. Мина киенергә булышты. Мин ана озата кайтырга рөхсәт иттем... Юл буе Тинчурин берни сөйләмәде, берни сорашмады. Мин дә сораштырмадым. Капкага җиткәч, тыныч йокы теләп, Тинчурин кайтып китте. Шуннан сон кичәләрдән мине гел Тинчурин озата кайта башлады. Мин инде аның озатуларына күнегеп беттем, ул булмаса, ул озатмаса, әллә ничек, читен-уңайсыз, күнелсез була иде. Мәктәптән чыкканымны да Кәрим көтеп тора. Соңгы озатуында мин:

—Кәрим әфәнде, безнең өйгә дә кереп утырыр идегез!— дидем.

—Башка вакытта!—дип, Кәрим кайтып китте.

Бервакыт мин өйдә юкта Тинчурин безнең өйгә килгән. Мин кайтып кердем. Тинчурин анакаем белән чәй эчеп, сөйләшеп утыралар иде. Мин бүлмәмә узып киттем. Мин бүлмәмнән чыкканда Тинчурин киткән иде инде.

Х ә д и ч ә х а н ы м. Бик иплe икән синең Тинчуриның. Татарчасы да бик яхшы, укыган кеше.

З а һ и д ә т у т а ш. Юк-бар нәрсә белән шаяртсалар, мин бик көйсез кыз идем, ләкин анакаемның "Синең Тинчуриның" дигәненә ни өчендер ачуым килмәде. Анам бик укымышлы кеше иде минем. Толстойны яттан белә, аның берничә әсәрен татарчага тәрҗемә итте, Орынбурда басылып чыкты ул тәрҗемәләре. "Камско-Волжская речь"ны хәрефен хәрефкә укып бара. Корьәнне яхшы белә. Аларның сөйләшергә сүзләре күп булгандыр. Анакаем Тинчуринны бик ошатып калган иде. Тинчурин инде минем үземә дә ошый башлаган иде.

Х ә д и ч ә. Кызым, сине Тинчуринга кияүгә чыга, дип сөйлиләр, хакмы шул?

З а һ и д ә т у т а ш. Анакаем, мин сина әйтмичә кияүгә чыгаммыни инде?

Син фатиха бирсәң, мин Тинчурингә чыгар идем, дидем.

Х ә д и ч ә. Ул синең кадереңне белерме соң?

З а һ и д ә т у т а ш. Әнием, ни булса да, мин Кәримне яратам.

Х ә д и ч ә. Алайса, фатиха, кызым! *(Елый.)* Рәхмәт, кызым. Сүземне аяк астына салмадың. Ичмасам, син бәхетле бул!

З а һ и д ә х а н ы м. Ул вакытта анамның хантамасы төшкән иде инде. Йортыбызны реквизировать иткәннәр иде. Керем юк, без үз йортыбызда килмешәк шикелле, квартирантлар булып яшәгән чак. Сайланып торыр җай юк. Кәрим Тинчурин дворян кызын байлыгы өчен генә алды, дип сөйләнүчеләр аз булмады. Кәрим безнең чабаталы морзалар икәнебезне белә иде. Анам аңа алдан ук барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп биргән.

З а һ и д ә т у т а ш. 1919 елда без Кәрим белән никах укыттык. Анакайлар, тутакайлар зурлап, туйлап тормадылар. Тары ярмасыннан ботка пешереп, мулла чакырдылар. Маһи тәтәм, Фатима такай, анакаем өчесе табын әзерләделәр. Чакырулы кунаклар килеп бетте. Никах вакыты килеп җитте дә узып та китте. Мулла да юк, кияү дә юк. Йорттагылар борчуга төште бит инде. Нишләргә дә, нишләргә, мир алдында оятка калабыз! Ух-вах килә халык. Мин, эчемдә ут булса да, үз бүлмәмдә тыныч кына утырам. Менә берзаманны ялтыравыклы көпчәкле фоэтонга утырып мулла белән Тинчурин кайтып килә. Кәрим күп итеп чәчәкләр алган. Кәләшенә бүләк юнәткән. Чин чином, никах бөтен тәртибе белән укылды.

З а һ и д ә х а н ы м *(көлә)*. Кәрим морза кызына өйләнгән, Тинчурин дворянка алган, дип көнләшүчесе дә күп булды. Ул дворянканың, ул морза кызының ашарга ипие дә юк. Икенче көнне Кәримнең кесәсендә сукыр тиене дә калмаган иде. Мулла белән фоэтонга, чәчәкләргә кереп беткән акчасы.

З а һ и д ә т у т а ш. Никахлашканнан соң без дүрт ел яшәгәч кенә ЗАГСка бардык. Кәрим әйтә: дин кануннарын тоттык, инде дәүләт канунынча да булсын, дип мине ЗАГСка алып китте. Ике татар кызы утыра. Икесе— маржа. Без килеп кергәч, маржасы сорый:—Вы пришли оформлять документы для вашей дочери? Татар кызлары пырхылдап көлә башладылар. Кәримне таныйлар, аның монарчы өйләнмәгәнен беләләр. Юк, ди Кәрим, без никахыбызны рәсмиләштерергә килдек. Мин Кәримнән ун яшькә кече бит. Ул олырак күренгәндер инде. Маржа тагын сорый:—Бу сезнең ничәнче өйләнүегез? Татар кызлары тыела гына алмый, көләләр. Кызларның берсе кычкыра: "беренчесе, беренче тапкыр өйләнә Кәрим абый", ди. Шунда Кәрим әйтеп куйды:—Беренчесе һәм соңгысы.

З а һ и д ә х а н ы м. Шулай булды да. Мин аның беренче һәм соңгы хатыны. Ул да минем беренче һәм соңгы ирем... Кәрим белән мин унсигез ел бәхетле булдым... Анакаем үзе дә сизмәстән минем алда Сара белән Суфияны бик нык мактый иде.

З а һ и д ә т у т а ш. Ачуым чыкты да әйттем:—Анакаем, мин сиңа үги бала булдым инде, аларны назлаган кебек миңа наз эләкмәде, алар белән мәтәвекләнгәнең кебек миңа игътибарың булмады, дидем. Мин ярсып әйттем бу сүзләрне, бу минем сабый чактан килгән үпкәм иде. Анакаем аптырап калды, кушады һәм гомергә ияреп килгән ялгышын аңлады кебек.

Х ә д и ч ә. И кызым Заһидә, син Кәримең белән бәхетле бит. Тегеләрнең, ни Маһипәрвазымның, ни Суфиямның, ни Сарамның бәхете булмады бит. Кичер мине, кызым, кичер.

З а һ и д ә т у т а ш. Мин дә ялгышымны аңладым. Ана кешегә алай каты бәрелмәскә иде... Анакаем, гафу ит мине, кызың киттем... кичер, анам...

Х ә д и ч ә. Мин синең бәхетле булуыңа сөенеп җылыйм, балам. Күз тимәсен сезнең бәхеткә. Йа, Раббым, шушы баламны бәхетеннән мәхрүм итмә, зинһар, ялварамын Сиңа, Тәңрем, сакла бу ике затның якты бәхетен. Минем бөтен куанычым Кәрим белән Заһидә...

З а һ и д ә х а н ы м. Анакаем ялгышмый иде, Кәрим белән без матур гаилә идек.

З а һ и д ә т у т а ш. Өйләнер алдыннан Кәрим миңа:—Сез минем иң кадерле хатыным булыр идегез, диде. Нәкъ атакаем Шаһбазгәрәйнең булачак хатыны Хәдичә туташка язган хатындагы кебек. Унсигез ел торганыбызда мин Кәримнән ул командировкаларда чакта нибары дүрт хат алдым. Беренче хаты

“Заһидә” дип башлана. Калганнары “Заһидәм” дип башлана. Без беркайчан да бер-беребезгә мәхәббәт аңлатмадык, яратам, сөям, дип әйтмәдек. Әмма мин Кәримнең мине сөйгәнен тора-бара гына аңладым. “Заһидә” сүзенең азагына “м” хәрефе генә өстәгән, бу мина “минем Заһидәм, Сөекле Заһидәм, мин сине сөям” булып ишетелә иде. Ул мине бик иркәли иде. Кәрим бик яхшы ир, бик яхшы дус иде.

Мәрвәр. Кәрим сина утыз ике яшендә өйләнде, сина кадәр аның кемнәре генә булмагандыр. Нигә син аның узганнары турында белешмисең… миннән, әйтик… мин сөйли алган булыр идем, Заһидә ханым.

Заһидә туташ. Сораштырмадым, кызыксынмадым, иремнең мина кадәр булганнары мине һич тә кызыксындырмый.

Мәрвәр. Аның кайларда булганын яхшы белүчеләр бар…

Заһидә туташ. Кайда гына булса да, ул барыбер минем янга кайта ич! Кызык бу кешеләр, валлаһи, мин Кәримне сагалап йөрергә тиешме, шулай итеп үземне түбәнгә куярга тиешмени?

Заһидә ханым. Бәлки мин Кәримнең узганнарында казынмыйча, аның артыннан шымчылык кылмыйча, иремне үземә бәйләп тотканмындыр. Бәйләнсәм, мәҗлесләрдә гауга куптарсам, сөенер иде бу хатын, ә ирем мине ташлап чыгып китәр иде. Кәрим ул өйдә, минем янда бәхетле иде. Анакаем белән аларның серләре килешә, тулысы белән бер-беребезгә ярашкан гаилә идек без… *(Көлә.)*

Заһидә туташ *(көлә)*. Бер тапкыр әллә кайсы гына бәйрәмдә, театрда, Мәрвәр ханым мине танцы бүлмәсенә алып китте.

Мәрвәр. Әйдәле, Заһидә ханым, бер әйбер күрсәтәм… Әнә, Тинчуриның ни кылана… Ике тез башына ике кызны утырткан.

Заһидә туташ. Утыртса соң, яткызмаган бит. Ул аларны ирексезләп утыртмаган, кызлар үзләре Кәримнең тезенә менгән.

Заһидә ханым. Мәрвәрнең җен ачуы чыкты. Ул минем Кәримнең чыраена тырнакларым белән ябышуымны көткәндер инде. Ябышмадым. Исем дә китмәде. Мунчага кермәгәннәр бит. Әгәр дә шунда мин гауга куптарган булсам, Мәрвәргә дә башкаларга да и рәхәт булыр иде. Бәйрәм ясарлар иде. Мин ямьсезләнсәм, Кәрим миннән бизгән булыр иде. Кәрим ул хатын-кызлар арасында нарасхват булды. Дәшмәдем, гауга куптармадым, мәҗлестән икебез бергә кайтып киттек, мин бер сүз әйтмәдем, ул да гафу сораган булып, сүз кузгатмады. Шуның белән бетте. Мәрвәр төне буе йоклый алмаган. Ирен үзеннән мәһабәтрәк, чибәррәк икән, син дә үз урыныңны чамала инде. Кәрим мина ир генә түгел, ул минем остазым да иде. Кәрим төне буе пьеса яза да, мине уятып укый, мин ана әсәр турында фикеремне әйтәм, аннан соң иртән бер-ике сәгать кенә ятып ала. Театрдан Кәримне алырга килгән саен Кәримнең йокыдан торып кына килгән чагы була. Кәрим олы гәүдәле иде бит ул. Кәрим абый йокы чүлмәге бит ул, ашый да йоклый, ашый да йоклый, шуңа күрә симерә, диләр. Йокы чүлмәге булса, көне буе театрда эшләп, шул кадәр пьесаларны, мәкаләләрне кайчан язар иде икән? Төне буе тәмәке тарта, пьеса яза. Бик эшчән кеше иде ул, эш аты, Кәримдә ун кешелек җегәр бар иде… Борыным ямьсез булып чыккан минем, ямьсез булса да, Кәрим иң гүзәл хатыннар арасыннан мине сайлады, мин шуңа горурланып яшәдем… Унсигез ел рәхәт яшәп калдым Кәрим белән. Калганы мәхшәр булды. Халык дошманнары юк чагында рәхәт иде. Халык дошманнары күбәеп киткәч, тормыш бетте, хаос, мин үзем дә халык дошманының хатыны булып киттем… Без Кәрим белән бик тату-сабыр яшәдек. Бер-беребезгә көнләү ямьсезлекләре күрсәтмәдек. Әүвәл мәҗлесләрдә ир белән хатын парлашып утыру юк иде. Ир-хатын парлашып кунакка килә, бергә кайтып китә. Ә мәҗлестә аерым-аерым утыралар. Хәзер күрәм, кунакта ир-хатынны янәшә утырталар. Ичмасам, кунакта башкалар белән аралашырга кирәк. Кәрим һәрвакыт дамалар арасында утыра. Мин дә ир-егетләр уртасында була идем. Мине бик ухаживать итәләр иде, борыным ямьсез булса да, игътибар уртасында идем. Безнең шулай иркенләп йөргәнебезгә күпләрнең эче поша иде. Мин музыка яратам, җырчылар, скрипкачылар, органчылар, Италия, Мәскәү, Петербург артистларының концертларына йөрим. Нежданова,

Игумнов, Гольденмейерларны тыңлыйм. Кәримнең вакыты булмый. Җә ул репетициядә, җә спектакльдә. Шулай да бернечә тапкыр Кәримне дә дөньякүләм мәшһүр музыкантларның концертларына алып баргаладым. Ойстрахны, Обуxованы бик яратып кайтты Кәрим... Шаккатам мин кайбер хатыннарга: иремнең кесәсеннән мәгъшукасының хатын таптым, мин иремне фәлән хатын белән тоттым, дип башкалар алдында мактанып сөйләшүчеләрне мин аңламыйм. Кәрим сигез ай Әстерханда ялгызы булды. Килеп күнелемә вәсвәсә салырга тырышучылар күп иде.

М ә р в ә р. Нигә Әстерханга төшеп менмисең, Зәһидә ханым, Кәрим анда ялгызы бит.

З а һ и д ә т у т а ш. Әстерханда мина ни калган... Кәрим нигә ялгызы булсын, аның анда театры бар ич.

М ә р в ә р. Театры бар шул, театрда чибәр-чибәр хатыннар да күп. Кәрим тик ятмый торгандыр, тикшер, кара...

З а һ и д ә х а н ы м. Мин Кәримгә ышана идем. Ул ир кеше. Әгәр ул башкаларны коча икән, кочсын. Мин моны хыянәт дип атамыйм. Ишетсәм дә белмәмешкә, ишетмәмешкә салышам. Ул барыбер мине ярата, ул барыбер минем янга кайта. Ни әйтсәң дә, ир кешегә сигез ай хатынсыз тору шактый катлаулы эш. Әгәр дә аның өчен чит-ят бер хатынга өйләнгәнемне сизенсәм, менә бу хәлне мин кичерә алмас идем. Концертлардан соң мине кавалерлар өйгә озата иде. Кем озатканын мин Кәримгә үзем әйтә идем. Сүз куерту юк. Миңа әйтәләр иде, какой же у вас красивый муж, диләр, янәсе, мин ямьсез, ирем матур.

З а һ и д ә т у т а ш. Театр халкы нишләптер мине сөймәде инде ул. Хәзер дә сөймиләр. Кәрим өйгә кайтып керер иде дә, ишек борысына сөялеп, өйдә рәхәт, дияр иде. Бу миңа: Зәһидә жаным, мин сине бик яратам, булып ишетелә иде. Мин ана рәхәт булсын, дип тырыша идем. Примуста аш пешереп, чәй кайнатып тора идем. Ир кеше хатыны белән бик яхшы торса да, эшендә уңыш казанса да, барыбер өченче бер мавыгу эзли башлый. Җә ул спорт белән шөгыльләнә. Җә башка берәүгә иялəшә. Кәрим фото белән шөгыльләнә иде. Чит ил фотоаппаратлары алды. Зурайткыч әсбаплар алды. Мәш килә иде. Аның германский сигез яхшы фотоаппараты гына бар иде. Абыйларым арасында үскәнгә мин ир кешенең психологиясен бик яхшы аңлый идем. Шул ярдәм иткәндер мина Кәрим белән тату яшәргә. Абыйларым мине ирекка куялар иде. Гимназиядә укыганда кызлар парта астына яшереп, ярамаган китаплар укый иде. Мин дә кызыгып йөрим. Кайттым да абыйларма әйттем: мина да табыгыз әле шундый китап, дидем. Абыйларым үзара мәгънәле генә карашып алдылар да:—"Сина аларны укымасаң яхшырак булыр. Бик укыйсың килсә—укы",—диделәр, шуннан соң минем кызыксынуым шиңде. Тыймыйлар ич. Кәримнең бавыры, бөерләре авырта иде, ул ел саен курортка бара. Мине дә үзе белән барырга кыстый. Мин бармыйм. Генерал утарына китәм.

—Зәйдә, син нигә минем белән ялга бармыйсың ул?—диде Кәрим.

—Син озын буйлы, чибәр ир, курортта гүзәл хатыннар күп була. Мишәйтләп йөрмим әле. Ату әйтерләр: кара, бу татар үзе чибәр генә, хатыны ямьсез икән, диярләр. Бар, үзең генә ял ит, дим. Шул чакта Кәрим: Һи, җүләр дә инде син, Зәйдә!—ди иде.

З а һ и д ә х а н ы м. Кәрим бик әдәпле ир була белде гаиләдә. Беркөнне әйтә: кеше хатыннары каракүл пәлтәгә акча жыя, нигә син каракүл кирәк, димисең ул? Каракүлгә акчанны әрәм итмә, дисәм дә беркөнне мул гына гонорар алгач, каракүл алып кайткан. Мин сөендем инде, әлбәттә. Кәрим Әбүбәкер Терегулов белән ярыша-ярыша комиссионкага йөри иде. Затлы савыт-саба күрсәләр, алдан алып калырга тырышалар. Проломный, хәзерге Бауман урамында комиссионный кибет бар иде. Менә бу кытай вазасын ул шуннан алып кайтты. Әбүбәкернең хатыны Әминә тәтә:—Их, Кәрим алдан өлгергән икән, аны Әбүбәкер алырга кызыккан иде,—ди.

З а һ и д ә т у т а ш. Кәрим, минәйтәм, "өйләндем" дип син өенә, авылына хат яздыңмы?—дим. Яздым, ди. Соң атан-ананның килен күрәсе киләдер бит, әйдә, дим, авылга кайтып килик... Сабыннар, башмаклар, читекләр төяп, авылга киттек. Кәрим атасы белән дус түгел иде. Әнисе—мулла кызы. Тәрбияле, укымышлы хатын иде, мәрхүмә. Кәримнең атасы наданрак

крәстиән иде. Алар турында имеш-мимешләр йөри иде. Янәсе, Шылдавыч мулласы Кәримнең атасына күп бурычлы булган икән. Шуна күрә, мулла кызын шушы мужикка бирергә мәҗбүр булган, диделәр. Хәлле крәстиән иде кайнатам. Каралты-кура нык. Ләкин ялчылар тотмый, үз көче, балаларының көче белән көләйгән хуҗалык иде ул. Шуна күрә, кайнатам Али Кәримне: хуҗалыкта калыр, кул арасына керер, ярдәмче булыр, дип үстергән, ана өметләнгән. Кайнанам исә: Мөхәммәткәрим зиһенле бала, аны укытырга кирәк, Казанга җибәрергә кирәк, дигән фикердә тора. Кәримнең атасы моңа каршы була, эшче куллар хуҗалыктан китә, лабаса. Әнисе яшертен генә Кәримне Казанга озата. Кәрим атасының фатихасын алмыйча киткән кеше. Шуның аркасында кайнанам белән кайнатам арасында гомерлеккә ризасызлык кала. Бәлки шуна күрәдер дә, Кәрим кунакка кайткач та атасы белән утырып сөйләшмәде. Атасы да гомер буе әшне минем аша йөртте. Ул турыдан-туры Кәримгә мөрәҗәгать итми иде. Кәрим дә атасына әйтер сүзен минем аша гына әйттерә. Кайнатам белән без бик дус идек. Ул һәрвакыт мина: Зәйдә, дип бик яратып эндәшә иде. Утызынчы елны Кәримнең атасын раскулачивать иттеләр. Улын, кызы белән киявен сөрделәр. Малларын, каралты-куралары, ике катлы йортларын талап Себергә сөрделәр. Сөргеннән атасы ялгыз гына кайтып төште. Кырып кына салганнар тегеләрен. Шыр ялангач, күлмәкчән генә кайтты кайнатам.

З а һ и д ә х а н ы м. Кәрим һаман атасына йомшамады. Ата белән угыл арасындагы бу татусызлыкка бик көенә идем. Икесенә дә читен, мина да читен.

—Кәрим, атаң бит, нигә син аның белән сөйләшмисең, нигә аңлашмыйсыз?—дип ялындым.

—Юк, Заһидә, үземне җинә алмыйм. Кыстама!— диде Кәрим.

Сүзне минем аша йөрттеләр. Ләкин Кәрим атасына акча җәлләми иде. Баштанаяк киендерде ул атасын. Ләкин кайнатам яна киемнәрен Казанда кимәде, авылга кайткач киярга саклады. Ул авылга кайтып керер алдыннан бер чокырга төшеп, юл киемнәрен салып, яналарын кигән. Аны сөреп йортына кереп утырганнар һаман сәләмә киемдә, бу жепбөртеген калдырмыйча таланса да әнә ничек бай киенеп кайткан, янәсе. Кайнатайда крәстиән психологиясе бик көчле иде. Көз житүгә кайнатай безгә килеп керә. Кыш буе тора да, тагын авылына кайтып китә. Шулай йөри торгач, ул авылында вафат булды. Урыны җәннәттә булсын!

З а һ и д ә т у т а ш. Кайнатамны мин эшчәнлеге өчен хөрмәт итә идем. Улыннан якты чырай тәтемәгәч, ул мина тартыла иде. Зәйдә, кибеткә барып килимме, кибеттән нәрсә алып кайтыйм, дип йомышка йөрергә ярата иде, авылда көне-төне эшләргә күнеккән, шәһәрдә эшсез торалмый... Ә минә кайнанам—Кәримнең анасы белән минем арада мәхәббәт иде. Анамнан мина наз эләкмәде. Аннан күрмәгән ана назын мин кайнанамнан татыдым. Мәхмүдә исемле иде, мәрхүмә. Бик сабыр, яхшы, матур хатын. Аның үзен тотышын күрсән, королевалар кебек, төз, мәгърур, аз сүзле, бик гүзәл хатын иде. Кәрим анасына охшаган. Кәрим белән анасы бер-берсеннән башка торалмый иде. Табын янында да гашыйклар кебек, берберсенә карашып, матур гына сөйләшәләр.

М ә р в ә р. Заһидә ханым, Кәрим анасын синнән күбрәк ярата, сизәсенме? Көнләшмисенме?

З а һ и д ә т у т а ш. Ана кешедән көнләшәләрмени? Кәрим әнисен ана буларак, мине хатыны буларак сөя, ә мин аларның икесен дә яратам, дип авызларын каплый идем... Һәм дөресе дә шул булды. Без өчебез дә бер-беребезне ярата идек. Кайнанам "Безнең Зәйдә" дип кенә тора иде. Ишегалдында утыручы карчыклар янында: безнең Зәйдә әмән күбәләк кебек, дип минем арттан сокланып кала иде. Ул мине үзенең кызы кебек ярата иде... Язып куегыз, язучы иптәш: мин ана мәхәббәтен бары тик Кәрим Тинчуринның анасы Мәхмүдә кайнанамнан гына татып белдем. Үз анамны мин хөрмәт итәм, кызганам, яратам да, ләкин Кәримнең анасы мина чын ана була белде. Ул рак белән безнең кулда вафат булды. Кәрим бик карады анасын. Янынан китми иде. Аны савыктырырга без бик күп көч куйдык. Ләкин узган иде инде. Кәримнең күз алдында җан тартты кайнанам. Әнисе җан биргәч, Кәрим "ah" итеп бер кычкырды да, күз яшьләрен йотып, жыла-

маска тырышты. Бик авыр кичерде ул анасының үлемен. Минем дөньяда ике кадерле кешем бар иде, берсе—Кәрим Тинчурин, икенчесе аның анасы Мәхмүдә кайнанам. Иннә лилләһи вә иннә иләйһи рәҗигун. Урыннары җәннәттә булсын! Алар икесе дә изге җаннар иде. Кәрим Тинчурин ул Кариевтән кала иң олы сәнгатьче иде. Шылдыр-былдыр гына түгел, төптән, тирәннән уйлап гамәл кылучы олы шәхес иде ул. Самарада татар театры өчен кадрлар хәзерләүне ул оештырып җибәрде.

Т и н ч у р и н. Остазыбыз Габдулла әфәнде Кариев башлап җибәргән изге эшне өстән-өстән генә, һәвәскәрләрчә генә, әйдә ярамаган тагын татарга, дигән өслүб белән башкарырга һич тә ярамый, иптәшләр. Мәктәп кирәк актерларга да, рәссамнарга да, драматургларга да, музыкантларга да. Белем кирәк бөтен сәнгатьчеләргә дә. Зыялылык кирәк татар театрына. Урамнан алып кереп, сәхнәгә уенчы чыгару вакытлары төкәнде. Без янача системада корырга тиеш үзебезнең сәнгатебезне. Аның өчен без Самара каласында студия ачабыз. Яхшы мөгаллимнәр чакырттык. Хәзер бары тик теләүчеләр арасында ярыш оештырырга калды.

З а һ и д ә х а н ы м. Һо-о, Самара студиясе ул үзе бер могҗиза иде. Драматург Тажи Гыйззәт, шәп актерлар. Әпсәләмов... Һо-о, Мифтах Әпсәләмов дигән шәп артист бар иде, 1927 елда вафат булды. Ул Иван Грозныйны, Ишанны уйнап күрсәтте халыкка. Аның ишаны ишаннарга ишан иде. Уразиков та ишанны яхшы уйный, сүз юк, әмма Мифтах Әпсәләмовны күргән кеше аларны чагыштыра алмый. Әпсәләмов белән бергә Әсгать Мәҗит, актер Хөсәен Уразиковлар шуннан чыккан шәхесләр. Теоретик белем дә Әпсәләмовта бик нигезле иде. Мин әдәбият укыттым. Ләкин Самара студиясендә эшләр гөрләп барганда Идел буенда ачлык башланды. Укытучылар ачлыктан качып китте. Артистларның да күбесе ачлыктан качты. Безнең барыр урын юк. Ачыга башлагач, Кәримнең әйберләрен базарга чыгарып сата башладык. Кәрим базарга чыгарга ояла, анда аны халык таный. Әйберләр сатарга мин остарып киттем. Иң соныннан аның бер пинжәге генә калды. Кәрим, дим, бар инде монысын үзең сатып кайт, минем хәлем юк. Теләр-теләмәс китте бу базарга. Бик озак көттем, кайтмый Кәрим. Үзем чыгып киттем Кәримне эзләргә. Барсам, күрсәм, мескенем аптырап, кыюсыз гына, үзенә генә ишетелерлек итеп: харуши пиджак, харуши пиджак, дип басып тора. Кыяфәте чиста, Кәрим бик мәһабәт кеше иде бит ул, янына килүче юк, бөтен спекулянт аны читләтеп уза тора. Барысы да Кәримне "подставной" дип уйлый. Озак басып торды, пинжәген селтәр-селтәмәс. Кызгандым бичараны. Мине күреп алгач, Кәрим, бата башлаган кеше ничек итеп бүрәнәгә тотынса, ул да шулай мина таба ымтынды. "Мә, мә, зинһар, үзең сат! Миннән сәүдәгәр чыкмый", дип пинжәген миңа ташлады. Шулай итеп, Самара студиясе башланыр-башланмастан ябылды. Илле ике шәкертне Тинчурин кая куйсын? Киттек Оренбургка. Анда да ачлык. Артистларыбыз ачлыктан кырыла башлады. Ике артистыбыз сәхнәдә үлде, тифтән ике артистыбыз вафат булды. Мин йөккә узган идем. Урамда барганда аһымны югалтып егылганмын. Мине Кәрим күтәреп алып кайткан. Мин шунда ана булу бәхетеннән мәхрүм булып калдым... Кәрим сау-таза ир кеше, башкага өйләнеп ата була ала иде, мин аңа бу турыда ике тапкыр әйттем: ул, гадәтенчә, и тиле дә инде син, Зәйдә, дип кенә куйды. Шуннан соң без бу турыда беркайчан да сүз кузгатмадык. Мин аякка бастым, башкалар егылды. Труппаны таратырга, дигән карар чыгарылды. Шулчак Ташкенттан Шәһид Әхмәдиевтән телеграмма килеп төшә Кәримгә: "Нишләп анда ачка кырылышып ятасыз, килегез Ташкентка, эш тә, аш та табарбыз". Телеграмманы Кәрим коллективка күрсәтте. Шатлык, бәйрәм, үләргә ята торганнар да сикереп торды. Кәрим иллеләп кешене вагонга төяп Ташкентка алып китте. Юлда ачлык башланды, бер ай буе бардык, җә вагонны өзеп калдыралар, дала уртасында состав көтеп ятабыз, җә ягулык бетә. Тагын ике артистыбызны дала уртасында җирләдек. Шыр сөяккә калып Ташкентка килеп егылдык. Кырык-илле кешене күргәч, Шәһит Әхмәдиев егылып китә язды. Мин бит Заһидә ханым белән икегезне генә чакырган идем, телеграмма коллективка түгел иде бит, ди Әхмәдиев. Икегезгә урын да, эш тә табам, кал-

ганнарыгыз өчен мин җавап бирә алмыйм, ди. Чыннан да Әхмәдиев безне урнаштырды. Калганнар кайсы кая таралып, үз җайларын үзләре карадылар. Тора-бара барысы да эш тә, аш та таптылар. Концертлар оештырып җибәрдек. Җырчылар, музыкантлар, уйнаучылар бар. Ләкин ун-унбиш артист эшләгәнне тагын утыз артист ашап ята алмый. Эстрада һөнәре булмаганнар башка эш таптылар. Шуннан соң 1922 елны Дәүләт театры корабыз дип, Тинчуринны Казанга чакыртып алдылар. Менә шулай оешты ул Камал исемендәге татар дәүләт драма театры.

З а һ и д ә  т у т а ш. Минем Тинчуринга кияүгә чыгасымны ишеткәч, Мохтар Мутинның миңа булган хөрмәтле мөнәсәбәтләрендә үзгәреш башланды. Һәрхәлдә ул миңа шулай тоела иде. Минем алда һәрчак әдәпле, итагатьле Мутин төртмә сүзләргә әверелде кебек. Бер тапкыр Мутин спектакль куярга җыенды, пьесадагы баш рольне—Сәлимәне миңа тәкъдим итте. Кызыклы пьеса, әйбәт роль, артисткалар яхшы рольгә ябышып яталар. Ә мин баш тарттым. Мутинның күзе шар булды. Ул кыстый, соныннан ялына башлады, ләкин мин бу эшкә алынмадым. Бөтен театр аптырады. Кәрим дә: «Син нишлисең, шәп роль, син җир җимертәсең аның белән»,—диде. Ләкин мин инде карар кылган, ваз кичкән... Шунда Мутин театр фойэсында үземне генә очратып, сүзе астына зәһәр салып, син Тинчуриннан куркып, минем спектакльдән баш тартасың, диде. Бу сүз ачуымны чыгарды. Мутин кайсы тәбәлдереккә басасын бик яхшы белә иде, ул минем самолюбиемдә уйнап, җиңмәкче иде. Ләкин мин барыбер уйнамадым. Театр эчендә, баш режиссер хатынына бик сак кыланырга, алдыңны-артыңны карап эш йөртергә кирәген белә идем.

З а һ и д ә  х а н ы м. Театрда төрле хәлләр булды инде. Тинчурин пьеса арты пьеса яза, үзе куя, үзе баш рольләрне башкара. Театр гөрли. Халык йөри. Шулай матур гына иҗат иткәндә, матур гына яшәп ятканда Кәримне театрдан кудылар. Кемдер: "Тинчурин театрны үз монополиясенә әйләндереп бетерде, фәлән-төгән", дип язган. Язган кешеләре дә билгеле... Исемнәреме? Әйтмим!.. Нигә иске яраларны кузгатырга? Мәшһүр артистлар да бар кул куйганнар арасында. Кәримем эшсез калды. Аптыраган-йөдәгән, балтасы суга төшкән. Кайгырма, дидем. Житешә алмый иден, әнә өйдә пьесаларыңны язып ят. Юк, Кәрим театрдан куылгач яза алмады. Көндезләрен әлсерәгәнче эшләп, төннәрен яза иде ул. Көндез эше дә юк, яза да алмый. Парадокс! Вакыты тар булганда ул бер төн эчендә бер пьеса язып ташлый иде. Иҗат өчен вакыт кысан булу кирәк булдымы икәнни? Шуннан моны Әстерханга сөрделәр. Ул анда бер фасыл эшләп кайтты. Аны тагын Академия театрына баш итеп чакырдылар. Чөнки Тинчуринсыз эш бармый. Куярга пьеса юк. Режиссер кулы юк. Кәрим үзе өстеннән язган артистларга бер сүз әйтмәде. Берни булмагандай, эшен дәвам итте. Театр канатланып иҗат итә башлады. Кәримне тагын эшеннән алдылар. Бу юлы инде сәяси гаепләүләр дә бар иде. Гражданнар сугышы башлангач, җизнәм Аскәр Шәех-Гали аклар гаскәре офицеры булып, кызылларга каршы сугышка китте. Суфия тәтәм театрга кайтты. Ул театрга кайтканга Тинчурин бик сөенде. Йорт театрының артисткасы булып, кухнәдә ятканчы, ичмасам, театрда гөрләрсең, диде. Исхакыйның тәнкыйте ана тәэсир итми калмаган, күрәсең, апам театрга кайтты. Ләкин Гаяз Исхакыйга үпкәсе бар иде аның. Генерал утарында кунак булып киткәннән соң Исхакый "Баянел-хак" газитендәме шунда, хәтерләмим, "генераллар халык икмәген ашап, уенмуен корып, рәхәт чигәләр, милләт язмышы турында кайгыртмыйлар", дип язып чыккан иде. Апамның шуңа җен ачуы чыккан: атна буе мунча кереп, кунак булып ятты да, Казанга кайткач безне сүгеп мәкалә язган, дип бик озак зарланды. Апам җин сызганып иҗат эшенә тотынган иде, гражданнар сугышы туктагач, китте чистка. Аскәрне төрмәгә утырттылар. Тинчуринны чакыртып, син нигә туган-тумачалык корып, ак офицер хатынын, генерал кыленен, шул недорезанная артистократканы театрына җыеп ятасың? дип пешерделәр. Суфия тәтәм театрдан китте, шуннан соң кабат әйләнеп кайтмады. Халык дошманнары күбәя башлады. Гаиләгә генә түгел, илгә кара шом иңде. *(Кара Шәүлә сәхнә буйлап чабып йөри.)* Театрның иң талантлы актерларын себереп ала башладылар. Халык дошманнары булып, Мутин кит-

те, Тинчурин китте, Гали Ильясов китте, Гомәр Исмәгыйловны театрдан кудылар. Ул Кырым-татар театрына баш булып китте. Аннан кырым татарларының халык дошманнары белән Гомәр Исмәгыйловны каторгага сөрделәр. Язучыларны кырып-себереп алдылар: Бурнаш, Гомәр Гали, Гомәр Толымбайский, Хәсән Туфан, Мирсәй Әмир, Кави Нәжми, Галимҗан Нигъмәти, Сәйфи Казанлы, Галимҗан Ибраһимов... Татар язучыларының каймагын гына алып киттеләр. Нинди шәхесләр, миһербан иялəре, бөек талантлар юкка чыкты. 1929 елда Ялтага, Галимҗан Ибраһимов янына барган куәтле төркемнән берсе дә калмады. Урамга чыккач, кем белән исәнләшергә, кем белән исәнләшмәскә кирәклеген дә белми идек. Исәнләшерсең, ул халык дошманы булып чыгар. Исәнләшмәсәң, итагать кануннары бозыла. Мин дә халык дошманының хатыны буларак, эшсез калдым. Элеккеге дусларым, танышларым урамда очраганда исәнләшми, яки күрмәмешкә салышып уза, яки "недорезанная дворянка" дип каһәрләп китәләр. Минем белән курыкмыйча исәнләшеп, хәл сорашып торучы бер генә язучы бар иде: Шәриф Камал. Ләкин аңа кыенлык килер дип, мин үзем аны күрсәм, йомыш тапкан булып, ишегалдына кереп китә идем. Шәриф абый узып киткәч кенә качкан җиремнән чыга идем.

Сезнең буынга Ходам күрсәтмәсен ул афәтне. Иблис каплады дөньяны. Мине атам өеннән, үз өемнән куып чыгардылар. НКВД Кәримнең бөтен документларын, әсәрләрен, алтын ятаганын, сигез герман фотоаппаратын, бай китапханәбезне талады. Мин урамда калдым. Ачтан үлмәс өчен үземнең алтын-көмеш әйберләремне сатып көн күрдем. Кәрим юкка чыкты. Мине дә чакырттылар.

С л е д о в а т е л ь. Исемегез, фамилиягез?

З а һ и д ә т у т а ш. Заһидә Тинчурина.

С л е д о в а т е л ь. Сез нинди халык дошманнарын беләсез?

З а һ и д ә т у т а ш. Мин халык дошманнарын белмим.

С л е д о в а т е л ь. Сезнең өйдә артистлар, язучылар җыела идеме?

З а һ и д ә т у т а ш. Җыела иде.

С л е д о в а т е л ь. Кемнәр килә иде?

З а һ и д ә т у т а ш. Барысы да.

С л е д о в а т е л ь. Кемнәр килә иде?

З а һ и д ә х а н ы м. Исем әйтсәм алып китәләр, шуна күрә мин кулга алынганнарның гына исемен атарга булдым.

З а һ и д ә т у т а ш. Фәтхи Бурнаш.

С л е д о в а т е л ь. Уже утыра. Тагын?

З а һ и д ә т у т а ш. Мохтар Мутин.

С л е д о в а т е л ь. Уже утыра. Тагын?

З а һ и д ә т у т а ш. Гомәр Толымбайский.

С л е д о в а т е л ь. Уже утыра. Тагын?

З а һ и д ә т у т а ш. Калганнарын хәтерләмим инде.

С л е д о в а т е л ь. Алар сездә озак утыралар идеме?

З а һ и д ә т у т а ш. Озак утырган чаклары да бар иде, тиз киткән чаклары да бар иде.

С л е д о в а т е л ь. Алар сезнең өйдә нишлиләр иде?

З а һ и д ә т у т а ш. Кәрт сугалар иде.

С л е д о в а т е л ь. Сөйләшәләр идеме?

З а һ и д ә т у т а ш. Сөйләшмичә кем кәрт суга инде.

С л е д о в а т е л ь. Ни турында сөйләшәләр иде.

З а һ и д ә т у т а ш. Мин аларны тыңламый идем.

С л е д о в а т е л ь. Контрреволюцион сүзләр сөйлиләр идеме?

З а һ и д ә т у т а ш. Кухнәгә аларның тавышы ишетелми иде.

З а һ и д ә х а н ы м. Ничек башыма килде. Аллага шөкер, мин бер генә кешенең дә исемен атамадым. Аерылышыр алдыннан Кәрим күземә туры карап, тутырып карап торды, бәлки соңгы күрешүебездер, дигән кебек. Аннан соң каты итеп, авырттырганчы кулымны кысты. Шул булды безнең гомерлеккә аерылуыбыз. Аңлавы кыен иде, ничек итеп Кәрим кебек кешеләрне юк итеп, коммунизм төзеп була ала икән ул? Кеше бәхете өчен яхшы кешеләрне үтереп бетерергә алынган система үзен-үзе буып үтерергә тиеш иде. Үтерде дә. Аңламыйм, аңлый алмыйм бүген дә: антинародная власть, антинародная система. Йортсыз, эшсез калдырдылар.

С л е д о в а т е л ь. Сез эшкә урнаша аласыз, ләкин аның өчен сезирегезнен Тинчурин фамилиясеннән баш тартырга, Әхмәровага өйләнеп кайтырга тиешсез, яки башка кешегә кияүгә чыгып, фамилиягезне алыштырырга тиешсез.

З а һ и д ә х а н ы м. Юк! Алыштырмадым мин Тинчурин исемен. Чөнки мин аның гаепсез икәненә инана идем.

1941 елда мине—халык дошманының хатынын Казаннан сөрделәр, кара бураннарда, көзге яңгырларда, фатирдан-фатирга күченеп йөргәндә Кәримнән калган савыт-саба ватылып бетә язды. Ләкин Кариев биргән алтын сәгатьне, көмеш балкашык белән стакан оясын сатмадым, сакладым.

Сугыш туктагач, мине Казанга кайтардылар. Ләкин Кәрим турында бер хәбәр юк.

1956 елда Кәримне акладылар. Ләкин бимазалар аның белән генә бетмәде. Мин Совет хөкүмәтеннән житмеш бер яшемдә генә бер бүлмә алдым. Рәхмәт инде! Атамның ярты квартал йортын биреп, бер бүлмә.

Озынга китте бу сөйләшү, әле күпмесе сөйләнмәгән. Күпмесе үзем белән кабергә китәр... Калганнарын башка вакытта сөйләрмен. Әмма бүген мин сезгә ике фажигале шәхес турында сөйләмичә булдыра алмыйм.

Габдулла Кариев—затлы нәсел баласы, укыган, белемле кеше, итагатьле шәхес. Татар театрында аннан да олы, аннан да югары башка шәхес юк. Минә шушы олы шәхес, мәһабәт, талантлы ирнең беренче һәм соңгы мәхәббәте Фатыйма Ильская иде.

Ильская—ут артистка, ут та ул, ялкын да ул, очкын чәчри иде ул уйнаганда. Табигать биргән гайрәт, дәрт, матурлык, чаялык—барысы да сәхнәдә чагыла. Фатыйма Ильская бөек артистка. Шаулады Ильская, бик нык шаулады. Олы талант иде... Ие, Фатыйма ханымның ирләре аз булмады. Ләкин Кариев аны барыбер ярата иде. Фатыйма ханым башта аңламады, Кариевның мәхәббәтен ул, чибәр хатынга булган гадәти игътибар гына, дип уйлады. Ильская вафаты алдыннан минем янга килде. Озак сөйләшеп утырдык. Ул сөйләде, мин тыңладым.

И л ь с к а я. Заһидә ханым, Кәрим абыйны алгач, мин сезгә килүдән туктадым. Кичерегез мине. Бүген мин сезнен янга килдем, үзем белән алып китә алмыйм. Сөйлисе сүзем бар. Зинһар, тыңлагыз. Мин моны беркемгә дә сөйләмәдем. Без инде икебез дә яшәсен яшәгән, ашасын ашаган. Минем тормышым сезнен күз алдында. Ләкин беркем белмәгән серләр бар минем тормышта. Гөрләдем мин театрда, мине фаэтоннарда гына йөрттеләр, байлар мине бриллиантларга, алтынга күмделәр. Гөрләдем мин, гөрләттем мин театрны. Улым туды, Фоатым мәһабәт жегет иде. Танк эчендә янып шәһит китте. Менә минем бәхетем шуның белән бергә кабергә күмелде. Ир-жегетләрнең ниндие генә юк иде минем аяк астымда. Мин ирләрнең патшабикәсе идем, мин сәхнәнең Алиһәсе идем. Ләкин минем бәхетем булмады. Алтын-көмешнең дә минем өчен поты бер тиен. Мин ялгыз, токымсыз, нәселсез карчык булып бу дөньядан китәм... Дөрес, мин татар театры тарихында урынсыз булмам. Әмма шәхси бәхетем минем алдан ук булмады. Мин бит үземнең кем баласы икәнемне дә белмим. Мине үстергән әби белән баба минем әби-бабамы ул, әллә алар мине—ташландык баланы алып тәрбияләргә тырышканмы, әллә алар мине үстереп, байданбайга сатып көн күрмәк булганмы, мәгълүм түгел. Байларга йон юдым мин, асрау булып тордым. Әшеннән курыкмадым, әмма исерек хужалардан йөрәгемдә курку калган. Ирләрдән курку, ирләргә жирәнеп карау калган, Заһидә ханым... *(Тынып кала, аның башыннан ямьсез күренешләр уза.)* Кичерегез, искә аласы килмәгән вакыйгалар каршыма килә... Мине Казанга чакыргач, сөенгәнемне белсәгез. Мин инде театрсыз яши алмый идем. Яшь-яшь кыз баланы Оренбургтан Самарага поезд белән озаттылар. Солдатлар составы иде ул, пассажир поезды киткән, бернечә көн булмаячак иде... Казанга тиз барып житәсе килә... Исерек солдатлар, офицерларның ни кылганнарын сезгә сөйләве авыр... *(Пауза.)* Ике атна килдем мин Казанга. Самарадан пароходка утырып Казанга мендем. Пристаньда мине Фатих Бәкер каршы алды. Минем кыяфәтне күреп, ул егылып китә язды. Ул барысын да аңлады. Кешегә күрсәтмичә, үз өенә алып кайтып, юындырып, яңа киемнәр алып, мине аякка бастырды. Мин ул кешегә мәңге рәхмәтле. Ул мине яман сүздән,

гайбəттəн коткарыр өчен мина өйлəнде. Бəлки ул мине яраткандыр да. Мин аны ярата алмадым. Лəкин мин хəзер анлыйм: Бəкер мəсхəрəгə калган кызны коткарып калырга тырышкан. Ни әйтсəн дə ирдə булган, аерылган, ул кадəр хурлыклы түгел. Минем холкымнын шулай чętерекле, кыен булуы əнə шуннан башланды кебек. Мин бөтен игътибарымны ижатка ташладым. Рольне алгач, мин женле кеше кебек өйрəнə башлый идем. Женле кеше кебек уйный идем. Чөнки минем эчтə ике жен утыра иде. Берсе анын талант жене, икенчесе—ирлəргə нəфрəт. Ирлəр мина талантлы һəм чибəр булганым өчен генə, женси ихтыяжларын канəгатьлəндерер өчен генə йөрилəрдер кебек тоела иде. Аларнын күбесе шулай булгандыр да. Мин аларнын хислəренə көлеп карыйм, минем арттан йөри-йөри əлсерəгəннəрен күреп, минем алда сəгатьлəр буе тезлəнеп торуны бəхет санаган ирлəрне мыскыл итəм. Ул тилергəн ирлəргə никадəр кырыс булсам, алар шулкадəр мина ныграк тартылалар иде. Юашларын юаш булганга яратмый идем, усалларын усал булганга сөйми идем. Юашларыннан батыр ясамакчы булып, чабаклыйм, күз алларында башка фаэтонга күчеп утырам да, гүлəйткə чабам. Усалларын юашланганчы ялындырам. Аларнын шулай күндəм булганнары да минем женемне чыгара иде. Мин чиклəрне белмичə шулай үрти идем аларны. Лəкин ялгыз калгач, тыела алмыйча елый идем. Аларнын гаебе юк бит, нигə мин алардан шулай мəсхəрə ясыйм, дип үземне сабырлатырга тырыша идем, лəкин дөньяга чыккач, аларнын женси азгынлык алгысыткан чырайларын күрəм дə тагын азарт кузгала, лəкин Кариев белəн Бурнаш башка холык кешелəре булды. Икесе дə сабыр, итагатьле булдылар. Икесе дə минем капризларыма түзə иделəр. Шулар арасыннан мин берсен генə исемнəн чыгармыйм. Кариев *(күнеле тула)*! Картлык көнемдə мин анладым, мин нинди олы мəхəббəттəн колак какканмын икəн! Кариев! Ул бит мине өзелеп сөя иде, анын ачуын чыгартыр өчен, ичмасам, бу мине бер тотып ярсын иде дип, юри байбəтчəлəрнен фаэтоннарына утырып пикниккə чыга идем. Ул сабыр гына каршы ала иде. Фатих Бəкер мине хурлыктан коткарып, миндəй тиктормас яшь хатынны авызлыклап тотарга алын-мыйча, аерылышып, Ташкентка китеп барды. Минем юлымда киртə булып тормас өчен. Нинди корбан! Нинди бөек шəхес! Сонгы елларда мин гел Кариев дип саташам, Заһидə ханым. Нишлим сон, үткəн эш кире кайтмый, үкен син, хет үл, жыла... Сез, Заһидə ханым, əхлак эталоны, сез тугрылык фəрештəсе кебек хатын. Сезнен гөнаһыгыз юк Кəрим абый алдында да, Алла каршысында да. Мин нишлим? Минем тормышымнын бердəнбер шаһиты сез, Заһидə ханым, минем тарафтан кыен күргəн, мин телəр-телəмəс рəнжеткəннəрнен барысы өчен дə сезнен алда гафу үтенəм. Кичерегез мине! Их, кайтарып булса икəн теге вакытларны. Мин Кариев янында гына калган була идем!.. Ə хəзер мин Кариев янына китəргə тиешмен!.. Кичерегез, Заһидə ханым, озын монологым өчен. Мин сезгə тагын бер килеп китəрмен əле!

З а һ и д ə  х а н ы м. Безнен сонгы көрəшүебез шул булды. Ул сөйлəде дə сөйлəде, бушанды, рəхəтлəнеп калды, хушлашып чыгып китте. Мин анын мажаралары турында сораштырмадым, ул үзе телəгəнен генə сөйлəде. Минем ни эшем бар анын мажараларында. Мин анын бөек артистка икəнен белəм—мина шул житкəн. Андый артистканын монархы күренгəне юк. Бер тамчы да бəхет күрмичə, театр өчен, халык өчен үзен корбан иткəн бөек артистканын язмышы, фажигасе турында язгыз, иптəш язучы. Тетрəнсен халык! Анласын халык үзенен талантлы шəхесен. Ул кабат минем янга килə алмады. Бер атнадан сон татарнын бөек артисткасы Фатыйма Ильская вафат булды. Авыр туфрагы жинел булсын.

З а һ и д ə  т у т а ш. Чыннан да, Кариев Фатыйманы шашардай булып ярата иде. Бөек ижат кешесенен илаһи дəрəжəдəге мəхəббəте иде ул... Со всей страстью большого художника Кариев любил Ильскую и только Ильскую. Бəхетсез мəхəббəт! Ə мəхəббəтнен бəхетлесе буламы?

З а һ и д ə  х а н ы м. Була! Кəрим белəн Заһидəнен мəхəббəте бəхетле иде. Унсигез ел бəхетле булды ул мəхəббəт.

З а һ и д ə  т у т а ш. Ə сонынннан?

З а һ и д ə  х а н ы м. Сонынннан ул бəхет жимерелде... Кайта-кайта уйлыйм, туксанымда да уйлыйм: Гаяз Исхакый никадəр дə əүлия булган икəн. "Ике йөз

елдан соң инкыйраз" әсәрендә ул барысын да күргән, барысын да белгән икән. Карагыз сез минем гаиләмә—инкыйраз. *(Кара Шәүлә һәр шәхескә канатын җилпи.)* Барысы да фаҗигале. Моннан сиксән ел Исхакый ничек әйткән булса, шулай килеп чыкты. Шаһбазгәрәйнең токымы калмады, юк, калганнары татарга нәфрәтле. Тинчуринның нәселе калмады. Калганнары да урыслашкан. Карагыз сез татар сәясәтенә, сәнгатенә-әдәбиятына—инкыйраз. Токым калмый! Нәселләр юкка чыга! Нәселе калганнар татарга хезмәт итәме? Юкмы?

Исхакый казакълар, чуашлар мәсьәләсендә дә хаклы булып чыкты, язучы әфәнде. Узды бит казакълар татарларны, узды. Кинолары, архитектуралары, телләрен дәүләт теле итүләре, башка төр сәнгатьләре белән казакълар татарларны куып җитеп, узып китте. Чуашлар үкчәгә күптән басып киләләр. Татарларның борын югары: алар чуашларның куып җитеп килгәнен күрми, күрмәгәнгә салыша, аларның куып җитүләрен башларына да китерә алмыйлар. Сез, язучы иптәш, Чуаш театрының спектакльләрен карадыгызмы?.. Сез татар спектакльләрен дә сирәк карыйсыз шул. Ә мин ике тапкыр гастрольгә килгәнендә карадым. Шәп театр! Татар артистлары үпкәләмәсеннәр: театр саен өч-дүрт мәхәббәт каһарманы, өч-дүрт мәхәббәт гүзәле булмаса, ул нинди театр була инде? Чуашларда, казакъ театрларында дүртәр-бишәр гүзәл, дүртәр-бишәр каһарман бар. Шул, үзебезнең башкорт театрында да буйлы, гайрәтле каһарманнар татар театрларындагына караганда күбрәк. "Отелло"ны куя алмаган коллектив театр булып хисапланырга хаклымы? Чуашларның поэзиясе чуаш теленнән турыдан-туры күп кенә Европа телләренә тәрҗемә ителгән, тегеләрнең классикасы да турыдан-туры чуаш теленә аударылган. Бармы татарда шундый тәрҗемәче кадрлар? Бөтен Франция, Англия чуаш поэзиясе белән якыннан таныш. Ә чуашлар Европа поэзиясе белән чуаш теленә турыдан-туры тәрҗемәдә таныш. Бармы татарда шундый кадрлар? Музыка өлкәсендә дә чуашлар татарларны әллә кайчан куып узды инде, әфәндем. Татарларның шаны артта, чуашларның шаны алда!

Татарның тарихы аның фаҗигаләрдән генә тора. Аның күренекле шәхесләрен яки үтерәннәр, яки алар көрәштә һәлак булганнар. Яки алар зинданнарда черетелгәннәр. Кол Гали—һәлак булган! Сәиф Сараи—горбәттә вафат! Кайгылы Хәсән—һәлак булган! Мөхәммәдьяр—һәлак булган! Мөхәммәд Әмин—үтерелгән! Гариф шагыйрь—һәлак булган! Кол Шәриф—һәлак булган!

Акмулла—үтерелгән! Дәрдмәнд—ачтан үлгән! Шәехзадә Бабич—җәзалап үтерелде! Даут Гобәйди дә—җәзалап үтерелде! Шамун Фидаи—үтерелде.

Исхакый—горбәттә вафат! Муса Биги—горбәттә вафат! Йосыф Акчура, Акдәс Курат, Садри Максуди, Зәки Вәлиди, Баттал Таймас, Сәгадәт Исхакыйлар горбәттә вафат!

Мирсәет Солтангалиев, Һади Атласый, Газиз Гобәйдуллин, Галимҗан Нигъмәти, Җамал Вәлиди, Мәхмүт Галәү, Кәрим Тинчурин, Гомәр Гали, Гомәр Толымбай, Галимҗан Ибраһимов, Шамил Усманов, Мохтар Мутин, Фәтхи Бурнаш, Ләбиб Гыйльмиләр, Сәйфи Казанлы, Сәгыйть Сүнчәләйләр җәзалап үтерелде!

Гарәфи Хәсәнов, Мин Шабай, Гомәр Исмәгыйлов, Кәрим Җаманаклы, Кави Нәҗми, Нәкый Исәнбәт, Бакый Урманче, Мирсәй Әмир, Хәсән Туфан, Аяз Гыйләҗев, Адлер Тимергалин, Сөббух Рафиков, Гали Ильясов, Гурий Тавлиннар совет зинданнарында җәзаланды.

Фәрит Яруллин, Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, Абдулла Алиш, Рәхим Саттар, Хәйретдин Мөҗәй, Аитзак Аитов, Кәшфи Басыйров, Нур Баян, Касыйм Вахит, Мифтах Вәдүт, Вәли Лотфи, Габдулла Галиев, Макс Гатау, Мансур Гаяз, Шамил Гәрәй, Рахман Ильяс, Кави Хәмит, Камал Әгъзам, Мамин Мөхәммәтша, Мөсәгыйть Мостафин, Хәбра Рахман, Исмәгыйль Шәфиев, Мөхәммәт Әблиев, Әхтәм Әминев, Мөхәммәт Әхмәтгалиев, Демьян Фәтхиләр сугышта һәлак булдылар.

Фәрит Гыйльми, Ринат Рәхимов, Малик Хәмитов, Фәиз Зөлкарнәй, Фаил Шәфигуллин, Рәфкать Бикчәнтәйләр дә тыныч вакытта һәлак булдылар.

Икенче бөтендөнья сугышында 42 татар язучысы һәлак булган. Мәскәү язучыларыннан бер Аркадий Гайдар шул сугышта һәлак була, калганнары Татарстанда эвакуациядә ята. Рәсми мәгълүматларда сугышта һәлак булган татар

язучыларын гел утыз санында йөртәләр. Ә мин 42 дим... Минем үз статистикам, үз мантыйгым, язучы әфәнде! Кырым татарлары татар түгелмени? Аларның уникеләп язучысы сугышта һәлак булды, калганнарының барысы да сугышта катнашып, орденнар алды, ләкин алар да сатлык сыйфатында сөрелде һәм аларның күбесе сөргендә һәлак булды.

Шулар өстенә һәр авылның һәр мулласы Себердә һәлак булды. Исән калганнарының да нәселе татар түгел. Татар язучылары, сәнгатьчеләренең балалары, торыннары татарга хезмәт итәме? Юк! Тукай нәселсез. Такташның берәр баласы яки оныгы татарга хезмәт итәме? Юк! Туфанның баласы яки оныгы татарга хезмәт итәме? Юк! Сәйдәшнең берәр оныгы татарга хезмәт итәме? Юк! Җиһановның баласы яки оныгы татарга хезмәт итәме? Фәрит Яруллинның токымы аның эшен дәвам итәме? Юк! Кичерегез мине, язучы әфәнде, мин бу дөньядан оптимизм белән китә алмыйм. Әйе, озак тормам, мин дә Фатыйма ханым артыннан куа китәрмен, ахрысы, атларым җигүле. Хөрмәтле иптәш язучы, Кәрим Тинчуринның кабере юк. Васыятем бар сезгә. Минем каберем өстендәге ташта өч исем булырга тиеш. Атамның исеме, Тинчуриннныкы һәм минеке. "Шаһбазгәрәй Әхмәров кызы, "Сәйяр" труппасы артисткасы, мөгаллимә, драматург Кәрим Тинчуринның хатыны Заһидә ханым", дип яздырырсыз! Тинчуринга чәчәк китергәндә атам белән мине дә яхшылык белән искә алырсыз. Амин!...

Кәефем китеп тора, без иртәгә дәвам итәрбез, язучы иптәш... Зинһар, гафу итегез... *(Заһидә булмаган язучыны ишеккә озата бара. Кире күренә, ятагына таба бара. Кыңгырау зыңгылдый, Заһидә ханым сискәнеп китә.)* Тефү, шайтан, шулай каты басалармыни инде, куркыттыгыз, мин куркып беткән инде, минә килеп алып китәрләр, дип көтеп утырам. Тагын кайсысы инде бимазалап йөри шунда. *(Ишек янына килә, Кара Шәүлә керә, кулында кәгазь.)*

З а һ и д ә х а н ы м. Син икәнсең әле, инкыйраз каргасы, үләксә козгыны! Шылтыратмыйча гына керә алмыйсыңмыни?

К а р а Ш ә ү л ә. Кичерегез, Заһидә ханым... Сез мине бикяр сүгәсез, ханым әфәнде. Мин инкыйраз каргасы да, үләксә козгыны да түгел. Мин татар халкын саклап калырга алынган зат!

З а һ и д ә х а н ы м. Мәкер һәрвакыт яхшылык чикмәненә төренгән булыр.

К а р а Ш ә ү л ә. Сез, Гаяз Исхакый һәм башкалар: милләт бетә, дин бетә, тел бетә, дип күпме гайрәт, күпме корбаннар сарыф иттегез. Барысы бикяр, файдасызга, заяга. Татар милләтен, аның тарихын саклар өчен сайланган сезнең юл—хата! Минә минем юл—Хакыйкать.

З а һ и д ә х а н ы м. Кара Шевлинский, урыслашкан татар сыныгымы татарны коткарырга алынган?

К а р а Ш ә ү л ә. Тел түгел татар халкының нигезе, дин түгел татар халкының тарихы, татар халкының тарихы—гыйлем, ханым әфәнде. Гыйлеме булмаса, халыкнын тарихы да юкка чыга. Сезнен Сара апагыз юлы минекенә якынрак. Татарча яхшы белгән татарлар надан була. Урыслашкан татарлар мәһабәтрәк, культурныйрак, белемлерәк, акыллырак. Милләт, милләт дип үкереп йөри торганнар надан фанатиклар, диндин дип ак яулык бәйләгән булып йөрүче көлсу-ак чырайлы хатын-кызлар, элеккеге аракы сатучылар, элеккеге ата атеистлар, коммунистлар мулла-абыстай булды хәзер. Мәчет, дин, азатлык хәрәкәте тирәсендәге татарлар биш тәрле була. Чынлап дингә, азатлыкка тартылган әхлаклы татар. Алары ин аз санда. Калганнары дин, азатлык шаукымы белән акча каерып калучы, шөһрәт яуларга тырышучылар. Алласыз, әмма мәчет, азатлык хәрәкәте янында хәер эстәүчеләр. Ниләр бар икән дип кызыксынып йөрүчеләр. Кайбер оешмаларның шымчылары һәм акылга таман—шизофрениклар. Болар белән динне торгызып, азатлык яулап булмый. Татар депутатларының күбесе надан, комсыз рәшвәтчеләр. Татарның тарихы ни аларга, теле ни аларга, киләчәге ни аларга. Минә татарның киләчәге кемнәрдә. Будущее татарской нации—в обрусевших татарах. Они спасут историю татар, жертвуя татарским языком и Исламом. Основа и будущее татарской нации—в характере. Берите пример от евреев. Бедные евреи веками страдали, их изгнали отовсюду, но они закрепились в России и сохранили еврейский, национальный характер, потеряли язык, даже религию, но еврея можно узнать по характеру, по сохраненным ими традициям. Родным языком всех

евреев России является русский. Евреи русским владеют лучше чем сами русские, почти у всех евреев имена русские или той республики в которой они живут. Они меняют имена, но не меняют характера и этим они завоюют весь мир. А вы ругнем ругаете обрусевших татар. А сами татары не хотят давать своим детям татарские имена. Во главе татарского инкыйраза стояли татарские писатели, ученые, учителя и партийные работники, которые по долгу службы должны были бороться за чистоту традиции и имен. Откройте любой справочник имен, вы там вряд ли найдете чисто татарские имена. Татарские отцы наводнили себя европейскими именами: Альберты, Роберты, Зигфриды, Рафаэлы, Клары, Луизы, Экземы, Октябрины, Марсельезы, чего только нет, каких только имен нет у татар, только не татарские, вся интеллигенция у татар гнилая, напроч забыты хорошие традиции, ритуалы... Вы не сможете задержать естественный процесс обрусения татар. Время упущено. Прошлому возврата нет. Остается мой путь, путь Кара Шевлинского. Инкыйраз наступает!

З а һ и д ә  х а н ы м *(кинәт хәле китә).* Күземнән югал, Шәүлә! Төнлә генә төшемә кергәнен житмәгән, көндезен дә килеп керәсен, чыгып кит!

К а р а  Ш ә ү л ә. Китәм! Ләкин менә моны тапшырырга рөхсәт итегез, Заһидә ханым. Сезгә телеграмма, Мәскәүдән, Шаһбазгәрәй Әхмәровнын оныгы, Сара апагызнын улы, сезнен племянниктан! Павел Яковлевич Букшпаннан!

З а һ и д ә  х а н ы м *(телеграмманы ача).* "Дорогая тетя Зина! Поздравляем Вас девяностолетием! Желаем долгих лет жизни и личного счастья. Семья Павла Букшпана." Павел. Спасибо, Павел, хоть ты не забываешь старую тетушку. Чыннан да, бүген 1987 елнын унөченче июне бит... Заһидә Тинчуринага бүген 90 яшь тулды. Ни Язучылар берлегеннән, ни театрдан кеше юк... Әллә Тинчурин өстендә тагын болытлар куера башладымы? *(Ишектән кергән язучыга. Анын кулында зур гына чәчәк бәйләме.)* Ойии, сезмени әле бу, хөрмәтле язучы!. Рәхмәт, юкка мәшәкатьләнгәнсез! Туган көнемә берәү дә килмәде, дип пошынган идем. Сез Язучылар берлегеннән дә, театр жәмгыятеннән дә буласыздыр инде... Рәхмәт!.. Менә мин сина шушы фотоларны, Тинчуриннын барлы-юклы архивын калдырам. Сез саклагыз хәзер. Сез тарихны барлагыз. Минем балам, Тинчуриннын варисы булмады. Мин сезгә үз балама ышанган кебек ышандым. Саклагыз!

**Кара Шәүлә узып китә, Заһидә апа да сәхнәдән югала.**

Т ә м а м



## Марсель Галиев

# ЙӨРӘКЛЕНЕҢ ЙӨРӘГЕНӘ...

## Йола

*Ф.С...га*

*Болгар җәмгыятендә бик тә акыллы кеше үсеп җитсә,*
*"Бу—безгә артык. Бу—Тәңрегә кирәк!"*
*дип аны теге дөньяга озатканнар.*

**Шанлы ил улларын учта чөеп**
**Үстерергә мөмкин елларда**
**Сәер тозак корган борынгылар,**
**Хәтәр йола булган Болгарда.**

**Асыл адәм калкып чыга икән,**
**Сискәндереп, халык диңгезен.**
**Тәхет тирәсендә шаукым купкан:**
**—Какшатмасмы дәүләт нигезен?!..**

**Бу бит бездән артык акыллырак,**
**Сирәк зирәклеге—чамасыз.**
**Аягурә басса, күпләр чүгә,**
**"Мин!" дигәннәр кала чарасыз.**

**Мондыйларга дәүләт чикләре дә,**
**Дәвер чикләре дә кысандыр.**
**Гаярь затка олы киңлек бирик!**
**Халык хуплар, халык ышаныр...**

**—Ул—Тәңрегә кирәк!**
**Мәйдан гүли,**
**Гавам өчен олуг тамаша.**
**Бөек мәгънә салгач, ышандыра:**
**Күк әмере—гадел кан аша.**

---

Марсель ГАЛИЕВ (1946) *—шагыйрь, прозаик; күпсанлы китаплар, шул исәптән дүрт томлык "Сайланма әсәрләр" авторы. Казанда яши.*

Мәйдан гүли. Олпат аксөякләр,
Иләмәннәр үзәк төркемдә.
Күндәм-тыйнак булганнарның башын
Бүкәннәргә куймый беркем дә.

Мәйдан гүли. Нинди бәхетле зат—
Тәңре үз катына сораткан.
Болгар иле күпме гали җанны,
Яшьли шулай күккә озаткан.

Ил гөмбәзен иңгә салыр ирләр—
Алтын баганалар киселгән.
Кәрлә ханнар и тантана иткән
Бу йоланың канлы исеннән.

Нинди гөнаһ! Ходай исеменнән,
Саташтырып, изге саналу.
Баһадирлык бәла булган илдә
Тинтәкләргә кала дан алу.

Гөмбәзләрең кая, и Болгарым,
Күкләр каргыш көле сиптеме?
Телсез халык—сусыз балык булып
Яшәгез, дип хөкем иттеме?!

Шул дәверне уйлап килдем менә
Хәрабәле Болгар ярына.
Сабак бирми тарих сабаклары,
Шул ук ташка заман абына.

—Тәңрегә кирәк!—дип, йә, кем әйтер,
Мәгънә калганмы ул йоладан?
Калган икән... Бүген дә шул йола,
Тик астыртын калка яңадан.
(Сәләтледән курка һәр заман!).

Киләчәкне уйлап басып торам,
Әрем исе килә даладан...

## Илһам

Мин бер колың бары... Чабан гына,
Сүз артыннан әрсез чабам гына.
Узыштырам,
Сугыштырам,
Ирештерәм,
Сөзештерәм,
Килештерәм,
Үбештерәм.

Табуннарда елкы Сүз—Атларым,
Табырлана елгыр тулпарларым.
Солтан сүзләр күпме,
Олтан сүзләр,
Субай сүзләр күпме,
Сукбай сүзләр,
Ялган сүзләр күпме,
Янган сүзләр,
Канлы сүзләр күпме,
Данлы сүзләр!

Дөнья карынында күпме серләр,
Күңел аранында күпме сүзләр,
Сез әзерме минем әмеремә?!
(Мин бу мәлдә тиңдер әмиреңә).

Иңерәеп, ярсу чыбыркымны
Бер шартлатсам, әгәр, кыланып;
Үрә баскан сүзләр табырында
Шомырайта барысы колагын.

Шул мәлендә дәррәү куба сафлар,
Кайный, уба сүзләр ташкыны.
Тупырдаган тояк тетрәвеннән
Күкрәп тибә йөрәк, ашкынып.

Бу бит сине күмеп китә торган
Гадел ташкын, изге гарасат.
Шушы ганимәттән тапталып бер
Көчсез калу бәхет ләбаса.

Туган телем минем—тиңсез диңгез,
Аргы яры—Ходай катында.
Мәдәт бир син, маяклары аның
Татар атлы дәрьял халкымда.

## Торналар төшкәндә

—Торыйк!—диеп, сузып-сузып,
Күк битенә сөрмә сызып,
Сагынып кайта торналар.

—Күлем кая?
Күгем—анда.
—Күгем кая?
Күлем—анда...
Буталдымы сагынудан
Туган як манзарасы.
(Дога кыладыр алар да,
Кошларның үз Алласы...)

Канатыннан кага-кага
Мадагаскар тузанын,
Күкнең зәңгәр басмасыннан
Төшә торна кәрваны.

Чигенегез, әй, тауларым,
Ышыклагыз, әй, талларым!
Йөрәк биеклеге калды
Канат шыгырдаулары.

Торна биегән туйларны
Тиздән күрер кырларым.

Уйсуланды уйларым...

## Тәкъдир

Күндәм-гашыйк колың булып,
Имәс башны исәм дә;

Көнчелекнең кара кошын
Упкыннарга чөйсәм дә;

Йолдыз алып бирәм, диеп,
Кыяларга менсәм дә;

Җирдәге оҗмах капкасын
Ачып түргә үтсәм дә;

Алтын тәхетләрне биләп,
Ханнар тажы кисәм дә...

Тургай сулышы кабарлык
Җырлар иҗат итсәм дә;

—Барыбер ярый алмассың!—
Тәкъдирем әйтә көлеп.

Аллаһтан узып яратсам,
Сине җуярмын кебек.

## Кая соң?..

Көнләшергә әзер торган
Күңелнең гамьлелеге;
Син генә, дигән чакларның
Самими гаделлеге

Хәтердә сыктап янара...
Сер бирми шул мин-минлек.
Кабат алданырга, язмыш,
Бир тагын бер мөмкинлек.

## Унсигездә язган хатың

Нинди садә, рәйхани язу,
Картлык ничек шәрехләр?..

Саргайган елларны үчекләп,
Бии ябь-яшь хәрефләр.

## Чагыштыру килер бер көн

Тартария, Татар Ия...
Ничә тапкыр җуйган инде
Тәхет-бәхет алмасын.

Инде җирсез-сусыз калып,
Халык гидай булмасын.

“Шаһ Гали—гали булган шул!”—
Дип әйтергә язмасын.

## Ермак

Себер изүен ул ачкандыр,
Юлбасарга һәйкәл куйгач,
Илдән иман качкандыр.

## Аксиома

Баш биргәнгә шундый инде
Кырыс тормыш уены:
Җегәрләргә ияр була
Җебегәннең муены.

***

Beləклeнeң бeлəгeндə
йомран уйнар.
Йөрəклeнeң йөрəгeнə
арыслан сыяр.
Белемлене, фəһемлене
фил, тезлəнеп,
Сыртындагы тəхетенə
чөеп куяр.

## Истирəхəт

Чатыртауда чалкан ятам.
Фəрештəлəр күзен кыса.
Җил күтəрə кояш итəген.

## И, иртəнге хозурлыклар!

Көз кочарга тора дөньяны.
Гөмбəлəрнең колагыннан тартып,
Агып бара август томаны...

## Сагыну

Бар иде бит һəр авылның
Бер җүлəре.
Бер җүлəргə тормый хəзер
Мең җүлəре!

## Əй, күрəзəче!

Кузгатма син рəмел ташларыңны,
Хыялларым күпме укталган.
Белми торыйм əле, белми торыйм,
Садагымда ничə ук калган...

***

Керкəле тауда йөргəндə,
Əллə каян искə төште
Кракатау вулканы.

Кыйтгаларда безнең телдəн
Тамган күпме сүз каны...

## Йə!

Калəм очында—галəм.

Ман калəмең галəм коесына,
Күлəгəсез Күңел Иялəре
Сүз каурыенда коенсыннар!

Калəм очында—галəм...

## Васыять

Пышылдады туган җирем:
—Пəрвез җебен өзмə,
Əнкəңнəн алда үлмə...

**Мөсәгыйт Хәбибуллин**

# АЙБИБИ

ТАРИХИ РОМАН

Айбиби улын юатып барды, үгет-нәсихәт бирде.

—Яхшы гына укы инде, абзанның йөзенә кызыллык китермә, улым.

—Китермим, әнием,—диде кырыс кына Ибраһим.

—Бәлкем әле Рәшидә абыстай да янына килеп китәр, мин ана хәбәр итәрмен, үзем дә килә йөрермен.

—Борчылма, әнием, мин синең башына кайгы китермәм.

Ниһаять, Гаязетдин тархан күтәрткән мәктәп бинасы күренде. Бина озын һәм ике катлы иде. Ни өчендер Аккаланыкы кебек мәктәп бинасын кальга эченә салдырган иде Гаязетдин тархан. Шәмгун хан каршы булса да осталарны яһүд сәүдәгәрләре аша румнан китерткән. Һәм сызымны да үзе сызып биргән. Кальга эченә үтеп бинаны күргә, Ибраһим торып ук басты.

—Ошый бу бина мина, гомумән, барысы да матур монда, таш диварлар, сакчылар, тархан сарае, уң якта атлар тоталар булса кирәк, җайдаклар күренә...

Үзәк урамнан үтеләр, тархан сарае каршында туктадылар. Аларны каршы алырга Гаязетдиннең хатыны чыкты. Килен кешесен өч-дүрт хатын-кыз озата, алардан кала төшә унлап житкән кыз килә. Барысы да ыспай киенгәннәр, жиләннәренә кадәр бертөрле, килен кешенең генә жиләне ямь-яшел, читләре кеш тиресе белән уелган, киленнең башында очлым сымаграк калфак. Килен ап-ак йөзле, йөзе шулкадәр ак иде ки, Айбиби, ике арада охшашлык күреп, аптырабрак калган иде. Хәер, Идел буеның өске тарафларында яшәгән халыклар күбрәк ак йөзлеләр, күк йөзе кебек зәңгәр күзлеләр иде. Шуның өчен Йосыфы анын күзләренә карар иде дә: "Айбибием, нигә синең күзләрең шул чиккә житеп зәңгәр, мин синең күзләренә карасам үземне күккә ашкандай хис итәм", дияр иде.

"Ә мин синен күзләренә карасам, упкынга очкандай хис итәм үземне",—дигән иде ана Айбиби, кет-кет көлә-көлә.

Һәм шулай да иде ич! Ул анын кочагына инсә, гүя упкынга очар иде.

—Хуш килдегез, хуш килдегез, жингәчәй!—дия-дия, Айбибине арбадан төшүгә каршы алды киленкәй һәм читкәрәк китеп, бер урында таптанып торган Ибраһимны кочагына алды да:—Менә кем килде безгә, менә кем!"—дип, энекәшенең аркасыннан сөйде.

Кунакларны сарайга алып керделәр. Аккаладагы сарайга охшаган бүлмәләр, төрле тарлавыклар күреп, Айбиби үзен кахан сараенда итеп хис

итте. Ләкин бу ялган чагыштыру гына иде. Тархан сараеның диварлары калын, тәрәзәләре кечкенәрәк иде.

—Юл бик авыр булмадымы, җингәчәй?—дип сорады Бибисара.

—Юк-юк, бик әйбәт килдек. Көн дә бик матур булды, кальгага да җиңел генә уздык. Асма күпердән Гаязетдин нәүбәтсез уздырды.

—Гаязетдин Идел буена китте, кораблар туктарга урын карарга. Мин ана сәүдә корабларын Болакка кертергә канау казырга кирәк, сәүдәгәрнең кораблары Казансу буйлап килерләр дә Болакка кереп бушанырлар, дигән идем, килешеп җитмәде, карап карарбыз, дип кенә калды. Минем әтием гомер буена кораблар төзеде бит, җиңгәчәй.

—Гаязетдингә башта әтиең белән киңәшергә кирәк булган.

—Әтием былтырларны гына вафат булды шул, җиңгәчәй. Казанга нинди бина күтәрсә дә Гаязетдин әтием белән киңәшер иде,—диде килен һәм кунакларны ашханәгә алып керде.

Алар каршына ап-ак чәче яшел яулык астыннан чыгып торган бер карчык килеп басты.

Аны күрүгә Айбиби ике кулын ана сузды, баш иде, аннары дога кылды. Шуннан соң гына карчыкның саулыгын сорады.

—Йөрим шунда шәүлә булып,—диде карчык бер дә исе китмичә, аннары үзе сорады:—Юл бик алҗытмадымы, килен? Әллә Ибраһимны яна мәктәпкә китердеңме?.. Кил әле, кил бире, улым. Һай син, гел егет булгансың икән бит инде. Кылыч тагарга да ерак калмагандыр?

—Тагын дүрт ел, тагын дүрт ел көтәсе әле ана, әни.

—Дүрт ел үтәр дә китәр, акылы белән үссен, акылы белән. Йә, килен,—диде карчык Бибисарага таба борылып,—табын әзерме анда, юлчылар арыганнардыр. Тамак ялгап алырлар да мәктәпне барып карарлар. Һәй кинәнде инде Гаязетдинем шул мәктәпне күтәргәч, һәй кинәнде. Абамны да уздырдым дип мактанды.

Аларның кулларын юындырырга җиз таз, җиз комган китерделәр. Кулларын чайкагач, сөртергә озын сөлге бирделәр. "Күр инде, барысы да Аккаладагы кебек",—дип уйлап куйды Айбиби.

Табын мул итеп хәстәрләнгән иде. Һәр кеше авыз эченнән догасын укып, ашый башлады, чөнки Сара анакай ашый башлаган иде инде.

—Килен,—диде Сара анакай.—Сине Рәшидә абыстай сагына икән, барып чыгар иден бер. Алар анда ипле генә сарай мәктәбендә балалар укытып яталар, балаларга сабак бирәләр. Мин аны бире дәшкән идем дә Ибраһимы килешмәгән. Имеш, аңа Биләр ошый төшә.

Айбиби бер сүз дә әйтмәде. Әйе, ул үзе дә Рәшидә абыстаен сагынган иде. Бер утырып серләшәсе килә, тик әлегә кадәр нигәдер аягы гына тартмады. Иске хатирәләрен кузгатып, йөрәгемә яна яралар гына салырмын дип курыкты. Чөнки өлкән равванын кинәттән имам хәзрәтләре булып китүенә күнеле белән әле дә булса ышанмый иде. Әмма Рәшидә абыстаенын хәленә керә—бит ул аны үз баласыдай тәрбияләп үстерде. Еш кына балачактагы кебек анын кочагына инеп, дөньясын онытасы килә иде.

—Барырмын мин анда, әнием, барырмын,—диде Айбиби.—Мена Ибраһимымны урнаштырыйм да, барып кайтырмын.

—Сезнең янда анда дәрвишләр авыл утырганнар икән, бөтен суфый-сафа шунда җыелган икән. Гаязетдин барып туздырам дигән иде, каршы төштем, тимә аларга, алар изге затлар, ил өстенә кара кош канаты булып кара болыт төшәр, дидем. Хазарстанга төшкән кара болыт кебек. Ил кадәр илне юк итте бит, гүя туфан калыкты, дөньяны су басты. Кала артыннан кала су астында калды, кала артыннан кала. Йосыфымны да шул янгыр аждаһасы йотмадымы дип яшим инде ил имгәге булып, киленкәй, ил имгәге булып... Йә, ярый, ризыктан житешеп утырыгыз, карт кешене тынласаң—ут йотарсын, яшь кешене тынласаң—ил кичәрсен, дигәннәр. Яшьләрдә өмет хәзер. Ибраһимда. Иншалла, барысы да әйбәт булыр, сабагын да укыр, мәктәбен дә тәмамлар, биленә кылычын да тагар. Йосыфым әнә биленә кылыч тагуга ук тәхет биләгән иде.

—Әйе,—диде Бибисара килене анасының сүзенә кушылып.—Ил исән булса, җир исән булса, ир исән булса—барысы да булыр, иншалла.

"Тик минем Йосыфым гына кайтмас",—дип уйлап куйды Айбиби.

Әйе, мин хәзер бер байгыш хәлендә, йөрәк парәм улымны да калдырып кайтсам, нинди юаныч калыр мина?.. Аккошларыммы?! Аларны да дәрвишләр килеп ашата башладылар. Бер аккошның түшен каракош яралагач, Айбиби яралы кошны аларга биреп җибәрде. Чөнки барыбер аның итен ашый алмас иде, ул аларны оҗмах кошларыдай күрде. Ә оҗмах кошын укка алган кеше оҗмахка керми, ди торган иде Хәрәзамнан килгән имам хәзрәтләре. Хәер, имам хәзрәтләре үзе дә тәмам изге зат иде Айбиби өчен. Тик Йосыф кахан өчен түгел. Йосыфы имамнарны хәйләкәр рәвештә илләренә озатса да, Айбиби күңеленнән ир-канаты белән килешмәгән иде. Ләкин рәнҗетмә аларны дип әйтә алмады...

Ашап-эчкәч, җыелышып, мәктәп күрергә киттеләр. Ибраһим каерылып-каерылып арттан бер-берсенә нидер әйтә-әйтә көлешеп барган кызларга карады. Әнисе аның җилән җиңеннән тартып куйды. Имеш, тәртипле генә бар. Ләкин ничекләр синең артыннан кет-кет көлешеп барган кызкайларга әйләнеп карамыйча бармак кирәк. Ибраһим башта аларга телен күрсәтте, аннары тешен ыржайтты. Бу юлы аның колагыннан әбисе эләктереп алды.

—Ипле генә бар, әнә мәктәп каршында ук безне имам хәзрәтләре көтеп тора,—диде.

Чынлап та мәктәп ишеге янында ук башына яшел чалма ураган, озын ак җиләң кигән кара йомры сакаллы берәү тора иде. Ул киләсе кунакларны баш ия-ия каршы алды һәм ишекләрне ачыгыз дип, ишекъяры торган шәкертләргә әйтте. Тегеләр исә мәктәпнең ике якка ачыла торган ишек канатларын ачып куйдылар. Иң алдан мәктәп бусагасын атлап Сара анакай узды, аңа кунаклар иярделәр, ләкин мәктәпкә көлешеп килгән кызларны уздырмадылар.

Имам хәзрәтләре шәкертләр укыйсы бүлмәләрне күрсәтә-күрсәтә икенче катка күтәрелде һәм кунакларны, алдан ук сөйләшкәнчә, Ибраһим укыйсы бүлмәгә алып керде. Шәкертләр тез биеклек кенә өстәлләр артында, асларына кырпача җәелгән урыннарда сабак алачаклар икән. Сара анакайга барысы да ошады, ул имам хәзрәтләренә карамый гына бүлмәдән чыга башлады. Ләкин шул мәлдә Айбиби имам хәзрәтләреннән:

—Бер мөгаллим ничә баланы укытачак?—дип сорады.

—Без Хазарстан мәктәпләренең тәртипләрен сакларга тырыштык, каханбикә Айбиби,—диде имам хәзрәтләре бер дә исе китмичә. Ул арада бүлмәдән чыгарга кузгалган Сара анакай алар янына борылып килде.

—Рәсүлем,—диде ул.—Мәктәптә сабак бирү Хазарстандагы кебек калгандыр бит?..

—Калды-калды, анакай, барысы да Аккала сараендагыча алып барылачак, тик инде ислам диненә йөз тотып, изге дингә.

—Рәсүлем,—диде аңа Сара анакай.—Балага сабак бирү һәр илдә дә сүздән башлана, сан белән дәвам итәлә, тарих вә фәйләсуфия белән тәмамлана. Хәтерем ялгышмаса, син дә Аккала мәктәбен тәмамлаган идең түгелме? Гаязетдин шулай дип әйткән иде.

—Хак шулай, анакай, укыган идем. Без шул тәртипләрне монда да дәвам итәргә булдык.

—Уңган кеше булдың әле син, Рәсүл. Исемең дә матур, үзең дә ипле күренәсең, иншалла, Гаязетдин тархан исеменә тап төшермәссең.

—Боерган итсә, анакай, Аллаһыбыз боерган итсә,—дия-дия Рәсүл атлы имам хәзрәтләре Сара анакайга бил бөкте.

—Адәм баласына түгел, мал көтүенә дә тиккә генә чыбыркы шартлатмыйлар. Әнә шуңардан сак бул, имам хәзрәтләре Рәсүл. Сиңа минем улым Гаязетдин—Казан тарханы Гаязетдин сарай мәктәбен ышандырып тапшырды. Синең мөгаллимнәрең сабак биргән шәкертләр ил түрәләре булып китсеннәр. Шуның өчен тырыша минем улым Гаязетдин, шуның өчен, имам хәзрәтләре...

Бөтен бүлмәләрне дә йөреп чыккач, Сара анакай ашханә бүлмәсенә юнәлде, барчасы да аңа иярде. Хәзер инде имам хәзрәтләре алдан йөрмәде, ә Сара анакай аларга суфыйчы булды. Айбиби янәшәсендә барган улының иненә кулын салды. Ошады аңа мәктәп, имам хәзрәтләре дә, хәтта Сара анакай да. Ә бит алар элек тә сирәк-мирәк булса да сарайга килгәләделәр, ләкин Сара анакай аларны беркайчан да болай җылы каршы алмаган иде. Бүген исә үзе үк суфый ана булып йөри. Аш янында да, кызым сиңа әйтәм, киленем син тыңла, дигәндәй, Сара анакай Айбибигә карап:

—Без, киленкәем, Казан каласын Аккаладан ким итмәбез, менә күрерсең, ким итмәбез. Язган булса, киләсе язга румнардан осталар китертеп, кала тирәли тагын да зуррак кальга күтәрергә керешербез. Калын иттереп коймаларын тарттырырбыз, өстәмә күзәтү манаралары төзетербез һәм тимер белән ныгытылган капкалар суктырырбыз. Капкаларда айбалталар тоткан яугир-сакчылар торыр. Нәкъ Хазарстандагыча. Казан каласы бер дә Ханбалыктан ким булмас.

—Шулай булыр, иншалла, шулай булыр. Кальгаларны күреп, баскынчы викинглар Казан тарафына әйләнеп тә карамаслар,—диде имам хәзрәтләре Сара анакай белән килешеп.

—Киленем әйткәнчә, Болакны да кораблар керерлек итсәк, сәүдә үзеге бирегә күчмәгәе әле, имам хәзрәтләре. Шулай бит, киленкәем. Бу мәктәпнең сызымнарын Гаязетдин улым киленем белән икәү сыздылар, икәү киңәшә-киңәшә эшләделәр. Һәм менә нинди мәһабәт бина күтәрдек...

Айбиби бер сүз дә әйтә алмады. Күрәсең, борын заманда да, ягъни Аккалада яшәгәндә дә Сара анакай беркемгә дә баш бирмәгәндер—бигрәк тә раввaларга.

***

Ибраһим улы аны асма күпергә кадәр озата килде. Айбиби күз яше белән елады. Калдырасы килмәгән иде улын Казанда. Әмма һични кыла алмады. Бала белем алырга тиеш, җитмәсә, аның улы. Атасы исән булса һәм алар Аккалада исән-имин көн күргән булсалар, бик ихтимал, Йосыф кахан улын Византиягә укырга җибәргән булыр иде. Шулай иткәннәр борынгы ил башлыклары. Ләкин язмыш аларны туган якларына кайтарып ташлады, Болгарга гына түгел, Казанга кадәр. Зарланмый Айбиби: Аккош күле буендагы утарда яшәү өчен барлык шартлар да бар иде. Бит аның хезмәтчеләр тотарлык та акчасы юк, бар чыгымнарны Гаязетдин тархан күтәрә.

Казан елгасының уң ягында зур гына базар. Күперне үткәндә шул базарга күз ташлады Айбиби. Халык арасында чалмасына тутый кош каурые кадаган мөхтәсиб йөри. Хәрамләшкән сатучыларны тикшерә, бизмәннәренә тамга сала.

Бүген Айбибинең базарга керәсе килмәде. Аңа кисәк кенә моңсу булып китте. Сәбәбе дә билгеле, ул Ибраһимыннан аерылды. Инде берьялгызы калды. Әлбәттә инде Ибраһим бик тиз сарай гадәтләренә өйрәнер, абасы Гаязетдин кырында булырга тырышыр. Әнисен бөтенләй үк онытмаса да бик сирәк исенә төшерер. Хак, нигәдер, Гаязетдингә түгел, Айбибигә Сара анакай: "Борчылма, килен, Ибраһим өчен, айга бер җибәреп торыр ул сиңа аны, үзем исенә төшерермен",—дигән булды. Күр әле, бик тә гаргади хәл ителә икән ләбаса! Ул инде карынында йөрәк индергән, йокысыз төннәрен калдыра-калдыра ана каздай карап, саклап үстергән бәбкәчен ят кеше кулына калдырып китәргә мәҗбүр ителде. Саубуллашканда Айбиби еламады, түзде, хәзер исә, юлга чыккач, ат теркелдәп юыртканда, күчәрбаш йокымсырап баргангамы, тамагына яшь төере килеп өелде. Аллаһы Тәгалә һәр адәм баласына да гомерне дә, мәхәббәтне дә, бәхетне дә бизмәнгә салып, тип-тигез итеп үлчәп бирми... Хәзер бер нәрсәне ачык аңлады Айбиби—әлегә кадәр ул кемнендер бәхете исәбенә бәхетле булды. Сулаган һава, эчкән су кебек бәхет тә һәр кешегә дә үлчәп бирелә, күрәсең. Мин Хода биргән суны артык эчәм икән, димәк, мин кемнендер өлешенә керәм,

йөрәк тибеше белән сулаган һава да шуннан. Әгәр дә мәгәр сина мона кадәр бәхет һәм мәхәббәт муллан бирелгән икән һәм син шул мәхәббәт һәм бәхет суында кайнап, шатланып яшәгәнсен икән, димәк, бу гамәлен белән син кемнендер өлешенә кергәнсен, кемнендер мәхәббәтен, бәхетен урлагансын... Күр инде, нинди дөньяда яши икән ул. Бик ихтимал, анын һәр бәхетен, һәр мәхәббәт тулы мизгелен Ходай үзе күзәтеп торгандыр?..

Айбиби шушы уйлардан сон бераз тынычлана төште һәм тирән итеп сулыш алды. Яши бит әле, яши, нигә ана бу кадәр уфтанырга, бит ул аласын муллан алды, хәтта артыгы белән муллан...

Казан елгасы күперен узып, урман юлына төшкәч, Айбибигә тагы да монсурак булып китте. Ул үзен әле агачлар арасында адашып йөргәндәй хис итте, әле корыган агачнын ботагына куныт, ялгызлыгына зарланган байгыш хәлендә калгандай әкрен генә ынгырашып куйды. Әйтерсен лә кемдер аны рәнҗетә, кемдер зинданга ташлаган һәм анын ихтыяр көчен сыный иде. Әйе, ул кем? Аллаһы бармаклары арасыннан жир өстенә төшкән тузан бөртеге генә ич. Азмы анын кебек ялгызлар бу дөньяда?! Бик күптер...

Шунда Айбибинен аръяктагы балык тотып утыручы дәрвишләргә күзе төште. Ни өчендер дәрвишләр суык көннәрдә дә, эссе көннәрдә дә тоташ карадан киенерләр иде. Һәм алар беркайчан да коенмыйлар. Судан куркалар булса кирәк. Дәрвишләрнен берәр йоласыдыр инде. Көн жылы булуга карамастан, дәрвишләрнен барысы да тоташ карадан киенгән килеш балык тоталар иде. Дәрвишләр өчәү. Сөйләшмиләр. Күзләре калкавычларда. Дәрвишләр балык яраталар икән. Кем балык яратмый?.. Тик монын өчен аны тотарга кирәк. Гаязетдин, әнә, жәйгә ике-өч тапкыр утарга килә дә балыкчы чирмешләрдән аккош күленнән жәтмә белән балык сөздертә. Шул көннәрдә утар гөжләп торыр иде. Балык шулпасы пешерерләр, утта кыздырырлар, бала-чагалар уйнарлар, көләрләр, бер-берсен куышырлар иде. Айбиби дөньясын онытып, Ибраһимынын каладан килгән балалар белән уйнавын күзәтер иде. Күрде-күзәтте ич, Ибраһим, анын Ибраһимы гел бер кыз баланы куды, гел аны куып тотты һәм гел анын янында булырга тырышты. Айбиби кечкенә, әле үсмер генә кызга теге яклап та карады, бу яклап та—кыз бала ана ошады. Әмма сонынннан кыз баланын чирмеш бәге кызы икәнен белгәч, аптырабрак калган иде. Тик монын белән генә кыз баладан гайрәте чикмәде. Чирмешләр гомер-гомерләргә Атилла бабалары чорларыннан бирле төрки-татарлар белән бергә булганнар, бергә яу йөргәннәр, бергә ил-жирләрен саклаганнар, дин-йола вә гореф-гадәтләрен читкә куеп, теге якны да, бу якны да рәнҗетмичә, кызларын төрки егетләргә кияүгә биргәннәр, егетләрен төрки кызларына өйләндергәннәр. Тик кем бәгенен кызы икән? Чирмеш бәге Гаязетдин кул астында хезмәт итә булса кирәк, чөнки бәк үзе бирелә булмаса да кызы килгән ич. Шул хакта сорарга теләсә дә нә Гаязетдингә, нә Бибисарага сүз ката алмады. Әмма кыз баланын төсе-йөзе генә түгел, буе-сыны, зифалыгы да күнеленә сенеп калган иде. Күр инде, ул үзе дә бит нәкъ шулай киенер иде. Бала итәкле күлмәк, башында калфак, зур булмаган хаситә, аягында ак читек. Кыз баланын инде күкрәге дә калкып чыга башлаган. Әле булса хәтерендә, күкрәге үсә башлагач, шул тирәләре кычыта башлаган иде. Ә Рәшидә абыстай моны күреп алды: "Курыкма, балакай, угала син аны, угала, кычытуы шундук бетәр",—ди. Шул мәлләр хәтер күгендә пәйда булуга, Айбиби үзалдына елмаеп куйды. Анын тик торганда елмаеп утырганын күреп тарханбикә Бибисара: "Жингәчәй, Гаязетдин бәге кызыннан күз дә алмыйсын, әллә Ибраһимга кыз да сайлый башладын инде?"—дигән иде. Айбиби ана бер сүз дә әйтә алмады. "Бишектәге бала—бишкә үзгәрә",—дип әйтергә итсә дә тыелып калды.

Айбиби аккошларны ашаткач, өйгә таба кузгалды. Шул чакта анын күзенә озын нарат башында утырган каракош күренде. Каракошны күрде дә Айбиби шып туктап калды. Һәм каракошка карады. Юк, ул ана уктан атарга дип туктамады. Ул—бу явыз кошка тагын ни житми сина? дип туктады. Чөнки ул ана да нарат агачына ит элдерә башлаган иде. Ин сәере

шул, каракош баштагы мәлдә агачка элгән итне рәхәтләнеп ашаса да, үтә канәгать калып, кай тарафкадыр очып китсә дә, соңрак бу яман кош итне алмый башлады. Әмма нарат башына килеп куну гадәтен ташламады. Айбиби аны куркытмады, берни булмаган кебек үтеп китте. Күрәсең, яман кош та аңа өйрәнә башлаган иде инде, кымшанмады да, бары тик битараф бер төстә күзен йөртеп кенә аның ягына карап алды.

Хезмәтчеләре табын хәстәрләгәннәр, аны күтеп торалар иде инде.

—Беләсенме,—диде аңа аш янына килеп утыргач, пешекче апа.—Безгә, һич көтмәгәндә ниндидер тоташ кара киемдәге аръякта яшәүче дәрвишләрнең берсе килеп китте.

—Кемне сорады?

—Ибраһимны. Теге углан кая булды, абыстай, дип сорады, менәтрәк, Айбибием. Мин әйтәм, углан тархан сарае мәктәбенә укырга китте, ул хәзер бик сирәк кайтачак, нигә кирәк булды сезгә ул бала, дигән идем, бер сүз әйтми, борылды да китте, Айбибикәем. Мин аны төзүче итәргә иткән идем, ди. Бөтен йөзен тутырып кара сакал баскан, күзләре генә елтырый үзенең, менәтрәк.

—Яңадан килсә, капкадан да кертмәгез,—диде Айбиби һәм бу хакта онытты да.

Тик кич кояш баеп, хатын-кызлар зур бүлмәгә җыелып, дөньяви китаплар укып утырганда гына сәер дәрвиш хәтер күгендә ялтырап үтте. Чынлап та ул йөзе-башы кара сакаллы дәрвиш кем булыр? Нигә аңа нәкъ менә аның улы Ибраһим кирәк булды икән?..

Җырлар җырлап, бәйләү бәйләп утырган һәр хатын-кыз үзенең яшьлектә булган беренче мәхәббәтен, язмышын сөйләде, әмма берсе дә, кыеп, син дә сөйлә әле, Айбиби, дип әйтмәде. Хәер, аның язмышын барысы да беләләр иде инде. Хан кызы ич!..

Нәрсә тапты да, нәрсә югалтты? Хазар каханы каханбикәсе булып Айбиби? Җавабы бер иде—ул үзенең мәхәббәтен тапты. Ни гаҗәп, кырык хатыны булган Йосыф кахан йөзендә. Кемгә сөйләп, кемне ышандыра ала ул?.. Ләкин ул аңа гашыйк булды ич, булды. Һәм бер күрүдә! Әле булса ул аны юксына, тансыклый. Нәрсә бу? Мәхәббәтме, әллә соң язмышына буйсынумы?..

Ятагында, укыган китабын бер читкә куеп, әнә шулай еш кына уйга калгалады Айбиби. Улы да киткәч, аңа көн саен моңсурак була башлады. Ул моны бөтен җаны-күңеле белән тойды. Ялгыз калды ич ул, бөтенләй ялгыз! Аңа хәзер бу утар да, хезмәтчеләре дә—беркем дә кирәкми. Улы, улы кирәк аңа—Ибраһимы...

Менә шунда кинәт зиһене аша яшен чаткысы узгандай күз алдына Йосыфы килә. Кинәт кенә ничек юкка чыга ул? Бит ул кахан! Илбашы!

Шул хакта беләсе килә иде Айбибинең, кемнән дә булса сорашасы, кем белән генә булса да шул хакта сөйләшәсе килә иде. Кеше тузан бөртеге түгел ләбаса, адәм баласы, җитмәсә, илбашы. Һәм шул кеше кисәктән юк булсын инде. Ә бит сарай халкын үз кулында тоткан өлкән равва исән! Кахан—юк?! Җитмәсә, күзен дә йоммый Шәмгун хан сараена кереп оялаган—мөфти булып киткән, мөфти, бөтен имамнарга имам, муллаларга мулла. Ул гынамы, аның анасы кебек кешене үзенә ябыштырып алып китте. Менә монысына җавап таба алмады Айбиби. Шул ук вакытта ни өчен Сара анакай аны кабул итми дә, ә менә Рәшидә анакае Ибраһим мөфтинең җәмагате булып китә?..

Айбиби кулына янә укыган китабын ала, укый башлый, башына килгән уйлардан арынасы килә. Тик инде укый алмый, уйлар аның бөтен күңелен биләп алган иде. Ул кузгала, аягына җофар чүәген элеп, иңенә шундый ук җофар халатын салып, йокы бүлмәсеннән урам ягына чыга, күл өстенә мөлдерәп төшкән тулы айга карый. Сәер дә соң бу дөнья. Нигә тулы ай көннәрендә аның күңеле хиссияти истәлекле уйларга чума да һәм ул сагышлана башлый? Әллә соң тулы ай аның хиссияти мәхәббәтен үзендә саклыймы һәм ай саен шул хакта искәреп торамы?..

Күл тыныч түгел, котмәгәндә адашкан үрдәк бакырып куя, күп тә үтми аның кырына ише килеп төшә һәм алар үзара сөйләшеп алгандай тыенкы гына бакылдашып алалар.

***

Бер ай да үтмәде Айбиби янә Казан каласына таба кузгалды. Барысына да иртән күргән төше гаепле булды. Имеш, аның улы Биләрдән килгән мөфти Ибраһимга ияреп китеп бара, ә ул аны күпме Казанда калдырырга теләсә дә, үгетләсә дә, Ибраһим аны тыңларга теләмичә китеп барды. Уянгач, күргән төшен янә бер тапкыр башыннан уздырды. Әүвәл Айбиби күргән төшен утар карачысы хатыны Хөснижамал абыстайга сөйләргә иткән иде, тыелып калды. Юрамый торсын әле, Ходай язганы булыр, үзем барып кайтам, үзем беләм күргән төшемнең хаклыгын, хак түгеллеген.

Күчәрбаш та аның ашыкканын белгән кебек атларны куалады, ни гаҗәп, асма күпердә дә гадәттәгечә кальгага керергә чират торучылар юк иде. Айбибинең күчәрбашын күреп, сакчылар капкаларны ачтылар һәм каханбикә күчәрбашы сакчыларга баш кагып кына сәлам юллады да, атларын туп-туры Гаязетдин тархан сараена таба куалады. Сарай болдыры янына атлар туктауга, күчәрбаш баскычны төшерергә дә өлгермәде, Айбиби арбадан төште, каханбикәсенә арбадан төшәргә ярдәм итә алмаган күчәрбаш, гафу үтенгәндәй кулларын җәйде. Айбиби беркемне дә күрми иде инде, йөгерә-атлый баскычлардан сарай ишекләренә таба ашыкты. Сакчылар ишекләрнең бер канатын ачтылар, бусаганы атлап керүе булды, аның каршында Ибраһим мөфти пәйда булды.

—Ау-о!—диде ул Айбибине күрүгә.—Йа Хода, Айбиби каханбикә үзе. Исәнме-саумы, каханбикә?—дип, күрешергә ике кулын сузды.

Мөфти булып алган Ибраһим артында кайдадыр күргән таныш йөз чалынып алды, әмма Айбиби игътибарын Ибраһим мөфтигә күчергән иде инде.

—Рәшидә абыстай...

—Монда, монда, Рәшидә абыстай да монда, кызлар мәдрәсәсенә киткән иде. Кайтыр ул, кайтыр, каханбикә Айбиби, кайтыр...

Теләсә-теләмәсә дә Айбиби Ибраһимга күрешергә кулын сузды. Көрәк кадәр кул эченә кереп эләккән сандугачтай сизде Айбиби үз кулын. Кулын гына түгел, тәне-җаны да. Һәм аркасы буйлап салкын дулкын узуын тоеп, куырылып китте.

Ул арада Айбиби каршына Гаязетдиннең тарханбикәсе Бибисара йөгереп килде.

—Җиңгәчәй, әйдәгез, узыгыз, Гаязетдин сезне көтә,—диде дә Айбибине кочаклап алды һәм колагына: "Улыңызны хан сарае мөфтие Ибраһим Биләргә алырга килгән, Шәмгун хан үтенече",—диде.

—Мин моңа шатланырга тиешме, киленкәем Бибисара?..—диде барыр җайда Айбиби.

—Шатланырга, тиешсең, җиңгәчәй, шатланырга. Хан дәшә ич, хан үзе.

Айбиби бер сүз дә әйтмәде. Ул бу хәлнең мөфти Ибраһим җәтмәсе икәнен бераз чамалый иде, ләкин бу хакта кемгә булса әйтергә курыкты. Бит Гаязетдин тарханның мәдрәсәсендә менә дигән белекле мөгаллимнәр сабак бирә. Әллә соң Гаязетдин дә Ибраһим мөфти җәтмәсенә эләгергә өлгергәнме?.. Башта Рәшидә абыстайны, Гаязетдинне, хәзер улы аша аны—Айбибине...

Ул арада тәхет ягына керделәр, Гаязетдин тархан хатыннар ишектән керүгә, үзе үк аларга каршы китте.

—Исән-имин киллегезме, җиңгәчәй, иминлекме?..

—Аллага шөкер, барысы да әйбәт, Гаязетдин.—Айбиби аның күзләренә карады һәм янә тәне кымыржып куйды.—Улымны ерагайталар дип ишеттем дә...

—Барысы да әйбәт булыр, Ибраһим сарай тәртипләренә өйрәнә торыр. Шәмгун хан фарсылардан белекле галимнәр дәштергән, гарәпләрдән дә

килгәннәр, сарай мәдрәсәсендә балаларга сабак бирәчәкләр. Әйдәгез, жиңгәчәй, түрдән узыгыз. Башта аш ягына узыйк, тамак ялгап алырбыз. Ул арада Рәшидә абыстай да кайтып житәр, бергәләп Кабан күленә төшәрбез. Мин, жиңгәчәй, Кабан күлендәге утрауга мәһабәт бер өй-утар күтәртеп ятам бит әле. Сызымнарын да үзем эшләдем. Осталар да таптым. Бишәүләр, өчесе фарсылардан, икесе румнардан.

—Сара анакай кая соң? Минем аны күрәсем, утырып бер сөйләшәсем килә, Гаязетдин тархан.

—Кайтыр ул, Самарага киткән иде. Аның тагын бер улы анда тархан булып утыра ич.

—Самарада, Сара анакайның улы тархан?!—дип гажәпләнде Айбиби.—Нигә мин бу хакта белмим?..

—Йосыф каханның кырык хатыны бар иде, Айбиби жиңгәчәй,—диде Гаязетдин табындагыларга ризыктан рәхим итегез дип баш какты.—Ул угланны да Сара анакай карап үстерә...

Килене Бибисара Айбибигә иелә төшеп, колагына гына:

—Ибраһимның монда килүен ишетүгә китте Самарага анакай, күрәсем килми шул мөртәтне, диде. Гаязетдин бу хакта белми, анакай әйтергә кушмады.

Айбиби килене Бибисарага карап алды, елмайды, ияк кагып кына рәхмәт әйтте. Менә хәзер Рәшидә абыстайны күрәсе иде, ә ул һаман кайтмый.

Ибраһим мөфти табынга да узмады.

—Ибраһим мөфти Рәшидә абыстайны каршы алырга китте,—диде Гаязетдин тархан Айбибинең ни уйлаганын белгәндәй.

Айбиби бер сүз дә әйтмәде, чәкчәк белән әкрен генә чәй эчте, ә үзе уйлады... Димәк, Хазарстанны таркаткан өлкән равва Ибраһим инде Идел буе Болгарын таркатырга жыена. Шулай булмаганда нигә бу кеше ислам динен кабул итеп Болгарга килә дә, хәтта Казанга кадәр уза. Кем кирәк ана, ни житми бу Исраил баласына?..

Айбиби шулай дип уйласа да бу хакта беркемгә дә әйтергә кыймады. Аны, гомумән, монда берәү дә аңламас иде. Аңласа-аңлар аны Сара анакай. Ләкин ул өйдә юк, Самарага киткән. Кайтыр ул аннан, кайтыр һәм Айбиби аның янына килеп, барысын да сөйләр. Ибраһимның чын йөзен ачар.

Ул арада Рәшидә абыстай кайтып керде. Керде дә йөгерә-атлый килеп, Айбибине күкрәгенә индерде.

—Сине күрер көнем дә бар икән, балакаем! Ябыгып киткәнсең димме? Юк, ябыга төшкәч, син тагын да сылулангансың. Күз алмалы түгел үзеңнән, күз алмалы түгел.

Ул аны тагын-тагын күкрәгенә кысты, елап ук жибәрде. Һәм колагына: "Талибымны күргән кебек булдым",—диде.

Ашап-эчкәч, фарсы келәменә кырпачалар ташлап, түгәрәкләшеп утырдылар да кем нинди яңалык белә, шул хакта сөйләргә тотындылар. Айбибигә нәүбәт житкәч, ул:

—Сөйләр яңалыгым юк, без анда яшәргә өйрәндек инде,—диде.—Менә Ибраһимым төшемә керде дә килдем әле. Иртән торабыз да аккошлар ашатырга төшәбез...

—Әнием, дәрвишләрнең безнең якка чыкканнары юкмы!—дип әнисеннән сорады Ибраһим.

—Юк, чыкканнары булмады. Без киткәчтен берәү килгән, балык тотарга камыр сораган.

—Камырга вак балык каба, эре балык сабан кортына эләгә, әнием.

—Мин ул дәрвишләргә сабан кортына кадәр казып бириммени инде, улым? Балыкларын үзләре ашыйлар, жимне без бирикме?

—Алар кимсетелгән халык, суфыйлар, изге жаннар.

—Изге жан күл буенда балык тотып ятмый, кырда эшли, улым.

—Йә булмаса, минем төзүчеләр кебек биналар күтәрә,—диде тархан Гаязетдин.

—Кабан күле буенда утар әзер булгач, Айбиби жиңгәчәй, мин сезне

шунда алып барам әле. Җәннәт анда,—диде тарханбикә Бибисара.

—Күрәсем килә. Тик мин үзем дә оҗмахта яшимдер кебек, Гаязетдин туганым безгә шундаен матур итеп күтәргән утарны, үткән-сүткән кеше туктап-туктап карый.

—Тырыштык инде, җингәчәй, сезнең өчен тырыштык. Тик менә абамның гына әле булса табылганы юк.

—Илдә чыпчык үлми, иншалла, табылыр. Фарсыларга фәлән киткәндер, йә викинглар алып киткәннәрдер үзен,—диде Гаязетдин.

Мөфти Ибраһим тамак кырды, әмма бер сүз дә әйтмәде.

Рәшидә абыстай гына:

—Ризыгы бетмәгән булса, иншалла, кайтыр. Минем әле булса хәтеремдә: сезне килеп алырмын, диде. Шулай бит, Айбиби?

Кыен иде Айбибигә бу хакта сөйләшү, аның күңеле тулды, бер сүз дә әйтмәде, башын тагын да ия төште. Һәммәсе дә аңладылар: Айбибигә авыр бу хакта сөйләшү.

## XX

Хазарстаннан Биләргә күчеп килгән Ибраһим сөннәтле казаклар унбашы Сатлыкны кая гына барса да үзе белән йөртте. Хазарстанда унбаш вазифасын үтәгән бу кеше, Биләргә килеп мөфти булып киткәч тә һәрчак аның янында булды. Нигездә унбаш Сатлык аның җансакчысына әверелде. Әйе, гәрчә бу кеше христиан булса да һәм муенына бакыр тәре тагып йөрсә дә, Хазарстан дәүләте диннәргә битараф булган кебек, Шәмгун хан да мондый хәлләргә игътибар итмәде. Иң мөһиме, аның кырында дистәләрчә еллар Хазарстан белән идарә иткән тәҗрибәле сәясәтче Ибраһим үзе иде. Болгар ханы: "Димәк, без Хазарстанның дәвамы",—дип үз-үзен юатты. Сарайда мөфти сурәтендә йөргән Ибраһимның чукынган сакчысын Шәмгун хан, гомумән, күрмәде, кызыксынмады да. Тарихлары белән дә таныш түгел иде. Бар белгәне шул—Хазарстан белән нигездә раввалар идарә итә, Йосыф кахан түгел, шул ук вакытта хәбәрдар иде инде: Йосыф каханны Хазарстан тәхетенә күтәрүче бүген аның сараенда мөфти вазифасын үтәгән Ибраһим була. Ләкин бит Хазарстанда кала тарханы булып торган Булат бәк тә бүген аның сараенда утыра һәм киңәшчесе генә түгел, сәргаскәре дә. Иң гаҗәбе, Биләр сараена килеп оялаган Ибраһимга Булат бәк тә шаккатмады. Моның өстенә хәйләкәр яһүд Ислам диненә күчеп кенә калмады, сарай мөфтие дәрәҗәсенә әверелеп, Казан тарафындагы Хазарстанда никахлашып Рәшидә абыстайны да алып кайтты. Шуның өчен нә Ибраһим, нә Булат бәк булган хәлләр турында сөйләргә дә, сөйләшергә дә теләмәделәр. Бу—алар өчен тыелган әңгәмә иде. Моның өстенә бер төрки дөньясының олуг илен югалтып, икенчесен шундый ук куәтләндереп җибәрәсе юнәлешендә хәрәкәт итәләр, җитмәсә Рәшидә абыстай ярдәме белән булса кирәк, Ибраһим Коръән хафизлыкта барчасын да шаккатырды. Ул гынамы, Ибраһим артыннан ук Ислам динен кабул иткән яһүд сәүдәгәрләре Болгар һәм Биләргә килеп урнаштылар. Һәм Самара, Казан, Кызсорама калалары аша Киев каласына сәүдә юлын аякландырып җибәрделәр. Идел буеннан күтәрелгән сәүдә юллары әкрен генә алар кулына күчә башлады.

Әлеге хәлгә, бигрәк тә, Ибраһим мөфти канәгать иде. Бу кеше сарай мәктәбен киңәйтүдә, яңача уку-укыту эшләрен алып баруда алгы сафларда булды. Дини вә хәрби сабаклар янына дөньяви фәннәрдән сабак бирүне җайга салды. Гыйлемлек төрки-болгар халкының канына сеңеп керә башлады. Мөфти Ибраһим белән Рәшидә абыстай бериш асыл шәкертләрне фарсыларга, хәтта Гарәбстанга укырга, сабак алырга җибәрделәр. Шулар янына сарай табибы үтенече белән аның улы Ислам да фарсыларга укырга озатылган иде.

Ибраһим, Биләр каласында мөфти вазифасын үтәсә дә, беркайчан да Яхвасын онытмады, шушы ерак бабалары Алласы аның күңелендә һәрчак зәбәрҗәт кебек җемелдәп торды. Үзе тәхеткә күтәргән Йосыф балакайны да шул юнәлештә тәрбияләргә тырышкан иде ул. Тик, балакай, кинәт юкка

чыкты, әйтерсең лә үзен жир йотты. Йосыф исемен хәтта Рәшидә абыстай да искә алмады. Тик, илдә чыпчык үлми, диләр бит. Гомере булган кешенең аты-исемен бер ишетмәсән, бер ишетәсең икән ул.

Бу хәл көтмәгәндә булды. Ибраһим еш кына базарга чыкты. Халык сүзенә колак салып йөрде. Базар читендәге мәйданчыкта бертөркем халыкны күреп, шунда таба атлады. Килде, бер читкәрәк басты, мәйдан уртасына жәймә салып бөкләнеп утырган суфыйның сүзләренә колак салды. Сүзенең аты-башы юк, вә ләкин көйле, жор телле иде суфый. Тагын да якынрак килде. Әһә, суфыйлыкка йөз тоткан борадәр зат сөйли. Теле-телгә йокмый. Борадәрнең алдында тирән кара түбәтәй, кара чикмән башлыгын күзләренә төшереп үк кигән, түбәтәйгә очкан тәңкәләргә күз дә ташламый, сөйли дә сөйли.

"...Атамыз Әхмәт Ясәви әсәрләренә күз салыгыз, мөгаллимебез Мәхмүд Болгари сәяхәттә. Кайтыр ул, кайтыр. Без борадәрләр Казан елгасы буендагы салада яшибез. Халык безнең каланы Дәрвишләр саласы дип атый. Табыныбыз, ризыгыбыз уртак, догабыз Ходадан. Дәрвишләр саласында тиздән мәктәп ачачакбыз. Жибәрегез улларыгызны, үкенмәссез. Әйе, без байлар түгел, әмма без рухыбыз белән ярлы янында ярлы, бай янында бай. Күңелем белән бай мин. Күңел байлыгының бәһасе юк. Күңел байлыгы— гыйлемдер, алтын-жәүһәр, көмеш-якут дип бер дә лаф орасы юк. Күңелем келәтендә жәннәт бакчасындагы барлык жимешләр дә бар. Ни өчен шул көнгә калдым соң мин? Гүзәл хатын мине шул көнгә калдырды, жәмәгать, гүзәл хатыным. Юк, мин аңа рәнжемим. Мактыйм мин аны. Сөбханалла, чибәр иде дә соң, гүзәлкәем. Кочагыма инү белән күгәрчендәй гөрли башлар иде. Назлап сөйдем, үпкәндә кершәннәрен коймаска тырыштым. Нечкә биленнән кочтым, зифа сынын онытa алмый әле булса жәфаланам, сагышланам, Аллаһыма: "Кайтар шул гүзәлне кочагыма!" дип ялварам. Бер төнгә булса да. Юк шул, юк, хәзер инде бәхетемне күктән көтәм. Оныта алмый интегәм сөйгәнемнең шомырт кара күзләрен, мин—синеке, син—минеке дигән сүзләрен. Хыял эссе, хисләр көчле чак иде, күңел яшен, тойгым чаткы иде. Юк-юк, мин ялгыз түгел, ул кайтыр миңа, кайтыр, кайтыр минем кырыма, күкрәгемә килеп капланыр да: "Гөрләшеп яшик әле тагын бер, Жәмилем", дияр сыман. Шайтан—өметсез, диләр, ә мин адәм баласы ич. Әлегә мин гыйлем жыям, зиһенем чарлыйм, хәтерем баетам. Кайда? Үзебезнең Дәрвишләр саласында. Алай да төшемә керәсең, гүя акбүз атта кайтасың, акбүз атка салып алып киттеләр ич бәгыремне! Төшме, өнме—белә алмый уянам, Хода биргән татлы төшләремә кинәнәм. Бер күрергә мон-зар булып яшимен, чарасыздан мендәр башын тешлимен. Тулган айдай күзләреңне бер күрәсем, үлсәм дә ризамындыр зифа сының бер сөйсәм. Әмма кавышып булмас, син дә, мин дә сәбәбен беләбез, жәннәтләрдә очрашырбыз дип әжәл көтәбез... Көлик, әйдә, көлү безгә килешә лә, йөрәккәем күкрәгемдә тибешә лә. Бәхетсезлегемне белү, үзе бәхет миңа, диванадай гашыйк кеше өчен мәхәббәтем тәхет миңа. Артык бәхет исертәдер адәмен, түзмәй жаным, кулга алам, каләмем. Агач башлары бөдрә-бөдрә, бөреләрен кояш көйдерә, күз алдыма килгән саен зифа сының, жаным, сөйдерә. Әй кешеләр, яшәмәгез яратмаган жаннар белән, коры-сары чит-ят каннар белән. Кая китте соң яшьлегем, дисезме?.. Сагышланмас өчен кулыма алам дисбемне. Беләм, сизәм, тоям күрәм үткәннәргә кайтулар булмастыр, бер баеган кояшларым янадан чыкмастыр. Тәүбә итә-итә гөнаһымнан качамын, сөбханалла дия-дия намазыма басамын...

Борадәр тынып калды, түбәтәйгә акчалар коелды. Халык: "Һай, Аллам, һай, Тәнрем!"—дия-дия тарала башлады. Ялгыз калган борадәр янына Ибраһим килде һәм түбәтәйгә бер бәлеш алтын ташлады. Түбәтәйдә алтын тәнкә төшүгә, борадәр башын күтәреп Ибраһимга карады.

—Хатынын үзең теләп биреп жибәрденме?—дип сорады эретерәк кенә Ибраһим.

—Үзең теләп атларны гына саталар, ил бәндәсе. Батыр бәккә ияреп китте, жанашым, күз-нурым.

—Хәзер башын диванага салып, Дәрвишләр саласында көн күрәсенме?

—Язмыштан—узмыш юк, Алла бәндәсе. Мин үз язмышым белән килештем.

"Минем кебек иткәнсең икән",—дип уйлады Ибраһим һәм түбәтәйгә тагын бер бөлеш алтын ташлады. Бу юлы инде, диванага башын салган борадәр торып ук басты.

—Мин үзем дә бәкләр санында йөргән кеше идем, Алла колы, мине хатыным шул көнгә калдырды.

"Мин шул көнгә калмадым, иншалла, юлымда Рәшидә абыстайга юлыктым",—дип, китәргә жыена башлады Ибраһим, гәрчә бу сүзләрне күнеленнән генә уйласа да, аның ни турында уйлаганын белгән кебек борадәр шагыйрь кисәге аның жиненнән эләктереп алды.

—Бездә дә кахан бар, үзен хазарстан каханы булдым дип мактана. Ләкин ана без ышанмыйбыз. Бездә һәр унынчы борадәр йә хан, йә кахан.

—Бер сүз белән диваналар оясы, шулаймы?..

—Жүләр—дивана түгел, дивана—жүләр түгел, Алла бәндәсе. Биш тапкыр намаз укыйбыз, тәһарәтен алабыз, мәктәп күтәреп ятабыз. Синең иганән мәктәп салуга китәчәк, игелекле жан.

—Дәрвишләрдән ханнар да, каханнар да чыкмый, Алла бәндәсе.

—Син хаклы, изге жан, хаклы. Саташкан халык яши бездә, ләкин һәммәсе үз акылында—гыйлем белән саташа, күктәге Аллаһыга һәрберебез үз баскычыбыз үрәбез, Коръән Кәрим аша.

—Мин китим инде, Алла бәндәсе.

—Атың ничек, изге зат?

—Ибраһим атлы мин, пәйгамбәрләр санында йөргән кеше.

—Син дә безнең кебек үк Хода бәндәсе икәнсең,—дип калды дәрвиш һәм, түбәтәйне алып, билендәге күн капчыкка тәнкәләрне койды, Ибраһим моны күрмәсә дә акча тавышы аның колагында калды. Чөнки акча дәүләтнең генә түгел, кешене дә куәтле итә дигәнне бик яхшы белә иде ул. Әйдә, төзесеннәр мәктәпне дәрвишләр, бер акча гына түгел, китап та яшәтәчәк илне. "Китапсыз халыкның киләчәге дә юк, акчасыз халыкның да",—дип уйлана-уйлана атлады сарай тарафына таба Ибраһим.

Әйе, алар ил кадәр илне югалттылар. Сәмәндәрне Сарманай кахан жимерде, чөнки ул каланы бик еш су баса иде. Хазарстан каханнары башкалаларын Итилгә күчерделәр, утрауга. Башка халыклар Ханбалыкта торалар. Ил белән яһүдләр идарә итә—раввалар. Атна-ун көн эчендә ил кадәр ил су астында калды. Бу хакта ничек, нинди сүзләр белән тарихка язарга, кем ышаныр мона?!

***

Көн азагында аның кырына Хөснижамал мөгаллимә керде.

—Айбиби, балакаем, хезмәтче бер үрдәкне аткан, шуны тазартып пешертимме әллә үзеңә, кичә дә тамагына берни дә капмадың?

—Безнең күлдән алдымы үрдәкне?

—Юк, Идел буеннан укка алдым дигән булды.

—Юк, кирәкми. Алган үрдәкне каршы яктагы дәрвишләргә бирсен.

—Үзе ашаса?

—Үзе бер сарыкны чалсын, вак-вак итеп турап, дөге ашы пешерсен.

—Яхшы, шулай дип әйтермен,—диде мөгаллимә һәм, борылып, чыгып китте.

Ни талкый аны, нигә аңа күнелсез? Әйе, нигә аңа кояш, күнелен кара болыт томалап торкач? Кем аны бу утарга яшерде? Улы янында булганда бу хакта аның уйланганы да юк иде, хәзер исә, кара урман эчендә берүзе калган берәүдәй, ялгызлык хәсрәте кичерә. Ана яшәү рәвешен алыштырырга кирәк. Шатлык белән яманлыкны бергә кушарга. Кешеләрдән көләргә, кирәк икән кайберләрен мыскыл итәргә, рәнжетергә, хәтта елатырга һәм көлү-кызгану аша күз яше түгәргә, алар белән бергә. Юкса сине ялгызаклык басачак, күнелең кайгы-хәсрәт күмәчәк.

Айбиби көмеш кынгыравын зеңләтте. Хезмәтче керде.

—Сарыкны чалган булсагыз, зур казанга бөтен итне салыгыз, күп итеп казан-казан дөге ашы пешерегез һәм аръяктагы дәрвишләрне дәшеп, ашатып-эчертеп җибәрегез.

—Бу мөмкин хәлме, Айбиби каханбикә?

—Мөмкин итсәгез, мөмкин хәл, Садрый абзый.

—Мөмкин итәргә туры килер,—диде Садрый агай һәм баш иеп чыгып китте.

Китап укый-укый күзе тала башлагач, Айбиби ишегалдына чыкты, күл буена таба атлады. Ә анда чынлап та дүрт-биш казан асканнар, тирә-якка тәмле ит исе таралган, казаннар тирәсендә хезмәтче хатыннар, ир-атлар урала иде инде. Берәүләре чирәмгә киез җәя, икенчеләре савыт-саба хәстәрли, беришләре чалган сарыкның баш-аягын көйдерә.

—Дәрвишләрне дәштегезме?—дип сорады Садрый агайдан Айбиби.

—Варяглардан калган баркаслар белән чыгачаклар. Ике баркас кеше булачак, димәк, кырыкка якын сукыр-суфый.

—Нигә сукыр-суфый?

—Казанлылар аларны шулай диләр, сукыр-суфыйлар, диләр. Чөнки алар арасында акылга җиңеләйгәннәре дә, күзсезләре дә бар, каханбикә Айбиби.

Айбиби янә нарат ботагында утырган каракошка карап алды. Күр инде, утыра, бер гамьсез утыра. Нигә утырмасын, тамагы тук, Айбиби хезмәтчесенә яңа суйган сарыктан өлеш чыгарырга кушты. Үзе дә белми ни өчен, әмма әйтте: "Теге мәртәткә дә ит кисәге ташла инде",—диде. Ләкин бу яман кош ашатуның кадерен белерме, яңа чыккан аккош бәбкәләрен алырга ажгырып тормасмы?.. Иң яман кошларның берсе ич!

***

Күл буенда шау-шу купты. Беренчеләрдән булып, бәйрәмгә викинглардан калган баркас көймәләре белән дәрвишләр килде. Аларны Садрый агай каршы алды, һәммәсенә дә көймәдән төшкәндә кул биреп, күл читенә төшәргә ярдәм итте. Дәрвишләр барысы да тоташ карадан киенгәннәр, күзләрен капларлык итеп, хөллә башлыкларын төшергәннәр. Күл буендагы чирәмгә аяк баскан берсе ике тезенә төшеп, дога кыла, һәммәсе дә Айбиби басып торган айванга* күз ташлап ала. Садрый агай аларны ат абзары кырындагы кечкенә мәчет янына уздырырга тиеш иде, барысы да көймәдән төшеп беткәч, ул аларны шунда таба ияртеп алып китте. Каз бәбкәләре кебек Садрый агай артыннан тезелеп барган дәрвишләр ашыкмый гына атлыйлар һәм янә-янә, Айбиби чыгып баскан, сырлап нәкышләнгән, төрле төсләргә буялган балконга карап алалар. Сәер халык та соң бу дәрвишләр, үз бакчаларында эшләсәләр дә, тамак туйдырырлык җиләк-җимеш һәм яшелчә үстерсәләр дә кунакка йөрүдән баш тартмыйлар. Ахыр килеп, кайлардан килә ошбу суфыйларга мал асрамау йоласы да һәм нигә алар халыктан читләшәләр?.. Айбиби моны белми иде. Ләкин бу кешеләргә хөрмәте зур иде. Суфыйчылык кылганнары өчен генә түгел, үз кагыйдәләренә тугры калып, аны кабергә кергәндә дә саклаганнары өчен.

Ни аягы тартса да Айбиби дәрвишләр янына ашыкмады. Шул ук вакытта белә иде—Казан каласы кырындагы дәрвишләр Харәзем суфыйлары белән элемтәдә торалар, һәр шәһәрдә диярлек ханәкәләре, үзләренең мәчетләре бар. Садрый агайның сүзләре хак булса, дәрвишләр арасына килеп кергән һәр кеше мөкамәт—суфыйлар юлын үтәргә тиеш. Мөкамәтне үткән кеше генә мөрид булып китә ала. Мөршәһит белән мөрид арасында бернинди дә сер булырга тиеш түгел. Акыллы мөршид үз мөридендә йоклап яткан хиссияти тойгысын уятырга тиеш, ягъни үзендә генә түгел, укучысы күңелендә йоклап яткан рухи тойгыны уятырга һәм аны Аллаһка йөз тоткан хакыйкатькә якынайтырга.

Анламады Айбиби бу халыкны, аңларга да теләмәде, ул аларга

*Айван—балкон.

дөньялыктан аерылган, үзләрендәге "Мин" дөньясына кереп адашкан мескен адәмнәр дип карады. Һәм ул аларның мескенлекләрен белгәнгә генә бәйрәмгә чакыртты. Хак, алар төп кунаклар янында булмаслар, бары тик Коръән хафиз гына чакырылыр. Калганнарының күнелен Садрый агай күрер.

Тиздән Гаязетдин белән Бибисара бикә, Сара анакай килеп төшәрләр, бәлкем әле, язган итсә, мөфти Ибраһим сизеп алмаса, Рәшидә абыстае да килеп житәр. Утар ишегалды шау-шу белән тулыр, күңел ачарлар, жырларлар, уйнарлар, көлерләр. Бәйрәм кешене яшәртә, кайгы картайта, диләр. Бәйрәм итеп, бер яшәреп алырлар, иң мөһиме, Айбиби Ибраһимын күрер. Шактый буй алгандыр инде, Шәмгун хан аны фарсылардан кайткач үз кырына алган, сәркатибе итеп тота икән дип ирештерделәр Айбибигә. Менә куанырга да, кайгырырга да белмәде Айбиби. Чөнки анда—сарайда аның яман дошманы мөрид Ибраһим эшли иде. Бу кешенең акылы гына түгел, кулы да озын дип сөйли иде сарай халкы. Әнә шуңардан курка иде Айбиби.

Айбиби өйдән чыкты, бәйрәм ашы хәзерләгән пешекчеләргә, бавырчыларга таба атлады. Тирә-юньне тутырып ит исе чыккан, зур-зур казаннарда ит пешә. Күл кырында ук кара чәчле Харәзем егете шашлык кыздыра. Ни сәбәпледер, Айбиби каракош утырган наратка карап алды. Үз ботагында утыра иде каракош. Ул да ит исен сизә. Тик бит инде аңа ит бирүче юк. Шуңа үч итепме, каракош күлдәге ике үрдәкне алган һәм Садрый агай күз алдында, нарат ботагына алып менеп, ботарлаган. Янәсе, күрегез, мин үз дигәнемне итәм, ашатмасагыз да ач тормыйм.

Айбиби күл кырына таба борылды, аккошлар ашаткан төбәккә житеп, кошларга жим ташлады. Шулвакыт нарат ботагыннан лап итеп каракош төште. Барысы да шул якка карадылар. Айбиби үзе дә сизмәстән шул тарафка таба йөгерде. Кем укка алды каракошны? Шуны беләсе килде. Әйе, кем?! Әллә соң чынлап та Ибраһим мөфти каракошны уктан алырга үз мәргәнен жибәрдеме? Һич булмас димә!

Каракош жирдә ята, әмма исән, бер канаты белән жилпенә, яман итеп ысылдый. Айбиби каракош янына килеп житәрәк туктады һәм шунда каракош аның күзләренә карады, нәкъ менә кеше кебек ялварып карады, хәтта күзләрендә яшь бар кебек иде. Ул арада Айбиби янына Садрый агай килеп житте, жирдә ысыллап яткан каракошның ике канатыннан алды да:

—Ит бирмәгәнгә үрдәкләрне алды ул, каханбикәм, ит бирмәгәнгә үч итеп ботарлады бичараларны.

"Димәк, мина үч итеп",—дип уйлады Айбиби һәм капкадан кереп барган сиртмәле һәм кыңгыраулы атларны күреп, шунда таба китте.

Улы Ибраһим кайта иде! Янәшәсендә чибәр кыз бала. Айбибинең йөрәге жуу итеп китте. Әллә соң өйләнденме, балакаем, дип уйларга өлгерде ул сиртмәле арба туктауга, кыз балага төшәргә ярдәм иткән Ибраһимына карап. Ләкин улы өлгеррәк булып чыкты.

—Менә без дә кайтып життек, әнием. Таныш бул, хан кызы Гөлбикә.

—Саумы, кызым, исән-имин килеп життегезме?—дия алды Айбиби һәм, килеп, улын кочагына алды.—Сагындым үзенне, бик сагындым, балакаем...

Аннары колагына гына: "Әллә соң?.."

—Юк, юк, әнием, Гөлбикә сезне күрергә генә килде, әнием, мин үскән утарны гына.

Айбиби улыннан аерылып, арбадан төшүгә үк туктап калган хан кызына таба бер адым ясады һәм тукталып калды. Кыз бала, хан кызы Гөлбикә үзе кебек үк ак йөзле, зәңгәр күзле, коңгырт чәчле иде.

—Исән-имин килдегезме, балакаем?

—Аллага шөкер, Ибраһимның туган-үскән жирен күрәсем килде дә менә иярдем әле үзенә...

—Бик әйбәт булган, бик әйбәт. Йә улым, алып кер кунагыңны өйгә, ә мин Гаязетдин абаңны каршы алам, әнә кыңгырау тавышлары да ишетелә анда, шулар киләдер,—дип капкага таба кузгалды. Атларны Садрый агай

лапаска таба алып китте. Айбиби борылмада кыңгыраулы атларны күреп, хезмәтчеләренә утар капкаларын киереп ачарга кушты һәм, әйләнеп, хан кызы белән улы Ибраһимга карап алды. Янә йөрәге мелт итеп, сискәнеп китте. Юк, бу курку түгел, шул ук вакытта куанычтан да түгел иде. Моңы гына яхшы белә иде Айбиби. Ана кеше ич, ничекләр борчылмасын, ди, бердәнбере, аның улы үзе белән хан кызы кадәр хан кызын алып кайткан. Димәк, тиккә түгел, анасына күрсәтергә. Янәсе, әнисе белән таныштыра... Һәй, улым-улым, анаң белмиме ул хәлләрне... Ләкин каршы төшә алмыйм, яратуың хак булса, өйләнсәң дә сүз әйтмәм, әмма сайлаганың да яратамы сине!.. Яратырмы!..

Табында утырганда Ибраһим улы хан кызына әле җиләк-җимеш тәкъдим итә, әле кош ите. Кыскасы, улы хан кызына гашыйк, дигән фикергә килде Айбиби. Бибисара килене балаларын ашата, Гаязетдин тархан аның кырында. Бер-берсенә карашып алалар да елмаешалар. Яраталар бер-берсен, ләкин бит, ни сәбәпледер, Гаязетдин тарханга Айбиби дә битараф түгел һәм үзе дә белми ни өчен. Юк, белә, бик яхшы белә, ул аны Йосыфы итеп кабул итте. Әгәр дә мәгәр исеме-аты Гаязетдин булмаса, ул аны, бәхәссез, Йосыфы итеп кабул иткән булыр иде. Бу бәйрәмне оештыруы да аны күру өчен генә булды түгелме?! Юк, юк, аны күрү өчен генә түгел, аларның барысын да күрү өчен оештырды ул бу бәйрәмне...

Хезмәтче хатыннар табынга ризык-ниг ъмәтләрне ташып тора, ә монда көлешә-сөйләшә ашап-эчәләр. Бер Айбиби генә гасабиланып утыра. Нигәдер аның җаны тыныч түгел, кем өчендер курка, күнеле нидер сизенә. Әллә соң Ибраһимы чынлап та хан кызына гашыйкмы, өйләнергә ниятлиме, тик әнисенә әйтергә генә кыймый торамы? Шулай, шулай, әйтергә кыймый тора, сукыр түгел әниең, барысын да күрә, йөрәге тоя, балакай, йөрәге. Хәер, иншалла, хан кызы игелекле баладыр, барысы да әйбәт булыр. Тик Айбиби өчен бу хәл кысыр кайгы гына лабаса. Улың бәлигъ булды, хан сараенда хезмәттә, хан кызына гашыйк, анасының утарын күрсәтергә булачак кәләшен алып кайткан. Бу начар гамәлме? Бик яхшы гамәл ич. Кәләшен әнисенә күрсәтергә алып кайткан. Хәзер миңа табынга дәрвишләр арасындагы Коръән хафизны дәштерергә кирәк һәм әрвахларга Коръән чыгарга булыр. Әнә теге нарат астына күчәрбез дә шунда укытырбыз. Анннары ирләр вә егетләр уктан алышырлар, ә без хатын-кызлар серләшеп алырбыз. Шунда булачак килене белән дә якыннанрак танышыр, Сара анакае Рәшидә абыстае белән дә шул хакта киңәшер.

Төнәтмәләр эчкәч, Айбиби аларны бөркет агачы исемен алган нарат янына алып китте. Ул арада Садрый агай уктан алучыларга ботак саен диярге була бөркет карачкылары куйган инде. Йөз адымнан бөркетне алган ир-егеткә Айбиби ат бүләк итәргә вәгъдә иткән иде. Садрый агай шул хакта житкергәч, барча ир-ат, егет-җилбәзәк урра кычкырдылар. Егет-җилбәзәк дигәне Ибраһим улы берүзе иде. Ләкин әүвәл нарат тирәли утырдылар да тоташ карадан киенгән Коръән хафиз Коръән чыгарга кереште.

Моңлы тавышлы иде Коръән хафиз, һәр авазы йөрәккә үтеп керә, ин сәере, кемнендер тавышын хәтерләтә. Ләкин Айбиби моңа игътибар итмәде. Нинди дер суфый, гәрчә Коръән хафиз булса да, бәхәссез, ят бәндә иде. Дәрвишләр белән ул кызыксынмады, бары тик ул бичараларны кызганды гына. Суфыйчылыкны фәкыйрьлеккә саный иде Рәшидә абыстае һәм ул шулай иде дә. Дөньяви гамәлләрдән баш тарткан, ниндидер сихри көчләргә өмет итеп, Рухы белән Аллаһка тартылган, хәтта Аллаһ кырына ашарга әзер булган затлар дип кабул итә иде.

Утырышкач ук дәрвишнең моңлы тавышы һәммәсен дә әсир итте, алар хафизны бирелеп тыңладылар. Айбиби бигрәк тә. Хак Тәгаләгә өнди иде изге китаптагы сүзләр, адашкан кешене туры юлга төшерергә, шәфкатьле булырга, адәм баласын игелеккә чакыра, гадел булырга куша. Йа Хода, бар кеше дә бу сүзләргә колак салса, дөньяда көн күргән кешеләр нинди шәфкатьле булырлар иде дә бит, изге китап сүзләренә колак салучылар

азаеп бара. Һәрхәлдә шулайрак тоела иде Айбибигә.

Коръән хафиз укып бетерде, кулларын күтәреп дога кылдылар. Шуннан соң гына барчасы да торып бастылар һәм Садрый агай һәммә ир-затына да ук-җәя бирде. Йөз адым бөркет наратыннан авыштылар да уктан ала башладылар.

Айбиби бер читтә җыелып, сөйләшеп торган хатыннар янына китте. Ир-затлар мәш килә. Янәсе, ботакларда чын бөркет утыра. Ук тиюгә, бөркет егылып төшәчәк. Һәр кешегә ун ук бирелә. Уклар төрле-төрле буяуда. Кемнең уклары бөркетләрне күбрәк төшерә—алмачуар ат шуна, дип игълан итте Садрый агай.

Бер читтәрәк торса да укчылар арасында Коръән хафиз да урала иде. Һәм нигәдер Ибраһим улы янында урала. Янә Айбибинең йөрәге ешрак тибәргә тотынды. Кем бу суфый зат? Нигә аның улы янында йөри. Аңа уклар биреп тора, хәтта нидер өйрәтә кебек.

Уклар атылып бетәр алдыннан нарат янында карадан киенгән кеше пәйда булды. Садрый агай кулын күтәрде.

—Туктагыз!

Шул мәлдә ук укчылар тарафына сызгырулы ук очты. Һәм нәкъ Айбибинең улы Ибраһимга таба. Ул да түгел, улы кырындагы суфый күкрәге белән Ибраһимны каплады. Ук дәрвишнең күкрәгенә кадалды һәм ул берьякка авып төште, улы Ибраһим аны тотып калмакчы итте, әмма өлгерә алмады. Ул арада нарат төбендәге яман затка бу тарафтан уклар очты. Кемнендер угы тиде булса кирәк, кара киемдәге кеше уң кулы белән күкрәгенә кадалган укка ябышты һәм чалкан төште.

Барчасының да күз алдында булган хәл иң әүвәл Айбибигә килеп җитте, ул чырайлап кычкырып җибәрде.

—Улым, Ибраһим!..

Дәрвишне укка алган карачкы киемендәге кешегә игътибар итмичә, бер читтә торган хатын-кыз ирләргә таба кузгалдылар, Айбиби исә, хәле китеп, баскан җирендә катып калды. Берара киткәч кенә Рәшидә абыстай ана таба борылып карады һәм кире килеп:

—Ни булды, балакай?—дия-дия аның терсәгеннән алды.

—Кем, кем укка алды минем улымны?!.

—Улың Ибраһим исән, исән, балакай. Әнә кәләше янына да барып җитте инде. Дәрвишне укка алдылар, дәрвишне. Ул җирдә ята...

Айбиби улы Ибраһимга килеп сарылгач кына, әле булса җирдә яткан һәм күкрәгенә ук кадалган дәрвишкә игътибар итте.

—Ул коткарды мине, әнием, дәрвиш коткарды.

—Дәрвиш?!

—Садрый агай, дәрвишне чирәмгә илтеп салыгыз...

Шул сүзләрне әйтергә дә өлгермәде, кан исенә Айбибинең башы әйләнеп китте һәм ул әкрен генә җиргә таба иңә башлады. Улы Ибраһим аны кулына күтәреп алды һәм читкәрәк чирәмгә илтеп салды, янакларына суккалады. Ул арада Рәшидә абыстай килеп җитте, барысын да куалап, Айбибинең колагына пышылдады.

—Улың исән, киленең дә, балакай. Дәрвиш коткарды улыңны, Коръән чыккан дәрвиш.

Ул арада ирләр нарат төбендә канга батып яткан мәргәннең мәетен, дәрвиш белән янәшә китереп салдылар. Күрде дә Ибраһим углан уктан алган адәмнең йөзен, бер адым артка чигенде.

—Ибраһим мөфтинең җансакчысы Сатлык ич бу! Сатлык! Димәк, димәк...—диде дә Ибраһим углан тукталып калды, Гаязетдин тарханның күзләренә карады.

—Димәк,—диде аның сүзен дәвам итеп Гаязетдин тархан,—Сатлыкны бирегә мөфти җибәргән.

—Хак, угылым, мөфти Ибраһим җибәргән,—диде Сара анакай алгарак чыгып.

Сара анакай шулай диюгә, Рәшидә абыстай куырылып куйгандай булды,

агарынып китте һәм нигәдер барчасы да аңа борылып карадылар. Ни кылырга белмәгән Рәшидә абыстай мәетнең чикмән изүләрен чиште, күкрәгендә бакыр тәре күреп, ике кулы белән йөзен каплады да үксеп-үртәлеп елап җибәрде. Ул арада Садрый агай дәрвишнең күкрәк сәдәфләрен ычкындырды, күлмәк бауларын чиште һәм муенына алтын чылбырга таккан көмеш бөтине күреп, тартып алмакчы итте, әмма аңа Сара анакай моны кылырга бирмәде.

—Тимә изге җан бөтиенә!

Сара анакай шулай диюгә, әлегә кадәр исе-акылы китеп, булган хәлгә ышанмыйча, сихри бер дөньяга китеп торган Айбибинең күзе мәет күкрәгендәге бөтигә төште һәм ул янә һуштан язды. Әмма янәшәсендә басып торган улы аны кулына күтәреп алды, мәетләр янынннан читкәрәк алып китте. Аларга бер тотам калмыйча, хан кызы иярде.

—Ибраһим, Ибраһим дим, атама чапкының җибәр, мөфти Ибраһимны каладан беркая да җибәрмәсен, аның эше бу,—диде.

Ибраһим углан барган җиреннән тукталды, борылып, артыннан ияргән хан кызына карады.

—Ә син кайдан беләсең, Айгөлем?

—Бирегә киткәндә атам миңа сине сакларга кушты.

Ул арада Айбиби аңына килде, күрәсең, булачак килененең сүзләрен ишеткәндер, аягына басты һәм хан кызына:

—Балам, бар әле дәрвиш муенындагы бөтине китер миңа,—диде.

Нигәдер чарасыз калды, кайчандыр Йосыфҗаны үз куллары белән аның түшенә таккан бөтине капшап карады. Ул аны бик сирәк ачты, ачкан саен хатирәләргә чума иде.

Ибраһим алып килгәч, тырнак очы белән бөтине ачты да әнисенә сузды.

—Ул дәрвиш синең атаң, әтиең Йосыф кахан!—диде Айбиби һәм ике кулы белән йөзен каплап, елап җибәрде.—Нинди, нинди язмышлар китерде аны монда?.. Мине эзләп килденме, безнеме?.. Йосыфҗаным!..

Ул арада дәрвиш мәете янына ишләре килделәр, берсе алгарак чыкты да:

—Каханны безгә бирәсез, без аны үзебез җирлибез. Кадерләп, Дәрвишләр саласы зыяратына.

Гаязетдин белән Ибраһим углан күзгә-күз карашып алдылар.

—Кем генә булмасын, бу мәетне без җирләрбез, дәрвишләр. Һәм сез әйткәнчә, кадерләп, олуг затлар зыяратына—Казан җирендә. Ә сез менә бу сукбайны җирләгез, дәрвишегезне уктан алган сатлык җанны.

—Адәм канын койган кешене без җирләүдән баш тартабыз. Гаязетдин тархан. Хушыгыз...

Дәрвишләр су буена төшкән казлар кебек, тезелешеп, күл буендагы көймәләренә таба киттеләр. Гаязетдин тархан Ибраһим угланга һәм Айбиби җиңгәчәсенә карап алды. Җиңгәчәсе хәтта аңа күтәрелеп тә карамады. Аның бер ягыннан хан кызы култыклаган, икенче ягыннан Сара анакай. Рәшидә абыстай исә, булган хәлгә исе-акылы китеп, басып тора. Бит ул Сатлык мәргәнне күрү белән үк таныган иде. Сатлык һәрдаим Ибраһим янында йөргәнгәме, аптырабрак калган, гасабиланган иде.

Әмма Гаязетдин тархан дөнья күргән ир-егет булды, ул хезмәтчесен чакырып алды да, мәетне тиз арада Казанга алып китәргә, сарай имамына мәрхүмне җиренә җиткереп җирләргә дип әмер бирде.

Ә үзе Айбиби җиңгәчәсе янына килде дә иненә кулын салып:

—Җиңгәчәй, әйт, ни кылыйм бу кан койган адәмнең мәете белән,—дип Сатлык яткан якка карады.

—Каракош утырган нарат төбенә күмдер ул бичараны, Гаязетдин,—диде бераз тынычлана төшкән Айбиби. Аннары Сара анакайның күкрәгенә капланды да:—Нишлим, инде мин нишлим, анакаем!—дип үксеп-үртәлеп еларга тотынды. Аны кем дә юатмады, бары тик булачак килене генә кырына килеп, йомшак кына, сак кына аркасыннан сыйпады.

—Ул бит, киленкәем, бирегә сине эзләп килгән булган, сине эзләп килгән

булган,—диде дә Сара анакай үзе дә еларга тотынды.

—Кайчан тукталыр бу дөньяда кан коюлар, кайчан тукталыр,—дия-дия тәкърарлады ачы күз яше аша Айбиби.

***

Айбиби Йосыф каханның җидесенә генә Казанга килде. Капкадан ук аны каршы алган Гаязетдин тархан җиңгәчәсенә арбадан төшәргә ярдәм итте һәм култыклап алды да кирмән-кала эчендәге олуг затлар зыйратына таба алып китте.

—Җиңгәчәй, без аны җиренә житкереп җирләдек. Сакалын кыргач, Сара анам шундук таныды: "Йосыф улым!"—дип, күкрәгенә капланып елады. Кичерә күрегез, сезне чакырырга теләмәдек. Яра өстенә яра өсталмәсен дип. Бибисара әйтте, җиңгәчәй сарайда калыр, безнең гаиләдә булыр, диде.

Шулай диде дә Гаязетдин тархан Айбибинең уң кулын учына алды һәм уч төбен үпте.

—Мин куркам, куркам, Гаязетдин. Кеше ни уйлар?

—Мин сиңа өйләнергә булдым, җиңгәчәй, улың Ибраһим да ризалык бирде, хатыным-бикәм Бибисара да, анакай да... Йосыф абамның елын уздырганнан соң никах укытырбыз...

Айбиби һич тә моны көтмәгән иде, Гаязетдин тарханның күкрәгенә капланды да тынып калды.

—Ул кичерерме соң мине, Гаязетдин, кичерерме?!

—Кичерер, җиңгәчәй, кичерер, кайчандыр мин аны кичергән өчен кичерер. Ә бит мөфти Ибраһим Хазарстан тәхетенә мине утыртырга теләгән иде. Теге вакытта, без Таман тархан җирендә яшәгәндә. Ул абамны инде шул вакытта ук ефәк бау белән...

—Кан коймый гына, әйеме, Гаязетдин?

—Әйе, кан коймый гына, җиңгәчәй.

—Ә бит мөфти Ибраһим кан койды, биредә, Казан төбәгендә, син салдырган минем утарымда. Күпме кан коела җирдә. Барысын да җыйсаң, диңгез булыр иде. Ә кешеләргә, явызларга һаман да аз, һаман кан коюю турында уйлыйлар. Мин риза, Гаязетдин, синең хатының булырга, риза. Синең баллы сүзләреннән соң мәхәббәтемә янадан җан иңгәндәй булды, Гаязетдин бәгырь. Әйтсәм әйтим инде, мин сине беренче күргәч тә Йосыфым дип кабул иткән идем.

Айбиби кисәк тынып калды, аңардан җавап көтте бугай, әмма Гаязетдин бер сүз дә әйтмәде. Шуннан соң Айбиби аның ике кулы белән битеннән алды да кара шомырт күзләренә карады һәм, чарасыз калып, Гаязетдиннең күкрәгенә капланды. Ул аңарда Йосыфының тән исен тойды һәм эчке бер хискә бирелеп, булачак ир-канатының күкрәгенә башын куйган килеш бермәлгә тынып калды. Ул исән икән ич әле, аны яраталар, ул янә үз кешесен тапты—мәхәббәтен. Йосыфның туганые Гаязетдин йөзендә тапты.

—Минем синең гүзәл Бибисараңны, аның кызларын күрәсем килә, аларның аркаларыннан кага-кага сөясем килә, Гаязетдин. Мин сиңа яхшы хатын булырмын. Мин беркайчан да, беркемне дә рәнҗетмәм. Мин сиңа атам-анам белән ант итәм. Мин кырык хатыны булган ир белән торып караган кеше. Яраткан кешенең кадерен белергә дөнья мине үзе өйрәтте. Мин биекләрдән биекләргә күтәрелгән хатын идем, бүген әнә нинди көнгә калдым. Ярый әле язмыш миңа сине җибәрде, мин аңа шуның өчен кат-кат дога кылармын, намазга утырып, рәхмәт яудырырмын.

***

Никах укыткач, берара торганнан соң, Айбиби барысын да утарга дәште. Гаязетдин дә, Бибисара да, Сара анакай да каршы килмәделәр. Каладан утарга таба кузгалган көнне күк йөзе чалт аяз, мөлдерәп кояш чыккан, шәһәр уянган иде инде. Ашыкмый гына бардылар. Иң алдагы арбага Гаязетдин белән Айбиби утырды, икенче арбага Сара анакай белән Бибисара. Балаларны алмадылар, сабакка барасылары бар икән.

Юл шактый булса да бер дә ялыктырмады, барыр җайда дөнья хәлләре турында сөйләшеп бардылар.

Аларны капкадан ук Садрый агай каршы алды. Ә утардагы хезмәтчеләргә кунакларга табын хәстәрләргә, мунча ягарга кушты. Садрый агайның чын хуҗаларча утарда эш итүенә Айбиби шат иде.

Капкадан узуга, Айбиби арбадан сикереп төште һәм Аккошлар күленә таба ашыкты. Гаязетдин Сара анакай белән Бибисараны күтеп алды. Алар да әкрен генә күлгә таба кузгалдылар.

—Җан кергән, Гаязетдин туган, каханбикәгә, җан кергән.

—Үлгән артыннан үлеп булмый, Садрый агай, дөньялыктагын дөньялыкта алып калу зарур. Ходай кемгә дә ике гомер бирмәгән.

—Айбиби, Айбиби, туктале, безне көт,—дип, куып житте Гаязетдин, әмма ул аңа әйләнеп тә карамады. Күл буена, аккошларны ашаткан җиргә ашыкты. Күл буена житеп, аккошларга жим ташлагач кына Айбиби артыннан килүчеләргә әйләнеп карады. Карады да кинәт күктән җиргә төште. Аның артыннан шактый кала төшеп, кулга-кул тотынышып, Гаязетдин белән Бибисара киләләр һәм кет-кет кемнәндер көләләр иде. Садрый агай алардан калыша төшеп килә. Күрде дә бу хәлне Айбиби ни өчендер йөрәге жуу итеп китте. Әмма икенче мәлдә инде эчке бер елмаю белән Бибисарага таба кузгалды. Килде, хатынның кулыннан алды һәм аккошларга жим ташларга кушты.

—Күрәсең, Бибисара, күрәсең нинди матурлар алар, горурлар, тәкәбберләр.

Садрый агай бер читтәрәк калып, кунакларның аккошларны ашатуларын карап-карап торды да Айбибигә:

—Каханбикә, каханбикә дим, теге каракош исән бит әле, урманда яши, ашарга безгә килә-китә йөри.

—Каракош! Теге вакытта Сатлык укка алган каракошмы?!

—Әйе, каханбикә, шул каракош.

—Минем аны күрәсем килә, Садрый агай. Ничек кышларны чыкты, ничек ачка үлмәде?

—Бездә кыш чыкты, аерым абзарда. Ләкин җәй килдеме урманга биләмгә чыгып китә, кайчак атналар буена кайтмый.

—Әле дә утардамы?

—Юк, атна була инде күзгә күренми.

—Сатлыкның мәетен ишләре алып китмәделәрме, Садрый агай?

—Шунда ята, нарат төбендә. Без аның каберенә тәре ясап кададык. Ул да Хода бәндәсе иде бит, каханбикә.

Айбиби дәшмәде. Көлешә-көлешә нидер сөйләшкән Гаязетдин белән Бибисарага борылып карады. Һәм эчке бер кимсенү белән: "Ул аны ныграк ярата" дип, көрсенеп куйды.

Кичке ашны ашап-эчкәч, кояш шактый югары булганга, урманга чыгарга булдылар. Гаязетдин белән Бибисара бергә йөрделәр, чәчәкләр җыйдылар. Көлештеләр, үзара нидер сөйләшәләр. Айбиби сиздерми генә алардан аерылды да таныш сукмактан күлгә таба китте. Барган җайдан бөдрә чәчле каеннарның чәчләреннән сыйпады, очраган бер наратны кочаклап, урман шавын тыңлады. Биредә аңа һәр нарат таныш иде. Улы Ибраһим үсмер чакта шушы урманга чыгарлар иде дә бу нарат минеке, әнә теге нарат минеке, дия-дия куыша башларлар иде. Ниһаять, киң ябалдашларын күлгә кадәр сузарга теләп каракош утырган мәһабәт наратка житте. Һәм килер җайдан, күптән күрмәгән танышын очраткандай, кочаклап алды да: "Бир миңа куәт, бир миңа көч!"—дип, кат-кат кабатлады. Шунда аның күзе Сатлык каберенә төште. Күр инде, кая ята Йосыфның канын койган яман адәм. Кисәк аның хәтеренә Бохарадан килгән мөгаллимнең сүзләре исенә төште: "Хода һәммә халык өчен дә бердер, ә Ана ышану төрле халыкта төрлечәдер..." Шул чакта ук аның мөгаллименә: "Нигә соң һәр халыкның үз кыйбласы?"—дип әйтәсе килгән иде. Кыймады, әйтмәде. Ә бүген әйтер иде, тик ул еллар күптән үткән шул инде.

Жир-туфрактан терсәк биеклек кенә калкып чыккан, каеннан ясап тәре кадалган кабергә Айбиби бик озак карап торды. Ахыр күзләре каберне күрмәс булды, ә күнел күзе күп еллар элек бирелә булган фаҗигагә юнәлде. Өлкән равва Ибраһимга ялланып, ул кая барса ана ияреп йөреп, әҗәлен Казан туфрагында тапкан, каракош яратып утырган нарат төбенә күмелгән Сатлыкның язмышы һәр адәм баласы өчен дә гыйбрәтле хәл иде. Аллаһ колы булсан да кеше колы булма икән.

Кичке чәй табынынннан кузгалгач та, Айбиби сиздерми генә Ибраһимын карап үстергән бүлмәгә таба кузгалды. Аны югалттылар бугай, бераздан кемдер ишекне шакыды. Айбиби ана:

—Мин яттым инде, бик арыдым,—дип, табын янына яналан чыкмады.

Әйе, чыкмады, ятты, әмма күзенә йокы кермәде. Зиһен тукымасын якты истәлекләр, тәүге хатирәләр күмеп китте. Атасы Мөхәммәд хан, Рәшидә абыстай, Ислам, Йосыф кахан, Сара анакай аның гомер юлында адаштырмый йөрткән изге затлар, ниһаять, Гаязетдин һәм Бибисара. Йа Хода, тагынниләр күрәсе бар икән аның?!. Гаязетдин Йосыф каханның улы һәм инде аның ире. Хәер, төрки халыкларда ирләре сугыш кырларында ятып калган хатыннарны үз канат асларына алган ир-атлар да булган. Ләкин ул бичара хатын-кызлар яраттылар микән йола ябыштырган ир-затны. Ә менә Айбиби Гаязетдинне ярата, гүя җингәчәй дип йөрсә дә никахлаштылар. Иллә һич кенә дә үкенү юк, тик кайчак йөрәк кенә чәнчеп куйгалый. Иншалла, ул да үтәр... Шулвакыт кемдер капка кага кебек. Җәйге төн кыска, тан да атып киләдер инде, кем йөри икән шулай иртәләп? Торды, тәрәзә янына килде. Тан нурлары яна гына күккә сузылган. Кем йөрер шулай иртә тан белән? Нигәдер Садрый агай да күренми. Кунакларны сыйлады бит, ул да арыгандыр. Айбиби иненә халатын салды, итеген киде. Ә кемдер һаман капканы тук та тук, шакый да шакый.

Айбиби өйдән чыкты, сак кына капкага якынлашты.

—Кем бар анда?

Дәшмәделәр. Айбиби шикләнә калды. Шулвакыт ул капкага таба килүче Садрый агайны күрде.

—Кем бар анда, каханбикә? Ачыгыз.

Айбиби кече капканы ачты, капкадан сөйрәлеп кереп килүче каракошны күрде дә:

—Абау, Садрый агай, ни бу?!

—Сатлык укка алган каракош бу, каханбикә. Теге вакытта урманга җибәрегез дип әйткән идегез бит, җибәрдем мин аны урманга, тик әйләнде дә кайтты, әйләнде дә кайтты. Бер канатын сәлендереп, төлке-бүреләр белән сугышып йөри шунда.

—Ашатасыздамы үзен?

—Җан иясе бит, каханбикә, ашатабыз инде. Бүген тагын бүре белән сугышкан, ахры, тәмам канга баткан, бичара.

Ләкин каракош ишегалдына сөйрәлеп керүгә, берничә тапкыр талпынды да тынып калды.

—Садрый агай, ни булды аңа?

—Җан тәслим кылуыдыр, каханбикә. Бу бичара да котылды,—диде дә Садрый агай, каракошны канатыннан сөйрәп, каядыр алып китмәкче итте.

—Нишләтергә исәбен аны, Садрый агай?

—Урманга чыгарып ташлыйм, бүреләр ашамаса, ишләре ашар.

Айбибинен келт итеп Хазарстанда булган хәл күз алдына килде. Каракошларны укка алучы мәргән бер явызны укка алгач, ишләре җиргә төшеп ботарлый башлаганнар иде бичараны. Айбиби шул хәлгә исе китеп карап торган иде. Өзгәлиләр, тарткалыйлар, ә теге үлеп тә җитмәгән, чиелдый, кемнедер ярдәмгә чакыра кебек. Әмма ишләре һичнигә карамый тегене бик тиз юк иттеләр, каурыйлары гына калды мескеннен. Шул хәлне күз алдыннан кичергәннән сон Айбиби каракошны сөйрәп алып китеп барган Садрый агага:

—Урманга ташлама син аны, Садрый агай. Үзе утырган нарат төбенә

илтеп күм, Сатлык яткан җиргә. Явызлыкның чиге юк, ишләре килеп ашаулары бар. Ә минем аны нигәдер ишләреннән ашатасым килми.

—Борын заманда кайбер халыклар үз адәмнәрен ашаганнар, каханбикә. Әйдә ашасыннар, каракошлар өчен гадәти хәл бу.

—Юк инде, Садрый агай, син аны үзе яраткан нарат төбенә күм.

—Димәк, Сатлык белән янәшә,—диде Садрый агай һәм китеп барды, ә озын канатлы каракоштан җирдә кан тамчылары калды.

—Хак әйттегез, каханбикә,—дип туктады Садрый агай.—Ятсыннар бергә. Сатлык җан белән дим. Туган туфрактан аерылган—Ил-Ватаннан аерылган, диләр бит.

—Хак әйттең, Садрый агай, бәхетне адәм баласы туган туфрагында гына тапса таба икән.

—Шулай шул туган якка җан тартмаса да кан тарта.

Шул вакыт Айбиби болдырга чыгып баскан, иңенә яшел атлас халат салган Гаязетдинне абайлады. Ул Айбибинең өйгә таба килүен күрде дә йөгереп төшеп, хатынны кулына күтәреп алды һәм барыр җайда колагына:

—Әллә нигә өшеп киттем, бүлмәнә алып кереп җылытчы, җиңгәчәй,—дип, кайнар сулышы белән Айбибинең муенын көйдереп алгандай итте. Бит аны кайчандыр кырык хатыны каршында Йосыфы да шулай кулына күтәреп чатырына алып кереп киткән иде. Ул чакта Айбиби шушындый хәлдән курка калган иде, үзенә карап калган хатыннардан оялган иде. Хәзер исә үзе үк Гаязетдиннең муенына сарылды һәм ятканда әйтә торган сихри сүзләрен тезде.

—Син мине яратасың, яратасың бит, Гаязетдинем, яратасың бит...

—Яратам, яратам, җиңгәчәй, яратам, мин сезнең икегезне дә яратам...

Айбиби сабыры төкәнеп, эченнән кабатлады: "Мине яраталар, яраталар! Явызлар, каракошлар бу дөньяга килә дә китә, мин калам, мин сиңа малай табармын, Гаязетдин, халкымның дәвамын бүләк итәрмен, чөнки без хатын-кызлар нәсел җебен дәвам итүчеләр, нәсел җебен, җаным-бәгърем, Гаязетдинем...

***

Кече капканы ачып урам ягына аяк басарга да өлгермәде, аның каршында өч мосафир пәйда булды. Алар бердәй Сара анакай аягына төштеләр.

—Коткар безне, анакай... Без адаштык. Безне язмыш адаштырды. Илҗиребез су басты, Хазар диңгезе ташты, җир-калаларыбыз су астында калды.

—Әллә Туфан калыктымы?

—Туфан калыкты, анакай, туфан. Хазарстан халкы кайсы-кая сибелде, таралды. Биләмҗир калабызны җир йотты, Аккала су астында калды. Мәхшәрдән котыла алганнары...

—Торыгыз, мосафирлар, яхшылап аңлатыгыз. Сәнең йөзең таныш та кебек,—дип Сара анакай кәттәрәк киенгән Шарунга туры карады. Ул күз ташлаган мосафир башына ак чәпләшкә каплаган, керләнеп, каралып беткән чәпләшкәсе баш түбәсен генә каплап тора.

—Шарун равва мин, каханбикә Сара, Шарун равва. Йосыф кахан сараенда өлкән равва Ибраһим кул астында балалар укыттым.

—Димәк, син Ибраһим равва кешесе.

—Юк-юк, мин чарасыздан аның кул астында гомерем сарыф иттем, анакай.

—Сезгә өлкән равва Ибраһим кирәкме, аны эзлисезме?

—Юк, анакай, без синең алга килдек. Коткарыгыз, безне сез генә коткара аласыз. Ибраһим равва Шәмгун хан сараена мөфти булып урнашкан. Безне ул барыбер кабул итмәс иде. Без Болгарга тукталып та тормадык.

—Адашкан Исраил балаларын, шулаймы, равва Шарун?—дип ирен чите белән генә елмаеп куйды Сара анакай.—Мин сине бераз хәтерлим, равва Шарун, хәтерлим, син коткардың бит мине өлкән равва кулыннан, син... Хәтерләми буламы... Йосыф кахан кая, кай тарафларга юлыкты, балакай?

—Йосыф кахан викинглар килүгә үк гаеп булды, анакай. Эзләделәр аны, тапмадылар.

—Викингларны илгә кем дәште?

—Хак булса, өлкән равва Ибраһим, анакай.

—Йосыф кахан түгелмени?

—Юк. Ул аларны калага кертмәскә тырышты, каршы торды. Өлкән равва Ибраһим викинглар ярдәме белән кала-салалардагы мөселманнар белән христианнардан котыласы иткән иде. Атна буена койган янгыр барысын да астын-өскә китерде. Без дә болгар юлаучыларына ияреп котылдык.

—Алай да, ничек кахан кадәр кахан кинәт гаеп булды соң?

—Викинглар китүгә, ул да юкка чыкты, анакай. Пиратларның китүләре булды, коеп янгыр ява башлады. Тәмам болыты белән төште, елгалар ташты, Ханбалыкның сәмән өйләрен су юды. Әйтәм бит, тәмам Туфан калыкты.

—Сез нигә минем каршыма килдегез? Каханмы әллә мин сезгә?.. Нигә Ибраһим кырында калмадыгыз?..

—Ибраһим равва минем сөймәгән кешем иде, анакай. Ул каханатка Гаязетдин угланны кайтарырга тиеш иде, ә Йосыф угланны баш бирмәгәне өчен...

—Ефәк бау беләнме?

—Әйе, анакай. Мин ана каршы төштем һәм ул мине күралмас булды. Коткарыгыз безне, анакай. Сез олуг кахан Убәдәйнең бердәнбер сөйгән хатыны идегез.

"Айбиби хатын кебекме?"—дип уйлап өлгерде Сара анакай, ләкин әйтмәде, тыелып калды. Үз алдында баш иеп, нидер өмет итеп көтеп торган мосафирлардан күзен алып, күктәге ак сарыклар кебек тезелеп аккан болытларга күз ташлап алды. Шул ук мәлдә аның күз алдына Убәдәй каханның ничек якты дөньяны ташлап киту мизгеле хәтер күген ачып җибәрде. Ана аны күрсәтмәделәр, ләкин ул бераз чамалый иде—раввалар аны ефәк бау белән буып үтергәннәр. Сәбәбе билгеле, нәкъ Йосыф кахан кебек Убәдәй дә үз кырына бары тик бер хатынны—Сараны гына тарттыра башлады. Бу инде каханатның канунын күрәлтә бозу иде. Һәм раввалар яшерен рәвештә табын җыялар да Убәдәй каханнан котылу чарасын күрәләр. Өлкән равва Йосыф урынына Ил тәхетенә Гаязетдин угланны кайтартырга тели, әмма Йосыф кахан аны Казан каласына тархан итеп озаткан була инде. Әле булса хәтерендә, Убәдәй каханны җирләгәч, Сара хатын кырына өлкән равва Ибраһим килеп керде. Сара хатын бала имезеп утыра иде, күкрәген каплап, баланы асрау хатынга бирде һәм торып басып өлкән равваны түргә дәште. Ләкин өлкән равва узмады, ишекъяры калды. Өлкән равваның кулында ефәк бау иде. Бауны күрде дә Сара хатын эсселе-суыклы булып китте, җаны белән түгел, тәне белән тойды бауның кем муенында булып алуын. Өлкән равва кулында Убәдәй каханны буып үтергән ефәк бау. Бау төрле төстәге ефәк җепләр белән ишелгән, оч-очлары төйнәлгән һәм чукланып тора иде. Ни әйтергә теләде икән моның белән Сара хатынга өлкән равва? Куркытасы иттеме?.. Сара хатын белмәде, чөнки ул Убәдәй каханга ике углан бала тапкан яшь, чибәр, иң яраткан хатыны иде. Очрашкан саен өлкән равва күзен ала алмый йотлыгып Сарага карап торыр иде.

Өлкән равва Ибраһим бер урында таптанып алды, ефәк бауны кесәсенә салды һәм турыдан-туры:

—Мин сине, Сара хатын, угланнарың белән үземә алып калырга булдым, Убәдәй кахан да каршы булмады,—диде.

"Буып үтергәндә ни вәгъдә итмәс кеше дәҗҗалына",—дип уйлады Сара хатын ни әйтергә, ни кылырга белми, чарасыз калып.

—Мина уйларга ике-өч көн вакыт бир, өлкән равва.

—Яхшы, ике-өч көн вакыт бирәм,—диде өлкән равва, ары таба бер сүз дә әйтми, борылып чыгып китте.

Дәҗҗалның чыгып китүе булды, Сараның гүя ташуы ташты, ятагына капланды да үксеп-үртәлеп еларга тотынды. Анасының елавын ишетеп,

асрау кулындагы бала еларга кереште. Сара баланы кулына алды да, якякка чайкала-чайкала раввага каһәр укыды. Менә шунда анын кырына равва Шарун килеп кергән иде. Керде дә, бусага төбендә үк:

—Мин сезне коткарам, Сара хатын. Киенегез, җыеныгыз, мин сезне Таман тарханы Галигә биреп җибәрәм,—диде.

Сара хатын һични аңламый бермәлгә мөлдерәмә тулы яшьле күзләре белән аңа карап торды.

—Өлкән равва Ибраһим җибәрдеме?—дип сорады.

—Мин өлкән равва көчеге түгел, булмадым да, Сара хатын. Мин сезне аның кулыннан коткарырга килдем. Гали тархан сезне алып китәргә риза булды. Ул сезне Ханбалыкта көтеп тора, Сара хатын.

Сара кинәт барысына да ышанды һәм кабалана-кабалана җыена башлады. Равва Шарун алдамады һәм эңгер-меңгер вакытта, асравын һәм бала белән Сараны Ханбалыкта көтеп торган тархан Гали кулына китереп тапшырган иде.

Зиһене ачылып китеп, күктән күзләрен алуга, Сара анакай каршында кайчандыр коткаручы басып торуына инанды һәм кече капканы ачып:

—Җәләлетдин, менә бу мосафирларны кече кунак өенә урнаштыр. Мунча керт. Ашат-эчер. Алар иртәгә юлга чыгалар, үзләренә айлык ризык-нигъмәт әзерлә... Юл акчасын үзем җайлармын,—диде.

—Хуш, анакай, хуш,—дия-дия кече капкада башына яшел түбәтәй кигән, кара сакаллы берәү пәйда булды, ул мосафирларга сәлам юллады һәм өчесе белән дә кушкуллап күреште дә, юлчыларны ияртеп, ишегалдына алып кереп китте.

Сара анакай янә күктәге ак болытларга күз төшереп алды һәм үзалдына:

—Мин дә, ахыры, иртәгә Казанга таба кузгалырмын. Әллә нигә киленнәрем, оныкларым күрәсем килә, ичмасам эчем бушаганчы сайрашырбыз,—дип сөйләнә-сөйләнә эчкәре узды һәм капканы япты.

*1999—2003 еллар.*
*Казан—Таман ярымутравы—Әстерхан.*

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кулъязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез.
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)



## Фирүзә Җамалетдинова

### Җәйге чиллә

**Шырпысыз да дөрләп китәр иде,
Утлар кабар иде көнемә.
Сукмагыма үлән башын салды,
Күчмәк булып җиһан көленә.**

**Тамчы суга мохтаҗ каеннарның
Яшел кое төште яфрагы.
Табигатькә барыбыз да тигез —
Якыны юк, һәм дә ерагы.**

**Дөрләп китәр дөнья, дөрләп китәр,
Кызганмаса кояш күкләрдә.
Ул да җаннан ерагаеп куя,
Чама белми нурын түккәндә.**

**...Иркенәеп сулыш алды җиһан,
Ярсып-ярсып яшен ут бәрде.
—Табигатькә барыбыз да тигез! —
Кипкән үлән башын күтәрде.**

**—Табигатькә барыбыз да тигез! —
Пышылдады каен тирәмдә.
Янмаска да мөмкин, көймәскә дә,
Тамырларың булса тирәндә...**

**Тамчы төшкән саен чыжлады җир,
Җилләп-җилләп яуды көн буе.
Тамырларга тигән дым хакында
Түгел иде бүген кем уе?**

---

Фирүзә ЖАМАЛЕТДИНОВА — *шагыйрә; "Яшен күзләре", "Утлы җил", "Толымлы ай" исемле китаплар авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Чаллыда яши.*

Тәмугың да, дөнья, үзеңдәдер,
Оҗмахың да синең үзеңдә.
Тамчың булыйм, милләт агачым тик
Яфрак койсын өчен көзеңдә.

Тамчы булыйм, яфрак ярсын өчен,
Куәтләнеп яшел язларда.
Сусамасын дымга, ныгысын ул,
Бөре саен бер җыр язганда.

Эх, үзебез булып яшибезме?
"Әйе",—дисәк, бар да үзгәрер.
Табигатькә һәммәбез дә тигез—
Тамырлары аның бездәдер,
Аның җаны чөнки бездәдер...

***

Мин кайларга ашкынамдыр,
Хыялны җигә-җигә.
Үләне дә, агачы да
Бөгелә лә бер җилгә.

Талларны да, әремне дә
Бер үк җил сыгылдыра.
Тормыш кул сузган була да,
Шунда ук егылдыра.

Мин дә тал-имәннәр өчен
Гүя очар кош кына.
Моңнарым да, оча-оча,
Шул җилләргә кушыла.

Шуңа да җил елап түгел,
Җырлап исә шикелле.
Шуңа моңлы кебек лә ул,
Хәтта милли фикерле...

Давылы дулап узса да,
Кояшы көлеп торсын,
Илдән аерым булмасын,
Бер үк җил сыгылдырсын!

Егылганда, сыгылганда
Әйтә алсам: "Ил белән"... -
Мин илле, димәк, җирле мин,
Димәк, нык басып киләм.

## Замана

Тормыш шундый каршылыклы,
Кем мактый, кем зарлана.
Чал әбекәй карап тора:
—Замана,—дип,—замана...

Таягы—таянычыдыр
Тотрыксыз дөньясының.
Шул таякларга таянгач,
Тоя яшәү асылын.

—И замана, замана,—ди,
Исләре китеп тора.
Яныннан сыра күтәргән
Яшьләр гел үтеп тора.

Алар шат. Сүгенгәндә дә
Тәмәке көйрәп тора.
Колакларында "чыбык"лар—
Заманча көйләп тора.

Мин дә туктап, уйлап торам
Кайларга барасымны.
Заман белән без икебез
Бер ана баласымы?

Әллә заман ятиме мин,
Әллә Казан ятиме?
Ә буласы килә ләса
Кайчак әни, әтиле...

—И замана, — ди әбекәй,—
Бозлы юл таядыр күк.
Беркөн килеп замана да
Таякка таяныр күк...

## Хикмәт

Берни дә мәңгелек түгел,
Мәңгелек түгел берни.
Ышанасы килми шуңа,
Жан әрни, әрни, әрни...

Мәңгелек түгел гомер дә,
Дөнья да фани гына.
Айлар, еллар, гасыр үтә,
Көн саный-саный гына.

Мәңгелек түгел карашың,
Бүген — боз, кичә — ялкын...
Хәтта сөю янып бара,
Бер ерак күк, бер якын.

Йолдызлар жиргә коелды
Күкләр учында чакта...
Ә бүген соң?.. Бу дөньяның
Хикмәте кара-акта:

Фанилыкны гомер белән
Ала алуда түләп,
Жирдән күккә атылуда
Нидер табарга теләп.

Күктән жиргә сибелүдә
Нур булып, иңләп-буйлап... —
Төшүләрдә, сүнүләрдә,
Бәхет хакында уйлап...

***

Көннәрдән беркөнне көз сыман
Йөгереп килерсең син миңа.
Күзеңдә моң булыр,
соң булыр,
Яфраклар сибелер тын гына.

Син берсен учыңа куярсың,
Сулулар сулышын тоярсың.
Шул булыр соңгару,
һәм тану
Жанга да көз яфрак коясын.



## Нәҗибә Әминева

### Яшисең...

Әй яшисең,
Тамчы шатлык өчен
Дөньясыннан бизми яшисең.
Гомерең белән бергә
бәхетең дә
Кимегәнен сизми яшисең...

Әй яшисең,
Кайчак кайгылардан
Күз яшьләрен өзми яшисең...
Гомерең белән бергә хәсрәтең дә
Кими бара—
Сизми яшисең...

Ник зур кайгы, ник зур шатлык бары
Гомерең кадәр—
Белми яшисең.
"Бар да фани, барысы да үтә"—
Шул акылга килми, яшисең...

### Алданырга әзер

Биек күктән карлар ява,
Зәңгәр күктән ләйсән ява...
Барысы да күктән дибез,
Серле дибез күкләр, һава.

Кар-яңгырның
Җир тартканга
Җиргә төшмичә юк хәле.
Күктә яралмаган алар,
Җирдән күтәрелгән әле...

Җирнеке бит кар-яңгырлар,
Ник безгә—күктән тоела?
Явалар...
Түшәмнән гүя
Җирдән салган туфрак коела.

...Дөньясының бер сере юк,
Төбенә төшсәң, аңласаң...
Күге зәңгәр, болыты ак—
Алдансаң, бары алдансаң...

---

Нәҗибә ӘМИНЕВА — *шагыйрә; "Иртә", "Сиенеч бар" һ. б. китаплар авторы. Башкортстанның Кушнаренко районы Әхмәт авылында яши.*

Алдый Дөнья...
Алданмасаң,
Килмәс кебек яшисең дә.
Яши бирә—
Алданырга
Әзер тора
Кешесе дә...

***

“Мин бу кырлар, сулар, җилләрдәге
Атомнарның иске туганы...”[1]
Һәр җисемнең, димәк, бар дигән сүз
Туфан исеме белән туганы...

Дөнья өчен
Һәр афәте саен
Мин дә, мин дә көенеп яшим.
“Тузаныннан Туфанына кадәр—
Туганым!”—дип, сөенеп яшим.

Туфан кебек, әйе, өзелеп сөям,
Туганымдай күрәм дөньяны.
Сөюем зур, бары Туфан кадәр
Әйтә генә белмим мин аны.

Телем әйтә алмый,
Күңелемдә,
Күңелемдә әмма бар шигырь.
(Җанындагын, бәлки, барыбыз да
Әйтеп бетерәлми яшидер...)

Тик, Шигърият, кушылырга риза,
Риза хәтта тузаныңа мин...—
Аз булса да охшаш булсам, Дөнья,
Туганыма—Туфаныңа мин!

## Үткәнчә үтсен иде

Яңа гомерләрем булса,
Яшәр идем бүтәнчә.
Үтмәс иде ул гомерем
Минем—
әле үткәнчә.

Кайда туар идем икән?
Беләм: монда, әлбәттә;
Мең гомерем булса, меңен дә
Башлар идем Әхмәттә[2].

Монда үсәрмен—
Бу җирнең
Җилләренә чыдармын.

Башка җирдә туып-үскәч,
Соң мин булып чыгаммы?!

Сөюем дә шул ук булыр—
Ятлар өчен тумыйм ла!..
Ничек башкаларга багыйм,
Мин булып мин булыйм да?!

Уф, кайгы-шатлыкларым да
Булмас инде бүтәнчә...
Гомер йомгагым барыбер
Сүтелер—әле сүткәнчә...

Их, булып яңа гомерем,
Үтсә—әле үткәнчә!..

[1] Хәсән Туфан шигыреннән.
[2] Әхмәт — авыл исеме.



## Камил Кәримов

# КУЕН ҖЫЛЫСЫ

ХИКӘЯ

Бу дөньяда эч серенне сөйләргә тилмереп йөргән чаклар да еш була икән. Бер уйлаганда, күрше-тирәндә дә, эшендә дә дуслар гына инде, сөйлә серенне, рәхәтләнеп тыңласыннар... Сернең серлелегенә карап кына сөйлибез дә бугай: дусларыбызны, таныш-белешләребезне очратсак, эндәшмичә үтеп китмибез, сер сөйлибез, сер алабыз; үз серебезне сакласак, кеше серен чишеп булса да әңгәмәдәшебезне куандырырга, шаккатырырга тырышабыз. Еш һәм бик еш кына адресы ялгыш язылган хат шикелле, үз серебез үзебезгә кире әйләнеп тә кайта...

Ә син менә вокзалга бар. Берәр буш урын тапсаң, кил дә утыр, сабыр гына көтеп тор. Эндәшмичә калмаслар. Курыкмыйча ачыл син боларга, вокзалдагы күршең барысын да күтәрә. Дөрес, сүз башладың исә мондагы һәр кеше тизрәк үз зарын сөйли башлый. Сөйләр өчен сиңа да чират тияр. Ул арада инде соңга калган поездлар да килеп җитә. Һәм, берегез әшрыйкъ, икенчегез мәшрыйкъ якка дигәндәй, китеп тә барасыз. Сөйләгән сүзләрегез хат булып та, таш булып та әйләнеп кайтмас.

Эш урыны юлда Фәйзелнең. Заводны кирәкле җиһазлар, чимал белән тәэмин итү өчен тырыша ул; күрше шәһәрләрдәге заводларга заказлар илтә, тегесен эзли, монысын таба, алыштырасыны алыштыра. Эшенә күрә танышлары да җитәрлек Фәйзелнең—юлга чыккан саен яңалары арта. Әлбәттә, һәр танышка да дус булып калырга диелгән әмер юк, күбесе әнә шул бер күреп сөйләшкән таныш килеш кенә бераз истә торган була да, әкренләп хәтер өеме арасында бөтенләй күмелеп кала. Еллар үткәч кабат очрашсаң да, алар белән инде яңадан танышырга туры килә. Иренми Фәйзел, кирәксә ярты көн вакытын да кызганмас—тик юлга чыккач серле танышлар тел шартлатып тыңларлык маҗаралар гына сөйләсен аңа. Юлда күңелсезләнмәс өчен, ул күргәненең туганы, күрмәгәненең дусты, бабайларның яшьтәше, ханымнарның мәхәббәте булырга да әзер.

...Фәйзел ике ягындагы күршесен дә җентекләп күзәтеп чыкты: берсе әбиләр яшендәге хатын-кыз—сентябрь башы гына дип тормаган, сырма киеп, шакмаклап сугылган калын шәл ябынган, ярты капчыклы биштәренә таянып, рәхәтләнеп йокымсырый. Юк, дип уйлап куйды Фәйзел, бу түмгәктән ни он, ни йон, ни запчасть, танышу ул һәрвакыт җимеш бирергә

---

Камил КӘРИМОВ (1950) *— прозаик; «Ундүрт яшьтә», «Бәхетле кеше», «Вәгъдә», «Күләгәдә төлке бар», «Үзеңне бел», «Ком сәгате»* китаплары авторы. Казанда яши.

тиеш. Менә икенче яктагы күршесе болай күрер күзгә эшлекле генә кеше, ахрысы. Ыспай гына киенгән, күзлекле, галстуклы дигәндәй. Ике йозаклы портфелен, алдыннан төшермичә, "өф!" итеп кенә тора. Иптәшләре дә, хатыны-мазар да янында юк. Ир кеше ялгыз гына юлга чыкса, бел дә тор: ул командировкада, ә командировкага теләсә кемне җибәрмиләр.

—Бу вокзал тирәсендә кеше бер дә бетеп тормый,— дип башлады сүзен Фәйзел, күршесен сөйләндерергә теләп. —Карасана, нихәтле эшсез әрле-бирле чемодан ташый. Ярый, хет ашыгучылары да бардыр инде. Ә менә болары,— диде ул, хатынының алдына башын куеп эскәмиягә сузылып яткан бер агайга таба ымлап,—мөгаен, тәүлекләр буе шушында аунап ятадыр... Әгәр мондагы халыкны поезд көткән арада гына эшкә кушып торсаң, ә?! Вокзал белән янәшәгә берәр комбинат салып куясы да эшләтәсе үзләрен. Билет бәясен дә каплар, вакыт та тиз узар иде.

Гадәттә, Фәйзелнең бу фикере һәр яңа танышны да елмайта торган иде. Әлеге кешенең генә кырыс йөзе һаман үзгәрмәде.

—Минем эшләп торырга вакытым юк, тиздән поездым килеп җитә,— дип кенә җавап бирде ул.

—Кайсы якларга юл тотасыз? —Фәйзел, кәприз ханымнар белән сөйләшкәндәй, тавышын йомшартты.

—Саратовка.

—Эш беләнме?

—Юк. Язмыш кызык итте бит мине: бер хатыным Казанда, икенчесе Саратовта. Икесендә дә берәр балам бар. Тәки йөрим менә шулай ике шәһәр арасында.

—Ә син билетыңны югалт та Казанда кал, йә, киресенчә, Саратовтан чыкма.

—Әйтергә генә җиңел. Уйлап карасаң...— дип, абзыйның ачылып китәргә исәбе бар иде дә, тик Фәйзел күңеленнән генә кул селтәде: ир белән хатын турындагы хикәяләрнең һәммәсенең дә эчтәлеге бертөрле.

Ул арада ике ханым үтеп бара иде, Фәйзел күршесеннән гафу үтенде дә аларга иярде. Ханымнарның берсе бик нык ашыга иде, озата килүе дә итагатьлек өчен генә бугай, дустын поезд туктыйсы платформага алып килгәч, үзе тиз генә олагырга ниятләде:

—Менә,— диде ул китәр алдыннан,—алтынчы вагон шушы тирәдәрәк туктар, үпкәләмә инде, вакытым юк, поездың килгәнче көтеп тора алмыйм.

Ханымнарның исемнәрен дә ишетеп калды Фәйзел: озата килүчесе Сания, ә китүчесе—актан киенгәне Роза икән. Тагын Фәйзелне кызыксындырганы алтынчы вагон дигән сүз булды. Аныкы да алтынчыда лабаса. Шушы кызыксыну, Роза белән саубуллашып киткән Санияне эзәрлекләп барырга һәм аулаграк дигән урында аның юлына аркылы төшәргә, иптәш кызы турында сорашырга мәҗбүр итте...

Ярты сәгатьләп вакыт үтте.

Фәйзел әйләнеп килгәндә хат ташучы поезд килеп туктаган иде инде.

Алтынчы вагонга кергәч, Фәйзел үз урынына утырырга ашыкмады, башкаларга сиздермичә генә ак күлмәкле ханымны эзләп тапты. Вагон эчендә һәркем урнашып, җайлашып беткән иде инде. Бер әби генә "ак ханым" тирәсендә зарланып тора:

—Вәт тамаша, билетны өске катка биргәннәр, нихәл итеп менепләр ятармын икән?!

Ә Фәйзелгә нәкъ шул гына кирәк тә.

—Әбекәй, пожалысты, менә минем урынга килегез,— дип, әбигә икеләнерлек вакыт та калдырмыйча, билетларны алыштырып куйды. Һәм шулай итеп Фәйзел, шакмаклы юл сумкасын тотып ак ханым янына килеп басты.

—Роза! —Фәйзел бу исемне шундый итеп әйтте, хәтта ак ханым, янындагы ирне танымаса да, аның, һичшиксез, иске таныш булуына ышана иде.

—Әйе, мин Роза,— диде ак ханым оялып кына,— тик сезне хәтерли алмыйм.

Бу оялу ир кешенең шушылай тилмереп, йотлыгып һәм бер үк вакытта

сөенеп каравыннан кыенсынып калу гына түгел, ә Фәйзелне исенә төшерә алмаудан уңайсызлану да иде. Ак күлмәгенең ачык изүеннән сафлык бөркеп, кызыктырып торган тәненә алсу төс йөгерде. Әйтерсең аңа әле Фәйзелгә кадәр бер генә ир-атның да күзе төшмәгән булган.

Фәйзел җавап бирергә ашыкмады. Хатын-кыз дигәнең җавапсыз калган сорауларны бик өнәп бетерми, җавап тапмый торып тынычланыр дип уйлама да. Кем-кем, ә Фәйзел инде моны яхшы белә.

Роза поездның кузгалганын сизмәде дә. Башка вакытларда ул телевизор экранына ябырылган нарасый төсле хирысланып тәрәзәдән карап барыр, кул болгап калган озатучыларның аерылу сагышларын күңеленнән генә кичереп карар, тәгәрмәчләр тыкылдаган саен ерагая барган Казан каласына үзе дә: "Сау булып тор!"— дип пышылдап куяр иде. Юк, бүген болар барысы да онытылды, ник дисәң, каршысында күзгә-күз карашып серле билгесезлек утыра.

—Танымавың да гаҗәп түгел, унбиш ел вакыт үткән...

—Унбиш ел элек мин авылда яшь идем әле.

—Салкын Чишмәдә. Карале, ул чишмәгез һаман шулай шаулап агып торамы?

—Әйе... Кызык, сез мине чынлап та беләсез. Мин генә хәтерләмим. Хәер, иртәдән кичкә кадәр күз алдыбыздан күпме кеше чагылып үтә, барысын да ничек искәреп каласың?.. Назландырып тормагыз инде, әйтегез, кем сез?

—Син авылга бер чибәр кыз идең. Сиңа күз тутырып караган өчен генә дә кайбер егетләр бер гаепсезгә тукмала торганнар иде.

—Анысы дөрес. Клубка гел абыема ияреп кенә килә идем.

—Сез, салкын чишмәлеләр, Аппакай авылына йөри идегез, аларның клубы да зуррак, егетләре дә шәһәрчәрәк. Ә мин читтән генә күзәтеп торам да шуның белән юанам.

—Якын килергә курыктыгызмы?

—Мин курка белмим. Хәзер дә менә үземне сиздермәскә кирәк булгандыр. Унбиш ел буе ничек түзгәнмендер, белмим, тик хәзер сөйләшәсем килә, сине бүтән очрата алмам төсле.

—Исемегезне дә белмим ичмасам.

—Фәйзел мин.

—Фәйзел, Фәйзел... Фәйзел... Юк, исемә төшерә алмыйм.

—Аппакайда кошчылык комбинаты төзегән идек. Тирә-яктагы колхозлардан бик күп җыйдылар безне. Ул вакытта йомыркадан чыккан әтәчләр дә бүген унбиш яшь тутыргандыр инде... Эштән кайткач, арыганнарны да онытып, Аппакай юлына чыгып басам—хыялланып-хыялланып сине күзәтәм.

—Килеп дәшәсегез калган. Егетләрем арасында алай артык өзгәләнеп сөя белүчеләр юк иде.

—Исәнме Роза, мин сине яратам, дисәм, мөгаен "мине бик күпләр ярата", дип кенә җавап бирер идең әле... Гомерем буе сиңа охшаган кеше эзләдем.

Ярату сүзләрен кем генә яратмый икән! Роза да йотлыгып тыңлады. Фәйзелгә караган саен күңеле сөенде. Роза ир алдында үзен бурычлы итеп санады... Элеккеге игътибар юк инде хәзер миңа, олыгаям, ахрысы, трамвайларда яшьләр урын да бирә башлады, дип өлкәннәр гаме белән яшәүгә күчкән ханым мәхәббәткә авазлаш сүзләр ишетә бүген. Ялгызлыкта үткән һәр көн үзен нык сиздерә, һәм менә бүген аның янында Фәйзел исемле өмет. Хәер, ниткән өмет булсын ди инде, юлаучы гына ич. Розаны да кем беләндер бутавы гынадыр. Бәлки, кайда ачык күңел күрсә, шунда бәреп керә торган берәр хәсис кенәдер. Тәүбә, тәүбә, анысы кирәкми...

—Чәч толымым элек нинди иде, әйтә аласызмы? —Роза, үз соравыннан үзе оялып, читкә борылды һәм җавап көтте. Артык кыен түгелме бу сорау, дөрес җавап бирә белерме? Ялгышмаса гына ярар иде. Күпертеп таралган куе кара чәчләремә сыный карасаң, кисеп ташланган толымымның озынлыгын чамалап та әйтә алырсың...

—Җиргә тиеп тормаса да, тел шартлатып үтәрлек иде...

—Дөрес. Клубка киеп чыга торган чәчәкле ак күлмәгемне хәтерлисезме?

Поезд әкренләп төнгә килеп керде. Тәрәзәгә якынайган урманнарда карурман төсе...

Пассажирлар урын-җир иплиләр. Тәгәрмәчләрнең тигез тыкылдавы һәркемне йоклатыр сыман. Пышылдашып кына сөйләшер чак якыная. Ә Розаның бүген көчле сүзләр ишетәсе килә.

Тамбурда көзге төн җиләслеге.

Розаның иңендә Фәйзел пинжәге.

Ике башка йөз төрле уй.

—Ак күлмәгең сиңа бик килешә иде.

—Ул миңа бик килешә иде.

—"Иде дә иде", дибез. Кайда эшлисең, Роза? Нәрсәләр майтарасың?

—Сөйли калсам, тыңлап арырсыз. Болай да инде күзләрегездә йокы бар.

—Минем күзләр гел шундый ла ул, игътибар итмә.

—Ирдән уңмадым. Бер кыз үстердем, техникумга укырга керде. Баласын очырган кош төсле, җилел сулап ялгызым гына ял итеп кайтырга исәп.

Сүз уңаеннан гына "һәр кешенең бәхетле булуын телим", дип купшыланырга яратса да, Розаның ирсез яшәве Фәйзелнең өметен азындырды, хәтта куандырды да бугай.

—Роза, син бер дә үзгәрмәгәнсең. Мин сиңа әле дә сокланам, ә соклану ул—ярату билгесе...

—Мондый сүзләрне ишетүе рәхәт. Сөйлә, Фәйзел, сөйлә.

—Хат язасым килә.

—Хат... Хат очрашу бит ул—бераң сөйли, бераң тыңлый.

—Кая языйм соң, адресыңны әйтәсеңме?

Фәйзел, Роза иңендәге пинжәкнең кесәсенә тыгылып, куен дәфтәрен алды. Ул моны шундый тиз эшләде, кесәгә үрелгәндә Розаның куен җылысын да тоймый калды. Әйтә-әйтелешкә үк урам исемен, йорт номерын да язып алды. Тиз язды, әйтерсең бер мизгелгә генә тоткарланса да, Розаның кире уйлавы мөмкин иде.

Хатларга гына языла торган аерым сүзләр бар, телдән әйтеп бирүе кыен аларны. Розаның әнә шул зарыгып көткән очрашуларга тиң хатлар алганы юкка яшьлекнең үзе кадәр гомер үткән инде. Һәм менә яшьлек тагын әйләнеп кайтты. Аккан сулар кире кайтмый, дип җырлыйлар тагы...

Киноларда күреп, китаплардан укыса да, очраклы күренешләргә юлыккан кешеләргә шикләнебрәк, ышанмыйчарак карый иде Роза. Фәйзел белән очрашу да очраклы хәл түгелме соң?! Бәлки болар һәммәсе дә алдавыч төш кенәдер. Була бит шулай: әллә кайдан гына кошлар сайравы ишетелеп китә—урманда да, болында да кебек. Куышып йөрисең, ул сине тотып ала, иреннәреңә орынып үткәндәй тоела. Уянсаң, куеныңда исерек ир бөгәрләнеп ята... Һай, татлы төшләрнең бигрәк тансык чагы!..

—Фәйзел, ачуланмасагыз, сорыйм әле, ник соң моңарчы ялгыз яшәдегез? Ирләргә гаилә янартуы җинел ич...

—Кичә өйләнсәм, бүген нишләр идем, сиңа читтән генә кызыгып карап утырыр идемме? Ир кеше өчен иң зур бәхет ирек бит ул. Минем менә теләсә кайсы чибәркәйнең аяк астына егылырлык ирегем бар.

—Ничә тапкыр егылдыгыз инде?— дип ялт кына сорап куйды Роза, шаяртудан бигрәк, ул Фәйзелнең "тел төбен" аңларга теләде.

—Блокнотымда ничә адрес булса, шулхәтле,— диде Фәйзел, комарланып һәм шул арада, болай мактануның тиешсезлеген аңлап, сүзне кирегә борырга теләде: —Ә блокнотым чип-чиста!

—Әйтегез әле, дөресен генә әйтегез, сез бит мине белмисез, әйеме, бу әкиятне уйлап кына чыгардыгыз?!

—Хатын-кыз белән танышу үзе бер сәнгать бит ул,— диде Фәйзел, Розаның күзенә туры карарга куркып.

—Ялган сәнгатьне җенем сөйми!

Шушы берничә сәгать эчендә күз алдында әкияттәгедәй сихри шәһәр калкып, ул шәһәрдә Фәйзел белән Роза өчен дә бер йорт корылган иде; тәрәзәләре якты, ишеге кин, атлап керәсе дә гөрләшеп яши генә башлыйсы. Бактың исә, шәһәре дә, йорты да балалар мәйданчыгындагы төсле комнан

гына өелгән булган икән. Җимерелде дә төште, җир белән тигезләнде.

Роза, үзенә-үзе сораулар яудырып, аларга җаваплар да табарга тырышты. Адресым нигә кирәкте икән? Хат язар өченме? Юк, Фәйзел хат язарга ярата торган кешегә охшамаган. Эш юктан, кызык өчен генә хатлар язышырга унҗиде яшьлек чагыбызмы? Яшьлек дигәннән, Фәйзелнең кайчандыр безнең якларда булуы миңа кызыгып йөрүе кебек үк чеп-чи ялгандыр әле. Ирләр, тол хатын икәнеңне белсәләр, сөйләндереп карар өчен әллә ничә төрле ысулын табалар. Салкын Чишмәдән икәнлегемне дә берәр ничек ишетеп кенә калгандыр... Сания озата килгән иде, аннан сораштыргандыр әле, җаен да тапкандыр, шундый әрсез иргә охшаган бу. Ә Сания ике дә уйламас. Мине күптәннән бирле сөяркәле итәсе килә иде инде аның. Чәчең озын иде, дип әйтүе дә, шикәргә карап, баллы ул, дигән кебек кенә—чәч үсәр өчен бирелгән, кыска чәчне кем киссен?! Ирдәге хатын булсаң да, ялгыз чагыңны туры китереп, тәрәзәңне чиртеп үтәргә иренмәс. Абау, нинди чиркангыч кеше. Адресымны ник алганын да белəм хәзер: тамагы туйган эт тапкан ризыгын күмеп куя, карыны ачкач эзләп ала. Фәйз... бу хәсис тә шундыйдыр, исемен дә искәрәсем килми хәтта. Их, блокнотын ачып карарга, хатын-кызлар адресы белән тулган микән?!

Розаның җаны өшеде, гүя әкренләп куен җылысы суынып бара иде. Гомердә булмаганны, йөрәге авырткандай тоелды.

Роза, кинәт кенә яшерен бер карарга килеп, сагаеп калды: ничектер җаен табып, блокноттагы адресны юк итәргә...

Роза, күзен йомса да, Фәйзелнең өске ятактан аңа каерылып карап барганын тойды. Карасын әле, карасын... Роза Фәйзелне сынарга теләп одеялны читкә этәрде, җәймә генә ябынды, болай юка аклык аша нәфис сынның бөтен барлыгы беленеп тора.

Фәйзел песи җитезлеге белән ятактан төште дә, аяк очларына гына басып, Розага якынайды, аның ачык муенын үбәргә теләдеме, әллә тән җылысын тоеп карарга ниятләдеме—белмәссең. Тик Роза, ир кеше сулышыннан өеп, чирканып куйды һәм, йокы аралаш кына борылгандай, мендәргә йөзтүбән капланды. Аяк тавышларын ишеткәч кенә Фәйзелнең тамбур ягына таба киткәнен аңлады.

"Адресым язылган блокнот якында гына!"—шушы тынгысыз уй Розаның бөтен холкы-акылы белән идарә итә башлады... Ул кесәдә. Алырга. Бер мизгел җитә. Әмма бит кеше кесәсенә керәсе!.. Ләкин ул ир синең өметеңне алгысытты. Намуссызга җәза бирү—намус эше. Озак уйлап икеләнеп ятсаң, Фәйзел килеп җитмәгәе... Ул кесәдә. Алырга. Бер мизгел...

Роза, урыныннан торып, күршеләрен күзәтеп чыкты: йоклауларына тәмам ышангач кына, өске ятакка үрелеп, элгечтәге пинҗәкнең куен кесәсен эзләп тапты. Куен дәфтәренә кул тигәч, әллә куркудан, әллә артык сагаудан маңгаеннан чеметтереп-чеметтереп салкын тир бәрде. Хәтта күңеле болгангандай булды. Тиз генә актарып, йөзәрләгән хатын-кыз арасыннан үз адресын ертып алды. "Абау, усаллык эшләве дә кыен икән, бөтенләй хәлдән тайдым",— дип уйлап куйды ул һәм башка берни дә уйламаска тырышты. Йокларга яткач та башыннан ук бөркәнде: Фәйзелне күрсә, гафу үтенмичә түзә алмас кебек иде...

Вакытның тизрәк үтүен теләгәндәй, поезд тизлеген арттырды.

***

Фәйзелнең ятактан сикереп төшүе сискәндерде Розаны: "Әллә сиздемикән?" Станциягә килеп җителгән иде. Фәйзел кабыл-тибел киенде дә аерылышу газаплары кичермичә генә саубуллашып чыгып китте.

Роза, сиздермәскә тырышып, Фәйзелне күзәтте. Тәрәзә экранында ватык телевизордагы кебек тавышсыз-тынсыз аксыл сурәтләр—куе томан таңны бастырып куйган. Әнә "теге", ялтыравык ботинкасына карап, перрон буйлап йөренде дә пычрак юлга төшеп, томан эченә кереп югалды. Шуны гына көтеп торгандай, поезд кузгалып китте. Роза, тәгәрмәчләр теркелдәвенә сөенеп, мендәргә ауды да кулын күкрәгенә куйды.

Сул күкрәк астында ярсынып-куанып Йөрәк тибә иде.

**Солтан Шәмси**

# КҮК КАПУСЫ АЧЫЛСА...

ТАРИХИ-ФӘЛСӘФИ БӘЯН

## КҮЧЕШ

## ИЗГЕ КАЛЕНДАРЬ ЦОЛКИН ХИКМӘТЛӘРЕ

**Серле Майя җәмгыяте**

Күбебез Америка континентының Мексика, Гватемала, Гандурас дәүләтләре җирендә кайчандыр Майялар дәүләте яшәвен белә, аның шушы көнгә чаклы ачылып җитмәгән бөек серләре, гаҗәеп мәдәнияте, сәнгате, архитектурасы, дине турында да азмы-күпме ишеткәнебез, бу хакта китаплардан укыганыбыз, фәнни-популяр фильмнар караганыбыз бар.

Майялар тарихы һәм археологиясе белән шөгыльләнгән галимнәр фикеренчә, бу дәүләт безнең эраның 1 нче меңьеллыгында *(435–830 еллар)* үсешенең иң югары баскычына күтәрелә һәм бу вакыттагы майяларны тарих фәнендә "классик чор майялар" дип атап йөртү гадәткә кергән.

Тарихтан билгеле – җир йөзендәге борынгы цивилизацияләр нигездә диңгез ярларында, коры һәм җылы климатлы зур елга үзәннәрендә үсеп чыккан, язгы ташу вакытында дымга туенып һәм ашланып калган уңдырышлы җирләр алар өчен яшәү чыганагы булган. Месопотамиядә, Мисырда, Һиндстанда һәм Кытайда барлыкка килгән цивилизацияләр шуны раслый. Ә менә майялар ни өчендер бу кагыйдәдән читтә тора. Алар яшәү шартлары шактый кырыс булган Үзәк Америка сельвасын, ягъни тропик урманнарны сайлаганнар, шунда үзләренең мәшһүр калаларын, пирамидаларын төзегәннәр.


Әйе, "классик чорда", ягъни безнең эраның 1 нче меңьеллыгында бу дәүләттә дини йолалар үткәрү өчен йөзләрчә үзәкләр төзелә, пирамидалар, храмнар, сарайлар, дини корылмалар, безнең мәшһүр стадионнар сыман туп уйнау комплекслары барлыкка килә. Бу чорны Мисырда пирамидалар, Бабилда зиккуратлар кору заманнары белән чагыштырып булыр иде. Тик майялар белән Мисыр, Шумер цивилизацияләре арасында ким дигәндә 3 мең ел вакыт аралыгы тора, ягъни "классик" майяларның чәчәк аткан чоры Европа тарихының гаять "караңгы" урта гасырларына туры килә. Икенче төрле итеп әйтсәк, Майялар цивилизациясе ни өчендер без белгән борынгы цивилизацияләрдән бик соңга калып, әйтелгәнчә, 3 мең елдан соң гына күтәрелә һәм чәчәк ата. Сәер хәл, шулай түгелмени? Бу вакытта дәүләттә халык саны да бик нык үсә. Әмма Азия, Шәрекъ, Европа цивилизацияләреннән аермалы буларак, майяларның үсеше бөтенләй үзгә юлдан китә. Алар технологик үсеш юлын гомумән инкяр итә, барлык кораллар, кирәк-ярак агачтан, таштан, яндырылган балчыктан ясала. Дөньяның башка төбәкләрендә металлдан ясалган әйберләр киң кулланылган дәвердә бу цивилизация металлдан бөтенләй файдаланмый, ни тәгәрмәчне, ни суканы белми, йөкләр ташу өчен хайваннары да булмый – аларда бар нәрсә кеше кулы белән башкарыла. Шуңа күрә бер генә

*Ахыры. Башы 7-8 саннарда.*

цивилизациягә дә охшамаган майялар серен галимнәр һаман ачып бетерә алмый.

Иң гаҗәбе – яшьнәп яшәгән шушы үзенчәлекле цивилизация кинәт сүнеп кала. Безнең эраның 830 елында зур калаларда тормыш кинәт туктала, храмнар, сарайлар төзелми, сынчылар да, элекке кебек, дини йола үткәрү урыннарында махсус календарь даталары язылган, иероглифлар белән бизәлгән зур-зур багана – стелалар утыртмый, һәйкәлләр куймый. Мәшһүр калаларның ишегалларын үлән, куак-агачлар басып китә, тропик климатның әрсез үсемлекләре ташландык биналарның тәрәзәләреннән, ишекләреннән эчкә үтеп керә, дивар ярыкларына ябышып өскә үрмәли, түбәләрне каплый. Шулай гөрләп торган калаларны йөз ел вакыт үтүгә сельва йота. Археологлар билгеләп үткәнчә, калаларда тормыш шулкадәр кинәт туктала ки, хәтта төзелә башлаган йортлар да төгәлләнмичә басып кала. Җәмгыятьнең идарәче катламы һәм халыкның бик күп өлеше кинәт юкка чыга. Галимнәр шушы серле вакыйгадан соң халыкның бары тик 10 проценты гына монда калган диләр. Күпмедер вакыт әле ташландык биналар, йола үткәрү, туп уйнау урыннары тирәсенә йолышып бераз яшәсәләр дә, тропик урманның калаларны йота баруына каршы тора алмыйча, күчеп китәргә мәҗбүр булалар.

Әлбәттә, майялар моның белән генә тарих мәйданыннан төшеп калмый. Соңрак бу төбәккә ят кабиләләр үтеп керә, хакимият алар кулына күчә, хәтта "яңа майялар империясе" барлыкка килә. Әмма бу инде бөтенләй башка дәүләт, үзгә халык була. Ике гасырдан соң, 10 йөз ахырында, кабат ныгып киткән Майялар дәүләте белән элекке "классик чор майялар" арасында аерма инде бик зур була. Ә бу төбәккә Испания баскыннары аяк басканда майя халкы инде үзенең шанлы үткәнен дә, нинди бөек мирас варисы булуын да онытып бетергән була. Конкистодорлар бу җирләрне яуларга килгәндә майялар цивилизациясе инде агония кичерә, үлем алдында тора.


Майя җәмгыятенең сыйныфлар баскычы

"Классик чор майялар"ның 830 елда кинәт сүнеп калуын галимнәр төрлечә аңлатырга тырышып карый. Берәүләр климатның үзгәрүе, җир тетрәүләр сәбәп булган дисә, икенчеләре майялар дәүләте малярия, сары бизгәк *(желтая лихорадка)* кебек авырулардан зыян күргән дигән фикердә тора, гәрчә европалылар килгәнче бу авырулар анда таралмаган булса да. Кайберәүләр дәүләт идарәчеләре, имеш, ят дин кабул иткән, шуның аркасында җәмгыятьтә каршылыклар килеп чыккан, халык баш күтәргән, дәүләт хәлсезләнеп, таркалган дигән карашны алга сөрә. Шулай ук сәбәпне күрше халыкларның һөҗүменнән, майяларга хас житештерү ысулының антогонизм китереп чыгаруыннан яисә җирләрнең уңдырышлылыгы кимүдән күрүчеләр дә бар. Шулай бик күп гипотезалар тәкъдим ителсә дә, һаман бу мәсьәләдә фән таләпләренә җавап бирерлек ныклы фикер урнаша алмый. Мәсьәлә һаман ачык килеш кала. Кыскасы, галимнәр Көньяк Мексика һәм Төньяк Гватеманың түбән урнашкан урманлы төбәкләрендә яшәгән майяларның зур фаҗига кичерүен ачык күрсәләр дә, моның сәбәбен төгәл генә билгели алмыйлар.

Инде майялар цивилизациясе ирешкән казанышлар турында да берничә сүз әйтеп үтик. Әгәр дә аларның мәшһүр архитектура ядкярләре белән сәнгать әсәрләре генә безнең көннәргә килеп җитсә дә, бу мәдәният Шумер, Мисыр, Борынгы Греция кебек цивилизацияләр сафында тора алган булыр иде. Аларның әле моннан тыш гаҗәеп төгәл календарь системасы, математикасы белән астрономиясе дә була. Беренче карашка примитив күренгән бу халыкның календарь системасы үзенең төгәллеге белән гаҗәпкә калдыра. Әйтик, майялар Җирнең Кояш тирәсендә ел әйләнәсендә үткән юлын зур төгәллек белән исәпләп чыгаралар, шулай ук ай календарен, аның тотылу циклларын

билгелиләр. Меркурий, Венера, Марс, Юпитер, Сатурн кебек планеталарның әйләнү периодларын, күк җисемнәренең үзара очрашу вакытларын төп-төгәл ачыклыйлар. Ә майя астрономнары исәпләп чыгарган ел озынлыгы бүгенге көндә билгеләнгәнгә караганда да төгәлрәк була. Бу шулай ук ай озынлыгына да кагыла. Венера планетасының үз орбитасыннан тулы әйләнеш ясау вакытын да алар гаҗәеп төгәллек белән билгелиләр. Соңрак "Дрезден кодексы" дип исем алган борынгы майя астрономнары төзегән таблицада, мәсәлән, айның 69 тотылу вакыты күрсәтелә, шуларның бары 18 ен генә алар үзләре яшәгән территориядән күрә алган, калганнары исә булачак ай тотылу вакытларын белдергән.

Математика өлкәсендә дә алар зур казанышларга ирешә. Аларның санау системасы 20 цифрына нигезләнә, шулай ук "нуль" төшенчәсе дә кертелә. 1 цифрасы нокта **(.)**, 5 цифрасы озын сызык **(—)**, нуль исә бака кабырчыгы сурәте белән языла. Әйтик, мисал өчен: 1(.), 4 (....), 5(—) һ.б.

Шулай ук язу өлкәсендә дә майяларның язу системасы күрше халыкларныкы белән чагыштырганда иң камилләрдән була. Ә 365 көннән торган ел озынлыгын алар безнең кебек чиратлашып килүче 30 һәм 31 көннән торган айларга бүлмәгәннәр, җитмәсә безнең календарьда ике ай бу кагыйдәгә буйсынмый да — бер ай *(февраль)* 28 көннән тора, дүрт елга бер тапкыр 29 көнле була. Дөресен әйткәндә, бу хәл шактый буталчыклык тудыра. Майяларда исә 365 көннән торган ел 20 көнле 18 айга бүленә, ел ахырында шуңа артык исәпләнгән 5 "начар" көн өстәлә һәм вәссәлам! Мондый система безнең календарь белән чагыштырганда гадирәк тә, исәп-хисап итәр өчен уңайлырак та түгелмени?! Моннан тыш аларның 260 көннән торган Цолкин дип аталган йола календаре да була. Бу мәсьәләгә без әле җентекләп тукталырбыз.

Күренекле Мексика археологы һәм тарихчысы Альберто Рус Луилье (1906 — 1979) үзенең "Майя халкы" (1986) исемле атаклы китабында майялар календарена югары бәя биреп: "Майялар календаренең катлаулылыгы, аның ышануы кыен булганча төгәл эшләнүе, меңәр һәм миллион елларга артка китеп санау мөмкинлекләре бирүе аркасында тикшеренүчеләр бу календарь дөнья халыклары тарихында уникаль күренешне тәшкил итә дигән фикергә килделәр", — дигән фикер әйтә.

Шулай да, ни сәбәпле гөрләп яшәгән майя калалары кинәт сүнеп кала? Майялар кемнәр булган? Кайдан килгән? Ни өчен бу цивилизация үзенең иң бөек ноктасында яшәүдән туктый? Ни өчен алар җир йөзендә бердәнбер нәтехнологик үсеш юлын сайлаган цивилизация булган? Алар кая китеп югалган? Сораулар артык күп һәм галимнәр күпме вакыт инде аларга җавап эзли. Күп нәрсә инде ачыкланса да, төп сорауга — ни өчен бу цивилизация яшәүдән туктаган һәм алар кая киткән дигәненә һаман җавап юк.

## Хозе нәзер әйтә

1987 елда сәнгать белгече, рәссам, шагыйрь, рухият тарихчысы һәм философ Хозе Аргуэльесның "Майя факторы: нәтехнологик юл" дип аталган атаклы китабы басылып чыга. Үз сүзләренә караганда, әлеге китапка аның утыз ел алып барган эзләнүләре, уйланулары һәм ачышлары кергән. Х. Аргуэльес 1939 елда АКШта туа, биш яшенә кадәр Мексикада яши, аннан алар гаиләләре белән кабат АКШка әйләнеп кайталар. Ул Чикаго университетын тәмамлый, аспирантурада укый, соңрак төрле югары уку йортларында укыта, фәнни дәрәҗәләргә ирешә, сәнгатькә, философиягә, фикер тарихына караган хезмәтләр яза, картиналар ясый, күргәзмәләр оештыра, актив рәвештә җәмәгать эшләре белән шөгыльләнә. Әмма бу еллар үзенең төп хезмәтен — "Майя факторын..." язу өчен әзерлек чоры булуын ул соңрак кына аңлый.

1953 елда ундүрт яшьлек Хозены әтисе Мексикага алып бара. Ул бөек пирамидалар шәһәре Теотихуаканда *("Аллалар җиргә төшкән урын")* була, анда Кояш Пирамидасының өстенә күтәрелә. Шул чакта күңелен биләп алган хисләрен ул менә ничек сурәтли: "... күңелемдә бик тә үзенчәлекле көчле хис уянды — минем б е л ә с е м килә иде. Сизенүемчә, бу шушы цивилизация хакында нәрсә дә булса беләсе килү хисе генә түгел, бу — гадәттән тыш көч һәм ихласлык белән тышка бәреп чыккан белемгә сусау тойгысы иде, һәм ул мине чолгап алган шушы мохит белән бәйле иде. Теотихуаканның монументаль гармония белән сугарылган манзарасыннан карашымны аера алмыйча пирамида баскычларыннан аска төшкәндә мин нәзер әйттем, ант иттем:

монда элекниләр булганын мин барыбер беләчәкмен... Һәм читтән торып күзәтүче яисә археолог сыйфатында түгел, ә чын серләрне ачучы, тирәнтен күрүче сыйфатында..."

Малай чакта кичергән шушы илаһи мизгел аның тормыш юлын билгели. Аспирантурада укыганда майялар тарихы, мәдәнияте, сәнгате аның төп мавыгуына әверелә. Әмма бу халык турында күбрәк укыган, уйланган саен Х.Аргуэльес галимнәрнең төп нәрсәне тотып ала алмауларын ачык күрә. Эш шунда ки, бу мәдәниятне өйрәнгән археологлар, тарихчылар, сәнгать белгечләренең барысы да майяларны "таш гасыр цивилизацияләре рәтендәге бер бәхетле һәм серле халык" дип кабул итә, аларның фикере гел шушы юнәлештә әйләнә. Галимнәр майялар җәмгыятен бары тик материалистик карашлардан чыгып бәяли, аларны тар схема кысаларында аңлатып бирергә омтыла. Ләкин үсеше технологик юлдан киткән цивилизациянең алдынгы вәкилләре 20 нче йөз ахырында бу юлның глобаль фаҗигагә китерүен инде ачык күрәләр, кешелек дөньясы үз-үзен коткарып калу өчен ниндидер башка юнәлеш сайларга тиеш дигән фикер алар арасында торган саен ныгый бара. Майялар тарихына, мәдәниятенә баштан-аяк кереп чумган Х.Аргуэльес та шушы елларда кинәт сискәнеп киткәндәй була. "Майяларны, гомумән, Борынгы Мексика мәдәниятен аңлау мәсьәләсе, дөресен генә әйткәндә, безнең үз цивилизациябез алдына килеп баскан мәсьәлә белән бик тыгыз бәйләнгән булуын мин акрынлап төшенә башладым", — дип яза ул. Чыннан да, майялар цивилизациясе табигать көчләреннән шулкадәр сак файдаланып, аны исраф итмичә, имгәтмичә шундый бөек казанышларга ирешә ки, бәлки, бу безнең өчен сабак булырдай үрнәктер. Җир йөзендәге башка борынгы цивилизацияләр сүнгәннән соң берничә мең ел үткәч тарих мәйданында майяларның пәйда булуы очраклы хәлме? Бу кризис дәверенә килеп кергән кешелек дөньясы өчен үз-үзен саклап калу, котылу юлын күрсәтү мисалы түгелме?

Майяларның иң яраткан шөгыле — вакыт белән эш итү була. Бу мәдәniяттә календарь төзү, астрономия белән шөгыльләнү, күк җисемнәренең орбиталарын исәпләп чыгару, аларның үзара якынаю, очрашу вакытларын билгеләү, ниндидер даталарга багышлап таш баганалар — стелалар утырту, бернинди техникадан файдаланмыйча, гаҗәеп күп кул көче түгеп, күккә омтылган бихисап пирамидалар төзү — болар барысы да көнкүреш ихтыяҗларын кайгыртып җирдә яши торган гади аң өчен бик тә сәер шөгыльләр түгелмени? Барысын да исәпкә алып уйлана башласаң, майялар бик сәер һәм башка цивилизациягә охшамаган гаҗәеп үзенчәлекле мәдәният булып чыга түгелме соң? Җәмгыятьнең күп көчен-вакытын ала торган мондый эшчәнлек аларга нигә кирәк булган? Ни өчен майялар җәмгыяте үз алдына реаль тормыш ихтыяҗлары белән аз бәйләнгән илаһи бурычлар куеп яшәгән? Моны нәрсә белән аңлатырга? Бәлки, алар Җиргә махсус вазыйфа үтәр өчен килгән чит планета вәкилләредер? Бәлки, бу сәер цивилизация безгә сабак бирү, үсеше ялгыш юлга кереп киткән кешелек дөньясы өчен башка төрле яшәү үрнәге бирү өчен оештырылгандыр? Кризис чорына килеп кергән кешелек дөньясы шушы катлаулы заманда, бәлки, йөзе белән алар калдырган мираска борылырга тиештер? Аннан соң майяларның 830 нчы елда кинәт тарих мәйданыннан юкка чыгуы, калаларының, дини комплексларының бушап калуы аларның Җирдә ниндидер вазыйфа үтәүләре һәм соңыннан аңлы рәвештә физик планнан юкка чыгуы турында сөйләмиме? Аларның Европада "караңгы дәвер" хөкем сөргәндә, дөнья нурга сусап яшәгәндә тарих мәйданына килеп чыгуы очраклы хәлме?


*Майяларның дин әһеле.*

Майяларны өйрәнгән археологлар, тарихчыларның, үзара сүз берләшкәндәй, бу мәдәниятгә күп нәрсәләрнең вакыт төшенчәсенә бәйләнгән булуы, табылган язуларда сүзнең гел Ай, Венера планетасы цикллары, аллаларга багышланган йолалар, календарьда билгеләнгән ниндидер даталар турында баруы да бу халыкның вакыт агышын исәпләү белән мавыгуы, аны бөек бер культ дәрәҗәсенә күтәрүе хакында сөйли бугай. Безнең эраның 200—400 елларында, майялар астрономик күзәтү һәм дини йолалар үткәрү үзәкләре төзи башлаганда, аларның иероглифлар һәм математик символлар системасы

инде тулысынча калыплашкан була. Шулай майя халкының мәдәният һәм фән өлкәсендә акрынлап үсә, катлаулана барган системасы барлыкка килү процессы бөтенләй күренми. Бу система кинәт барлыкка килә. Шулай булгач, үз өстенә ниндидер галәми вазыйфалар, илаһи бурычлар куеп яшәгән бу цивилизациянең нигезләре Җирдә түгел, ә бөтенләй башка күк җисемнәрендә салынган булса кирәк. Фәкать шулайдыр, майялар Җиргә махсус вазыйфа үтәү өчен килгән җәмгыять булгандыр. Классик майяларның зур көч-куәт туплауларына карамастан, сугыш һәм яулар белән мавыкмыйча, көчне башка юнәлештә сарыф итүләре, җир йөзендәге башка цивилизацияләр юлыннан китмичә, үзләренең бөек максаты итеп рухиятне кайгыртуы шул хакта сөйли кебек.


Күп еллар дәвамында майялар мирасын өйрәнү, алар яшәгән борынгы калаларда булу, күкләргә омтылган пирамидалар, мәшһүр биналар тирәсендә атналар-айлар буе уйланып йөрүләрдән соң Х.Аргуэльес бу халыкның , чыннан да, Җир тумасы булмыйча, махсус вазыйфа башкару өчен бүтән күк җисеменнән килүенә тәмам ышана һәм өч дистә ел буе бөртекләп туплаган белемнәрен шушы фикер чылбырына тезәргә керешә.

## Изге Календарь

Әйе, майялар җәмгыятендә вакыт төшенчәсенә чамадан тыш зур урын бирелә, алар Галәмне дә бихисап зур вакыт һәм яшәеш цикллары гәүдәләнеше буларак аңлаталар. Әлбәттә, бу юкка гына түгелдер, вакыт төшенчәсе бөек культ дәрәҗәсенә күтәрелгән бу җәмгыятьнең төп вазыйфасы, күрәсең, вакытны төгәл исәпләү, аның ритмнарын билгеләүгә бәйледер. Ә вакыт һәм аның цикллары майяларның календарь системасында чагылыш тапкан. Димәк, майяларның гаять катлаулы, әле беркем дә аңлап бетерә алмаган календарен өйрәнергә кирәк. Шул чакта гына бу цивилизациянең серен ачып булачак. Шулай Х.Аргуэльес майяларның Цолкин дип аталган Изге Календарен өйрәнергә керешә.

Майя телендәге сүзләр еш кына төрки халык вәкилендә таныш ассоциацияләр тудыра. Әйтик, кин — көн, кояш, каан — күк, чан — кояш улы дип аңлатыла; бу очракта чанны — җан сүзе дип уйларга кирәктер. Яшь — яшел төс, яңару көче һ.б. Шушы принципка таянып, мин майяларның Изге Календаре Цолкин сүзенең дә мәгънәсен аңларга тырышып карадым. Эзләнә торгач, Цолкинның — көннәр исәбе дигән мәгънәгә ия булуын ачыкладым. "Кин" сүзенең "көн" икәне билгеле булса да, кушма сүзнең беренче өлеше "цол" нәрсәне аңлата соң? Уйлана торгач, аның гап-гади "сал, салу" мәгънәсенә туры килүен күрдем.

Чыннан да, "салу" — ул бит бер рәткә салып санап баруны, ягъни көннәрне санап баруны аңлата. Димәк, Цолкин — сал һәм көн — көннәр салынышын, аларны исәпләп баруны аңлата булса кирәк. Шулай майялар календаре исеменә бераз ачыклык та керә кебек. Шундый уйлануলардан соң бу календарь бөтенләй күңелгә якын булып китте, гүя аны ерак бабаларыбыз безгә мирас итеп калдырган.



*Изге Календарь Цолкин*

Майяларның Изге Календаре гаять сәер нумерология системасын тәшкил итә. Ул сәер генә түгел, аңлау өчен бик катлаулы да. Шуңа күрә тикшеренүчеләр күп заманнар аның серен ача алмыйлар. Күп елларга сузылган өйрәнүләрдән соң Х.Аргуэльес, ниһаять, бу серне ача, шул хакта китап яза, әмма

аның хезмәте дә гаять катлаулы язылган, аңлау өчен күп көч куюны һәм вакыт сорый. Шул сәбәпле китаптан катлаулы цитаталар тәкъдим итеп укучылар башын катырмас өчен, без анда китерелгән төп концепцияне гади рәвештә укучыга җиткерү юлын сайладык. Бу дөресрәк булыр дип уйлыйм.

Цолкин турыпочмак рәвешендәге таблицаны тәшкил итә. Ул 13 вертикаль һәм 20 горизонталь юнәлештә урнашкан баганадан тора. Вертикаль баганалардагы саннар белән горизонталь баганалардагы саннар 20 изге символ-сурәт белән ниндидер мөнәсәбәттә тора. Вертикаль һәм горизонталь баганаларның кисешүе 260 оя – ячейкадан торган цифрлар челтәрен хасил итә. Майялар системасында саннар күләм, микъдар, кече яки зуррак саннар мөнәсәбәтен күрсәтүче буларак кына кулланылмый, ә нумерологиядәге кебек, энергетик сыйфат күрсәтүче буларак хәтта зуррак әһәмияткә дә ия. Изге Календарьда урын алган 13 сан – төрле нурланышлар энергиясен белдерсә, 20 изге символ-сурәткә караган саннар исә Галактикада хөкем сөргән тибрәнеш ешлыклары диапозоннарын күрсәтә. Шулай календарьда барлыкка килгән 260 оя бербөтен резонанс кыры барлыкка китерә. Фәлсәфи яктан килеп аңлатканда, нәкъ менә шушы резонанс кыры яшәешнең барлык сыйфатларын-якларын үзендә гәүдәләндерә, ягъни үзенә күрә бер универсаль код ролен үти икән. Шулай итеп, майяларның календарь системасы гаять үзенчәлекле кодка ия булган матрица тәшкил итә һәм бу матрица Галактикада тупланган мәгълүматны безнең планета шартларында файдалану мөмкинлеге тудыра. Кыскасы, Цолкин календаре үзенә күрә бер мәгълүмат алу коралы, тапкырлау таблицасы кебек, универсаль ярдәмлек булып тора. Шушы корал ярдәмендә без Галактиканың мәгълүмат банкыннан файдалану һәм аның ритмнарына көйләнү мөмкинлегенә ирешә алабыз. Әмма моның өчен рухи үсешнең бик югары баскычында тору сорала.

Телгә алынган 20 изге символ-сурәт турында да берничә сүз әйтеп үтик. Бу символлар яшәеш юлын, аның төрле баскычларын билгели.Әйтик, беренче җиде символ түбән баскычта торган физик организм эволюциясен, аның мөмкинлекләрен чагылдыра, калган унөче – аның менталь, ягъни аң-фикер үсеше эволюциясен күрсәтә. Гомумән алганда, әлеге 20 символ-сурәт тереклекнең гади формалардан алып, югары үскән аң дәрәҗәсенә кадәр күтәрелү процессын ачып сала. Шулай безнең алда яшәешнең төрле дәверләрдән, баскычлардан торган тулы картинасы гәүдәләнә. Әлбәттә, бу картина энергия һәм тибрәнешләр ешлыгын чагылдырган саннар ярдәмендә бирелә. Шуңа күрә дә аны аңлавы гаять кыен. Х.Аргуэльес фикеренчә, яшәешнең универсаль моделен чагылдырган бу система Җирдәге тереклек эволюциясенә генә кагылмыйча, бөтен Җиһанның яшәеш закончалыкларын чагылдыра, шул сәбәпле галим аны Гармония Тудыручы Модуль дип атый.


## Бөек Дәвер һәм без

Менә без майяларда төп шөгыль һәм кайгырту өлкәсе булган вакыт төшенчәсенә якынайдык. Эш шунда ки, Цолкин календаренда чагылыш тапкан башка мәсьәләләрдән тыш анда кешелек дөньясының үсеш дәверләре турында да бай мәгълүмат салынган һәм бу мәгълүмат бүгенге көндә зур әһәмияткә ия. Анда Җир тарихының безнең эрага кадәр 3113 елдан алып безнең эраның 2012 елына кадәр килеп җиткән һәм 5125 ел вакытны эченә алган гаять зур циклы тасвирлана. Бу цикл майяларда Бөек Дәвер дип атап йөртелгән. Бүгенге көндә без үзебезнең, өченче меңьеллыкка атлап чыгып, 2004 елда яшәвебезне искә төшерсәк, анда теркәлеп калган әлеге Бөек Дәвер тәмамланырга дистәдән дә ким ел вакыт калганын ачыкларбыз. Табигый, бу хәл бездә бик күп сораулар уятыр һәм аларга җавап аласыбыз килер.

Чыннан да, майялар бу дәверне ни өчен шулай зурлап Бөек Дәвер дип атаганнар һәм ни өчен ул, безнең эрага кадәр 3113 елда башланып, безнең эраның 2012 елында тәгәлләнә? Бу 5125 елга сузылган вакыт аралыгының кешелек дөньясы өчен нинди әһәмияте бар, аның асыл мәгънәсе нидән гыйбарәт?

Сорауларга җавап биргәнче шуны искә төшереп үтик: без инде язмаларыбызның алдагы бүлекләрендә 2012 ел турында берәз сүз алып барган идек. Галәмдәге Остазларыбыздан алынган мәгълүматларда да шул ук 2012 ел күрсәтелә, классик диннәр дә төп китапларында "вакыт төкәнгәндә" Ахырзаман, Хисап көне, Хөкем көне килер дип кешелек дөньясының исенә төшереп тора. Майяларның Изге Календаре Цолкин исә, бу хакта бернинди шик-шөбһә калдырмыйча, ачыктан-ачык итеп – 2012 ел кешелек

дөньясы өчен чикне үтеп чыгу, язмыш хәл ителү елы булачак дип кисәтә.




*Изге Календарьда символлар*
*һәм Кояш системасы планеталары*

5125 елны эченә алган Бөек Дәвер майяларда 13 дәвергә—бактунга бүленә. Бер бактун үзе 394 елга тиң вакыт аралыгын тәшкил итә. Шулай 5125 елга сузылган тарихи процессны—Бөек Дәверне—алар сыйфат һәм эчтәлек ягыннан бер-берсеннән шактый аерылып торган 13 бактун рәвешендә күз алдына китергәннәр. Бактун 20 катунга бүленгән, һәр катун 19 елга тиң булган. Катун исә 20 тунга бүленгән, тун 1 елга тиң булган. Тун үзе 360 кинга *(көнгә)* тиң булган. Шулай итеп иң кече вакыт берәмлеге кин саналган.

Шулай итеп, майяларның Бөек Дәвере бактуннарга бүленгән 13 чордан торган. Без алда тарихи процессның этапларын ачып салыр өчен нигездә шушы бактун *(394 ел)* төшенчәсе белән эш итәрбез.

Сорау туа: ни өчен майяларның Бөек Дәвере безнең эрага кадәр 3113 елдан башлана? Моңа җавап бирү өчен Җир тарихының ераграк дәверләренә күз салу кирәк булачак. Атлантиданың соңгы утравы моннан 12,5 мең ел элек су астына китә, һәлак була. Бу катастрофа тарихка Бөек Туфан *(Великий Потоп)* дип кереп калган. Өстәвенә нәкъ шушы вакытта Җирнең күчәре урыныннан күчә. Планетабызның күчәре күчү Җир тарихында булгалый торган хәл. Бу һәрвакыт глобаль катастрофаларга китергән. Галимнәр әйтүенчә, Җир үзенең яшәү дәверендә инде берничә тапкыр күчәренең торышын үзгәрткән. Әйтик, Җир шарының моннан алдагы 26 мең еллык циклы тәмамланганда да планетабызның күчәре күчә һәм полюслары алмашына, кешелек дөньясы бик зур һәлакәтләр кичерә. Әгәр дә ул чактагы күчәр күченүгә хәтле җир йөзендә 2 миллиардка якын кеше яшәгән булса, катастрофалардан соң планетада бары миллион ярым гына кеше исән кала. Җитмәсә, исән калган кешеләр дә бөтен планетага таралып беткән була *(Ченнелинг. Послания Старших Братьев Человечества. Киев, "София", 1998. -С.40)*. Бу саннар кешелек дөньясының нинди зур югалтулар кичерүен һәм гаять авыр шартларда планетада кабат тормыш башлануын бик ачык күрсәтә. Без белгән "тарихның" чын тарихтан ничек ерак торуын шуннан да чамаларга мөмкин.

Моннан 12,5 мең ел элек булып узган Атлантида һәлакәте, шуның белән бергә туры килгән Җир күчәре күчү , бу фаҗигаләрнең бөек Туфан белән тәмамлануы кешелек дөньясын бик авыр хәлгә куя. Кешеләр ул чакта хәтта күчәр күчеп, полюслар алмашынганын аңламый да калалар. Моны Бөек Туфан—җир йөзен су басу галәмәте дип кабул итәләр. Шулай Җирдә 6 мең елга сузылган караңгы дәвер урнаша. Моңарчы ирешелгән цивилизация казанышлары юкка чыга, кеше бик күп нәрсәләрне оныта, кыргыйлана, саны бик нык кимегән кешелек дөньясы, әле генә туган бала кебек, үзенең тарихын әр-яңадан башларга мәҗбүр була.

Шушы вакыйгадан соң алты мең еллап вакыт узгач кына планетаның зур елга үзәннәрендә кабат җир эшкәртү, нәрсәләрдер үстерү кебек шөгыльләр барлыкка килә. Хәзер шундый заман килде ки, кеше үзе яшәгән Җир планетасының Галәмдәге Көчләр өчен тәҗрибә үткәрү мәйданы икәнен аңлап яшәргә тиеш. Галәмнең, Раббыбызның төп максаты—планетада тереклек орлыклары чәчү һәм шул тереклек орлыкларын күзәтеп, багып, тәрбия кылып тору. Тереклек барлыкка килгәннән соң аңа аң кертү, шул аңны акрынлап үстерү, аңа юнәлеш бирү. Юнәлеш исә диннәр аша бирелә. Әгәр дә инде, Атлантида җәмгыятендәге кебек, гаять югары дәрәҗәгә күтәрелгән шушы аң, үз-үзенә артык ышанып, тәкәбберләнеп китеп, Галәм, Раббыбыз кануннарына каршы килсә, Тәрбиячелеренең сүзенә колак салмаса, үсешендә ялгыш юлга кереп китсә, шулай үзен

туендырган, иркәләп үстергән Җир-Анабызга зыян сала башласа, көт тә тор — җәза киләчәк. Галәмнең кануннары гадел, шул ук вакытта алар гаять кырыс та. Җир-Анабыз үзенә зыян китерүчене беркайчан да саклап тотмаячак, аннан тизрәк котылырга тырышачак. Кеше һаман шушы гап-гади хакыйкатьне аңлау дәрәҗәсенә күтәрелә алмый. Кеше кылган вәхшилекләргә Җир-Анабыз ничек түзеп тора икән дип гаҗәпләнергә генә кала. Атлантида фәкать шуның аркасында һәлак була.

Хәер, без төп мәсьәләдән бераз читкә тайпылдык бугай. Алты мең елга сузылган һәм әле бүгенге көндә дә ачыкланып бетмәгән караңгы дәвердән соң кешелек дөньясының күзләре кабат ачыла башлый. Планетаның төрле төбәкләрендә киләчәктә бөек казанышларга ирешәчәк бөек мәдәният үзәкләре үсеп чыга — Шумер, Мисыр, Һиндстан, Кытай, Крит күтәрелә, цивилизацияләрнең өр-яңа дәвере башлана. Бу заманнарны без инде сакланып калган тарихи ядкярләр, сәнгать әсәрләре һәм язма чыганаклардан беләбез. Шуңа күрә дә аларны "язма тарих" дәверләренә кертәләр.

Майяларның Цолкин календаре безнең эрага кадәр 3113 елдан башлана, диде. Бу андагы беренче бактун башланган ел, һәр бактун кебек, ул да якынча 400 ел буе дәвам итә. Беренче бактун *(б.э.к. 3113—2718)* нинди заманны эченә ала, ул нәрсәсе белән әһәмиятле? Ни сәбәпле майялар Изге Календарьларын фәкать шушы елдан башлаганнар? Моның өчен бик җитди сәбәпләр булырга тиеш кебек.

Җавап нигезле булсын өчен, кабат эзотерик чыганакларда яктыртылган мәгълүматларга, Җир тарихының бик борынгы, бүгенге кешелек дөньясына билгесез тарихына мөрәҗәгать итәргә туры килә: "Соңгы 500 мең ел эчендә төрле йолдызлыклар системасыннан килгән цивилизацияләр Җирдә бик күп тапкыр хәят орлыклары чәчтеләр (...) Бу вакыйгалар Җирдә Галактикаара Тере Китапханә *(Үзәк)* булдыру программасының аерым өлешләре иде. Һәр цивилизация Җиргә үз вакытында килде. Әмма планетаны яулап алып, анда үз хакимиятен урнаштырган, аны башка дөньялардан аерып куйган, изоляциядә тоткан һәм бик күп заманнар башка күк җисемнәрендә яшәүчеләрне Тере Китапханәгә якын җибәрмәгән көчләрнең Җир тирәсендә электромагнит кырыннан киртә ясап куюына карамастан, төрле цивилизация вәкилләре бу киртә аша үтеп чыга тордылар, шулай Җирдә төрле цивилизацияләр төзелде. Бу цивилизацияләрнең кайберсе 500, 5000 яисә 10000 ел буе яшәде. Шулай да планетада хакимлек урнаштырган көчләр аларны куып җибәрә яисә башка берәр ысул белән юк итә барды. Шулай итеп, бу цивилизацияләр Җиргә хуҗа булу хокукына ирешә алмадылар, ләкин үзләреннән соң бик күп эзләр, кинаяләр, төрле билгеләр салып калдырдылар. Шушы билгеләр ярдәмендә, баскыч басмаларына басып аргы ярга чыккан кебек, Галактикаара Тере Китапханәнең нинди максат белән төзелүен ачыклау һәм аңа үтеп керү мөмкинлеге яшәп килде" *(Барбара Марсиниак. Земля. Киев, "София", 2000. -С.33—34).*

"... Мисырлылар, инклар, полинезиялеләр, греклар, тибетлылыр, шумерлар, Американың борынгы халкы, майялар, Австралия аборигеннары һәм Җирдә яшәүче башка абориген мәдәниятләр шушы эзләр-ачкычларны аңлауга үзләреннән зур өлеш керттеләр һәм аларның барысы да йолдызларга төртеп күрсәтә килде. Бу мәдәниятләрнең һәркайсы Тере Китапханәгә үтә торган ишекне бераз ачып калдырдылар". *(Шунда ук. — 34 б.)*

"Бу цивилизацияләр ничек барлыкка килде дип сорыйсызмы? Әллә алар, тузганак кебек, җирдән үсеп чыкканмы? Юк, алар уй-фикер рәвешендә барлыкка килә... Аларга яшәү өчен импульс бирелә. Югары рухи идеалларга ирешкән барлык цивилизацияләр дә иң элек Бөек Уен Осталарының *(Галәмдәге Тәрбиячеләребез — С.Ш.)* фикере рәвешендә туа. Бөек Уен Осталары төрле дәверләрдә төрле цивилизация үрнәкләренең концепцияләрен төзи, аннан бу цивилизацияне төзү өчен төрле йолдызлардан вәкилләр китерелә. Җиргә төшерү алдыннан алар генетик яктан җир кешеләренә охшаш итеп үзгәртелә, адәми затның генетик линиясенә яраклаштырыла". *(Шунда ук. — 35 б.)*

Мондый юл белән Җирдә башка цивилизация вәкилләренең урнашуын эзотерик әдәбиятта "йолдыз чәчмәсе" *("звездный посев")* дип атыйлар.

"Җирдәге бик күп цивилизацияләр шушы юл белән төзелде. Цивилизацияләр мәгълүм бер импульс буларак туа, һәр импульсның тормышка ашу программасы була. Барлык программалар да алдан әзерләнә". *(Шунда ук. — 35 б.)*

"Бөек Уен Осталары уй ярдәмендә төзек мәдәният-цивилизация матрицалары *(өлгеләре)* төзиләр, аннан үлчәм-вакыт капкаларын ачып, әлеге цивилизацияләрне Җиргә

индерәләр. Шулай ук бу цивилизацияләргә үсәр һәм чәчәк атар өчен шартлар тудыралар, шушы цивилизациянең башка дәверләргә тәэсир итү һәм аларны киләчәктә орлыкландыру көче дә саклана". *(Шунда ук. – 38 б.)*

Үзәк Америкада чәчәк аткан һәм 830 нче елда кинәт юкка чыккан "класик чор майялар" дәүләте дә шушы ысул белән индерелгән цивилизацияләрдән була. Б.Марсиниак китабында китерелгән бер өзек шул хакта сөйли: "Кайчандыр Үзәк Америкада һәм Мексикада яшәгән майя кабиләләре дә шундый уеннар остасы була. Алар төрле чынбарлыкны *(реальность)* үзара куша һәм бер системадан икенчесенә күчә белгәннәр. Алар яшәгән дөньяның нигезе Плеяда йолдызлыгына барып тоташса да, майялар бу йолдызлыкта даими яшәүчеләрдән түгелләр. Аларның үз дөньялары бар. Бүгенге көндә майя халкы вәкилләре Галәмдәге бик күп дөньяларда эш алып бара, гүя ул беркайчан да өзелмәгән шикелле, алар шушы бөек цивилизация традицияләрен дәвам иттерәләр. Алар үз цивилизацияләрен, бер үлчәмнән икенче үлчәмгә, бер дөньядан икенче дөньяга күчереп, аны "үзләре белән алып китәләр"... Майялар, Вакыт Сакчылары буларак, рухи үсеш юлында шундый камиллеккә ирешәләр ки, чынбарлыклар тудыру алар өчен гадәти нәрсәгә әверелә". *( Шунда ук. – 36 б.)*

Мәгълүм булганча, цивилизациянең матди гәүдәләнешләре булган калалар, пирамидалар, һәйкәлләр, спорт корылмалары тәзек килеш утырып кала, ә халык үзе Нәфис дөньяга күчә.

Укучыларыбызның күңел дөньясын шушы мәгълүматлар белән баетканнан соң безгә инде майяларның кем булуын да, "йолдыз чәчмәсе" дигән төшенчәнең нәрсә аңлатканын да сөйләп тору хаҗәте калмый. Ә бит майяларның Изге Календаре Цолкинда күрсәтелгән Беренче бактун нәкъ менә шушы "йолдыз чәчмәсе"ннән башлана. Безнең эрага кадәр 3113 елда башланып, якынча 400 елны эченә алган бу дәвердә җир йөзендә нинди хәрәкәтләр, мөһим вакыйгалар күзәтелә соң? "Йолдыз чәчмәсе бактуны" дип аталган бу дәвердә Җир планетасы Галактика Үзәгеннән килгән синхронлашу нуры көлтәсенә килеп керә. Әлбәттә, бу нур безгә үз системабыз үзәге булган Кояш аша тапшырыла. Безнең системада бар нәрсә безгә Тереклек Бирүче Кояш ризалыгы һәм фатихасы белән башкарыла. Галактик синхронлашу нурына килеп кергән шушы дәвердә җир йөзендә Мисыр цивилизациясе күтәрелә һәм ныгый, безнең эрага кадәр 3100 елда Мин исемле патша Өске Мисыр белән Аскы Мисырны берләштерә. Нәкъ шул чорда Шумер дәүләте *(б.э.к. 3000 нче ел)* чәчәк ата, Британия территориясендә атаклы Стоунхендж комплексы төзелә. Дөньяның өч тарафында өч бөек цивилизация үзәге калкып чыга. Шунысы кызык, бөек цивилизацияләр ни өчендер "кинәт" барлыкка киләләр, кешенең аңы бик акрын үсү-өлгерүгә карамастан, калкып чыккан цивилизацияләрдә тормыш-яшәешнең дә, мәдәниятнең дә һәр ягы төптән уйланган һәм камиллеккә ирешкән була. Мондый дәрәҗәгә ирешү өчен бу цивилизацияне барлыкка китергән халык бик күп заманнар максатчан эш алып барырга тиеш иде ләбаса. Юк, тарихка кереп калган һәр бөек цивилизация "кинәт" өлгерә һәм калыплашкан килеш тарих мәйданына чыга, шулай үз вазыйфасын башкара. Бу хәл цивилизацияләрнең Бөек Уен Осталары, Күктәге Тәрбиячеләребез тарафыннан әзер матрица-өлге рәвешендә Җиргә индерелүе хакында сөйли.

"Классик чор майялар" дәүләте Үзәк Америкада нәкъ шулай барлыкка килә һәм үзеннән соң бүгенге көнгә хәтле ачылмаган күп серләр калдыра. Майялар дәүләте башка күк җисеменнән килгән цивилизация вәкилләре тарафыннан оештырылган булган дигән фикерне беренче булып Х.Аргуэльес әйтә һәм бу аның зур казанышы дип саналырга хаклы. Моны хәзер Б.Марсиниакның Плеядалар йолдызлыгы вәкилләре тапшырган материалларга нигезләнеп язылган китабы да раслый.

Шулай җир йөзендә Атлантида дәвереннән соң өр-яңадан калыккан цивилизацияләр дәвере башланып китә. Әле Мисырдагы Гиза шәһәрендә Бөек Пирамида да төзелмәгән, Шумер да үз мирасын Аккад белән Бабил патшалыкларына тапшырмаган, Инд елгасы бассейнында Махенджо-Даро һәм Хараппа кебек атаклы мәдәният үзәкләре барлыкка килмәгән, Кытай һәм Крит цивилизацияләре дә күтәрелмәгән. Тарихның бормалы юлларында әле бик күп казанышлар һәм югалтулар булачак, күп көч сарыф ителәчәк, адәми зат каны елгалар булып агачак, гүзәл калалар төзелеп, күп тапкырлар җимереләчәк, дөнья халыклары төрле патшалыклар, дәүләтләр, империяләр төзеп, алар да үз чиратында юкка чыгачак. Дөньяны тетрәтеп яшәгән көчле кавемнәр, күпмедер вакыт үткәч тәмам хәлсезләнеп, башка халыклар арасында йотылып эзсез югалачак. Тарих сәхифәләрендә

аларның бары тик исемнәре генә уелып калачак. Соңрак чорларда тереклек иткән кавемнәр ул дәүләтләр, халыклар яшәгән җирләрдә гүзәл кала калдыклары, сарайлар, күз явын алырдай сәнгать әсәрләре казып чыгарачак, — шулай бу халыкларның цивилизацияләрнең даны, мирасы кешелек дөньясы хәтерендә кабат урын алачак. Эволюция процессы кешелек дөньясын бертуктаусыз алга әйдәячәк. Әмма тарихи дәверләрдә нинди кыенлыклар, киртәләр очрауга карамастан, эволюция спиралена аяк баскан адәми зат, үз-үзенә нык ышанган хәлдә, аны ахырына кадәр узу өчен барысын да эшләячәк. Күкләр билгеләгән үсеш юлыннан һаман алга — алга атлаячак...

Хикмәт шунда ки, майялар бик ерак заманнарда ук Изге Календарьлары Цолкинга кешелек дөньясы үтәчәк шушы үсеш юлын ачыклап, башын һәм азагын күрсәтеп, аны якынча 400 әр елга тиң 13 дәвергә — бактунга бүлеп, нинди дәвердә нәрсә буласын билгеләп калдырганнар. Һәм иң гаҗәбе шунда — алар планетабызда барган шушы эволюция процессын, Кояш системасына кергән планеталарның әйләнү цикллары белән үзара бәйләп, аларның барысын Галактикабызда хөкем сөргән вакыт челтәренә — вакыт константасына яраклаштыруга ирешкәннәр. Икенче төрле итеп әйтсәк, мәктәптәге дәресләр расписаниесенә аерым предмет сәгатьләрен керткән кебек, майялар да Җирдә барган тарихи процессның шул этабын төгәл билгеләп, аны Галактика расписаниесенә төгәл итеп кертүгә ирешкәннәр. Шулай итеп, Җирдә барган эволюция процессы Галактиканың вакыт челтәрендә төп-төгәл үз урынын алган, Гомуми Планның аерылгысыз һәм контрольдә тотып була торган табигый өлешенә әверелгән. Шуңа күрә дә майялар җәмгыятендә вакыт дигән төшенчә иң зур игътибар һәм кайгырту өлкәсе булган. Вакыт 5, 10, 20 ел саен махсус багана-һәйкәлләр рәвешендә билгеләнеп барылган. Менә нинди Бөек Уен Осталары була майялар! Күрәсең, юкка гына аларны Галактиканың Вакыт Сакчылары дип атап йөртмәгәннәрдер. Бу шөгыль аларның төп вазыйфасы булганга охшый.

Шушы урында алда әйтелгән фикерне раслаучы өстәмә дәлил китереп узасым килә. Эш шунда ки, бу китапны язганчы авторга мәгълүматларны төрле басмалардан бөртекләп җыярга туры килде. Китап язылды, ике еллап кульязма хәлендә тик ятты. Аны икенче кат карап, төзәтеп, кыскартып-өстәп чыгарга утырганда кайбер фактларны Күктәге Тәрбиячеләребезгә контактер аша турыдан-туры сорау биреп ачыклау мөмкинлеге туды. Шундый сорауларның берсе майялар цивилизациясенә карый иде. Бу хакта шундый сорау бирелде: "В цивилизации майя существовал культ времени. Их называют Хранителями Времени. Что означает выражение Хранитель Времени?"

Алынган җавап түбәндәгечә иде: "Дело в том, что вопрос задан не в бровь, а в глаз. Цивилизация Майя в самом деле с планеты системы Плеяд и является Хранителем Времени. Хранитель Времени — это должность, данная народу для того, чтобы обеспечить преемственность поколений, знаний и т.д. Но эта цивилизация со своей задачей не вполне справилась, распалась и самоуничтожилась, освободив место для другой, более сильной и интересной цивилизации. Задача *(цивилизации Майя)* была поставлена, цель определена, а решение было перенесено из плотного мира *(Земли)* в мир иной, где задачи остались те же, а способ исполнения изменился..."

Шулай итеп, бу хәбәрдән без майяларның чыннан да Плеяда йолдызлыгыннан килеп, Җирдә гаять үзенчәлекле цивилизация төзегән халык булганлыгын ачыклыйбыз. Өстәвенә, майяларның, төзек калаларын шул килеш калдырып, җир йөзеннән кинәт юкка чыгуының сәбәбе дә безнең өчен сер булудан туктый. Җирдә тарихи вазыйфаларын үтәп бетерү өчен Галәм тарафыннан бирелгән вакытка алар сыеша алмаган, күрәсең. Шуңа күрә майяларга урынны икенче бер цивилизация өчен бушатырга туры килгән, ә үзләре Нәфис дөньяга күчеп, вазыйфаларын анда үтәүне дәвам иттергән. Алар бүгенге көндә дә шушы эш белән шөгыльләнә — Вакыт Сакчылары вазыйфасын башкара. Шушы хәбәрләр яктылыгында фикер йөртсәк, "классик чор майялар"ның безнең эраның 830 нчы елында кинәт юкка чыгуының сәбәпләре дә тәмам ачыкланып бетә, дип әйтергә мөмкин.

Х.Аргуэльес фикеренчә, майялар кешелек дөньясын киләчәктә көтелгән Галактика масштабындагы синхронлашу-тәңгәлләшү процессына әзерләү белән шөгыльләнгәннәр. Ә бу хәл, Цолкин календарендә күрсәтелгәнчә, нәкъ 2012 ел ахырында көтелә. Төзеп калдырган Изге Календарьның киләчәктә кешелек дөньясына ничек кирәк булачагын һәм, аның серләрен ачкан очракта, кешеләрнең аңы ни дәрәҗәдә киңәячәген, адәми зат үзен Кояш системасы гаиләсенең генә түгел, Галактикадагы ифрат күп дөньяларны

эченә алган Зур Гаиләнең тулы хокуклы әгъзасы итеп хис итәчәген майялар алдан күрә белгәннәр, шуны истә тотып эш иткәннәр.

Шушы фактлар белән коралланганнан соң без инде "майя факторы" дип аталган төшенчә турында да кыенсынмыйча сүз алып бара алабыз. Гади генә итеп әйткәндә, "майя факторы" — бүгенге фәндә һәм хәзерге көндә кешелек тарихын күзаллауда әлегә чагылыш тапмаган мәгълүматлар катламын тәшкил итә. Х.Аргуэльес сүзләре белән әйтсәк, "майя факторы" дип аталган төшенчә Җирдәге цивилизацияне Галактика масштабыннан чыгып карауны аңлата. Бу инде кешелек дөньясын Галактиканың Гакыл Бергәлеге Системасы белән арадашчылык итүче әгъза буларак күзаллауны күздә тота. Майялар кешелек дөньясын Галактикадагы башка дөньялар белән бер рәткә куеп караганнар һәм аның яшәү мәгънәсе Галәм киңлекләрендә тереклек иткән күп дөньялар тарихын күздә тотып бәяләнгән. Шуңа күрә майяларның Цолкин календарендә Галактика масштабындагы гомуми караш чагылыш тапкан.

Майя җәмгыятенең мәгълүм бер дәвердә Җирдә пәйда булуы һәм бөек цивилизация төзүе очраклы хәл түгел. Алар — Галәм сәяхәтчеләре. Шуңа күрә, әгәр дә Галактиканың берәр йолдызлыгында яки берәр Кояш системасында үз-үзен аңлау дәрәҗәсенә күтәрелеп килгән планета күзгә чалынса, майялар анда килеп төшә, әлеге планетаны шушы процесска әзерләү белән шөгыльләнә башлый. Әйтергә кирәк, Галәмдә мондый изге эш белән шөгыльләнүче цивилизация бер майялар гына түгел. Аларның күбесе эшчәнлекләрен Галактиканың Намус Кодексы кысаларында алып бара.

Табигый, кемне дә булса көчләп үз асылын аңларга мәҗбүр итү мөмкин түгел. Шулай ук аңы өлгереп җитмәгән берәр дөньяны да көчләп Галактиканың Зур Гаиләсе әгъзасы булуын тану дәрәҗәсенә күтәрү мөмкин эш түгел. Әмма шушы дәрәҗәгә якынлашып килүче берәр дөньяга үз-үзен, асылын аңлауны җиңеләйтү, аңа ярдәм итү мәслихәт эш санала. Шуңа күрә үсешендә мәгълүм бер стандартка якынлашып килгән, өметле күренгән дөньяларга Галәмдәге Илаһи Көчләр тарафыннан һәрвакыт ярдәм килә. Бүгенге көндә Җир һәм анда яшәүче кешелек дөньясы үсешенең нәкъ шундый дәверенә килеп керде. Без Галәмдәге Тәрбиячеләребезнең даими күзәтүе астында гына яшәмибез, Алардан күп төрле ярдәмнәр дә алып торабыз — җир йөзендәге тоталитар режимнарның бер-бер артлы җимерелә баруы, халыкларны бер-берсеннән аерып торган идеологияләрнең берәм-берәм тарих чүплегенә чыгарып түгелүе, цензураның, сүз иркен кысуның да һаман кими баруы, бүгенге көндә күп илләрдә теләсә нинди рухи тәгълиматны чагылдырган әдәбиятның иркен сатылуы һ.б. шул хакта сөйли кебек. Шик юк, майялар әле ничә йөз ел элек шушы көннәрнең киләсен белеп эш иткәннәр, аны алдан әзерләүчеләр булганнар — Изге Календарь Цолкин шул хакта сөйли.

Анда чагылыш тапкан Бөек Дәвер 2012 ел белән тәмамлана. Шушы 5125 елга сузылган вакыт дәвамында планетабыз Галактика Үзәгеннән килгән махсус нурланышлар йогынтысында яши һәм кешелек дөньясы 13 тарихи дәвергә — бактунга бүленгән зур үсеш юлы уза. Әлбәттә, безнең эрага кадәр 3113 нче елда да, аннан якынрак дәверләрдә дә кешелек дөньясы үзе килеп кергән әлеге нурланышлар йогынтысын тояр дәрәҗәдә булмаган. Без моны шушы процессның соңгы бактунында гына, алай гына да түгел, — соңгы 13 нче бактун тәмамланырга ике дистә ел калганда гына сизә башладык. Һәм шушы елларда Җир кешесе үзенең планета язмышы өчен җаваплы зат икәнлеген аңлау дәрәҗәсенә күтәрелде. Шуңа бәйле рәвештә экология мәсьәләләренә багышланган фәнни, фәнни-популяр әдәбият, публицистика, кинодокументалистика, иҗтимагый хәрәкәтләр, бик күп оешмалар барлыкка килде. Кеше үзенең нинди хәтәр һәм җаваплы, зур үзгәрешләр һәм сынаулар чорына килеп керүен бөтен кискенлеге белән аңлады. Шушы ук елларда кешелек дөньясының нинди җаваплы дәвер кичерүен аңлаткан китаплар, брошюралар дөнья күрде. Төрле илләрдә яшәүче арадашчы — контактёрлар, Галәмдәге Затлар белән элемтәгә кереп, алардан кызыклы мәгълүмат ала, аларны бастырып чыгара башладылар. Бу китапны язып утыручы без фәкыйрегез дә безнең ил өчен өр-яңа күренеш булган андый басмаларны йотлыгып укып баручыларның берсе иде. Андый китаплар беренче тапкыр кулга килеп кергәч, нинди көчле шаккату хәлендә калуымны һич онытасым юк. Бу минем өчен бер революция булды, аңым зур тетрәнү кичерде. Таңга калу һәм соклануның чиге юк, укыганда тыннар кысыла. Бу минем өчен Христофор Колумбның Америка континентын ачуы кебегрәк бер нәрсә булды. Мондый әдәбият уннарча еллар уйлап йөреп тә очына чыга алмаган фундаменталь сорауларга әтрафлы җавап бирә иде. Андый китапларның сатыла

башлавын бер белеп алгач, аларны бөтен җирдән эзлисең һәм эзләгән саен кулыңа килеп керә тора. Башта бу хәл мине бик нык гаҗәпләндерсә дә, күпмедер вакыт узып, кайбер яшерен закончалыкларны белә башлагач, шуны ачыкладым — охшаш нәрсәләр бер-берсен тартып китерә икән. Син аларны уйларың белән үз тормышыңа тартып китерәсең, уй-фикерләрең чынбарлыкта тиешле вакыйгалар барлыкка китерә. Гап-гади канун. Шулай яшәешнең серләре акрынлап ачыла торды. Тормыш торган саен кызыклырак була барды...

Менә тагын читкә тайпылдым. Башлаган сүзгә, кешелек дөньясы узган тарихи юлларга әйләнеп кайтыйк.

Без инде беренче бактунда Җирнең "йолдыз чәчмәсе" белән орлыкландырылуын әйтеп үткән идек. Шул сәбәпле җир йөзендә бөек цивилизацияләр күтәрелә. Әгәр дә шул цивилизацияләр үткән юлны җентекләп тикшерә башласаң, аларның һәркайсында читтән килгән берәр цивилизация эзләрен ап-ачык күрергә мөмкин. Әйтик, Шумер калаларының Тигр һәм Евфрат елгалары өстенә салынган геометрик фигура — очлы почмак эчендә урнашуы, алай гына да түгел — бу калаларның әлеге почмакны хасил иткән һәм аны урталай бүлеп торган өч сызык буенча урнашкан булуы үзе үк ни тора! Галәмнән очып килгән кораблар, калалардан хасил булган шул почмакка юнәлеш тотып, аның урта сызыгы буенча хәрәкәт иткәндә җиргә якыная барган һәм почмакның нәкъ очында урнашкан изге Ниппур каласы янындагы космодромга төшә торган булганнар. Ниппур каласы — дәүләтнең үзәге, аллалар торган кала саналган.

Шулай ук Борынгы Мисыр пирамидаларының җирдә урнашу тәртибе Сириус йолдызлыгының төп-төгәл копиясен тәшкил итүе дә очраклы хәл түгелдер. Әгәр дә без Мисыр мифологиясендә һәм сәнгатендә сурәтләнгән җан ияләренең кем һәм нәрсәләр булуы белән кызыксына башласак, шулай ук күп серләр ачкан булыр идек.

Бу язмаларның максаты 5125 елны эченә алган Бөек Дәвердә кешелек дөньясының нинди үсеш баскычлары үтүен җентекләп тасвирлау түгел, — безнең максат күпкә тыйнак. Без бары тик шушы зур тарихи дәвернең башында дөньяның нинди хәлдә булганын һәм шушы дәвер тәмамланырга торган безнең көннәрдә нинди процесслар барганын бераз ачыклап кына китмәкче булабыз. Аң булып яшәр өчен!

Безнең көннәрдә бу процесска карата нинди мөнәсәбәттә булырга, үз-үзеңне ничек тотарга һәм кешелек дөньясы тарихында Сират Күпере кичүне тәшкил иткән 2012 елны ниндирәк уй-хисләр, омтылышлар белән каршыларга кирәклеген бераз гына аңлатып үтәргә булдык.

Әгәр дә без кешелек дөньясы үткән шушы 5 мең еллык дәвергә гомуми караш ташласак, иң элек тарихи процессның торган саен тизләнә, вакыйгаларның тыгызлана, дөньяда мәгълүмат алмашуның һаман саен арта баруына игътибар итәрбез. Кешелек дөньясы, үзе дә аңлап җиткермичә, каядыр ашкына, алга чаба. Аңа бөтен нәрсә күбрәк һәм тизрәк кирәк. Шушы 5 мең ел элек башланган тормышны безнең көннәр белән чагыштырсаң — аерма җир белән күк арасы. Кеше кая ашкына, нигә ашкына, аны кем һаман алга куа — ул моны белми. Кешелек дөньясы, борылган сәгать кебек, бара да бара, торган саен тизрәк атлый, эшчәнлеге һаман киңәя-колачлана бара. Моның бер зур мәгънәсе булырга тиештер бит?!

Әлбәттә, тарихи процесс булып күренгән бу тизләнүне без белгән тарихи дәверләр кысасында гына аңлатып бирү мөмкин эш түгел. Әгәр дә адәми зат бу юлдан аңлы рәвештә барса, аны әле кешенең үз инициативасыннан килә дип уйларга да мөмкин булыр иде. Әмма бу алай түгел. Бу очракта кешелек дөньясы бары тик ниндидер яшерен программаны үтәүче ролен генә үти. Димәк, бу процесс, гомумән, планетабызның эволюциясе белән бәйле. Кешелек дөньясының һаман алга ашкынуы, торган саен яңа биеклекләр яулавы, аң дәрәҗәсе үсә баруы — болар барысы да Җир-Анабыз үтәргә тиешле үсеш юлының бер элементы гына булып тора. Кендегебез Җир-Анабызга бәйләнгән, Җир безне тудыручы, туендыручы, энергия бирүче, саклаучы, безгә Галәмдә яшәү урыны бирүче. Җир безнең бишегебез, Туган Йортыбыз, Кадерле Әнкәбез. Шулай булгач, Әнкәсе куенында яшәгән адәми затның үсеше Җир белән бәйләнмәгән башка бер Программа буенча алып барыла дип уйлау ахмаклык булыр иде. Димәк, эш монда адәми затта гына түгел, ә Җир-Анабыз үтәргә тиешле эволюция юлына, Галактикадагы Югары Структуралар билгеләгән конкрет вакыт аралыгына бәйле. Һәм Галактиканың Вакыт Сакчылары саналган майялар Цолкин календаренда ул чикне 2012 ел азагы белән билгеләгәннәр. Моны ап-ачык итеп теркәп калдырганнар. Шулай итеп, Җир

Бөек Дәвер дип исемләнгән шушы вакыт аралыгына безнең эрага кадәр 3113 елда кереп, 5125 елга тиң зур тарихи юл үтеп, аннан 2012 елда чыгарга тиеш. Әмма бу әле, дин китаплары куркытканча, Кыямәт көне дә, Ахырзаман килү дә, дөнья бетү дә түгел. Бу – кешелек дөньясы өчен Олуг Имтихан, үзгә сыйфатка күчү генә. Кешелек дөньясы бетмәячәк, бары тик зур сынаулар кичереп, үсешен башка шартларда дәвам гына иттерәчәк. Яшәешнең сыйфаты, мәгънәсе үзгәрәчәк.

Бу хакта Х.Аргуэльес бик мәгънәле сүзләр әйтә: "2012 елда Планетабызның Галактик синхронлашу нурыннан чыгуы, Бөек Дәвернең тәмамлануы үзгә бер циклның башлануы булачак, шул чакта кешелек дөньясы гүя яңадан туачак, үзен беренче тапкыр күргәндәй хис итәчәк. Әмма ул инде элекке кешелек дөньясыннан нәрсәсе беләндер аерылып торачак" *( Х.Аргуэльес. Фактор Майя: Внетехнологический путь. "София", Киев, 1996. С. – 161).*

## ХИСАП КӨНЕ

Соңгы ун-унбиш елда дөньяга әллә нәрсә булды. Бу беренче чиратта планетада һава шартларының кискен үзгәрә баруында чагыла – кышлар җылы, хәтта ара-тирә яңгырлар да явып ала, җәйләр исә салкын, яшелчәләр дә өлгереп җитә алмый. Дөньяда һәлакәтләр күбәеп китте, бер сәбәпсез дигәндәй, илләрне тоташ су баса, зур-зур мәйданнарда айлар буе янгыннар котырына, төрле җирләрдә локаль сугышлар кабынып китә, дини каршылыклар, социаль тетрәнүләр көчәя, тоталитар режимнар егыла... Шунысы гаҗәп – хөкем сөргән шушы хаос һәм буталчыклыкка карамастан, илләр һәм халыкларның үзара якынаю юллары эзләве, шул нигездә дөньяда барган хәлләргә уртак караш һәм мөнәсәбәт булдырырга тырышуы да күзгә нык ташлана, гүя алар планетада бергәләп яшәү кагыйдәләре, ысуллары табарга омтылалар. Шушы хәлләрне күзәтеп торган кешедә ниндидер көчләр кешелек дөньясы үзенең яшәү рәвеше һәм киләчәге турында уйлансын өчен мондый вәзгыятьне махсус тудырмыймы дигән фикер дә туа.

Соңгы елларда шомлы фаразлары белән кеше күңеленә хәвеф салучы күрәзәчеләр һәм ялган пәйгамбәрләр дә күбәеп китте. Астрология чәчәк ата, кулына газит-журнал алган кеше иң элек анда урнаштырылган йолдызнамәгә күз салырга ашыга, буталышкан дөньяга кереп чумган адәми затның үзен ни-нәрсәләр көткәнен беләсе, эш-гамәлләре һәм язмышы турында мәгълүмат аласы килә. Чыннан да, соңгы ун елда бигрәк тә ярсып киткән дөнья кеше күңелендә хәвефле уйлар кузгата: бу хәлләр нәрсә белән бетәр? Кая барабыз? Безне алда ниләр көтә? Бер нәрсәгә ышанып бетеп һәм алдан планлаштырып булмый торган мондый болгавыр заман тагын күпме дәвам итәр?

Әйе, буталчыклык, билгесезлек хөкем сөргән мохиттә яшәү кешегә зур кыенлыклар тудыра – бу стресс китереп чыгара, көчне ала. Адәм баласы үз-үзенә ышанган хәлдә тормышын нык нигезгә корырга омтыла, әмма барысын аңлатып биргән, күңелгә ышаныч һәм ныклык иңдергән чын хакыйкатьне ачып салучы юк, бары тик дөреслеге шик тудырган фаразлар, пәйгамбәрлек итүләр, чамалаулар гына бар. Билгесезлектә һәм борчу хисләренә уралып яшәгән адәми зат, аптырагач, дин китапларына мөрәҗәгать итә, анда күп гасырлар буе кешелек дөньясының исенә төшерелеп килгән Ахырзаман, Кыямәт көне, Мәхшәр көне хакындагы урыннарны эзләп таба. Шулай аның күз алдына заманнар төкәнгәндә кешелек дөньясы кичерәчәк дәһшәтле Хисап көне күләгәсе килеп баса.

Бәлки, кешелек дөньясы шушы илаһи вакыйгага – Хисап көненә якынлашып киләдер, бәлки, тиздән җир йөзендә зур һәлакәтләр башланып, диннәрдә күрсәтелгәнчә, адәм балаларын Раббыбызның ышанычын аклаганнарга һәм Ул күрсәткән юлдан бармаганнарга бүлү булачактыр? Безгә мәгълүм классик диннәрнең Төп Китаплары барысы да шул хакта сөйли түгелме соң? Барысы да, заманнар төкәнгәндә кешелек дөньясын Хисап көне көтә, адәм балалары кылган гамәлләре өчен имтихан тотачак, дип күрсәтә түгелме соң?

Борынгы классик диннәрдән саналган иудаизм, ягъни яһүдиләр дине "Даниил пәйгамбәр китабы"нда *(ул Ветхий Завет – Иске Гаһедтә урын алган)* бу Көн турында түбәндәгеләрне сөйли – бәян Даниил пәйгамбәр исеменнән алып барыла:

"Менә, ниһаять, мин тәхет куелганны һәм шул тәхеттә Ходайның *(Библиядә — Вегхий Днями)* урын алганын күрдем. Аның өстендә кардай ак кием, чәчләре саф дулкын сыман, тәхете ут ялкынындай, аның тәгәрмәчләре — уттай дөрлиләр. Аның алдыннан сузылып утлы елга ага; Аңа меңнәр һәм меңнәр хезмәт күрсәтә, бихисап халыклар язмышы хәл ителгәнне көтеп Аның алдында тора. Хөкемдарлар урын ала һәм Китаплар ачыла". *(7 : 9–10)*

"Китаплар"ның нинди китаплар икәнен аңлатып торуның, бәлки, кирәге дә юктыр. Һәркем диярлек җир йөзендә кылган барлык эш-гамәлләре өчен генә түгел, әйткән сүзе, хәтта уйлаган уе өчен җавап тотачагын белә булса кирәк. Шушы Гамәл Китапларында тупланган мәгълүматларга карап һәркемгә бәя бирелә һәм Раббыбызның хөкеме чыгарыла.

Даниил пәйгамбәргә бу манзара әле безнең эрага кадәр үк күрсәтелә, ул дәвердә Хисап көненә әле бик ерак була. Шулай да киләчәктә кешелек дөньясын җитди сынаулар көткәне адәм балаларының хәтеренә салып куела, ул Көнне беркемнең беркемгә ярдәм итә алмаячагы турында кисәтелә, гамьсез кешелек дөньясының моны истә тотуына өмет ителә.

Гасырлар артыннан гасырлар уза, Җирдә тормыш үзгәрә тора, мәшһүр патшалыклар, дәүләтләр бер-бер артлы тарих томаны эченә кереп гаип була бара. Адәми зат акрынлап белем һәм акыл туплый, күп нәрсәләргә өйрәнә. Элегрәк бирелгән диннәр тора-бара искерә, заман таләпләренә җавап бирми башлый. Шулай яңа рухи тәгълимат сыйфатында христиан дине туа. Гайсә пәйгамбәр исеменә бәйле бу дин адәм балаларына үзгәрәк рухи кыйммәтләр һәм башкача фикер йөртү, яшәү рәвеше тәкъдим итә.Яңа Гаһедтә *(Новый Завет)* урын алган "Иоанн Богословка ачылганнар" *("Откровение Иоанна Богослова")* дип аталган китапта киләчәктә Җирдә Хисап көне булачагы тагын бер кат искә төшерелә:

"Мин күз салдым һәм ак болыт күрдем, болыт өстендә Адәм Углы сыман берәү *(Библиядә кайвакыт Иисус Христос шулай дип атала — С.Ш.)* утыра иде: башында алтын таҗ, кулында үткен урак. *(Күктәге)* гыйбадәтханәдән бер фәрештә чыкты да болытта утыручыга көчле тавыш белән әйтте: "Урагыңны эшкә җик, ура башла, чөнки уракка төшәр вакыт җитте, җирдә игеннәр инде өлгерде". Һәм болытта утыручы урагын җиргә төшерде. Һәм җирдә игеннәр урып алынды". *(14: 14–16).*

Библиядә кешелек дөньясы үтәргә тиешле имтихан шундый символлар аша тасвирлана. Урак — Раббыбыз кулындагы Илаһи Корал, Аның Ихтыяры, ә Җирдә өлгергән игеннәр — Хисап көне аша үтәргә тиешле кешелек дөньясы. Сынау Көне инде якынлашып килә. Менә ни сәбәпле Яңа Гаһедтә кешегә бик тә таныш күренеш — игеннәрне уру сурәтләнә.

Чыннан да, кешелек дөньясы Раббыбыз тарафыннан чәчелгән иген кыры түгелмени? Табигый, вакыты җиткәч, бу кырдан мул уңыш җыеп алу күздә тотыла. Менә шушы символик картина аша адәм балаларына Хисап көненең ничегрәк узачагы күрсәтелә. Әмма сынау көннәре әле килеп җитмәгән, яшәү тәртибеңне үзгәртергә һәм тәүбә кылырга вакыт бар.

Әмма христиан дине дә үз вазыйфасын үтәп җиткерә алмаганга охшый. Тора-бара Гайсә пәйгамбәр аша бирелгән тәгълимат зур үзгәрешләр кичерә, аның асылы бозыла, яңа дин төрле тармакларга бүленә. Бер сүз белән әйткәндә, бу дин дә үзенең баштагы сафлыгын саклап кала алмый.

Хисап көне дигән төшенчәне тарихи перспективада тикшерә башласаң, ирексездән, бер күренеш игътибарны җәлеп итә. Әйтик, әгәр дә яһүдиләр динендә бу дөньякүләм вакыйга эпик картиналар аша гаять тыныч рәвештә бирелгән булса, христиан диненә караган чыганакларда ул кешелек дөньясы кылган гамәлләрдән күңел кайту, борчылу, хәтта ярсу хисләре белән тасвирлана. Текстка ныклап кисәтү, куркыту төсмерләре килеп керә *("Иоанн Богословка ачылганнар"да)*:

"Ул Ходайның ярсу шәрабен эчәр, көчле шәрабен, Аның нәфрәтендә кайнап чыкканын...". *(14: 10).*

"Һәм Фәрештә урагын җиргә төшерде, һәм җирдә йөземнәрне кисеп алды, һәм Ходайның бөек ачуы чарына ыргытты". *(14: 19).*

"Һәм мин гыйбадәтханә эченнән җиде фәрештәгә әйтелгән көчле тавыш ишеттем: барыгыз һәм Ходай ачуының җиде касәсен җир өстенә түгегез". *(16: 1).*

Вакытлар үтү белән тарих мәйданында соңгы классик дин — Ислам урын алгач,

Раббыбызның кешелек дөньясы кылган гамәлләрдән разый булмавы үзен бик нык сиздерә һәм бу хәл Коръәндә дә чагылыш таба. Коръән Хисап көнен, Мәхшәр көнен, Кыямәт көнен кешелек дөньясы тарихында көтелгән иң зур вакыйга буларак гел искә төшереп тора. Һәм аны бик якын торган вакыйга буларак тасвирлый.

*"Әй, кешеләр!*
*Раббыгыздан куркыгыз.*
*Чөнки ул Сәгатьтәге сынаулар*
*Бик дәһшәтле булачак". (22 : 1).*

Аллаһ тарафыннан билгеләнгән бу Көндә *(Сәгатьтә)* башланган коточкыч һәлакәтләр җир йөзен бөтенләй танымас хәлгә китерәчәк. Кешелек дөньясы бу көнне Соңгы Сынауны узачак. 81 нче сурәдә ул менә ничек сурәтләнә:

"Кояш бөрешеп калыр, йолдызлар таркалыр, таулар кубарылыр, дөяләр караучысыз булыр, кыргый җәнлекләр бер урынга тупланырлар, диңгезләр күпереп ярларыннан чыгар, җаннар *(кылган эшләренә карап)* бер-берсеннән аерылыр, тереләй җиргә күмелгән кыз баладан: "Нинди гөнаһың өчен сине харап иттеләр?"—дип сорарлар; Гамәл Дәфтәрләре ачылып *(бар нәрсә)* фаш ителер, күкләр бушап калыр, җәһәннәм ут бөркеп торыр, җәннәт якынаер,—шул чакта һәр адәми затның җаны үз-үзенә ниләр әзерләгәнен ап-ачык күрер". *(81: 1–14).*

Һәм Хисап көненең тетрәндергеч манзарасын сурәтләп күрсәткәннән соң кешелек дөньясына Аллаһ исеменнән фундаменталь сорау бирелә:

*"Кая юл тотасыз?*
*Бу бит халыклар өчен,*
*Туры юлдан барырга теләгәннәр өчен*
*Бер вәгазьдер". (81: 26–28).*

Әйе, кешелек дөньясы яшәгәндә бу бөек сорау беркайчан да үзенең актуальлеген югалтмаячак. Аңа төгәл җавап таба алмыйча, әллә инде табарга да теләмичә, менә без өченче меңьеллыкның капкаларын ачып кердек—әгәр вакыт исәбен Гайсә пәйгамбәрдән саный башласак. Аңа кадәр күпме меңнәр, миллион еллар узганын бер Раббыбыз үзе генә белә. Кешелек дөньясы инде сабый бала түгел—байтак дәверләрне кичерде, нәтиҗә ясар вакыт җитмәдеме? Ә нәтиҗәне Раббыбыз үзе ясый—Хисап көне аша. Ә Хисап көненә барыбыз да ышанабызмы соң? Күпчелек аны куркытып тәрбияләү максатыннан уйлап чыгарылган әкият, дини мифология дип санамыймы? Ә Күкләрнең меңнәрчә еллар буе җир йөзендә таралган рухи тәгълиматлар аша безгә ирештереп торган кисәтүе әкият яки уйдырма була аламы? Алай дип уйларга берәр төрле нигез бармы? Бәлки, кемдер без корган дөньяны, моннан 12,5 мең ел элек булып узган Атлантида һәлакәтеннән соң кабат аякка баскан дөньяны, иң алдынгы һәм камил акыл белән төзелгән дөнья дип саный торгандыр. Бәлки, кемдер үтеп киткән берничә мең ел эчендә безнең нинди комфорт һәм фән–техника казанышларына ирешүебезне дәлил итеп китерергә җыенадыр. Ул чакта ни өчен Җирдә яшәү елдан-ел кыенлаша бара, саф һава, чиста су һәм чиста азык-төлек кимегәннән кими? Гарип туган балалар саны арта? Без төзегән коточкыч зур калалар Җир тәнендәге яман шешне хәтерләтә, аларда яшәү елдан-ел авырая, кешеләр машина төтененнән тончыга. Бәс, шулай икән, димәк, без корган дөнья бигүк дөрес юлдан бармыйча, ниндидер ялгыш юнәлешкә кереп киткән түгелме? Һәм кабат безнең алга Коръәндәге төп сорау килеп баса:

" Кая юл тотасыз?.."

Бу сорауны безгә Раббыбыз Үзе бирә, бу сорау кешелек дөньясы өчен бер заманда да көн тәртибеннән төшмәде һәм төшмәячәк. Бу сорау адәми заттан һәрвакыт акыл һәм рухият таләп итте. Әмма аны ишетүчеләр, колакка алучылар гына санаулы булды. Инде менә барысы өчен дә җавап бирер, өлгергәнлегебезгә имтихан тотар вакыт җитте.

## 2.

Заманнар төкәнгәндә кешелек дөньясының зур сынаулар һәм тетрәнүләр аша үтәчәге турында диннәр генә түгел, башка чыганаклар да искә төшереп торды. 20 йөз, бигрәк тә аның икенче яртысы Кешелек Дөньясы Остазларыннан килгән мөрәҗәгатьләргә гаять

бай булды. Аларда кешелек дөньясының тиздән өр–яңа үсеш дәверенә керәчәге, Җирдәге тәртипләрнең һәм яшәү рәвешенең үзгәрәчәге, адәмнәрнең бераздан башка нигезләргә корылган яңа дөньяга аяк басачагы турында әйтелеп килде. Бу яңа дөньяга аяк басар алдыннан кешелек дөньясы Хисап көне аша үтәчәк. Хисап көне адәм балалары өчен Яңа Дәвергә атлап керү имтиханын тапшыруның бер баскычы булачак. Бу Яңа Дәвердә планетабыз рухи яктан югарырак дәрәҗәгә күтәреләчәк,—нәкъ шул сәбәпле, вакыты җиткәч, Хисап көне үткәрү планлаштырылган була да инде. Моннан ничә мең еллар элек! Аның барышында кешеләр рухи өлгергәнлек җәһәтеннән Раббыбыз таләпләренә җавап бирүчеләргә һәм җавап бирмәүчеләргә бүленәчәк. Ашлыкны кибәктән аеру булачак.

Шулай да, бу Хисап көне дигәннәре кайчан булачак соң? Гомумән, ул булачакмы? Күп дәверләр буе ул Күкләрнең төп сере була килде. Җирдә яшәгән бер генә кеше дә аның төгәл вакытын белә алмады. Һәм шунысы сәер—диннәрнең әлеге мәсьәләне гел кузгатып, искә төшереп торуына карамастан, Хисап көне һаман саен ерак киләчәккә чигерелеп килә. Бу хәл Яңа Гаһедтә дә чагылыш таба, анда апостол Петр исеменнән болай диелә:

"Сезгә бер нәрсә ачык булырга тиеш, газизләрем, Ходайның бер көне мең елга тиң һәм мең елы бер көн кебек. Кайберәүләр моны акрынлык дип уйласа да, Ходай вәгъдәсен үтәми калмый; Ул безгә карата түземлелек күрсәтә, берәүнең дә һәлак булуын теләми, барлык кешеләрнең дә тәүбәгә килүенә өметләнә. Ходайның ул көне, төнге угры сыман, сиздермичә килер, һәм күкләр, тавышлар чыгарып, урыныннан күчәр, уянган табигать көчләре таралыр, Җир һәм андагы бар нәрсә янып бетәр". *(Петрның 2 нче хаты. 3 : 8–10).*

Бу мәсьәлә гасырлар, мең еллар буе фәһемле кешеләргә тынычлык бирмәгән, алар аңа җавап табарга тырышкан. Коръән дә аны әйләнеп узмый:

"Кыямәт Сәгатенең кайчан сугачагын бары тик Аллаһ кына белә". *(31 : 34).*

Икенче бер урында Яңа Гаһедне сүзгә-сүз диярлек кабатлый:

"Ул Сәгать *(Хисап көне)* һичшиксез киләчәк. Мин *(аның кайчан киләчәген)* белгертмәм. Һәркем ни кылса, шуның әҗерен алсын, дип". *(20 : 15).*

Әмма Аллаһ кешелек дөньясының әхлакый халәтен әйбәт белә, шуңа күрә аның рухи яктан уянуына артык өметләнми:

"Кыямәт көне һичшиксез киләчәк! Монда бернинди шик тә булуы мөмкин түгел. Тик кешеләрнең күбесе моңа ышанмый". *(40 : 59).*

Менә шулай бернигә ышанмыйча без инде өченче меңьеллыкка килеп кердек. Телевизор экраннарына, гәзит-журнал битләренә күз салыгыз—анда мондый мәсьәләләр күтәреләме? Үзара сүз берләшеп, дөньяның үсеш тенденцияләренә юнәлеш бирүче дәүләт җитәкчеләре мондый мәсьәләләрне күтәреп чыгамы? Халыкара сәясәт, икътисад, банк системасы, сәүдә, сугыш һәм солых мәсьәләләре—менә нинди темалар даими игътибар үзәгендә. Әмма мондый очрашулар вакытында кешелек дөньясының рухи халәте һәм аны яңа баскычка күтәрү юллары турында кайчан да булса сүз алып барылганы бармы? Бу хакта ләм-мим, гүя аңа "табу" салынган диярсең. Мондый мәсьәләләр бары тик галимнәрнең тар даирәсендә генә тикшерелә. Ә аларның сүзенә кем колак сала?

Әйтергә кирәк, булачак Хисап көне турындагы хәбәрләр кешелек дөньясына күптән бирелеп килә һәм заманча, фәнни яктан нигезле итеп бирелә. Баштарак әлеге материалларда көтелгән Хисап көне кисәк кенә үтәргә тиешле процесс буларак тасвирлана иде. Бу борынгы вариант буенча, Раббыбыз тарафыннан билгеләнгән Хисап көне беркем көтмәгәндә-искәрмәгәндә килә һәм шул вакытта бөтен кешелек дөньясына һәм аерым кешегә илаһи хөкем чыгарыла. Әмма тора-бара бу Программага үзгәрешләр кертелде һәм алар гаять җитди үзгәрешләр булып чыкты.

Хикмәт шунда ки, кешелек дөньясы үзенең үсеш темплары, рухи халәте белән Хисап көнен уздыруның Әүвәлге Планы кысаларына һич тә сыя алмый, ул үсешендә гел каядыр читкә тайпыла, артка кала, шул сәбәпле аның үсеше тоткарлана килә. Әгәр дә бу шартларда Хисап көне борынгы вариант буенча берьюлы үткәрелсә, кешелек дөньясы артык зур югалтулар кичерер иде.

Чыннан да, Раббыбыз тарафыннан яраттылган һәр җан гаять зур үсеш юлы узган һәм Раббыбыз аны югалтырга теләми. Җаннар Җирдә һәм башка дөньяларда күп тапкырлар гәүдәләнгән, аларны тәрбия кылуга һәм эволюция юлыннан алып баруга күп көч, хезмәт һәм вакыт сарыф ителгән. Һәм шундый җанны югалту исраф ителгән энергияне, вакытны әрәм итү булыр иде. Шул сәбәпле бер селтәнүдә "ашлыкны кибәктән

аеру"га караганда кешеләргә котылып калу мөмкинлеге бирү дөресрәк түгелмени?

Шулай килеп туган вәзгыять аркасында Раббыбыз Әүвәлге Планына кайбер үзгәрешләр кертә, Җирдә Хисап көнен үткәрүнең йомшаграк вариантын сайлый. Бу процесс 1998 елның 5 июлендә бирелгән бер мәгълүматта бик ачык чагылыш таба *(текстның төгәллеген саклау өчен аны тәрҗемә итмичә генә китерәбез)*:

"...в данное время условиями спасения и выживания людей будет принятие новых идей, воззрений, которые будут направлены на изменение физических тел людей. Новое мировоззрение приведет в работу новый механизм вибраций, которые в свою очередь, заставят по другому работать клетки организма, перестраивая его постепенно в нужном для эволюции направлении. Это совершенно новый прием постепенного, плавного перехода человечества в новое качество. Это Час "Х" протяженный во времени" *(Exsodus. Послания Иерархов группе русских учеников. Книга 4. С.-Петербург, 1999. -С. 218).*

Шушы фундаменталь мәсьәләне хәл итүдә Раббыбыз, Аның күпсанлы Ярдәмчеләре генә түгел, сәләтләрен ачкан кешеләр дә катнаша.

1998 елның 3 августында бирелгән мәгълүматта мәсьәлә тагын да ачыклана төшә: "Российские контактеры совместно с посредниками из Америки и некоторых других стран дают человечеству огромные сведения от Вознесенных Владык и представителей других Галактик, других Солнечных Систем. (...) Все в Космосе, во Вселенной находится в напряженном ожидании решающего поворотного момента. Великие труды Космической Иерархии с совместными усилиями воплощенного человечества дали возможность изменить Планы Единого.

Поворотный момент *(Хисап көне – Ш.С.)* не будет сиюминутным, то есть слишком скоротечным Часом "Х", но при содействии продвинутых духовно душ человеческих, будет проходить плавно с наименьшими болезненными приемами, которые, так или иначе, необходимы для очистки светлой силы от тьмы. Для нас – момент, для человечества – это могут быть годы..." *(Шунда ук. 303 – 304 б.).*

Бу хәбәрнең Санкт-Петербургтагы төркемгә 1998 елның 3 августында тапшырылуын тагын бер кат искә төшереп үтик.

Шулай итеп, Раббыбыз Әүвәлге Планын үзгәртә һәм шул сәбәпле Хисап көнен йомшаграк рәвештә, берничә өлешкә бүлеп үткәрү көн тәртибенә килеп баса. Дөнья меңәр еллар буе адәм балаларының исенә төшерелеп килгән шушы Олуг Көнне көтеп яши башлый. Ул Көн килдеме, килсә – ничек килде?

***

Хисап көне якынлашуын бөтенләй белмәгән кешелек дөньясы үз мәшәкатьләре белән яшәвен дәвам итә. Әмма инде Сәгать сугар көн котылгысыз рәвештә якынлаша бара, тик аның төгәл вакыты бер Раббыбызга гына билгеле була. Ниһаять, ул Көн килеп җитә, Сәгать суга.

Әгәр дә без ул көнне чыккан абруйлы дөнья газитләренә күз салсак, кешелек дөньясының язмышы хәл ителгән шундый көндә адәм балаларын нинди мәсьәләләр кызыксындырганын ап-ачык күрер идек. Шуннан чыгып кешелек дөнъясының рухи-әхлакый халәтен дә чамаларга мөмкин.

Инде әйтелгәнчә, Раббыбыз кешеләрне саклап калу өчен Хисап көнен йомшаграк рәвештә үткәрүне кулай дип таба, дөньяны кара көчләрдән чистарту өчен, сынауларны берничә өлешкә бүлеп уздырырга һәм кешелек дөньясын рухи яктан яңа сыйфат дәрәҗәсенә күтәрергә карар кыла.

Әйтергә кирәк, кешеләр гомер-гомергә Хисап көне, Кыямәт көне белән кызыксынып килгәннәр, аның төгәл вакытын белергә омтылганнар. Бу хәл дини чыганакларда да чагылыш таба, шул исәптән Коръәндә дә әлеге мәсьәлә күтәрелә:

"Синнән Кыямәт көненең кайчан киләчәген сорыйлар. Әйт син аларга *(и Мөхәммәд)*: "Бу хакта Аллаһ үзе генә белә, диген. Аның вакытын Аннан башка зат ачыклый алмас. Күкләр вә җирдәгеләр өчен бу кыен мәсьәлә. Ул *(Көн)* сезгә көтмәгәндә килер". *(7 : 187).*

Чыннан да, Хисап көне кешелек дөньясы һич көтмәгәндә башлана. Бу хәл 2002 елның 2 июнендә 00 сәгать 02 минутта була һәм 2 минут дәвам итә. Шул ике минут вакыт эчендә Җир планетасындагы бөтен нәрсә Хөкем үлчәве аша уза. Шул ук көнне контактёр иптәшебезгә Раббыбыздан хәбәр килә:

"Шушы көннән Җирдә Хисап көне башлана. Һәркем ни кылган булса, шуның әҗерен алачак. Һәр кешегә үзенә тиешле урын әзерләп куелган. Сүз белән гамәл – ул сәбәп һәм аның нәтиҗәсе, кылган эшең һәм аның өчен җавап тоту. Элекке тормышларда булган гөнаһларны Мин гафу итәм, бу тормышта кылганнар өчен җавап бирергә туры киләчәк. Хисап көне Җирне явызлыктан һәм әшәкелектән чистартачак, Җирнең үсешен бик нык алга җибәрәчәк һәм аңа дөньядагы иң гүзәл цивилизацияләрнең берсенә әверелергә ярдәм итәчәк. Амин. Раббыгыз. 2.06.2002".

Вакыйгаларны бераз ашыктырып, алга сикереп, әлеге планетакүләм вакыйгага Раббыбыз тарафыннан соңрак бирелгән аңлатманы китереп үтү дөрес булыр сыман. 2003 елның 26 маенда алынган хәбәрдә шундый нәтиҗә ясала:

"Хисап көне кешелек дөньясының бик күп проблемаларын ачып салды, аларны хәл итәргә кирәк. Кешелек дөньясының бер халәттән икенче халәткә күчәргә әзер түгеллеге ачыкланды, гади генә итеп әйткәндә – ул чистарынырга һәм яхшырырга әле әзер түгел. Ул әлегә тирес өстендә азык эзләп чокынган карганы хәтерләтә, тирә-якта ни барганын да, үзенең нинди хәлдә икәнен дә аңларлык дәрәҗәдә түгел. Явыз көчләр моннан бик оста файдалана, аның башын миңгерәйтә һәм ялгыш юлга өстери. Мондый үсеш юлы – илаһи юл түгел һәм ул кешене тупикка алып бара... Кешелек дөньясының 82 проценты үзе яшәгән сазлыктан чыгарга әзер, 4 проценты икеләнә, сазлыкта калуны кулай күрүчеләр 14 процентны тәшкил итә. Амин. Раббыгыз. 26.05.2003".

Шулай итеп, Җирдә узган Хисап көне кешелек дөньясының нинди рухи халәттә яшәвен тулысынча ачып сала. Аның хәле бик авыр булганга, сынауны уза алмаган кешеләрне коткару өчен өстәмә чаралар үткәрү сорала. Сынауны үтә алмаганнар әле артык күп була. Аларны коткарып калу өчен нишләргә кирәк соң? Беренче чиратта, кешенең энергетикасын нормаль хәлгә китерү сорала. Начар энергетика – ул төрле авырулар, газаплар, таушалган нервлар, тормыштан ризасызлык һәм шулар нәтиҗәсендә дөньядан иртә китү дигән сүз. Болар кемнәргә файдалы соң? Әлбәттә инде, кара көчләргә. Алар фәкать тискәре хисләр энергиясе белән туенып яши.

Көн тәртибенә кешеләрне коткарып калу мәсьәләсе бөтен кискенлеге белән килеп баса. Ә моны Раббыбыз Үзе генә башкарып чыга ала. Илаһи энергияләр тылсым көченә ия. Әмма Җирдә зур сынаулар – Хисап көне башлануын һәм нинди процесслар барганын белмәгән адәм балалары тормышны элеккечә дәвам итә – бер-берсенә зыян сала, алдаша, гөнаһларын арттыра, әхлак кануннарын бозып, Раббыбыздан һаман ераклаша бара. Шулай кешеләр үз-үзләрен пычрак энергетика белән тутыра, пычрак энергетика исә тора-бара төрле авырулар рәвешендә физик тәндә төртеп чыга. Хәлнең берничек тә яхшырмавын күреп торган Раббыбыз Җирдә башланган Хисап көнен дәвам иттерергә карар кыла.

Шулай Хисап көне сынауларының икенче этабы – Мәхшәр көне килә. Мәхшәр көне 2002 елның 27 декабрендә 6 сәгать 25 минутта башлана. Берничә айдан соң, ягъни 2003 елның 6 апрелендә Раббыбыздан килгән хәбәрдә бу сынауның мәгънәсе болай аңлатыла:

"Дөнья икенче тапкыр Хисап көне аша узды, бу юлы зуррак таләпләр куелды. Кешеләрнең 20 проценты Мәхшәр көне сынавын узды, 80 проценты уза алмады. Алар иң кадерле нәрсәләрен югалтты – аурасыз, энергетик тәнсез һәм җансыз калды. Проблемалары артты..."

Хисап көне узганнан соң адәм балаларын тагын да җитдирәк сынау – Мәхшәр көне аша үткәрү нигә кирәк булды икән соң? Югарыда китерелгән хәбәрнең дәвамында бу сорауга ачык җавап бар: "Моның сәбәбе – кешеләрнең үз көчләренә артык ышануында һәм, Ходайны онытып, үзләрен Аңа каршы куюында. Дөнья куу, матдиятчелек рухияттан өстен куелды, мал-мөлкәт туплау омтылышы кеше акылын буйсындырды. Матдиятчелекнең рухияттан өстен куелуына түзеп тору мөмкинлеге калмады".

Кешеләрдәге рухият белән матдият плюс 6 белән минус 6 арасында тирбәлгән диапазонда чагыштырылса, Раббыбыз аларның нисбәтен түбәндәгечә билгели: кешеләрдә матдият плюс 6 *(ягъни 100 процент)*, ә рухият бары тик минус 4 дәрәҗәсендә генә калган. Һәм шул ук хәбәрдә мәсьәләгә өстәмә ачыклык кертелә: "Кеше аңындагы мондый тайпылыш аның рухи үсешен туктатты. Бу әле кешеләр азрак укый башлады дигән сүз түгел, әмма уку аларга инде рухи үсеш бирми, киресенчә, читкә алып китә иде. Ак һәм кара көчләр арасындагы каршылык шушы нигездә барлыкка килде. Һәр көч кешелек дөньясын үз ягына тарта иде".

Җир йөзендә дәвамлы Хисап көне үткәрү моның белән тәмамланмый, адәм балаларына ярдәм итү йөзеннән Раббыбыз аларга Амнистия бирә. Амнистия, билгеле булганча, гөнаһларны кичерүне аңлата, гәрчә, монда һәркем һәм һәрвакытта да лаек булып чыга алмаса да. Һәрхәлдә, кешегә амнистия бирү—ул аның гөнаһларын аванс рәвешендә гафу итүне һәм киләчәктә тәртибенә карата ризасызлык булмауны күздә тота.

Раббыбыз тарафыннан ясалган Беренче Амнистия 2003 елның 25 гыйнварында 17 сәгать 02 минутта үтә. Мәхшәр көне белән Беренче Амнистия арасындагы бер ай вакыт эчендә кешеләрдә берәр төрле үзгәреш булганмы соң, дигән сорау туа. Бу сорауга Раббыбызның 2003 елның 6 апрелендәге хәбәрендә ачык җавап бар:

"**Беренчедән**, кешеләр үзләрендәге саулык энергетикасын, яшәү энергетикасын, аң энергетикасын югалттылар.

**Икенчедән**, элекке чирләре тагын да көчәеп китте һәм катлауланды.

**Өченчедән**, кеше килеп туган вәзгыятьтән чыгу юлын күрми һәм аңа беркем дә ярдәм итә алмый иде.

**Дүртенчедән**, бу хәл аның дөньяда яшәү вакыты бетеп килүне аңлата иде. Кешеләр авырый һәм дөньядан китә башлады, бу хәл кара көчләрнең энергетик яктан көчәеп китүенә китерде, аларның энергетикасы һаман ныгыды, үзләре үрчеде һәм Җирдә явызлык арткannan-арта барды. Әгәр дә Мәхшәр көнен үткәргәндә *(27.12.2002)* дөньяда явызлык энергиясе минус 2 дәрәҗәсе белән билгеләнсә, бер айдан соң, кешеләргә Беренче Амнистия ясалган көнне *(25.01.2003)*, явызлык энергиясе инде плюс 6 га кадәр җиткән иде".

Раббыбыз тарафыннан кешеләргә ясалган Беренче Амнистия нәтиҗәсендә явыз көчләрне туендырып торган энергия каналы ябып куела.

Кабат Раббыбыздан алынган хәбәргә мөрәҗәгать итик:

"Мәхшәр көне сынавын үтеп, адәми зат нәрсәгә ирешә соң? Амнистия алганнарга яшәүләрен дәвам итәргә мөмкинлек бирелде. Аларда кабат аура, энергетик тән һәм җан барлыкка килде. Мәхшәр көне сынавын уза алмаганнарның хәле гаять катлауланды, авырулары көчәйде һәм алар өчен дөньядан китү вакыты якынайды".

Һәм бу хәбәр аяныч нәтиҗә белән тәгалләнә: "Мәхшәр көне узды. Кешеләрнең хәле гадәттән тыш авыр. Аларны бер Раббыбыз гына дәвалый ала".

Җир йөзендә вакыйгалар куергannan-куера барса да, алар яшерен тестә алып барыла. Кеше дигәнең үзенең гадәти эшләре белән шөгыльләнә, планнар кора, тик күпчелек кешеләр үз язмышының үзенең рухи-әхлакый халәтенә, яшәү һәм фикер йөртү рәвешенә, тәртибенә бәйле булуын аңлаудан әле бик ерак тора. Беренче Амнистиядән соң бер ай чамасы вакыт узгач, 2003 елның 22 февралендә 18 сәгать 25 минутта Раббыбыз адәм балаларына ярдәм кулы сузу йөзеннән Җирдә Икенче Амнистия ясый. Шулай кешеләрне дәвалау һәм коткару дәвам итә. Амнистия ясалган саен кешегә Җирдә яшәү, Раббыбыз күрсәткән юлга аяк басу, Аның кануннарын үтәү мөмкинлеге тудырыла.

Ә без, адәмнәр, Раббыбызның бу Рәхмәтләрен ничек кабул иттек соң? Күпчелек кешеләр: "Ә без берни белмәдек!"—дип җавап бирер. Алдан кисәтелеп куелгач, ул Хисап көне буламыни?! Дин китаплары аша гасырлар буе бу хакта искә төшерелеп киленмәдемени? Хисап көне сиздермичә килер, дип кисәтелмәдемени? Ә безнең күңелебез, интуициябез, җаныбыз нигә аваз салмаган? Әллә инде без, матди тормышка артык бирелеп китеп, аларның барлыгын бөтенләй диярлек оныттыкмы? Ничәшәр мәртәбә Җирдә гәүдәләнеп яшәгән җаныбыз, күп цивилизацияләрдә тәҗрибә һәм гакыл туплаган илаһи җаныбыз ни өчен шундый сынаулар якынлашуын безгә белгертмәде, искәртмәде икән соң? Ул бит барысын да сизә, белеп тора. Ни өчен без аңа мөрәҗәгать итмибез дә аның пышылдавын ишетергә теләмибез? Әллә инде аның барлыгын бөтенләй оныттыкмы? Аның Раббыбыз тарафыннан безгә бүләк ителгән илаһи очкын икәнен истән чыгардыкмы?

Әмма Раббыбыз моның белән Җирдә башланган чистарту процессын, кешелек дөньясын иләк аша үткәрүне туктатмый, күбрәк җаннарны саклап калу өчен, Өченче Амнистия ясый. Аның алдыннан контактёр иптәшебез аша шундый хәбәр алына:

"Бүген 2003 елның 28 мартында Җирдә бик зур вакыйга булачак. Бу көн кешеләрнең хәтеренә уелып калачак, чөнки ул Җирдәге кешелек дөньясы өчен төп вакыйгаларның берсе буларак теркәлеп калачак. Бу вакыйга Өченче Амнистия дип атала. Ул 19 сәгать 15 минутта көтелә. Бу Амнистия адәми затка нәрсә бирә соң? Беренче һәм Икенче

Амнистияләр кешеләрнең Ходай тәгалә рәхмәтен кабул итәргә һәм рухи үсеш юлына басарга әзер түгеллеген күрсәтте. Шуңа да карамастан, Ходай тәгалә Җир кешеләренә туры юлга басарга һәм акылга килергә тагын бер мөмкинлек бирде. Бүгенге көндә вәзгыять шундый аяныч ки, бары тик 60 процент кешеләр генә Хисап көне сынавын үтте һәм аларның аурасы бар.

Явызлыкка киртә кую һәм аның туену чыганакларын юкка чыгару ялгыш юлдан киткән кешеләрне чистарту, аларны Ходай тәгалә юлына кайтару мөмкинлеге бирде. Өченче Амнистия дә барлык кешеләр өчен түгел, ул Хисап көнен уза алмаган 9 процент кешене генә коткара".

Шулай итеп, адәм балалары өчен Өченче Амнистия ясалганнан соң да бик күп кеше әле аның шифалы йогынтысыннан читтә кала, бу исә аларның аурасы, энергетик тәне дәваланмаган, тәнне ташлап киткән җаны *(дөресрәге—рухы)* үз урынына кире кайтарылмаган дигәнне аңлата. Андый кешеләрнең гомере бик нык кыскара, алар тиздән җир йөзен ташлап китәргә тиеш була. Әмма Раббыбызга һәр җан кадерле һәм Ул, күп ташламалар ясап булса да, аларны мөмкин кадәр күбрәк саклап калырга омтыла. Адәм балаларына карата булган мәрхәмәте, аларны ЧЫН АТАЛАРЧА ЯРАТУЫ Раббыбызны адәм балаларын коткарып калу өчен тагын бер омтылыш ясарга этәрә. Шулай 2003 елның 6 апрелендә 20 сәгать 00 минутта Җирдә Дүртенче Амнистия була.

Җир йөзендә кешеләргә сиздермичә алып барылган дәвамлы Хисап көне, төрле этаплар үтеп, бик күпләрне явыз көчләр кочагыннан тартып ала, аларга, Галәм масштаблары белән чагыштырганда бик кечкенә булса да, гаҗәеп матур Җир планетасында яшәүләрен дәвам иттерү мөмкинлеге тудыра. Әмма Дүртенче Амнистиядән соң да Җирдә Хисап көне имтиханнарын узмаган кешеләр, димәк, җаннар әле байтак кала. Аларны нишләтергә? Явыз көчләр кочагында калдырып, ул җаннарны шушы көчләргә бүләк итәргәме? Һич юк, бу акылсызлык булыр иде. Һәм Раббыбыз гадәти булмаган карар кабул итә— Җир йөзендә Гомуми Амнистия үткәрергә һәм шуның белән Дәвамлы Хисап Көненә нокта куярга карар кыла.

Гомуми Амнистия Җирдә яшәүчеләрнең байтагы өчен истәлекле көндә—2003 елның 9 маенда 11 сәгать 25 минутта ясала. *(Моны очраклы хәл дип уйламыйсыздыр бит?!)*. Русиядә яшәүчеләр бу көнне кара көчләр гәүдәләнеше булган фашизмны Җиңү бәйрәмен билгеләп үтте. Шәһәрләрдә урамнар тулы халык, мәйданнарда, бина фасадларында әләмнәр җилферди, оркестрлар дәртле маршлар уйный, парадлар, демонстрацияләр үткәрелә. Кешеләр кояшның ягымлы нурларына, язның җылы-матур көненә сөенешеп ял итәләр, табигатькә чыгалар, дачага барып, җирдә казыналар. Әмма беркем дә Җирдә нинди Бөек Көн тууын абайламый. Бу көнне адәм балаларының күпчелеге Раббыбыз тарафыннан гафу ителә, алар Гомуми Амнистиянең шифала канаты астына алына.

Шулай итеп, бу көнне кешелек дөньясы эволюция юлын дәвам итү өчен ифрат житди имтихан тапшырды дип исәпләргә нигез бар. 2002 елның 2 июнендә башланып киткән Хисап көне сынаулары 2003 елның 9 маендагы Гомуми Амнистия белән тәмам була. Ул 11 ай да 7 көн дәвам итә. Хисап көне сынаулары кешеләр өчен уңай, йомшак рәвештә үткәрелә. Раббыбыз күпчелек җаннарны коткарып кала, шуның белән Ул безгә Илаһи Мәрхәмәтен күрсәтә.

Кеше дигәнең бик сәер зат бит ул. Әле бу мәкалә язылганчы мин, кулымдагы материалларга таянып, кайбер кешеләргә җир йөзендә булып узган шушы планетакүләм вакыйгалар турында сөйләп карадым, тик реакция һәрвакыт бертөрле булды—һәрберсе миңа шикләнеп карады. Җирдә халыкларны тетрәндерерлек вакыйга булганы юк бит, алай яшерен рәвештә үткәч, ул нинди Хисап көне була соң инде, дигән җавап ишетергә туры килде. Кешелек дөньясы үзен канга батырган, җәзалаган-җәфалаган тираннарны, диктаторларны гына исендә калдырырга сәләтле, күрәсең. Илаһи Мәрхәмәтне кабул итәргә ул әле әзер түгел ахрысы.

2003 елның 11 маенда, Гомуми Амнистиядән соң ике көн үткәч, Раббыбыздан кабул ителгән хәбәрдә бу вакыйгага шундый нәтиҗә ясала: "Хисап көне 2002 елның 2 июнендә башланды һәм 2003 елның 9 маенда тәмамланды. Бу көнне кешеләргә Гомуми Амнистия ясалды һәм, 98 процент адәм балалары Хисап көнен узып, ауралы, энергетик тәнле һәм җанлы кеше булуга иреште. Хисап көнен узмаган 2 процент кешегә Гомуми Амнистия ясалмады, алар җәмгыять өчен хәтәр кешеләр".

Бер елга якын Җирдә дәвамлы Хисап көне барды. Шушы вакыт эчендә кара көчләр

йогынтысында булган җаннарны коткарып калу өчен Җирдә һәм Күктә киеренке эш, көрәш дәвам итте. Киләчәктә бу катлаулы процессның этапларын җентекләп тасвирлаучы затлар әле табылыр дип уйларга кирәк. Әлбәттә, Җирне һәм кешелек дөньясын чистарту, нурландыру җинел генә бармый, төрле каршылыкларны җиңеп чыгар өчен яңадан–яңа ысуллар табарга, чишелешләр эзләргә туры килә. Тик бу бер ел дәвамында алып барылган көрәшне санаулы кешеләр генә белә,—күпчелек үз тормышы белән яши, кайдадыр хезмәт итә, планнар кора, балалар үстерә, карьера ясый, тормышын көйләү белән шөгыльләнә. Әмма боларның барысын да кабул иткән хәлдә, үз-үзебезгә сорау бирик: "Җаныбыз авазына колак салмыйча, Раббыбызны онытсак—без нәрсәгә ирешә алачакбыз? Төзегән дөньябызда Раббыбызга урын калдырмыйча, шәхсән үзебез өчен генә бәхет утравы оештыру тормышка ашмаслык хыял, бер иллюзия генә булып калмасмы? Барысы да ахыр чиктә Раббыбызга барып тоташа түгелме? Аны инкяр итеп, тормышта нәрсәгә дә булса ирешеп буламы?"

Җир йөзендә яшәүче кешеләрнең күбесе өчен бу әлегә гаять актуаль мәсьәлә булып кала бирә. Хисап көне инде формаль яктан тәгәлләнгән булса да, Раббыбызның безгә карата куелган таләпләре һич тә кимеми, хәтта арта гына төшә дип әйтергә мөмкин. Кешелек дөньясына үсеш өчен бирелгән мәгълүм вакыт аралыгы тәгәлләнеп килә, тиздән ул үзгә рухи халәткә күчәргә тиеш. Җирдә Хисап көне үткәрү шушы процессның бер этабы булып тора. Бүгенге көндә кешелек дөньясын иләк аша үткәрү кебек бер эш алып барыла. Галәм безгә һәрвакыт ниндидер ташламалар ясап торыр дип уйлау беркатлылык булыр иде. Анда кануннар каттый, билгеләнгән вакытка әзер булмасаң, сафтан төшәсең дә каласың. Бирелгән мөмкинлектән файдаланмасаң—үзеңә үпкәлә! Без, кешеләр, моны аңлыйбызмы соң? Дөньябыз яхшырамы? Раббыбыз күрсәткән юлдан барабызмы? Аның кануннары буенча яшибезме?

Сорау туа: Хисап көне сынауларын уза алмаган кешеләргә нишләргә кала соң? Бүгенге көндә алар алдына бик катлаулы мәсьәләләр килеп басты. Аларны ничек хәл итәргә? Гомумән, аларны хәл итеп буламы? Пычрак энергия белән тулган кешеләргә яшәү мөмкинлеге каламы? Дөресен генә әйткәндә, бу мәсьәлә җир йөзендә күпме яшәү срокларына кайтып кала. Бүгенге көндә моны Раббыбыздан ярдәм алучы бик югары квалификацияле дәвалаучылар гына хәл итә ала. Бу очракта да рухият алгы сафка чыга, соңгы сүзне ул әйтә.

Җирдә Хисап көне узды, тик Имтихан тоту дәвам итә...

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында саклангаан кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире иязләренә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**

Равил
Фәйзуллин

# ГЫЙБРӘТЛӘР АЛЫРЛЫК ҮТКӘН ЮЛ

## ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНЫҢ 70 ЕЛЛЫГЫ УҢАЕННАН КАЙБЕР КҮЗӘТҮЛӘР, ХАТИРӘ-УЙЛАНУЛАР

### III

Бу өченче бүлектә инде үзебез дә шаһит булган, шул мөхиттә үзебез дә беркадәр әвәрә килгән елларга күчеп, 1960-90 еллардагы әдәби хәлләргә күз салыйк. Әдәби хәрәкәтне шартлы рәвештә шәкли периодларга бүлүебез буенча, 1934 елдан сугыш ахырына кадәр 10 нан артык ел булса, икенче чор дигәнем сугыш соңыннан алып 60 еллар башына кадәр—15 ләп елны, бу өченче чор исә, чагыштырмача озын—30 еллап вакытны эченә ала. XX гасыр икенче яртысының саллы төп өлеше дигән сүз. Киләчәктә бу чорның бер-ике сүз белән генә әйтелә торган төгәл билгеләмәсе дә табылыр. Хәер, әйтә дә башладылар инде: "торгынлык" чоры (бу билгеләмә, минемчә, бер яклы)...

Әлеге чорны характерлый торган кайбер вакыйгаларны, тарихи фактларны, лозунг-шигарьләрне искә төшерик. Шул еллар әдәби хәрәкәтенең асылын анларга җинелрәк булыр. 60 еллар башларында Хрущев вәгъдә иткән "коммунизм"ның төзелеп бетәргә тиешле чоры бу. 30 елның 20 ләбендә Брежнев стабиль идарә иткән чор. СССРның, АКШ лидерлары тарафыннан "явызлык империясе" дип тамгаланса да, дөньякүләм мәйдан тоткан, табигать байлыкларын, бигрәк тә нефтьне ифрат күп чыгарып, нигездә, шуның хисабына милитаристик державага әверелгән чагы. Идеологик яктан да шактый катлаулы чор: тышкы сәясәттә—көч-тырышлык ике системаның көрәшенә (беренче чиратта хәрби потенциалны арттыру юлы белән) сарыф ителсә, эчке сәясәттә—төп игътибар халыкларның милли үзенчәлекләрен бетереп, бердәм совет (рус дип анларга да була) халкы ясауга бирелде (мәсәлән, Казанда татар мәктәпләре бөтенләй диярлек бетерелде, авыл мәктәпләренең күбесендә уку-укытылу русчага күчерелде). Әдәбият хәлләренә килсәк, аның әле абруйлы чагы. Иң күп китап укучы халык СССРда дип әйтәләр иде. Дөрес тә булгандыр—өйдә-китапханәдәме, юлда-пляждамы дигәндәй, олысының да, кечесенең дә кулларында китап булыр иде. "Китап—белем чишмәсе" дигән канатлы сүзләр күпчелекнең анында, күнелендә иде. Әдәбиятның дәрәҗәсе—халыкның шигърияткә мөнәсәбәтендә бигрәк тә ачык чагылды. Халык ташкын булып, мәйдан-стадионнарны, мәдәният сарайларын тутырып шигырь тынларга җыелсын әле! Кабатланмас еллар! Без дә—60 еллар башында әдәбиятка килеп, хәзер 60 яшькә җиткән буын—шигырь язып, иҗат итеп, дөньяны яхшыга үзгәртәбез дип, нык ышандык ул елларда! Һәм шул ышаныч илһамландырды да, эшләтте дә, яшәтте дә. Кызыклы чор, парадоксларга бай чор. Бер яктан "нык үскән социализм" иленда иҗат ирege турында тәкърарланса, икенче яктан, мәгълүм канун-кысаларга яраклы партияле иҗат таләп ителде. "Без йөрәгебез кушканча язабыз, ә йөрәкләребез партиягә бирелгән" дигән сүзләр еш янгырый иде. Ялгышмасам, бу сүзләрне партия съездында М. Шолохов әйтте шикелле. Әдәбият белән җитәкчелек итүне партия, беренче чиратта, Язучылар оешмасы аша башкарды. Тулысынча партия идеологиясенә хезмәт

Ахыры. Башы 8 санда.

иткән оешманың эш стиле дә, табигый, партия дисциплинасына буйсынган булды. Ул стиль шул система өчен унайлы һәм шактый ук мөкәмәл дә иде. Язучылар съездлары, пленумнары Устав буенча төгәл вакытында уткәрелә (1960-90 елларда V-XI нче съездлар, җәмгысе җиде съезд), партия оешмасы җыелышлары вакытында уздырыла, әдәби ел йомгаклары утырышлары зур вакыйгага тин була (андый җыелышлар уткәрелә башлауга быел 40 ел тулды, ел йомгакларына багышланган беренче җыелыш 1964 елда үтте)... Булдыклы, талантлы язучыларның (дөрес, сирәк-мирәк кайбер әсәрләрдән идеологик "ялгыш" табып, басылмау очраклары булгалады) әсәрләре даими чыгып килде. Каләм хакы бәрабәренә заманы өчен яхшы гына яшәп, гаилә тотып була иде. Язучыларның китапларын бастырып чыгаруда Язучылар союзы реаль булыша алды. Оешма әгъзалары, аларның гаилә әгъзалары иҗат йортларына, курорт-санаторийларга барып иҗат белән шөгыльләнә, ял итә һәм дәвалана ала иде... 50-60 ел эчендә язучы халкы өчен Әдәби фонд аша меңләп путевка-юллама алынгандырдыр дип уйлыйм.



*Муса Җәлилнең тууына 80 ел тулу уңаеннан үткәрелгән тантаналы җыелыштан күренеш. Мәскәү. Колонналы зал. 1986 ел.*

*

Янә съезд хәлләренә кайтыйк. Үземнең беренче мәртәбә Язучылар съездында катнашуым да шул чорда—60 еллар башында булды. Ул—Татарстан язучыларының V съезды. (Шуннан соңгы 40 елдан артык вакыт эчендә Татарстан язучыларының 10 съездында, СССР, РСФСР язучыларының 7 съездында катнашырга туры килде. Хәтер офыгында һәммәсе дә стенографик эзлеклектә сакланмаса да, күбесендәге топ чыгышлар, шәхесләр, кызыклы эпизодлар әле һаман истә. Шуна күрә, соңгы берничә дистә еллар әдәби тормыш хәлләрен шәхси күзәтүләрем белән "сипләп" баруым табигыйдер. Тик шунысы бар: күбрәк белгән саен, белгәненнең асылын, төшен төгәл итеп кәгазьгә төшерү кыенлаша гына икән; берсе онытыла, икенче берсе төшеп кала кебек).

**V съезд 1963 елның 7 февралендә М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрында** (бу—театр бинасында үткән соңгы съезд, калган җыеннар кечерәк—бүтән биналарда уткәрелә башлады) **ачылды.** Татарстан язучылары белән бергә, кунак сыйфатында союздаш һәм автономияле республика вәкилләре, республиканың партия-совет җәмәгатьчелеге, сәнгать һәм фән эшлеклеләре катнашкан бу җыен 8-9 февральләрдә үз эшен КПСС өлкә комитетының конференц залында дәвам итте. Съездда "Татарстан Язучылары союзының идарәсе эше" (Мирсәй Әмир), "Бүгенге татар поэзиясе" (Нил Юзиев), "Татар балалар әдәбияты" (Җәвад Тәрҗеманов), "Әдәби тәнкыйтебезнең торышы" (Гали Халит), "Татарстандагы рус язучылары иҗаты" (Геннадий Паушкин) турында докладлар тыңланды. Чыгыш ясаучылар арасында Г. Бәширов, С. Баруздин (Мәскәү), Г. Әпсәләмов, М. Кәрим (Уфа), С. Хәким, Г. Ахунов, Ш. Маннур, Ә. Давыдов, А. Шамов, Я. Ухсай (Чабаксар), Р. Мостафин, Ф. Хөсни, Р. Төхфәтуллин һ. б. катнашты. Съездның 10 февральдә үткән соңгы утырышында 17 кешедән торган яңа идарә составы сайланды. Алар: Мирсәй Әмир (председатель), Габдрахман Әпсәләмов, Гомәр Бәширов, Хәсән Туфан, Фатих Хөсни, Зәки Нури, Газиз Мөхәммәтшин, Рафаэль Мостафин (җаваплы секретарь), Ләбибә Ихсанова, Гариф Ахунов, Илдар Юзеев, Хәй Вахит, Хатип Госман, Александр Булгаков, Шәукәт Галиев, Гали Халит, Геннадий Паушкин.

Театр залында съездда катнашкан атаклы язучылар, кунаклар арасында Р. Харисов, Г. Рәхим (Г. Родионов), Р. Мингалимов, Ә. Синугыл, Х. Хөснуллин, Р. Гатауллин (Р. Гаташ) кебек яшьләрнең дә "өлкән" йөзләре хәтердә калган. Халыкча әйтсәк, кеше арасына керә башлаган чаклар...

Шул ук 1963 елны Татарстан Язучылар союзының филиалы рәвешендә Әлмәттә язучылар бүлеге оештырылды. Шул вакыттагы әдәбият үсеше өчен зур вакыйга. Бу төбәктә моның өчен җирлек һәм инициатива булган, димәк, югарыдан да тиешле булышлык-ярдәм күрсәтелгән. Әлмәт бүлегенең җитәкчесе, ягъни җаваплы секретаре итеп язучы Гариф Ахунов билгеләнә. Бу бүлек Татарстанның көньяк-көнчыгыш районнарында яшәүче шактый күп санлы талантлы каләм ияләрен туплап, иҗади рухландырып, шул регионның үзгә бер мәдәни-әдәби үзәгенә әйләнде. Әлмәт ул вакытта нефть башкаласы саналды. Илкүләм масштабтагы төрле чаралар—киңәшмәләр, слетлар, фестивальләр еш үтә иде анда. Татарстанга килгән атаклы язучылар, әдәбият-сәнгать әһелләре Әлмәткә сугылмый калмадылар. Алар чыгышлар ясап, җирле язучылар белән аралашып, Әлмәт оешмасы ныгуына унай йогынты ясадылар. Язучыларның Әлмәт бүлеге саны һәм әдәби куәте ягыннан кайбер өлкәләрдәге язучылар оешмаларына караганда көчлерәк саналды. 70 елларны бүлектә СССР Язучылар союзы әгъзасы булган каләмдәшләрнең саны 25-30 га җитте, ә яшь һәм башлап язучылар йөзәрләп исәпләнде. Нефть төбәге җирлегендә укучы яратып укырлык байтак күренекле әсәрләр—романнар, поэмалар, повестьлар, пьесалар язылды, күп санлы җырлар туды. Ул әсәрләрне язган берничә язучы Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, соңрак Татарстанның халык шагыйре, халык язучысы исемнәренә лаек булды. 40 ел эчендә бу оешма белән Г. Ахунов, Р. Фәйзуллин, Ә. Маликов, Ә. Гаффар, Н. Әхмәдиев, Р. Вәлиуллиннар җитәкчелек итте. Хәзер Әлмәт язучылар оешмасында вәзгыять бутәнрәк: иҗади ялкынның сүрелә төшүе сизелә. Г. Афзал, С. Сөләйманова, Ә. Маликов, Ш. Бикчурин, Р. Төхфәтуллин, Э. Мөэминова, М. Хәсәнов, Ю. Әминов, Ж. Рәхимов, Ф. Гыйльми һ. б. эстафетасын дәвам итеп, татар әдәбиятын яна үрләргә күтәрерлек яшь көчләр, кызганыч, бик аз... Өлкән буыннан да бүген дә актив иҗат итүчеләрдән К. Булатова, Ә. Сәлахов һәм А. Хәсәнов кенә калып бара бугай...



*Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлегендә каләмдәшләр очрашуы: Сафа Сабиров, Мәхмүт Хәсәнов, Марат Кәримов, Әдип Маликов, Үзбәк Саттаров, Зәки Нури, Гамил Афзал, Юныс Әминов. 1971 ел.*

Шул чор әдәби елъязмасында мөһим бер сәхифә булып калган факт: ул—"Совет әдәбияты"ның бүгенге исемдә—"Казан утлары" булып чыга башлавы (июнь, 1965). "Совет әдәбияты" дигән гомуми исемне алыштыру өчен формаль сәбәп тә бар: ул заманда төркмәннәрдә дә "Совет әдәбияты" дигән әдәби журнал чыга иде. СССР күләмендәге каталогта икесе дә бер исемдә чыккач, төрле төбәкләрдә журналны яздырып алучылар арасында буталу очраклары булгалый иде. Язучылар арасында берәр ай журналга яна исем эзләү мәрәкәләре булып үткәч, идарәдә (рәис М. Әмир) "Казан утлары" исеме кабул ителде. Нәкъ шул айда журналның баш редакторы итеп Рафаэль Мостафин билгеләнде (ул Газиз Мөхәммәтшинны алыштырды). Баш редактор эшне бик актив башлап җибәрде (тәмамланган фигыль белән сөйләвем шуннан: үзем дә бу журналда эшли башлаган идем инде). СССРның татарлар яши торган регионнарына—республика, өлкә газеталарына журналның исеме алышыну

турында мәкалә-хәбәрләр җибәрдек. Шунда ук, «сезнең өлкәдә фәлән мең татар яши, безнең журнал фәлән данә тарала ала» дигән күрсәтмә-аңлатма да бирергә онытмадык. Редактор кушуы буенча турыдан-туры шушы эш белән шөгыльләнгәч, хәтердә: 100 дән артык хат җибәрелде, шуның күбесе СССРда чыга торган республика, өлкә газеталарында басылып чыкты. Һәм... нәтиҗә дә яхшы булды. 1965 елда тираж 19246 булса, бер ел эчендә 18 меңгә якын артып, 1966 елны "Казан утлары" 36800 булып чыкты. Ә 1968 елны—64000 данәгә җитте. Ул елларда журнал тарату белән Тәүфикъ Әйди бик нык шөгыльләнде. Үз теләге белән велосипедка утырып күрше республикаларга чыгып йөргәне хәтердә калган. Күпләргә үрнәк зат булган ул чакта яшь язучы саналган Тәүфикъ! (Юкса үзе ул вакытта редакциядә дә эшләми иде.) Журнал исеме алмашу уңаеннан күңелдә калган матур хатирәләр, матур нәтиҗәләр...



*Журналның "Казан утлары" исеме белән чыккан беренче саны.*

**Шул ук 1965 елны (14-15 январьда) Татарстан язучыларының чираттан тыш тагын бер—сан буенча VI съезды булып үтте.** V съездан соң ике ел үтүгә яңадан съездга җыелуның төп сәбәбе: РСФСР язучыларының II съездына делегатлар сайлау. Без бит инде хәзер РСФСР Язучылар оешмасына буйсынабыз. Шуңа күрә аның Устав кагыйдәләрен үтәргә туры килә! Съездда Союз идарәсе председателе Мирсәй Әмир татар әдәбиятының торышы һәм бурычлары турында доклад ясады. Доклад буенча фикер алышуларда Г. Әпсәләмов, И. Нуруллин, Б. Гыйззәт, Ж. Тәрҗеманов, И. Гази, А. Булгаков, Г. Ахунов, З. Мәҗитов, съездга кунак булып килгән Мәскәү язучылары Л. Соболев, С. Михалков, Б. Дубровин, чуваш язучысы Н. Ильбеков һ. б. катнашты. Съездда, шулай ук, КПСС өлкә комитеты секретаре З. Тутаев чыгыш ясады. Аннары съезд РСФСР язучыларының II съездына делегатлар сайлады. Алар—М. Әмир, Г. Әпсәләмов, Г. Бәширов, Р. Ишморат, Л. Соболев, Ф. Хөсни, С. Хәким, Ә. Исхак, Г. Ахунов, З. Нури, Г. Минский, С. Радзиевская, А. Расих.

Язучыларның VI съездында, саналган кунаклардан тыш, күренекле язучылардан А. Алексин, Л. Андреевская, М. Львов, Р. Моран һәм Мостай Кәрим катнашты.

РСФСР язучыларының II съезды алдыннан чираттан тыш үткәрелгән җыенда яңа идарә сайланмады, үткән V съездда сайланган Идарә үз эшчәнлеген дәвам иттерде.

Бу съезд көннәре минем хәтергә тагын бер сәхифәсе белән сеңеп калды әле. Күптәннән килгән традиция буенча, Казанга килгән исемле шәхесләр, гадәттә, Казан университетына килми калмыйлар иде. Бу юлы да шулай булды: съезд кунакларын (Л. Соболев, С. Михалков, М. Кәрим, М. Львов, А. Алексин һ. б.) студентлар белән очрашуга чакырдылар. Бу әдәби кичә Актлар залында узды. Студент яшьләр исеменнән кунакларны котлауны миңа йөкләделәр. Күрәсең, әдәби түгәрәк җитәкчесе, яшь шагыйрь саналып, инде китап авторы булуымны искә алганнардыр. Университет парткомы наказы бу! Русча-татарча котларга тиешмен. Йөкләвен йөкләделәр, әмма чыгышым гына үзем теләгәнчә булып чыкмады бугай: артык дулкынлanудан каушадым, тирләп чыктым, җитмәсә кәгазьсез-нисез сөйләп азапланам... Татар әдәбияты вәкиле булып, үзебезне тиешенчә күрсәтә алмадым дип, бик нык битәрләдем үземне. Кул чаптылар чабуын. Яшьлеккә ташлама ясаганнардыр инде... Хәзер дә, бу хәл искә төшкәч, сәер бер хис кичерәм.

•

Съездлар, корылтайлар—театр биналарында, зур залларда үтә торган рәсми һәм күпмедер дәрәҗәдә тантаналы җыелышлар алар. Шуңа күрә (кәбисә елы кешеләренең туган көннәре кебек), сирәк, гадәттә 4-5 елга бер тапкыр үткәреләләр дә (күзәтүләр шуны күрсәтә: билгеле бер чиге була ул съезд саннарының. Партияләр-некеме яки оешмаларныкымы, XXXX яки XXXXX съезд дигәнне тарихта ишеткән

юк әле. Кем белә, бәлки язучылар оешмасының да корылтайлары фәләненче санда тукталып калыр?). Ә бит көндәлек иҗади хәрәкәт бүтән җирләрдә бара: эш бүлмәләрендә, газет-журнал редакцияләрендә, нәшрият кабинетларында... Каләм ияләрен җыя торган бер үзәгебез дә бар безнең. Кемнәрдер өчен "бар иде" дип тә әйтеп була... Ул—әлбәттә, атаклы Матбугат йорты. 30 еллар уртасында архитектор С. Пэн проекты белән төзелгән бу бина 70 еллар буе чын мәгънәсендә татар матбугаты, татар китабы, татар әдәбияты учагы булды. Аның таш баскычларын таптамаган зыялылар сирәк булгандыр. Элегрәк Татарстанда чыккан бөтен газет-журналларның редакцияләре шунда тупланган иде. Гомер-гомердән дигәндәй, дүртенче катны Татарстан китап нәшрияты биләде. Язучылар оешмасы штабы—Союз да ярты гасырдан артык шушы бинада булды. Икенче кат. Баскычтан мәңгү унаеннан сулга борыласың, якты тәрәзле коридор буйлап 10-15 адым атлаганда "Азат хатын", "Ялкын" редакцияләре кала... Коридор төпкелендә—Язучылар союзы, Әдәби фонд. Шундук "Совет әдәбияты" ("Казан утлары") редакциясе. Ничек сыйганнардыр! (Хәзер бинаның икенче катындагы бу канатын бер "Мәдәни җомга" били). Дөрес, дүртенче катта җыйнак кына, йөз иллеләп кеше сыешлы атаклы Тукай клубы бар. Безнең буынның (бездән алдагы буынның да) әдәбиятка чынлыклап аякка басуы шушы клубтан башланды да инде. Шәхсән үзем 1960—елдан студентлыкның беренче айларыннан ук таптый башладым мин бу клуб баскычларын. Әдәби кичәдә шигырьләр укып беренче тапкыр чыгыш ясаулар да шушы клубта булды. Әсәрләрен дәресләрдә өйрәнгән язучыларны шушында күрдек. Гомәр Бәширов, Хәсән Туфан, Мирсәй Әмир, Шәйхи Маннур, Афзал Шамов, Фатих Хөсни, Габдрахман Әпсәләмов, Сибгат Хәким... Болары XX гасырда туган шәхесләр. XIX гасыр ахырында туган өлкән затлар белән дә беренче тапкыр биредә таныштык: Нәкый Исәнбәт, Исмәгыйль Рәми, Риза Газизов, Госман Бакир... Аларның замандашлары—солтангалиевчелектә гаепләнеп, теге заманнарда төрмә-сөргеннәр кичкән Бакый Урманче, Мәхмүт Бөдәйлиләрне дә шушы бинада күрдек. Аена бер-ике мәртәбә булына иде Тукай клубында. Традицион җомга кичләре, Казанга кунак булып килгән атаклы язучылар белән очрашулар, студент яшьләрнең концертлары, юбилей кичәләре... Без—яшь язучыларны иң кызыктырганы (тизрәк зур шагыйрь, язучы буласы килә бит!), әлбәттә язучыларның җыелышлары иде. Бигрәк тә ел йомгакларына багышланган җыелышларны калдырмаска тырыша идек. Икешәр көн бара иде ул "йомгак"лар. Күпме шәхесләр күрәсең, күпме чыгышлар тыңлап, күпме кызыклы фикерләр ишетәсең! Чыннан да, әдәби җәмәгатьчелек өчен вакыйга иде ул җыелышлар. Яшьләр дә, зыялы өлкәннәр дә көнозын йотлыгып тыңларлар иде чыгышларны, тәнәфесләрдә чама белеп кенә бәхәсләшерләр, алган тәэсирләрен күңелләрендә озак йөртерләр иде. Күрәсең, ул заманда татар әдәбияты һәм сәнгате турында авыз тутырып ана телендә сөйләү, иркенләп фикер алышу өчен бүтән урын да булмагандыр...



*Татарстан язучыларының VI съезды президиумы. Уртада—Мирсәй Әмир һәм Сергей Михалков. 1965 ел.*

Мәшһүр Матбугат йорты! Житмеш ел эчендә дөньяның бик күп атаклы кешеләрен (сугыш вакытында, бигрәк тә) күргән истәлекле бина. Хәзер дә син әле исән. Әле хәзер дә синдә ике нәшриятыбыз (Татарстан китап нәшрияты һәм "Мәгариф"), Китап палатабыз, "Мәдәни җомга" газетабыз гомер кичереп ята. Бирегә хәзер дә килгәләп йөрибез, фикердәшләр,

нәширләр белән көрәшәбез. Шулай да, күңелне тырнаган сорау бар: киләчәктә бу диварларда элеккеге милли рух, китап рухы сакланып кала алыр микән? Акшарлары купкан түшәмнәргә, тузган тәрәзә өлгеләренә, күгәргән торбаларга карап күңелгә монсулык иңә... Кемнәр кулына калып, киләчәктә кемнәр хуҗа булыр бу тарихи Үзәктә!..



*Матбугат йорты.*

*

Татарстан язучыларының чираттагы (ул вакытта, СССР Язучылар союзының яңартылган уставы нигезендә, съездлар биш елдан биш елга үткәрелә иде) съезды 1968 елны үтте. Бу съездны да яхшы хәтерлим. Инде СССР Язучылар союзы әгъзасы булынган, берничә шигырь китабы чыгарылган, шигырьләрем турында байтак бәхәс-низагълар, мактау-тиргәүләр ишетеп шактый ук чыныгылган, гаилә корылган, солдат хезмәте үтелгән... Президиумга ук утыртып, идарә әгъзасы итеп тә сайладылар мине бу съездда. Гармоник фон тудырыр өчен өлкәнрәкләр арасына бер яшь кешене сайлау гадәте бар иде ул!.. Ә болай, тәртип белән сөйләгәндә **VII нче съезд, 1968 елның 25-26 март көннәрендә Г. Камал исемендәге (хәзерге Тинчурин театры) татар дәүләт академия театрында узды.**

Съездны аксакал язучы, СССР Дәүләт премиясе лауреаты Гомәр Бәширов ачты. Идарәнең ике съезды арасындагы (1965-1968) эшчәнлеге турында хисап докладны, идарә рәисе буларак, Мирсәй Әмир ясады. Ул язучылар ирешкән уңышлар һәм алда торган бурычлар турында сөйләп, язучылар оешмасының 25 кешегә артуын әйтте, СССР Язучылар союзы әгъзасы булган язучыларның саны 111 кешегә җиткәнен белдерде. Доклад буенча фикер алышуларда Г. Ахунов, Л. Татьяничева (Мәскәү), Л. Ихсанова, Ф. Хөсни, Г. Камалиев (нәшрият директоры), Р. Мостафин, Х. Гыйлаҗев (Уфа), Р. Харисов, В. Ганиев (Мәскәү), Ш. Рәкыйпов, Ә. Давыдов, А. Калган (Чувашстан), А. Расих, М. Сәлимҗанов (режиссер), Сәхип Җамал (гарәп язучысы), Ж. Тәрҗеманов һ. б. катнашты. КПСС өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев нотык сөйләде. 26 мартта яңа идарә сайланды. Аның составына түбәндәге язучылар керде: Ибраһим Гази (председатель), Мирсәй Әмир, Гариф Ахунов (җаваплы секретарь), Гомәр Бәширов, Зәки Нури, Равил Фәйзуллин, Хәсән Туфан, Фатих Хөсни, Сибгат Хәким, Афзал Шамов, Риза Ишморат, Хатип Госман, Гази Кашшаф, Илдар Юзеев, Валерий Синев, Ләбибә Ихсанова, Рафаэль Мостафин.

Шушы 17 кешенең бүген инде 4 се генә (Л. Ихсанова, Р. Мостафин, И. Юзеев, Р. Фәйзуллин) исән. Безнең замандашлар булган нинди олпат затларыбызны югалткансбыз! Ирексездән шигырь юлларын кабатларга туры килә: "Кемнәр бар да, кемнәр юк!"

Бу съездтан тагын ике нәрсә күңелдә җуелмас булып хәтердә калган. Беренчесе — тәнкыйтьче, М. Җәлил иҗатын өйрәнүче Рафаэль Мостафинның чыгышы. Чыгышның төп бер тезисы шул иде: 1913 елда татар китаплары сан буенча хәзергедән күбрәк чыккан. Әдәбият әһелләре арасында сөйкемле сөяк саналган, русча-татарча иркен сөйләшә һәм яза алган, дәрәҗәле Р. Мостафинның бу чыгышы партия түрәләре өчен һич тә көтелмәгән хәл булды. Ничек инде революциягә кадәр шулай булырга тиеш ди (гәрчә тәнкыйтьче конкрет статистик саннар китереп, дәлилләп сөйләгән иде!)? Әнә бит, республика җитәкчеләренең берсе — татарлар революциягә кадәр тоташ грамотасыз булган дип бара! Нинди каршылык! Дөресрәге: партия линиясенә каршылык!.. Бу чыгышка рәсми реакция катгый булды: бер айдан Р. Мостафин "Казан утлары" журналының баш мөхәррире вазифасыннан азат ителде... Икенчесе (монысын ул заман өчен инцидент дип әйтеп була) — бер төркем яшьләрнең театр балконыннан татар яшьләре өчен әдәби журнал кирәк, дигән



*Аксакал язучылар Аккош күлендә. Сулдан уңга—Гомәр Бәширов, Нәкый Исәнбәт, Нәби Дәүли, Нури Арсланов.* Виктор Кудelькин рәсеме.

эчтәлекле листовкалар очыруы. Зал өстеннән ак яфраклар кебек листовкалар очып-әйләнгәндә президиумда—янәшәмдә утырган югары урын биләгән түрәләрнең чырайлары ничек үзгәргәне һаман күз алдында. Каушау һәм аптырау! Нәрсә бу?

Листовкалар очырткан студент егетләрне (Разил Вәлиев, Зөлфәт, М. Мансуров) КГБ бүлмәләренә байтак йөрттеләр. Бу хәл (хәзерге күзлектән караганда гап-гади таләп) үзе һәм аңа булган реакция—шул заман иҗтимагый тормышын характерлап торган бер күренеш иде.

*

1960-90 еллар. Бу чор татар әдәбиятының алтын чоры булды бугай. Еллар ераклыгыннан шулай күренә. Р. Мингалимов әйтмешли, “ул шулайдыр әле, уйласаң”. Әдәбиятның кадере булган чор. Язучы да үзен җәмгыятьнең кирәк һәм хөрмәтле кешесе санап, чагыштырмача иркен тоеп, көченә һәм киләчәккә ышанып иҗат итте. Нигә язмаска? Максатың бар, хезмәтеңнән ләззәт тою бар, иң мөһиме—әсәрләреңне көтеп торган күп санлы укучылар бар. Әзме-күпме белемле кеше кибетләрдән яхшы китап эзли, күптомлы басмаларга берәр ел алдан языла куя, таныш-белеш аша берәр дефицит китап юнәтсә, төлке тоткан кебек, сөенә... Атаклы язучыларның яңа әсәрләрен вакытында укып бару—зыялылык билгесе санала. Айтматовның “Ак пароходы”на фикерең ничек? Хемингуэйның соңгы романының русча тәрҗемәсе чыккан! Неруданың мемуар китабы кемдә бар икән? Исхакыйның “Зөләйха”сын берәү машинкадан чыгарган!.. Кызыксына, укый иде халык! 80 еллар башында “Казан утлары” журналының 100 меңнән артык данә белән таралуы күп нәрсәне аңлата (заманында трамвай бәясе дә 3 тиен иде дигән шикелле, ул елларда миллионга якын тираж белән чыккан бөтенсоюз журналлары—“Новый мир”, “Дружба народов”, “Знамя” кебек журналлар хәзер тиражлары безнең “Казан утлары”ннан ким булып—нибары 3-6 мең данә чыга). Әйе, укый иде халык. Татар телендә чыккан китапларның тиражлары да шактый югары: шигырь китаплары—3-10 мең, проза китаплары—10-30 мең, балалар китаплары—10-100 меңнәр була иде. Татар язучыларыннан, бездә генә түгел, илкүләм популярлары мәйданга чыкты. Шуларның иң күренеклесе, алда әйтелгәнчә, Г. Әпсәләмов булды. Г. Кутуйның “Тапшырылмаган хатлары” шикелле, Г. Әпсәләмов романнарын, беренче чиратта “Ак чәчәкләр”не, миллионлаган төрле милләт вәкилләре йотлыгып укыды... Татар-башкорт укучылары арасында Ә. Еники дә аерым бер урын тотты; аның “Әйтелмәгән васыять”ен укымаган зыялы зат калмагандыр... Саный китсәң, бар иде популяр әсәрләр. Ш. Хөсәеновнең “Мәхәббәт сагышы”, И. Юзеевнең “Таныш моңнар”ы, Х. Вахитның “Беренче мәхәббәт”е... Х. Туфан, С. Хәкимнәрнең шигырь, поэмалары, Г. Афзал, Ш. Галиевләрнең юмор-сатира, Роберт Әхмәтҗановның лирик шигырьләре... “Давыл хәбәрчеләре” сыман 60 еллар башында әдәбиятка килгән яшь шагыйрьләр иҗатына игътибар аеруча зур булды. Республика газеталарында атна саен диярлек дискуссион характердагы зур-зур мәкаләләр чыкты. Традицияләр, новаторлык, формализм, “ирекле шигырь”... Мәш килде әдәби мөхит!


*60 елларда әдәбиятка килгән шагыйрьләр. Сулдан уңга — Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, Рөстәм Мингалимов, Гәрәй Рәхим. 1971 ел.*

Чорлар турында сөйләгәндә табигый процесс—әдәбиятта буыннар алышынуы турында да искәртеп узу кирәктер. Чыннан да, өлкән язучылар (XIX гасыр ахырында һәм XX гасыр башында туганнар) 70-80 елларда үзләренең дөньялыктагы гамәлләрен йомгаклап киләләр иде инде... Төп әдәби мәйданны исемнәре 50 нче еллар урталарында һәм беразсонрак күренә башлаган буын яулады. Алар—прозада Г. Ахунов, Р. Төхфәтуллин, Н. Фәттах, А. Гыйләҗев, М. Рафиков, Ә. Баян, Ш. Бикчурин, Б. Камал, М. Мәһдиев, Х. Камал, А. Тимергалин, Х. Сарьян, Э. Касыймов, М. Хуҗин, М. Юныс, Ф. Шәфигуллин, Т. Әйди, М. Маликова, М. Хәбибуллин, В. Нуруллин...; шигъриятә—алдагы абзацта әйтелгәннәрдән тыш, Р. Гәрәй, М. Шабаев, Ш. Анак, С. Сөләйманова, Ф. Яруллин, Р. Фәйзуллин, Рәш. Әхмәтҗанов, Р. Харис, Р. Мингалим, Г. Рәхим, Р. Гатауллин, К. Сибгатуллин, А. Хәлим, М. Әгъләмов, Зөлфәт...; драматургиядә—Х. Вахит, Ю. Әминов, Ш. Хөсәенов, Т. Миннуллин, Батулла, Р. Хәмид..; әдәбият гыйлеме һәм тәнкыйтьтә—Мансур Хәсәнов, И. Нуруллин, Ә. Кәримуллин, И. Ахунҗанов, Н. Юзиев, М. Госманов, А. Әхмәдуллин, Ф. Мусин, Т. Галиуллин, Ф. Урманче, Х. Миннегулов...

*

Бу урында сугыштан соңгы шактый дистә еллар буена татар әдәбияты барышына нык тәэсир иткән берничә фактор турында әйтү мөһим. Алар—**Ватан сугышы, Татарстанда нефть чыгару,** соңрак **КамАЗ төзелү**. Ватан сугышы, дөньякүләм фаҗига буларак, күп халыклар яшәешендә чагылыш тапса, ә нефть белән КамАЗ турыдантуры Татарстан, бигрәк тә татар халкы язмышына кагылды. Республиканың йөзе, кешеләрнең кальбе үзгәрде. Татарстанда читтән килгән халык күбәйде, яшь һәм көчле килмешләр армиясе хасил булды. Рәсми идеология индустриаль казанышларга дан җырларга өндәде. "Хезмәт кешесе образы" дигән ясалма термин туды (безнең әдәбиятның каһарманы гомер гомергә хезмәт иясе булды лабаса!). Социалистик реализм методы алымнарына тугърылыклы булып, эшче сыйныфын, хезмәт романтикасын сурәтләгән (яки сурәтләргә тырышкан) байтак әсәрләр, китаплар чыкты. "Гади кешеләр" (И. Гази), "Хәзинә" (Г. Ахунов), "Томан аша" (Э. Касыймов), "Зәй энҗеләре" (А. Гыйләҗев), "Каты токым" Ш. Бикчурин, "Ут һәм су" (Ә. Баянов), "Тау белән тау очрашмаса да" (М. Хәбибуллин)... Саналганнар—проза әсәрләре, бүтән жанрлардан да мисалларны китерергә була. Болар, нигездә, социаль заказ белән язылган әсәрләр. Бу күренешне яңа дип тә әйтеп булмый. 30 елларда, бигрәк тә СССР язучыларының I съездыннан соң, булган иде инде андый хәлләр. Язучылар, иң әүвәл, завод-фабрикалар тарихын язарга, "металл җыры"н яңгыратырга, "мотор гигант"ын сурәтләргә, "миллионнарның энтузиазмы"н күрсәтергә тиеш иде. Бу чорның ядкарьләре—Ш. Камалның "Матур туганда", Р. Ильясның "Горизонт" кебек әсәрләре...

Әлбәттә, республикадагы баш әйләндергеч үзгәрешләр, нефть һәм КамАЗ индустриясе белән бәйле контрастлар, уңай (заман технологиясен үзләштерү, халыкара бәйләнешләр ныгу, техник интеллегенция оешу, юллар салу, торакларны газлаштыру һ. б.) һәм тискәре (авыллар бетү, экологик кризис, миллилекнең асылы кимү, әхлаксызлык, ассимиляция, татар теленең кысрыклануы һ. б.) күренешләр язучылар иҗатында чагылыш табарга тиеш иде. Һәм ул шулай булды да. Әмма... Хикмәт шунда: чагылыш нинди дәрәҗәдә һәм нинди тирәнлектә булды соң? Дөресен әйтик,

нигездә, авылдан чыккан татар язучысы ФТР (фәнни-техник революция) тудырган бу хикмәт-тамашалар алдында, табигый, югалып та калды. Югалырсың да, фантазия белән күз алдына китерик: идиллик-патриархаль тормыш белән яшәп ятучы авылның су тегермәне янына "НЛО корабы" төшсен дә, шуны аңлап-белеп кара әле! Вәзгыять, халәт, әзерлек шулайрак иде. Әйткәнемчә, тырышмады түгел, тырыштылар язучыларыбыз. Алар—командировкаларга барып, буровойларда, кыр вагоннарында, тулай торакларда, баракларда булдылар, бораулаучылар, ташчылар, шоферлар, торбачылар белән (өстән юнәлтелгәнчә, нәкъ чын хезмәт кешеләре белән) аралаштылар һәм шулар тормышы турында яздылар да. Нишләтәләр бу җирне? Байлык кая китә? Бу гамәлләрнең ахыры ни белән бетәчәк? Бу хакта дөнья танырлык итеп язылмады, һәрхәлдә, язылып та дөнья күрә алмаган берәр зур әсәрне белмим мин.



*Язучылар төзелеш мәйданнарында.*
*80 еллар.*

Төзелешләр мәйданын хәтерләткән республика тормышында майлы киемле хезмәтчәннәрдән тыш, идарәчеләр, югарыдан куелган стратегик максатны тормышка ашыручылар катламы—Табеевлар, Шмаревлар, Васильевлар, Шашиннар, Мингәрәевләр, Лемаевлар, Бехлар һәм тагын күпләр бар иде. Татар язучылары алар белән якыннан аралашып, якындагын гына түгел, ерак офыктагы булачакны фаразлап, җитәкчеләр белән бер дәрәҗәдә яки, хәтта өстәнрәк торып иҗат итә алмадылар. Берәүне дә гаепләргә җыенмыйм. Әлеге әфәнделәр туры һәм күчерелмә мәгънәдә дә бүтән телдә сөйләшәләр иде шул...

*

Ватан сугышы—60-90 елларда да әдәбиятыбызның төп темаларыннан берсе булып кала бирде. Фронтта катнашкан язучылар, хәтерләрен яңартып, яна әсәрләр яздылар ("Мәңгелек кеше"—Г. Әпсәләмов, "Дуга"—С. Хәким, "Муса"—Ш. Маннур, "Җимерелгән бастион"—Н. Дәүли, "Йолдызлар шаһит"—Ә. Галиев, "Һәркемнең гомере бер генә", "Безне өйдә көтәләр"—Х. Камал, "Без дә солдатлар идек"—Ә. Еники, «Яшьлек утравым»—Ә. Маликов...) Сугыш чорын күреп үскән кайбер яшьрәк язучыларыбыз да, өлкәннәр үрнәгендә, хәрби-патриотик тәрбиягә өлеш кертәбез дип иҗат иттеләр ("Кайда син, Җан?", "Кызлар—йолдызлар"—Ш. Рәкыйпов, "Легенда егетләре"—С. Шакир һ. б.). Бу әсәрләрнең күбесе сугыш темасына 50 елларда язылганнардан шактый ук аерылалар иде. Элгәргеләрендә сугыш (без яшь чакта күргән "Взятие Берлина", "Смелые люди" кинофильмнарындагы шикелле), күбрәк батырлык мәйданы кебегрәк күрсәтелсә, соңгыларында, кешелек фаҗигасе буларак, кеше язмышлары аша реаль чынбарлыкта чагылдырыла башлады. Башкача мөмкин дә түгел иде. Әдәбият сөючеләр бүтән халык язучыларының сугыш турында язылган әсәрләре белән дә яхшы ук таныш иде. Әйтик, В. Быковның "Сотников", К. Симоновның "Живые и мертвые", Й. Авижюсның "Потерянный кров", В. Астафьевның "Плацдарм", "Последний поклон" һ. б... В. Ажаевның "Мәскәүдән еракта", С. Бабаевскийның "Алтын йолдыз кавалеры", М. Бубенновның "Ак каен"нарын уку заманнары үткән иде шул... Безнең буын яшь чакта сугыш турында күп укыды. Ялган пафос, ялган батырлык күп булган ул әсәрләрдә, ә кешеләргә дөреслекне белү кыйбат. Шәхсән мин үзем, Х. Мөҗәйнең "Сугыш көндәлекләре" дигән документаль язмаларын сугыш турында язылган бик күп ясалма әсәрләрдән өстен саныйм.

Бу чорда, әлбәттә татар әдәбиятынын җанын тәшкил иткән авыл дөньясын, аның кешеләрен тасвирлау тагын да җанлана төште. Бу хакта дәлилле итеп күп сөйләп булыр иде, кайбер әсәрләрне атап китү белән генә чикләнәм. "Әйтелмәгән васыять"—Ә. Еники, "Артта калган еллар"—Н. Фәттах, "Берәү", "Язгы кәрваннар"—А. Гыйләҗев, "Шинельсез солдатлар"—В. Нуруллин, "Тау ягы повесты"—Ә. Баян, "Бер ананың биш улы"—Х. Сарьян... Сугыштан соңгы чордагы авыл турында язылган әсәрләрнең иң характерлыларын Мөхәммәт Мәһдиев иҗат итте дип беләм. Аның әсәрләрендә—сугыштан соңгы авыл рухы бөтен нечкәлекләре белән чагылыш таба. Әсәрләреннән берсен генә аерып искә алу килешми кебек. "Без—кырык беренче ел балалары", "Фронтовиклар", "Кеше китә, җыры кала", "Торналар төшкән җирдә... Гомумән, М. Мәһдиевнең әдәби иҗатта үзен, "мин 60-90 еллар язучысы" дип тә әйтерлеге булды. 60 еллар ахырында әдәбиятка килеп, утыз еллап иҗат итеп, ни аяныч, 90 еллар уртасында, үлмәс әсәрләр калдырып, китеп тә барды...


*Якташлар—Татарстанның халык шагыйре Сибгат Хәким, халык язучылары—Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев. Арткы планда—шагыйрә Роза Хәлиуллина. 1984 ел.*

Татарның бар дөньяга шауларлык тарихы булса да, дөресен әйтик, аны юньләп белгәннәр бик сирәк. Җинелгәннәр үзенең чын тарихын яза алмый. Җиңгәннәр үзләренең үткәнен бөекләтеп язганда, аста калган халык тарихы юкка чыгарыла... Шулай да... халык тәне суынмаган бит әле! XX гасырның беренче чирегендә тарихи әсәрләр язу беркадәр башланса да, 30-50 елларда бу хәрәкәт туктап кала. Ниһаять, 60 еллар башында әкренләп "боз кузгалды", "беренче карлыгачлар"дан—Н. Фәттахның "Этил суы ака торур" әсәре булды. Бераздан шул ук авторның—"Сызгыра торган уклар"ы язылды. Соңрак бу эшкә М. Хәбибуллин ("Кубрат хан"), Ж. Рәхимов ("Батырша"), Р. Батулла ("Сөембикә кыйссасы"), Ф. Латыйфи ("Хыянәт") кебек язучыларыбыз алынды.

Әдәбияттагы төп казанышлар турында сөйләгәндә, бу дәвердә Республиканың (соңрак Дәүләт дип әйтелә башлады) Г. Тукай премиясен алган әсәрләрне һәм аларның авторларын искә төшереп үтсәк, әдәби хәзинәбез тулырак күз алдына килер. Кырыктан артык лауреат язучының утызга якыны бу дәрәҗәле исемне 60-90 елларда алган. Укучыларыбыз өчен мәгълүмат тулы бер бөтен булсын өчен, еллар исәбен чигендереп, бүгенге көнгәчә булган лауреатлар исемлеген хронологик тәртиптә тулысынча санап китик. Әхмәт Фәйзи—"Тукай" романы өчен (1958). (Тукай премияләрен бирә башлау шушы елдан башлана). Габдрахман Әпсәләмов—"Сүнмәс утлар" романы (1959), Сибгат Хәким—"По зову Ленина", "Җил исми—яфрак селкенми" исемле шигырь китаплары өчен (1960), (1961-1965 елларда премия бирелү туктатылып торылды), Хәсән Туфан—"Сайланма әсәрләр" китабы (1966), Нәкый Исәнбәт—"Татар халык мәкальләре" дигән өч томлы хезмәт (1968), Ибраһим Гази—"Онытылмас еллар" роман-трилогиясе (1969), Фатих Хөсни—"Гыйльмениса һәм аның күршеләре" повесте (1972), Шәукәт Гали—"Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр", "Котбетдин мәргән", "Шәвәли", "Тәмле йорт" китаплары (1972), Гариф Ахунов—"Чикләвек төше" повесте (1973), Мирсәй Әмир—"Агыйдел" пьесасы (1974), Нил Юзиев—"Шигырь гармониясе", "Хәзерге татар поэтикасы" китаплары (1974), Диас Вәлиев—"Дарю тебе жизнь" (русча) пьесасы (1976), Марс Шабаев—"Җикән камыш", "Онытма", "Сине эзлим" дигән шигырь китаплары (1976), Гамил Афзал—"Айлы кичләр" китабы, "Борылам да карыйм" исемле шигырь циклы (1977),

Равил Фәйзуллин—"Шигырьләр һәм поэмалар" китабы (1978), Туфан Миңнуллин—"Ай булмаса, йолдыз бар" драмасы (1979), Илдар Юзеев—"Таш диварлар авазы", "Өзелгән кыллар" поэмалары (1980), Атилла Расих—"Язгы авазлар", "Ике буйдак", "Ямашев" романнары (1981), Ибраһим Нуруллин—"Тукай турында китаплар" (1982), Аяз Гыйләҗев—"Жомга көн кич белән", "Әтәч менгән киртәгә" повестьлары (1983), Әмирхан Еники—"Повесть һәм хикәяләр" (1984), Гәрәй Рәхим—"Кара йөзләр" операсы өчен либретто (1984), Нури Арслан—"Иделем—Илем" исемле шигырь һәм поэмалар китабы (1985), Хисам Камал—"Һәркемнең гомере бер генә", "Безне өйдә көтәләр" китаплары (1986), Марсель Зарипов "Поступь моей республики", "Выгодный оборот" исемле публицистик китаплар (1987), Мәхмүт Хәсәнов—"Язгы ажаган" романы (1988), Мөхәммәт Мәһдиев—"Кеше китә—жыры кала", "Торналар төшкән жирдә", "Бәхилләшү" повестьлары (1990), Әбрар Кәримуллин—"У истоков татарской книги", "Татарская книга XX века" h. б. китаплары (1991), Гөлшат Зәйнашева—"Илле жыр" китабы (1991), Мөдәррис Әгъләмов—"Киләчәккә кайту", "Мин әйттем" исемле шигырь китаплары (1992), Ринат Мөхәммәдиев—"Сират күпере" романы (1993), Нурихан Фәттах—"Сызгыра торган уклар" романы (1994), Фәнис Яруллин—"Жан авазы" шигырь китабы (1995), Гомәр Бәширов— "И язмыш, язмыш" китабы (1996), Ренат Харис—"Хисемнең жиseме" исемле шигырьләр һәм поэмалар китабы (1997), Роберт Миңнуллин—"Кучтәнәч" исемле китап (1998), Әхсән Баянов—"Урланган ай" китабы (1999), Зөлфәт (Маликов Дөлфәт)—"Ике урман арасы", "Йөрәгемне былбыл чакты" шигырь китаплары (2000), Роберт Әхмәтжанов—"Тургай тәрәзәсе", "Кичке кошлар" исемле шигырь китаплары (2001), Якуб Зәнкиев—"Иртыш таңнары" романы (2002), Мөсагыйт Хәбибуллин—"Кубрат хан" китабы (2003), Миргазиян Юныс "Альбатрос язмышы", публицистик язмалар (2004). Җәмгысе—кырык дүрт язучы, илледән артык әсәр (Бу исемлекне җентекләбрәк укыган кеше анларга кыен моментларны да искәртер: әйтик, бу премияне Д. Вәлиев 1976 елда алса, ә Ә. Еникигә 1984 елда; М. Зариповка—1987 елда булса, ә Г. Бәшировка—1996 елда бирелә... Милли әдәбият зарурлятеннән караганда, бу язучыларның "авырлык категорияләре" төрле, бүтәнчәләп әйтсәк, пәри башка да, жен башка! Мондый алогизмнар тагын бар әле бу исемлектә. Гомумән, Тукай премияләре тарихы—үзе бер патетик драма ул. Әгәр кырык дүрт язучы лауреат булса, иң киме тагын шул чама санда башка дәгъвачылар да булган бит әле, арасында лаеклылар да... Күпме эмоциональ киеренкелек, дулкынланулар, тетрәнүләр, сөенечләр, үпкә-рәнжүләр! Язар өчен аерым бер тема). Тукай премиясенә лаек булган әсәрләрне иҗат итүдә Язучылар оешмасының тәэсире яки файдасы күпмедер, анысы бәхәсле, әмма өләшүдә, ягъни бирелү процессында роле шактый (тәкъдим итү, премияләр комитетында яклау), һәрхәлдә монарчы шулай булып килде. Дөрес, соңгы елларда Язучылар берлеге тәкъдим иткән кандидатлар лауреатлыкка бик "үтми" башладылар әле...



*Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатларыннан бер төркем. Утырганнар, сулдан уңга—Заһит Хәбибуллин, Җәүдәт Фәйзи, Шәхсәнәм Әсфәндиярова, Хәсән Туфан, Александр Ключерев; басканнар—Эрнест Гельмс, Айрат Арсланов, Марсель Сәлимҗанов, Николай Ключерев, Шәүкәт Биктимиров. 1970 ел.*

*

"Торгынлык" еллары... Кем ничек кенә бәяләмәсен, "житлеккән социализм"

чорынын үз тәртибе хөкем сөргән тотрыклы да иде ул еллар. Коммунистлар партиясенең кайбер демократик алымнарны үзләштереп идарә итүенең үз апогеенә житкән еллары. Язучылар союзлары да, партиянең ышанычлы таянычы буларак (дөрес, язучы халкы арасында да төрлесе бар: диссидентлы да, эзоп телендә язучысы да...), үз функциясен төгәл үтәп килә. Партжыелышлар да, политукулар да, семинар-пленумнар да планлы рәвештә бара. Әлбәттә, язучыларның иң югары органы булган съездлар да. Мозаик пландагы язмамны бер үзәккә җилемләп торучы әнә шул съездларга янәдән кайтыйк. Бу дәвердә язучыларыбыз делегат булып өч төрле дәрәҗәдәге съездларда катнашалар: СССР, РСФСР, ТАССР съездларында (бу елларда СССРның биш—IV-VIII съездлары, РСФСРның биш—II-VI съездлары, Татарстанның җиде—V-XI съездлары үтте). Безнең әдәби хәрәкәт тарихы—үз съездларыбызда. Аларның байтагы турында информацион характерда гына булса да язып уздым инде. Хәзер чираттагылары турында да әйтеп үтим (бәлки кемнәргәдер бу кадәр саннар, исемнәр, даталар санап китү ошап та бетмәс, әмма социологик эссе характерындагы язмамдагы фактик материал әдәбият тарихын өйрәнүчеләр өчен киләчәктә кирәк булуы ихтимал).

**Татарстан язучыларының VIII съезды 1974 елның 24-25 май көннәрендә Казанның политик-мәгариф йортында үткәрелде.** Татарстан Язучылар союзы идарәсенең 1968-1974 еллардагы оештыру-иҗат эшчәнлеге турында отчет-хисап докладын Зәки Нури ясады. Моннан тыш, проза турында Гариф Ахунов, поэзия турында Илдар Юзеев, драматургия буенча Туфан Миңнуллин, тәнкыйть турында Рафаэль Мостафин, балалар әдәбияты буенча Ләбибә Ихсанова, рус язучыларының иҗаты турында Тихон Журавлев докладлары тыңланды. Ревизия комиссиясенең отчетын комиссия председателе Гариф Гобәй ясады. 25 май көнне докладлар буенча фикер алышуларда Р. Ишморат, Ә. Баян, Ү. Саттаров, С. Хәким, Р. Фәйзуллин, Н. Жиһанов (композитор), Ф. Миңнуллин, Ш. Хамматов, Х. Госман, А. Әхмәдуллин, Ә. Маликов, Р. Жиһаншина (артистка), Ә. Тумашев (рәссам) һ. б. катнашты. Съездга килгән кунаклардан С. Михалков (Мәскәү), О. Савицкий (Минск), Ф. Гарин (Киев), Б. Байкабулов (Ташкент), А. Алиев (Ашхабад), А. Аетбаева (Фрунзе), И. Араз (Баку), Н. Дедушкин (Чабаксар), И. Пеняев (Саранск), С. Вишневский (Йошкар-Ола), Г. Сабитов (Ижевск) котлау-чыгышлары ясадылар. Съездда КПСС өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев речь белән чыкты. Съезд тикшерелгән мәсьәләләр буенча карарлар кабул итте, союзның җитәкче органнарын сайлады. Идарә составына түбәндәге язучылар сайланды: Гариф Ахунов (председатель), Равил Фәйзуллин (җаваплы секретарь), Мирсәй Әмир, Азат Әхмәдуллин, Гомәр Бәширов, Әхсән Баянов, Марсель Зарипов, Мәдинә Маликова, Әдип Маликов, Туфан Миңнуллин, Зәки Нури, Вакыйф Нуруллин, Геннадий Паушкин, Атилла Расих, Шамил Рәкыйпов, Гәрәй Рәхим, Хәсән Туфан, Мөсәгыйт Хәбибуллин (оештыру эшләре буенча секретарь), Сибгат Хәким, Марс Шабаев, Илдар Юзеев.



*Габдулла Тукайның тууына 100 ел тулган көннәрдә Казанда аның исемендәге музей ачылды. 1986 ел.*

Ревизия комиссиясе председателе итеп Рәис Даутов сайланды.

Бу рәсми хроникага тартым белешмәгә тагын нәрсә өстәргә? Шул елларны характерлый торган кайбер фактлар, вакыйгалар. Ленинның тууына 100 ел, Татарстан АССР төзелүгә 50 ел тулган еллар бу (VII белән VIII съезд арасын әйтүем).

Шуңа күрә бу даталар унае белән Казанда да, Мәскәүдә дә бик күп чаралар үткәрелгән. Конкрет язучылар тормышына караган вакыйгалардан—Муса Җәлил турында "Ленфильм"да "Моабитская тетрадь" исемле кинофильм чыга; өлкән язучыларыбыздан Н. Исәнбәт, Х. Туфаннарның 70 яшьлек юбилейлары үтә; С. Хәкимгә РСФСРның М. Горький исемендәге премиясе бирелә; татар язучылары Донбасска барып әдәбият көннәре үткәреләр, шул ук җәйне (1972) Ворошиловград өлкәсеннән җавап визиты белән украин язучылары Татарстанга килә... Бу елларда Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премияләре булдырыла. Язучылардан беренче лауреатлар: И. Юзеев (1970), Р. Фәйзуллин (1972). Гомумән, ассызыклап әйтеп үтәргә кирәк, 70 нче еллар башында яшь иҗат көчләренә хакимият тарафыннан игътибар зур булды. 1969 ел ахырында ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты каршында "иҗади яшьләр оешмасы" төзелде, җитәкчесе итеп Р. Батулла билгеләнде. Шул елларда Актерлар йортында үтә торган "Ядкарь" кичәләрен өлкәнрәк буын иҗатчылар яхшы хәтерли булыр. Халыкара яшьләр лагеры—"Волга"да ("Идел"дә) һәр ел саен яшь язучылар, рәссамнар, композиторлар, актерлар катнашында бер атнага сузыла торган республика семинарлары...



*Яшь шагыйрьләр "Волга" лагерында. Сулдан уңга—Рөстәм Акъегет (Фәйзуллин), Зөлфәт, Марсель Галиев. 1972 ел.*

VII нче съезд белән VIII нче арасында идарә җитәкчелегендә дә үзгәреш булды. 1968 елда язучылар союзы җитәкчесе итеп И. Гази сайланган иде. Рәис статусында ул СССР Верховный Советы депутаты, РСФСР Язучылар союзы секретаре, КПССның өлкә комитеты члены, КПССның чираттагы съезды делегаты булды. Әмма... 1971 елның февралендә И. Гази көтмәгәндә вафат булды. Аның урынына З. Нури билгеләнде. Шуңа күрә Союз идарәсенең 1968-74 еллардагы оештыру-иҗат эшчәнлеге турында отчет-хисап докладын ул ясады да. Рәислек елларында З. Нури да СССР Язучылар союзы секретаре булып эшләп алды.

**Татар язучыларының IX съезды 1979 елның 23-24 май көннәрендә үтте.** Анда өч йөзгә якын язучы, Мәскәүдән, союздаш һәм автономияле республикалардан килгән кунаклар, Татарстанның партия, профсоюз һәм комсомол оешмалары вәкилләре, сәнгать эшлеклеләре, промышленность, авыл хуҗалыгы һәм культура хезмәткәрләре катнашты. Съездны шагыйрь Сибгат Хәким ачты. Республика язучыларының иҗаты һәм идарә эшчәнлеге турында хисап докладын Гариф Ахунов ясады. Ревизия комиссиясенең биш еллык эше белән Рәис Даутов таныштырды. Өстәмә докладлар—Атилла Расих (проза), Нил Юзиев (поэзия), Азат Әхмәдуллин (драматургия), Мөхәммәт Мәһдиев (тәнкыйть), Шәукәт Галиев (балалар әдәбияты), Марсель Зарипов (очерк һәм публицистика), Геннадий Паушкин (рус язучылары иҗаты), Илдар Юзеев (яшь язучылар белән эшләү), Әдип Маликов (Әлмәт оешмасы эшчәнлеге) тыңланды. Фикер алышуларда З. Нури, Р. Мостафин, Ә. Гаффар, Ф. Мусин, К. Тимбикова, Ә. Тумашев (Рәссамнәр союзы), В. Нуруллин, Ш. Хамматов (Журналистлар союзы), Ф. Газизуллин (Комсомолның Татарстан өлкә комитеты секретаре, соңрак Россиянең дәүләт милке министры булды), Ф. Әхмәтов (Композиторлар союзы) һ. б. катнашты.

Съезд кунаклары С. Михалков (Мәскәү), Ә. Мирзаһитов (Башкортстан), А. Мороз (Украина), Ш. Муртазаев (Казакъстан), Л. Прокша (Белоруссия), А. Емельянов (Чувашстан), О. Абдрахманов (Каракалпакстан), Н. Нефедов (Мәскәү) татар әдәбиятын олылап, коллегаларына тәбрик һәм киңәш сүзләрен житкерделәр. Съездга,

шулай ук КПСС өлкә комитетының идеология буенча секретаре М. Вәлиев чыгыш ясады.

Съезд Татарстан Язучылар союзы идарәсен түбәндәге составта сайлады: Гариф Ахунов (председатель), Азат Әхмәдуллин, Әхсән Баянов, Шәүкәт Галиев, Тәлгат Галиуллин, Әдип Маликов, Мәдинә Маликова, Туфан Миннуллин, Роберт Миннуллин, Фәрваз Миннуллин (җаваплы секретарь), Мөхәммәт Мәһдиев, Зәки Нури, Вакыйф Нуруллин, Геннадий Паушкин, Атилла Расих, Хәсән Туфан, Равил Фәйзуллин, Сибгат Хәким, Ренат Харис, Илдар Юзеев. М. Хәбибуллин оештыру эшләре буенча секретарь итеп билгеләнде.



*Язучылар съездының президиумында. Фикърәт Табиев, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким. 1979 ел.*

Республика Язучылар союзының ревизия комиссиясе председателе итеп янадан Рәис Даутов, Әдәби фонд председателе итеп Азат Әхмәдуллин сайланды.

Рәсми белешмә стилендә тагын бер съезд—X съезд турында да информация биреп узыйк. Алай эшләгәндә, бу ике съезд хисап биргән унъеллык (1974-1984) турында кайбер фикерләр әйтеп, гомумкүзәтүләр ясау җинелрәк булыр. Ул елларны күз алдына китерү өчен анык ориентирлар: бу—Язучылар союзында рәис булып Гариф Ахунов торган еллар. Партия өлкә комитетында идеология буенча җаваплы җитәкчеләр—секретарь (өченче секретарь дип йөртелә иде) Мөҗәһит Вәлиев, культура бүлеге мөдире Мөдәррис Мусин, куратор-инструктор Илгиз Хәйруллин. Минем үземә дә бу чорда—1973-77 еллар аралыгында Язучылар союзында җаваплы секретарь (рәис урынбасары) булып эшләргә туры килде. Шуңа күрә байтак вакыйгаларның турыдан-туры шаһитемен.

**Татарстан язучыларының X съезды 1984 елның 21-22 май көннәрендә Казанның Политик-мәгариф йортында үтте.** Съездны шагыйрь Сибгат Хәким ачты. Республика язучыларының иҗади эшчәнлеге һәм идарәнең ике съезд арасындагы биш еллык эше турындагы отчет-хисап докладын идарә председателе Гариф Ахунов ясады. Съездның беренче көнендә өстәмә докладлар да тыңланылды: поэзия (Илдар Юзеев), проза (Мөхәммәт Мәһдиев), драматургия (Туфан Миннуллин), тәнкыйть (Тәлгат Галиуллин), балалар әдәбияты (Шәүкәт Галиев), очерк һәм публицистика (Марсель Зарипов), рус язучыларының иҗаты (Нонна Орешина), тәрҗемәчеләр эшчәнлеге (Кыям Миңлебаев).

22 майда съезд эшен дәвам иттерде, докладлар буенча фикер алышулар булды. Чыгыш ясаучылар—С. Михалков (Мәскәү), Разил Вәлиев, Р. Мөхәммәдиев, Р. Мингалим, Р. Миннуллин, Н. Доризо (Мәскәү), Р. Харис, Г. Шәрәфетдинов (Татарстан китап нәшрияты директоры), Б. Мөлеков (композитор) һ. б.

Татарстан язучылары форумын Ә. Мирзаһитов (Башкортстан) А. Емельянов (Чувашстан), Г. Имамвердиев (Әзәрбайҗан), В. Карамазов (Белоруссия), К. Укаев (Кыргызстан), Т. Тула (Үзбәкстан), Н. Бәйрәмов (Төркмәнстан), Т. Жумаморатов (Каракалпакстан), Н. Рыбаков (Мари-Эль), С. Самсонов (Удмуртия) тәбрикләде. Съездда, шулай ук, КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев чыгыш ясады.

Съезд Татарстан Язучылар союзы идарәсенең һәм ревизия комиссиясенең яңа составларын сайлады. Съездда сайланган идарә әгъзалары: Туфан Миннуллин (председатель), Азат Әхмәдуллин, Гариф Ахунов, Николай Алешков, Әхсән Баянов, Разил Вәлиев (председатель урынбасары), Шәүкәт Галиев, Тәлгат Галиуллин, Әхәт Гаффар, Аяз Гыйләҗев, Зөлфәт Маликов, Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев,

Мәдинә Маликова, Роберт Миннуллин, Фәрваз Миңнуллин, Флүн Мусин, Ринат Мөхәммәдиев, Вакыйф Нуруллин, Нонна Орешина, Равил Фәйзуллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин (җаваплы секретарь), Сибгат Хәким, Ренат Харис, Илдар Юзеев.

Ревизия комиссиясе председателе итеп янадан Рәис Даутов сайлана. "Казан утлары" журналының баш редакторы итеп Ренат Харис раслана.



*Татарстан язучыларының X съездында катнашучылардан бер төркем. Сулдан уңга—Лирон Хәмидуллин, Ибраһим Нуруллин, Сакен Жунусов, Шерхан Мортазаев, Зөһрә Мирзаһитова, Әсгать Мирзаһитов, Әмирхан Еники, Туфан Миңнуллин. 1979 ел.*

Еллар агышына, эш барышына карап дигәндәй, тора-бара идарә составында да үзгәрешләр булды. Р. Вәлиев Республика китапханәсенә (хәзер Татарстан республикасы милли китапханәсе дип атала) директор итеп билгеләнгәч, рәис урынбасары вазифаларын Ризван Хәмид башкарды, сонрак аны Гәрәй Рәхим алыштырды.

*

1970-1980 еллар (үзгәртеп кору чорына кадәр), мөгаен, күпмилләтле Совет әдәбияты дип йөртелгән әдәбиятның иң югары биеклегенә ирешелгән еллары булгандыр. Иң яхшы дип саналган әсәрләр Ленин, СССР Дәүләт премияләре белән билгеләнделәр. 80 еллар ахырында илкүләм танылган дистәләгән язучыга Социалистик Хезмәт Герое исеме бирү хәлләре дә булып алды. Бөтенсоюз, хәтта бөтендөнья масштабындагы дан-хөрмәткә лаек булганнар арасында, руслардан тыш, бүтән халыкларның әдипләре дә бар иде. Гадәттә, һәр республикадан берәр зур шәхес күтәрелде яки күтәрделәр (Ч. Айтматов—Кыргызстан, Э. Межелайтис—Литва, Р. Гамзатов—Дагстан, М. Кәрим—Башкортстан, Д. Күгелтинов—Калмыкстан, С. Капутикян—Әрмәнстан, К. Кулиев—Кабарда-Балкар)...

Совет әдәбиятының балкыган чорында бу когортада татар әдәбиятыннан да берәр вәкил булуы көтелгәндер. Табигый хәл. Төрле тарафларга таралып, әле татарлыгын җуймаган милләттәшләргә дә горурлык хисе тудырыр өчен дә кирәк булгандыр әле андый шәхес. Әмма, популярлыклары һәм рәсми танылуы буенча Р. Гамзатов яки Ч. Айтматовлар дәрәҗәсендәге шәхес бездә пәйда була алмады. Дөрес, заманында Г. Әпсәләмовне, Н. Исәнбәтне Социалистик Хезмәт Герое ясарга дигән фикерләр булгалады, С. Хәким Ленин премиясенә тәкъдим ителеп каралды... Барып чыкмады, шул заман өчен бездән "символ" табылмады. Юкса, яхшы әсәрләр тудырган һәм перспективасы булган әдипләребез бар иде шикелле. Берәү дә классик булып тумый. Биюченең итәкләре бии-бии кыскара дигән шикелле, әдип кеше дә, шартлар, мөмкинлек һәм терәк булганда гына үсә ала. Бәлки, үзебезнең "милли менталитет"ыбыз—бер-беребезнең үсүеннән күпсенүебез комачаулагандыр; бәлки биек сәяси Олимптан—татарларга бу чор өчен Муса Җәлил дә җитеп торыр, дип исәпләгәннәрдер... Әмма ул чорда "бөтенсоюз аренасы"на чыгып, татар әдәбиятын бүтән халыкларга да белдерү нияте белән иҗат итүчеләр дистәләгән иде. Бу—нормаль хәл, һәрхәлдә ул еллар өчен табигый хәл. Әсәреңне дөнья базарына чыгарып сынау теләге, хәтта, хуплауга лаек. Әмма бу ярышның үз тәртибе, үз кануннары бар: әсәрең дөнья телләренә, безнең шартларда, беренче чиратта, рус теленә тәрҗемә ителү мөһим иде. Бу чорда, чыныннан да, байтак татар язучыларының әсәрләре Мәскәү нәшриятларында русча тәрҗемәдә чыкты да. Бер елда Үзәкнең төрле дәүләт нәшриятларында ун-унбиш, кайбер елларны егермеләп китап чыга

иде. Араларында, урта кул авторларныкы очраштыргаласа да, нигездә, хәзинәбездә булганнын ин яхшы дигәннәре чыкты. Әгәр тәрҗемә булмаса, шул ук Җәлилне яки Әпсәләмовне дөнья халыклары белә алыр идеме?

70-80 еллардагы әдәби хәрәкәтнен бер унай күренеше (күрсәткече дияргә дә ярыйдыр)—язучыларыбызнын бүтән әдәбият вәкилләре белән даими аралашуы, үзара йөрешүе. Әдәбият көннәре, әдәбият-сәнгать декадалары, бөтенсоюз яки региональ семинарлар, иҗади-фәнни конференцияләр, теге яки бу әдипнен юбилейлары... Аларнын һәрберсенә диярлек Татарстаннан вәкил булып кемдер барды. Әлбәттә, андый җирләргә республика исеменнән сөйләрлек, әсәрләре кин җәмәгатьчелеккә билгеле, язучы буларак дәрәҗәле-ләр бара иде. Заманында төрле республикаларга З. Нури, Г. Ахунов, С. Хәким, Р. Мостафин, Р. Харис һәм тагын кайберәүләр күп йөрделәр. Минем үземә дә СССРнын бөтен республикаларын диярлек гизеп чыгарга туры килде, сирәгрәк булса да, рәсми делегацияләр составында чит илләргә дә чыгылды, 1985 елда СССР Язучылар союзы делегациясенен җитәкчесе сыйфатында Италия кебек илләргә дә барып жителде. Чит ил диметән, бу елларда татар язучылары төрле илләргә шактый еш чыга башладылар. СССР һәм РСФСР Язучылар союзларында чит ил эшләре комиссияләре язучылар өчен махсус туристик сәяхәтләр оештыра иде. Бүгенге белән чагыштырганда, символик бәягә атна-ун көн дәвамында Европа, Азия илләрен гизеп кайта иде язучыларыбыз. Ул елларда безнен байтак каләмдәшләр бу мөмкинлекләрдән даими файдалана белделәр. Язучы халкынын кадере һәм мөмкинлекләре шактый иркен булган димәк! Бу чорда драматургларнын эшләре бигрәк тә яхшы барды (хәер, матди яктан алар һәр чорда да чагыштырмача яхшырак яшәделәр), төрле республикаларда, өлкәләрдә аларнын пьесалары буенча спектакльләр еш куелды. Безнен театр коллективлары да бөтен СССР кинлекләрен гизделәр, аеруча Казакъстан, Урта Азия якларында җәй саен гастрольләрдә булып, халыкны туплау, рухи берләштерү юлында тарихи миссия башкардылар.



*Эстониядә татар әдәбияты көннәрендә катнашучылар Таллин шәһәренең Татар урамында. Сулдан уңга—Зиннур Мансуров, Мөхәммәт Мәһдиев, тәрҗемәче С. Митт, Равил Фәйзуллин, Аяз Гыйләҗев, Ләбиб Лерон, Ренат Мөхәммәдиев, Мөдәррис Вәлиев. 1989 ел.*

*

1980 елны Чаллыда язучылар бүлеге ачылды. 60 еллар башында Әлмәттә Язучылар оешмасы ачылуга Татарстанда зур нефть чыгу сәбәп булса, Чаллыдагы бүлек оешу КамАЗ төзелешенә бәйле. Бу ике оешманын төзелү-оешу тарихы Гариф Ахунов исеме белән аерылгысыз. Әлмәттәге язучылар оешмасынын беренче җитәкчесе ул булды, ә Чаллы оешмасы—анын Язучылар союзы рәислеге чагында ачылды. Әлбәттә, җирлек, тиешле зәмин юк җирдә оешма кадәр оешма төзеп булмас иде. Чаллы бүлеге—шул төбәктә актив эшләгән ике төп әдәби берләшмә нигезендә барлыкка килде: берсе—Чаллыдагы "Ләйсән"(җитәкчесе—Р. Лотфуллин), икенчесе—Түбән Камадагы "Кама таңнары" (җитәкчесе—Р. Хисмәтуллин). Сонрак Зәйдәге "Зәй энҗеләре" (җитәкчесе—Р. Сәлимҗанов) берләшмәсе дә килеп кушылды. Чаллынын җыелма халкы шикелле, язучылар оешмасы да, нигездә, төрле тарафлардан килгән төрле язучылардан хасил булды. Берара җитәкчеләрне дә, Әлмәт мисалынчарак, Казаннан китереп кую хәлләре дә булды (Разил Вәлиев). Киләсе елга бу



Чаллы Язучылар оешмасы әгъзалары. Сулдан уңга: Равил Нотфуллин, Хәниф Хәснуллин, Кадыйр Сибгатуллин, Вахит Имамов. 80 еллар башы.

оешманың төзелүенә 25 ел тула. Үзенә күрә бер юбилей. Шул чакта күбрәк, тәфсилләбрәк сөйләрләр әле. Зур югалтуларны да кичерергә өлгерде инде бу оешма: төрле елларда бүлек эшен житәкче булып жигелеп тарткан Э. Касимов, Г. Кашапов, Я. Игәнәйләр инде гүр ияләре... Шулар рәтендә—С. Рафиков, Х. Хәснуллин, Н. Мадъяров, Р. Хисмәтуллин, З. Гомәрова... Шулай да, әлегә шактый көчле каләмдәшләребез яши Чаллыда (А. Хәлим, Ф. Әмәк, Ф. Бәйрәмова, В. Имамов, Р. Бәшаров һ. б.). Әдәби хәрәкәтне берләштерүдә Чаллы язучыларының үз әдәби басмасы булу да бик мөһим. 1991 елдан гасыр ахырына кадәр "Аргамак" журналы чыкты, соңрак аның урынын "Мәйдан" алыштырды. Бу журнал хәзер татар матбугатында чыннан да үзенең абруйлы мәйданын яулап килә.

*

Ул чорларда Язучылар союзы каршындагы партия оешмасының бик актив эшләвен әйтергә кирәк. Ай саен бер тапкыр тәгаен уза торган партия жыелышлары язучыларны үзенчә туплау, берләштерү ролен үтәп килде. Көн тәртибенә рәсмирәк мәсьәлә (әйтик, фәлән "съезд яки пленум карарлары яктылыгында язучылар алдында торган бурычлар") куелса да, язучылар, партиялеме, партиясезме, барыбер, әдәбият турында, актуаль проблемалар турында житди итеп сөйләшәләр, киңәшләшәләр иде, ниндидер проблемаларны хәл дә итәләр иде. Хәзер өлкәннәр үзгә бер ностальгик хис белән искә алалар ул елларны, ул жыелышларны. Язучыларның партия оешмасы бездә, күрәсең, шактый демократик булган. Мәсәлән, безнең оешмада композитор Сара Садыйкова, библиограф Асия Гыйниятуллина һәм башка тармакта эшләүче кайбер пенсионерлар да әгъза булып тора иде. Оешма булгач, аның житәкчеләре—партоешма секретарьләре да бар, әлбәттә. Комиссарлар кебегрәк булып чыга инде. Ул елларның парторглары—Г.Гобәй, Г. Минский, Л. Ихсанова, Р. Мостафин, В. Нуруллин, Т. Миннуллин, Р. Мөхәммәдиев, Р. Кәрамиләр яхшы хәтердә. Партия таркалыр алдыннан соңгы парторг К. Латыйп булды.

Әлбәттә, төрлесе булды ул жыелышларда. Партия өлкә комитеты даирәләренең таләпләренә туры килеп житмәгән әсәрләр басылган яки басылырга әзерләнгән очракта, партияле каләмдәшләр, ишарә булу белән дигәндәй, андыйларны оператив рәвештә тәнкыйть итәргә һәрвакыт әзер иделәр. Ул елларда иң күп "тукмаклар" алган кеше, мөгаен, шагыйрь Салих Баттал булгандыр. Аның "Батый ханга хат" дигән поэмага тартым озын шигыре тирәсендә генә дә сүз куертулар дистә елларга сузылды... Шулай ук, Әмирхан Еники ("Саз чәчәге"), Нурихан Фәттах ("Сызгыра торган уклар", Мөхәммәт Мәһдиев ("Фронтовиклар"), Аяз Гыйләжев ("Өч аршин жир") әсәрләре дә үз вакытында актив коммунист иптәшләр тарафыннан шактый ук "чыбыркыландылар".

Партия заманында интернационализм дигән сүз киң кулланута иде. Кызганыч, бу сүз сирәгрәк ишетелә башлады. Күпләр өчен интернациональлекнең иң яхшы билгесе—доллар яки евро хәзер. Интернационализм, минемчә, бөек төшенчә. Дөньяда халыклар дуслыгы дигән нәрсә булса, аның нигезе шушы төшенчә белән бәйле. Татарстан Язучылар союзы гомер-гомердән яхшы мәгънәдәге интернациональ оешма булды. Татар телле язучылар да, рус телле яки башка бүтән телдә язучылар да бердәм, тату ижади хезмәттәшлектә яшәделәр. Татарстанда һәрвакыт рус язучыларының зур төркеме яшәде. Кайбер исемнәрне генә искә төшерик:



*Чуваш язучыларыннан бер төркем. 70 еллар.*

М. Бубеннов, Т. Журавлев, А. Салмин, С. Радзиевская, Г. Паушкин, М. Скороходов, Я. Винецкий, Ю. Белостоцкий, Н. Орешина, В. Корчагин... Шулай ук милләте белән татар, әмма рус телендә иҗат итүчеләр—И. Кәлимуллин, Р. Кутуй, Д. Вәлиев, Р. Бохараев, М. Зарипов, А. Мушинский, Роза Кожевникова, Л. Газизова... Безнен оешма жирлегендә чуваш язучылары секциясе дә унышлы эшләп килде (шунысы игътибарга лаек: бүтән республикаларда һәм өлкәләрдә яшәгән татар язучыларының беркайчан да диярлек ни оешмалары, ни иҗади секцияләре була алмады. Соңгы елларда Башкортстанда татар язучылары оешмасы борынлады борынлавын...) Дөрес, республикада чуваш телендә язучылар сирәкләнде хәзер. Шулай да, без үз сафларыбызга кардәш халык вәкилләрен алуны дәвам итәбез. Мәсәлән, үткән ел чуваш Евгений Турханны Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп алдык.

*

...Алдарак әйтелгәнчә, 1984 елны Язучылар союзы рәисе итеп драматург Туфан Миннуллин сайланды. Торгынлык еллары дип йөртелгән олы бер чорның соңгы рәисе Гариф Ахунов житәкчелек аренасыннан китте. Үзгәртеп кору еллары якынайган иде инде... Мина калса, Г. Ахунов белән бергә әдәбиятның тулы бер чоры китте, ул гына да түгел, тиздән тарихи Матбугат йортыннан Язучылар оешмасы да күчеп китте...

Һич шик юк, Т. Миннуллин житәкче чагында Язучылар союзының Казандагы иң матур биналарның берсенә күчүе үзе бер тарихи вакыйга (дөрес, яна бинага күчү мәсьәләсе егерме еллар элек үк күтәрелгән һәм ул хәл ителергә тиеш иде). Ул мәһабәт бинаның адресы—Мөштәри урамы, 14. (Ул вакытта Комлев урамы дип йөртелә иде). Яна жир, борынгы булса да, яна йорт, яна хужалар, яна тәртипләр... Язучылар оешмасының соңгы 15 елы шушы бина белән бәйле. М. Галиевнең "Өмә" исемле юмор әсәрендә бу бинага яна күчкән елларның бер хатирәсе бик матур сурәтләнгән.

Әйе, Язучылар оешмасына йомыш төшкәндә без хәзер яна бинага йөрибез. Ә Баумандагы (бу үзәк урам үзенең жисеменә туры килгән берәр исемгә кайчан алыштырылыр икән инде, бу хакта сүз күп булды бит!) Матбугат йортының күңелдән чыкканы юк. Нишлисең, хәтердән китеп булмый: яңа заман татар әдәбиятының татар совет әдәбиятының дисәм дә була, яшьлеге, олпат тулы чагы шушы бинага бәйле шул. Соңгы дистә еллардагы хәлләргә күчкәнче Матбугат йортына бәйле берничә оешма турында берәр кәлимә сүз әйтеп узыйм.

Андый оешмаларның берсе—Әдәби фонд, дөресрәге СССР Язучылар Әдәби фондның Татарстан бүлеге. Икенче катта, коридор өлешне такта белән генә бүлеп алган кечкенә генә бер бүлмә. Кечкенә булса да, мәгънәсе белән төш кенә бүлмә! Язучының тормыш-көнкүреш мәсьәләләренә караган байтак мәсьәләләр хәл ителә иде анда! Кайбер яшь һәм башлап язучылар оешмага кабул ителгәнче (ә бу процесс бик озак—дистә елларга сузылырга, сузылып та, кабул ителмәскә мөмкин), Әдәби фондка кереп, анда әгъза булырга тырыштылар. Чөнки, Әдәби фонд әгъзасы язучыларга бирелгән ташламалар (путевка-юлламалар, төрле пособиеләр, поликлиникаларга билгеләнү, ярдәм акчасы алу һ. б.) белән файдалана ала иде. Үз вакытында С. Сабиров, Ә. Шамин, М. Хәсәен, И. Рәми, Р. Ишморатова һәм тагын кайберәүләрнең язучылар тирәлегендә шул сыйфатта йөрүләре истә калган.

60 еллар башында Әдәби фонд башлыгы Сөнгать ага иде. Фамилиясе Сафиуллин

булганын соңрак белдек. Какча гына гәүдәле, ипле, тыныч кына сөйләшә торган, эшлекле, сабыр кеше булып хәтердә калган. Соңрак (1964-1967 елларда) бу җаваплы урында язучылар Хәсән Сарьян, Мәсгут Шәрифуллиннар (икесе дә Башкортстаннан иделәр, икесенең дә гомерләре кыска булып чыкты: беренчесе 1978 елны 48 яшьтә, икенчесе 1966 елны 38 яшендә вафат булдылар) эшләп алды. Әдәби фонд җитәкчесе булып иң озак (1967-1983 еллар) һәм нәтиҗәле эшләгән кеше—язучы һәм тәрҗемәче Лирон Хәмидуллин булды. Соңгы егерме ел эчендә Әдәби фонд башлыгы булып тагын 5-6 кеше эшләде. 1996 елдан бирле директор—Данил Салихов, җәмәгать тәртибендә Әдәби фондның хәзерге рәисе—шагыйрь Гәрәй Рәхим. Гомумән, Әдәби фонд тарихы һәм эшчәнлеге язучылар тормышында үзе бер аерым хезмәткә лаек сәхифә (алдагы санда Татарстан Әдәби фонды эшчәнлеге турында Л. Хәмидуллинның махсус мәкаләсе басылачак—**ред.**). Язучыларның кавышу-туй хәлләреннән башлап үлем-китем мәшәкатьләренә кадәр Әдәби фондның катнашы булды. Заманында язучылар һәм аларның гаиләләре өчен махсус сабантуйларга кадәр оештыра иде Әдәби фонд егетләре!



*Төрле елларда Әдәби фондта эшләгән язучылар: сулдан уңга—Хәсән Сарьян, Гәрәй Рәхим, Лирон Хәмидуллин. 1978 ел.*

Матбугат йортында урнашкан, заманында уңышлы гына эшләп килгән тагын бер оешма—Татарстан Язучылар союзының матур әдәбиятны пропагандалау Бюросы. 60 еллар ахырында, М. Әмир рәислек иткән чорда оешты ул. (Дөрес, әдәбиятны пропагандалау гел актуаль булып килгән, язучыларның беренче съездларында ук күтәрелә бу мәсьәлә. 1953 елда җәмәгатьчелек тәртибендә берничә язучыдан торган (М. Садри, М. Хөсәен, Г. Шамуков) махсус бер бюро да оештырыла. Әмма аның юридик статусы булмаган, әлбәттә. Соңгы вакытта бу фактны, оешма төзелүнең башы санап, ясалма юбилей да билгеләп йөрделәр әле). Чынлыкта штатта кешеләре, реквизиты, тиешле бүтән атрибутлары булган оешма 1967 елда төзелде. Бер ел элек Мәскәүдә, СССР Язучылар союзында Бөтенсоюз пропаганда Бюросы оешкан иде. 70-80 елларда Советлар Союзының күп республикаларында һәм өлкәләрендә бик тантаналы һәм рәсми рәвештә үтә торган Совет әдәбияты көннәрен (заманында Татарстанда да узды), нигездә, шушы Бөтенсоюз бюросы оештырды да.

Безнең пропаганда Бюросының штаты өч кешедән гыйбарәт иде: директор, әдәби хезмәткәр, бухгалтер. Конкрет эшкә килгәндә, Бюро төрле оешмалар, предприятиеләр, колхозлар белән хезмәттәшлек договорлары төзеп, шул килешү нигезендә берничә язучыдан (арада берәр популяр җырчы белән баянчы да була иде) торган бригада төрле аудиторияләр алдында чыгышлар ясый иде. Бюроның җитәкчеләре булып Мөнип Шәймөхәммәтов (сәнгать буенча аспирантура үткән Сарман ягы кешесе. Мөнип Газар псевдонимы белән шигырьләр дә яза иде), Мансур Шиһапов, Эльс Гаделов, Рифкать Кәрамиләр, әдәби хезмәткәр булып төрле елларда Марсель Галиев, Фәннур Сафин, Хәкимҗан Халиков, Камил Кәримов, Нурислам Хәсәновләр эшләде. Үзгәртеп кору дигән елларда 6-7 ел Бюроның эше тукталып та торды. 2000 елдан янадан торгызылган бу оешманы хәзер Рәдиф Сәгъди җитәкли.

Сүз дә юк, пропаганда бик кирәк нәрсә. Хәзерге заманда бигрәк тә. Реклама индустриясенең көннән көн колачлана баруы тикмәгә түгел. Татар китабы (300 елга якын тарихы бар үзенең!) яклауга, пропагандага аеруча мохтаҗ. Пропаганданың ысуллары күп: радио, телевидение, газета-журнал, буклет-проспектлар, афишалар, төрле видео-аудио кассеталар... Әмма язучының үз укучылары, бигрәк тә мәктәп

балалары белән очрашулары бөтенләй үзгә эффектка ия. Тере язучыларны күрү, алар белән аралашу бала күнелендә гомерлеккә калучан. Әлбәттә, сүз—чын, зыялы язучының югары дәрәҗәдә үткән очрашулары турында бара. Зур мәгънәдә әдәби-әхлакый дәрес булган кичәләр, шөкер, бихисап булды. Шулай да, әдәбият файдасына булмаган аралашу фактларын да танымыйк. Берзаман, әлеге бригадаларда урта кул яки үзешчән дәрәҗәдәге каләм ияләре күбәеп китте (чөнки зур язучылар очрашуларга бик еш чыга алмый, талант иясенен һәр сәгате исәпле). Урта кул каләм ияләре артыннан гөл үсеп калмый, әлбәттә. Минемчә, язучының төп вазифасы артык күренеп йөрү түгел, иҗат итү. Гарәпләрдәге бер әйтемне дә онытмыйк "Мөгайдинен үзен күргәнгә караганда шигырьләрен ишетү хәерлерәк".

Матбугат йортындагы Тукай клубы! Алда аның турында әйтеп үткән идек инде. Тагын берничә сүз өстисе килә. Үзенен 50 елдан артык тарихында кемнәрне генә күрмәгән дә, кемнәрне генә мөнбәреннән сөйләттермәгән ул! Әдәбият-сәнгать өлкәсендәге үзебезнен бөек затларыбыз булган бу бинада: С. Сәйдәшев, Б. Урманче, Н. Жиһанов, Х. Әбжәлилов... Үзебезнен классик язучыларыбызны әйткән дә юк! —Ш. Камал, К. Тинчурин, К. Нәжми, Х. Туфан, Г. Бәширов, С. Хәким... Казанга килгән бик күп атаклы шәхесләр дә язучылар белән очрашырга шушы клубка килгәннәр. Итальянлы Дж. Родари, композитор А. Хачатурян, артист А. Райкин, космонавт В. Терешкова, дингезче Ә. Жиһаншин, атаклы шагыйрьләр М. Кәрим, К. Кулиев, С. Кудаш, Д. Кәгелтинов, Е. Евтушенко, Б. Әхмәдуллина... Төрле елларда клуб директоры булып унга якын кеше эшләде. Алар арасында аеруча эш күрсәткәннәре: 60 елларда фронтовик шагыйрь Маннур Саттаров, 70-80 елларда шагыйрь Әхмәт Рәшитов булды. Хәзер Тукай клубының адресы бүтән: Язучылар берлеге бинасының янкормасында ул. Хәзер анда бүтән кешеләр, бүтән рух... Дөрес, анда да атаклы кешеләр булмый түгел, хәтта 1991 елда Россия Президенты Б. Ельцин да булып, язучылар белән очрашып китте.


*Язучыларның Матбугат йортындагы Тукай клубы.*

Язучылар союзының шактый бай фондка ия үз китапханәсе дә бар иде әле. Ул әле дә бар исәпләнә. Хәзер яңа китаплар белән бик тулыландырылмый шикелле. Ул китапханәдә Брокгауз һәм Эфрон исемнәре белән йөртелә торган, алтын йөгертелгән фолиант томнар да барлыгы истә. Кстати, дип әйтик, яңа союз бинасында, икенче катка менә торган баскыч култыгында—бер сәнгать әсәре—хатын-кыз сурәтләнгән матур бронза сын да бар иде...

Шул ук Матбугат йортында 80 елларда республикакүләм дәрәҗәдә китап сөючеләр җәмгыяте дә эшләп килде. Хәзерге яшьләр өчен сәеррәк янгырыйдыр бу сүзтезмә... Бу язмамны әзерләгәндә яшьләр газетасында бер кечкенә генә хәбәр укыдым да, сискәнеп киттем. "Россия халкының 40 проценты бер дә китап укымый. 80 нче елларда илдә андыйлар 10 процент кына тәшкил иткән. 1990 елда Россиядә 18 мең китап кибете эшләгән булса, бүген алар 3 меңгә калган. Көндәлек газеталарны исә ил халкының 24 проценты гына укый. Чагыштыру өчен: финнарда бу сан 87 процентка тин". Хәтердә: бу оешмада ул вакыттагы яшь язучылар Н. Акмал, А. Хәсәновләр эшләп йөрде... Менә хәзер—халык китаптан бизеп барган чорда кирәктер ул Китап сөючеләр җәмгыяте!

•

Хроникаль күзәтүнен "жеп очын" җуймыйча, X съездан сонгы әдәби халләргә кайтыйк. 1984-89 елларда, шиксез, байтак иҗади-оештыру эшләре башкарылды. Агымдагы эшләрдән тыш, хәтердә җуелмаслыклары—Башкортстанда һәм

Чувашстанда татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре. Шул заманга хас колачлылык, патетик рух, бәйрәмчә тантаналар. 1986 елда Тукайның 100 еллыгы, табигый, монарчы күрелмәгән дәрәҗәдә яхшы үтте. Тугандаш республикалардан да байтак кунаклар килгән иде (1986 елның 26 апреле—Тукай туганга нәкъ 100 ел тулган көн—Чернобыльдәге коточкыч фаҗига көне белән дә тарихка кереп калды).

Туфан Миннуллин идарә иткән чорда "халык шагыйрьләре", "халык язучылары" дигән мәртәбәле исем булдырылды. 1985 елда бу исем турында Татарстан Верховный Советы Указы игълан ителгәннән соң (хәзер ул Президент Указы белән бирелә) бүгенге көнгә кадәр халык шагыйре, халык язучысы исемен йөрткән әдипләрнең саны 17 гә җитте. Күбрәк тә бугай бу сан. Шуларның 10 сы мәрхүмнәр. Әдәбият тарихы белән кызыксынганнар өчен тулы исемлекне санап үтәм: халык шагыйрьләре—Сибгат Хәким (1986), Гамил Афзал (1991), Илдар Юзеев (1993), Шәүкәт Галиев (1995), Равил Фәйзуллин (1999), Фәнис Яруллин (2001), Ренат Харис (2004), Әхсән Баян (2004); халык язучылары—Гомәр Бәширов (1986), Нәкый Исәнбәт (1986), Әмирхан Еники (1989), Фатих Хөсни (1993), Гариф Ахунов (1993), Аяз Гыйләҗев (1993), Мөхәммәт Мәһдиев (1993), Нурихан Фәттах (1998), Хисам Камалов (2001).

1986 елның җәендә (24-28 июнь) СССР Язучылар союзының чираттагы һәм соңгы съезды булып үтте. Бөтенсоюз съездының I нчесе турында шактый тәфсилле язган идек, мантыйк буенча, соңгысы турында да берничә сүз әйтеп узыйк. Татарстаннан делегат булып бу съездда түбәндәге язучылар катнашты: Ә. Еники, Н. Фәттах, Т. Миннуллин, М. Госманов, И. Юзеев, Р. Харис, Н. Орешина, Т. Галиуллин, Р. Гатауллин. Делегат булып сайланылсалар да, С. Хәким—каты авыру, Р. Фәйзуллин—ерак командировкада булу сәбәпле бу съездга бара алмадылар.



*СССР язучыларының VIII съездында катнашучылар. Сулдан уңга – Ренат Харис, Дания Зарипова, Сергей Кошечкин, Раиса Горбачева, Әмирхан Еники, Тәлгат Галиуллин, Илдар Юзеев, Миркасыйм Госманов. 1986 ел.*

I Бөтенсоюз съезды белән VIII нчесе арасында 50 дән артык ел. Бу еллар эчендә әдәби вәзгыять, әлбәттә, нык үзгәргән. 50 ел эчендәге идеологик сәясәтнең нәтиҗәләре ярылып ята. Милли әдәбиятлар турында сөйләгәндә сүз, нигездә, союздаш республикалар әдәбияты турында. I съездда, М. Горький докладында булсын, чыгышларда булсын, татар әдәбияты СССР халыкларының әйдәп баручы әдәбияты итеп тәкърарланды. Ә бу съездда? Дөрес, СССР Язучылар союзының беренче секретаре Г. Марков ясаган төп докладта бер исем (тыйнаксызлык саналмасын, ул—Р. Фәйзуллин исеме иде. Әмма моннан, миннән гайре, бүтәннәргә ни юаныч!) башка халыкларның кайбер язучылары белән бергә саналып китә китүен. Ә тагын? Татар әдәбияты кадәр татар әдәбияты бит ул! Съездның пленар утырышларында (жанрлар буенча секция утырышлары аерым да булды) җәмгысы 73 кеше чыгыш ясаган. Иң соңгы оратор булып сүз Т. Миннуллинга бирелә... Ахырга иң яхшы җырчыны чыгаралар, дияр кемдер. Бу очракта, рус сүзен кыстырып әйтсәк, случай другой. Туфанның чыгышы яхшы булган булуын: стенография язмасыннан шулай күренә. Хәер, съездда катнашкан язучыларыбыз кулуарларда югалып калмаганнар калуын: патша хатыны (Генсек М. Горбачев хатыны Раиса Максимовна) белән фотога төшкәннәр. Бу хакта безнең матбугатта матурлап язып та чыктылар...

VIII съездны СССР язучыларының соңгы съезды дип язсам да, кемдер, бу бит дөреслеккә туры килми, дияр. Һәм, чыннан да, ул—үзенчә хаклы булыр. Формаль яктан тагын бер съезд җыелды әле. Бу хәл 1992 елның июнь аенда булды. Әмма

аны инде, элеккеге мәгънәдәге СССР совет язучылары жыены дип әйтеп булмый. Партиянең беткән, СССРның тәмам таралган чагы. Советлар Союзы җирлегендә дистәләп мөстәкыйль, яңа дәүләтләр оешкан. Кая ди анда, коммунистлар партиясе җитәкчелегендәге, социалистик реализм нигезендәге күпмилләтле совет әдәбияты турында сөйләүләр!.. Өстәвенә, бу съездда, Латвия, Литва, Эстония, Молдова, Грузия, Әрмәнстан, Әзәрбайҗан язучылары бөтенләй катнашмады. Украина һәм Беларусь вәкилләре күзәтүче сыйфатында утырдылар. Шулай булгач, нинди СССР Язучылары Съезды була инде ул! Дөрес, Казахстан, Үзбәкстан, Татарстан, Төрекмәнстан, Таҗикстаннан килгән язучылар кызып-кызып шактый сөйләделәр бу съездда. Төрки халыклар һәм рус язучыларының (Евразия тәгълиматенә саллы мисал!) активлыгы белән үткән бу съездны үзбәк Т. Пулатов ачты һәм Язучылар союзларының халыкара берлеге (МСПС—Международное сообщество писательских союзов) рәисе итеп ул сайланды да. Биш-алты ел үткәч бу шәхес язучылар Олимпыннан төшерелде, каядыр юкка чыкты... Кыскасы, СССР язучыларының чын мәгънәсендәге съезды 1992 елда түгел, ә 1986 елны узган булып чыкты. 1934 елда старт алган Бөек башлангычның ахыры шулай тәмамланды.

(Язмамның беренче өлешендә үз-үземә дигәндәй сорау куйган идем: 1934 елдагы I Бөтенсоюз язучылар съездында катнашкан берәр исән кеше бар микән? Күптән түгел "Лит. Газета" аша ачыкланды—бар икән! Ул—Екатеринбургта яшәп ятучы 95 яшьлек шагыйрә Елена Хоринская. Съездда яшь шагыйрә сыйфатында Бурят-Монголия вәкиле булып катнашкан. Татарстаннан делегат булып катнашкан Хәсән Туфан 1981 елны вафат булды. Калганнары—яшьли диярлек һәлак булдылар, югалдылар...)



*Татарстанның халык язучылары, халык шагыйрьләре. Сулдан уңга—Гариф Ахунов, Шәукәт Галиев, Илдар Юзеев, Аяз Гыйләҗев.* Абрек Абзгильдин картинасы.

Фикер агышына ияреп, без берничә елга алга сикердек шикелле. Хроникаль эзгә төшеп үзебезнең хәлләргә янә кайтыйк.

**Татарстан язучыларының XI нче съезды 1989 елның 17 маенда В. И. Ленин Үзәк музееның Казан филиалында (хәзер Милли-мәдәни үзәк) ачылды, икенче көнне Язучылар союзының Г. Тукай исемендәге клубында дәвам итте** (шул ук көнне Н. Дәүлине дә соңгы юлга озату булды). Съездны кереш сүз белән Татарстанның халык язучысы Әмирхан Еники ачты. Республика язучыларының иҗаты турындагы отчет-хисап докладын идарә председателе Туфан Миңнуллин ясады. Аннары, жанрлар буенча өстәмә докладлар—проза (Фәрваз Миңнуллин), поэзия (Талгат Галиуллин), драматургия (Азат Әхмәдуллин), рус язучылары иҗаты (Михаил Скороходов), балалар әдәбияты (Роберт Миңнуллин), очерк һәм публицистика (Газиз Кашапов), "Казан утлары" журналы эшчәнлеге (Ренат Харис), тәрҗемә (Солтан Шәмси)—тыңланды.

Фикер алышуларда Р. Мөхәммәдиев, Н. Әхмәдиев, Разил Вәлиев, Р. Кутуй, С. Наметбаев (Кыргызстан), Р. Фәйзуллин, Ә. Рәшитов, Ә. Мәхмүдов, Ф. Мусин, И. Салахов, Ә. Гаффар, Р. Хәмид, Р. Мингалим, Ш. Янбаев (Башкортстан), Мансур Вәлиев, И. Нуруллин h. б. катнашты.

Съездда КПСС өлкә комитеты секретаре (хакимияттәге соңгы рәсми секретарь!) Р. Идиятуллин, РСФСР Язучылар союзы идарәсе председателе С. Михалков чыгыш ясадылар.

Съезд яшерен тавыш бирү юлы белән Татарстан Язучылар союзы идарәсе

председателе итеп Ринат Мөхәммәдиевне, "Казан утлары" журналының баш редакторы итеп Ренат Харисны сайлады. XI съездда сайланган 23 кешелек идарә составы: Ринат Мөхәммәдиев (председатель), Роберт Батулла, Әхсән Баянов, Мансур Вәлиев, Мөдәррис Вәлиев, Разил Вәлиев, Аяз Гыйләжев, Әмирхан Еники, Фәиз Зөлкарнәев, Ркаил Зәйдуллин, Газиз Кашапов, Владимир Корчагин, Рәфкат Кәрами, Мәдинә Маликова (председатель урынбасары), Зиннур Мансуров, Рөстәм Мингалимов, Роберт Миннуллин, Фәрваз Миннуллин, Ибраһим Нуруллин, Гәрәй Рәхим, Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Нур Әхмәдиев (сонрак, идарә карары белән бу составка Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев тә кертелде).

Кызык, гыйбрәтле җыен булды бу съезд. Үзгәртеп кору дигән чорнын үз пигына житкән еллары. Партия дигән ат-арбанын дирбияләре тугарылып бетеп барса да, кемнәрнендер әле дилбегәне нык итеп тотарга тырышып тырмашкан чаклары... Шул ук вакытта, җәмгыятькә демократик үзгәрешләр кергән еллар. Инде ничә ел рәттән халык ихластан шаккатып кәгазьсез сөйләүче түрәләрне күрә, халык депутатларының һәр чыгышын йотлыгып тынлый. Килешә, ярсый, бәхәсләшә... Безнең бу съездда да демократик шытымнар чагылды, әлбәттә.

Съезд кабул иткән резолюциядә, мәсәлән, Татарстанга союздаш республика статусы бирү, татар телен дәүләт теле итеп игълан итү, татар язучыларының Бөтенсоюз ассоциациясен оештыру кебек мөһим проблемалар күтәрелде. Шулай ук, бу съездда беренче мәртәбә рәис берничә кандидатура арасыннан яшерен тавыш бирү юлы белән сайланды.

## IV


Ниһаять, язмамның соңгы бүлегенә килеп җиттек. 90 еллардан башлап XXI гасырның беренче еллары, ягъни бүгенгегә кадәрге әдәби хәлләр. Өр-яңа тарих булып чыга инде. Чыннан да, хәзер генә кайнап-пешеп чыккан ризык шикелле: кабаланып йотсаң... Суыныр өчен вакыт кирәк. Шулайдыр, юкса, 2001 елда чыккан "Татар әдәбияты тарихы"ның соңгы VI томы 90 еллар белән тәмамланмас иде. Шулай да, соңгы 10-15 еллардагы әдәби хәрәкәт турында сөйли башларга, анализлап, сабак алып, кайбер нәтиҗәләр ясый башларга вакыт җитте кебек. Бу еллардагы җәмгыять тормышын бирәү дә тулы итеп объектив бәяли алмас әлегә. Ә еллары нинди диген! Революцион үзгәреш, хөррият еллары диикме, халык милкенең бәгъзеләр тарафыннан үзләштерелү еллары яки ачыклык һәм болганчыклык еллары диикме?.. Бу елларга эпитетларның кайсы да—унае да, тискәресе дә бик ипле ябыша ала... Бу еллардагы иң зур үзгәреш, хәтта сенсацион үзгәреш, әлбәттә—СССРның таркалуы булды. Күпләр өчен көтелмәгән тетрәнү. Төп йорт таркалгач була торган хәлләр башланды илдә.



*Халыкара язучылар оешмасы ПЕН-клуб әгъзаларыннан бер төркем. Сулдан уңга—Рафаэль Мостафин, Разил Вәлиев, Нурихан Фәттах, Илдар Юзеев, Равил Фәйзуллин, Әмирхан Еники, Әхәт Мушинский, Миркасыйм Госманов, Туфан Миңнуллин, Ркаил Зәйдуллин. 1996 ел.*

Аерымланулар, бүлгәләнүләр, мал бүлешүләр... Бу процесс иҗат оешмаларын да читләтеп үтмәде. Иҗат оешмаларының иң күчлесе саналган Язучылар союзларында бу процесс бигрәк тә ачык күренде. Үзәк Әдәби фонд карамагында булган мөлкәт тирәсендә

шау-шулар, суд-низаглар аеруча көчле булды. Чөнки байлык та бар иде шул! Атаклы иҗат йортлары гына күпме иде! —Пицундала, Ялтала, Дубултада, Переделкинода… Мал-мөлкәт тирәсендәге ыгы-зыгы (Мәскәүдә анын әле хәзер дә тынганы юк) бер хал, язучылар үзләре дә бүлгәләнеп бетеп, төрле төркемнәр булып оештылар. Башкалалан үрнәк алыпмы, үзләренең ихтыяжы булыпмы, мондый хәлләр регионнарга да күчте. Мисалга ерак барасы түгел, күрше чувашларда язучыларның берничә оешмасы хасил булды… Ә бездә? Бездә андый бүлгәләнүләр булмады дип әйтеп була. Дөрес, 80 еллар ахырында язучылар оешмасының кирәклеген шөбһә астына куйган фикерләр булгалады. "Язучылар колхозы"н тәнкыйтьләгән мәкаләләр күренгәләде. Әмма, сүз, нигездә, оешманы бетерү турында түгел, оешманы янача үзгәртеп кору, камилләштерү кирәклеге хакында барды. Язучылар оешмасының безнең өчен зарур булуы хакында XI съездда Т. Миңнуллинның хисап докладында да кистереп, дәлилләп әйтелде. Оешмабызның таркалмый-бүлгәләнми тотрыклы булып калуы, минемчә, бердәмлегебез, эчке көчебез билгесе. Дөрес, 1995 елда Татарстанда, халыкара язучылар оешмасының бер тармагы буларак, ПЕН-үзәк төзелде. Әмма ул—үзебезнең төп оешмадан аерымлануны түгел, киресенчә, язучылар коллективының иҗади-сәяси мөмкинлекләренең зурлыгын гына күрсәтте. Чөнки ПЕН-үзәктә шул ук абруйлы язучылар, байтагы Татарстан Язучылар оешмасының идарә әгъзалары…




СССР таркалу белән сәяси вәзгыять тә бик нык үзгәрде: милли үсеш максатлары шул ук калса да, ориентирлар алышынды. Әйтик, союздаш республика статусы алу максаты мәгънәсен югалтты. Үзбилгеләнүдә грузин, үзбәк, латышлар һәм башка халыкларның дәрәҗәсен аласы булса, аерым мөстәкыйль дәүләт булырга омтылырга кирәк булып чыкты… Әгәр теге яки бу басма ачуга дистә еллар буе ялынып дигәндәй йөреп Үзәктән рөхсәт алу кирәк булса, хәзер андый рөхсәт-карарларның хаҗәте бетте. Оештыр үз республикаңда, үз өлкәңдә; канунлаштыр, чыгар—берниндн каршылык юк. Һәм… кем әйтмешли "процесс башланды!", буа ерылды… 1989 июленнән яшьләр журналы "Идел" (ярты гасырлап хыялда йөргән басма!), 1990 елның мартыннан "Салават күпере", 1991 елның сентябреннән "Мирас", шул ук елның октябреннән "Аргамак" чыга башлады… Мөгаен, мәдәният-мәгариф өлкәсендә иң зур казанышларыбызның берсе—1991 елда "Мәгариф" нәшриятының оештырылуыдыр (дөрес, мондый исемдәге нәшрият XX гасыр башында ачылып, 1922 елда ябылган булган). Бөтентатар дөньясын дәреслекләр, төрле методик әсбаплар белән тәэмин итеп торучы бу зур "рухи завод"ның башында безнең язучыбыз Мөдәррис Вәлиев торды. Цензура бетерелде. Гомумкешелек гуманизмына каршы килмәгән теләсә нинди әсәрнең дөньяга чыгуына юл ачылды. Кайчандыр басылган булып та, совет заманында тыелган әсәрләр янәдән халыкка кайтты. Менә Г. Исхакый иҗаты ачык мисал. (Хәзер Г. Исхакый иҗатына елышкан галим-голәмә житәрлек; классикны дөньяга янә танытучы—«мин!», диеп йөрүче мөтәпионерлар да табыла. Асылда, бу эшнең башында Ибраһим Нуруллин, Лена Гайнановалар торды. Г. Исхакыйның күләмле әсәрләрен беренче булып янадан чыгаручы журнал "Казан утлары" булды. "Ике йөз елдан соң инкыйраз", "Сөннәтче бабай" әсәрләре И. Нуруллинның кереш сүзе белән журналыбызда 1990 елның 1 санында басылып чыкты.) Әйе, хакимият органнары тарафыннан чикләү, тыюлар бетерелде. Моны мин журналда эшләү тәҗрибәсенә таянып, белеп-инанып әйтәм. Эш дәверендә, идеологик караштан чыгып, әдәби-эстетик кыйммәткә ия бер генә әсәр дә читкә тибәрелмәде. Киресенчә, безнең заман язучыларының элекке елларда басылмыйча калган шәп әсәрләре юк дәрәҗәсендә булып чыкты. Чыгарма булып, бәлки, С. Батталның "Я—Иванов Иван Иванович" дигән күләмле памфлеты гына санала аладыр… Күрәсең, безнең язучылар конъюктура законнарын яхшы үзләштергән прагматиклар, һәм алар "баш китәрлек" әсәрләр язып киләчәк буыннарны "бимазаламаска" булганнардыр…

•

"Атай үлде, хөррият килде!" дип әйткән ди, имеш, бер малай. СССР таркалып, демократия дигән хөррият килеп алды алуын (Казансу ярында хәтта "Хөррият"

исемле биек сын-стелла да калкып чыкты!), әмма аның "ләкин"нәре дә безнең өчен күп икән шул! Чәчелгән, сибелгәнлекнең тагын бер "татлы" җимешен татыдык: байтак милләттәшләребез тарихи Ватаныннан тәмам өзелеп, чит дәүләт-мәмләкәтләрдә калды... Үз туфрагында берегеп күмәкләшеп яшәгән халыклар үз дәүләтләрен корды, ә без—татарлар тагын да азаеп Россия карынында калдык... Казахстан һәм Урта Азиядә күпләп яшәүче милләттәшләребез белән рухи аралашу бөтенләй диярлек бетте. Кая ди ул театрларыбызның ел саен Урта Азиягә чыга торган гастрольләре? Газета-журналларыбыз, китапларыбызның юлы кырт киселде. Элек "Казан утлары", "Азат хатын" ("Сөембикә") журналларының өчтән-дүрттән бере (ул 15-20 мең дигән сүз!) шул якларда таралса, хәзер алар өч-дүрт дистә данәгә калды... СССР таркалгач татар матбугатының (бу хәл башка халыкларга, шул исәптән русның үзенә дә кагыла) тиражлары катастрофик дәрәҗәдә кимеде. Дөрес, Россиянең татарлар яши торган төбәкләрендә татарча газеталар ачылды ачылуын. Әмма алар безнең район газеталары сымак, әдәбият-сәнгать үсешенә әллә ни тәэсир итәрлек дәрәҗәдә була алмадылар. Казанда чыга торган төп басмаларның таралуына да әллә ни булышлы тәэсир итмәделәр шикелле. Бәлки әле киресенчәдәдер: чөнки татарча укучылар катламы бик "юка", гомумтатар укучысының матди яклары кысынкы икәнлекләрен дә исәпкә алсак, әбунәчеләр, гадәттә, берәр басмадан артыкка языла да алмыйлар. Кайберләре, бәлкем, әнә шул җирле газетаны алдырадыр?.. Кыскасы, татар телендәге басмаларның тиражы кимүе безгә—язучыларга бик "кырын сукты", укучыларыбызның кискен кимүенә китерде. Ә язучының укучысы булмаса...

Газета-журналларның таралышы һәм иҗтимагый әһәмиятләре турында абстракт сөйләү бер хәл, аларны чыгарып өчен иң мөһиме—матди җирлек, финанс чыганагы кирәк бит әле! 90 еллар башында газета-журналларыбызны нәшер итү мәсьәләсе бик катлаулы һәм киеренке булды. Элек керем китергән басмалар, тиражлар нык



*"Казан утлары" журналы коллективы. 2002 ел.*

кимегәч, үз чыгымнарын каплый алмый башладылар. Яңа чыганаклар эзләү ихтыяҗы туды. СССР таркалып, Россия, үзенә үзбаш булып калгач, экономик, шуңа бәйле финанс яктан, бизгәк тоткан кешедәй, калтыраулы хәлдә иде. Элек сүзлекләрдән генә ишетеп белгән инфляция, дефолт кебек терминнар актив сүзләр булып китте... Хезмәт коллективларында киеренке хәлләр туды. Хезмәткәрләргә вакытында түләп булмый, авторлар символик гонорарларын да яртышар ел көтәргә мәҗбүр. Мәскәүдә әдәби журналларның бөтенесе диярлек Язучылар союзы органы булудан туктадылар. Чөнки, иҗтимагый оешма статусындагы (үзләре дотациягә, ярдәмгә мохтаҗ) Язучылар союзлары теге яки бу басма өчен беренди финанс ярдәме күрсәтә алмый.

Безнең "Казан утлары" журналы башына да килеп басты бу проблема. Дистә еллар буе, дәүләткә керем китереп, традицион рәвештә Татарстан Язучылар союзы органы саналып, жай белән генә чыгып килгән журналга базар мөнәсәбәтләре чорында нишләргә иде соң? Әбүнәчеләрдән жыелган акчага нибары берничә сан гына чыгарып була... Жир кемнеке булса, жыр шуныкы, дигәндәй, кем түли—шул гамәлгә куючы була. 1991 елны Татарстан матбугат министрлыгы тарафыннан журналның оештыручылары булып Газета-журналлар нәшрияты, Татарстан Язучылар берлеге, редакциянең хезмәт коллективы расланды. Ә ярты елдан соң журналның төп оештыручысы булып Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты булуына ирешелде. Шулай итеп, 1992 елның башыннан бүгенгә кадәр "Казан утлары"н оештыручылар—гамәлгә куючылар булып, Татарстан хөкүмәте, Язучылар берлеге, редакциянең хезмәт коллективы санала. Күрәсез, оештыручылар үзгәреп торса да, Язучылар берлеге алар арасында гел сакланып килендe. Моны журналның традицияләргә тугрылык билгесе, Язучылар берлегенең бердәмлеген саклауда өлеше дип санарга кирәк. Бу очракта шуны да әйтеп узу урынлы булыр: гамәлгә куючыларның берсе саналу бер нәрсә, ә чын гамәли эш икенче нәрсә. Язучылар берлеге "Казан утлары" эшчәнлегенә сизелерлек ярдәм дә итә алыр иде. Әйтик, журнал таратуны активрак оештыруда гына булса да... (Милли матбугатны, бу очракта төп әдәби журналны укучыларга житкерү, зур проблема хәзер. Халык дәррәү китап-журнал укыган заманда да Язучылар союзы житәкчелеге бу мәсьәләне гел күз уңында тота иде. Язучылар коллективына, бигрәк тә идарә әгъзаларына махсус бурычлар йөкләнә, соныннан аларның хисап-отчетлары тыңлана, тикшерелә иде. Хәзер бу гамәлләр онытылып бара... Ә бит, төптән уйласаң, хезмәте булган язучыларга һәм мораль, һәм матди, бүтәнчә әйтсәк, социаль яклау ягыннан хәйран гына булышып килә журнал. Гомумән, "Казан утлары"сыз татар әдәбиятын күз алдына китерү кыен.)

Бер ел элек Республикада "Татмедиа" дип аталган массакүләм коммуникацияләр агентлыгы оешты. Без әлегә шул агентлык канаты астында. Туктаусыз реформалар заманында алга таба журналны гамәлгә куючылар кемнәр булыр, нинди үзгәрешләр кичерелер, кистереп әйтү кыен.

Шулай да, оптимист буласы килә: соңгы 15 ел эчендә Татарстан хөкүмәте ярдәме белән журналыбызның өч юбилеен—70-75-80 еллыкларын зур итеп үткәрә алдык, житәкчелекнең әдәби жәмәгатьчелек белән берлеген тойдык. Вакыйгага әверелгән бу күңелле фактлар безгә алга таба да яшәячәгебезгә ышаныч тудыра.

•

Нинди генә икътисади кыенлыклар булмасын, 90 еллар Татарстан, гомумән татар тарихында кабатланмас бөек еллар! Халыкның үзаны уянган еллар, Татарстан дөньяга ныклап таныла башлаган еллар! Суверенитет турында Декларация кабул итү, Татарстанның Президентын сайлау, Референдум уздыру, чит илләрдә һәм Россия төбәкләрендә Татарстанның вәкиллекләрен булдыру... Жиңүгә тиң бу казанышларда безнең каләмдәшләребезнең дә саллы өлеше бар дип саныйм мин. Матбугатта чыгыш ясапмы, жыелыш-митингларда катнашыпмы, ачлык акцияләре оештырыпмы, депутат мөнбәреннән сөйләпме, бик күпләр ихластан Татарстанның киләчәге, аның бәйсезлеге өчен жан атып йөрделәр. Депу-



*Татарстан Югары Советының XII чакырылыш депутатлары. 30 август, 1991 ел.*

татларыбыз да күп эшләде ул елларда. Мандатлы вәкаләте булгач, табигый, эшләргә тиеш иделәр дә. Элегрәк, язучылардан бер кеше, гадәттә, идарә рәисе югары органнарга (СССР, РСФСР, ТАССР Югары Советларына) сайлана иде. 90 нчы елда депутат булып алты кеше үтә алды (Р. Мөхәммәдиев—РСФСР Югары Советына, Ф. Бәйрәмова, Р. Вәлиев, Р. Миннуллин, Р. Фәйзуллин, Р. Харис—Татарстан Югары Советына). Шул еллардан башлап бүгенгә кадәр язучылардан дүрт-биш кеше депутат булып Татарстан парламентына сайланып килә. Әгәр парламентта язучыларның көчле төркеме булмаса, милли мәнфәгатьләрне кайгырткан кайбер законнар, карарлар, белдерүләр, мөгаен, дөньяга чыга да алмас иде.

1989 елдан (язмадагы бүленеш буенча 90 еллар башы дип алыйк) бүгенгә кадәрге унбиш ел эчендә идарә рәисе вазифаларын Р. Мөхәммәдиев (1989-1999) һәм Ф. Галимуллин (1999 елдан) башкарды (соңгысы—башкарып килә). Идарәнең, гомумән, Язучылар оешмасының эшчәнлеге күпмедер дәрәҗәдә рәиснең шәхесенә, аның әдәбияттагы абруена, оештыру сәләтенә, фидакарлегенә бәйле. Р. Мөхәммәдиев Союз рәисе булуы дәверендә, РСФСР Югары Советына сайланды һәм анда даими эшли торган комитет җитәкчесе булды. Мәскәүдә йортлы-җирле булып дигәндәй, төп вакытын башкалада үткәрде. 1990-93 елларда кайтып-килеп җитәкчелек итте. Оешмадагы төп оештыру эшләрен аның урынбасарлары З. Мансуров, М. Шиһапов алып барды (бер ара урынбасар вазифаларын Г. Гыйльманов, М. Маликова, Ә. Гадел, Р. Әймәт, Д. Салихов башкарды).

Иҗади һәм оештыру эшләре ничек кенә бәяләнмәсен, оешманың 90 еллар башындагы эшчәнлегенең бер характерлы моментын искәртеп үтәргә кирәк: ул—Татарстан Язучылар оешмасының мөстәкыйльлеген тәэмин итеп, аны Халыкара Язучылар бердәмлегенә кертү. Шул максатны күздә тотып, 1991 елның 15 мартында язучыларның съезд дип аталган бер җыены булды. Ул, асылда, ел йомгакларына багышланган җыелыш иде. СССР (?) Язучылар союзының, алда әйтелгән IX—соңгы съездына вәкилләр сайлау өчен, Устав кушканча, бу җыелышның съезд дип аталуы кирәк иде. Шуна да, бу җыелыш-съезд, чираттан тыш саналып, фәләненче санлы съезд булып исәпләнмәде дә. Шулай да, бу җыелышта әле хәзер дә гамәлдә булган Татарстан Язучылар берлегенең Уставы кабул ителде. Шул ук елның октябрендә "РСФСР Язучылар берлеге белән Татарстан Язучылар берлеге арасында хезмәттәшлек килешүе" төзелде. Килешүнең беренче җөмләсендә "РСФСР Язучылар берлеге белән Татарстан Республикасы Язучылар берлеге, тигез хокуклылык шартларында һәръяклап хезмәттәшлек итәргә килешенделәр" диелә. Тарих өчен кызык, гыйбрәтле документ. (Соңгы вакытта бәгъзе иптәшләрнең Татарстан оешмасын янә Россия Язучылар оешмасына буйсынулы итәргә омтылышлары булды. Безнеңчә, ашыгырга ярамый. Россия язучылары әлегә үзләре берничә үзәккә бүленеп беткән. Икенчедән, иске үзәккә кайтуның безнең өчен әлегә берминди файдасы күренми. Чөнки Мәскәүдәге нәшриятлар һәм басма органнар Язучылар союзына карамый, элеккечә



*Кабул итү Коллегиясе утырышы. Сулдан уңга—Мөсәгыйт Хәбибуллин, Рөстәм Кутуй, Шаһинур Мостафин, Зиннур Мансуров, Равил Фәйзуллин, Гөлшат Зәйнашева, Газинур Морат, Марсель Галиев. 2003 ел.*

үзәктә китаплар чыгару шансы юк дәрәҗәсендә. Киресенчә, кайбер Мәскәү журналлары үзләре ярдәм сорап Татарстанга мөрәҗәгать итәләр... Иҗат эше—сәнагать тармагы түгел (анда чыннан да интеграциясез булмый!), безнең эш ирекләккә,

демократик тигезлеккә корылган. Гомумән, чын дуслык, хезмәттәшлек тигезләр арасында гына була ала. Бу—аксиома).

Язучылар берлеге тарихына кагылышлы бу хезмәттә союзның төрле еллардагы составы, сан-исәбе турында берничә сүз әйтмәсәм, язмам тулы булмастыр. Сүз Язучылар союзы әгъзасы саналган каләмдәшләр турында бара. Күптән түгел бер каләмдәшебезнең газетада чыккан мәкаләсендә мондый юлларына тап булдым: "Хәзерге көндә Язучылар берлегенә каләм тибрәтүчене алу кемне дә булса комсомолга алуны хәтерләтә. Таләпләр түбән дәрәҗәдә, шул сәбәпле Союз әгъзасы булып ни язганнары беркемгә дә мәгълүм булмаган каләм тибрәтүчеләр йөри, аларның күбесе хәзерге иҗтимагый тормыштан гына түгел, хәтта әдәбияттан да (әдәбият үзе иҗтимагый тормышның бер өлеше инде ул—**Р. Ф.**) бик ерак тора". Бу юллар гаҗәпләнү яки берәр этәргеч реакция тудырды димим, шулай да көлемсерәү тойгысы уятты. Соңгы биш елда Татарстан Язучылар каршындагы Кабул итү Коллегиясе рәисе буларак, әлбәттә, мондый карашка үз фикерем, үз җавабым бар. Бу хакта бераз соңрак.

Алда әйтелгәнчә, әдәбиятны бернинди оешмалар тудырмый, әдәбиятның сыйфатын оешмадагы әгъзаларның саны билгеләми. Әдәбиятны талантлы аерым шәхесләр тудыра. XIX гасырда русларда махсус дәүләти әдәби оешмалар булмаса да, бөек әдәбият бар. XX гасыр башында Тукай, Исхакый, Ибраһимовлар мисалында бөек татар әдәбияты бар. Шагыйрь әйтмешли, әдәбиятның зурлыгын билгеләр өчен "бер Толстой җитә, бер Тукай!" Үткән гасыр башында, ягъни йөз ел элек, татар мохитендә язучы-мөхәррирләр, бердәм иҗади оешмада әгъза булып тормасалар да, бүгенгедән ким булмаган дип уйлыйм.

1934 елда, Татарстан Язучылар Союзы оешканда утызлап язучы оешма әгъзасы саналган. Сугыштан соңгы елларда СССР Язучылар союзы таныклыгын йөрткән кешеләр иллеләп исәпләнгән. Алда әйтелгәнчә, 1968 елда бу сан 111 гә җитә. 1990 елларда Союзга алу артыгы белән активлаша. Ун ел эчендә (1989-1999) 126(!) кеше әгъза итеп кабул ителә (XI-XII съезд арасында 72 кеше, XII-XIII съезд арасында 54 кеше). "Кояш" сүзен язганда биш хата җибәрүче кешеләр Союзга керә" дигән төртмәле сүзләр шул елларда чыкты шикелле. Шулай итеп, XXI гасыр башына гомумсан 280гә җитә. Хәзерге көндә Татарстан Язучылар берлегендә 302 әгъза. Уртача яшьләре—59,7 яшь. Искә төшереп чагыштырыйк: СССР Язучыларының беренче съездында катнашкан делегатларның уртача яше 38,5 булган. Без—пенсионерлар оешмасы булып чыгабыз түгелме соң?

"Кадрлар һәммәсен дә хәл итә" дигән бер искерми торган гыйбарә бар. Бу гыйбарә безнең эшкә дә кагыла. Язучылар берлегенә алганда төп роль Кабул итү Коллегиясенә (Комиссиясенә) йөкләнгән. Коллегия карарын идарә, гадәттә, хуплап раслый. Кире кагылган фактлар, гайре табигый хәл саналып, бик сирәк була. 90 елларга кадәр соңгы мөһерне Мәскәү—СССР Язучылар союзы секретариаты суга иде. Соңгы 10-15 ел эчендә бу мәсьәлә үзебездә—Татарстан Язучылар берлегендә хәл ителә. Кабул ителгән каләм иясенә "Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы" дигән таныклык тапшырыла. Бар иде заманнар: теге яки бу халыкның республиканың әдәби потенциалын, дөресрәге, оешма потенциалын саннар да билгели иде. Әле хәтердә: 60-70 елларда өлкән язучы агайлар: кара, үзбәкләр язучылар саның 300 гә житкергәннәр, украиннар—400 гә... безгә дә арту кирәк, диләр иде. Чыннан да, сан арттыруда мәгънә дә бар иде: язучылар исәбенә карап җирле союзларга Үзәктән акча җибәрелә, торак төзелешләренә өстәмә чыганаклар бүлеп



*Язучыларның әдәби ел йомгакларына багышланган җыелыштан күренеш. 1994 ел.*

бирелә, санаторийлар, иҗат йортларына юлламалар күбрәк килә... Хәзер вәзгыять бөтенләй бүтән: җирле бюджет хозурына һәм үз тырышлыгына карап үз көненне үзен күрәсен.

Ә инде "беркемгә дә мәгълүм булмаган (укып барырга да кирәк! Язучыларның күбесе бер-берсенен иҗатын игътибар белән күзәтеп бара дип әйтә алмыйм) каләм тибрәтүчеләр"не союзга—берлеккә алу мәсьәләсенә килсәк, җавап мондый: Кабул итү Коллегиясе әзме-күпме әдәби сәләте булганнар арасыннан, булган хәзинәдән иң яхшыларын сайлап алырга тырыша һәм шулай эшли дә. "Балкып торган 20-25 яшьлек фәлән иптәшне нигә һаман берлеккә алмыйсыз?" дип беркем дә әйтә алмас. Бүгенге Коллегиядә түбәндәге иптәшләр эшли: Равил Фәйзуллин (рәис), Әхсән Баян, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Владимир Корчагин, Нурмөхәммәт Хисамов, Марсель Галиев, Гөлшат Зәйнашева, Газинур Морат, Ркаил Зәйдулла, Шаһинур Мостафин. Орлыктан кибәкне генә аера белә торган иптәшләр дип беләм мин бу язучыларны. Элек тә кабул итү комиссиясендә зур абруйлы язучылар эшләде—Г. Бәширов, С. Хәким, А. Гыйләҗев, Ш. Галиев... Шуны аңларга кирәк: вәзгыять элекке белән чагыштырганда нык үзгәрде, язучының җәмгыятьтәге роле тоныкланды... Чит төбәкләрдән түгел, үз республикабызда да яшьләр әдәбиятка ургылып килми... Сер түгел, бүтән өлкәләрдә яшәүче авторларга игътибарны күбрәк бирергә тырышабыз, аларга кайчак ташламалар да ясарга туры килә... Шунысы да бар: артык чикләүләр куеп, иҗади оешманы алып булмаслык крепость-кирмән дә ясарга кирәкмидер. Фикеремне ачык әйтеп бетерим: әйе, бездә 300 язучы юк, бездә оешмада саналган 300 ләп әгъза бар. Таныклык йөртү—син әле коеп куйган язучы дигән сүз түгел. Әнә, Зөлфәт Хәкимгә, (анда йөзгә якын пьеса язучы катнашты) язучылар таныклыгы йөртмәү драматурглар ярышында җиңүче булырга комачауламады бит әле! Язучылар оешмасы—демократик характердагы ирекле иҗтимагый оешма. Бу оешмага керергә теләүчеләр бихисап булса да, аннан гариза биреп чыгарга теләк белдергән кешеләр дә бар. Хәтта идарә составыннан да...

*

**Татарстан язучыларының чираттагы XII нче съезды 1994 елның 3 июнендә Казанның Актерлар йортында узды.** Аны, кыскача кереш сүз белән Татарстанның халык язучысы Гомәр Бәширов ачты.

Идарә рәисе Ринат Мөхәммәдиев Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең 1989-94 еллардагы эшчәнлеге турында доклад ясады.



*Татарстан язучыларының XII съезды Президиумы. Трибунада—Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев. 1994 ел.*

Язучылар корылтаенда Татарстан Президенты М. Ш. Шәймиев чыгыш ясады. Иң элек ул Татарстандагы бүгенге сәяси һәм икътисадый хәлләр турында сөйләде. Аннары Президент Татарстан белән Россия арасында төзелгән Шартнамәгә һәм Б. Н. Ельцинның Татарстанга визиты йомгакларына кагылышлы фикерләре белән уртаклашты, татар телен дәүләт теле буларак тормышка ашыру, татар мәктәпләре һәм балалар учреждениеләре санын арттыру, газета-журналлар нәшер итү, китап бастыру, язучыларның матди хәлләрен җиңеләйтү турында сөйләде. Аларга иҗат мөмкинлекләре тудыру мәсьәләләренә дә кин тукталды.

Аннары ревизия комиссиясе отчеты (Р. Даутов), төрле жанрлар буенча докладлар—поэзия (Г. Морат), драматургия (Р. Мингалим), балалар әдәбияты (Р. Миннуллин), әдәби тәнкыйть (Ф. Зөлкарнәй), тәржемә (К. Миңлебаев), рус әдәбияты (В. Корчагин) тыңланды. Проза (Ә. Гаффар) һәм публицистика (М. Зарипов) буенча докладлар тыңлаучылар таләбе буенча тулысынча яңгырамады. Фикер алышуларда Р. Фәйзуллин, С. Михалков (Мәскәү), Ә. Баян, Ә. Еники, Ф. Баттал, Г. Ахунов, С. Баттал, Т. Галиуллин, Р. Хисмәтуллин, М. Нәзиров (Уфа), Р. Вәлиуллин, З. Зәйнуллин, М. Маликова, Т. Пулатов (Мәскәү), Х. Әшрафҗанов катнашты.



*Татарстан язучыларының XII съездында сайланган Идарә составы. 1994 ел.*

Корылтайда Татарстан Язучылар берлегенең төзелешен үзгәртеп кору хакындагы декларация кабул ителгәч, ачык тавыш бирү юлы белән яңа идарә әгъзалары сайлау булды. Алар: Ринат Мөхәммәдиев (идарә рәисе), Гариф Ахунов, Рабит Батулла, Мөдәррис Вәлиев, Әхсән Баян, Фәүзия Бәйрәмова, Разим Вәлиуллин, Әхмәт Гадел, Шәүкәт Галиев, Фоат Галимуллин, Тәлгат Галиуллин, Аяз Гыйләҗев, Вахит Имамов, Владимир Корчагин, Рәфкат Кәрами, Мәдинә Маликова, Зиннур Мансуров (рәис урынбасары), Рөстәм Мингалим, Роберт Миннуллин, Рашат Низамиев, Данил Салихов, Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Зиннур Хөснияр, Мансур Шиһапов (рәис урынбасары), Илдар Юзеев, Азат Әхмәдуллин, Харрас Әюпов.

90 еллар башына туры килгән XI һәм XII съездлар арасы, ягъни 1989-94 еллар Татарстан, гомумән татар халкы тарихында онытылмас еллар! Авыр, киеренке, әмма халык рухының күтәренке еллары. Суверенлык, мөстәкыйльлек турында хыялланып һәм ышанып авыз тутырып сөйләнгән еллар. Урамнарда халык ташкыны. Митинглар, Югары Советта кайнар бәхәсләр. Ниһаять, Татарстан Суверенлыгы турында Декларация! Президент сайлаулары, Референдум үткәрүләр... Бөтендөнья татарларының I конгрессы. Болгар җиренең ислам динен кабул итүгә 1100 еллыкка багышланган тантаналар. Татар энциклопедиясе әзерләнә башлау... Татарстан белән Россия арасында төзелгән тарихи Шартнамә...

Бу елларның рухи елъязмасында, кабатлап әйтәм, язучыларның өлеше зур. Татар халкы өчен хәлиткеч көннәрдә язучыларыбыз көрәш мәйданының уртасында булдылар. Кирәк чакта меңләгән халык алдында яндырып сөйләделәр, мәйданнарга чыгып ачлыкта утырдылар, шигарь булырлык кайнар шигырьләр яздылар, күпләргә фидакярьлек үрнәге күрсәттеләр.

XX гасыр ахырында чираттагы янә бер съезд булып узды. Аныңы, санау тәртибе буенча XIII нчесе. Әнә шул уникенче белән унөченче арасындагы (1994-1999 еллар) кайбер мәдәни-әдәби вакыйгаларны, фактларны искә төшерик. Камал театрында Татарстан Язучылар оешмасы төзелүгә 60 ел тулуга багышланган тантаналы кичә узды (ноябрь, 1994), Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре үткәрелде. Анда язучыларның зур төркеме катнашты (июнь, 1995), атналык "Мәдәни җомга" газетасы

чыга башлады. Баш мөхәррире—З. Мансуров (июль, 1995), Г. Ахуновның 70, Т. Миннуллинның 60 (1995), Г. Тукайның 110 (1996), Мөхәммәдъярның 500, Г. Кандалыйның 200 (1997), Г. Исхакыйның 120 (1998), Ә. Еникинең 90 (1999) еллык юбилейлары киң билгеләнеп үтелде. Шулай ук, Татарларның II Бөтендөнья Конгрессы көннәрендә "Казан утлары" журналының 75 еллыгы бәйрәм төсендә үтте... Тарих булып калган хрониканы дәвам итәргә дә була...

*

**Татарстан Язучыларының чираттагы XIII нче съезды Казанның Актерлар йортында 1999 елның 28 маенда башланды.** Корылтайны татар әдәбияты аксакалы—90 яшьлек әдип Әмирхан Еники ачты. Ике корылтай арасында идарә тарафыннан башкарылган эшләр турында хисап докладын татарстан Язучылар берлеге рәисе Ринат Мөхәммәдиев ясады.

Корылтай эшендә катнашкан Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев, җыенны котлап, җәмгыятебезне үзгәртеп коруга, әдәбиятыбызны баетуга кертгән өлешләре өчен, язучыларга рәхмәт белдерде һәм әдипләр алдында торган бурычлар турында сөйләде.

Корылтайда катнашучылар әдәбиятыбызның бүгенге прозасы, очерк һәм публицистикасы, шигърияте, драматургиясе, балалар әдәбияты һәм рус әдәбияты турында Фоат Галимуллин, Фәүзия Бәйрәмова, Фәрит Яхин, Юныс Сафиуллин, Галимҗан Гыйльманов, Владимир Корчагин докладларын тыңладылар. Фикер алышуларда Ә. Баян, Ш. Галиев, Т. Миннуллин, Г. Ахунов, И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, А. Хәлим, Р. Батулла, Л. Ихсанова, Л. Шагыйрьҗан, З. Зәйнуллин, К. Булатова, Р. Җамал (Корбанов), М. Маликова, А. Хәсәнов, Ә. Гадел, Д. Салихов һ. б. чыгыш ясады.


"Казан утлары" журналы редколлегиясе утырышыннан күренеш. 1988 ел.

Гадәттәге сценарий белән барырга һәм тәмамланырга тиеш булган бу съезд финиш алдыннан көтелмәгән "борылмалар һәм сикәлтәләр" үтәргә дучар булды. Җыен барышында идарә һәм аның җитәкчесе адресына тәнкыйть фикерләре байтак әйтелсә дә, "мунчаның чын пары" яна җитәкчелек сайлаганда чыкты. Залдагы тамаша—сүз һәм хәрәкәт накалы трагикомик спектакльләрдәге кайбер күренешләрне хәтерләтте. Съездга нинди нокта (яки—!) куеласы анык булмаганга күрә, Президиум—съездны вакытлыча өзеп, Язучылар берлеге идарәсен сонрак сайларга дигән нәтиҗәгә килде; һәм бу сайлаулар ике айдан соң, 27 июльдә узды. Идарә рәисе итеп, бик үк фараз ителмәгән, җәмәгатьчелек арасында язучылыктан бигрәк, беренче чиратта радио дикторы һәм пединститут укытучысы буларак билгеле филология фәннәре докторы Фоат Галимуллин сайланып куелды. Яңа Идарә составына түбәндәге язучылар керде: Харрас Әюпов, Мөдәррис Вәлиев, Мансур Вәлиев, Разил Вәлиев, Разим Вәлиуллин, Әхмәт Гадел, Марсель Галиев, Фоат Галимуллин (рәис), Галимҗан Гыйльманов (рәис урынбасары), Җәүдәт Дәрзаманов, Вахит Имамов, Рәфкат Кәрами, Владимир Корчагин, Ләбиб Лерон, Зиннур Мансуров, Газинур Моратов, Шаһинур Мостафин (рәис урынбасары), Рашат Низамиев, Гәрәй Рәхим, Равил Рахмани, Данил Салихов, Нәҗибә Сафина, Равил Фәйзуллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Айдар Хәлим, Солтан Шәмси, Фәрит Яхин.

Контроль-ревизия комиссиясе рәисе итеп язучы Лирон Хәмидуллин, Кабул итү

комиссиясе Коллегиясе рәисе итеп Р. Фәйзуллин сайланды.

Иҗат остаханәләре җитәкчеләре итеп Солтан Шәмси (проза), Зиннур Мансуров (шигърият), Равил Рахмани, соныннан Җәүдәт Дәрзаманов (балалар әдәбияты), Мансур Вәлиев (әдәби тәнкыйть), Кыям Миңлебаев (әдәби тәрҗемә), Владимир Корчагин (рус әдәбияты), яшь каләм ияләре белән эшләү бүлеге җитәкчесе итеп Фирдәвес Әһлия билгеләнде.

Идарәдә Әлмәт язучылар оешмасына Разим Вәлиуллин, Чаллы Язучылар оешмасына Вахит Имамов җитәкче итеп сайланды.

"Тамгалы" бу XIII съезд узганга да биш елдан артык вакыт узды. Анда катнашкан кешеләр өчен гыйбрәт һәм сабак алырлык съезд булды ул. Кайбер чыгышларда әдипләргә хас булып бетмәгән дорфалык, субъективизм чалымнары булгаласа да, каләмдәшләр күңелендәгеләрен яшермичә, ачыктан-ачык ихлас сөйләделәр, татар әдәбиятының киләчәге өчен борчылып чыгыш ясадылар. Демократиянең, сүз ирегенең безнең җәмгыятьтә дә беркадәр урнаша башлавына дәлил иде инде бу. Дөрес, бериш чыгышларда, "яхшы патша" кирәк, дигән шикелле, шәп рәис сайласак, эшләребез гөрләп алга китәр, китапларыбыз тоткарлыксыз чыгып килер, каләмхаклар артыр, матди яклар яхшырыр дигән наив ышаныч мотивлары байтак яңгырады. Табигый хәл. Киләчәккә ышаныч булмаса, ничек язмак кирәк? Әмма... вәзгыять бүтән: дәүләт күзенә карап торган, иҗтимагый оешма саналган иҗат берлекләренең мөмкинлекләре хәзер бик чикле шул... Бу съездда, өстә ярылып ятмаса да, тагын бер хәлне күзәтергә мөмкинлек булды, ул—язучылык хезмәте һәм агымдагы сәяси эшчәнлек. Язучы иҗтимагый тормышта актив катнашырга тиеш (мәҗбүр) булса да, сәясәткә ул башы-аягы белән кереп йотылырга тиеш түгелдер. Язучының хезмәт җимеше—күңел аша үткәрелгән акыл һәм хис квинтэссенциясе. Ә сәясәттә канунннар каттый, анда күңел кичерешләренә, чын хисләргә урын тар... Үен тәртипләре бүтән. Элеккеге берлек рәисенең эшчәнлеге әнә шундый уйлануларга этәрде. Шулай, съездлар, кайберләре кара тәңгә кадәр утырып, бер көн эчендә йомгаклана, йә икешәр айлык тәнәфес ясап тәмамлана да ала икән.



*Татарстан язучыларының XIV съезды президиумы.*

**Соңгы (әлегә)—XIV съезд, яңартылган Устав нигезендә, галәттәгечә биш елдан түгел, өч елдан соң үткәрелде. Ул—2002 елның 31 маенда Казанның К. Тинчурин исемендәге театрында узды.**

Корылтайда катнашучыларны Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев котлады. "Язучыларның зур җыелышы—Татарстан өчен гаять әһәмиятле вакыйга",—диде ул үзенең чыгышында.

Язучылар берлеге идарәсенең ике корылтай арасындагы эшчәнлеге турындагы хисап доклады белән идарә рәисе Фоат Галимуллин чыкты. Ревизия комиссиясе хисабын Лирон Хәмидуллин ясады. Әдәби жанрлар буенча Резеда Әхтәмова (шигърият), Факил Сафин (проза һәм публицистика), Рафис Корбан (балалар әдәбияты), Дания Гыйммранова (драматургия), Мансур Вәлиев (әдәби тәнкыйть), Флера Сафиуллина (әдәби тел мәсьәләләре), Лилия Газизова (рус язучылары иҗаты) өстәмә докладлар ясадылар.

Докладлар буенча фикер алышуда Г. Зәйнашева, Г. Рәхим, В. Имамов, Р. Вәлиуллин, З. Мансуров, М. Маликова, Р. Батулла, Ф. Бәйрәмова, Ж. Дәрзаман, Л. Шагыйрьҗан, З. Зәйнуллин, А. Хәлим, В. Лавришко, И. Хөснетдинов һ. б. чыгыш ясады.

Корылтайда альтернатив нигездә күпчелек тавыш белән Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе итеп янә Фоат Галимуллин сайланды. Берлек идарәсенә түбәндәге язучылар керде: Харрас Әюпов, Фәүзия Бәйрәмова, Мансур Вәлиев, Мөдәррис Вәлиев, Разил Вәлиев, Разим Вәлиуллин, Лилия Газизова, Фоат Галимуллин (рәис), Галимҗан Гыйльман (рәис урынбасары), Җәүдәт Дәрзаман, Вахит Имамов, Рәфкать Кәрами, Зиннур Мансуров, Хатип Миннегулов, Газинур Морат, Шаһинур Мостафин (рәис урынбасары), Рашат Низами, Гәрәй Рәхим, Данил Салихов, Равил Фәйзуллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Зиннур Хөснияр, Солтан Шәмси.

Язучылар корылтаенда Ф. Зыятдинов житәкчелегендә ревизия комиссиясе сайланды.

Вакыт—котылгысыз алга ыргыла, еллар бер берсен алыштырып кына тора. (“Гомерләрне талкып еллар үтә!)... XIV съезддан соң да ике ел ярымга якын вакыт үткән. Бу вакыт аралыгындагы әдәби хәлләр турында сөйләүгә әлегә хәҗәт юктыр. Алар күз алдында, хәтер офыгына күчәргә өлгермәгәннәр әле. Устав буенча, киләсе елның җәй башларында яңа съезд җыйналыр, язучылар оешмасының эшчәнлеге турында тәфсилле сүз булыр.

***

Шулай итеп, чакрым баганаларын санагандай, без чорлардан чорларга, съездлардан съездларга “тотынып барып” дигәндәй, язмабызның ахырына життек. Гадәттә, мондый очракта нәтиҗәләр сорала. Юк, катгый нәтиҗәләр үк ясарга җөрьәт итмим. Үземә андый бурычны куймадым да. Күзәтүче сыйфатында билгеле бер чордагы әдәбиятыбыз дөньясындагы хәлләрне үземчә барлап кына чыктым (укырга җиңелрәк булсын дип, язмамда кулланылган әдәбият һәм архив материалларының төрле чыганакларнын исемлеге күрсәтелмәде—**Р. Ф.**). Шулай да, билгеле бер үргә менеп, ерактагы офык-манзараларны күзәткәндә, аерым бер урыннарга озаграк карап торасың, алар—биеклекме, агачлар куелыгымы яки шәрә тау итәгеме—карашыңны күбрәк җәлеп итә, уйландыра. Әлбәттә, еллар теземнәре аша артта калган әдәбият кинлекләрен күзәткәндә минем дә теге яки бу вакыйга яки әсәр нисбәтеннән тукталып, уйланып калган



*Язучыларыбыз—ПЕН-үзәк әгъзалары Финляндиядә үткән Бөтендөнья язучылары Конгрессы көннәрендә. Сулдан уңга—Вахит Юнысов, Әхәт Мушинский, Разил Вәлиев, Тәлгат Бариев, Ркаил Зәйдулла, Туфан Миңнуллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Мөдәррис Вәлиев, Марсель Галиев. 1998 ел.*

чакларым булмады түгел. Алай гына да түгел, ул уйларның бер ишләре фикер төеннәре булып күңелдә утырып та калдылар. Кайберләрен укучылар белән бүлешсәм дә ярыйдыр.

Иң әүвәл шуны ачык итеп әйтергә кирәк: әдәбиятыбыз, шөкер, бай әдәбият. Гомумкешелек мәдәнияте мирасына керерлек әсәрләр бар. Теләк жимеше итеп әйтелгән сүз түгел, бу—хакыйкать. Әмма... бу хакыйкатьне беләләрме?—бүтәнчәрәк әйтсәк, дөньяда моны белүчеләр күпме? Кызганыч, күп түгел, һәрхәлдә, без теләгән дәрәжәдә түгел. Өстәвенә, белүчеләрдән танучылар һәрчак ким чыга бит әле!.. Минемчә, татар әдәбияты тарихын объектив өйрәнү һич кенә дә канәгатьләнерлек түгел. Борынгысын әйткән дә юк (аны бармак белән генә санарлык кешеләр яхшы белә булыр), сонрак чор әдәби мирасны да юньләп белмибез һәм, шуна күрә дә, әдәбият белемендә мона кадәр булган критерийлар күп сораулар тудыра да. Татарстан Фәннәр Академиясе призеденты Мансур Хәсәнов (ул безнен Язучылар оешмасы әгъзасы да) моннан ун еллар элек үк тикмәгә генә мондый сүзләр язып чыкмады: "Иң зур проблемаларның берсе: әдәбият белеменен, гомумән, татар әдәбияты белеменен хосусан үз методологиясен булдыру зарур. Анын төп принцибы—фәлсәфи категорияләрне турыдан-туры, механик рәвештә әдәбиятка күчерүдә түгел, ә әдәбиятнын, сәнгатьнен, кеше рухи эшчәнлегенен мөстәкыйль өлкәсе икәнлеген тануга нигезләнгән, корылган булырга тиеш. Әдәбият сәясәткә, идеологик күренешләргә өстәмә, иллюстрация рәвешендә түгел, дөньяны һәм кешене образлы танып белү объекты буларак өйрәнелергә тиеш". Чыннан да, әдәбият тарихы буенча үткән гасыр ахырларына кадәр чыккан хезмәтләрнен абсолют күпчелеге сыйнфый караштан чыгып, сәяси күрсәтмәләр тәэсирендә теге яки бу идеологик схемаларга туры китереп язылганнар. Хәзер аларны уку кыен, чөнки алар тарихи анны рәнжетә, эстетик тоемны боза, чын әдәбияттан биздерә... Ә бит бер гасырга якын диярлек, методологик кулланмалар булып, алар берничә буынның әдәбиятка караш-мөнәсәбәтен формалаштырган... Хәзер, бәлки, хәлләр бик нык үзгәргәндер? Кызганыч, алай ук түгел шул, әзер шаблон схемалар белән эш итүне дәлилләгән күп мисаллар китерергә булыр иде. Язмамның тәмен жибәрәсем килми... Шулай да, "Татар энциклопедиясе сүзлеге"ннән берничә цитата китерергә жөрьәт итәм. Корьәннән (энциклопедия Корьән үк булмаса да житдиләрнен дә житдие булган академик басма) ялгыш эзләп азаплануым түгел, мисалнын да бик өстә ятканын, күзгә ташланганын гына китерәм, анда да сүз конкрет бер мәкалә турында гына булыр. "Сүзлек"нең 622 битен ачып, "Татарстан Республикасы" дигән мәкаләдән әдәбиятка багышланган кайбер юллар: "60 еллардан үткәннәргә янача карарга, бүгенгене тасвирларга мөмкинлек туа (андый мөмкинлек элек тә булган, күрәсен, тулырак яки объективрак тасвирларга мөмкинлек туа дип әйтергә теләгәннәрдер инде— **Р. Ф.**). Татар әдәбиятынын бу этабында Р. Төхфәтуллин, Ә. Давыдов, А. Гыйләжев, Ш. Мөдәррис, Г. Ахунов, Н. Фәттах, Х. Камал, Ә. Баян, Г. Афзал, Э. Касыймов, Ш. Бикчурин, М. Шабаев, Ш. Галиев, И. Юзеев, Ш. Хөсәенов, Б. Камал кебек "алтмышынчы елгылар" үзләре яшәгән заманның мөһим ижтимагый һәм әхлакый мәсьәләләрен күтәреп чыгалар". Бу саналган исемнәрнен берсен дә диярлек "60 нчы елгылар" дип санап булмый. Гадәттә, "фәләненче елгылар" дип әдәбиятка килү чоры белән бәйләнештә әйтәләр. Бу язучыларның бер ишләре әдәбиятка сугыш чорында аяк баскан, күбесе—50 елларда күтәрелеп чыккан шәхесләр (Г. Ахунов, Г. Афзал, Ш. Галиев, Х. Камал, Р. Төхфәтуллин, Ш. Хөсәенов һ. б.). Чынында, 60 нчы еллар буыны дип безнен буын (Р. Мингалим, Р. Харис, Рәш. Әхмәтжанов, Г. Рәхим, Р. Гатауллин һ. б.) санала ала. Энциклопедиягә мәкалә язган авторларнын яки авторның исенә



*Күптән көтелгән бу уникаль тарихи басмада бик күп татар язучылары турында мәгълүмат табып була. "Сүзлек" 2002 елда басылган.*

төшерик: сез "60 елгылар" дип санаган кайбер шагыйрьләр 60 елларда инде дөньяви тормышларын һәм иҗатларын тәмамлап мәңгелеккә китеп тә бардылар (Ш. Мөдәррис—1964 елда, Ә. Давыдов—1968 елда вафат). Шунысы да игътибар иттерә: "Энциклопедик сүзлек"нең русчасында (1999) бу абзацта 9 язучы саналса, шул ук "Сүзлек"нең (2002) татарча вариантында инде 16 исем. Аерма шактый! Бер үк материал нинди телдә бәян ителсә дә, тәңгәл булырга тиештер. Хәер, бу ишәю, шул ук белешмә-мәкаләдә әйтелгәнчә, "әдәбият белеме исә бер яклы идеологик ысуллардан арына бара, әдәби күренешләргә һәм тенденцияләргә фәнни һәм объектив бәя бирергә омтыла". Гомумән, яхшы омтылыш... Дәвам итик, шул ук мәкаләдә "...1970-80 елларда И. Нуруллин, М. Мәһдиев, Т. Миннуллин, Ф. Яруллин, М. Юныс, М. Хәбибуллин, Ә. Галиев, С. Сөләйманова, Мәхмүт Хәсәнов, Р. Харис, Р. Фәйзуллин, Зөлфәт, Роберт Әхмәтҗанов, Рәшит Әхмәтҗанов, М. Әгъләмов, В. Нуруллин, Р. Батулла, М. Гали, Ә. Гаффар, З. Хәким, Ә. Рәшитов, Л. Шагыйрьҗан, Х. Әюп, М. Маликова, Р. Гатауллин һ. б. (русча "Сүзлек"тә исемнәрнең бу блогында 13 язучы санала, татарчасында—25) иҗади активлык күрсәтәләр". Нигездә, дөрес. Ә төгәлсезлекләр? Әйтик, З. Хәким әдәбиятта 90 еллар башында күренә башлады, Роб. Әхмәтҗан һәм башкалар инде билгеле шагыйрьләр булып йөргәндә, З. Хәким әле тумаган да иде бугай Саный белеп санаунын да үз тәртибе бар бит. Әйе, саналганнар активлык күрсәткәннәр. Ә А. Хәлим, Ф. Садриев, Р. Мингалим, Г. Рәхим һәм тагын кайберәүләр иҗади активлык күрсәтмәделәрме? 1990 еллар әдәбияты турында сүз барганда ни өчендер тарихи темаларга язучы 3 каләмдәш кенә телгә алына (анда нигәдер Ф. Латыйфи төшеп калган). 90 елларда өч кенә кеше актив иҗат иткән булып чыга түгелме... Ул елларда бүтән язучылар да күп хезмәт куйдылар бит: З. Мансуров, Ф. Бәйрәмова, Ф. Сафин (Ф. Әмәк), Р. Зәйдулла, Г. Морат... Һәммәсен кертеп бетереп булмый диярләр. Алай дисән, шул ук бик чикләнгән урында кайбер исемнәр икешәр мәртәбә кабатлана. Әйтсән—сүз, төртсән күз дигәндәй, житеп торыр. Язучыларны шәкли рәвештә "вакыт ояларына төгәл утырта"да алмагач, аларнын иҗатларына иҗтимагый бәя биргәндә, конкрет әсәрләренә фәнни-эстетик анализ ясаганда нинди "чытырманлы карурманнар" барлыгын чамаларга була. Бу фикерне очлап шуны әйтәсе килә: язучы исеме галим-голәмәгә, кайбер очракта мөтәгалимгә, унайлы ясалма кысалар өчен иллюстратив рәвешендә генә файдаланылмаска тиеш. Үткән тарихыбызны, бүгенгене үзебез өчен дә дөрес һәм ачык итеп аңлый алмасак, аны бүтәннәргә ничек аңлатмак кирәк?



*Көрәшчеләр рухы безнең белән. 80 еллар фотосы.*

Без съездлар, юбилейлар, лауреатлыклар турында сөйлибезме, оешманын көндәлек эше турында сүз алып барабызмы, барыбер, уйлануларыбызнын төп мәгънәсе язучы хезмәтенең асылына—аның әсәрләренә барып тоташа. Һәрхәлдә шулай булырга тиеш. Житәкчеме син, урын биләмәгән каләм иясеме, язучы

саналасын икән, байрак булып ин алдан әсәрен барырга тиеш. Укучы өчен, язучының шәхесеннән бигрәк, аның әсәре кадерле (балачакта китапханәдән китапның, авторыннан бигрәк, исемен сорап ала идек; күрәсен, яшь чакның логикасы хакыйкатькә күбрәк якын булган). Минә калса, хәзер, бигрәк тә, соңгы 10-15 елда хәл бөтенрәк: игътибарыбыз күбрәк беренчелгә караганда икенчел факторлар тирәсенәрәк юнәлгән. Гадәттә, без фәлән әсәрнен язылуына (чыннан да, "Туган тел"нен яки "Моабит дәфтәре"нен вакыт-вакыт кайчан язылуларын җәмәгатьчелеккә белдереп торсак, тарихи хәтер өчен зыян булмас, һәрхәлдә ниндидер графоманнын фәлән елда туганлыгын белгертүгә караганда файдалырак булыр иде), фәлән китапнын чыгуына фәлән ел димибез, фәлән язучы яки шагыйрьгә фәлән яшь, дибез. Без теге яки бу язучынын яна әсәрен укып-тикшерү утырышында яки китап укучылар конференциясендә булдык дию урынына, күбрәк, фәлән язучынын юбилеенда яки банкетында булдык, дибез. Юбилей димәктән, аларнын иге-чиге юк. Хәер, уртача яше 60 тирәсе булган оешмада юбилярлар күп була инде ул—ел саен йөзәрләп жыеладыр. Шуна өстәп, әдәби мирастан классик әдипләрнен истәлекле даталары (боларын чыннан да әдәбият файдасына дип әйтик)... Ә юбилейлардагы пафоснын ниндилеген барыбыз да яхшы беләбез. Бу ыгы-зыгылы чаралар язучылар коллективынын, бигрәк тә, оешма аппаратынын күпме жегәр-энергиясен ала! **Әдәби хәрәкәт тирәсендәге хәрәкәт** килеп чыга. Ә әсәрләребез турында кайда сөйлибез соң? Газета-журнал битләрендә. Табигый, беренче чиратта, "Казан утлары"нда (китап күзәтүләр, рецензияләр, дискуссияләр һ. б.). Әмма бу гына аз. Әгәр көндәлек матбугатта чыккан материалларны анализласаң, аларнын күбесе әлеге дә баягы юбилейлар, премияләргә тәкъдим ителү уңаеннан булыр. Әлбәттә, алар инде мактау, зурлау рухында... Иҗат секцияләрендә (хәзер аларны остаханә дип йөртәләр) дә яна әсәрләрне укып-тикшереп анализ ясауга корылган жыелышлар сирәк үтә. Бу остаханәләрнен соңгы еллардагы төп эше теге яки бу авторны Язучылар берлегенә тәкъдим итү булды дип әйтергә ярыйдыр. Дөрес, хәзер хәл беркадәр үзгәрде: каләмдәшләрнен иҗатларына караш җитдиләнә төште, шул сәбәплеме, жыелышлары да сирәгәйде бугай... Язучылар үзләре (бигрәк тә рәис үзе) өзлексез йөреп торалар. Жыелышлар, конференцияләр, сабантуйлар, юбилейлар, сайлаулар яки бүтән сәяси вакыйгалар уңаеннан агитбригада рәвешендәге "десант"лар... Чыннан да, хәрәкәт шактый көчле... Теләк шул: бу хәрәкәт, әйткәнебезчә, әдәби хәрәкәт тирәсендәге хәрәкәт кенә түгел, конкрет әдәби әсәрләр нисбәтендә, укучыларга, шулай ук, язучыларнын үзләренә дә кирәк һәм файдалы хәрәкәт булсын.



*Шигърь бәйрәме тантанасыннан бер күренеш. 90 еллар фотосы.*

Әйе, татар әдәбияты зур (аны белү өчен Мәскәүгә яки Орелга бару хаҗәт түгел), әмма аны дөнья без теләгәнчә танымый әле, дидек. Сүз, мантыйк буенча, үзеннән үзе әдәби бәйләнешләргә, мирасыбызны пропагандалау мәсьәләләренә кайтып төшә. Алда әйтелгәнчә, үткән гасырнын икенче яртысында ул бәйләнешләр шактый нык иде. Соңгы дистә еллар эчендә, һәммәбезгә мәгълүм сәбәпләр аркасында (СССР

таркалу, глобализм факторы һ. б.) әдәбиятлар, бигрәк тә, гадәт буенча әйтелә торган милли әдәбиятлар (дөреслектә һәр әдәбият милли) беркадәр изоляциядә, үз кабыгындагы йомылуда калды. Билгеле бер вакыт аралыгы өчен бу хәл дә ярыйдыр. Бай тарихлы, бай мираслы әдәбият берара үзенең асылын ныграк өйрәнә, үзләштерә ала, үзенең эчке потенциалы хисабына яши ала. (Бу вәзгыятьтә тарихи, тамыры булмаган "яшь" әдәбиятлар гадәттә, "киселеп" кала.) Укучылары беркадәр кими төшсә дә, татар әдәбияты, әдәбият буларак, бу елларда әллә ни оттырмады дип уйлыйм. Кызыксынган кеше онытылган яки әле монарчы күпләргә бөтенләй мәгълүм булмаган мирас белән таныша алды. Дөрес, бу заманда үзеннең "эч мае"н хисабына гына озак яшәп булмый. Гомумкешелек цивилизациясенә кушылып, бердәм хәрәкәттә катнашып кына, заманча әсәрләр язып, эстетик кыйммәтләр тудырып була. Димәк, бүтән халык әдәбиятлары белән тыгыз бәйләнеш зарурият булып чыга. Тик шунсы бар: бер кергән агым суга икенче кат кереп булмаган кебек, әдәби багланышларда совет заманындагы ысуллар бик үк ярап бетмәс шул хәзер. Күпмилләтле совет әдәбиятына лаеклы өлеш кертәбез, дигән заманнар үтте. Күпмилләтле россия әдәбияты дигән сүзләр бик ишетелми. Безнең өчен багланышларның иң ышанычлы һәм дәлилле күрсәткече булган тәрҗемә эшенә дә бүген беркадәр бүтән яссылыкта карарга мәҗбүрбез. Элек тәрҗемәләр ике яклы иде: русчадан татарчага, татарчадан русчага. Хәзер күренекле әдәби әсәрләрне татарчага тәрҗемә итү юк дәрәҗәсендә. (Рус һәм чит ил әдәбияты үрнәкләрен берничә буын татарча тәрҗемәдә укып үсте. Бу—факт). Ә татарчадан русчага? Бу процесс әзме-күпме бара әле. Барса да, элеккегечә эффектлы дәрәҗәдә түгел. Чөнки бүген атаклы рус язучыларының яки шагыйрьләренең дә китап тиражлары—2-3 мең данә (тиражлары зур булган детектив жанрындагы бестселлерларны чын әдәбиятка санамыйм). Ә аз санлы халыклар әдәбиятыннан тәрҗемә үрнәкләренә ни сан? Россиядә яна Гамзатовлар мәйданга килүе бик шикле... Димәк, зур дөньяга чыгуның бүтән юлларын эзләргә кала. Рус кириллицасыннан тыш, бу кояш астында бүтән имлялы телләр дә бар. Әйтик, инглиз теле, гарәп, испан теле... Бар компьютер, интернет теле... "Тимер пәрдәләр" заманы түгел. Әлбәттә, традицион рәвештә, үзебезнең тирәлектәге, элеккечәрәк әйтсәк, тугандаш әдәбият вәкилләре белән тыгызрак элемтәләр урнаштыру бик мөһим. Безнең республикада уза торган дәрәҗәле поэзия бәйрәмнәрендә (Тукай, Пушкин, Державин), Сабантуйларда, классикларның юбилейларында, съезд-корылтайларда мөмкин кадәр күбрәк эшлекле кунаклар чакырырга кирәктер. Шулай ук, язучылар оешмасының 70 еллык тантанасына да... Мәхәббәт белән дуслыкка чикләр юк. Олы максат булсын да, зур теләк булсын! Даими рәвештә инглиз телендә китаплар чыгарып килүче ПЕН-үзәк тә бу юнәлештә эшен тагын да активлаштырыр дип ышанабыз. Һәрхәлдә бу мөһим проблеманы чишү юлында һәммәбез өчен эшлисе гамәлләр тау кадәр.



*Татарстан Язучылар берлеге бинасы.*

Татар әдәбияты дигән зур дәрья турында фикер йөрткәндә, гыйбрәтләр алып, уйланыр нәрсәләр җитәрлек. Кайчак шундый сорау да туа: бүгенге әдәбиятыбыз гомумтатар әдәбиятымы, әллә Идел-Урал регионы әдәбияты гынамы (онытмыйк:

заманында яңа татар әдәбиятында беренче проза әсәрләрен Ростов, Пенза якларыннан чыккан шәхесләр язды бит. Әйтик, безнекеләр хәзер еш кына баргалап торган Олы Әләзәнлеләр тормышы татар әдәбиятының бер әр сәхифәсе була алмас идеме? Бу җәһәттән, бүтән төбәкләрнең исемнәрен әйтеп узарга була. Түбән Идел—Сарытау, Астрахань.., тоташ Урал—Пермь, Чиләбе, Җаек.., Урта кинлекләр—Рязань, Касим...). Без, еш кына, әдәбиятыбыз берничә гасыр буе, югалган дәүләт институтларының кайбер функцияләрен (мәгърифәт, мәдәният) башкарып килде, дибез; бу хәл хәзер ничек? Милли анны, милли идеяне халыкка җиткерүдә язучыларыбызның бердәмлеге бармы (әгәр язучылар, галимнәр арасында, сүз көрәштерүдән бигрәк, бердәмлек булса, имля мәсьәләсендәге дискриминацион хокуксызлыклар килеп тә чыкмаган булыр иде)?

Язмамның баштагы өлешендә сораулы җөмләләрем инде булган иде: әдәбиятыбызның язмышы алга таба ничек булыр? Элгәргеләрдән эстафета итеп алган арбаны кемнәргә калдырабыз? Гомумән, ул әдәбият дигән арбаның кирәк-хаҗәте ни дәрәҗәдә булыр? Алдан ук куелган сорауларым күңелемдә, сөттә йөзгән елан кебек, язмам буе шомлы уй булып барды. Чыннан да, безне ниләр көтә? Әдәбият язмышы белән оешма язмышын да күз алдында тотып әйтүем (оешмасыз да әдәбият бетмәс бетүен).

Уйланырлык сәбәпләр бар. Язучылар берлеге—иҗтимагый оешма. Ә әлегә андый оешмаларның яшәешен билгеләүче канун юк. Димәк, юридик хәят—бар белән юк арасында. Бүгенге көндә язучы хезмәтен социаль яктан гарантияләгән законнар юк (шуңа күрә дә Россиядә бик күп язучылар фәкыйрьлек дәрәҗәсендә. Бу яктан бездә дә, матди яктан иркен яшәгән язучыларны бармак белән генә санарлык). Димәк, хәзерге прагматик яшьләр өчен әдәби иҗат өлкәсендә гарантияле тормышчан перспективалар күренеп тормый (шуңа күрә дә, бүген шигърияткә Тукай, Дәрдемәнд, Такташ, Җәлилләр урынына, үсмер егетләрдән бигрәк, кыз-кыркын килә дә инде). Ә оешманың гомум уртача яше 60. Фәкыйрь карт-корыны кайсы җәмгыятьтә үлеп яраталар икән? Дөрес, бездә Россиянең бүтән регионнары белән чагыштырганда хәлләр әлегә шөкер итәрлек. Әгәр Республика булмаса, борынгыдан дәүләт тоткан хисне йөрткән затлы катлам булмаса, татарның ил-көн хәлен тоймаган Илбашы булмаса, эшләр бик мөшкелгә әйләнер иде.

Хәер, гомумән, нигә мөшкел булырга тиеш ди әле! Талантлы булу фаҗига булырга тиешме? Талант—Күкләрдән иңдерелгән илаһи байлык, ил-халык байлыгы, дәүләт байлыгы. Без әлегә ил- дәүләтле булудан ваз кичкән халык түгел. Мина калса, бүгенге көндә мең еллык татар әдәбиятының бөек традицияләрен дәвам итәрлек, ким дигәндә биш дистәләп талантлы язучыларыбыз бар. Бу—зур байлык. Язучы кеше—тел сакчысы. Ә тел—милләтнең төп билгесе. Халык, милләт булып сакланып калырга телибез икән—иҗат кешеләренең, шул исәптән заман елъязмачылары—язучыларның кадерен белик! Алар булганда, шөт, нинди генә рәвештә булмасын, иҗат оешмасы да яшәр.

*2004 ел.*

*Дискуссия: "Безнең заман герое"*

## ПЕГАС КАШЫНА МИКӘН?

Татарның университеты юк диләр һәм аны ачтыру өчен байтактан көрәшәләр. Әмма, минемчә, татарның берничә, шул исәптән "Казан утлары" исемле затлыдан затлы университеты да бар. Һәм, кайчандыр бу университетта бик күпләр укый иде... Яна татар университетлары ачылуны хуплаган хәлдә, булганнарының да тулы куәткә эшләве тәэмин ителүен телим. Миңа калса, Марсель Сәлимжанов житәкләгән Камал театры, Лима Кустабаева эшләгән татар жыр һәм бию ансамбле, Илһам Шакиров, Әлфия Афзалова, Таһир Якуповлар эшләгән филармония дә чын мәгънәсендә татарның халык университетлары иде... Аяныч ки, илдә барган үзгәрешләр нәтижәсендә, республикабызда акыллы житәкчелек булган шартларда да, кая ди сиңа яңа татар университетлары ачу! Булганнарын саклау, бетерми калдыру да көннән-көн катлаулыга әйләнеп бара...

...Элек, Рим Кәримовлар эшләгән замандагы радионы татар халкының бер көттә дәрелфөнүне дип санасак, бүген исә ул шактый гади, ПТУ сымаграк белем учагы гына булып калды бугай... Һәрхәлдә элек аннан татар рухы кайнап, бәреп тора иде. Татарча телевидениебез дә, Жәлил исемендәге опера-балет театры үрнәгендә, сүздә генә татарныкы булып бара төсле. Шәхсән, телевидениебездә татар рухы дөм юк димәсәм дә, аны рәхәтләнеп караучылардан түгелмен. Милләт йөрәгенә сары май булып ятарлык тапшырулар ташка үлчим, һәм хәл уңай якка үзгәрер дә төсле түгел... WIP-зал исеме астындагы рус телендә барган тапшыру, миңа калса ин-ин эч пошыргычы һәм ул анда катнашучы түрәләргә очко өстәмидер дип уйлыйм. Ә менә шуның татарчасын чын татар зыялысы булган алып баручы белән оештырырга иде һәм сүзнең, әлбәттә, милләт, шул исәптән әдәбиятыбыз турында да баруы урынлы булыр иде...

Ә "Казан утлары" дигән университетыбызның, кыйбланы югалтмаска омтылып, жан асрап яшәп яткан көне. Кайчандыр "Коръән серләре"н чыгарган журнал бүген изге Китапның татарчасын биреп барып иске гөнаһларын юа. "Безнең заман герое" исеме астында чын тәнкыйть мәкаләләренә киң мәйдан ачылу да кыйбла дөреслеүгә дәлил...

Аллаһе Тәгаләнең "заманны сүкмәгез, чөнки заман—ул мин", дигән кисәтүен исәпкә алсак, заманга бәйсез рәвештә чын кеше була алучыны, заманыбыз герое дип тә таный алабыз булып чыга. Бармы алар? Шушы урында нәни генә чигенеш ясап, күнегелгән гадәт буенча рус классик әдәбиятына мөрәжәгать итәргә рөхсәт итсәнче, хөрмәтле укучы. Ф. М. Достоевскийның "Жинаять һәм жәза" романында үзенчәлекле үтә дә тискәре герой бар. Ул—Свидригайлов. Әлеге герой, кайчандыр ниндидер гөнаһлар эшләгән, акыллы гына кеше, кыю, житмәсә бар байлыгын ятим һәм ятимәләргә калдыра, Дуняны алдап кулына төшергәч, кызның катгыйлыгын күреп, аның үзеннән котылуына юл куя. Ә автор аны барыбер кабахәт бәндә итеп тамгалый. Һәм үз-үзенә кул салуына да исе китми. Инде килеп шушы ук авторның "Бертуган Карамазовлар" әсәрендәге Катерина һәм Дмитрий кыйссасына туктыйк. Кызның әтисе, хәрби командир, казна акчасын оттыра. Тикшерү килү белән бу

фаш булачак һәм әлеге гаилә хурлыкка төшүгә мәхкүм. Митя горур Катеринаны "тиешле сумманы алырга кил",—дип фатирына чакыра. Катерина, әтисен, гаиләләрен хурлыктан саклап калу бәрабәренә үз-үзен корбан итәргә була һәм буйдак офицер фатирына юнәлә. Митя ана тиешле сумманы, ягъни бар булган акчасын тоттыра һәм бернинди корбан да кабул итми генә кыз белән хушлаша. Һәм шушылай кыз горурлыгы белән уйнавы өчен үзен кабахәткә саный... Үз-үзен корбан итү хакына башкаларга игелек кылам дип килгән Катерина да мәсьәләнең болай хәл ителүеннән канәгать түгел. Күренә ки, классик язучы шәхескә бик югары таләпләр куя. Кызганычка каршы татар әдәбиятында, бигрәк тә соңгы елларда, Свидригайлов сыман агайлар унай герой буларак тәкъдим ителә башлады...

Егет чагымда нииндидер гәҗиттә хикәям басылып чыккан иде. Колхозыбыз рәисе Мәннаф ага мине очратып:

—Очеркыңны укыдым, әйбәт чыккан,—диде.

—Кая инде безгә очерклар язу, хикәя генә иде бит ул,—дим.

—Юк, юк. Очерк, очерк. Әйбәт чыккан,—дип Мәннаф агай үз сүзеннән чигенмәде.

Әлбәттә бу, белгечлеге буенча агроном аганың, "хикәяң очерк булып чыккан" дип тәнкыйтьләве түгел, аныңча татарча яңгырашлы "хикәя"гә караганда русча яңгырашлы "очерк", дәрәҗәсе буенча югарырак баскычта тора, һәм үзенчә ул мине купайтмакчы булды. Әмма Мәннаф агайның шул бәяләмәсе һаман онытылмый һәм татар әдәбиятында урын алган күп кенә хикәя, повесть, роман һәм хәтта драматургия әсәрләренең дә асылда очерк жанрына якынлыгы сискәндерә. Бигрәк тә авылда тормышны яхшыртуны әйбәт колхоз рәисләре проблемасына кайтарып калдыручы әсәрләргә бу хас. *(Бүгенге татар телевидениебез журналистлары әле дә шушы бұразнадан чыга алмый.)*

Әлеге җәһәттән, талантлы драматург Туфан ага Миңнуллинның "Кырларым, тугайларым" әсәрен күздән кичерик. Бу әсәрдә, 60 нчы елларның "Дело было в Пенькове" фильмындагыча, трактор белән трактор тартыштырган шикелле, комбайннарны өзештерәләр *(җөмләдән, Аяз ага Гыйләҗевнең "Әтәч менгән читәнгә" повестенда дә шушы штамп кабатлана һәм нәтиҗә дә уртак: техника ватыла).* Әсәрнең төп герое, колхоз рәисе, комбайнчыларны тукмый. Борын асты кипмәгән малайларның комбайнга утыртылуын автор, кеше, кадрлар кытлыгы белән аклый. Ә рәиснең җинаятен *(баш кешенең үз кулы астында эшләүчеләргә кул күтәрүенә карата җинаятьләр кодексында махсус маддә бар)* "икмәк хакына" гафу итә. Ягъни автор өчен югары уңыш алу—панацея. Тукмалучы малайның әнисе шикаяте буенча журналист китерелүе герой башына төшкән бәла итеп тасвирлана. Авторга үзе тудырган герое сөйкемле булып тоела, ул аны бәла-казалардан да тиз аралый. Журналист кыз ана студент чакларында гашыйк булган икән... Әчкегә сабышкан хатыны да аны ярата, салган баштан ялгышып кына хыянәт итә. Ахырда, гаебен тирәнтен аңлап, асылынып үлеп, геройны үзеннән коткара... Тукмалучы малайның әтисе, моннан алда эшләгән колхоз рәисе, ялын ташлап бик вакытлы кайтып кереп, геройны "усал" хатыны каһәреннән житез генә аралый. Берочтан, хезмәт юлын үзеннән алда эшләгән житәкченең улын тукмау белән "бизәгән" яна рәискә "кыйммәтле" киңәшләрен бирә, тегесе, *(рәхмәт сабыр итүенә)*, бүлдерми тыңлый...

Кол хәлендәге колхоз малайларын тукмарга батыр колхоз рәисе, үзенә белгеч итеп эшкә жибәрелгән, тиз арада хатынын "тозагына төшергән" кала егете каршында коелып төшә, мыскыллавына түзә һәм ул теләгән кәгазьгә имзасын сырлый...

Ягъни, ирлек горурлыгы чамалы, намус кодексының ни икәнен белмәүче, мөселманга фахишә белән бер түбә астында яшәргә ярамавын танымаучы—унай герой буларак тәкъдим ителә. Хатынының шул көнгә калуына, соңыннан үз-үзенә кул салуга барып житүендә автор, героеның гаебен күрми, күргән өлешен икмәк хакына кичерә... Әлбәттә, югары күрсәткечләргә ирешүче мондый геройларны мактап мәкаләләр, очерклар язарга, кем белә, бәлкем ярыйдыр да, әйтик, авыл хужалыгы министрлыгы игълан иткән конкурс кысаларында, әмма матур әдәбиятыбызда мондый персонажларны пьедесталга күтәрү мин фәкыйрьгә аңлашылмый.

Дөнья әдәбиятында кол хезмәтенә, колның "матур" язмышына, гомумән коллыкка дан җырланмый. Надсмотрщикның гүзәл образын да тудыручы юк. Бу җәһәттән татар язучылары дөнья әдипләренең борыннарына чирттеләр... "Әйбәт

колхоз рәисе" образын кем генә тудырмады бездә. *(Тудырулар шул темага төшерелгән уртакул урыс фильмнарыннан соң башланды.)* Язучы агайлар геройларының прототиплары булуы белән дә горурланды...

Алар "уңай һәм шәп" дип тәкъдим иткән геройларның байтагы шактый чикләнгән шәхесләр, эчәләр, «уҗымга да чыккалыйлар» һәм автор тарафыннан бу нәрсәләр норма буларак тәкъдим ителә... Хатыннары—йорт тота, яки каядыр эштә хисаплана. Мондый "умырткасызлар" классына караган геройлар белән конфликтка керүчеләр дә, рух-ан югарылыгы буенча, "амеба" баскычыннан әллә ни биек тормый...

Рус әдәбиятыннан алынган штампларны татарныкына җирләштерү җәһәтеннән тагын бер рус язучысы иҗаты аерым игътибарга лаек. В. Распутинның " Живи и помни" тәэсирендә татар әдәбиятында дезертир образлары пәйда булды. Распутин әсәрендә дезертир ир һәм аның хатыны арасындагы мәхәббәт беренче планда торса, һәм бу әсәр мәхәббәт турында үзенчәлекле, тетрәндергеч әсәр булып чыкса, татарча аналоглардагы геройлар "Кеше" югарылыгыннан ерак. Хатыннар да үтә сознательный... Ниткән мәхәббәт ди ул?.. Илдә сугыш барганда... Партия һәм хөкүмәт ничек куша—шулай яшәргә! Ягъни сарыкларга хас инстинкт безнең әдәбиятта аңлылык үрнәге буларак тәкъдим ителә...

Шагыйрь Равил Фәйзуллинның милләт язмышы өчен сызланып язган бер шигырендә, хәлебезне аның картаюына бәйләп аңлаткан иде. Аянычка каршы бәлкем ул хаклыдыр да? Әмма кайбер үткен прозаикларыбыз әлеге фикердән үзләре өчен файда бирүче нәтиҗә чыгарып "алтын сенер"гә юлыктылар төсле...

Рас, милләтебез картайган, аның киләчәге юк, аны үлем көтә, ул бүгенгене аңламый, аның матур үткәне генә бар... Димәк, татар әдәбиятында гавәм укырлык уңышлы әсәрне, үткәнгә, картлыкка мөрәҗәгать итеп тудыру—иң отышлы юл. Һәм китте бер заман гүзәл әби һәм бабай образлары...

Әмма "Әлдермештән Әлмәндәр" бу исемлектә түгел, аның проблемасы бүтән. Гел Туфан ага әсәрләренә мөрәҗәгать итү ниндидер бәйләнү булып аңлашылмасын иде, мин таланты бәхәссез булганы өчен шушы олпат авторны сайладым. *(Роберт Миңнуллин да бер мәкаләсендә аның гына җырлары тәнкыйть ителүеннән зарланды. Ә зар урынсыз, талантлы шагыйрь әсәрләре тәнкыйтькә иркен җирлек тудыра, чөнки камиллекнең чиге юк, ә графоманнар язган текстлар тәнкыйтьтән түбән тору сәбәпле тәнкыйтьче игътибарын җәлеп итми).* Тамашачы бу әсәрне дә, төп геройны да яратып кабул итте, тамашаны күз яшьләрен түгеп карады, карый һәм карар да әле. Ә төптән уйласак, бу монсу комедия буларак тәкъдим ителгән әсәр төбендә татар трагедиясе ята. Туксан бер яшькә җиткән карт, намазлыкка басасы урында, күрше урыс авылына барып, эчеп кайтып, үлә...

Үзгәртеп кору чоры һәм базар экономикасы әлеге процесска үз төзәтмәләрен кертте. Кемнәрдер бозыклык турында авыз сулары корыткан тәсфилле әсәрләр язып гавәм йөрәгенә юл эзләде, әмма халкыбыз язмышы өчен җан атып иҗат ителгәннәре дә мәйданга чыкты...

Аңлыйм, Достоевский геройларын тудыру өчен авторның Достоевский булуы шарт. Янә килеп, югары лигада уйнаучы спортчы булсын өчен аны кече яшеннән чемпионлыкка әзерләргә алынырга, ягъни вакыт, шартлар, шәп тренер һәм зур чыгымнар кирәк. Һәм хезмәтнең, тырышлыкның, ахыр килеп акланачагына өмет, ә бәлкем гарантия дә булуы зарур бит әле. Ә татар язучысын нигездә авыл мәктәпләре һәм университетның татар бүлеге әзерли... Ниндидер матди файда булачагы да күренеп тормый һәм язучылыкның тукталмавын, мөбарәк тәсбихның өзелмәвен талантка хас рухи ихтыяҗ гына саклый...

Хак булса, кайсыдыр аз санлы төньяк халкында шундый гадәт бар: хуҗа кунагына урынны хәләл хатыны белән бергә җәя. Әлеге халык кан катышып гариплеккә чыгудан шулай саклана. Бердәнбер чыганактан туенучы әдәбиятыбызны савыктыру өчен дә бәлкем әлеге халыктан үрнәк аласыдыр? Әдәбиятыбызга инженерлар, табиблар, башка профессия вәкилләре дә килсен, күбрәк килсен иде. Әнә бит, Зәки Зәйнуллин һәм Миргазиян аганың әдәбиятка килүе, минә калса үтә дә шифалы булды. Алар бит традицион юл белән әдәбиятка тәпиләүчеләрдән һәр мәсьәләгә үзгә якын киләләр.

"Казан утлары" журналының бер санында Мөхәммәт ага Мәһдиевнең "Татар язылысы ул кем?" исемле мәкаләсе дөнья күргән һәм ул андый затларның төкәнүе хакында күңелсез нәтиҗә чыгарган иде. Инде менә татар әдәбиятында "заман каһарманы ул кем" дигән исем астында дискуссия бара. Мина калса язылыларыбыз да дөм төкәнмәгән, һәм замана герое саналырлык персонажлар да күзгә чалынгалады. Шәхсән үземә ин ошаганы Фәкил Сафиннын "Соңгы көз" повесте булды. Һәм ул тудырган, сөйгәнен кабахәт колхоз рәисе куеныннан аралап, үзе белән алып киткән саф күңелле тракторчы егет Илгиз, урындагы деспотиягә буйсынмаган, жайлашырга теләмәгән Сабиров, золымга каршы торырлык көч тапкан тракторчы егет Фәнис, һәм рәискә жайлашмый үз дигәнен әйтеп яшь алучы Иманле авылы бригадиры Зәбир Мирзиев. Әлеге автор, колхоз рәисе турында халык колагына эленә килгән легенданы, ялганны, ниһаять, фаш итте, колхоз-совхоз системасының жинаятьчел асылын укучыларына сәнгать телендә бәян итте... Әлеге автор "Саташып аткан таң" романында исә дәүләт Системасы асылын да сәнгатьчә тасвирларга жөрьәт итте һәм алынган эшен шактый уңышлы башкарып чыкты дип тә уйлыйм.

Мәкаләмдә телгә алынган бөек рус язучысы Достоевскийны, хәзергеләрен әйтә алмыйм, совет чоры әдәби белгечләре реакцион карашлы дип тамгалыйлар иде. Мәктәпләрдә укыган чорларыбызда да безгә демократик әдәбият, демократик карашлы автор әйбәт дип тукыдылар. Янә килеп кадимчеләр иске, ә жәдитчеләр яңалык яклы, димәк ки алар шәп дип тәгаенләделәр.

Мәгълүм ки, бер үк нәрсә агу да дару да була ала. Хикмәт дозада. Рухи азык, рухи тәрбия чыганагы булган әдәбиятны да жимергеч корал итеп файдалану берни тормавы белән базар экономикасы чорында якыннан таныштык. Әмма шушы сукмакка керүнең юл башында, минем карашча, нәкъ менә демократик әдәбият торды да инде.

Әйтик, Һиндстанда төп халык касталарга бүленгән һәм әлеге структура ил хакимиятенә ятларның үтеп керү мөмкинлеген кат-кат чикләп торган. Димәк боларны таларга, мөлкәтләрен үзләштерергә омтылучы ятлар өчен, әлеге милли саклану чарасын, идеалда милләтнең үз кулы белән жимерергә кирәк. Ярдәмгә демократик әдәбият алына. Һәм демократ язучы илдә яшәп килгән дин-йола аркасында бәхетсезлеккә дучар булган саф мәхәббәт турында кыйсса яза. Шундый эчтәлектәге фильмнар төшерелә. Нәтижәдә, жирле халык күңеленә, яшәп килгән дин-йолаларга, ә асылда үз милләтенең яшәү шартына каршы агулы протест орлыклары чәчелә. Әлеге сюжет барлык халыкларның да әдәбиятларына жирләштерелгән. Татар милләтен харап итү өчен иң кулае, саф мәхәббәт хакына катнаш никахны яклау, татар хатынын "азат итү" өчен, милли гадәткә, дингә, динчеләргә каршы көрәшү иде. Татар демократик әдәбияты үзен нәкъ шул юнәлештә тапты, һәм бүген ул чәчкән орлыкларның жимешләре дискотекаларда чишенеп биюче, панельгә чыгучы, зиначы "милли туташларыбыз" буларак гәүдәләнеш ала...

Жир шарында кеше бик күбәйде. Фәнни-техник революция роботларга жан өреп тә әлеге проблеманы кискенләштерде. Хәер, ник әле ике куянның койрыгын берьюлы тотмаска, нигә дип әле кыйммәтле материаллар һәм күп акча сарыф итәргә бу эшкә? Ник әле аларны ясауда нигез ташы итеп арзанлы да, дифицит та булмаган чимал, кешенең үзен алмаска? Безнең экраннардан төшмәгән Америка фильмнарын *(триллерлар, боевиклар, эротика, ужастик һ. б. ш.)* французлар кеше өчен зарарлы дип саный һәм әлеге ил хөкүмәте аларны экраннарына үткәрмәү белән генә чикләнмичә, боларны хәтта телеэкранда телгә алган өчен генә дә зур-зур штрафлар түләтүне кануни жирлеккә салган. Һәм французлар бик дөрес эшлиләр, чөнки әлеге "рухи азык" нәкъ менә кеше жирлегендә биороботлар житештерүне күздә тота да. Колхоз системасы өчен авылның бригада булуы зарур булганы кебек, базар экономикасына корылган дөнья, халыкның электоратка, шәхеснең товар житештерүче карусыз биоработка әйләнүен куәтли... Һәм мондый үзгәртеп коруларда әдәбиятка нинди роль бирелүенә тукталдык кебек. Соңгы вакытта тәнкыйть сәнәгенә эләккән *(шул исәптән мин фәкыйрегезнең "Кашка тәкәме, кәжә тәкәсеме" исемле мәкаләсендә дә кайбер әсәрләр негатив яктан телгә алынды)* татар язучылары әсәрләре дә, кем әйтмешли, нәкъ шушы тегермәнгә су коя...

Кайчандыр Татарстан телевидениесе "ЗИППОПО" *(Заочный институт*

*позитивного поведения)* атлы тапшыру алып барды. Кайбер әдипләребез дә, матур сүзләргә мөкиббән китеп, югары даирәләргә позитив мөнәсәбәттә торуны хуплап язып чыккаладылар. Әмма христиан морале дә, ислам әхлагы да позитивлыкны икейөзлелек дип бәяли һәм ихласлыкны куәтли.

Шәхсән үзем татар язучыларына Достоевскийча "реакционлык"-кадимчелек телим. Ният изге, кыйбла дөрес, ихласлыкка хилафлык китерми торган иҗат зарур. Һәм ул кешелегебез сагында торсын өчен, язучы халкына иң киме: акнын—ак, ә каранын кара булуына иман китерү һәм шул позициясеннән бер нәрсә бәрабәренә дә бер карыш та чигенмәү таләп ителә...

**Рөстәм ЗАРИПОВ**

# УКЫР ҖАННАР БЕТМӘСЕН!

"Казан утлары" журналы—татар халкының телен, милли әдәбиятын үстерүдә зур роль уйнаучы басмаларның берсе. Мин аны алтмышынчы еллардан, "Совет әдәбияты" исемен йөрткән чордан ук, яратып укып барам. Чөнки журнал битләрендә танылган әдипләребезнең, әдәбиятның олы юлына аяк басучы талантлы яшьләрнең иң яхшы әсәрләре—романнар, повестьлар, хикәяләр, үткен-үткен шигырьләр, тәнкыйть материаллары басылды. Алар белән даими танышып барганда әдәбиятыбызның ничек сулыш алуын, аның тоткан кыйбласын һәрвакыт дөрес билгеләп булды. Бу, әлбәттә, тел белгечләре, идеология эшчәннәре өчен генә түгел, әдәбиятыбызны сөючеләр өчен дә зур куаныч.

Әмма узган гасырның туксанынчы елларында башланган демократия җилләре җәмгыятебезнең икътисадый, сәяси, рухи тормышын тамырдан үзгәртеп ташлады. Әшсезлек, халыкның хәерчеләнүе белән беррәттән, көндәлек матбугатка да тискәре йогынты ясады. Аларның бәяләре нык артты, "мең кешегә мең газета-журнал" дигән чакырулар да юкка чыкты. Нәтиҗәдә, укучыларны үзләренә җәлеп итү максаты белән җирле матбугатта, аеруча телевидениедә талауга, үтерешкә, секска корылган материаллар өстенлек алды. Шуна күрә "Безнең заман герое" темасына фикер алышу бик вакытлы һәм кирәк.

Чынлап та, бүгенге татар әдәбиятының геройлары кемнәр? Алар безнең бүгенге җәмгыятебездә яшәүчеләргә, аеруча киләчәктә телебезне, әдәбиятыбызны үстерергә тиешле яшьләргә нинди йогынты ясыйлар, яшәешебезне яхшыртуда нинди роль уйныйлар? Бүгенге көндә күп гасырларга сузылган бай традицияле әдәбиятыбыз саекмыймы?

Соңгы елларда әдәбиятыбызда, аның төп юнәлешен билгеләүче "Казан утлары" журналы битләрендә, минемчә, милли тематика колачы киңәйде. СССР, коммунистлар хакимияте чорында нык тыелып килгән, шуның өчен шактый шәхесләребезгә "күсәк" эләккән татар тарихын, милләтебезнең үткән чынбарлыгын дөрес күрсәтүгә игътибар нык артты. Узган елның 9 нчы санында басылган "Идегәй дастаны" үзе генә дә ни тора! Дөресен генә әйткәндә, моңа кадәр укучылар гына түгел, белемле интеллигенция вәкилләренең дә шактые әлеге әсәр турында мәгълүматсыз иде. XIV-XV гасырдагы Идел-Җаек буенда яшәүче халкыбызның көрәшен чагылдырган дастан өчен һәр укучы шат булгандыр, әлбәттә.

Соңгы елларда укучылар күнелен Фаил Сафин иҗаты яулый бара. Аның әсәрләрендә төп тема булып милләтебез язмышы, аның фаҗигале үткәне, халкыбызның үз урынын яулау өчен көрәше тора. Үзенең "Биек таунын башларында" романында да әнә шуларны, "бандитларга", "террорчыларга" каршы сугышта чеченнарны җәберләүне, рус армиясендәге рәхимсезлекне, кыргыйлыкны бөтен тулылыгы белән ачып күрсәтә алган. Ә 2001 елның 8-9 саннарында басыла башлаган "Саташып аткан таң" романының тәмамланганын укучы түземсезлек белән көтеп алды. Өч китаптан торган бу әсәрдә тасвирлана торган вакыйгалар XX йөз башында

ук башланып, революция һәм аннан соңгы чорларны үз эченә сыендыруы белән дә отышлы булган диясе килә. Шуның нәтиҗәсендә шәхес культын үзебезнең республика җирлегендә тасвирлавы да, аеруча Әхмәтсафа Дәүләтъяров, Шамил Усманов, Һади Такташ, Муса Җәлил кебек күренекле шәхесләребезнең, гомумән, халыкның тормыш-көнкүрешен яхшыртуга омтылган эшчәнлекләрен бөтен тулылыгы белән сурәтләү мөмкинлеген тудырган. Халыкларның ирекләрен, хокукларын яклау өчен барган бүгенге көндә дә бу гаять мөһим. Хәтта йөзләрчә мең кешеләрне Ежовның канлы тегермәнендә тарттырган һәм соңыннан үзләре дә шунда туралган Алемасов, Михайловлар да—бүгенге көн геройлары. Укучыларны алар үз хокукларын яклауда нык торырга, килешмәүчән булырга әйдиләр.

Татар әдәбиятында Айдар Хәлим аерым урын алып тора. Демократия елләре исә башлаганчы ук аның иҗатында милләтләр язмышы төп урынны алды. Аның 1992—1994 елларда язылган "Гомеремнең ун көне" китабында да газиз халкының ачы язмышы тасвирланган. Әлеге китапта Берләшкән Милләтләр Оешмасы һәм башка халыкара оешмалар җитәкчеләренә, Россия, Татарстан, Башкортстан Президентлары исеменә юлланган мөрәҗәгате дә урын алган. Бу үзе ук Айдар әфәндедең милләтләрнең хокуклары өчен үз-үзен аямыйча көрәшүче шәхес икәнен дәлилли. Әнә шуның өчен дә ана "Җирдә тормышны һәм кешелеклелекне яклау буенча Бөтендөнья Рыцарьлары Конфедерациясенең АК ХАЧ ордены кавалеры" исеме бирелгән дә. Аның әсәрләрендә кеше шәхесенең түбәнсетелүенә, төрлечә мыскыллануына ачы нәфрәт яңгырый. "Өч аяклы ат" повестенда авыр, кырыс еллар тасвирлана. Әле Сталин репрессияләре дәвам итә, кешелек сыйфатлары аяк астына салып таптала. Әнә шул вакытта ук яшүсмер Кәбир Бөкебаш Галләметдин, участковый Сәйфуллиннардан курыкмыйча үзенең хаклылыгын расларга тырыша. Әсәр гаҗәеп матур теле, көчле чагыштырулары белән укучыларда матур тәэсир калдыра һәм ирексездән үзләрен дә шул Кәбирләр сафына бастыра. Хәтта ерткыч бүре дә аны ээрлекләүдән туктый, чегәннәр урманнан чыгарга ярдәм итәләр. Ә исерек Бөкебашлар үзләренең явыз ниятләрен тормышка ашырырга, алай да булмаса, әнисе Санияне, егетнең үзен дә гаепләп төрмәгә утыртырга тырышалар. Галләметдин исә үзенең барлык кара эшләрен хакимлек итүче Совет власте исеменнән башкара. Шуның белән язучы Совет властенең түбән катлауга әверелдергән халыкны туктаусыз изүен, аның хокукларын кысуын ассызыклый.

Алдыбызда күләме зур булмаган "Татар вакыты" романы. Көчле сурәтләү чаралары, йөгерек теле шунда ук укучыны үзенә тарта. Шунлыктан аны кызыксынып, бер сулыш белән укыйсың. Роман үзәгендә—татарның милли гореф-гадәтләрен оныта, мутантлаша баручы сугыш ветераны Мотаһар Чанбарисов. Аның белән янәшә җәмгыятьнең үзәген тәшкил итүче, ата-балалык вазифаларын югалткан, изгелек кылу, ярдәм итү гамәлләрен белмәүче улы Мөдәррис, мал өчен әтисен үтерүдән дә тайчынмаган кызы Фәрдүнә, оныгы Вадим образлары сурәтләнгән әсәрне укучылар арасында аны татар милләтенең бетә баруына чаң сугучы әсәр—"кара роман" дип исәпләүчеләр дә шактый. Дөрестән дә, аны укып бетергәч, күңелдә гаять авыр тойгы кала. Ирексездән Г. Башировның "Намус" романындагы Нәфисә образы искә төшә. Шул образлар аша һәркем хатын-кызларның тырышлыгына, үрнәк күрсәтеп эшләвенә горурланып яшәде бит. Әмма фикер алга атлый. Колхозда "таяк" исәбенә эшләп, төрле налоглар белән күмелгән, республиканың нефть чыгару буенча СССРда беренче урында баруына шатланып, басу-кырларның казылып-тырналып бетүен күрмәмешкә салышкан, ягарына утыны, газы булмаган, көне ачлы-туклы яшәгән Нәфисәләр, башка геройларыбыз шул Мотаһарларны барлыкка китерүче "гүзәл" затлар булдылар түгелме соң? Алар үзләренең хокукларын, милли гореф гадәтләрен, туган телләренең бөеклеген яклап көрәшкән булсалар, бәлкем бүгенге көндәге Мөдәррисләр, Фәрдүнәләр булмаслар да иде?! Язучының барлык әсәрләрендә дә—романмы, повестьмы, хикәяме, публицистик материалмы—үзенең хокуксызлыгына, өлкән "братның" мыскыллавына риза булып яшәүчеләрнең битарафлыгына чаң суга, көрәштә һәркемнең лаеклы урыны булырга тиешлеген ассызыклый.

Әмма бүгенге көн яшәешен тасвирлау сылтавы белән матбугат битләрендә җиңел куллан язылган төссез, әхлаксыз әсәрләр дә басылып килә әле. Ара-тирә ана инде

тәҗрибә туплаган, укучыларның хөрмәтен яулаган әдипләребез дә ияреп китә. Әсгать Сәлах үзенең "Соңгы вальс" повестенда Чернобыльдагы коточкыч атом фаҗигасендә катнашкан һәм шунда көчле нурланыш алып та кешеләргә тирән ышанычын, яшәүгә олы омтылышын саклап кала алган Газиз образын бирде. Мондый әсәрләре аның шактый. Әмма, шушылар белән бергә, журналда Сафуан, Сандра, Микулай, Минзәки, Гөлмәрфуга кебек ир хатынын, хатын ирен бутап бетергән образлары белән "Каеннар юлы" повесте дөнья күрде. Кем инде үзенең хатынын сөяркә итеп тоткан кешегә, шуны белә торып йорт төзергә бүрәнә бирсен дә, изгелек кылып йөрсен ди?! Халыкта "Кеше ышанмаслык хәлне чын булса да сөйләмә" дигән әйтем дә бар бит әле. Ә. Сәлах, кызганычка каршы, әлеге гыйбарәне онытып җибәргән.

Халык язучыга зур таләпләр куя. Аларны ул гомер-гомергә гаделлеккә юл күрсәтүче, хаклык өчен көшәрүче дип исәпли. Шуңа күрә халыкта "Китап сүзе", "Китап—бер нәселнең икенчесенә калдырган мирасы", "Каләм кылганны кылыч кыла алмый" дигән әйтемнәр саклана. Шуңа күрә дә әдип исемен йөртүче олы зат үзенең иҗатына гаять сак карарга тиештер. "Казан утлары" журналының баш мөхәррире Р. Фәйзуллин күрсәтеп үткәнчә, демократия чоры башлангач, үзләрен язучы санаган графоманнар армиясе нык ишәйде. Үзләренең чиле-пешле, әхлак, әдәп кысаларына кермәгән әсәрләрен бай эшмәкәрләр ярдәмендә китап итеп чыгарган "талант ияләре" барлык капкаларны җимереп, Язучылар берлегенә дә аяк басалар. Бу безнең укучыларыбыз күңелендә җылы хисләр йорткән әдипләребез исеменә күләгә төшерә. Ул турыда, һичшиксез, уйланырга, ныклы таләпләр куярга кирәктер.

Сүземне йомгаклап һәм кабатлап шуны әйтәсе килә. "Казан утлары" журналы—әдәбиятыбызның маягы, татар милләтенең үсешенә олы юл күрсәтүче ул. Аның оештыручылары да—Татарстан хөкүмәте, Язучылар берлеге һәм талантлы әдипләрне берләштергән редакциянең хезмәт коллективы. Әнә шул олы ышаныч коллектив иҗатының үзәк буынын тәшкил итсен иде. Хөрмәтле шагыйребез үзе дә кисәтә түгелме соң?

*Кичәрләр дип, озак еллар күпер салдым,*
*Эш беткәндә карап баксам—елгам кипкән...*
*Нур чәчәм дип, гомер буе җырлар яздым,*
*Томнар чыккач карыйм: укыр җаннар беткән!*

Әйе, "Казан утлары" һәм бүтән газета-журналларны, һәр китапны укучылар көтеп алсыннар, яратып укысыннар!

**Револь РАКОВ,**
*Татарстан Журналистлар*
*берлеге әгъзасы.*

*Хәтер*

# МИРГАЗИЗ УКМАСЫЙНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

**(1984 — 1946)**

1910 елда Казанның "Шәрекъ" клубында сөйләгән халык иҗаты турында мәгълүм лекциясендә Г. Тукай, чордаш шагыйрьләренә фольклорның йогынтысын күрсәтеп, шуның бер мисалы итеп, М. Укмасыйның "Килен" исемле шигырен китерә. Аннан— Сәгыйть Рәмиев җырын, үзенекен... Халык иҗаты, бигрәк тә җырлары нигезендә язылган бу төр әсәрләрне ул "сонгый" (ясалма) шигырь дип атый. Үзенең "Милли моңнар", "Эштән чыгарылган татар кызына" һ. б. җырларын әнә шул рухта иҗат итә. Бу лекция соңрак китап булып та басылып чыга, бөек шагыйрьнең томнарына керә—инде ул әдәби тарих булып, аның битләрендә чордаш-каләмдәшләренә, шул исәптән М. Укмасый шигырьләренә җылы бер мөнәсәбәте дә яшәвен дәвам итә. Халыкчан, гади шагыйрь дип таныган М. Укмасый шигырьләрен ул—үзе төзеп бастырган "Мәктәптә милли әдәбият дәресләре" исемле хрестоматиясенә дә керткән (сүз җаеннан: мондый характердагы "Алтын таҗ" исемле уку китабын М. Укмасый да 1909 һәм 1915 елларда дөньяга чыгара; Дәрдемәнд кебек шагыйрьләр белән ярыша-ярыша, көнчыгышның үгет-нәсихәт шигырьләрен тәрҗемә итеп бастыра...).

Шулай да, бүгенге укучы өчен Укмасый исеме яхшы билгеле дип әйтеп булмыйдыр. Егерменче гасыр башы шигъриятенең иң зур исемнәре—Г. Тукай, С. Рәмиев, Дәрдемәнд, Бабич исемнәре белән дә янәшә куелмый ул. М. Гафури, Н. Думавилар белән дә... Мөгаен, үз вакытында шактый билгеле булуы, халыкның шул чордагы тормышын, уй-хыялларын, табигать һәм мәхәббәт хисләрен үтемле чаралар белән чагылдыруы белән ул З. Ярмәки, З. Бәшири, С. Сүнчәләйләргә якынрак торадыр. Шулай да әдәбият тарихында үз эзен калдыра алган, югыйсә, галимнәр язуынча, гасыр башында 800 шагыйрь иҗат иткән бит. 1956 һәм 1993 елларда басылган шигърият антологияләребездә дә урын тапкан М. Укмасый; быел "Мәгариф" нәшриятында дөнья күргән "Татар шигърияте. XX гасыр башы" исемле саллы (төзүчесе, кереш сүз, аңлатмалар язучы—З. Рәмиев) китапта да шактый күп шигырьләре басылган. Моннан ун ел элек журналыбызда Мөхәммәт Мәһдиевнең шагыйрь иҗаты һәм фаҗигале язмышына багышланган "Кара тарихыбыздан бер ләүхә" исемле әтрафлы мәкаләсе басылуын да укучыларыбыз хәтерлидер...

М. Укмасый (чын фамилиясе—Зәбиров)—әдәбиятыбызга егерменче гасырда шактый күп шагыйрьләр биргән үзенчәлекле Балык Бистәсе төбәгеннән: чордашы Фәрит Ибраһимов, соңрак Зәйнәп Бәширова, Роберт Әхмәтҗан, Равил Фәйзуллин, Кадыйр Сибгатуллин, Акъегет исемнәрен генә искә алыйк. Соңгы еллардан исә—Вазыйх Фатыйхов, Рәсимә Гарифуллиналар...

Кече Укмас авылында туган шагыйрь төрле авыл мәдрәсәләрендә, соңрак Казанда, атаклы "Мөхәммәдия"дә укый; Каюм Насыйрины күреп калу бәхетенә ирешә; мәдрәсәдә Фатих Әмирхан, Зариф Бәшириләр белән аралаша (соныннан ул бу хакта истәлекләр дә язып калдырачак.). Аннары — мөгаллимлек эше, халык арасында эшләү, сугышка алыну... Революциядән соң янә укыту эше, туган авылында мулла булу... 1931 елда М. Укмасый "контрпропаганда өчен" кулга алына, 8 елга сөргенгә хөкем ителә...

Әдәбият дөньясында ул кабат 1945 елда, нәкъ менә безнең журналда (ул чакта—"Совет әдәбияты") яңа шигырьләре белән күренеп кала. 1946 елда (кайбер басмаларда—1948 елда дип тә күрсәтелә) Казанда вафат була.

Китаплары: "Хатирәләр яки укучыларыма сүзләрем" (1906), "Миргазиз Укмасый шигырьләре" (1909), "Алданма кызыл алмага" (1910), "Өмет йолдызым" (1912). 1959 елда галим Мөхәммәт Гайнуллин кереш сүзе белән шагыйрьнең "Сайланма әсәрләр" исемле җыйнамасы дөнья күргән (аңа рецензияне Н. Ямалин (Нил Юзиев) язып, журналыбызда бастырып чыгарган). М. Гайнуллинның "Татар әдипләре" (1978) китабында да М. Укмасыйга багышланган сәхифәләр бар.

Укучыларыбыз игътибарына, 120 еллыгын билгеләп, шагыйрьнең берничә шигырен тәкъдим итәбез.

# Миргазиз Укмасый

## Нигә?

Нигә алды мине бер мәхәббәт, нигә миңа газап тарттыра?
Ул булмаса, мин бит җир астында, нигә шул гомерне
арттыра?

Аның өчен яшим, бу фәләкнең золмын йөклим, түзәм, аһ
димим;
Ник бу хәтле бәйле бу бер кеше, нигә башкаларны мин
сөймим?

Аның миңа күзе ник рәхмани[1], ник бу хәтле аны мин сөям,
Аның миңа сүзе—Коръән, һәрбер әмеренә баш иям.

Атам якын миңа, анам якын, ник аларга болай җан атмыйм?
Көннән-көнгә моны сөюем арта, башкаларны ник яратмыйм?

Эш башласам, аның бәхетенә дим—шул эшләрем даим уң
була;
Иртә торсам—уйда, кич—төшләрдә,
көндез күңелләрдә ул була.

Ни матурны күрсәм — аңар охшый,
кояш — аның көлгән чаклары;
Түгәрәк тулган айны күрсәм, дим: җанымның яңак аклары.

Ай үндүрте кичне тымык һәм тын, сокланам карап күлләрне;
Аның кара күзе шул күл кебек, керфекләре — аның гөлләре.

## Тагын берсе

Аерылыр: ат янына ат кушылса,
Аерылмас бәндәгә бер кат кушылса;
Йөзгә тигән кара китәр, әмма китмәс
Ак, мөкатдәс шаныңа бер тап кушылса.

## Милли тел

Милли тел—күрке халыкның, бетми милли телләләр,
Күп яшәргә дәртле милләт халкы милли тел биләр.

Хәтфәләнгәч, җир яшәргәч, бик матур сәхра, болын,
Әмма бакча тагы башка, күп сачәк вә гөлләләр.

Бик бизәнгән төрле төстә төрле кошлар күп, ләкин
Таң ярып сайраучы былбылга тиң килмиләр.

Яхшы милли телле—милләт, милли тел—милләт җаны,
Изге хисне, милли гадәтне дә милли тел сөйләр.

[1]Рәхмани—илаһи; гаҗәеп матур.



## Рәфкать Кәрами

# ИҖАТТАШЛАРЫМ

### Сара Садыйкова

Татарстан Язучылар берлегенең Матур әдәбиятны пропагандалау бюросында эшләгән чорда миңа әдәбият-сәнгать әһелләренең күбесе белән бәйләнешкә керергә туры килде. Чөнки очрашуларга әдипләрне генә түгел, композиторлар, музыкантлар, нәфис сүз осталары һәм җырчыларны да чакыра идек. Күпчелек очракта бу тамашачы теләген искә алып эшләнә иде. Шуна күрә, алар бик шатланып, "Казан язы", "Туган тел бәйрәме" кебек әдәби-музыкаль кичәләрдә чыгыш ясадылар.

Сара апа Садыйкованы да чакыргаладым. Олы яшьтә булуына карамастан, ул ризалаша иде.

Бервакыт мин аны кайсыдыр заводның тулай торагына дәштем. Очрашу кичке якта буласы иде. Сара апаны өе янында, урамда каршы алдым. Әкрен генә тукталышка барып, сигезенче трамвайга утырдык.

Барабыз. Сирәк-мирәк Сара апага күз салам. Аны танып белмәгән кеше (хәер, андыйлар Казанда булды микән?) уйлагандыр: менә бәләкәй генә бер карчык, башын иеп, уйланып бара. Кая бара микән ул? Кемгә бара икән ул? Мөгаен балалары янынадыр, аерым яшәүче оныкларын күреп кайтасы килгәндер. Кыскасы, күп гомер кичергән, шактый дөнья нужасы татыган бер әби трамвайга кушылып җай гына тирбәлеп бара. Үзем ана карыйм һәм ничектер үземә үк уңайсыз булып китте. Өлкән кешене борчыйсым калмаган икән. Атап чакырганнар иде шул.

Тукай исемендәге кинотеатр яныннан кузгалып киткән трамвай шактый озак барды. Кирәкле тукталышта төшеп, тулай торакка юнәлдек. Кызлар аны ишек төбендә үк каршы алдылар. "Сара апа, Сара апа", дип өтәләнеп торалар, куанычлары эчләренә сыймый. Тәрбияче бүлмәсендә алдан ук чәй дә хәстәрләгәннәр иде.

...Безне залга дәштеләр. Иң алдан, өстенә озын алсу ефәк күлмәк, аягына биек үкчәле туфли кигән, башына укалы калфагын кыңгыр салган Сара апа атлый. Ул залга килеп керү белән кызлар-егетләр дәррәү кул чаба башладылар. Сара апаның йөзе яктырып китте, аяк атлавы ныгыды, ул яшьләргә карый-карый, башын ия-ия аларны сәламләп, сәхнәгә таба бара. Бу инде бөтенләй икенче кеше иде. Йөгереп үк булмаса да, житез генә, минем сузылган кулыма таяныр-таянмас кына сәхнәгә менде ул. Ә инде бераздан, тәрбияче аның чыгышын игълан итеп, зал янә гөр килеп кул чаба башлагач, мин бөтенләй хәйран калдым: Сара апаны алыштырып куйдыларммыни! Чү, мин сәхнәдә кемне күрәм?! Бу сон трамвайда йокымсырап килгән, өлкән яшьтәге теге "әбиме", әллә дәрте ташып торган берәр яшь артисткамы?! Сәхнәдә—урта яшьләрдәге, сылу гәүдәле, чибәр артистка иде. Бу—актриса. Бөтен гомерен сәхнәдә үткәргән, сәхнәгә багышлаган, баш-аягы белән сәхнә тормышына чумган актриса иде: йөзеннән елмаю китми, көләч, нурлы. Сәхнә стихиясе аны үз агымына бөтереп алып кереп китте! Пианино артына утырып, нәзек көчле бармакларын житез хәрәкәтләндереп уйнаган көйгә, калфаклы башын кыңгыр салып, җырлап та җибәргәч, зал тын калды. Һәм кызыл почмакны

тутырып, аның моңлы, әле дә чисталыгын югалтмаган югары аһәнле тавышы яңгырады. Чыгышы тәмам булганчы ул үзенең актриса икәнен онытмады...

Чәйләр эчеп, тукталышка хәтле озата килгән кызлар белән саубуллашып, трамвайга утыргач, янә мин бәләкәй генә гәүдәле, мөлаем кыяфәтле, күнелебезгә якын татар әбисен күрдем. Ләкин аның рух күтәренкелеге сүрелмәгән, тамашачы белән очрашудан алган тәэссораты әле бетмәгән иде. Ул анын кулындагы роза чәчәкләренә баккан күзләрендә, алсуланып киткән илһамлы йөзендә чагыла иде...

*Артист һәм тамашачы.*
*Җырчы һәм тыңлаучы.*
*Композитор һәм халык.*

Алар арасында була торган фикер берлеге, үзара аңлашуның гаять әһәмиятле, кирәкле әйбер икәнен мин шунда аңладым. Менә ни өчен сәхнәдән иртә киткән артистлар тиз картаялар да, гомерләренең соңгы көннәренә кадәр сәхнәне ташламаганнары озак яшиләр, халкыннан аерылмаган иҗат әһелләре үзләренең иҗади эшчәнлекләрен ахыргача саклап калалар икән.

Сара Садыйкова йөзләгән җырлар авторы. Хәтта сүз авторларының да автордашы, дияр идем мин аны. Ул озак еллар Язучылар союзының партия оешмасында исәптә торды. Безнең һәр җыелышка килә, теге яки бу шагыйрьнең иҗатын тикшергәндә (ә андый тикшерүләр элек еш була иде) ул ялкынланып чыгыш ясый, дөрләп-кабынып бәхәсләшә, үзенең төпле кинәшләрен бирә; ул шигъриятне тирәнтен аңлый иде. Аның бөтен гомере иҗатка, фәкать иҗатка гына багышланган иде, дисәм, һич хата булмастыр. Әүвәл—җырчы, аннары—композитор. Хәер, болар гомере буена икесе бергә үрелеп барды шикелле. Моң чишмәсе соңгы көннәренә хәтле кайнап, ургып торды Сара апаның, ул чишмәдән без әле дә авыз итәбез.

Кайбер сәләтле генә кызларыбыз, матур-матур шигырьләр язып, бер-ике китап чыгаралар да, сүреләләр, пыскып кына яналар һәм... бөтенләй сүнәләр. Андыйлар композиторлар арасында да юк түгелдер. Әйе, кем әйтмешли, сәнгать—корбаннар таләп итә. Фәкать көн саен, сәгать саен барлык көчеңне туплап, төн йокыларыңны җәлләмичә, зур җаваплылык тоеп, бөтен күңелеңне ихластан иҗатка бирсәң генә чын мәгънәсендә иҗади әсәрләр туарга мөмкин, күрәсен. Әйе, бу шулай.

Әлбәттә, Сара Садыйкова кебек "асыл таш"лар (бу сүзне хәзер курыкмыйча әйтик) сирәк табыла.

Шулай да дөнья мәшәкатьләренә чумып, аның вак-төягенә бөтен игътибарыңны юнәлтеп, яки шан-дәрәҗә артыннан куып, төп эшенә айда—бер, кайда—бер генә кул тидерәсең икән—иҗат моны өнәми. Ул синең бөтен вөҗүдеңне биләп алырга тиеш. Ул—синең көндәлек эшең булырга тиеш. Фәкать шулай яшәсәң генә—син чын иҗатчы, әдәбият-сәнгать дигән олы җиһанның тугрылыклы колы. Тик, билгеле тәгълиматтагыча, сәнгать—сәнгать өчен түгел, сәнгать—халык өчен булырга, ул аңа хезмәт итәргә тиеш. Үзең үлгәч тә иҗатың кала бит, халыкка хезмәткә... Еллар узган саен синең кемлегең ачыла бара. Үзе исән чакта дан-шөһрәт казанганнарның да еллар үтү белән бәһасе сукыр бер тиен дә тормаска мөмкин, ә дөньялыкта эт типкесендә йөргән кайберәүләрнең иҗаты яңа бер күтәрелеш кичереп, тегеләрнекеннән бер баш өстен калкып, халык күңелен яулап алуы ихтимал.

Сара Садыйкова иҗаты һәм тормышы әле үзендә бик күп серләр саклыйдыр. Мин бары аның бер генә мизгелен, үзем күргән ягын, тамашачы алдында ничек әсәрләнеп китүен һәм аны ничек кабул итүләрен, аңа булган мөнәсәбәтне генә әйтеп бирергә тырыштым.

*2003 ел, 18 декабрь.*

## Рәшит Әхмәтҗан

Дөньяда осталар күп. Әйтик, тимерче гади генә кораллар белән дә карап туймаслык әйберләр ясый. Ул тимерне яндыра, бөгә, чүки, әллә нилэр

кыландыра—нәтиҗәдә көнкүрештә генә кулланыла торган әйбер дә күз явын алырлык булып килеп чыга.

Ә балта осталары?! Алар салган өйләргә кемнәр генә сокланмый икән?! Аларның тәрәзәләре дә ялт итеп тора, чөнки тәрәзә йөзлекләре һәр останың үзенә генә хас орнаментлар белән бизәлгән, кәрнизләре дә, гади такта гына булуына карамастан, тишек-сырлар белән чуарланган, кыегына карагач та, тел шартлатып, останы искә аласың.

Шундый ук мактау сүзләрен ташчыларга карата да әйтергә булыр иде. Кул җылысын салып кына түгел, күз нурларын да кушып төзелгән йортлар матур да, якты да, яшәү өчен унайлы да булалар. Гап-гади ак яки кызыл кирпечләрне аралаштырып, бизәкләп-матурлап тезергә бары чын осталар гына сәләтле. Мин андыйларны күп күрдем.

Дөресен әйтим, Рәшитнен Әлмәттә йортлар төзегәнен күрмәдем. Гәрчә ул Чупай тавыннан махсус комбайн ярдәмендә шакмаклап, зур кирпеч сыман итеп кисеп алган ташлардан йортлар салса да. Ләкин аны, яшьлегенә карамастан, бик оста ташчы булган диләр. Атаклы Саттаров бригадасы белән ул төзегән йортлар әле дә нефтьчеләр каласына ямь биреп торалар.

Шактый еллар әдәбият белән шөгыльләнү дәверендә мина бик күп иҗат әһелләренен "җимешләре" белән танышырга туры килде. Дөнья классикларынын, рус, казакъ, грузин, әрмән, үзбәк, таҗик, төркмән, украин һәм башка якын-тирә милләт вәкилләренен ин яхшы шигъри үрнәкләрен дә укып беләм, сокланам. Ә үзебезнен татар шигъриятенен, Кол Галидән башлап, мең еллык тарихы булган Олы шигъриятнен, нинди генә осталары юк! Һәм менә шушы тирән вә мул сулы Шигърият дәрьясында, батып калудан курыкмыйча, колач салып йөзгән Рәшит Әхмәтҗан да бар!

Ташчылар арасында оста булган кебек, ул шигърияттә дә оста иде. Ташлар тезгәндә ул кул җылысын салып тезсә, шигырь язганда җан җылысын салып, йөрәк җылысын биреп, анын һәр тибешен укучысына җиткерерлек итеп, аны битараф калдырмаслык итеп яза иде. Анын һәр юлы ихлас. Шуна күрә дә шигырьләрен укыганда эчке бер тетрәнү кичерәсен. Шигырьләре салкын кан белән түгел, бертуктамый тамырлардан агучы кайнар кан белән сугарылган.

Ни кызганыч, Рәшит иртә китте. Ләкин ул халкына җиткерәсе фикерләрен әйтеп китте.

Еллар узган саен Рәшит татар халкынын сөекле улына әверелә бара. Чөнки ул үзе дә шул халыкны сөйде, анын өчен тырышты, янды-көйде, анын киләчәге өчен борчылды, дөнья халыклары арасында үзенең лаеклы урынын киләчәктә дә югалтмаячагына өмет белән яшәде.

Әйе, дөньяда осталар күп. Фәкать үзе башкарган, гомерен багышлаган эшне яраткан, ана бөтен күнелен салган осталар гына биеклеккә ирешә ала. Балта остасымы ул, тимерчеме, ташчымы... Әгәр шунын өстенә ул әле кеше җанын, анын рухын тоеп иҗат итүче шагыйрь дә булса—андыйлар икеләтә бөек! Рәшит Әхмәтҗан шундыйларнын берсе иде.

*2003 ел, 19 ноябрь.*

## Батулла

Азмы-күпме спорт белән шөгыльләнүчеләр belә: спорт төрләре шактый күп, ләкин анын ин абруйлысы—җинел атлетика. Әйе, юкка гына җинел атлетиканы "спорт алиһәсе" дип йөртмиләр. Ләкин бу "алиһә" әле үзе бик күп тармакларга бүленә: сикерү, йөгерү, сөнге ыргыту, колга белән сикерү... Әмма шушы тармакларны бергә берләштергән төре—ирләр өчен ин абруйлысы—ун төрдә көрәш. Анын белән шөгыльләнүче кимендә ике метр биеклеккә, җиде метр озынлыкка сикерергә, кыскасы, ун төргә кергән һәр ярышта спорт мастеры нормасын үтәргә тиеш.

Әдәбият-сәнгать әһелләре арасында берничә жанрда иҗат итүче әдипләрне,

ике-өч төрле һөнәргә ия сәнгатькәрләрне очратабыз. Әйтик, Пушкин һәм Лермонтовны шагыйрь, прозаик, драматург буларак беләбез, безнең Тукаебыз да коеп куйган шагыйрь генә түгел, Такташ, Кутуйлар мисалы да бар. Атаклы артист Шукшин, мәсәлән, режиссер да, хикәяләр остасы да, Высоцкийны алсак, ул да актер, җырчы, шагыйрь...

Батулла төп һөнәре буенча артист, чөнки ул Мәскәүдә биш ел (1956-1961) укып, Щепкин исемендәге театр училищесын тәмамлый. Балалар өчен язылган "Исемем минем Дүрткүз" повесте белән, прозаик буларак, СССР Язучылар союзына алына. "Өчәү юлга чыктык" һәм башка пьесалары театрларда зур уңыш белән бара икән, димәк, ул талантлы драматург. Телевидениедә балаларга әкиятләр сөйләүче дә—Батулла "бабай".

Актерлар йортының шаулап-гөрләп торган чагын күпләр хәтерлидер. Әйе, анда Батулла оештырган ШТМ озак еллар уңыш казанды. Шаяннар һәм тапкырлар мәҗлесен үткәрергә ул Мәскәүдә СССР Язучылар союзының Югары әдәби курсларында укыган елларында да (1977-1979) кайтты. Ул заманда Актерлар йортының ишеге төбендә милиция хезмәткәрләре кизү тора иде, чөнки керергә теләүчеләр гаять күп, ә урыннар—санаулы.

Мәскәү дигәннән, без Югары әдәби курсларда өчәү укыдык: Батулла, Рөстәм Мингалим һәм мин. Бер ел укыгач, каникулга задание биреп җибәрделәр: һәркем үз республикасы яки өлкәсе турында доклад әзерләсен. Без бүлештек: Батулла әдәбият-сәнгать-мәдәният өлкәсен яктырта, Рөстәм—авыл хуҗалыгын, мин—промышленностьны. Безнең лекцияләр курсташларны таң калдырды, алар өчен һич көтелмәгән яңалык булды, бигрәк тә Батулланыкы. Чөнки, ул татар халкының бу өлкәдәге казанышларын шулкадәрле дә тирәнтен белеп, дәлилләп, тәфсилләп сөйләп бирде.

Уку чорында мин Батулланың тагын бер ягын ачтым: ул үтә дә милләтпәрвәр һәм шул ук вакытта башка халык вәкилләре белән тиз аралашучан кеше булып чыкты. Аның бүлмәсендә "Исконные земли татар" дигән зур карта эленеп торды. Кунак-төшем анардан өзелмәде. Бергә укыган әрмән, үзбәк, казакъ, кыргыз, монгол, латыш, молдован егетләрен аның бүлмәсендә еш күрергә туры килә иде. Ә бервакыт, Ленинградтан килгән шагыйрь Макаров татар халкы турында ямьсез сүз ычкындыргач, Батулла аның якасыннан эләктереп алды... Рөстәм белән без аларны көчкә генә аера алдык. Ул беркайчан да, беркемнән дә үз халкына карата яман сүз әйттермәде!

ВЛК да укыган елларда, аннан соң да Батулланың пьесалары уңыш белән бара. Ләкин аңа ул гына җитми, ул Казанның әле бер, әле икенче театрында режиссер буларак дистәләгән спектакльләр куя, артистлар әзерләүче уку йортларында—мөгаллим. Һәм... тагын прозага кереп китеп, "Сөембикә" романын яза.

Берзаман мин аның Финляндиядә, Америкада, Төркиядә лекцияләр укып йөрүен ишетәм.

Ә берничә елдан Батулла янә җәмәгатьчелекне шаккатырды: "Коръән" аятьләренең татарча мәгънәләрен халыкка ирештерде. Моңа тотынырга, беренчедән, бик зур батырлык, икенчедән, нык әзерлек—русча, төрекчә, татарча чыккан тәрҗемәләрне өйрәнү, чагыштырып карау кирәк иде. Һәм Батулла аны ихлас күңелдән, зур тырышлык куеп, башкарып чыккан, халык күңелен яуларлык иткән. Китапның икенче басмасы чыгу шул хакта сөйләүче бер дәлилдер.

Мәзәкләр, сатира-юморга корылган миниатюралар да даими языла килгән икән, алар да бергә тупланып, аерым җыентык булып чыккан.

Менә Батулла иҗаты хакында соңгы мәгълүматларым: Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында һәм К. Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театрында пьесалары уңыш белән бара, Казан татар дәүләт яшьләр театрында "Сак-Сок" әсәренең премьерасы булган.

Сүз башында юкка гына спортның иң авыр өлкәсе—ун төрдә көрәш турында

телгә алмадым. Әйе, анда һәр ун төрдә дә спорт мастеры нормативын үтәгән кеше генә тулаем унышка ирешә ала.

Батулла да кайсы өлкәгә, жанрга тотынмасын, оста икәнен күрсәтте һәм әле һаман да раслап килә. Каян ала икән ул шулхәтле җегәрне, каян таба икән ул һич саекмас илһам чишмәләрен?! Ә бит берничә ел элек Германиягә барып, дәвалап-ремонтлатып кайткан йөрәк белән йөри ул. Бүтән берәү булса, һәр адымын санап кына атлар иде. Ә ул гел хәрәкәттә...

Күрәсең, нәсел-нәсәбе барып тоташкан изге Зәй туфрагыннан аладыр ул көч-куәтне, күрәсең, газиз татар халкының бетмәс-төкәнмәс авыз иҗаты ана илһам чыганагы булып хезмәт итәдер.

Халкыбызга кирәкле мондый шәхесләрнең гомере озын, иҗатлары дәвамлы булып, балаларны да, олыларны да яңадан-яңа әсәрләр белән куандырып торсыннар иде. Амин берүк.

*7.01.2004 ел.*

## Илһам Шакиров

Рязань өлкәсендә Константиновка дигән авыл бар. Ул табигатьнең гаять матур җирендә урнашкан: биек яр астында җәелеп зәңгәр сулы Ока елгасы ага, еракта яшел болыннар күзне иркәли, тагын да арырак—куе урманнар һәм мәһабәт таулар. Ирексездән: "бу яклардан да шагыйрь чыкмаса, тагын каян чыгар?!"— дип уйлыйсың. Һәм, гасырга бер генә түгел, ә һәр елны бер шагыйрь туар кебек. Ләкин Сергей Есениннан башка бу якларда туып-үскән шагыйрьне мин белмим. Бер булган, берәгәйле булган. Чөнки, Сергей Есенин исемен телгә алу белән Константиновка авылы искә төшә.

Сарман якларында Яңа Буләк дигән авыл бар. Аның да табигате искиткеч. Һәм менә шушы табигать ничәмә-ничә гасыр җыйган моңны сина, кадерле якташым, сина бүләк иткән! Әгәр дә тагын йөз, ике йөз ел эчендә дә бу авылдан бер генә әдәбият-сәнгать әһеле чыкмаса да, халык рәнҗемәс. Чөнки—син бар! Яңа Буләк авылы дигәч тә күз алдына син килеп басасың. Авылың, аның шаулы урманы, чылтыр чишмәләре, чәчәкле аланнары сиңа моңын да, сагышын да, шатлыгын да җәлләмичә, кочагы белән биргән. Ә син аларны менә кырык ел инде, үзеннең олы, юмарт йөрәгең аша үткәреп, яңадан халыкка өләшәсең. Ләкин инде Яңа Буләк, Сарман халкына гына түгел, ә бөтен Татарстанга, татар халкы яшәгән барча төбәкләргә... Мен яшә! Илһам чишмән саекмасын, Илһам туган!

*15.02.1995*
*Казан*

# БЕР ӘСӘРНЕҢ БАСЫЛУ ТАРИХЫ

"Сызгыра торган уклар" романы "Казан утлары" журналы редакциясендә ике елдан артык басылмыйча ятты. Аптырагач, Нурихан Язучылар берлеге идарәсе исеменә әсәрне анализлауны һәм кимчелекләрне күрсәтүне сорап гариза язды. Ул вакытта рәис язучы Гариф абый Ахунов иде. Тиз арада, төгәлрәк әйткәндә, 1980 елның 17 июлендә идарә утырышы җыелды. Анда 19 язучы катнашты. КПСС өлкә комитетыннан вәкил булып Ринат Закиров килгән иде. Мин бер почмакка кереп утырдым, сүз әйтүче булмады һәм бөтен сөйләгән сүзләрне язып барырга тырыштым. (Идарә утырышының беркетмәсе бәлки Язучылар берлеге архивында сакланадыр да әле.)

Идарә рәисенең урынбасары, тәнкыйтьче Фәрваз Миннуллин Нурихан Фәттахның гаризасын кычкырып укыды, ни өчен җыелганнарын әйтте һәм бик игътибар белән бер-берсен тыңларга, эшлекле булырга чакырды. Сүзнең татар әдәбияты өчен гаять мөһим роман турында барачагын искәртте. Әйтергә кирәк, әллә сүз Нурихан әсәре турында барганга, әллә шундый җаваплы җыелышта беренче тапкыр утырганга, мине бөтен язучыларның да бик киеренке хәлдә утырулары шаккаттырды. Нурихан үзе дә хөкемгә тартылган кешене хәтерләтә иде.

Сүзне "Казан утлары" журналының ул вакыттагы баш редакторы Зәки Нури башлады:

—Бүгенге көндә,—диде ул,—дөнья тынычсыз. Кытай чикләрендә коралы бәрелешләр бара. Шулай булгач, әгәр без бу әсәрне журналда чыгарсак, кемгәдер "авыз чайкарга" урын калачак. Кытай яңа территорияләр яулап алырга тырыша. Безнең бурыч—бүгенге көн әсәрләренә күбрәк игътибар итү, укучыны патриотик, коммунистик рухта тәрбияләү. Милли әсәрләр белән дөньяны болгату партия таләп иткән кагыйдәләргә туры килми. Күчмә халыклар, гуннар һәм башка шундый нәрсәләр турында язу, мөгез чыгару, тарихны шуннан башларга тырышу үзе үк дөрес политика булмаячак. Әлбәттә, әсәр буларак роман укыла. Шулай да, буташтырмыйк укучыны да, үзебезне дә! Аннан соң, ни өчен әле нәкъ менә "Казан утлары" журналында бастырасы килә авторның бу әсәрен? Безнең журналны бит чит илләрдә дә укыйлар. Бик теләгәч, китап итеп чыгарсын, йә булмаса, икенче "скромныйрак" журналда бастырсын. Главлит хәл итте бит инде, рәсми рәвештә әйтте, "басмаска", диде. Менә аларның хакы бар. Бүгенге биеклектән киләчәккә күз салуы соң бу әсәр! Максим Горький әйткәнгә туры килми бит. Билгеле, әсәрне укучыга тәкъдим итәргә дә булыр иде, ләкин икенче китабы язып бетерелмәгән бит әле. Минем тәкъдимем шундый, башта сүзгә-сүз тәрҗемә (подстрочник) ясатып, урыс укучысына укытырга кирәк, алар ни әйтерләр...

Зәки Нури сүзен әйтеп тә бетермәде, Язучылар берлеге партия оешмасы секретаре Туфан Миннуллин чәчрәп чыкты. Ул шундый ярсулы, киеренке халәттә иде, мин эчемнән генә низаг чыга күрмәсен дип куркып та куйдым.

—Ни өчен урыс укучысына, Зәки абый?! Гумилевны басканнар, ни өчен безгә язарга да, бастырырга да ярамый? Автор эзләнгән, язган, хәзер әсәрен ике-өч ел бастыра алмыйча йөри. Ул ничек иҗат итсен алга таба? Кайда күренгән хәл бу?!

Гариф Ахунов аны тынычландырырга ашыкты:

—Кызма әле, Туфан! Тәртип кирәк, сиңа да сүз бирелер.

—Кызмыйча, безнең өчен тарихны урыс та, чуваш та эшләп бирмәс. Эшләгән кешенең кулына сугарга ярамый!

Сүзгә китап нәшриятының ул чактагы баш редакторы Шәүкәт Галиев кушылды:

—Язучылар һаман зарланалар. Нишләптер аларның әсәрләрен башта журналда чыгарасылары килә, аннан соң гына аерым китап булып чыксын, диләр.

Бу сүзләрдән соң бераз шау-шу, көлешү кебек авазлар, "белмәгән кеше кебек

сөйләнмә инде, язучының карап торганы шул гонорар бит", кебек сүзләр ишетелде.

Гариф Ахунов янадан шау-шуны туктатып, сүзне тәртип белән әсәр буенча алып баруны сорады.

Сүз "Казан утлары" журналының редколлегия әгъзасы Сибгат Хәкимгә бирелде. Ул, гадәтенчә, акрын гына сөйли башлады:

–Мин гуннар белгече түгел, әмма бәхеткә каршы Гумилевны ике-өч ел элек укыган идем. "Гунны в Китае" дип атала. Зәки чыгышында "Кытай ни әйтер, басарга ярамый, политик хата булыр" дигәнрәк фикер ишетелде. Ул чор, ул территорияләр хакында бүтән тарихчыга язарга ярый, Гумилевка ярый, нишләптер безгә ярамый. Бу гаҗәбрәк. Мәсәлән, миндә андый шик юк. Әсәр буларак, бүгенге көн әйберләре генә кирәк дигән фикер белән шулай ук килешә алмыйм. Әдәби әсәр буларак карасак, (С. Хәким Г. Ахуновка карап елмаеп куйды) әсәрдән аерылып булмый. Әсәр көчле. Әле киләчәктә мондый әсәре булу белән татар әдәбияты горурланачак. Минем тәкъдимем–әсәрне журналда бастырырга кирәк. Киләчәктә китап итеп тә чыгарырга. Төзәтәсе төше бармы? Алай күзгә төртелә торган булгач "Кытай" дигән фразаларны алып ташлап та буладыр, бәлки.

Г. Ахунов "тынычландынмы, Туфан, әйдә сөйлә", дип сүзне Туфан Миннуллинга бирде.

–Зәки абыйның "Казан утлары"н чит илләрдә дә укыйлар, китап булса ярый, яки башка берәр журналда бастырсын, дигән сүзе белән дә килешәсе килми. Совет матбугатында чыга икән, барыбер түгелмени. Мин Сибгат абый белән килешәм. Ничек инде, анысы, ярый, монысы ярамый. Кирәгеннән артык сак кылану, куркаклык галәмәте түгел микән? Бу сәнгать әсәре. Подстрочник ясатып Мәскәүдән фикер көтеп яту үзе җинаять! Без югары белемле кешеләр, галимнәребез, фән докторлары җитәрлек. Әгәр без теләсә каян фикер җыеп йөрсәк мескен булыр идек. Бездән көләчәкләр генә... Мин әсәрнең тикшерелүгә куелачагын белгәч хәтта этлек эзләп тә укыдым, ләкин миндә беркинди шик уянмады. Фикер ачык, әсәр укыла. Әсәрне типкәләп йөртү, авторны кыерсыту бик кызганыч. Урта Үзән белән Урта Азия терминнарын кемдер бутый икән, әлифба укысын. 2200 еллык тарихны яза алмыйбыз икән, якынрак тарихны бөтенләй яза алмаячакбыз. Романның ахырын бәлки икенче китаптан башларгадыр? Монысы автор эше. Мин кабатлап, бөтен җаваплылык белән әйтәм: әсәр партийный, әсәр матбугатта урын табарга тиеш, романны бастырырга кирәк.

Җыелышны алып баручы:

–Мөхәммәт, син ни әйтерсең?

Мөхәммәт Мәһдиев:

–Басмый калырга нигез булырлык бер сәбәп тә күрмим.

Илдар Юзеев:

–Нуриханның "Әтил суы ака торур" романы әдәбиятыбызда бер зур вакыйга булса, монысы тагын да зуррак батырлык дип исәплим. Бу әсәр татар һәм төрки тарихы гына түгел, гомумән, әдәбият өчен шатлыклы вакыйга. Әсәрне, һичшиксез, укучыга тәкъдим итәргә кирәк, бастырырга кирәк.

Татарстан китап нәшрияты редакторы Рәис Даутов:

–Роман калын. 455 бит. Мин бөтен эшне ташлап бер тында укып чыктым. Укучыны тотып тора торган, укыла торган әсәр. Әгәр әсәрнең төп җирлеге дөрес икән, аны татар язамы, урыс язучысы язамы–бу язучының җитлеккәнлеге турында сөйли, батырлыгын күрсәтә. Сюжет корып тасвирланган икән, әсәр укыла икән, аның басылырга хакы бар дигән сүз. Матур әдәбиятка шарт куелмый.

Шагыйрь Равил Фәйзуллин:

–Автор материалны ничә еллар буена җентекләп өйрәнгән, язган, көч түккән. Нурихан абыйның үзен аямый, җиренә җиткереп эшли торган кеше икәнен беләбез, ул инде моны күптән исбат итте. Шулай булгач, аның әсәре квалификацияле бәя дә алырга тиеш. Әсәрнең типкәләнеп йөрүе аяныч. Әдәби әсәр ике күзлектән карала. Берсе–халыкка бу әсәр ни дәрәҗәдә кирәк. Икенчесе–эстетик як, укучыны эстетик тәрбияләү. Минемчә "Сызгыра торган уклар" романы ике таләпкә дә туры килә.

Мин ул чорны махсус өйрәнгән кеше түгел, ул чорны белмим. Тарихчылар ачыклаган икән, Нурихан абый аны җентәкләп өйрәнгән икән, бернинди шүрләр урын юк. Мин әсәрне журнал вариантында да, китап итеп тә чыгарырга кирәк дип саныйм.

Рәис:

—Галимнәр ни әйтер?

"Казан утлары"ның редколлегия әгъзасы, филология фәннәре докторы Нил Юзиев:

—Нуриханның бу яңа романын мин ике ел элек үк укыган идем инде. Романны мин ике көндә укып чыктым, яраттым, шундук фикеремне әйттем, фикеремнән чигенгәнем юк. Язучылар бүгенге тормыш белән бергә үткәнне дә яктырталар. Хәзер Урта Азия халкында тарих белән кызыксыну бик көчле. Һәм бу дөрес тә. Марксистик-ленинчыл философия моңа киң мөмкинчелек бирә. Тарих галимнәре дә еракка керә баралар, телчеләр дә моны эшли. Дөрес, фәндә схоластик караш бар, кайберәүләр үткәндәге бер тарихчыга нигезләнеп кенә эшлиләр. Бу турыда бөтен ил галимнәре яза. Безнең очракта мин язучының, Нуриханның үзен зур галим дип саныйм, чөнки минем белүемчә, Нурихан күп еллар дәвамында тарих, этнография, тел, археология, фольклор һ. б. өлкәләрдәге әсәргә кагылышлы фактларны өйрәнде, махсус командировка белән Монголиягә барып кайтты. Совет әдәбияты һәм тарихчылар өчен бу әсәр зур яңалык дип уйлыйм. Инде килеп, башта икенче китапны бетерсен, карарбыз, беренчесен басаргамы-юкмы дигән фикер белән дә килешеп булмый. Шолоховның "Тихий Дон"ы дүрт китап, А. Толстойныкы шулай ук 4 китаптан тора. Аларга беркем дә: бөтенесен язып бетер, аннан карарбыз, димәгәндер бит. Кави Нәҗми "Язгы җилләр"нең бер өлешен яза, икенчесен язарга өлгерми. Сюжеты, эчтәлеге һәм теле ягыннан әсәр бөтен таләпләргә җавап бирә икән, мин әсәрнең "Казан утлары" журналында басылырга хакы бар дип саныйм.

Шәүкәт Галиев:

—Татар әдәбиятын мин җитлеккән әдәбият дип уйлыйм. Җитлеккән әдәбиятта бер жанр да кимсетелеп калырга тиеш түгел. "Бу бүгенге көн турында түгел, шуна басарга кирәкми",—дигән сүзне мин дә дөрес түгел дип саныйм. Роман әдәби әсәр буларак камил әсәр, бу бәхәссез. Ә инде Кытайга мөнәсәбәте нәкъ Нуриханча (кытайча астыртын дисәк тә, ялгыш булмас). Әсәрне бастырмыйча йомып калу дөрес булмас.

"Казан утлары"ның редколлегия әгъзасы Атилла Расих:

—Нигездә, бу зур романның беренче өлеше басылырга тиеш дип табам. Ике китап булачак, дигәч, кайбер фикерләрем дә бар: тарихи әсәр язу—тарихны ясаучылар турында язу ул дип уйлыйм. Ә тарих ясаучы—ул гади халык: игенче, терлекче һ.б. Нурихан ханнар белән мавыга. Гади хезмәт халкы турында язсын иде ул. Мин хөрмәтле редакторларыбызның борчылуын бик аңлыйм. Албуга җиңелә. Бәлки ул гади халык арасына килеп керер? Нишләптер, ханнар "каралар" белән буталып йөриләр. Алар бит аерым каста кешеләре... Икенче китапта менә мин әйткәннәрне дә истә тотып романны төзәткәндә әсәрнең укучыга барып җитәргә хакы бар дип уйлыйм.

Сибгат Хәким:

—Расих, аучылар, терлекчеләр, сугышчылар—болар барысы да гади халык бит инде.

Мөсәгыйт Хәбибуллин:

—Мин романны укып чыгалмадым әле. Ләкин шуны әйтәсе килә, ханнарсыз гына тарихи роман буламыни? "Әтил суы ака торур"да балыкчысын да, игенчесен дә чагылдырылган иде бит инде. Нурихан тарихи чынлыкка омтыла. Кайчандыр Дюма: "Мин үземнең Парижымны тудырдым",—дип әйткән. Лев Толстойның да үз Наполеоны бар. Төрки халык—карт милләт. Телебез сакланган. Мине иң борчыган нәрсә: башлангыч чорында ук эчәләр. Эчмәсеннәр. Татар электән үк эчкән, эчеп башлаган димәсеннәр.

Роберт Миңнуллин:

—Нурихан абый ничәмә-ничә еллар казынып, алны-ялны белмичә язган романын

сүтеп ясый алмый. Һәм моның кирәге дә юк. Ул әле түзгән, көткән, әрсезләнмәгән. Башка автор шундый роман язса ничәнче көн чыгасын да белеп торыр иде. Инде килеп идарә тикшерүенә куелган икән, бөтенебез дә әсәрне бастыру яклы икән, сузмыйча, авторның кулына сукмыйча, иҗат дәртен сүндермичә тизрәк бастырырга, авторны котларга һәм ана киләчәктә иҗади уңыш теләргә кирәк, дип уйлыйм.

Марсель Галиев:

–Роман турында кызыклы сүзләр әйтелде. Минем дә бер фикерем, тәкъдимем дисәк тә ярыйдыр, бар–бәлки аны "тарихи роман" дип түгел, "роман" дип кенә куяргадыр. Ул вакыттагы кеше ничек йөргән, нәрсә ашаган, ничек киенгән–бәлки аларның кайберләре Нурихан абый фантазияселәр, ләкин безгә бит аның әле сәнгать ягы кыйммәт. Татар әдәбиятын зур әдәбият диябез икән, нишләп әле бездә тарихи жанр үги бала хәлендә булырга тиеш?! Җирдә бер әйбер дә юктан бар булмый. Әсәр тәрбияне төрлечә бирә, роман да төрлечә тәрбияли. Әсәрнең бүгенге укучы өчен файдасы зур булыр дип уйлыйм. Романны һичшиксез басарга кирәк.

Әхсән Баянов:

–Зәкигә нәрсә булса да өстәү җайсыз. Жанр мәсьәләсенә килгәндә, әдәби ягыннан әсәр бәхәссез. Образлар кызыклы түгел, дигән фикер булмады. Тарихи яктан бәя бирергә безнең беребезнең дә компетенция җитәрлек түгел. "Хун" дип аталган икән, ни өчен Нурихан "сөн" дип бирә икән? Фәнни ягын исбат итәсе бар. Әллә тарихка дәгъвасыз әдәби әсәр булып чыгамы?

"Казан утлары" журналының җаваплы секретаре Кояш Тимбикова:

–Әсәрнең ничек язылуына шик юк. Әсәр әйбәт. Романны журналда бастырасым килә минем дә. Бәлки эшне Шакиржановага (ул чактагы Главлит вәкиле, цензор. Р.Ф.) җиткерергә тиеш булмаганбыздыр. Ләкин бүгенге көндә һәрбер язган әсәрнең энә күзеннән үткәнен барыгыз да яхшы беләсез. Сибгат абый, сезгә монда сөйләү җиңел. Сезнең обкомга барып җавап бирәсегез юк, анда Зәки абый белән мин барып басасы!

Фәрваз Миңнуллин:

–Мин әсәрне ни өчен укыганымны белеп, ягъни идарә утырышында тикшереләчәген белеп укыдым. Игътибар белән укыдым. Әсәр сәнгатьчә эшләнеше, эчтәлеге, идеясе ягыннан миңа ошады. Без, идарә әгъзалары, бу әсәрнең басылу-басылмавына битараф кала алмыйбыз."Обком хәл итсен" булгач, бу идарә әгъзалары утырышы нигә кирәк соң? Роман дөнья күрсен дисәк без аны чыгарырга булышырга, ярдәм итәргә тиешбез.

Соңыннан авторга–Нурихан Фәттахка сүз бирелде:

–Миңа бүген сезнең алда бик уңайсыз, — дип башлады ул сүзен.–Сезне төп эшегездән аерып, күп эш йөкләдем. Хөрмәтле иптәшләр, каләмдәшләр! Сез әдәбият күзләгеннән чыгып, чын күңелдән сөйләдегез. Шуңа ихлас күңелемнән барыгызга да зур рәхмәт. Безнең каршылык нигә чыга соң? Бу безнең белем, культура дәрәҗәсе түбәнлеген күрсәтә түгелме? Әлмәт театры Шекспирны куя. Грек, Европа тарихы булса ярый, аларга Сталин премиясе, Дәүләт бүләге бирәләр. Үзебезгә, татарга килеп җиттекме–башта филиалда тикшерсеннәр, фәлән-төгән җирдән рецензия булсын, обком ни әйтер, h.б. Бүтәннәр язса Коръән итеп укыйбыз. Нурихан бөтенләй өйрәнмичә барысын шыттырып язды микәнни? 30 ел бит инде өйрәнә башлауга да! Атилла абый ат караучылар турында язарга куша. Минем әсәрдә ханнар гына түгел. Аларның титуллары гына аксөяк. Алар шул ук "каралар" белән көтү куалар, яу чапканда сугышның башында баралар. Гафу итегез, ул чакта обком да юк, цензура да, телефон да. Бюрократия юк дәрәҗәсендә. Ни хәл итим... Мин кулдан килгәнчә төрле-төрле катламны искә алдым. Редколлегия белән безнең арада каршылык булмады. Редактор әйткән бөтен тәкъдимнәргә колак салдым кебек. "Тарихи роман" да, хәтта "роман" да димәсеннәр, әгәр "басабыз" диләр икән, мин риза.

"Казан утлары" журналының баш редакторы Зәки Нури:

–Әсәр инде җыелган. Ни өчен тегe редколлегия әгъзасы укымаган, монсы укымаган–бу турыда бәхәс булмады. Бөтенесе чират торып, бер-берсен ашыктырып укыдылар. Редакциядә һаман шул турыда сөйләделәр. Сүз әсәрнең җирлеге турында

бара. Полосада конъюнктурный төзәтү булырга мөмкин. Тәмамлану өлешеннән баш тартырга да була.

Гариф Ахунов (сәгатенә карап):

–Утырыш инде ике сәгать ярым бара. Иптәшләр бик җентәкләп укыганнар, бик җентекләп тикшердек, дип уйлыйм. Әдәби әсәр буларак, сәнгатьчә югары дәрәҗәдә язылган. Минем журналга үпкәм дә бар: шундый әсәр килгән икән, ни өчен аны ике ел яткырырга кирәк иде соң? Редколлегия җыеп кұмәкләшеп хәл итеп булмый идемени? Ни генә булмасын, без, идарә әгъзалары унай хәл иттек, дип уйлыйм. Барыгызга да рәхмәтемне белдерәм, ә сине Нурихан дус, "җину"ен белән тәбрик итәм, яна романнар белән укучыларынны һәм каләмдәшләренне әле күп тапкырлар сөендерерсен дигән теләктә калам. Беркетмә язылды, ул тиешле урынга тапшырылыр. Шушының белән идарә утырышын ябык дип белдерәм.

Шуннан бераз ыгы-зыгы, котлау, көлешүләр дә булды. Бу бөтен бер диссертация яклау кебегрәк тәэсир калдырды миндә. Бүгенге көн күзләгеннән караганда, ул вакыттагы язучыларның бер-берсен яклавы, бердәмлеге таң калдыра.

Янадан бер ел да сигез айдан, ягъни 1982 елның март, апрель һәм май саннарында, ниһаять, Нурихан Фәттахның сүз башы белән роман " Казан утлары" журналында дөнья күрде. Беренче китап 1984 елда, икенчесе 1988 елда. Аннан соң ул Татарстан китап нәшриятында аерым китап булып басылып чыкты.

Мина калса, иң кызыгы шул, шушы тикшерүләр, борчулардан соң ундүрт ел узгач, "Сызгыра торган уклар" романын мактап берсеннән-берсе матур мәкаләләр басыла башлады. Бу мәкаләләр бөтенесе бер үк вакытта, апрель аенда булып "Тукай премиясенә кандидатлар" рубрикасында басылдылар. Менә алар:

*Рафак Тимергалин. "Ватаным Татарстан", 8 апрель 1994 ел. Нил Юзиев. "Татарстан хәбәрләре", 17 апрель 1994 ел. Фоат Галимуллин. "Шәһри Казан", 20 апрель 1994 ел. Флүс Латыйфи. "Сабантуй", 20 апрель 1994 ел. Азат Әхмәдуллин. "Мәгърифәт", 20 апрель 1994 ел.*

Н. Фәттах 1994 елда "Сызгыра торган уклар" романы өчен Республиканың иң зур бүләге–Тукай премиясе лауреаты дигән исемгә лаек дип табылды. Соңгы елларда бу комиссиянен әгъзасы да булды.

**Руфина ФӘТТАХОВА,**
*Н. Фәттахның хатыны,*
*Республиканың атказанган врачы.*

*2004 ел.*

Гэп Фэн

# Адлер Тимергалин

## МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***ЖӘХШЕЛХӘЙ*** *г.* — Тере ишәк (тиргәнү сүзе). Ләкин шулай да гарәпләрдә ишәк кушаматы аңгыралык түгел, бәлки чыдамлык һәи түземлек синонимы булган (мәс., аруталуны белмәс Мәрван хәлифәне (744—750 елларда хәлифәлек иткән) *Мәрван-ишәк* дип атаганнар).

***ЖӘҺӘННӘМ*** — Тәмуг. *Җәһәннәм* сүзе борынгы гыйбри (еврей) телендәге *гехинном* сүзеннән. Русча: *геенна*. Гехинном дип исә Иерусалим янында төрле шакшылар түгелә торган җирне атаганнар. Р.Әхмәтьянов бу урын турында: "Палестинада үзәнең корылыгы һәм эсселеге белән атаклы булган бер үзән," — дип яза, ә *гә-й-һәннам* — һәннам балалары җире. Анда *Молох* дигән пот торган, балаларны шуңа корбан итеп китерә торган булганнар. Коръән буенча, җәһәннәм — Иблискә ияргәннәрнең киләчәктә газаплану урыны (15:43). Фарси телендә *дузәх* — тәмуг, җәһәннәм.

Җәһәннәмнең җиде каты булып, берсе берсеннән җиде мең еллык түбәндәр, берсе берсеннән җитмеш өлеш кызудыр, болар:

1. Һәвийәһ (Һавия) — Мөнафикъларга һәм кяфир булганнар өчен. Фиргавен, Карун, Һамман һәм мөселманнарның, шулай ук Гайсә галәйһиссәламнең дошманнары шушы һавиягә куылачак. Мәүлана Мөхәммәд Али буенча мәгънәсе — "төпсезлек, төпсез тирәнлек." "Тәфсир Ногмани"да "Ул һавийә кыздырылган утдыр" дип аңлатылган (100:11).

2. Җәһим — Мәҗүсиләргә. Мәгънәсе — "җәһәннәм уты". "Җахим" язылышы да очрый. "Тәфсир Ногмани"да (57:19) "аятьләребезне ялганга тотучы кяфирләр җәһим тәмугында янучылардыр" дип күрсәтелә.

3. Сәкарь — кеше ашаучылар һәм диннән язганнар, ягъни Исламнан башка дингә күчкәннәр өчен. "Яндыручы ут" мәгънәсендә.

4. Ләза (Ләзыя) — Иблис һәм аның якыннары өчен. Башкача *ләзан* дип тә языла, мәгънәсе — "Ялкын".

5. Хотәмәһ (Хитмә) — Яһүдиләр өчен. Мәгънәсе — "ватык кисәкләр".

6. Сәгыйр — нәсарилар өчен. Мәгънәсе — "ут", "учак".

7. Җәһәннәм — зур гөнаһлы булып та тәүбә кылмыйча үлгән мөселманнар өчен.

Риваятьләрдә җәһәннәм бүрәнкә сыман кратер рәвешендә сурәтләнеп, шундагы җиде концентрик түгәрәктә җәһәннәмнең төрле катлары урнашкан дип сөйләнә. Коръәннән соңгы бер риваятьтә җәһәннәмдә черек сулы, кайнап торган буалар, төпсез коелар барлыгы әйтелгән.

Җәһәннәмнең җиде ишеге бар (15:44). Җәһәннәмгә бидгатьче кешеләр һәм бидгатьче җеннәр кертеләчәк (11:119). Берәүләре анда мәңге газапланачак, икенчеләре вакытлыча гына булачаклар (23:103; 11:107).

Җәһәннәмдә тормыш юк, чөнки тормыш ул тәкъва кешеләр өчен генә билгеләнгән, ләкин анда үлем дә юк, чөнки үлем — ул тулы тынлык һәм хәрәкәтсезлек дигән сүз. Бу турыда "Тәфсир Ногмани"да: "Соңра ул җәһәннәмдә үлмәс, үлсә газаптан котылыр иде, һәм файда күрә торган тере булу белән дә тере булмас" (87:13). "Та ha" сүрәсенең (20) 74 нче аятендә дә шул ук фикергә тап булабыз: "Ул анда үлмәс һәм тереклеге дә булмас."

"Коръән"дә: "Аллаh дошманнары җәһәннәмгә кертелсәләр, әүвәле кергәннәре, туктап, соңыннан кергәннәрне көтәрләр, бер-берсен күрсеннәр өчен", — диелгән (41:20).

Гөнаһкярларны җәһәннәмдә көткән иң каты газап — ут газабы. Тиреләре янып беткәч, аларга яңа тире үстерелә һәм алар җәһәннәм утын кабат татыйлар (4:56). Үләре богауланган хәлдә, ә киемнәре утта кызган сагыздан булыр (14:49,50). Кяфирләргә эчәргә кап-кайнар су, йә булмаса үлекле су бирелер (47:15; 14:16,17). Әхмәтһади Максуди язуынча,

*Дәвамы. Башы журналыбызның алдагы саннарында.*

"Дөньяда вакытта саваплы эшләрне дә күп кылган азрак гөнаһлы бәндәләр тәмугта җиңел газаплар илә генә газап кылыначаклардыр".

Җәһәннәмнең мәңгелек түгеллеге "Терлек" сүрәсенең 128 нче аятеннән аңлашыла.

Җәһәннәмдә *зәкъкум* агачы үсә, аның җимешләре – шайтан башларыдыр.

Кайбер чыганакларда җәһәннәмнең 8 синонимы телгә алына: 1) Нар; 2) Ниран; 3) Сәгыйр; 4) Ләһәб; 5) Җәһим; 6) Сәкарь; 7) Әл-хитмә; 8) Һавия, ләкин болар җәһәннәмнең югарыда телгә алынган җиде катына туры киләләр диярга мөмкин.

Җиде тәмугның җиде гөмбәзе булып, анда зобанилар хезмәт итә. Җәһәннәмдә гөнаһкярларны астына ут ягылган гаять зур казанга салып газаплыйлар.

Түбәннән-түбән мәгънәсендәге *әсфәлес сафилин* сүзе җәһәннәмгә карата әйтелә. Җәһәннәмдә газап кылыначак бәндәләр турында *җәһәннәм кисәве* диләр. Җәһәннәм турында *гасыйлар мәүкыйгы* – гөнаһлылар урыны дигән сүз бар.

Башка халыкларда җәһәннәм мәгънәсенә якын төшенчәләр: *Ад* (христианнарда), *Тартар* (грекларда), *Нарака* (һиндуистларда, буддиларда), *Диюй* (кытайларда).

Йәһүди вәгазьчеләр (магидлар) җәһәннәмнең җиде бүлегендә җиде төрле гөнаһка җиде төрле ут күздә тотылган дип өйрәткәннәр. Алар җәһәннәмдә 6000 бүлмә бар, һәр бүлмәдә 6000 тәрәзә, ә һәр тәрәзә төбендә 6000 чүмеч тора, аларга гөнаһкярларга эчерергә әче ут салынган дип сөйләгәннәр. Гөнаһлы бәндәләрне алмаш-тилмәш йә утлы табада, йә ут диңгезендә тотып җәзалыйлар, йәисә кар һәм боз тавында туңдыралар имеш.

Православие руханилары да гөнаһлы кешеләрне утлы җәһәннәм һәм күзгә төртсәң күренмәслек караңгылык белән куркытканнар.

Билгеле булганча, Данте (1265 – 1321) "Илаһи комедия"сендә "Җәһәннәм" бүлегенең 58 нче җырында "тугызынчы чокыр" эченә Мөхәммәд Пәйгамбәрне һәм башы җәрәхәтләнгән хәзрәти Галине дә урнаштырган. Гомумән әйткәндә, Данте җәһәннәм тасвирын Шәрык суфиларыннан алган дип уйларга нигез бар. Мәс., Е.Э.Бертельс XII гасыр фарсы шагыйре Санаиның "Сәйрәл-гыйбад илә-л-мәгад" – "Алла колларының кайтыр җиргә сәяхәте" белән охшашлыкка игътибар иткән, итальян галиме Энрико Черулли тәмуг һәм оҗмах турында сөйләнгән гарәпчә "Китабет-тәдриҗ"нең XIII гасырда ук латинчага тәрҗемә ителгән булуын әйтә, ягъни Данте җәһәннәмне тасвир иткәндә турыдан-туры Шәрык әдәбиятына мөрәҗәгать иткән булырга тиеш. Тагы шунысы кызыклы, Данте белән бер үк гасырда яшәгән төрки шагыйрь Хөсәм Кятиб үзенең бераз соңрак иҗат иткән "Җөмҗөмә солтан" әсәрендә тәмугны сурәтләгән вакытта Данте кулланган буяулар белән эш итә, чөнки бу ике бөек шагыйрь икесе дә бер үк шәркый чыганакларга таянганнар.

*/ / Җәһәннәм уты тоту. Җәһәннәмгә сөрелү.*

Тагын кара: ***ТӘМУГ.***

***ҖЕН, ҖЕННӘР*** – Гарәпчә шул ук мәгънәдәге *җин* сүзеннән. Коръәннән күренгәнчә, җеннәр Алла тарафыннан Адәмгә тикле меңнәрчә еллар элек "кояш утыннан яратылганнар". "Хиҗер" сүрәсенең (15) 27 нче аятендә: "Вә Адәмнән элек җенне ялкынлы уттан хәлык кылдык", – диелә ("Коръән тәфсире" буенча). В.Порохова җеннәр кайнар сәмум җиленнән яратылган, алар ялкын эченнән күтәрелеп чыгалар дип яза. Җеннәрнең гәүдәсе һавадан яки уттан гыйбарәт булып, үзләре теләсә нинди кыяфәткә керергә сәләтле. Алар чүлләрдә һәм урман-тауларда яшиләр, гадәттә кешегә дошманлык кылалар. Җеннәрнең төрләре: 1.*Гул* (курыкканда күзгә күренә, гадәттә хатын-кыз җенесеннән була; ирләр җенесеннән булганын *Кутруб* дип (кайчак *Силату* дип) атыйлар. Теләсә нинди кыяфәткә керә алалар. Гулләр чүлдә, буш һәм калдау җирләрдә яшиләр, адәмнәрне алдап китереп, аларны ашыйлар имеш. Кайбер чыганакларда гул башыннан алып кендегенә кадәр кеше кыяфәтендә, ә кендектән түбән ат кыяфәтендә, тояклары исә ишәкнеке төсле дип тасвир ителә (монда грекларның *кентавры* күз алдына килә).. Коръәндә гул термины юк. 2.*Гыйфрит.* 3.*Си'лат.*

Коръәндә "җен" атамасы еш кына христианнар һәм йәһүдиләр мәгънәсендә кулланыла. Мәсәлән, "Комлык" сүрәсенең (46) 29 нчы аятендә: "Һәм без бер төркем җеннәрне сиңа җибәрдек, алар Коръәнне тыңлап тордылар һәм аның янында бер-берсенә тынлык сакларга, шаулашмаска куштылар" дигәндә йәһүди кабиләләрнең юлбашчылары күздә тотыла, чөнки моннан соңгы аятьтән аларның Мусага табынулары аңлашыла.

"Җен" сүрәсе (72) турында да шуны әйтергә мөмкин.

Суфи Мәһдүм-и Әгъзам бер рисаләсендә җеннәр гыйбадәт вакытында төрлесе төрле

халәттә булып, берләренең сәҗдәгә китүе, икенчеләренең рөкүгъдә һ.б. булуы турында яза.

Кайчак ривайәтләрдә шайтаннарны да җеннәргә кертәләр. *Адәми шайтаннар* һәм *җени шайтаннар* бар дип исәпләнелә. Ислам терминологиясен белеп җиткермәү аркасында мондый буталчыклык уку ярдәмлекләренә дә үтеп кергәли. Мәсәлән, Л.А.Харисованың "Игелек һәм иминлек дине" исемле китабында "Иблис (җен, шайтан)", "Шайтан (Иблис, җен)" кебек аңлатмаларны очратабыз.

Коръәннән күренгәнчә, Мөхәммәдне Аллаһы кешеләргә дә, җеннәргә дә Рәсүл итеп җибәрә. Җеннәрнең бер өлеше, Пәйгамбәрнең Коръән укыганын ишеткәч, иман китерә һәм үзләре дә Исламны тарата башлый (72:1–17; 46:29/28–32/31). Башкалары исә Иблискә ияргәннәр һәм, шайтаннар белән бергә аның гаскәрен төзеп, явыз эшләр кыла башлаганнар. Барлык имансызлар кебек үк, алар да җәһәннәм газапларына дучар булачаклар.

Җеннәр кешегә авыру җибәрергә, аңа зыян эшләргә һәм, киресенчә, ярдәм итәргә дә мөмкин. Аллаһы әмере белән Сөләйман патшага бик күп җеннәр хезмәт иткән, алар аңа аксарайлар һәм гыйбадәтханә төзеп биргәннәр, күз ачып йомган арада хозурына *Сәба* патшабикәсе *Бәлкыйснең* тәхетен китереп куйганнар.

Җеннәр дә, шайтаннар кебек үк, каһиннәргә һәм шагыйрьләргә теге дөньядан илһам алырга ярдәм итәләр.

Халык ышануларында югарыда сөйләнгәннәрдән шактый аермалар да бар. Әйтик, җеннең җенесе булмаса да, ул татарның хатыны яки татар хатынының ире булып яши ала. Җеннәр татарга эт, мәче һәм елан кыяфәтендә күренәләр. Җен күргән кеше авырый башлый, төнлә саташа, бирән зәхмәтенә төшә. Әгәр татар ялгыш кына җенгә кагылып китсә, ул җенләнә, аңар җен кереп оялый һәм кеше авыруга сабыша. Җеннәр тимердән һәм артыш агачыннан куркалар имеш. Җен-парийләрнең аягы һәм йөзе кирегә караган була дип ышанганнар һәм кире беткән кешене җен, шайтан дип сүгү урынына *тирес аяк* (кирегә караган аяк), *тирес бит* дигәннәр.

Татар телендә *җен* сүзе кешенең *күңеле* мәгънәсендәрәк йөри. Мәсәлән, *җен ачулары чыкты, җене карыша* дигәндә татар үзенең күңелен (түбәнге аңын, эчке зиһенен, подсознаниене) күздә тота һәм кеше күңеленә оялаган бу "җен"нең хуҗасына бик үк буйсынмаганлыгын да чагылдыра. Кайбер галимнәр, көнбатыш Европа телләре аша рус һәм татар телләренә үтеп кергән *"гений"* сүзе дә тамыры белән гарәпчә "җен" сүзенә барып тоташа дип уйлыйлар (мәс., Т.А.Шумовский).

Инҗилнең татарчага тәрҗемәсендә "җен" сүзе "шайтан" белән мәгънәдәш дип карала. Мәс., татарча Инҗилдәге бит асты искәрмәсендә "Вельзевул – җеннәр башлыгы" диелгән, хәлбуки Вельзевул – шайтани зат, җени зат түгел.

Тагын кара: ***ГЫЙФРИТ***.

***ҖИЛЕМ БАСМА*** *гар.* – Гектограф. Исмәгыйль Рәмиев: "XX йөз башында, 1918 елларга кадәр, татарча рәсмиләштерелгән газита-журналлар белән беррәттән, төрле әдәби түгәрәкләр, берлекләр, мәдрәсә шәкертләре тарафыннан җилембасмада (гектографта) яки кульязма рәвешендә чыгарылган матбугат үрнәкләре дә шактый", – дип яза һәм ике дистәләп шундый басмаларны санап күрсәтә. Җилем басмалар Казанда әле егерменче елларда да киң кулланылган. Мәсәлән, күп кенә беренче терминологик сүзлекчәләр шул ысул белән басылганнар.

***ҖИР КИСҮЧЕ*** – Землемер, җир үлчәүче. Бик халыкчан "җир кисүче" сүзе "Татарча – урысча сүзлек"кә (1931) теркәлгән.

***ҖӨМЛӘ*** *г.* – **1**.Грамматикада тәмамланган уйны белдерүче гыйбарә – җөмлә. **2**.Бөтен, барлык, һәммә. // *Алтмыш йөштә карилыгы каршы килүр, Коты китеб, җөмлә тәне зәгыйфь үлүр.* Җамалетдин әс-Сабави. *Тавис оҗмах кошы, Җөмлә кошларның башы, Биш вакыт намаз укыган Пигамбәрләр эчендә. (Мәүла Колый.)* **3**.Иш, рәт, исәп. // *Шул җөмләдән* – шул исәптән.

***ЗӘЙТҮН АГАЧЫ*** – Гарәп телендә *зәйтүн* сүзе майлы агач мәгънәсенә ия. Р.Әхмәтьянов бу атама төптә Кытай порты *Цзяоцунь* исеменнән килеп чыккан дип яза (зәйтүнне башта шуннан кайтарганнар).

Зәйтүн агачы Коръәндә "Нур" сүрәсенең 35 нче аятендә телгә алына: "Аллаһ җирне вә күкләрне кояш вә ай белән яктыртучыдыр. Аллаһ нурының мөэмин күңелендә мисалы, эчендә шәм янып торган өйнең тәрәзәсе кебидер, ул шәм пыяла эчендәдер, лампа биш зур йолдызның берсе кебидер. Ул лампа уты яндырылыр зәйтүн агачының мае белән, ул агач көн чыгышында да түгел, көн батышында да түгел — урталыктадыр." Монда тәфсирчеләр зәйтүн мае яктысының Ислам нуры белән чагыштырылуын һәм Исламның көнчыгышка да, көнбатышка да бердәй таралачагы турында хәбәр күрәләр.

*Зәйтүн / Зәйтүнә* сүзе исем булып та йөри. Борынгылыкта гарәпләр кара тәнле колларга еш кына шундый исем биргәннәр. "Бүзьегет" дастанында да чит ил егете Зәйтүн исемле.

***ЗӘМҺӘРИР*** *г.* — "Алынмалар сүзлеге"ндә "Көчле суык, әче суык, каты салкын" дип аңлатылган. Җәһәннәм турындагы бер риваятьтә җәһәннәмнең төрле бүлекләре арасында *әз-Зәмһәрир* бүлеге дә булып, анда коточкыч салкын хөкем сөрүе турында әйтелә. Ибн Фадлан Идел буена сәяхәтнамәсендә Хәрәземгә килеп җитеп, кар буранына юлыккач: "безнең каршыбызда Зәмһәрир капкасы ачылгандыр дип уйладык", — дип яза. *"Сәкарь тәмуты", "Сәкарә — җәһәннәмнең салкыны"* дигән сүзләр дә билгеле. Һәм тикшерә башласаң, чыннан да бу сүзләрдә мәгънә барлыгын күрәсең. Фуратиның "Кырык сөаль" дигән китабында җәһәннәмнең коточкыч салкын бүлегендә барлык мәхлуклар катып үләрләр иде диелә. Памир тауларында 3 мең метр биеклектә кырыс шартларда яшәгән исмәгыйлийә мәзһәбе тарафдарлары исә "тәмуг — бик салкын ил, анда беркайчан да җылы булмый..." дип күз алдына китергәннәр.

***ЗӘҢГӘР ҺӘМ КҮК ТӨС*** — Мөселманнар арасында зәңгәр һәм күк төсләр кайгы (траур) билгесе булып саналган. Госман дәүләтендә, мәсәлән, җәзалап үтерү турындагы фәрманны зәңгәр кәгазьгә яза торган булганнар.

***ЗӘҢГӘРТ*** *тар.* — Таш ыргыту өчен баудан элмәкләп ясалган җайланма, *сапан* (русча — *праща*).

***ЗЕНИТ*** — Күк гөмбәзендә баш түбәсендәге нокта, иң югары нокта. "Зенит" сүзе урта гасырларда Европа телләрендә күчереп язучыларның гарәпчә *"самт (әр-ра'с)"* — баш очы, юнәлеше терминын ялгыш язулары аркасында туган. Зенитның капма-каршысы — *надир.*

***ЗИЛЗИЛӘ, ЗӘЛЗӘЛӘ*** *г.* — Җир тетрәү, җир селкенү. Коръән-Кәримдәге 99 нчы сүрә *"Зүлләзиләт"* ("Зилзилә") сүрәсе дип атала. Бу сүрәдә кыямәт көнендә "җир селкенеп, үзенең өстендә эшләнгән эшләрдән хәбәр бирәчәге" турында әйтелә.

Гомумән, гарәбләр җир тетрәүне яхшы белгәннәр һәм бу афәтне ахырзаман белән чагыштырганнар. Җир селкенеп тә, зыян-зарар килми калган гаҗәеп очраклар тарих сәхифәләренә теркәлгән. Мәс., IX гасыр галиме Мөхәммәд ибн Муса әл-Хәрәзми миляди 749 елда Фәләстыйндагы бер шәһәрнең үз урыныннан кубып барлык өй-каралтылары белән дүрт мильгә күчереп куелуы һәм бу вакытта йортлардан балчык кисәге дә купмавы, бер генә кешенең, бер генә хайванның, хәтта әтәчнең дә үлмәве турында яза.

Сейсмологлар фикеренә караганда, Россиянең 27% мәйданы сейсмик яктан тотрыксыз, ягъни анда вакыт-вакыт җир тетрәү күренешләре сиздерә. Тулаем алганда, 25 — 30 млн. кеше шундый җирләрдә яши. Бу территорияләргә Камчатка, Сахалин яки Үзәк Азиядәге таулы төбәкләр генә түгел, Европа өлешендәге өлкәләр дә керә.

Аерым очракларда җир селкенүләрнең сәбәбе кешенең үзенә, аның сәнагый эшчәнлегенә (җир асты байлыклары казып чыгару, нефть суырту, гаять зур гидробуалар төзү һ.б.) бәйле була. Безнең Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәкләрендә (мәс., Әлмәт шәһәрендә) җирнең вакыт-вакыт тетрәп куюы сизелә, кайчагында люстралар гына селкенә, савыт-сабалар кузгалып куя. Моның сәбәбе җир астыннан нефть һәм газ чыгаруда, чөнки табигать "бушлыкны сөйми" һәм, җир асты катлаулары хәрәкәткә килеп, басымның тигезрәк бүленеп урнашуына омтылалар. Зур ясалма сулыклар да, җир кабыгына миллионнарча тонна авырлык белән басып, катламнарның бөгелүенә китерәләр һәм сейсмик яктан тотрыксыз җирдә убылулар булырга, җир тетрәргә мөмкин.

1967-87 еллар арасында Татарстанда 1 — 1,5 баллы 67 җир тетрәү, 1987 — 94 еллар

арасында 1,5 – 5 баллы 138 тетрәү теркәлгән *(җир тетрәүләрнең көче 1 дән алып 12 баллга кадәр булырга мөмкин).*

Моннан 10-15 еллар элек Татарстан җирләрендә сейсмик яктан хәвефле җирдә атом электр станциясе төзү эшенә керешкәннәр иде. Халык күтәрелеше хакимиятләрне чигенергә мәҗбүр итте һәм хәзер анда Алабуга җиңел автомобильләр заводы төзелә. Аэрофоторәсемнәр Казан янында Идел аша салынган күпер тирәсендә дә геологик сынык барлыгын күрсәттеләр, ягъни ул урын да сейсмик яктан тыныч ук түгел.

***ЗИНА*** *г.* – Уйнаш, сифах; фахишлек. Ир кешенең *(зани)* хатын кеше *(зания)* белән шәригатьтән тыш җенси мөнәсәбәткә керүе.

Зина турындагы мәсьәлә Коръәндә ачык хәл ителгән: ир кешенең үзенә хәрам тиешле хатын белән элемтәсе башкаларга мәгълүм булган очрак *зина кылу* дип исәпләнә. Никахтагыларның һәм никахта тормаучыларның зинасы аерып карала: беренче очракта гөнаһлылар рәҗем кылыналар, ягъни билдән күмелгән килеш өсләренә таш атып җәзаланалар, икенче очракта исә 100 тапкыр суктыру җәзасы һәм, төрле шартларга карап – илдән куу, штраф салу, тәүбәгә китерү һ.б. төрле җәзалар кулланылган. *(Шулай да Коръәннең "Нур" сүрәсендәге икенче аятьтә йәһүдиләр кануныңдагы кебек таш атып үтерү түгел, бәлки суктыру турында сүз бара.)* Беренче очракта ирләр һәм хатыннар, иреклеяки кол булуларына карамастан, бертигез җәза алалар. Икенче очракта исә бер мәзһәбләрдә коллар да 100 тапкыр суктырыла, ә башка мәзһәбләрдә 50 тапкыр суктыру белән чикләнәләр. Ирекле хатын бер мәзһәб кануннары буенча – 100 тапкыр, ә кол хатын 50 тапкыр суктырылса, икенче мәзһәбләрдә ирекле хатынга 50 тапкыр, ә кол хатынга 25 тапкыр *(ирекле хатынга бирелгәннән икеләтә кимрәк)* сугу каралган. Суктыруның максаты гаепле кешене газаплау түгел, бәлки аңарда оят тойгысы уяту булган. Пәйгамбәр үзе исән чагында һәм аның вафатыннан соң да беркадәр вакытлар гаеплене камчы белән суктыру булмаган, аңа таяк белән, кул белән яки аяк киеме белән сугу каралган. Гаеплене анадан тума чишендермәгәннәр, өске киемнәрен генә салдырганнар.

Зина кылганлыкны исбат итү тулысынча гаепләүчеләр өстенә төшә, алар тулы хокуклы дүрт шаһитне китерергә, ә шаһитләр зина кылынганлыкны үз күзләребез белән күрдек дип казый каршында ант итәргә тиешләр. Кеше зина кылуда үзен-үзе дә гаепли ала, моның өчен ул казый каршысында дүрт тапкыр ант итәргә тиеш һәм шул чагында аңа тиешле җәзасы бирелә. Гафу итәргә яки җәзаны йомшартырга ярамый, ләкин әгәр дә зина кылуда гаепле кешеләр казый алдында бер-берсе белән никахлашырга сүз бирсәләр, алар һәртөрле җәзадан котылалар. Башка диндәге хатынга өйләнгән мөселман кешесе зина кылса, бер мәзһәб кануннары буенча, никахтагы кеше кебек, таш ату җәзасына хөкем ителә, башка мәзһәбләрдә исә, өйләнмәгән кеше кебек, суктырылырга тиеш. Бер мәзһәбләрдә кайчан да булса зина кылганнары өчен җәза алган кешеләр киләчәктә үзләре кебекләр белән генә никахка керә алсалар, икенче мәзһәбләрдә җәза һәм тәүбә аларны пакьли. Зина кылуда гаепле җефетен ире, казый хөкеменә тартмыйча да, үлгәнче ябылуда тота алган.

Зина кылган бер яһүдне Мөхәммәд Пәйгамбәрнең Тәүрат нигезендә җәза кылганлыгы турында ривайәт бар. Чөнки Ислам шәригате элекке шәригатьләренең бөтенесен дә юкка чыгармый, фәкать алардагы үзенә каршы килгән хөкемнәрне генә гамәлдән чыгара. Коръәнкәрим Тәүрат, Инҗил китапларын кире какмый, бәлки аларны тасдыйклый.


// *Зинага якынлашмагыз, чөнки ул җирәнгеч эштер.* "Исра" сүрәсе, 32 нче аять.

***ЗИНАӘЛГАЕН*** *г.* – Күз зинасы. // *Вә зинаәльгайни әнназарын* – күз зинасы – караудыр. *(Хәдис.)*

# БӘНДӘЛӘР ХАТАСЫ— БӘНДӘГӘ САБАК

—Акыллы кеше беркайчан да революция ясамый. Бу эшкә, әгәр аны эш дип әйтергә яраса, йә наданнар алына, йә хөсет күнелле, явыз ниятле бәндәләр кулы белән ясала түнтәрелеш... Акыллары томаланган бәндәләр саташа ул революция дигән нәмәрсә белән.

Язучы Факил Сафин үзенең "Саташып аткан таң" исемле роман-трилогиясендә әлеге фикерне Мифтах хәлфәдән әйттерә. Иске тормышны җимереп, янасын төзүнең барышы хакында губком вәкиле белән бәхәскә кереп әйтә аларны хәлфә. Каршы якның мәнсезлегенә бик ачуы килгәндер, күрәсен, ул чор хәлфәләренә бик үк хас булмаганча, ипсезрәк итеп әйтә. Әлбәттә, Мифтахның шулай дип ышанып сөйләнүенә әдип Факил Сафинның һәм күпләребезнең иҗтимагый түнтәрелешләргә карата бүгенге мөнәсәбәте һәм өлкәннәрнең ачы тәҗрибәсе дә салынган, хәзерге пырдымсыз тел бизәкләре дә кергән. Югыйсә, заманында революцияләрнең халыкка ирек һәм бәхет китерәчәгенә чынлап өметләнүчеләр дә аз булмагандыр үзе...




Тарих тәҗрибәсе түнтәрелешләр уңаеннан бүтән карашларны да китереп җиткерде безгә. "Революцияне даһилар уйлап чыгара, фанатиклар гамәлгә ашыра, ә җимешен эт кешеләр файдалана" дигән Герман империясенең 1871—1890 еллардагы беренче рейхканцлеры Бисмарк. Чынлап та, бәла, бәлки, революцияләрдә түгел, аның үзләре өчен хәләл булмаган җимешләрен тиз-тиз әләктереп калучы әнә шул "эт кешеләр"дәдер, ә? "Саташып аткан таң" *(Татарстан китап нәшрияты, 2003 ел)* китабының эчтәлеген бер җөмлә белән "узган гасырның беренче яртысында татар милләтенең каймагы юк ителү вакыйгалары хакында" дияргә була. Әйе, иманеч 1552 елдан соң икенче тапкырдыр, мөгаен, өч дистә ел чамасы вакыт аралыгында татар халкының умыртка баганасына рәхимсез сугыла, рухы имгәтелә. Факил Сафин әсәрендә бу фаҗигале чорның өчтән ике өлеше генә күрсәтелә, анда сурәтләнгән вакыйгалар Бөек Ватан сугышы дигән уртак кырылышка килеп җитми кала. Халкыбызны рухи имгәтерлек явыз гамәлләрне революция тудырган Сталин һәм аның яраннары башкарды. Болай караганда, дөрестән дә, революция татар милләтенә зыяннан башка берни китермәгән булып чыга. Әмма милләтне хөр дәүләтле итү нияте белән утка-суга кергән, "данлы" НКВД зинданнарында коточкыч газаплар кичергән Шамил Усмановлар, Әхмәтсафа Дәүләтъяровлар, үзе үлсә дә, нык рухы шул Бисмарк токымы белән тигезсез сугыштан җиңүче булып чыккан Муса Җәлилләр, китапка исеме генә кергән Мирсәет Солтангалиевлар төркемен дә нәкъ менә революция мәйданга чыгарды бит! Менә "үзгәртеп кору" дигән кире түнтәрелеш, ягъни контрреволюция дә гади халыкка көтелгән ирекне һәм муллыкны, ә татарларга үз дәүләтен төзү мөмкинлеген бирмәде, әмма шул ук вакытта үзгәрешләрдән чумырып файдаланучылар да җитәрлек. Мифтах хәлфәме, әллә Бисмаркмы хаклы булып чыга монда?

Һәм тагын сораулар: революция акылсызлар гамәле генә булгач, нигә аның 1905 елгысыннан соң татар милләте чын-чынлап рухи җанлану чорына килеп кергән, нәкъ шул кыска чорда үзенең Тукайдай тинсез даһиларын тудырып калдырган? Җәдитче Мифтах хәлфә үзе дә шул янарыш баласы ич! Әйе, ул чор кыска булды, артыннан кара реакция елла-

Факил Сафин. Саташып аткан таң. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2003 ел.

ры килде, әмма бу котылгысыз идеме? Октябрь түнтәрелешеннән соңрак килгән коточкыч утызынчы еллар да революциянен котылгысыз нәтиҗәсеме? Шунда ил дилбегәсен Каф тавы артынын "эт кеше"се эләктермәгән булса, хәерлерәк юл белән дә китү ихтималыбыз юк идеме? Аннары, "революцияләр кирәкми" дип нигә Мифтах хәлфәләр һәм аның Әхмәтсафа Дәүләтъяровтай шәкертләре генә сабак алырга тиеш соң? Халыкны әледән-әле шундый гаҗизлек чигенә китереп житкерүчеләр, акыллы дәүләт житәкчесе болай кыланмас дип, ник бер дә уйланмыйлар?

Факил Сафин романын уку барышында жанны бимазалаучы мондый сораулар күнелдә яралып кына тора. Ләкин бу хәл әсәрнен кимчелеге түгел, киресенчә, аның көче, авторның кыюлыгы. Укучыны уйга салырлык, бәхәскә тартырлык фикерләрне курыкмыйча бәян итә ул. Төгәлрәге, әсәр каһарманнары шулай сөйләшә. Тарихи яктан бик еракта калмаган, хәтәр шәүләсе баш өстебездә эленеп торган халык һәм милләт язмышында кискен борылышлар, жуелмас фажигаләр китереп чыгарган үткәнебезне безнең алга болай бар рәхимсезлеге, кан саркып торган яралары белән сурәтләп бирүче юк иде кебек әле. Ибраһим Салаховның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге алган "Колыма хикәяләре" бар-барын, әмма андагы вакыйгалар вакыт ягыннан кыскарак чорны эченә ала, өстәвенә, Ибраһим ага бу әсәрен язганда ижтимагый фикер колачы бүгенге киңлеккә ирешмәгән, әдипләр дә жәмгыятьнен узган гасыр азагындагы яна бер борылыш сабагын кичмәгән иде әле. Әйе, тарих сабагы—куллана белгәннәр өчен зур нәрсә. Әгәр татар халкы, аның милләтне әйдәүче төркеме бу борылышка Факил Сафиннын шушы роман-трилогиясе күләмендә гыйбрәтле белем һәм уй белән кергән булса, шул белемен эштә файдалана да белсә, аннан, мөгаен, куанычлырак нәтиҗә белән чыгар иде. Хәер, моннан унбиш-егерме ел элек андый әсәр туа алыр идеме икән? Бүгенге күп әдипләренен гасыр башы түнтәрелешен тирәнрәк аңлавы һәм төпле бер фикергә килеп сурәтләве өчен шуна охшаш вакыйгаларны гасыр азагында үз башыннан уздыруы зарур булгандыр, мөгаен.

Гасыр башы һәм гасыр азагы вакыйгаларында да, аларның нәтиҗәләрендә дә шактый охшашлык булуга карамастан, ике чорның хәрәкәтләндерүче көчләре бер-берсеннән шактый аерыла икән инде. Ни үкенеч, бүгенге янарыш татар милләтенен Шамил Усмановтай гаярь һәм нык холыклы улларын тудыра алмады. Ә ихтыяж никадәр зур иде! Моның берничә сәбәбе бардыр. Беренчедән, Шамил Усмановлар, Мирсәет Солтангалиевлар үз гаярьлекләре белән дә татарның югалган дәүләтен кайтара алмадылар. Димәк, алар юлы бүгенгеләргә үрнәк түгел, гыйбрәт кенә бирде. Безнең заманда Дудаевның "батыр шашкынлыгыннан" да чечен халкына ирек һәм дәүләт килмәде. Икенче сәбәп—татар халкы үзенең хөр дәүләтле чорыннан, иркеннән, данлы тарихыннан, рухи тамырларыннан тагын бер гасырга ераклашты, тәбәнәкләнде, вакланды, иман-әхлагеннән тайпылды, аңа хәзер Тукай чорының пәһлеваннарын мәйданга чыгару тагын да кыен. Тәрбия дә бүтән. Әйтик, Факил Сафин китабының баш герое Әхмәтсафа Дәүләтъяров татарның мәшһүр Риза Фәхретдиннәрен, Гаяз Исхакыйларын укып, Тукай һәм Рәмиевларын ятлап, алардан рух ныклыгы алып үскән. "Күз тимәсен, Мифтах хәлфә сезгә төпле белем биреп ята түгелме соң?" дип, яшь Әхмәтсафаның белемлелегенә сокланa үзе дә киң карашлы сәүдәгәр, халыкка китап таратучы Гомәр агасы. Петр патша "бөеклегенә" хәйран калып, "Рус дәүләтен киңәйткән" Явыз Иванга һәм аның тугры дәвамчысы Сталинга дан жырлап теле ачылган бүгенге буын кош очар биеклектәге милләт каһарманнарын, Дәүләтъяровлар токымын аңлый да алмый—кая ул аларның башлаган эшләрен дәвам иттерү! Тамырларыбыздан аерырга, тарихыбызны оныттырырга тырышулары бушка китмәгән, димәк. Инде кызыксынуыбыз да сүрелеп бара. Тарихи хәтеребезне уятырга омтылган Факил Сафиндай әдипләр ижатына да шактый битараф без.

Унөч яшеннән әсәргә килеп кергән баш каһарман Әхмәтсафа Дәүләтъяровны Сталин-Ежов жәлладлары 33 яшендә һәлак итәләр. Дәүләтъяровлар буынының саташып аткан таңы әнә шунда бөтенләй сүнә. Нибары ике дистә ел, егерменче гасырның биштән бере! Факил Сафин аны ун ел өйрәнеп язган. Чор вакыйгаларына төшенү ана да жинел бирелмәгәндер. Шәхесләре дә нинди каршылыклылар, әдип каләме өчен жәйсызлар бит. Аңлап кара син аларны! Әйтик менә, мәктәп белеме нигезендә, Шамил Усманов безнең өчен кем иде? Әдип һәм, бигрәк тә, данлы кызыл комиссар. "Татбригада алга бара..." дип горур жырладык без. Гасыр азагында карашлар үзгәрде: "Урта Азиягә урысларны һәм урыс тәртибен татар сугышчылары алып килде" дип, үзбәк кардәшләрненең рәнжүен генә ишеттек. Чынлыкта Шамил Усманов ике генә "төстә" түгел, аны безгә өйрәнергә дә өйрәнергә икән бит әле. Ул

җәһәттән Факил туган үз укучысына төпле зиһен бирә. "Безгә үз дәүләтебез кирәк, гаскәрсез дәүләт юк"—татарлардан милли кызыл армия туплаганда Шамил Усмановны менә нинди изге ният дәртләндерә! Диндәш төрки туганнарга каршы яу чабарга уенда да юк аның. Дөрес, кызыл комиссарның "шашкын батырлыгы" күп меңнәрчә татар егетләренең мәгънәсез алышта кырылуына китерде. Шул чакта эшче көчләрсез, туендыручысыз калган Идел буе татарлары сугыш азагындагы коточкыч ачлыктан да зур югалту белән генә кичте. Ләкин, милли армия төзелмәгән очракта да, татарлар сугыштан читтә кала алмаячак иде шул. Болай да бер өлеше Зәки Вәлидинең "татарлардан торган башкорт гаскәре"ндә, тагын байтагы урыс командалыгында тикмәгә кан коя әнә.

Әйе, милли гаскәр туплап дәүләт яулау нияте, Рәсәй шартларыннан һәм бүгенге вәзгыятьтән караганда, Шамил Усмановның һич чынга ашмас хыялы булып күренә. Ә ул вакытта? Менә хәрби халык комиссары Троцкий Сталинга ни ди:

«Барлык фронтларда да авыр йөк—татарлар җилкәсендә. Аеруча пехота, артиллериядә шулай. Кайсы гына фронтны алма, сан ягыннан карасак, гаскәрләрнең күпчелеге—Идел буе татарлары.»

Татарлар революциягә һәм аны корал белән саклауга нилектән болай ашкынып керешкәннәр соң әле? Кемдер аңлатырга теләгәнчә, элек-электән сугышчы, башкисәр халык булгангамы? Акыл белән уйлаганда, сәбәбе бер генә: татар кайчандыр дәүләтледән дәүләтсез калган, һәм ул үзе өчен унайлы дип санаган һәр очракта аны кире кайтарырга теләп, ирекқә омтыла. Пугачев явына милләттәшләребезнең күпләп кушылуы да шуннан килә. Башкортларның мәшһүр Салаватын да, Зәки Вәлидине дә татарларныкы кебегрәк омтылыш биләгәндер. Хәзерге башкорт җитәкчеләре "Без Рус иленә үз теләгебез белән кушылдык" дип бик канәгать белдерү ясыйлар-ясавын, әмма Салаваттай һәм татар Канзафардай, Бәхтиярдай, әлеге Шамил Усмановтай батыр шәхесләрнең гамәлләре белән, бүгенге карашлар түгел, халык ихтыяры, аның җуелып бетмәгән тарихи хәтере, ирекқә сусавы идарә иткән. Хәтта башкортның үз "игез туган"ын өнәп бетермәве, "ан төбендә" ничектер аны гаепле санавы да тарихи вакыйгалар җирлегендә җиңелрәк аңлашыла: заманында татар мөстәкыйль дәүләтен саклап кала алган булса, аның ышыгындагы башкортларга "Рус дәүләтенә ирекле кушылу" ихтыяҗы тумый иде.

Кызыл гаскәрдә татарларның мөһим урын биләвен Троцкий чынлап таныганмы, юкмы—тарихчылар хөкем итәр. Ләкин аның китапта китерелгән сүзләре Шамил Усмановның гамәлләрен тирәнрәк аңларга булыша. "Революцион" буш хыял белән йөрмәгән, дәүләт яуларлык көчле гаскәр туплауны һәм күп гасырлык изге максатка ирешүне кулдан килерлек дип исәпләгән, "вакыт җитте!" дип фикер йөрткән ул. Миркасыйм Госманов кебек фәһемле тарихчылар да 1917—1918 елларда мөстәкыйль дәүләтебезне торгызу өчен форсат чыккан иде, тик кулдан ычкындырылды, дигән карашта торалар *("Идел" журналы, 1999 ел, 1 сан).* Кызганыч, гасыр азагында без тагын бер җайлы вакытны кулдан җибәрдек. Офыкта яна мөмкинлек шәйләнми дә инде, аңнарыбызны "бердәм Россия" идеясе каплап килә, дәүләтле чорыбыздан отыры ераклашабыз. Бәлки аны искә дә алмый башларбыз.

Шамил Усмановны нинди "хәтәр" хыял җилкеткәнен Сталин да күреп торган. Шуна күрә төзелеп, оешып бетмәгән, өйрәтелмәгән һәм коралланмаган полкларын регуляр ак казаклар армиясенә каршы бастырып тураттырган. Янадан төзелгәннәрен Урта Азиядәге диндәш туганнар белән сугышырга җибәргән. Татарларның көчәюеннән куркулары шулкадәр көчле булмаса, аны таркату өчен, халыкның зур өлешен Курәлтә Башкортстанга бирел, автономияләр нигезенә, туганнар арасына шартлаткыч салмаслар, заманында Казаннан да күренеклерәк мәдәни үзәгебез булган Оренбургтай төбәкләрне Татарстаннан читтә калдырмаслар иде. Хәер, элек татарлар яшәгән, татар атамалары йөрткән авыл-калаларның барысын Татарстанга бирсәләр, илнең үзен дә бүтәнчә исемләргә туры килер иде шул!

Роман-трилогиянең баш каһарманы Әхмәтсафа Оренбург янындагы Каргалы авылында туып-үсә, Оренбургның "Хөсәения" мәдрәсәсеннән үзгәртелгән Көнчыгыш халык мәгарифе институтында белем ала. Сәгыйть Агишевның да шушында укыган, тиктормас һәм боегу белмәс Муса Җәлилнең, җанына тынгы тапмаган Такташның Оренбургта чагы бу. Шәһәрнең балалар йортында—Шәриф Камал, музыка мәктәбендә—Салих Сәйдәшев директор булып эшлиләр. Шамил Усманов монда гаскәр туплый. Йөз еллар элек үк бәхәссез урыс шәһәре *(С. Рыбаков. Ислам и просвещение инородцев в Уфимской губернии. С.-Петербург 1900 г.)* дип исем-ат алган Казаннан үзгә буларак, бу вакытта татар милли мәдәни тормышының күп җепләре Оренбург тирәсендә төенләнә. Хәтта милләт

зыялыларының, әдәбият-сәнгать кешеләренең канына байтак тоз салган "тәнкыйть остасы" Фатыйх Сәгыйтов *(Мөсәгыйть)* та биредә, Әхмәтсафа белән бергә институтта укый. Болар бөтенесе дә Факил Сафинга Әхмәтсафа Дәүләтьяровның канат ярган, акыл утырткан, фикерләр көрәшендә чыныгу алган тирәлегеп тулырак ачарга, шуның белән бергә, кискен иҗтимагый борылыш чорындагы милли тормышны тирәнрәк анлап, нәкъ менә роман кинлегендә сурәтләргә булыша, кинәнеп язарлык мәгълүмат бирә. Сонрак без, китапның баш каһарманы "артыннан", Урта Азия якларына да барып чыгабыз, андагы милләттәшләр һәм төрки туганнар белән хәйран танышабыз. Аннары—Казан хәлләре, милләт язмышында тагын да фаҗигалерәк, шомлы шәүләсе күз алдыбызда әле дә күренгәләп ала торган кара еллар...

Оренбург мәктәбен узу анда тәрбияләнгән Әхмәтсафалар буынын гына түгел, алар белән бергә Факил Сафинны да әдип буларак отыры чыныктыра, күрәсең: роман-трилогиянең "Ялган тәрәзәле йорт" исемле өченче кисәге, арада иң катлаулысы булуга карамастан, тагын да тәҗрибәлерәк каләм белән язылган дигән фикер калдыра. Андагы сюжет төзеклеге, вакыйгалар тыгызлыгы, сурәтләүдә эзлеклелек... Теләсә кайсы әдипнең үзе иҗат иткән әдәби каһарман белән бергә үсүе дә, "кара" геройлар белән артык мавыгып караңгы чырайлыга әверелүе дә табигыйлар, билгеле. Татарстанның югары даирәләрен һәм әдәби-мәдәни мохитен өтеп-көйдереп узган 1937 ел тәмугын сурәтләгәндә Факил туганның иң зур отышы—бу хәлләр өчен андагы корбаннарны гаепләп хаталанмаган, алардан түбән җаннар ясау ясСылыгына төшмәгән ул. Һәм шуңа күрә үзе дә Шамил Усмановларның рухи биеклегендә калган. Ә уйласаң, гаепләрлек сәбәп таба алыр иде. Әнә Фатыйх Сәгыйтов атлы маһир әләкче авторны да, аның каһарманнарын да әсәрнең буеннан-буена эзәрлекли, "дуслар"ын "Черек күл" йотып бетергәндә дә исән-имин кала. Исән калулары исә аларның үтә ныклыгында, ышаучәнлегендә түгел, милли болганыш, үзара низаг тудыру өчен кемнәргәдер һәр заман кирәк булуларында. "Ике эт үзара талашканда бүрегә тыныч" дип уйлыйлардыр. Сер түгел, барлык бәлаләр өчен халыкның үзен, аның хәсетлеген, әләк сөюен гаепләргә һәм шул юл белән татарга каршы көчләрнең ямьсез гамәлләрен йомшартып күрсәтергә омтылучылар да бар. Янәсе, Казан дәүләтен дә Явыз Иванныкыннан көчлерәк Сөембикә-ханбикә гаскәре җимерешкән, утызынчы елларда да үчле татарлар бер-берсен "утырткан". "Татарның иң яраткан эше—әләк язу" дигән фикер бервакыт тар маңгайлы Сталин миендә дә чагылып ала. Әмма бүген генә ясалма күпертелгән караш әсәрдәге житмеш-сиксән ел элекке Сталинга ябышып бетми. Ә менә татар халкы турында "Сәләтлеләрне тарих мәйданына ыргытып кына тора, чүпләп кенә өлгер" дип, чынлап та уйлавы мөмкин аның. Һәм чүплиләр дә. Рәхмәт, нигездә, татарлар кулы белән түгел. Татарларны үзара иң үчлекле халык дип уйласа, алар бер-берсен аяусызрак кыйнарлар дип ышанса, Сталин Татарстан башына шул милләт улларын куяр, гел читтән Лепа, Алемасов кебекләрне җибәреп тормас иде. Казаннан киткән, татарларны ярыйсы белгән Ежов та, милләтебез бәхетенә диикме, Татарстан НКВДсына халык комиссары итеп Рудь, Алемасов, Михайловларны гына җибәрә. Нәкъ шулар 1937 ел азагына кадәр Татарстаннан 500 "халык дошманы"н атарга дип И. Сталин һәм Н. Ежов имзасы белән бирелгән лимитны 2196га үтиләр! Бу коточкыч саннар—Татарстанның репрессия корбаннарына багышланган «Хәтер» китабыннан. "Саташып аткан таң" нурында без аларның азын гына күрәбез әле.

Татарстан Халык комиссарлары советы рәисе булып бер-ике ай гына эшләп калган Әхмәтсафа Дәүләтьяров "Черек күл" зинданында яшьлек дусты Заһидә белән очраша. Оренбургта бу чибәр кызга гашыйк иде ул. Әмма саф күнелле, хыялый Заһидәнең Такташ дип өзгәләнгән, бүтән бер егетне дә күрми йөргән чагы була. Инде менә, хыялдагы якты киләчәк урынына—бер гаепсезгә җәһәннәм газаплары, кешеләрнең бер-берсенә кыла алган иң зур явызлыгы... Әйе, тозакны бер-берсенә дип коралар, тиздән үзләре дә төшү ихтималын беркем уйламый.

—Ходай каргышы төшәр микән аларга, Әхмәтсафа?—дип өзгәләнә Заһидә, чарасызлыктан гаҗиз калып.

Әмма гыйбрәтле китап авторы Факил Сафин безне—каргыш-рәнҗешләргә, үчлеккә, үзара дошман ясашуга чакырмый, киресенчә, андый хаталардан сак булырга, горур кеше булып калырга өнди. "Таң саташмый, кешеләр саташа"—Әхмәтсафаның атисе Мостафа Дәүләтьяров сүзләре болар.

**Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ**

## «Казан утлары» архивыннан



*Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев татар мәгърифәтчесе Мөхәммәдъярның 500 еллыгына багышланган кичәдә чыгыш ясый.*
*1997 ел.*



*Киңәшмә-җыелыштан соң: сулдан уңга—Зәки Нури, Мөхәммәт Садри, Гариф Ахунов, Мөҗәһит Вәлиев, Давыт Көгелтинов.*
*1981 ел.*



*Шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов белән җырчы Гөлзада Сафиуллина.*
*1996 ел.*



*Дус әдипләр очрашуы. Сулдан уңга—А. Гыйләҗев, Ш. Мәхмүдов (Ш. Анак), Х. Туфан, А. Айвазов, М. Кәрим, Г. Ахунов, Х. Госман. 1970 ел.*



*Бүгенге көндә Красноярск шәһәрендә яшәүче якташ-язучыбыз Роман Солнцев (Суфиев Ренат Харисович). 2003 ел.*

*Сибгат Хәким шагыйрь Илгиз Кәлимуллинны 50 яшьлеге белән тәбрикли. 1979 ел.*



# *Хатлардан юллар*

* * *

Хөрмәтле редакция!

Безнең гаилә "Казан утлары" журналын 1970 елның январь аеннан башлап өзлексез алдырып килә. Хәтта ерак Себер якларында яшәгәндә дә яраткан журналыбыздан аерылмадык. Һәр санын көтеп алабыз, беренче битеннән иң соңгы битенә кадәр җентекләп укып барабыз. Бүгенге вәзгыять, телебез һәм әдәбиятыбыз, сәнгатебез хакында тирән эчтәлекле мәкаләләр, дин вә тормыш хакында уйланулар, халкыбызның үтә бай һәм тирән тарихын чагылдырган язмалар, күләмле хезмәтләр бастырган өчен чиксез зур рәхмәт Сезгә!

Без үзебезнең тормышыбызны татар әдәбиятыннан башка күз алдына да китерә алмыйбыз. Монда, Башкортстанда кем нәрсә генә сөйләмәсен *(андыйлар да җитәрлек)*, без татар китабының, язма татар әдәбиятының мең еллык бай тарихы барлыгын яхшы беләбез. Андый тарих белән дөньядагы теләсә кайсы халык горурлана алыр иде. Монысы сүз уңаеннан гына. Әйтәсе килгәнем шул, элегрәк елларда журналда яңа чыккан китапларны "Книга–почтой" кибетләреннән ничек итеп алдырып булуы хакында бәйнә-бәйнә мәгълүмат бирелә иде. Безнең кебек читтә яшәүчеләргә бик уңайлы иде ул. Әллә андый кибетләр беттеме, әллә нәшриятлар чыгарган китапларын башкача юл белән таратып, сатып бетерәләрме, анысы безгә караңгы, әмма без – Башкортстанда яшәүчеләр кайчан нинди татар китаплары чыгу турында бихәбәр булып яшибез. Журналның өченче тышлыгында биреп барылган хәбәрләр генә бик аз бит. Алар диңгездән бер тамчы гына.

Шунлыктан минем Сезгә бер үтенечем бар. Казан шәһәренең – безнең һәм җисмән, һәм рухи башкалабызның *(без аны һәрчак шулай дип саныйбыз)* 1000 еллыгын билгеләп үтәргә әзерләнгәндә, Казан ханлыгы, Казан шәһәренең тарихы турында тулы мәгълүматлы, дөреслекне чагылдырган китаплар басылып чыккандыр яки басарга әзерләнә торгандыр. Шул китапларны табарга ярдәм итсәгез иде. Безнең якларда андый китапларны табып булмый.

**Сәгать ГАЯЗОВ.**
*Башкортстан,*
*Дүртөйле шәһәре.*

**Редакциядән:**

*Хөрмәтле Сәгать әфәнде!*

*Кызганычка каршы, редакциянең теге яки бу китапны әбүнәчеләргә җибәреп бару мөмкинлеге юк. Бу гаять тә җитди һәм матди чыгымнар сорый торган эш белән хәзер китап нәшриятлары турыдан-туры үзләре шөгыльләнә. Сезгә һәм күпсанлы укучыларыбызга Татарстандагы иң зур ике нәшриятның почта һәм интернет адресларын җибәрсәк, алар белән бәйләнешкә кереп, үзегезне кызыксындырган китаплар хакында мәгълүмат ала алырсыз, дип уйлыйбыз.*

***Татарстан китап нәшрияты***
*420111, Казан шәһәре, Бауман урамы, 19.*
***http: // www.tatarstan.ru/books/***
**E-mail: tki@books.kazan.ru**

*Тел. (8432) 92-00-13*

***"Мәгариф" нәшрияты***
*420111, Казан шәһәре, Бауман урамы, 19.*
***http: // magarif.kazan.ru***
**E-mail:** magarif@mail.ru

*Тел./факс (8432) 92-57-48*

P.S. "Казан утлары" алдагы саннардан башлап, Татарстандагы нәшриятлар бастырып чыгарган яңа китаплар турында тулырак мәгълүмат биреп барырга җыена. Табигый ки, ул белешмәлекләрдә нәшриятларның адреслары һәм алар бастырып чыгарган китапларны ничек итеп соратып алдыру хакында да сүз булыр.

* * *

Исәнмесез, кадерле "Казан утлары"!

Менә тагын 2005 ел өчен газета-журналларга язылу кампаниясе башланды. Башкортстанда яшәүчеләргә Татарстанда чыгучы басмаларга язылуда кайбер проблемалар юк түгеллеген Сез беләсездер, дип уйлыйм. Укып барсагыз күрерсез, татар һәм башкорт халыкларының тарихына, бүгенге хәл-халәтенә карата бу ике республикада нәшер ителүче газета-журналларда еш кына капма-каршы фикердәге язмалар да дөнья күрә. Ә безнең—гасыр-гасырлар буе монда көн күрүче татарларның–үз тарихын дөрес итеп, күзгә томан җибәрелмичә язылган мәкаләләрдән, хезмәтләрдән укып барасы, танышасы килү табигый хәлдер. Шуңа күрә, безнең якларга игътибарны көчәйтегез әле. Казаннан язучылар, артистлар, галимнәр ешрак килсен, үзләре белән күбрәк китап, газета-журнал, аудио-видео кассеталар алып килсеннәр иде.

Без Казанның ярдәменә бик мохтаҗбыз.

**Рәнил АРСЛАНОВ.**
*Уфа.*

* * *

Журнал битләрендә "Бүгенге заман герое" дигән темага фикер алышу башлап, бик дөрес эш эшләдегез әле. Ул язмаларны кызыксынып укып барам. Бик акыллы, төпле язылган мәкаләләр бар. Тик кайбер авторлар әдәби әсәр герое белән нindидер каһарманлык кылган батыр шәхесләрне тәңгәл куеп, анык төшенчәләрне бутыйлар кебек тоела. Әгәр әсәрдә кемдер сурәтләнгән, әсәрнең үзегенә куелган икән ул инде барыбер шул әсәрнең герое була түгелме соң?! Уңай героймы, тискәреме, анысы инде башка мәсьәлә. Пәри башка, җен башка, дигәндәй, әмма һәр икесенең әдәбиятта яшәргә хакы бар. Берсе үрнәк алырдай булса, икенчесе – гыйбрәт алыр өчен. Әйтик, Гогольнең мәшһүр "Үле җаннар"ын укып, берәр баланың яисә олы кешенең "Мин шул Чичиков кебек булыйм әле, йә булмаса, Собакевич кебегрәк яшим әле, Ноздрев кебек "дөньясына төкереп бирим әле" дип уйлаганы, аларга охшарга тырышканы булдымы икән?! Юк бит! Димәк, тискәре геройлар да әдәбиятта гаять зур тәрбияви мәгънәгә ия була ала. Әсәре генә яхшы булсын. Димәк, сорау башкача, әйтик, бүгенге әдәбиятта нинди геройлар өстенлек итә дигәнрәк формада куелган булырга тиеш иде кебек.

Дөресен генә әйткәндә, мин үз-үземә еш кына сорау биреп карыйм: бармы соң ул бүгенге заманда чын мәгънәсендә геройлар? Финанс махинацияләре, алдау-йолдау, яисә ачыктан-ачык криминал юл белән байлык туплап, ярты гомерләрен иң мәгълүм курортларда, җәннәткә тиң утрауларда сәхрә чигеп, дөньясына төкереп яшәүче заман байлары геройммы? Юкса, алар үзләрен бу дөньяның тоткалары, геройлары итеп сизсәләр дә… Йә булмаса, барлы-юклы хезмәт хакына, җан асрар өчен генә фермаларда, иген кырларында хезмәт куючы "авыл эшчәннәре" геройммы, фермерлыкка чыккан газиз туганнарыбыз батырмы? Мәсьәләгә кайсы яктан карыйсың бит. Бер карасаң, аларда да билгеле бер дәрәҗәдә батырлык бардыр ул. Менә калса, бу Рәсәй дигән илдә, гомумән "батырлык" кылмыйча гына яшәп тә булмый бугай. Бер хезмәт хакына өч-дүрт бала асраучы ялгыз ана батыр түгелме? Мең ярым тәңкә хакына иртәдән кичкә хәтле "илдәге иң кадерле катлауга – балаларга" белем иңдерергә тырышучы укытучы, яисә шундый ук хезмәт хакы бәрабәренә эренле яраларда казынучы табиблар, шәфкать туташлары герой түгелме?! Чынлап баксаң, Рәсәй әнә шулай иттереп халкын батырлыкка өйрәтәдер дә әле ул.

Күкрәкләре белән дошман амбразурасына капланган егетләргә исә сокланмыйм гына түгел, хәтта чын күңелемнән җәллим мин аларны. Булдыксыз командирларының гөнаһларын үз тормышлары исәбенә каплаган, заманында партиянең "ялкынлы" үгет-нәсихәте, коммунистик пропаганда белән агуланган, хәзергечә әйтсәк, зомбилаштырылган затлар инде алар. Сугышта да чын батырлык үз-үзеңне корбан итүдә түгел, ә дошманны акыл белән, хәйлә белән җиңүдә, аннан өстен чыга алуда. Борынгы татар ханнары нәкъ шулай иткәннәр дә. Мисал өчен, Олуг Мөхәммәт ханның Белев шәһәре янында үз гаскәреннән биш-алты мәртәбә күбрәк санлы урыс чирүен ничек юк итүен генә исә алыгыз. Аның һәр хәрәкәтендә, стратегиясендә үз гаскәрен саклап калу, һәр сугышчыны яудан исән алып чыгу максаты чагыла.

Ә инде әдәбиятта бүген үк, хәзер үк калку образларын күрергә теләгән шәхесләр юк түгел анысы. Шуларның берсе дип мин, һичшиксез, узган гасырның сиксәненче еллары азагында татар милли азатлык хәрәкәтен башлап җибәргән Марат Мөлековны саныйм. Әдипләрнең берәрсенә ник аның тормыш юлы хакында туры канлы роман яисә повесть язмаска?! Аның бөтен кылган гамәле, уй-омтылышлары шул чор өчен батырлык саналырга хаклы. Андый кешеләребез, якты образларын киләчәк буыннар күңеленә сеңдереп калдырырга кирәкле милләтпәрвәр затлар җитәрлек бит?! Аларның кылган гамәлләре минем өчен чын батырлык үрнәге булып тора да инде.

Әйтәсе килгәннәрем менә шулар иде.

**Ф. ИБРАҺИМОВ.**
*Казан.*

*Рахмай Хисмәтуллинның туууына 70 ел*

## Җитмешкә җитәм дигәндә...

Әҗәл аның якасына инде чатырдап ябышканны, көннәре санаулы гына калганны сизә иде бугай Рахмай. Соңгы мәртәбә Чаллыдагы фатирында очрашкач, мин аның картларча салмак хәрәкәтләренә, күзләрендәге сискәндергеч монсулыкка, әледән-әле куллары белән күкрәгенә тотынуына, кабалана-кабалана дару төймәләре кабуына гаҗәпләнгән дә идем. Югыйсә мин аны инде ярты гасыр диярлек искиткеч тормыш сөючән итеп беләм һәм күнелгә, бу кеше шушы гөнаһлы җирне генә таптамыйдыр, кайчакта күктәге болытларга да басып йөридер, аллалар һәм фәрештәләр белән дә сөйләшәдер, пәйгамбәрләр һәм зур акыл ияләре кылган гамәлләргә хөкем дә чыгарадыр шикелле тоела иде. Борчу-мәшәкатьләр, низаг-бәхәсләр, гаделсезлек-фаҗигаләр тулы бу аңлаешсыз дөньяга, күрәсен, оптимистик күзләр белән карау гына житмидер, гомер дә мәңгелек түгелдер, соңгы сүзенне-васыятенне дә әйтеп калырга кирәктер — аны ул мизгелләрдә, мөгаен, шундый ачы хакыйкатьләр билгәндер.



*Сулдан уңга: З. Мансуров, Р. Хисмәтулла, Ш. Маннапов. Апрель, 1983 ел.*

Без ул көнне элеккечә озаклап бәхәсләр куертмадык, егет чактагыча чынга ашмастай хыялларга бирелмәдек. Ул ашыга иде. Кичекмәстән эшләп бетерәсе эше булган кеше шикелле ашыга иде. Минем белән берничә сүз алышкач, гел еларга гына торган оныгын юата да, тиз генә компьютер артында утырган малае Азат янына барып:

—Улым, менә бу җөмләне дә кыстырып җибәрик әле әнә теге абзац ахырына... — дип икенче бүлмәгә кереп китә иде. Аның ул язылып бетәсе китабы туган ягы Актанышның бәрәкәтле туфрагы, сабакташы — Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев — татар шигъриятенең якты йолдызы булган Нур Баян һәм шул төбәкнең йөзләрчә күренекле шәхесләре турында иде. Ишетеп белүемчә, тәмамларга өлгергән икән ул аны. Ә менә күп еллар буе эзләнүләре-казынулары нәтиҗәсен, ниһаять, китап рәвешендә күрергә насыйп булмады аңа. Нишлисең, заманасы шундый. Бәлки... Хәер, анысын инде башка даирәләр хәл итәр.

Рахмай Хисмәтуллинның безнең арадан китеп баруы күпләгән әдәбият сөючеләр өчен, һичшиксез, зур югалту иде. Шәхсән минем үземне ул ниндидер аңлаешсыз гайре табигыйлеге белән тетрәндерде. Шул ук вакытта уйландырып борчуларга да салды. Аның вафаты турында "Ватаным Татарстан" газетасында хәбәр урнаштырган Түбән Кама түрәләре аны "әдәби тәнкыйтьче, Түбән Камада "Жидегән чишмә" әдәби-музыкаль берләшмәсенә нигез салучыларның берсе" дип бер түбәнсетсә, исемен "Рахман" дип атаулары (Рәхмәтулла бит ул, Ходай бәндәләре!) аның рухын икенчеләтә рәнҗетә иде. Ирексездән Тукай сүзләре искә төште:

*Бармыни бездә, гомумән, чын кеше кадерен белү?..*

Юк, мокытлык дәрәҗәсенә төшеп, ул кадәр тыйнакланмыйк — әдәби иҗаты да, кылган гамәлләре дә мактауга лаек иде аның! Барыннан да бигрәк ул ШАГЫЙРЬ иде. Алтмышынчы елларда әдәбият мәйданына аяк баскан күп кенә яшьләр аны

үзләренең кумирлары санадылар — чөнки ул трафарет кысаларга сыймастай хакыйкатьләрне иҗат байрагы иткән, артыннан башкаларны да ияртерлек көчле шәхес иде. Аның "Дөньяга көләп чык", "Яшенле тау", "Ак догалар" китаплары гына түгел, хәтта көндәлек матбугатта басылган аерым-аерым шигырьләре дә, дистә еллар дәвамында сәхнәдән, радио дулкыннарыннан яңгырап торган җырлары да, ялкынлы публицистикасы да тынгысыз каләмдәшнең җан авазы иде. Кемнәрдер өчен ул шигъри остаз да булды.

Аның 20 ел дәвамында "Җидегән чишмә" иҗат берләшмәсен җитәкләве, ана Түбән Кама һәвәскәрләреннән тыш, хәтта әдәбиятыбызның һәм сәнгатебезнең Г. Бәширов, С. Садыйкова, Ф. Кудашева, Н. Нәҗми, Б. Урманче, С. Хәким кебек олпат затларын да тартуы, аны бөтен татар хәятына танытуы үзе үк батырлык иде. Коллективның Муса Җәлил исемендәге республика бүлегенә лаек булуы, әлбәттә инде, беренче чиратта Рахмай Хисмәтуллин эшчәнлегенә, аның тынгысызлыгына бәйләнгән иде. 1984 елда "Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре" дигән мактаулы исем ана шул фидакарьлеге өчен дә бирелде. Ә Язучылар берлеге аны Гаяз Исхакый премиясе белән олылады. Замана борылышларына гаять сизгер иде Рахмайның йөрәге! Һәр мөһим тема өчен генә хас, бердәнбер кулай әдәби жанрны да унышлы сайлый иде ул — әйтәсе фикерләрен бүгенге таләпчән укучыга шигырьдә дә, сәхнә әсәрендә дә, хикәя яки публицистикада да бердәй осталык белән җиткерә белә иде.

Иҗатка тартылуы илленче елларда ук гаять үзенчәлекле шигырьләрдән башланса да, аның "Салават күпере", "Күкрәү авазлары", "Үземне таптым", "Сусау" кебек очерклар китаплары алданрак дөнья күрде—аңа бай тормыш тәҗрибәсен замандашлары белән уртаклашу мөһимрәк иде. Берара ул, байтак кына танышларын да гаҗәпләндереп, Оргсинтез заводы төзелешендә гап-гади бетончы булып та эшләп алды. Ул тасвирлаган каһарманнар, күрәсең, шуңа күрәдер дә нәкъ тормыштагыча тере булып, җанлы булып күз алдына килеп баса. Аның ул очерклары гадәти газета материалы булудан бигрәк оста кул белән язылган чын әдәби әсәрне хәтерләтә иде.

Белүемчә, Рахмай Хисмәтуллинның әдәби мирасы шактый бай. Аны барлауда һәм тәртипкә китерүдә журналист улы Азат кайбер адымнар ясады да инде. Әлбәттә, бу эш күп вакыт һәм зур түземлелек сорый. Ярты гасыр буена төрле-төрле газета-журналларда дөнья күргәннәреннән тыш кульязма хәлендә калганнары да байтак бит әле—алары да әдәби җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итәрлек. Кызганыч, бөтенесен бергә тупларга үзе өлгерә алмады — җитмеше тулырга санаулы гына айлар калгач, мөбарәк тәсбих өзелде.

Башка дус-ишләрендә булган кебек минем шәхси архивымда да аның дистәләгән хатлары, автографлы китаплары, фоторәсемнәре саклана. Кайчан да булса, аларны актарып, тәфсилләп-тәфсилләп язасы булыр әле. Чөнки аларда безнең замандашларның уй-хыяллары, гыйбрәтле язмышлары чагылган. Борынгы елъязмачы кебек күргәнен дә, ишеткәнен дә бәйнә-бәйнә теркәп бара иде ул — кайчан да булса, зур күләмле әдәби әсәр яки мемуар-истәлекләр язганда кирәге чыгар дип алдан хәстәрен күрүе шул булгандыр.

Шәхес буларак гаҗәеп кызыклы иде шул Рахмай. Алдагы көннәрдә дусларының аның турындагы әр-яна истәлекләрен дә укырбыз әле. Әлегә сабыр итик—югалту ачысы бераз басыла төшсен инде.

**Әхмәт РӘШИТ**

*Котлыйбыз!*

## Шамил Рәкыйповка 75 яшь



Шамил Рәкыйпов, язучы буларак, узган гасырның 60 елларында танылды. Ул иҗат иткән художестволы-документаль проза әсәрләренен барысын да үзәк бер тема—Бөек Ватан сугышы темасы берләштерә. Онытылып барган, теге яки бу сәбәпләр аркасында еллар тузаны астында кала язган бик күп шәхесләрне якты дөньяга чыгара алды ул. Дөреслекне табу, хаклыкны ачу юлындагы авыр хезмәткә алынып, Ватан сугышында катнашкан якташларыбызга дөрес, гадел бәя бирергә тырышты.

Шамил Жиһанша улы Рәкыйпов 1929 елның 22 сентябрендә Татарстанның Чүпрәле районы Яңа Чокалы авылында туа. Үсмер чагы сугыш елларына туры килгән, яшьли ятим калган *(әтисе 1941 елда фронтта һәлак була)* Шамил авыл мәктәбенең жиденче сыйныфын тәмамлагач берөзлексез колхозда эшли. 1950 елны, колхозда амбарчы булып эшләгәндә, ачлыктан интегүче авылдашларына ярдәм рәвешендә колхоз амбарыннан ашлык бүлеп биргәне өчен аны жавапка тарталар һәм Себер якларына ун еллык мәҗбүри хезмәт колониясенә жибәрәләр. Ул Красноярск шәһәре тирәсендәге хәрби төзелешләрдә ташчы, жир казучы, балта остасы, сварщик, бетончы һ.б. булып эшли, фәкать 1954 елда, Сталин культы фаш ителгәннән соң гына бу бәладән котыла.

1955 елда Ш. Рәкыйпов Казанга килә һәм ике ел трамвай паркында электрик-моторист булып эшли. Аннары "Татарстан яшьләре" газетасында башта әдәби хезмәткәр, тәржемәче, соңрак газетаның яшьләр тормышы һәм пропаганда-агитация бүлекләре мөдире вазифаларын башкара. 1966-1993 елларда Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты редакциясе мөдире, 1993тән 2000 елга кадәр "Шәһри Казан" газетасында журналист булып эшли.

Ш. Рәкыйповның беренче очерклары, хикәяләре, нәсерләре һәм кече формадагы сәхнә әсәрләре матбугатта илленче елларның урталарында күренә башлый. Анын дистәдән артык бер пәрдәле комедияләре, драма һәм скетчлары—күбесе "Күңелле сәхнә", "Үсү юлы" кебек жыентыкларда басыла.

1967 елда язучының "Чәчәкләр сөйли белә" исемле повесте дөнья күрә. Анда ул Александр Матросов һәм Газинур Гафиятуллинның батырлыгын кабатлаган якташыбыз Барый Шәвәлиев турында бәян кыла. Белорус партизаны Иван Кабушкин турындагы "Кайда син, Жан?", татарлардан беренче Советлар Союзы Герое Гыйльфан Батыршин турындагы "Таннар һаман матурмы?", данлыклы хатын-кыз очучы Мәгубә Сыртланова һәм анын полкташларына багышланган "Кызлар-йолдызлар" һәм "Кипарислар жыры"—әлеге әсәрләр язучының Бөек Ватан сугышы темасын яктыртуда татар әдәбиятына керткән житди өлеше.

Шамил Рәкыйповның бу көннәрдә олуг юбилее. Аны ихластан тәбрик итәбез, тазалык, яна иҗат уңышлары теләп калабыз.





## КЕШЕ ХОКУКЛАРЫ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Кремльдә Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Кеше хокуклары буенча Европа Советы Комиссары Альваро Хиль-Роблес белән очрашты. Россия ягыннан очрашуда РФ Президенты каршындагы Кеше хокуклары комиссиясе рәисе Элла Памфилова катнашты.

Яклар Россия җәмгыятендә гражданлык хокукларына һәм ирекләренә кагылышлы проблемалар буенча фикер алышты. Хәзерге вакытта Комиссар илебездәге кеше хокукларына кагылышлы хәл турында доклад әзерләү белән мәшгуль. "Әлеге докладны ул Европа Советы комитеты министрларына, Европа Советы Парламент ассамблеясе һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенә алдагы ел башында тәкъдим итәчәк. Альваро Хиль-Роблес Россиянен җиде федераль округынын алтысында булырга җыена.

Минтимер Шәймиев, очрашуны ачып, республикабызда һәм гомумән, Россиядә кеше хокуклары буенча алып барыла торган демократик процессларга Европа Советы Комиссарынын объектив бәяләмәсе мөһим әһәмияткә ия булуын билгеләп үтте. Әле 15 ел элек кенә,—диде ул,—"кеше хокуклары" төшенчәсе алга киткән илләрнен "капризы" буларак, формаль сүзтезмә рәвешендә генә кабул ителә иде. Үзгәртеп кору елларында илебез демократия юлында зур адым ясады. Хәзерге вакытта хакимияттә торучылар гражданнарны хокук һәм ирек белән тәэмин итү мөмкинлеген һәм кирәклеген тулысы белән аңлыйлар. Тик җәмгыять тормышындагы әлеге мөһим нәрсәне ничек тә нәтиҗәлерәк итү турында уйларга кирәк. Күп милләтле һәм күп төрле конфессияләрдән торуы үзенчәлек дип саналган, интеллектуаль көчкә һәм икътисади потенциалга ия Татарстан Европа институтлары белән тыгыз хезмәттәшлек иткәндә, әлеге өлкәдә күп нәрсәләргә ирешергә мөмкин",—диде Президент.

Очрашудан сон журналистлар белән әңгәмәсендә М. Шәймиев үзгәртеп кору елларында республикада Европа үсеше дәрәҗәсенә җитү өчен күп нәрсәләр эшләнгәнен һәм эшләнүен билгеләп үтте.

ТР Президентынын әлеге белдерүен Хиль-Роблес әфәнде җәмгыятькә үзенчәлекле "послание" дип бәяләде. Анын ининуынча, демократия өчен көрәш һәм хокукый дәүләт төзү—югары җитәкчеләр җаваплылыгы өлкәсенә генә карамый торган көндәлек эш.

Очрашуда Европа Советы ягыннан—Комиссар Аппараты җитәкчесе Эммануэль Лезертуа, юридик мәсьәләләр буенча Комиссар киңәшчесе Александр Гессель, Татарстан ягыннан—Президент Аппараты җитәкчесе Экзем Гобәйдуллин, Премьер-министр урынбасары Зилә Вәлиева, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова, юстиция министры Мидхәт Корманов, Татарстанда кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Рәшит Вәгыйзов катнашты.

## "БӨЕК ИДЕЛ ЮЛЫ" БУЙЛАП

4 августта Смольныйда (Санкт-Петербург) Бөек Идел юлы халыкара конференция-экспедициясен рәсми ачу тантанасы булды. Аны Санкт-Петербургнын вице-губернаторы Александр Вахмистров ачты. Ул конференциядә катнашучыларга Россиянен төньяк башкаласы дип йөртелгән шәһәрнен губернаторы Валентина Матвиенконың котлавын җиткерде.

"Бу очрашулар, нигездә, Санкт-Петербургның Казан алдында йөкләмәләрен үтәүгә багышлана",—дип белдерде ул. Санкт-Петербург Казанның 1000 еллыгына Татарстан башкаласында Петербург урамын тулысынча төзекләндерергә йөкләмә алган иде. Бәйрәм ашы, кара-каршы дигәндәй, казанлылар Санкт-Петербург юбилеена бу шәһәрдәге Казан урамын тулысынча үзгәртеп корганнар иде бит.

Әле күптән түгел генә Казанның Свердлов урамы Петербург урамы дип үзгәртелде. Аны төзекләндерү Казан шәһәренең юбилеена кадәр тәгалләнәчәк. Александр Вахмистровның әйтүенә караганда, ул Петербург стилендә төзелә. Хәзер аның проекты эшләнә. Ул урамда сәүдә комплексы, торак йортлар Санкт-Петербургтагы кебек булачак. Урамга Петр I нең бюсты куелачак. Шәһәр үзәгендә казанлыларның Ленинград блокадасына ярдәмен чагылдыручы махсус почмак булдырыла. Бүген Казанда блокадада катнашучы 500 дән артык кеше яши әле. Конференциядә Казан шәһәр хакимияте башлыгы Камил Исхаков чыгыш ясады. Ул Бөек Идел юлы халыкара проектының Казан шәһәренең 1000

еллыгына әзерлек унаеннан Россия Федерациясенең дәүләт программасында үзәк урынны алуын белдерде.

Конференциянең беренче өч этабында экспедиция 5 мен миль юл үтте. Анда 25 илнең 200 дән артык күренекле галимнәре катнашты.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова конференциядә катнашучыларга Минтимер Шәймиевнең котлавын житкерде. Конференциядә шулай ук Бөтендөнья Ислам оешмасы каршындагы тарих, мәдәният һәм сәнгать халыкара фәннитикшерү үзәге генераль директоры Әкмәлетдин Ихсаноглый, Барселона шәһәре Метрополисы генераль секретаре Джозепа Ройджа, Россия тышкы эшләр министры урынбасары Юрий Федотов, Кострома өлкәсе губернаторы Виктор Шершунов котлаулары яңгырады. Бөек Идел юлының бу төбәктә урнашкан шәһәрләрне үстерүдәге әһәмияте турында Россия Фәннәр академиясе президиумы әгъзасы, академик Александр Гранберг һәм Россия Федерациясенең баш герольдмейстеры Геннадий Велинбахов сөйләде.

Смольныйда "Казанга—1000 ел" дип исемләнгән күргәзмә ачылды. Бөек Идел юлы экспедиция-конференциясендә катнашучылар Санкт-Петербург татарларының милли-мәдәни мөхтәрияте вәкилләре белән очраштылар.

### КАЗАН БҮЛӘК ӘЗЕРЛИ

Казанның 1000 еллыгына санаулы гына вакыт калып бара. Шуңа күрә әлеге мөһим вакыйгага әзерлек эшләре кызганнан-кыза. Кунаклар алдында оятка калмас өчен һәр нәрсә, биналардан алып сувенирларга кадәр югары дәрәжәдә эшләнергә тиеш.

"Казан" милли мәдәният үзәгендә республика башкаласы юбилеена багышланган басма продукция экспозициясе куелган иде. Анда Казанның төрле нәшриятлары үз продукцияләре белән катнашты. Купләгән стендларда элекке елларга караган басма әдәбият, календарь, шәһәр күренешләре төшерелгән открыткалар урын алган. Проектларның берсе "Мең йөзле Казан" дип атала. Авторлар уенча, әлеге альбомга Казанның фотосурәт осталарының иң яхшы 1000 фотосы керергә тиеш. Казанның үткәне һәм бүгенгесенә кагылышлы фотолар, юбилейга багышланган басма продукция проектлары белән Президент Минтимер Шәймиев, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Премьер-министр урынбасары Зилә Вәлиева һәм шәһәр мэры Камил Исхаковлар танышты.

### "ТАТМЕДИА" ҺӘМ "ТАИФ"ТА ОЧРАШУЛАР

Президент Минтимер Шәймиев Татарстан Республикасының "Татмедиа" гаммәви коммуникацияләр агентлыгында, "ТАИФ" ачык акционерлар җәмгыятенең офис үзәгендә булды.

"Татмедиа" коллективы белән очрашуда республика гаммәви мәгълүмат чаралары журналистларының эш шартлары, редакцияләрне техника белән тәэмин итү, кадрлар әзерләү, район газеталарын финанслау мәсьәләләре һ. б. буенча фикер алышу булды.

Минтимер Шәймиев әңгәмә барышында: "Агентлык—яңа структура, ул элеккеге Матбугат министрлыгына караганда (гаммәви мәгълүмат чаралары вәкилләре аңа фәкать дәүләт органы буларак кына карый иде) гаммәви мәгълүмат чаралары тарафыннан яхшырак кабул ителә һәм җәмгыятьнең бүгенге торышына күбрәк туры килә",—дип билгеләп узды. "Агентлыкның перспективалары зур, гаммәви мәгълүмат чаралары "Татмедиа" белән хезмәттәшлек итәргә әзер, һәм алар инде уңышлы тәстә хезмәттәшлек итә дә. Бу процесста барлык яклар да республика мәнфәгатьләреннән чыгып эш итәргә тиеш",—диде ул. Премьер-министр урынбасары Зилә Вәлиева да Президентның бу фикерен хуплады.

Минтимер Шәймиев шулай ук "Мобиль телесистемалар" ачык акционерлар җәмгыятендә дә булды. Республикада "МТС" кәрәзле элемтә абонентлары бүген Россиянең күпчелек территориясендә, шулай ук Европа, Азия, Америка илләрендә автомат роумингтан файдалана ала. "МТС" челтәре исә Татарстан территориясенең 98 процентган артыграгына хезмәт күрсәтә.

М. Шәймиев берләшмә җитәкчелеге белән әңгәмәсендә төзүчеләрнең планнары, төзелеп килүче биналарның архитектурасы белән кызыксынды, шулай ук төзелеш материаллары сыйфаты турында да сүз барды.

Әлеге чарада "Татмедиа" гаммәви коммуникацияләр агентлыгы генераль директоры Марат Моратов, "ТАИФ" ачык акционерлар җәмгыяте генераль директоры Альберт Шиһабетдинов һ. б. катнашты.

### ЯҢА МИНИСТР

Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиевнең 2004 елның 2 августында чыгарган Указы нигезендә, Татарстан мәгариф министры итеп Р. Ф. Шәйхелисламов билгеләнде.

Шәйхелисламов Рәис Фалих улы 1951 елның 24 октябрендә Татарстан АССРның Мөслим районы Мөслим авылында туган. Алабуга дәүләт педагогика институтын, Казан дәүләт университетын тәмамлап, математика һәм физика укытучысы, икътисадчы-менеджер белгечлекләре алган. Профессор, икътисад фәннәре докторы, педагогика фәннәре кандидаты.

Хезмәт эшчәнлеген Алабуга педагогика институтын тәмамлагач, Яр Чаллы шәһәрендә урта мәктәп укытучысы булып башлый. Армиядә хезмәт итеп кайтканнан соң 1976 елдан 1986 елга кадәр Татарстан АССРның Тукай районы Шилнәбаш сигезьеллык мәктәбе, Бәтке урта мәктәбе директоры булып эшли. Казан дәүләт педагогика институтында аспи-

рантура тәмамлагач, 1988 елдан 1992 елга кадәр Яр Чаллы дәүләт педагогика институтында укыта. 1992—1997 елларда Яр Чаллы шәһәре администрациясе мәгариф идарәсе башлыгы. 1997 елдан—Казан дәүләт университетының Яр Чаллы филиалы директоры. Өйләнгән, өч улы бар.

## МОСТАЙ КӘРИМ КАЗАН КУНАГЫ

Чорыбызның каһарман әдибе—шагыйрь, прозаик, драматург, публицист, җәмәгать эшлеклесе, Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәрим Казанда булып китте. Казанга, Татарстанның халык шагыйре Ренат Харисның шәхси кунагы сыйфатында килсә дә, Мостай Кәримнең Татарстанда булуы республика җәмәгатьчелегенең дә игътибар үзәгендә булды. Мостай Кәримне Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев кабул итте. Очрашуда, шулай ук, Премьер-министр урынбасары З. Вәлиева, Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин, шагыйрь Р. Харис һ. б. катнашты.

## "СӘЛӘТ"ЛӘР—БЕЗНЕҢ КИЛӘЧӘК

Татарстан Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Фәннәр академиясе, Алексеевск районы хакимияте, "Сәләт" иҗтимагый фонды Биләрдә яшьләрнең республика иҗат фестивален уздырды. Биредә "Сәләт" җәйләвенең 8 профильле аланы бар. Үткән 10 ел эчендә аланнарда һәм фәнни мәктәптә 5 меңнән артык бала ял иткән, гыйлем эстәгән.

"Сәләт" проектлары җитәкчесе, профессор Жәүдәт Сөләйманов һәркемне фестиваль ачылу белән котлады. Тантанада Алексеевск районы хакимияте башлыгы урынбасары Н. Чурин катнашты. Фестивальнең кунаклары—күренекле археолог Фаяз Хуҗин һәм галим Әнвәр Хәйри балаларга: "Өмет сездә—татар рухын саклагыз",—дигән теләкләрен ирештерде.

Икенче көнне "Сәләт" аланы фестиваль кунакларын каршы алды. Алар арасында ТР яшьләр эшләре һәм спорт министры урынбасары Й. Якубов, Татарстан Фәннәр академиясе президенты урынбасары профессор Д. Хәйруллов, Алексеевск районы хакимияте башлыгы В. Козанков, "Таиф-телком" акционерлар җәмгыяте генераль директоры Р. Закиров һ. б. бар иде. Й. Якубов: "Монда балаларның иң сәләтлеләре җыелган. Алар киләчәгебезнең ныклы нигезе булырга тиеш",—диде. Аланда балаларның иҗат күргәзмәсе дә эшләде.

Фәнни-гамәли конференциядә 7 сәлкешнең проект-докладлы тыңланды. Аларда табигатьне саклау, "Сәләт"нең символы булган сигез таҗлы йолдызга канатлар өстәү кебек тәкъдимнәр әйтелде. Конференциядә яшьләр академ-шәһәрчеге проектын тормышка ашыру юллары турында да сүз барды.

700гә якын яшь кешене үзенә җыйган "Сәләт" җәйләве дүртенче көнне иртән Чаллының "Нур" үзәгеннән килгән "Мизгел" төркемен каршы алды. "Сәләт"ләр белән очрашуга Татарстанның яшьләр эшләре һәм спорт министры М. Бариев та килде.

"Сәләт" аланнарының эш стиленә һәм эчтәлегенә әллә ни үзгәрешләр кертергә хаҗәт юк. Әмма дәүләт ягыннан ярдәм җитеп бетми әле. Без киләчәктә ана игътибарны арттырачакбыз,—диде ул.

## ҖЫРЧЫ ИСЕМЕНДӘГЕ ФЕСТИВАЛЬ

Июль аенда Түбән Новгород өлкәсендә Рәшит Ваһапов исемендәге татар җыры фестивале дәвам итте.

Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты, Түбән Новгород татарларының Казандагы "Якташлар" җәмгыяте, "Казан" милли мәдәният үзәге һәм "Татарстан" журналы редакциясе тарафыннан оештырылган фестиваль апрель аенда Казанда башланып киткән иде. Бу юлы эстафетаны бөек җырчының туган төбәге—Түбән Новгород өлкәсе үзенә кабул итте. Кызыл Октябрь районында шушы фестиваль чарасы зур уныш белән үткәрелде. Бәйрәмдә Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров җитәкчелегендәге Татарстан делегациясе катнашты. 33 кешедән торган бу делегация составында Зилә Сөнгатуллина, Илдар Юзеев, Равил Шәрәфиев, Зөһрә Сәхабиева, Рафаэль Сәхабиев, Мөнир Якупов, Шамил Әхмәтҗанов кебек күренекле шәхесләр бар иде. Кызыл Октябрь районы хакимияте башлыгы Таһир Хәйретдинов әйткәнчә, Татарстаннан мондый зур делегация Нижгар татарлары тарихында әле булмаган.

Бу җыр бәйрәмендә Рәшит Ваһапов репертуарыннан җырлар башкарылды, мәшһүр җырчы турында шигырьләр укылды һәм истәлекләр яңартылды. Фестиваль кысаларында Рифат Фәттахованың "Рәшит Ваһапов. Заман. Иҗат. Шәхес" дигән китабы тәкъдир ителде.

Фестивальдә катнашучыларга һәм аның кунакларына Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев һәм Түбән Новгород өлкәсе губернаторы Геннадий Ходырев үзләренең котлавын юллады. М. Шәймиев билгеләп үткәнчә, Татарстанның борынгы башкаласында ачылган фестиваль, республика чикләреннән чыгып, читтә урнашкан төбәкләргә үк барып җитте һәм Россия күләмендәге олы мәдәни вакыйгага әверелде. Г. Ходырев үзенең бөек якташының гаять бай иҗади мирасына соклануын белдерде һәм Рәшит Ваһапов истәлеген мәңгеләштерү җәһәтеннән Татарстанда алып барылган зур эш өчен Президент М. Шәймиевкә рәхмәт белдерде.

Киләчәктә Финляндиядә, Мәскәүдә, Санкт-Петербургта, Екатеринбургта һәм татарлар күпләп яши торган башка төбәкләрдә Рәшит Ваһапов исемендәге фестиваль чаралары узачак. Фестивальнең гала-концерты исә декабрь аенда Казанда булачак.

## БӘЙРӘМ ҺӘЙКӘЛЕНӘ КОНКУРС

Казанның 1000 еллыгына багышланган иң яхшы һәйкәл проектына конкурс октябрьнең уртасына кадәр озайтылды. Шунысын исе-

гезгә төшерәбез: әлеге конкурста профессиональ архитекторлар гына катнаша ала. Конкурсның икенче шарты мондый: шәһәр юбилеена багышланган һәйкәл Казанның тарихи үзәгенә урнаштырылырга, шуңа күрә, белгечләр әйтүенчә, ул тирә-юньгә "ябышып торырга" тиеш. Конкурста катнашучылардан һәйкәл проектларын Груздев урамындагы 5 нче йортта урнашкан Архитектура һәм шәһәр төзелеше баш идарәсенә җибәрү сорала. Хәбәрләшү өчен телефон: 36-17-91.

### "РУХИЯТ" РУХЛАНДЫРА

"Татнефть" ачык акционерлар җәмгыяте каршындагы "Рухият" рухи янарыш фонды 1997 елда оештырылды. Фонд ярдәме белән алты дистәдән артык китап дөнья күрде. Авторларның күпчелеге—Татарстанның нефть төбәгеннән. Хәзерге көндә "Татар тарихы" дигән затлы китапның беренче томы дөнья күрде. Ул җиде томда булачак. Фонд адресына "китабымны чыгарсагыз иде" дигән үтенеч белән күп хатлар килә. Иң уңышлы дип табылган әсәрләр фонд каршында оештырылган экспертлар төркеме тарафыннан "Рухият" нәшриятенә тәкъдим ителә.

Күптән түгел әлеге эксперт утырышында аның җитәкчелеген, эш тәртибен раслау булды. Экспертлар төркеме нигезләмәсе проектына үзгәреш һәм тәкъдимнәр кертелде. Фонд советы рәисе "Татнефть" акционерлар җәмгыятенең генераль директоры урынбасары Рөстәм Мөхәммәдиев утырышта чыгыш ясап, эксперт төркеменең кирәклеген, аның мөһимлеген искәртте. Аннары фонд рәисе урынбасары, "Татнефть"нең бүлек җитәкчесе Рөстәм Рафиков, күптән түгел генә "Рухият" фондының башкаручы директоры итеп билгеләнгән Флюра Шәйхетдинова фонд эшчәнлегендәге яңалыклар турында сөйләде.

### ӘМИРХАН ЕНИКИНЕ ЯД ИТҮ

Күренекле әдибебез, Татарстанның халык язучысы Әмирхан Еникинең тууына 95 ел тулды. Шушы уңайдан әдипнең туган ягы—Башкортстанның Благовар районында һәм аларның гаиләсе байтак еллар яшәгән Дәүләкән шәһәрендә хәтер һәм искә алу чаралары үтте.

Башкортстанда атаклы әдипнең чираттагы юбилеен үткәрү тәкъдиме белән Башкортстан Татар конгрессы башкарма комитеты һәм БР Язучылар берлеге чыккан иде. Әмирхан ага яшәгән йортка мәрмәр такта кую өчен дә әзерлек алып барылды. Халык язучысының 95 еллыгын билгеләү чараларында катнашу өчен Татарстаннан да вәкилләр килде. Алар арасында Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Галимҗан Гыйльманов, композитор Ренат Еникиев, Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитетының чит төбәкләр белән эшләү бүлеге җитәкчесе Фәрит Уразаев, татар морзалары оешмасыннан Айрат Терегулов, Әмирхан ага Еникинең кызы Флүрә, икетуган сеңлесе Хәтия Еникиевалар бар иде.

Башкортстан ягыннан хәтер чараларында катнашу өчен БР Язучылар берлеге каршындагы татар язучылары берләшмәсе рәисе Рәшит Сабит җитәкчелегендәге вәкиллек тәгаенләнде. БР Мәдәният һәм милли сәясәт министрлыгы хезмәткәрләре дә үз өлешен кертте. Иң зур тырышлыкны, әлбәттә, үзе дә шушында туып-үскән танылган шәхес, Башкортстан татар морзалары оешмасы рәисе Максат Мәмлиев салды.

### "ТАЛАНТЛЫ СИН, КЕШЕ ТУГАНЫМ!"

Татарстан Язучылар берлегендә Ульян өлкәсенең Димитровград (Мәләкәс) шәһәрендә яшәп иҗат итүче Гакыйл Сәгыйров белән очрашу булды. Мәгълүм булганча, 66 яшьлек каләмдәшебез күп дистә еллар буена урын өстендә ятып көн күрә, шул хәлендә әдәби әсәрләр яза, рәсемнәр ясый. Әлегә кадәр ул әнисе тәрбиясендә яшәде. Әмма быел изге күңелле ана вафат булды. Хәзер Гакыйл Сәгыйров туганнары карамагында калды. Туганының улы Ринат (шулай ук талант иясе, көйләр яза) аны җәйнең матур көннәрендә озын сәфәргә алып чыккан. Алар Чистайда булганнар, Казанга килеп җиткәннәр.

Әңгәмә вакытында Г. Сәгыйров үзенең яңа әсәрләре белән таныштырды. Очрашуда катнашкан Фоат Галимуллин, Шаһинур Мостафин, Галимҗан Гыйльманов, Ркаил Зәйдулла шагыйрьнең иҗаты турында фикерләрен әйттеләр, аның әсәрләрен бастырып чыгару мөмкинлекләре турында сөйләштеләр.

### МӘЛӘКӘСТӘ ТАТАР ГИМНАЗИЯСЕ

Ульян өлкәсенең Димитровград шәһәрендә яшәүче татарлар өчен яңа уку елы сөенеч китерәчәк. Быел анда беренче тапкыр татар гимназиясе эшли башлаячак. Элеккеге рус мәктәбе бинасына урнашкан әлеге гимназия бүген 10 сыйныфны кабул итәргә әзерләнә. Укырга теләк белдерүчеләр бик күп булса да, тест нәтиҗәләре буенча һәр сыйныфка 15-18 әр баланы гына кабул иткәннәр.

60-90 нчы елларда бер генә татар сыйныфы да булмаган Димитровград шәһәре өчен бу зур бәйрәм. Директор Мөнирә Джумаева әйтүенчә, әлеге гимназияне ачарга инде 10 ел әзерләнеп йөргәннәр икән. Фәннәрне югары категорияле укытучылар укытачак.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Казан шәһәренең Аракчино бистәсендә күренекле рәссам **Илдар Ханов** җитәкчелегендә төзелгән төрле дини конфессияләрне берләштергән рухи-дәвалау үзәге. *Г. Зәйнуллин фотосурәте.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы-публицист **Марсель Зарипов**.

# ЯҢА КИТАПЛАР



**Татар эпосы. Дастаннар**: Төзүче, кереш сүз һәм искәрмәләр язучы—Флера ӘХМӘТОВА-УРМАНЧЕ.—Казан: "Раннур" нәшр., 2004.—640 бит. Тиражы — 50000 данә.

«Кулыгыздагы китап—татар халык иҗатының җемелдәгән шигърият үрнәкләре, югары әхлак идеяләре белән сугарылган, фаҗигаи күренешләрне дә сабыр сурәтләгән дастаннары. Алар халкыбызның үз авызыннан язып алынган яисә кулъязма вә басмаларында сакланган рәвешендә тәкъдим ителә»,—диелә кереш сүздә.

Дастаннар—Тел, әдәбият һәм тарих институты тарафыннан 1984 елда бер том булып чыккан иде инде. Әмма, төрле сәбәпләр аркасында байтак күренекле дастаннар, шул исәптән "Идегәй" дастаны да ул томга кертелмәгән иде. Бу китапка элек чыккан унҗиде тарихи дастан янына янәдән ун яңа *(басылу ягыннан)* әсәр өстәлде.

Томлыкта дастаннар белән бәйле унбиш җыр-көй ноталарга салынып бирелгән.



Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ. **Күңелем кошы.** Әдәби тәнкыйть мәкаләләре.—Казан: "Мәгариф" нәшр.,—2004.—222 бит. Тиражы—1000 данә.

Танылган әдәби тәнкыйтьче, Татарстан Язучылар берлегенең Җамал Вәлиди исемендәге премиясе лауреаты Мансур Вәли-Барҗылының бу китабында язучыларыбызның иҗатларына бәйле фәлсәфи уйланулары, әдәби тәнкыйть язмалары, әңгәмәләре тупланган. Аерым алганда, Ә. Еники, С. Хәким, А. Гыйләҗев, Р. Фәйзуллин, Г. Рәхим, М. Әгъләмов һ. б.лар иҗаты хакында сүз бара.

Китап әдәбият укытучыларына, педагогия колледжлары һәм югары уку йортлары студентларына кулланма буларак тәкъдим ителә.



Марсель Зарипов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)